Александр Куприн

Повестьлар



Александр Куприн

ПОВЕСТЬЛАР

Рәис Даутов
тәржемәсе

Казан
Татарстан Китап нәшрияты
1988

ББК 84(0)5
К 83

Куприн Александр Иванович
К 83 Повестьлар. Рәис Даутов тәрҗемәсе.— Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. — 496 бит.

Бу җыентыкка XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы рус әдәбиятының күренекле вәкиле А. И. Куприянның (1870—1938) әдәби мирасыннан „Молох“, „Олеся“, „Атышу“ һәм „Гранат кашлы беләзек“ исемле повестьлары урнаштырылды.

К $\frac{4702010200-027}{М\ 132(03)-88}$ 127—88 ББК 84(0)5

© Татарчага тәрҗемә.
Татарстан китап нәшрияты, 1988.



МОЛОХ

I

Завод гудогы, эш көне башлануын белдереп, сузып-сузып кычкыртырга тотынды. Гудокның карлыккан тавышы, каяндыр җир астыннан чыккан тоташ бер гүелдәү кебек, түбәнтен генә җир өсте буйлап тәгәрәде. Яңгырлы август иртәсенең соргылт шәүләсеннән бу тавышка тагын да кырысрак һәм шомлырак бер аһәң, сагыш өстәлгәндәй булды.

Гудок кычкырта башлаганда, инженер Бобров чәй эчеп утыра иде. Соңгы көннәрдә Андрей Ильичны йокысызлык бигрәк тә ныкъ җәфалый башлаган иде. Кичләрен, авырайган башын мендәргә кую белән, ул болай бик тиз йокыга да китә иде китүен; әмма аның бу йокысы бик тынычсыз, борчулы була, тәнен нәрсәдер гел чәнчеп торгандай, ул минут саен сискәнеп-сискәнеп куя һәм таң атар-атмас ук, кыйнап ташлангандай тәмам хәлсезләнеп, кәефе китеп, яңадан уяна иде.

Моңа, һичшиксез, Бобровның рухи һәм физик яктан йончыган, арыган булуы һәм шулай ук элек-электән килгән начар бер гадәте — морфий уколлары белән артык мавыгуы сәбәпче иде. Хәер, соңгы көннәрдә Бобров морфийга каршы көрәшә дә башлаган иде инде.

Хәзер ул менә, вак йотымнар белән әкрен генә чәен чөмерә-чөмерә, тәрәзә янында утыра. Чәй аңа яфрактан кайнатылган сыман, бөтенләй тәме юк кебек тоела. Тәрәзә пыяласы буйлап борыла-сырыла тамчылар тәгәрәшә. Ишегалдындагы күлдәвек суларның өсте җыерчыкланып, шадраланып дерелди. Тәрәзәдән шәрә кәүсәле, куе соргылт яфраклы тәбәнәк өянкеләр белән каймалап алынган кечкенә генә күл күренә. Җил чыкканда күл өстендә кыска, вак дулкыннар йөгерешә, ә өянке яфраклары, көмеш йөгертелгәндәй, чаларып селкенә башлыйлар. Үләннәр, яңгыр астында тәмам сулып һәм хәлсезләнеп, җиргә сыланып яткан. Якындагы авыл йортлары һәм коңгырт төстәге киртләч тасма сыман офык чите буйлап сузылган урман агачлары, кара һәм саргылт ямаулар салынган басулар — болар барысы да, куе томан аша күренгәндәй, чак-чак кына төсмерләнә иде.

Сәгать җиде тулганда, Бобров өстенә башлыклы клеенка плащын киеп өйдән чыкты. Нервлы кешеләргә хас булганча, иртән ул үзен бик начар хис итә иде: хәле булмый, кемдер авыр нәрсә белән басып торгандай, күзләре әрнеп сызлый; авызыннан ят тәм килә. Ләкин соңгы вакытта аны иң борчыганы үз-үзеннән канәгатьсезлек, рухи төшенкелек хисе булды. Тормышка уен-көлкегә карагандай иң гади күзлектән — практик файда күзлегеннән генә караган ипташләре Бобровның бу яшерен газаплары турында белә калсалар, кычкырып көләрләр, һәрхәлдә, аның бу газапларын аңлый алмаслар иде. Бобровның заводтагы үз хезмәтеннән җирәнү хисе көннән-көн үсә, көчәя һәм кот алынуга якын бер хискә әверелә бара иде.

Акылы-фигыле, тормыштагы гадәт һәм зәвыклары буенча аның өчен иң кулае кабинетта утырып эшләү, профессорлык итү яки авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнү булыр иде. Инженерлык хезмәте исә аны канәгатьләндерми һәм, әнисе аяк терәп каршы килмәсә, ул өченче курстан ук инде институтны ташлап киткән булыр иде.

Чынбарлыкның гадәти, ләкин кырыс күренешләре, ихтыяҗлары тупас орынудан Бобровның кызларныкыдай йомшак табигате чиксез газаплана, сыкрана. Бу мәсьәләдә ул үзен тереләй тиресе туналган кешегә тиңли. Бүтәннәр игътибар да итмәгән тормыш ваклыклары кайчакта аның күңелендә озак вакытларга кадәр төзәлмәс бер яра сызып калдыра иде.

Бобров төсе-кыяфәте белән алай күзгә бәрелерлек матур түгел... Уртача буйлы, гәүдәгә дә чандыр гына. Ләкин аңарда нидидер ашкынулы, тынгысыз бер көч сизелеп то-

ра иде. Аның йөзенә карагач, иң элек биек, мәһабәт ак маңгаена игътибар итәсең. Икесе ике зурлыктагы күз бәбәкләре артык эре булганга мыдыр, аның соры күзләре ничектер кара булып күренә иде. Бер-берсенә кушыла язып үскән тигезле-тигезсез куе кашлары исә бу күз карашын, аңа дәрвишләрчә бер кырыслык өстәп, үткенәйтеп җибәрә кебек. Андрей Ильичның иреннәре нечкә, тынычсыз, әмма усал түгел, беркадәр чалышрак: уң як авыз кырые сул ягына караганда аз гына калкыбрак тора; аксыл төстәге сакалы-мыегы яшүсмерләрнекечә бик сирәк һәм кыска төкле. Аслында ямьсез булган бу йөзнең күркәмлеге бары тик елмайганда гына күренә иде. Бобров елмаеп көлгән чакта, аның күз карашы җанланып, күңеллеләнеп китә, бөтен йөзенә ягымлы бер күркәмлек тарала иде.

Ярты чакрым чамасы җир үткәч, Бобров үргә менде. Аның аяк астында, түбәндә, бер илле квадрат чакрым мәйданга җәелеп утырган зур завод күренеше пәйда булды. Корымлы морҗаларын югары чөеп, тоташ кызыл кирпечтән салынган, бөтен җиренә күкерт исе, тимер сөреме сеңеп беткән һәм берөзлексез чыңлап-шаулап торган зур бер шәһәр кебек иде бу завод. Дүрт домна миче, үзләренен коточкыч зур морҗалары белән бөтен нәрсә өстеннән югары күтәрелеп, калкып тора. Домналар янәшәсендә түгәрәк гөмбәзле, тимердән эшләнгән зур сигез башня — һава җылыткыч җайланмалар — кауперлар күккә күтәрелгән. Болар тирәсендә, төрлесе төрле якка сибелеп, ремонт мастерскойлары, рельс прокатлау, чуен кою, юдырту цехлары, паровоз депосы, мартен һәм чуеннан тимер эшләү мичләре һәм башка биналар урнашкан.

Завод, өч зур табигый тау киртләченә урнашкан булып, түбәнгә таба баскычланып-баскычланып төшә иде. Әле анда, әле монда кечкенә паровозлар тыз-быз йөгерә. Алар киртләч баскычларның иң түбәнгесендә күренәләр дә, эче сызгырта-сызгырта, югарыга таба ыргылалар, берникадәр вакытка тоннельләр эчендә югалып торгач, ак парга уралып яңадан атылып чыгалар, дөберди-шатырдый күперләр аша узалар һәм, ниһаять, үзләренә төялгән йөкне — руда белән коксны — домна миче морҗасының нәкъ авызына китереп ташлар өчен, җирдән күтәрелеп очып киткәндәй, таш эстакадалар өстенә чабып менәләр.

Арырак, табигый бу киртләч мәйданчык артында, тагын бер ачык урын бар. Монда озакламый бишенче һәм алтынчы домна мичләре салынырга тиеш. Хәзергә исә бу урындагы мәхшәрне күреп күз камаша. Әйтерсең лә мондагы һәммә нәрсәне коточкыч бер көч җир карынныннан

актарып чыгарган. Төрле зурлыктагы һәм төрле төстәге кирпеч өемнәре, ком пирамидалары, әрдәнәләп-әрдәнәләп өелгән таш плиталар, тимер-томыр һәм бүрәнәләр — болар һәммәсе дә гүя шулай очраклы рәвештә генә өелеп яталар. Шунда ук, тузгытылган кырмыска оясы тирәсендә кайнашкан кырмыскалар кебек, йөзәрләгән олау, меңәрләгән кеше әрле-бирле килә. Шуларның барысы өстендә, һавада, известь тузанының томан сыман ап-ак болыты асылынып тора.

Тагы да арырак, бөтенләй офык сызыгында диярлек, бер төркем эшчеләр озын бер товар поездыннан йөк бушаталар. Вагоннардан җиргә сузып төшерелгән авыш тактталар буенча берөзлексез кирпеч шуа; зыңгылдап-чыңлап тимер-томыр тәгәри; һавада пружина сыман бөгелә-сыгыла юка тактталар оча. Поездга таба бертуктаусыз буш олаулар агыла, ә икенче берләре, түбәләмә төялеп, бер-бер артлы китә торалар.

Ачык, нечкә тавышлар чыгарып ташкискечләр чыкылдавы, казан клепкаларын чүкегән яңгыравык тавышлар, авыр гөрселдәгән пар чүкечләре дөпелдәве, сызгыра-сызгыра ухылдап пар торбаларының сулыш алуы һәм әллә нигә бер, бөтен тирә-якны дер селкетеп, саңгырау тавыш белән ыңгырашкан җир асты шартлаулары — мең төрле бу авазлар, һәммәсе бергә кушылып, калынлы-нечкәле сузынкы бер гүелдәү хасил итә.

Коточкыч һәм шул ук вакытта мавыктыргыч күренеш иде бу. Кеше хезмәте монда, галәмәт зур, катлаулы һәм төгәл механизм сыман, бертуктаусыз гөрләп, кайнап тора. Меңләгән кешеләр — инженерлар, ташчылар, механиклар, балта осталары, слесарьлар, җир казучылар һәм тимерчеләр — дөньяның төрле почмакларыннан бирегә җыелганнар да, тереклек өчен көрәшнең катгый законнарына буйсынып, промышленность прогрессының нибары бер адым алга китүе бәрабәренә үзләренең бөтен көч, сәләтләрен, акыл һәм сәламәтлекләрен корбан итәләр.

Бүген Бобров үзен аеруча начар хис итә иде. Кайчакны, гәрчә бик сирәк булса да, — әйтик, елына өч-дүрт тапкыр, — аны ниндидер сәер, эч пошулы һәм шул ук вакытта ярсулы бер хис биләп ала. Гадәттә бу болытлы көзге иртәләрдә яисә җепшек карлы кышкы кичләрдә була. Андый чакта бөтен нәрсә аның күзенә күңелсез, төссез күренә; кешеләр, томан эчендәге кебек, авыру йөзле яисә ямьсез булып тоелалар; аларның сөйләгән сүзләре дә, кайндыр бик ерактан ишетелгәндәй, күңелдә эч пошудан башка бернинди хис кузгатмыйлар.

Рельс прокатлау цехындагы эшчеләрнең ут-ялкыннан кипшергән һәм күмер тузанына буялып беткән йөзләре бүген аның кәефен бигрәк тә төшерде. Бер яктан шыр ачык ишек аша үзәккә үтәрдәй көзге салкын җил исеп тора, икенче яктан утлы тимер кисәүләреннән бөркелгән кызу тәннәрне пешерә. Мондагы авыр хезмәтне күргәч, Бобров эшчеләр кичергән физик газапларның бер өлешен үзе дә татыгандай булды. Ул үзенең пөхтә, шома кыяфәте өчен дә, өстенә кигән нәфис күлмәге өчен дә һәм үзе ала торган өч мең сум еллык эш хакы өчен дә оялып куйды...

II

Ул эретү миче янында эш барышын күзәтеп тора иде. Дөрләп янган мичнең зур авызы, минут саен ишеләй ачылып, әле генә ялкын эченнән чыккан егермешәр потлы апак корыч «пакетларны» бер-бер артлы йота гына бара. Чирек сәгатьтән бу пакетлар, дистәләгән станоклар аша дөбер-шатыр узып, цехның икенче башында озын, шома, ялтыравык рельслар булып өелә торалар.

Кемдер арттан Бобровның иңбашына орынды. Ул ачулы бер чырай белән артына борылып карады һәм үзе белән бергә эшләүче Свежевскийны күрде.

Шыпырт кынамы, ялагайланыпмы синең яныңа якынаючы кеше сыман гәүдәсен һәрвакыт бераз бөгебрәк атлаган, дымлы, салкын учларын бер-берсенә ышкып, бертуктаусыз хихылдап көләргә яраткан бу кешене Бобровның жене сөйми иде. Аңарда ниндидер усал бер ялагайлану, мәкер бар иде. Ул заводтагы барлык гайбәтләрне белеп тора һәм аларны нәкъ менә шул гайбәтләрне сөймәгән кешегә аеруча бер ләззәт белән сөйләргә ярата; сөйләшкәндә ул үзен бик тынычсыз тота, минут саен әңгәмәдәшенең йә биленә, йә җилкәсенә, йә кулына, йә төймәсенә кагылгалап куя.

Хәзер дә ул, учларында Бобровның сыңар кулын әвәләп һәм үзалдына хихылдап:

— Югалдыгыз сез, Андрей Ильич, бик күптәннән бирле күренгәнегез юк, — дип куйды. — Һаман китап укып утырабызмы? Өйдән чыкмыйча, ә?

— Исәнмесез, — диде Бобров теләр-теләмәс кенә һәм кулын тартып алды. — Соңгы көннәрдә бераз авырып яттым, шул сәбәпле генә.

— Зиненколарда сезне сагынып беттеләр инде, — дип дәвам итте Свежевский, мәгънәле генә елмаеп. — Сезгә дә бер килеп чыгарга иде, ә? Өченче көн анда директор

килгән иде, сезнең хакта сораштырып утырды. Домна эшләре турында ничектер сүз чыкты да, шунда сезне бик зурлап, мактап телгә алды.

— Бик шатмын, рәхмәт, — дигән булды Бобров, мыскыллы бер елмаю белән баш иеп.

— Юк, валлаһи менә... Идарә сезне зур белемле инженерга саный, ди. Әгәр сез үзегез теләсәгез, бик ерак китә алыр идегез, ди. Аныңча, үзебездә дә Андрей Ильич шикелле белемле, сәләтле кешеләр эшләгәндә, завод проектын төзүне французларга бирүнең һич кирәге булмаган, ди. Тик...

«Хәзер берәр күңелсез хәбәр әйтә инде», — дип уйлап алды Бобров.

— Тик шунысы начар, ди, Андрей Ильич җәмгыятьтән читләшә, үз кабыгына бикләнеп яши, ди. Аның кем икәнен дә, янында үзеңне ничек тотарга икәнен дә һич белмәссең, аңламассың, ди. Аһ, карале! — дип, Свежевский кинәт маңгаена шапылдатып алды. — Такылдыйм да такылдыйм, ә үзем иң кирәген әйтергә дә онытканмын... Директор иртәгә сәгать уникедәге поездга бар кешенең вокзалда булуын үтенде.

— Тагын берәрсен каршылыйбызмы?

— Нәкъ өстенә бастыгыз. Беләсезме кемне?..

Свежевскийның йөзенә тантаналы, хәйләкәр бер елмаю җәелде. Ул кулларын угалый һәм, күрәсең, кызыклы яңалык әйтергә җыенудан үзен чиксез бәхетле тоя иде.

— Чынлап, белмим, кемне каршылыйбыздыр... Мин бит алай фараз кылуларга оста түгел, — диде Бобров.

— Юк-юк, алай батмый, егеткәем, әйдә әйтеп бирегез... Ну, һич югы, якынча чамалап, кемнең дә булса исемен әйтегез...

Бобров, бер сүз дә дәшмичә, юри артыграк игътибар иткәндәй, пар кранының эшен күзәтергә тотынды. Свежевский, аның хәйләсен сизеп, элеккегә караганда да тынычсызлана төште.

— Шул шул, һич белә алмассыз... Ярар, алайсам, артык тилмертмим инде. Квашнин килә, ди, Квашнин!

Бу исемне әйткәндә аның тавышында шундый ялагайлану сизелде ки, Бобров хәтта җирәнеп йөзен җыерды.

— Искитәрлек нәрсәсен таптыгыз аның? — дип куйды ул, дорфа гына.

— Ничек инде «нәрсәсен таптыгыз»? Гафу итәсез, егеткәем, ул идарә кешесе, нәрсә тели шуны эшли: аны күрәзәне тыңлагандай тыңлыйлар. Менә хәзер дә: идарә эшне тизләтү өчен аны монда җибәргән, ягъни, икенче төрле

итеп әйткәндә, ул үзе бу эшкә алынган. Ул килгәченнән нинди яшеннәр яшьни башлавын үзегез күрерсез әле. Үткән елны да төзелешне кәрарга дип шулай килгән иде. Ул чакта сез монда түгел идегез бугай әле?.. Менә шул: директор белән дүрт инженерны үз урыннарыннан алып атты. Сезнең өрдерү эше[1] тиз бетәме әле?

— Инде беттс диярга була.

— Бик әйбәт алайса. Квашнин килгәч, димәк, домна миченең бәйрәмен дә уздырырбыз, таш эшләрен дә башлап җибәрербез. Квашнинны берәр вакыт күргәнегез бармы соң?

— Фамилиясен ишеткәнем бар иде барын, күргәнем булмады.

— Ә мин аңдый бәхеткә ирештем. Квашнин кебек кешене, мин сезгә әйтим, бүтән беркайчан да очрата алмаячаксыз. Бөтен Петербургта дан тота. Беренчедән, ул чамасыз юан корсаклы, ике кулын бергә кушыра алмый. Ышанмыйсызмы? Валлаһи, шулай. Ул каретаны да үзе өчен махсус эшләтеп алган. Каретасының уң ягы шарнирларга утыртылган, тоташы белән ачыла. Аның соңында, бик озын буйлы ул, үзе җирән, ә тавышын иерихон трубасыннан гөрелдәп чыга диярсең. Акылны инде әйткән дә юк! Искитмәле!.. Нинди генә акционер ширкәте булмасын, барысында да идарә әгъзасы булып тора... Елына нибары җиде-сигез утырышта катнашуы өчен ике йөз мең сумны кесәсенә сала! Аның каравы, гомуми җыелышларда берәр эшне коткарып калырга кирәк булса, аңа гына куш — һичкайчан сынатмас! Еллык отчетның иң шикле дигәнен дә шундый итеп сөйләп бирә, акционерлар караны да ак итеп кабул итәләр, ә соңыннан идарәгә ничек рәхмәт әйтергә белми аптырап йөриләр. Иң кызыгы шул: әлеге эш белән ул бөтенләй таныш булмый, ә болай бугазы белән, кыюлыгы белән генә алдыра. Менә иртәгә аны тыңлагач күрерсез әле: гомере буе домна мичләре белән генә эш иткәндер бу, дип уйларсыз. Ә дөресен әйткәндә, ул бит домна мичен мин санскрит телен белгән кебек кенә белә...

— Тра-ра-ра-ра-рам! — дип, көйне юри бозып, ялгыштырып җырлап җибәрде Бобров һәм Свежевскийга аркасы белән борылды.

— Аннары тагын... шунысы искитмәле... Петербургтагы өендә кунакларны ничек кабул итә дисез? Җирән башын

---

[1] Домна мичен, эшләтер алдыннан, температурасы руданы эретерлек дәрәҗәгә, ягъни якынча 1600 градуска җиткәнче кыздырып кую... Бу эш кайчакны берничә айга сузыла. *(Автор искәрмәсе.)*

су өстеннән чыгарып, муен тиңентен ваннага кереп утыра икән дә тыңлый бирә икән. Ә кунагы, — әйтик, нинди дә булса тайный советник, — ихтирамлы кыяфәттә кырыкка бөгелеп, аның каршында йомышын сөйли... Аннары коточкыч күп ашый торган кеше ул... Әй ризыкның төмен белеп ашый да инде; яхшы ресторанларда â'la Квашнин дигән котлетларны белмәгән кеше юк. Ә хатын-кыз мәсьәләсендә инде сорап та тормагыз. Моннан өч ел элек аның белән гаҗәеп кызыклы бер хәл булды...

Бобровның тыңлап бетермичә китәргә җыенуын күреп, Свежевский аны кинәт төймәсеннән эләктереп алды һәм ялварулы тавыш белән пышылдарга тотынды:

— Туктагыз инде... бик кызык бит... ике-өч сүз белән генә... Болай була бу хәл. Моннан ике-өч ел элек, көз көне, чиновникмы-ниме шунда — ярлы гына бер егет Петербургка килә... Фамилиясен дә белә идем, хәзер генә хәтердән чыккан. Ниндидер бәхәсле мирас артыннан йөри торган була ул. Һәр иртәне бу, судтан-фәләннән кайтышлый, Летний садка кереп, чирек сәгать чамасы эскәмиядә тегене-моны күзәтеп утырырга ярата икән... Шуннан шул. Өч көн утыра бу, дүрт көн, биш көн утыра... Бервакыт күрә: җирән чәчле, галәмәт юан гәүдәле бер әфәнде дә көн саен килеп сарып йөри, ди. Бераздан болар танышалар. Әлеге җирән әфәнде дигәнебез, ягъни Квашнин, егеттән сорашасораша аның бөтен хәл-әхвәлен белә, кайгысын уртаклашып, аны кызганган була... Әмма ләкин аңа фамилиясен әйтми. Шуннан шул. Бервакыт әйтә бу егеткә: «Сез фәлән-фәлән бер кызыйга өйләнергә риза булыр идегезме? — ди. — Тик бер шарт белән: туйдан соң ук сез кая да булса китеп барырга һәм кәләшегез белән бүтән очрашмаска тиешсез», — ди. Ә егетнең кесәсендә бер тиен акчасы булмаган чагы, хет ачтан үл. «Бәһасе килешенеп, акча алдан бирелсә, мин риза!» — ди бу. Күрәсезме, егет тә белә бит әспе тамырын кайсы очыннан тотып ашарга кирәклеген. Шуннан шул... Килешәләр болар. Бер атнадан соң җирән баш әлеге егеткә фрак кигезә дә, таң атар-атмас бер вакытта аны каядыр шәһәр читенә чиркәүгә алып китә. Халык-мазар юк, бары кәләш кенә, башына челтәр бөркәнчеген каплап, аларны көтеп тора. Яшь кенә, чибәр генә икән үзе. Шуннан никах уку башлана. Тик егет күрә: кызкай нигәдер бик моңсу, күңелсез. Шыпыртлап кына сорый бу тегеңәрдән: «Сез монда үзегез теләп килмәгәнсез, ахры?» — ди. «Сез дә үз иркегез белән түгел бит, әйеме?» — ди кыз. Шулай бер-берсе белән аңлашып та алалар. Кызны кияүгә чыгарга үз әнисе мәҗбүр иткән икән. Турыдан-туры Квәш-

нинга бирергә вәжданы кушмаган, ягъни мәсәлән... Шуннан шул... Тора торгач, егет әйтә тагын кызыйга: «Әйдәгез, бер кызык эшлик әле, ди: икебез дә яшь, таза, безне алда әле, бәлкем, күп бәхетләр көтәдер, нигә Квашнинны төп башына утыртып калдырмаска!» — ди. Кызый да төшеп калганнардан булмый, эшнең кая таба барганын бик тиз чамалап ала. «Ярый, әйдәгез, шулай эшлик», — ди. Никахлашу беткәч, һәммәсе дә чиркәүдән чыга; Квашнин инде шат, инде шат — йөзеннән елмаю китми тегенең. Ә егетебез бу вакыт тиешле акчасын да алып куйган була. Өйтергә кирәк, шактый күп сума була, чөнки Квашнин мондый хәлләрдә акчаны кызгана торганнардан түгел. Шуннан шул. Квашнин яшьләр янына килә дә, хәйләкәр генә көлемсерәп, тегеләрнең котлый, тәбрикли башлый. Тегеләр ихтирам белән тыңлаган булалар, рәхмәтләр әйтәләр, аны туй атасы дип зурлыйлар, аннары кинәт икесе дә коляскага менеп утыралар. «Ниткән эш бу? Кая барасыз?» — «Кая булсын! Вокзалга, туй сәяхәтенә. Кучер, әйдә ку атларны!..» — Менә шулай Василий Терентьевич баскан урынында авызын ачып тора да кала... Ә менә тагын икенче бер тапкыр... Сез нәрсә, Андрей Ильич? Китәсезмени инде? — дип, такылдавыннан туктады Свежевский, Бобровның тәвәккәл кыяфәттә эшләпәсен батырып киеп, пальтосын төймәли башлавын күреп.

— Гафу итегез, вакытым юк, — диде Бобров коры гына. — Ә инде сез сөйләгән анекдотка килгәндә, мин аны кайчандыр ишеткән идемме, укыган идемме шунда... Сау булып торыгыз.

Һәм, кискен сүзләре белән Свежевскийны тәмам аптыраштa калдырып, Бобров кырт борылды да җил-җил атлап мастерскойдан чыгып китте.

III

Заводтан кайтып, аннан-моннан гына тамак ялгап алгач, Бобров болдыр баскычына чыкты. Әле бая ук Фарватерны иярләргә боерык алган кучер Митрофан көчәнә-көчәнә ат сыртына инглиз иярен тарттырып маташа иде. Туры айгыр, киреләнгәндәй, корсагын кабарта һәм әледән-әле озын муенын сузып, тешләре белән Митрофанның күлмәк җиңен эләктереп алырга омтыла. Андый чакта кучер ачулы һәм гайре табигый бер калын тавышы белән: «Но-о! Нәрсә шаярасың!» — дип кычкыргалый һәм, көчәнүдән мышный-мышный: «Кара син аны, нишләгән була бит, хайван!» — дип тә өстәп куя иде.

Фарватер уртача биеклектәге, киң күкрәкле, симез арт саны бераз салыныбрак торган озынча җиңел гәүдәле, нык, таза тояклы, йонлач аяклы, нечкә сылу бәкәлле Дон айгыры иде. Аның калкыбрак торган маңгае һәм бугаз төере бүлтәйгән озын муены кайбер ат осталарына бөтенләй ошамаска да мөмкин. Ләкин барлык Дон атларына хас бу сыйфатларны Бобров үзе Фарватерның күркәм бер матурлыгы итеп саный. Әйтик, такса этенә кәкре аяк, э сеттерга озын колак ничек килешсә, монда да шулай. Аның каравы бөтен заводта Фарватердан да чабышкырак бүтән ат юк иде.

Гәрчә Митрофан, һәрбер булдыклы рус кучерынча, ат белән кырыс мөгамәләдә булуны кирәк санаса да һәм, үзара бернинди назланулларга, хискә бирелүләргә юл куймыйча, атны «каторжан», «үләксә», «башкисәр» һәм хәтта «хамлет» кебек яман сүзләр белән сүксә дә, күңеленнән ул Фарватерны үлеп ярата иде. Аның бу мәхәббәте шунда күренә: Дон айгыры, Бобровның Карлыгач һәм Диңгезче кушаматлы казна атлары белән чагыштырганда, һәрвакыт яхшырак чистартыла, солыны да аларга караганда күбрәк ала.

— Син аны эчерттеңме, Митрофан? — дип сорады Бобров.

Митрофан җавап бирергә ашыкмады. Аның яхшы кучерларга хас тагын бер үзгәлеге — үзен эре тотып, ашыкмыйча сөйләшү гадәте бар иде.

— Эчерттем, Андрей Ильич, ничек инде эчертмәскә! Әй, син, нәрсә боргаланасың, үләт! Мин сиңа боргаланырмын менә! — дип, ачу белән тагы кычкырып куйды ул атка. — Бүген бик тә иярләнеп йөрисе килә аның, барин. Күрәсезме, ничек сабырсызлана.

Бобров Фарватер янына килде. Сул кулына тезгенне алып һәм ялына тотынып, атланырга гына әзерләнгән иде, Фарватер тагын үзенең көндәлек матавыгын башлап җибәрде. Хуҗасы өйдән чыкканнан бирле сыңар күзен шарландырып, ачу белән карап торган ат, Бобров якынлашкач та, башын уңга-сулга боргаларга һәм, арт аяклары астыннан пычрак чәчрәтеп, бер урында биергә тотынды. Бобров исә, өзәнгегә басарга тырышып, сыңар аягында сикеренә иде.

Ниһаять, ул ничек кирәк алай сул аягын өзәнгегә кигезде дә, уңын тиз генә ат сырты аша ыргытып, ияргә атланды.

— Тезгенне җибәр, Митрофан, тизрәк тезгенне җибәр! — дип кычкырды ул кучерга.

Җайдакның шпорлы үкчәсен сизгәч, Фарватер шундук юашланды, баскан урынында тагын бераз тыпырчынып алды да, кинәт пошкырып, башын чайкый-чайкый, ачык капкадан канатлы коштай элдертеп алып чыгып китте...

Җан-фәрманга чабу, колак төбендә сызгырган салкын җил, көзге басуның борынга бәреп торган җиңелчә дымлы исе — болар һәммәсе дә тиздән Бобровны тынычландырып, сүлпән нервларын тергезеп җибәрде. Шуның өстенә, Зиненколарга барырга чыккан саен ул үзендә һәрвакыт ниндидер тынгысыз бер күңел күтәренкелеге тоя иде.

Зиненколар гаиләсе эти кеше белән әни кешедән һәм биш кыздан тора иде. Эти кеше үзе заводта склад мөдире булып эшли. Карап торышка ялкау табигатьле һәм минһербанлы гына күренгән бу әзмәвер асылда гаять тә әрсез һәм мәкерле адәм иде. Теләсә кемгә «чын дөреслекне» күзенә бәреп әйтәм дигән булып, түрәләр алдында тупас, дорфа, ләкин күңелгә хуш килер дәрәҗәдә ялагайланып сөйләшүче, хезмәттәшләре өстеннән ачыктан-ачык әләк йөртүче, ә үз кулы астында эшләүчеләр белән коточкыч әшәке мөгамәлә итүче явыз, хәйләкәр бәндәләрнең берсе иде ул. Юк кына нәрсә өчен дә ул тавышы карлыкканчы кычкырына-кычкырына кызып бәхәсләшә башлый һәм бүтәннәрнең фикерен колагына да элми; тәмле ашарга ярата һәм, көйне бозмыйча җырлый белмәсә дә, күмәк башкарыла торган малорус җырлары белән бик мавыга. Шул ук вакытта ул, үзе дә сизмәстән, бөтен җаны-тәне белән үзенең хатынына — тәбәнәк буйлы һәм кечкенә соры күзләреннең бер-берсенә бик якын урнашуы сәбәпле йөзе әллә ничек сәер, көлкеле тоелган кыланчык, авыру табигатьле Анна Афанасьевнага буйсынып яши иде.

Кызларның иң олысы Мака, аннан калганнары Бета, Шура, Нина һәм Кася исемле иде.

Кызларның һәркайсы гаиләдә үзенә аерым бер урын тота. Балык башыдай очлы йөзле Маканы басынкы, юаш холкы өчен үзара фәрештә дип йөртәләр. Урамга йөрергә чыкканда яисә кичен өйдә җыелып утырганда, ул үзенә ничек тә күләгәлерәк урын сайларга, сеңелләре файдасын күздә тотып, гел алардан читтәрәк булырга тырыша (Макага инде утыз тулып узган иде). «Безнең Мака садәлек үрнәге!» — дип кабатларга ярата иде эти-әнисе аның турында.

Бета арада иң акыллысы булып санала һәм күзлек киеп йөри. Сөйләүләренә караганда, ул кайчандыр хәтта курсларга укырга китү турында да хыялланган, имеш. Башын ул, мичәүгә җигелгән карт алаша шикелле, гел бер

якка янтайтып һәм аска салындырып тота, ә йөргәндә, җилгә каршы барган кешедәй, адым саен бер күтәрелеп, бер иелеп куя. Өйгә килгән һәрбер яңа кунак алдында ул һәрвакыт хатын-кызларның ирләрдән әйбәтрәк һәм намуслырак булуы турында эчпошыргыч бәхәс кузгата яки беркатлы, уенчак тавышы белән кунактан: «Менә сез зирәк кеше... әйтегез әле, минем холкым нинди?» — дип сорый. Кунак-җитем арасында элек-электән сөйләнеп килгән: «Кем бөегрәк: Лермонтовмы, Пушкинмы?» яисә: «Табигать кешенең холкын яхшыртуга ярдәм итәме?» шикелле борынгы темалар хакында сүз чыкса инде, бәхәс мәйданының иң алгы сафына, сугышчан фил сыман, Бета чыгып баса.

Өченче кызның — Шураның — үзенә сайлап алган төп кәсебе — барлык буйдак инженерлар белән чиратлашып карта сугу. Карта уенындагы әүвәлге партнеры өйләнә икән дигән хәбәр ишетелсә, ул шундук, күңеләндә кайнаган ачу һәм үпкә хисләрен басып, үзенә яңа партнер эзләп таба. Әлбәттә, уен вакытында шаярту-көлүләр күп була, азмаз гына күңелле алдашуларга да урын калгалый; андый чакта Шура, кыланчыкланып, партнерын «мәхәббәтсез» дип атый һәм карталары белән җиңелчә генә аның кулына суккалап куя.

Гаиләдә иң яратылганы, сөелгәне — Нина. Ул бик иркә, ләкин чибәр. Юан гәүдәле, шыксыз, тупас йөзле сеңелапалары арасында ул бераз гайре табигыйрәк булып күренә. Талдай зифа буй-сын, асыл зат хатын-кызларныкыдай нәфис куллар, вак-вак миңнәр төшкән кара-кучкыл матур йөз, алсуланып торган кечкенә колак яфраклары һәм аз гына бөдрәләнеп торган куе йомшак чәч — Нинадагы бу гүзәллекнең каян килүен, бәлкем, бер генә кеше — m-me Зиненко үзе генә беләдер. Әти кеше белән әни кеше Нинага зур өмет баглыйлар, шул сәбәпле аңа бөтенесе: үтләгәнче конфет ашарга да, кыланчыкланып сакау сөйләшергә дә һәм хәтта апаларыннан яхшырак киенергә дә рөхсәт ителә иде.

Төпчек кызлары Касяга әле күптән түгел генә ундүрт тулган иде. Ләкин шулай яшь булуына да карамастан, гажәеп бу кызчык, гәүдәсенең тулылыгы белән апаларын артта калдырып, буйга әнисен дә узып киткән. Шәһәрдән ерак булу сәбәпле хатын-кыз белән аралашу мөмкинлегеннән бөтенләй мәхрүм калган завод егетләре инде бик күптәннән аңа күз аткалап йөриләр, һәм Кася үзе дә ул күз атуларны иртә өлгергән беркатлы кызыйларга хас бер оятсызлык белән яратып кабул итә.

Гаилә эчендәге бу хәлләр заводта һәммә кешегә мәгъ-

лүм. Бер шаянрагы хәтта ничектер әйтеп тә ташлаган: имеш, Зиненколарга кияү булырга теләгән кеше, һичшиксез, биш кызның бишесенә дә берьюлы өйләнергә тиеш дигән, ди. Инженер халкы һәм заводта практика узучы студентлар өчен Зиненколар өе мөсафирханә шикелле: алар анда иртә таңнан төнге караңгыга хәтле чыкмый яталар, гарык булганчы ашыйлар, ашаганнан да күбрәк эчәләр, әмма өйләнү шикелле хәтәр эшләрдән ничектер гаҗәеп оста рәвештә котылып калалар иде.

Бу гаиләдә Бобровны бик үк өнәп бетермиләр. Бөтен нәрсәне тыштан шома, эчтән пычрак әдәплелек рамкасына, эчпошыргыч провинциаль гореф-гадәт калыбына сыйдырырга тырышкан m-me Зиненконың мещаннарча чикләнгән зәвыгы өчен Андрей Ильичның кайбер кыланышлары мыскыллау, хурлау булып тоела иде. Бобровның күңеле күтәренке чагында уңга-сулга сипкән зәһәр шаяртуларын алар гаҗәпләнгән төстә күзләрен акайтып тыңлыйлар, ә ул, киресенчә, ару-талудан һәм көефе юклыктан кич буе сөйләшмичә утырса, моны Андрей Ильичның горурлыгыннан, астыртынлыгыннан күрәләр, шулай дәшмичә, ул эчтән көлеп утырадыр яисә — иң хәтәре! — «журналларга хикәяләр язадыр һәм шул хикәяләре өчен кызыклы кеше типлары эзлидер», — дип шикләнәләр иде.

Өстәл янында ашап-эчеп яисә сөйләшеп утырганда үзенә карата салкын мөгамәлә һәм әни кешенең әледән-әле гаҗәпләнгән төстә җилкә җыерулары аша сиздерелгән бу яшерен дошманлыкны Бобров белә иде, әлбәттә. Ләкин ул барыбер Зиненколарга барып йөрүен туктатмады. Ярата идеме соң ул Нинаны? Бу хакта Бобров үзе дә ачык итеп әйтә алмас иде. Һәрхәлдә, өчме-дүртме тәүлек Зиненколарга бармый торса, Нина турындагы уй-хисләрдән аның йөрәге рәхәт һәм тынгысыз бер сагыш белән тибә башлый; күз алдына кызның зифа буй-сыны калкып чыга да, Андрей Ильич аның көлеп-елмаеп торган серле кара күзләрен күргәндәй була һәм әйләнә-тирәгә нәфис тәнеңең ни өчендер ябышкак яшь тупыл бөрсләре исеп хәтерләткән дәртләндергеч исе таралгандай тоела.

Әмма Зиненколарга өч кич рәттән бардымы, аны тагын күңелсезлек биләп ала; андагы бер үк төрле мохит, бер үк төрле сүзләр һәм кешеләреңең бер үк төрле гайре табигый йөзләре аның саруын кайната башлый. Биш «туташ» белән аларга «табынучы кавалерлар» (бу сүзләр Зиненколарда еш кулланыла иде) арасында беркайчан да үзгәрми торган шаярулы-кинәле бер мөнәсәбәт урнашкан. Тегеләре дә, болары да үзләрен үзара дошманлашучы ике

лагерь итеп күрсәтергә тырышалар. Еш кына кавалерлардан берәрсе, шаяртып, кайсы да булса туташның берәр әйберен чәлдерә дә, кайтарып бирмим дип, тегене ирештерә, үрти башлый. Туташлар үпкәләгән булалар, үзара пышылдашып, әлеге шаяручыны «мәхәббәтсез» дип тиргиләр һәм, ниндидер дыңгырдык агач тавышы чыгарып, бертуктаусыз кычкырып көләргә тотыналар. Һәм болар һәммәсе дә бер үк төстә, бер үк кыланыш һәм бер үк сүзләр ярдәмендә көн саен кабатлана тора. Кичә ничек булса, бүген дә шулай. Шуңа күрә Бобров Зиненколардан башы авыртып, провинциаль мохит тәэсиреннән нервлары тәмам ватылып, арып кайтып китә иде.

Шулай итеп, Бобров күңелендә Нинаны сагыну, аның һәрвакыт кайнар кулларына орыну рәхәтен юксыну хисе Зиненколар гаиләсендәге эчпошыргыч бертөрлелеккә, кыланчыклыкка булган җирәнү хисе белән чиратлашып торды.

Кайчак шундый минутлары була — ул инде Нинага тәкъдим ясарга да әзер. Андый чакта аны әлеге ниятен әйтүдән хәтта Нина белән үзенең бөтенләй капма-каршы караштагы, икесе ике телдә сөйләшүче кешеләр булуын белү дә һәм, өйләнгән тәкъдирдә, рухи яктан буп-буш, көяз холыклы, кыланчык бу кызның гаилә тормышын бик тиз тәмугка әверелдерәчәген сизенү дә туктата алмас иде шикелле. Әмма үз ниятен ачыктан-ачык әйтергә Бобровның ничектер җөрьәте җитми иде.

Хәзер, Шепетовкага якынлашып килгәндә, ул анда ниләр булачагын, теге яки бу очракта кемнең нәрсә әйтәчәген, хәтта нинди чырай белән әйтәчәген дә алдан ук белеп торды. Өйгә таба җайдак якынлашып килүен террасадан күргәч, һәрвакыт «сөйкемле кавалерлар» көтеп яшәгән туташлар арасында иң элек җайдакның кем булуы турында озын бәхәс кубачак, билгеле. Ә җайдак якынлашып, йөзе танырлык булгач, юравы дөрескә чыккан туташ, кулларын чәбәкли-чәбәкли сикеренеп һәм телен шартлатып: «Күрдеңме? Күрдеңме? Мин белдем! Мин белдем!» — дип дәртле тавыш белән шатланып кычкырачак. Аннары ул җәһәт кенә Анна Афанасьевна янына йөгерәчәк. «Әнием, Бобров килә, беренче булып мин белдем!» — диячәк. Ә әни кеше, иренеп кенә чынаяклар сөртә-сөртә, Нинага таба — нәкъ менә Нинага таба борылып, ниндидер ифрат кызык һәм көтелмәгән хәбәр әйткәндәй бер тавыш белән: «Ниночка, беләсеңме, Бобров килә», — диячәк. Шуннан соң инде алар һәммәсе, гадәттән тыш гаҗәпләнгән кыяфәттә шаулашагөрләшә, ишектә күренгән Андрей Ильичны каршы алачаклар.

IV

Фарватер, тезгенне тарткалый-тарткалый башын чайкап, пошкыра-пошкыра бара. Ераста, куерып үскән тоташ яшел канәфер һәм сәрви агачлары арасыннан чак-чак кына төсмерләнеп, Шепетовка экономиясенең [1] кызыл түбәле, ак стеналы йорты күренде. Тау астында, яшел чирәмле ярларыннан калкынып, кечкенә генә буа җәйрәп ята.

Йорт болдырында бер хатын-кыз гәүдәсе калкып чыкты. Өстенә кигән ачык-сары төстәге кофтасыннан Бобров аның Нина икәнлеген шундук танып алды. Бу төс кызга бик килешә, ул аның кара-кучкыл йөзен тагын да матуррак итеп күрсәтә иде.

Бобров, тезгенне тартып, гәүдәсен турайтты да өзәнгегә артык эчкәре кереп торган аяк табанын чыгарарак төште.

— Сез тагын шул гарибегезгә атланып килдегезме? Күпме әйткәнем бар: җенем сөйми шул атыгызны! — дип кычкырды Нина баскыч башыннан, иркә балаларча назлы, шат тавыш белән. Бобровны яраткан аты белән үртәү күптән аның гадәтенә кергән иде. Гомумән, Зиненколар өендә кемне дә булса һәм ни белән булса да гел үртәргә яраталар иде.

Бобров үз янына җәһәт кенә килеп җиткән завод конюхына тезгенне бирде дә, атының тирләүдән кара-кучкылланып торган текә муенын шапылдатып бер сөйгәч, Нина артыннан кунак бүлмәсенә керде. Самовар янында чәйләп утырган Анна Афанасьевна, көтелмәгән кунакны каршылагандай, йөзенә гадәттән тыш бер гаҗәпләнү билгесе чыгарды һәм көйләп-вәземләп:

— А-а-а! Андрей Ильич! Ниһаять, безгә дә килер иткәнсез!.. — диде.

Аннары, үбәргә дип үрелгән Бовровның борын төбенә үк кулын күтәреп, калын, тыңкыш тавыш белән сорап куйды:

— Нәрсә телисез? Чәйме? Сөтме? Алмамы? Үзегезгә кирәген әйтегез.

Mercі [2], Анна Афанасьевна.

Mercі oui, ou mercі non? [3]

Зиненколар гаиләсендә шундыйрак французча сөйләшүләр еш була иде. Бобров бар нәрсәдән дә баш тартты.

---

[1] *Экономия* — революциягә кадәр алпавыт утары, имение.

[2] Рәхмәт.

[3] Телим — рәхмәтме, әллә теләмим — рәхмәтме?

— Алайса, барыгыз, террасага чыгыгыз, яшьләр анда ниндидер фант уйныйлар бугай, — диде m-me Зиненко, китәргә рөхсәт итеп.

Бобров балконга чыгуга, туташларның дүртесе дә берьюлы кубып, нәкъ әниләренекедәй тыңкыш тавыш белән көйләп-вәземләп:

— А-а-а! Андрей Ильич! Менә кемнең ул күптәннән күренгәне юк иде! — дип, Бобровка ябырылдылар. — Сезгә нәрсә китерик? Чәйме? Алмамы? Сөтме? Теләмисез? Юк, чыннан теләмисезме? Ә бәлкем, телисездер? Ярар алайса, кыстамыйбыз, безнең янга утырыгыз да уенга катышыгыз.

Уеннардан бүген «барыня йөз тәңкә акча җибәргән», «кем нәрсә уйлый» дигән уеннар һәм «с» урынына «ш» авазын әйтүче сакау Касяның «шавыт-шаба»сы уйнала иде. Кызлар янында биш кунак егет тә бар. Өчесе заводта практика узучы студентлар; алар күкрәк киереп яки кулларын кесәгә тыгып һәм бер аякны алгарак чыгарып, һәйкәл сыман бер кыяфәттә катып калганнар. Дүртенчесе техник Миллер — соклангыч баритон тавышлы, төскә-биткә чибәр, ләкин бераз ахмаграк егет. Һәм, ниһаять, бишенчесе — соры киемле бер әфәнде. Сөйләшми утырганга күрәме, анысына беркем дә игътибар итми иде.

Ни өчендер уен бүген көйсезрәк бара иде. Егетләр уен барышында чыккан үз җәзаларын ничектер эчпошыргыч кыяфәттә, илһамсыз-дәртсез, теләмичә генә үтиләр; кызлар исә җәза үтәүдән бөтенләй баш тарталар; аларның бар белгәне пышылдашу да шырык-шырык көлешү иде.

Караңгы инә башлады. Якындагы авыл өйләре артыннан әкрен генә зур түгәрәк кызыл ай калыкты.

— Балалар, өйгә керегез! — дип сөрән салды Анна Афанасьевна аш бүлмәсеннән. — Миллергә әйтегез, берәр җыр җырласын әле.

Бераздан инде кызларның күңелле бытылдавы бүлмәләргә күчте.

— Иллә дә кызык булды, шундый көлдек, шундый көлдек, эчләр катып бетте менә... — дип сайрашырга тотындылар алар әниләре тирәсендә.

Балконда Нина да Бобров кына торып калды. Нина, соклангыч бер кыяфәттә балкон баганасына сыенып һәм аны сул кулы белән кочагына урап, култыкса өстенә утырган. Бобров исә аяк астындагы тәбәнәк эскәмиядән урын алып, күз карашын югарыга — кызның эңгер-меңгердә чакчак кына төсмерләнеп торган нәфис муенына һәм иягенә таба юнәлткән.

— Андрей Ильич, берәр кызык сөйләгез инде, — дип боерды Нина, сабырсызланып.

— Нәрсә сөйләргә дә белмим бит, — диде Бобров. — Заказ белән сөйләшү коточкыч кыен бит ул. Кайчак мин уйлап куям: сөйләшкәндә файдалану өчен төрле темадагы хикәяләрне бергә туплаган махсус җыентык юк микән, дим...

— Фу-у! Бу кадәр күңелсе-ез адәм булы-ырсыз икән, — дип сузды Нина. — Әйтегез әле, кәефле чагыгыз буламы сезнең?

— Ә сез миңа шуны әйтегез: нигә сез сөйләшмичә утырудан куркасыз? Чак кына сүз бетә башладымы, шундук кәефегез кырыла... Дәшмичә генә аңлашу начармыни?

— «Без синең белән сүзсез генә сөйлә-шер-без...» — дип көйләп һәм көлемсерәп әйтте Нина.

— Әлбәттә, сүзсез генә сөйләшербез. Карагыз әнә: аяз күк йөзе, зуп-зур җирән ай, балконда тып-тын... Тагын ни кирәк?..

— «Күк йөзе дә ахмак, ае да ахмак», — дип, шигырь укыгандай әйтте Нина. — А propos [1], ишеттегезме, Зина Макова Протопоповка кияүгә чыга икән! Тәки чыга бит! Гажәеп тә кеше инде ул Протопопов. — Нина иңбашын җыерып куйды. — Зина өч тапкыр аның тәкъдимен кире какты, ә ул, тыпычланмыйча, дүртенче мәртәбә тәкъдим ясаган. Әйдә, үзенә үпкәләсен. Зина аны, бәлкем, ихтирам да итәр, әмма яратуы — беркайчан да булмаячак!

«Кыз аны ярата, әмма ихтирам итми», «Кыз аны ихтирам итә, әмма яратмый» кебек Зиненко кызларының мещанлыгын, тар карашлылыгын күрсәтә торган мондый сүзләр Бобровның һәрвакыт җен ачуын чыгара иде. Ир кеше белән хатын-кыз арасындагы иң катлаулы мөнәсәбәтләрне дә алар, гадәттә, шушындыйрак мәгънәсез гыйбарәләр белән аңлаталар һәм берәр кешене әхлаки, рухи һәм физик яктан сыйфатларга кирәк булса, аның «кара чәчле» яки «сары чәчле» икәнлеген әйтүдән ары китә алмыйлар иде.

Бу юлы да Нинаның соңгы сүзләре Бобров күңелендәге ачуны кузгатып җибәрергә сәбәп булды. Ул, зәһәрен чәчәргә җай чыгуга сөенгәндәй, төрпе генә сорап куйды:

— Ниндирәк кеше соң ул Протопопов дигәнегез?..

— Протопоповмы?.. — диде Нина, уйга калып. — Ул... ничек дип әйтергә... шактый озын буйлы... коңгырт чәчле!..

— Шул гынамы?

---

[1] Сүз уңаенда.

— Ә тагы ни кирәк? Аһ, тагын шул: акцизда хезмәт итә.

— Шуның белән беттеме? Гажәпләнәм мин, Нина Григорьевна, ничек инде сез кеше турында сөйләгәндә аның коңгырт чәчле булуыннан яисә акцизда хезмәт итүеннән башка бүтән берни дә әйтә алмыйсыз! Үзегез уйлап карагыз әле: тормыш юлында безгә күпме кызыклы, талантлы, акыллы кешеләр очрый бит! Аларның һәммәсе дә «коңгырт чәчле» дә «акциз чиновниклары» гына микән? Әнә крестьян балаларына карагыз: алар тормышны нинди зур кызыксыну белән күзәтәләр, теге яки бу нәрсә турында нинди төгәл, тапкыр фикер йөртәләр! Ә сез, шундый сизгер, акыллы кызый була торып, бөтен нәрсәне яныгыздан тыныч кына уздырып жибәрәсез, чөнки сезнең һәр очракка тел очыннан ычкынырга торган дистә — дистә ярым шаблон сүзегез бар. Мин алдан ук белеп торам бит: сөйләшкәндә әгәр кем дә булса ай турында әйтә икән, сез шундук: «Ае да ахмак, күк йөзе дә ахмак», — дип әлеге шаблон сүзне кыстырып жибәрәчәксез. Әгәр мин, әйтик, гадәти булмаган берәр хәл турында сөйлим икән, сез тагын төрттереп: «Сөйләве күңелле дә, ышануы гына читен», — дип куячаксыз. Һәммә нәрсәдә шулай... Алла хакы өчен дип әйтәм, ышанығыз миңа: һәр кешенең үзгәлеге, шәхси сыйфатлары...

— Миңа акыл өйрәтмәвегезне үтенәм! — дип, кискен төстә әйтеп куйды Нина.

Бобров, авызында ниндидер ачы тәм тойгандай, сүздән туктады. Аннары алар икесе дә дүрт-биш минут чамасы тын гына, кымшанмыйча гына утырдылар. Кинәт кунак бүлмәсе ягыннан яңгыравык музыка һәм аңа кушылып Миллерның тирән хис белән бераз калтыратып жырлаган моңлы тавышы ишетелде:

Средь шумного бала, случайно,
В тревоге мирской суеты,
Тебя я увидел, но тайна
Твои покрывала черты [1].

Бобровның күңелендәге ачуы шундук сүрелде. Нинаны үпкәләтү өчен ул хәзер үз-үзен битәрләде. «Кызның сабыйларныкыдай беркатлы, саф акылыннан ниндидер яңа, кыю

[1] Сүзгә-сүз тәрҗемәсе:
Шау-шулы балда очраклы гына,
Дөнья куып аһ орып йөргәндә,
Сине күрдем. Ләкин сер
Томалаган иде йөзеңне.

фикерләр таләп итү нигә кирәк булды әле миңа? — дип уйлады ул. — Сайрар кош белән бер бит әле ул: күңелендәгесен бытылдый бирә. Кем белә, аның бу бытылдавы, бәлкем, шәхес иреге турында, Ницше яки декадентлар турында сүз куертуга караганда күп мәртәбә яхшырактыр?»

— Нина Григорьевна, ачуланмагыз миңа. Мавыгып китеп, ахмак сүзләр әйтеп ташладым бугай, — диде ул, ярым пышылдап.

Нина, йөзен читкә борып һәм күзләрен офыктан күтәрелеп килгән айга таба юнәлтеп, дәшми утыра иде. Бобров, караңгыда капшанып, кызның хәрәкәтсез түбән салынып төшкән кулын эзләп тапты да эчке бер хис белән яратып кысты:

— Нина Григорьевна... Зинһар, кичерегез... — дип пышылдады.

Нина капыл гына аңа борылды, егетнең кул кысуына кыска, нервлы кысу белән җавап биреп, үпкәләвен һәм кичерүен берьюлы аңлаткандай, кыланчыкланып:

— Усал! Сез мине гел рәнҗетәсез... минем сезгә ачулана алмавымнан файдаланасыз!.. — диде.

Аннары, Бобровның кинәт калтырана башлаган кулын читкә этәреп, бер кырыйга тайпылды да йөгерә-йөгерә балкон ишегенә кереп югалды.

Күпак бүлмәсендә әле һаман Миллерның моңлы һәм дәртле тавышы яңгырый иде:

...И в грезах неведомых сплю...
Люблю ли тебя — я не знаю,
Но кажется мне, что люблю... [1]

Бобров, тирән сулыш алып һәм дөп-дөп типкән йөрәге турысына кулын куеп:

— Күңелем сизә, яратам бугай! — дип, җыр сүзләрен пышылдап кабатлады.

«Янәшәмдә, үз янымда гына гади, ләкин тирән бер бәхет булганда, нигә әле миңа үземне ниндидер билгесез, илаһи бәхет турындагы хыяллар белән җәфаларга? — дип уйланды ул, күңеле нечкәреп. — Әгәр хатын-кыз, үз хатының шулкадәр нәфис, инсафлы, игътибарлы-назлы икән, аңардан тагын нәрсә таләп итәргә мөмкин? Без, нервланып авыруга сабышкан бичара кешеләр, тормышның гади шатлыгын тоя да белмибез, аңардан файдалана да белмибез,

[1] ... Йоклый алмыйм — татлы төшләр күрәм...
Яратаммы, юкмы — белмим, тик
Күңелем сизә, яратам бугай...

без ул шатлыкларны үзебезнең һәрбер тойгыда, һәрбер уйниятебездә казынырга яратуыбыз белән туктаусыз агулап торабыз... Тынлыкка чумган айлы төн, янәшәңдә генә утырган кызның күңелле, эчкерсез бытылдавы, кыска вакытка гына ачуы кабынып, көтмәгәндә генә тагын назланып иркәләнүе — йа ходай! — тереклекнең бөтен матурлыгы, гүзәллеге шунда түгелмени?»

Бобров кунак бүлмәсенә тәмам күңеле күтәрелеп, бөтенләй диярлек тантаналы кыяфәттә барып керде. Керүгә үк күзләре Нина белән очрашты һәм аның үзенә таба төбәлгән күз карашында күңелендәге уй-хисләргә назлы хуплау күрде. «Ул минем хатыным булыр», — дип уйлады Бобров, күңеле түрендә тыныч бер шатлык хисе урнашуын тоеп.

Бүлмәдә сүз Квашнин хакында бара иде. Анна Афанасьевна, калын тавышы белән бөтен бүлмәне яңгыратып, иртәгә Квашнинны каршыларга вокзалга кызларын да алып төшәргә ниятләве турында сөйли иде.

— Василий Терентьевич бәлкем әле безгә дә визит ясар, кем белә. Һәрхәлдә, аның монда киләсен туганнан туган сеңелемнең иренә кардәш тиешле Лиза Белоконская миңа моннан бер ай элек үк язып җибәргән иде инде...

— Бу теге — абыйсы князь Муховецкий кызына өйләнгән Белоконскаяны әйтәсеңме син? — дип, гадәттәге сүзләрен кыстырып куйды Зиненко әфәнде, буйсынучан-килешүчән бер кыяфәт белән.

— Соң, шул инде, шул үзе, — диде Анна Афанасьевна, эре генә кыланып, ире ягына баш какты. — Ул әле теге син белми торган Стремоуховларга да ерак әбиләре ягыннан кардәш туры килә бугай. Менә шул, Лиза Белоконская миңа җибәргән хатында язган: бер мәҗлестә, дигән, Василий Терентьевич белән очрашып сөйләшергә туры килде, дигән, шунда аңа, заводка бара-нитә калса, сезгә сугылырга әйттем, дигән.

— Йөзгә оят китермәслек итеп кунак итә алырбызмы икән соң без аны, Нюся? — дип, борчылып сорады Зиненко.

— Кызык та сүзләр сөйләп куясың кайчакны! Соң, кулдан килгәнчә тырышырбыз инде. Елына өч йөз мең кереме булган кешене әллә ни шаккатыра алмабыз, билгеле.

— Йа аллам! Өч йөз мең! — диде Зиненко, ыңгырашып. — Әйтергә телең әйләнмәс!

— Өч йөз мең! — диде Нина сабыр гына, һәм аның тавышы кайтаваз сыман яңгырап ишетелде.

— Өч йөз мең! — дип, акыллары-исләре китеп, берьюлы кабатладылар кызлар.

— Әйе, өч йөз мең! Шул акчаны тиененә хәтле тоздырып бетерә икән үзе, — диде Анна Афанасьевна. Аннары кызларының тел очында эленеп торган сорауга җавап биргәндәй, өстәп куйды: — Өйләнгән кеше. Тик, әйтүләренә караганда, хатыннан бер дә уңмаган икән. Ниндидер төссезкыяфәтсез, бөтенләй күрексез бер хатын, ди. Ни әйтсәң дә, хатын кеше үз иренең эшләренә ямь бирә торырга тиеш шул.

— Өч йөз мең! — дип, саташкан кешедәй кабатлады Нина. — Бу хәтле акчаң булса, ниләр генә эшләмәс идең!..

Анна Афанасьевна аны яратып, кабарынкы чәчләреннән сыйпап куйды.

— Менә син шундый иргә тап булса идең, кызым, әй? Чит кеше ала торган бу өч йөз мең акча бөтен мәҗлескә тылсымлы бер тәэсир ясады. Дулкынланудан битләре кызып янган, күзләре очкынланып елтыраган кешеләр, чиратлаша-чиратлаша, бер-берсенә миллионерлар тормышыннан эллә нинди гаҗәеп мәзәкләр, акыл җитмәслек бай сый-мәҗлесләр, сылу аргамаклар, соклангыч кичәләр һәм акылсызлыгы белән тарихта калырлык типтерү, акча тоздырып йөрүләр турында сөйләргә тотындылар.

Бобровның күңеленә боздай салкын йөгерде һәм ничектер авырттырып, чемерттереп алды. Ул эшләпәсен эзләп тапты да тавыш-тынсыз гына болдырга чыкты. Хәер, аның чыгып китүен барыбер сизмәгән булырлар иде. Атын куалый-куалый өенә кайтып барганда, бөтенләй диярлек дөньясын онытып, күзләрен тондырып: «Өч йөз мең!» — дип пышылдаган Нинаны күз алдына китергәч, Бобров иртә белән Свежевский сөйләгән анекдотны исенә төшерде.

— Бу да үзен... сата беләчәк! — дип пышылдады ул, тешләрен шыкырдатып, һәм ачудан камчысы белән Фарватерның муенына сугып алды.

V

Өенә якынлашканда Бобров үзенең тәрәзәләрендә ут күрде. «Доктор килгәндер дә, мин кайтканны көтеп, диванда ятадыр», — дип уйлады ул, ак күбеккә баткан атын тыя төшеп. Хәзергесе кебек кәефсез чагында аның, ярсуын кузгатмыйча, бердәнбер түзеп торырдай кешесе шул доктор Гольдберг кына иде.

Киң мәгълүматлы, яшьләрчә тере табигатьле, төрле абстракт хасияттәге бәхәсләргә бик һәвәс булган беркат-

лы, юаш бу яһүдне Бобров чын күңеленнән ярата, үз күрә иде. Гольдберг янында нинди генә мәсьәләне кузгатма, ул һәммәсе турында да бер үк дәрәҗәдәге кызыксыну белән бәхәсләшә башлый. Әледән-әле кабынып торган бу очсыз-кырыйсыз бәхәс-әңгәмәләрдә һәр икесенең фикер-карашлары гел капма-каршы булса да, алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар һәм көн саен диярлек күрешеп, очрашып торалар иде.

Доктор, чыннан да, аякларын диван аркасына атландырып чалкан яткан да, ерактан күрми торган күзләренә якын ук китереп, ниндидер китап укый иде. Бобров китапның тышлыгындагы язуга тиз генә күз төшереп алды һәм, аның Мевиусның «Металлургия курсы» дәреслеге икәнлеген белгәч, җиңелчә елмаеп куйды. Ул докторның бу гадәтен, ягъни кулына эләккән бер китапны урта җиреннән ачып, мавыгып укырга керешү гадәтен яхшы белә иде инде.

Доктор китабын бер читкә алып куйды, күз карашын күзлек пыялалары өстеннән генә Бобровка таба күчерде дә:

— Ә мин сез юкта чәй дә куйдым инде, — диде. — Ну, Андрей Ильич, әфәндем-солтаным, эшләр ничек тәгәри?.. У-у, нинди ачулы сез? Ни булды? Тагын шул мәзәк меланхолияме?

— Ah, доктор, доктор, дөньяда яшәве шундый авыр, белмисез генә, — диде Бобров, арыган тавыш белән.

— Ник алай дисез, Андрей Ильич?

— Шулай инде... гомумән шулай... бөтенесе күңелсез. Ну, үзегездә ни хәлләр, больницагыз ничек?

— Больницабыз ярыйсы... эшли бирә. Бүген менә бик тә кызыклы бер кешегә юлыктым. Чыннан менә, көлсәң көл, еласаң ела. Күз алдына китерегез: иртәнге якта Масал ташчыларыннан бер егет килә. Алар, Масал егетләрен әйтәм, һәммәсе бер-берсенә торырлык таза, баһадир кешеләр. Менә шул, сорыйм әлеге егеттән: «Сиңа нәрсә кирәк?» — дим. «Дохтур әфәнде, — ди бу, — әртилгә ипи турыйдыр ием, шунда чак кына бармагымны кистем, хәзер таш тотар хәл юк», — ди. Карыйм моның кулын: куркырлык берни булмаган, кечкенә генә яра, тик бераз эренләгән генә; фельдшерга пластырь белән бәйләп куярга куштым. Тик, карыйм, егетем һаман китми. «Йә, тагын нәрсә кирәк? Кулыңны бәйләдек, инде юлыңда бул», — дим. «Дөрес, кулны бәйләдең, — ди бу, — анысы өчен ходай тәгалә сиңа исәнлек-саулык бирсен, тик менә минем башым да бик хәтәр авырта, берочтан аңарга да берәр дару бирмәссең

микән, дим»... — «Ни булды башыңа? Берәрсе тондырган-дыр әле, шулаймы?» — дип сорыйм тегеннән. Егет шатлы-гыннан хәтта чаңгылдап куйды. «Шундый гөнаһ булган иде шул, — ди. — Өченче көн, Спаста, әртилебез белән җый-наулашып бик тә хәтәр бәйрәм иткән идек, чиләк ярымлап аракы эчелгәндер, валлаһи. Ну, эчкәч малайлар тик тора-мыни, якалаша башладылар... Билгеле инде, мин дә чит-тә калмадым. Соңынтын... сугышканда кем аны-моны ка-рап тора?.. берәвесе тимер кискеч белән кит-тереп то-рып кундырмасынмы түбә капкачыма... Баштарак әллә ни авыртмады да шикелле, э менә хәзер сызлапмы-сызлый». Моның «түбә капкачына» карасам, — ышанасызмы? — шаклар гына каттым да калдым! Баш сөяге үтәли чәрдәк-ләнеп, биш тиенлек бакыр акча зурлыгында тишек ыржаеп тора, сөяк кыйпылчыклары хәтта ми тукымасына хәтле кереп кадалган... Инде хәзер һушын-аңын югалтып больница-да ята... Менә бит нинди гажәеп халык: бер үк вакытта герой да, сабый да. Валлаһи дип әйтәм, «түбә капкачын» болай «төзәтүгә» фәкать рус мужигы гына түзсә түзәр. Башка берәү булса, баскан урынында ук жанын бирер иде. Җитмәсә, ачу да тотмый бит әле үзе: «Сугышканда кем аны-моны карап тора?..» — дигән була. Уйласаң, вал-лаһи, исең-акылың китәр!

Бобров, озын купычлы күн итегенә камчысы белән шапылдатып суга-суга, бертуктаусыз бүлмә буйлап йөренде һәм докторның сөйләвен рәтләп тыңламады да. Аның Зи-ненколарда чакта күңеленә утырып калган әрнүе әле һа-ман сүрелеп бетә алмый иде.

Доктор сөйләүдән туктады һәм, Бобровның аңгәмәне алып барырга кәефе юклыгын күреп, килешкән төстә әй-теп куйды:

— Беләсезме нәрсә, Андрей Ильич? Әйдәгез, берме, икеме кашык бром йотыйк та ничек тә йокларга тырышып карыйк. Кәеф начарайган чакта бромның сезгә файдадан башка зыяны булмас дип уйлыйм...

Алар икесе дә бер үк бүлмәдә: Бобров караватка, док-тор диванга йокларга яттылар. Әмма тегесенең дә, моны-сының да күзенә йокы кермәде. Гольдберг Бобровның ка-раңгыда уфылдый-уфылдый боргалануына бик озак колак салып ятты-ятты да беренче булып үзе тынлыкны бозды:

— Йә, ниткән эш инде бу, Андрей Ильич? Нигә шул-кадәр газап чигәргә? Һич югы яшермичә әйтегез дә салы-гыз күңелдә җыелганны. Җиңеләеп китәр идегез, ичмасам.

Мин сезгә чит-ят кеше түгел, эч пошканнан гына сораштырмыйм ич.

Бу гади сүзләр Бобровның күңелен эретеп җибәрде. Алар арасында инде күптәннән бирле дусларча диярлек якын мөнәсәбәт урнашкан булса да, моңарчы әле һичкайсының бу турыда ачыктан-ачык әйткәне юк иде, чөнки һәр икесе дә, нечкә хисле кешеләр буларак, күңел төбендәге андый серләрне бер-берсенә ачып салырга ничектер оялалар иде. Ниһаять, доктор бүген беренче булып үзенең йөрәген ачты. Моны эшләргә аңа төнге караңгылык һәм Андрей Ильичны кызгану хисе ярдәм итте.

— Бөтен нәрсә газаплы, күңелсез, бөтен нәрсә җирәнгеч, — дип сүз башлады Бобров әкрен генә. — Беренчедән, миңа үземнең иң яратмаган, иң җенем сөймми торган җирдә — заводта эшләвем җирәнеч, шул эш өчен күп акча алуым чирканыч! Мин үземне намуслы кешегә саныйм, шуңа күрә үз-үземнән туп-туры сорыйм да: «Син нәрсә эшлисең? Эшең белән кемгә файда китерәсең?» — дим. Инде аңлый башладым шикелле: минем бу хезмәтем нәтиҗәсендә йөзләп француз кибетчесе-рантьесы белән дистәгә якын алдакчы рус эшкуары кесәсендә миллионнар туплана. Шушыннан башка мин үз хезмәтемнең бүтән бернинди максатын, мәгънәсен дә күрмим. Ә бит үземне бу хезмәткә озерләү өчен миңа гомеремнең иң яхшы өлешен корбан итәргә туры килде!..

— Сез инде арттырып җибәрдегез, Андрей Ильич, хәтта көлке тоела, — дип каршы төште доктор, караңгыда йөзен Бобровка таба борып. — Сез ниндидер буржуйларның гуманлы эш кылуын таләп итәсез. Шуны истә тотыгыз, Андрей Ильич: дөнья яралганнан бирле барлык жан иясе алга таба корсагы белән шуыша, бу гел шулай булган һәм моннан соң да шулай булачак. Ләкин хикмәт анда түгел. Буржуйларга төкереп бирегез сез, чөнки сез алардан өстен кеше — менә нәрсәдә хикмәт. Газета мәкаләләрендә язылганча әйтсәк, «прогресс арбасын» алга таба батырларча этәрүчеләрнең берсе булуыгыз сезне горурландырмый, канәгатьләндермимени? Шайтан алгыры! Пароход ширкәтләре акцияләре пайчыларга акыл ышанмаслык зур файда китерә, әмма шуңа карап кына без Фультонның кешелек дөньясына эшләгән яхшылыгын юкка чыгара алабызмыни?

— Ah, доктор, доктор! — диде Бобров, аяныч белән йөзен җыерып. — Сез бүген Зиненколарда булмадыгыз шикелле, шулай да хәзер сезнең авыздан кинәт аларның тор-

мыш фәлсәфәсе яңгырый башлады. Аллага шөкер, дәлилләр эзләп ерак барырга туры килмәс, чөнки мин сезне хәзер үзегезнең яраткан теориягез белән үк тукмаклап ташлыйм.

— Нинди теория белән ул?.. Гафу итәсез... никтер бер дә исемдә юк андый теория... валлаһи менә, исемдә юк, жанкисәгем... онытканмын...

— Оныттым дисезме? Ә кем соң, шушы үк диванда утырган җиреннән төкерекләрен чәчә-чәчә, без инженерлар, уйлап табучылар, үзебезнең хезмәт ачышларыбыз белән иҗтимагый тормышны саташу хәленә җиткерәбез, аның йөрәк тибешен тизләтәбез, дип кычкырынган иде? У-у, бик яхшы хәтеремдә әле, сез ул чакны, егерменче гасырда булачак коточкыч хәлләрне, ул гасырның арып авыруга сабышкан, акылдан шашкан, үз-үзләрен үтерү дәрәҗәсенә җиткән неврастеник балаларын санап китеп, кешелек дөньясына яхшылык эшләүче әлеге эшкуарларыгыз өстенә күз ачырмаслык каргышлар яудырган идегез. Телеграф, телефон, сәгатенә йөз егерме чакрым тизлек белән йөрешле поездлар, дидегез сез, ераклыкны minimum'га кадәр кыскартты, аны тәмам бетерде... Вакыт шулкадәр кыйммәтләнде, тиздән төнне көнгә эйләндерергә кирәк булачак, чөнки андый икеләтелгән тормыш белән яшәү теләге инде хәзердән үк сизелә, дидегез. Элек айлар буена сузыла торган эш хәзер бишь минут эчендә эшләнә. Ләкин безнең сабырсызлык шушы коточкыч тизлеккә дә риза түгел... Озакламый без бер-беребезне йөзәр, меңәр чакрымнан чыбыклар аша күрә башлаячакбыз!.. Ә шул үк вакытта моннан нибары илле еллар гына элек безнең ата-бабаларыбыз, авылдан губерна каласына барасы булса, алдан бөтен хәстәрен күреп, ашыкмыйча гыйбадәтләр кылып, юлга котып сәфәренә җитәрдәй азык-төлек белән чыгып китә торган булганнар... Без исә уңны-сулны карамый һаман алга чабабыз да алга чабабыз; аждаһадай машиналар улавыннан безнең колаклар тонган, котырып чабудан башларыбыз миңгерәүләнгән; бозык тормыштан, меңәрләгән әллә нинди яңа чирләрдән нервларыбыз какшап беткән, дидегез. Хәтерлисезме, доктор? Болар бар да сезнең үз сүзләрегез бит, «игелекле прогресс» тарафдары!

Инде берничә мәртәбә каршы сүз әйтергә ымсынып та, әйтергә җай таба алмый йөдәгән доктор, ниһаять, Бобровның аз гына вакытка туктап торуыннан файдаланды.

— Әйе шул, әйе, жанкисәгем, болар һәммәсе дә мин сөйләгән сүзләр, — дип, ашыгып җөпләп куйды ул, бик үк

ышанычлы булмаган тавыш белән. — Мин бу сүзләрне хәзер дә раслый алам. Тик, мин сезгә әйтер идем, тормышка ничектер җайлашырга кирәк бит инде. Башкача ничек яшәмәк кирәк? Һәрбер профессиядә бар ул андый җитешсез яклар. Мәсәлән, менә безне — докторларны гына ал... Бездә һәммәсе дә китаптагыча яхшы, аныкдип уйлыйсызмыни? Кая ул! Хирургиядән ары без бер генә нәрсәне дә төгәл белмибез әле. Ниндидер яңа дарулар, системалар уйлап чыгарган булабыз, әмма үзебез, әйтик, мең организм арасында, кан составы белән булсын, йөрәк эшчәнлеге, нәселдәнлек шартлары яки башка шундый сыйфатлары белән булсын, бер-берсенә аз гына булса да охшаган ике генә организм да юк икәнлеген онытып җибәрәбез! Без терапиядә хайваннар һәм им-томчылар медицинасы бергәләп салган дөрес юлдан читкә тайпылдык, фармакопеяны эллә нинди кокаиннар, атропин, фенацетиннар белән күмеп ташладык, әмма шул ук вакытта иң әһәмиятлесен истән чыгардык. Әгәр дә гади бер авыруга бу бик яхшы дару дип чиста су эчертсәң һәм аны шуңа ышандырсаң, ул кеше, һичшиксез, тереләчәк. Практикадан күренгәнчә, йөз очракның туксанында авыруның терелүенә әнә шул ышаныч ярдәм итә, аны безнең борынгы күрәзәләрчә кыюлык белән инандыра белүебез ярдәм итә. Яхшы гына бер врач — бер үк вакытта акыллы, намуслы кеше — миңа: аучылар этләрне без кешеләрне дәвалаганга караганда нәтиҗәлерәк дәвалыйлар дип, ачыктан-ачык әйткән иде. Аларда бердәнбер дару — күкерт; ул организмга эллә ни зыян китерми, ә кайчакта шулай да ярдәм итеп куя... Гажәеп бит, ә, җанкисәгем? Хәер, без дә кулдан килгәнне эшләргә тырышабыз... Башкача һич ярамый, кадерлем Андрей Ильич: тормыш компромисслар таләп итә... Кайвакыт барысын белүче күрәзә кыяфәте белән генә дә авыруның газапларын җиңеләйтәсең. Анысы да файдалы ич.

— Ярар, компромисс икән компромисс булсын, — диде Бобров, ачулы тавыш белән. — Шулай да әнә Масал ташчысының тишек башын сөякләрдән арындыргансыз бит әле...

— Әй, җанкисәгем, төзәтелгән бер баш нәрсә ул? Менә сез күпме кешене туендырып торасыз да, күпмесенә эшләргә ирек бирәсез? Уйлап карагыз әле, Иловайскийның тарих китабында ничек диелгән?.. «Борис патша, гавамының ышанычын казану өчен, ачлык елны җәмәгать йортлары төзергә кереште». Менә шуның сымаграк... Шуннан санап карагыз инде, сез нинди зур сумалык файда...

Докторның соңгы сүзләре Бобровның тәненә, әйтерсең, инә булып кадалды: ул караватына җәһәт кенә торып утырды да, ялан аякларын идәнгә салындырып, шашынкы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Файда?! Сез миңа файда турында сөйлисезме? Әгәр файда белән зыян турында сүз кузгатасыгыз икән инде, әйдәгез алайса мин сезгә статистикадан кечкенә генә бер мәгълүмат китереп үтим. — Һәм ул, кафедрадан торып сөйләгәндәй, тигез агышлы, кискен тавыш белән тезеп китте: — Күптән билгеле: рудник, шахталардагы, металл заводлары һәм зур фабрикалардагы хезмәт эшченең гомерен якынча дүрттән бер өлешкә кыскарта. Көч җитмәслек авыр эш яки фаҗигале хәлләр турында әйтеп тә тормыйм. Шакшы барак, юеш землянкаларда интегеп яшәүчеләр исәбенә күпме процент сифилис, алкоголизм туры килә — сез моны, врач буларак, миннән яхшырак беләсездер... Туктагыз, доктор, каршы сүз әйткәнче иң элек бер нәрсәне искә төшерегез: фабрикада эшләүчеләр арасында кырык — кырык биштән узган кешеләрне сез күп күрдегезме?.. Мин үзем андыйларны очратканым юк. Икенче төрле итеп әйткәндә, әшче кеше ел саен үз гомеренең өч аен завод хуҗасына корбан итә, һәр айга бу бер атна, ягъни көнгә алты сәгать туры килә дигән сүз... Инде тыңлагыз, моңардан нәрсә килеп чыга... Озакламый бездә алты домнада утыз меңгә якын кеше эшләячәк — мондый саннар Борис патшаның, шәт, төшенә дә кермәгәндер! Утыз мең кеше, һәммәсе бергәләп, тәүлек эчендә үз гомерләреңнең йөз дә сиксән мең сәгатен, ягъни җиде мең ярым көнне һәлак итәчәкләр. Ел тәүлегенә әйләндерсәк, күпме була инде бу?

— Егерме ел чамасы, — дип санап чыгарды доктор, чак кына вакыт дәшми уйланып торгач.

— Тәүлегенә егерме ел гомер! — дип кычкырып җибәрде Бобров. — Ике тәүлек эш бөтен бер кешенең гомерен ала дигән сүз! Шайтан алгыры! Үз аллаларына корбанга тере кешеләрне бирүче ниндидер ассириялеләр белән моавиялеләр турындагы Инҗил әкиятен хәтерлисезме? Ләкин андагы ул бакыр аллалар — Молóх белән Дагóн — мин әле генә китергән саннарны ишетсәләр, оялудан кая керер тишек тапмаслар иде...

Үзенчәлекле бу математик исәпләүләр Бобровның башына әле генә килде. (Артык тәэсирләнүчән кешеләрнең күбесе кебек, ул да яңа фикерләрне бары сүз җаенда, сөйләшү вакытында гына таба иде.) Шулай булса да, бу исәп-

ләүләр аның үзенә дә, Гольдбергка да гаять кызыклы тоелды.

— Шайтан алгыры, сез мине шаккатырдыгыз бит әле, — диде доктор диванда яткан җиреннән. — Хәер, бу саннарыгыз бик үк төгәл булмаска да мөмкин, әлбәттә...

— Ә сезгә икенче бер статистик мәгълүмат билгелеме икән? — дип, тагын да кызыбрак дәвам итте Бобров. — Сезнең теге шайтан арбагызның — «прогресс арбасының» алга барышындагы һәр адымы өчен, уйланып табылган һәрбер җилгәргеч, чәчкеч, рельс прокатлау машинасы өчен күпме гомер корбан ителә? Теләсәгез, сез моны да бик төгәл исәпләп чыгара аласыз. Әгәр һәрбер ирешелгән уңышы — тимер машинасымы, башкасымы берле саны, ә шуңа корбан ителгән кеше гомере бер-бер артлы тезелгән нульләр белән билгеләнә икән, бик шәп була инде ул сезнең цивилизациягез. Әйтәсе дә юк!

Бобровның ярсулы сүзләре докторны тәмам аптыраштa калдырды.

— Карагыз әле, ул чакта борынгы замандагыча гади хезмәт белән яшәү яхшырак булып чыга түгелме соң, җан кисәгем? — дип каршы төшәргә тырышты ул, кыюсыз гына. — Нигә сез тормышның гел кара ягын гына аласыз? Менә бит бездә, сезнең ул китергән саннарыгызга да карамастан, завод каршында мәктәбе дә бар, чиркәве, яхшы гына больницасы да бар, эшчеләр өчен арзанлы кредит җәмгыяте дә эшләп килә...

Бобров, караватыннан сикереп төшеп, яланаяктан гына бүлмә буйлап йөренергә тотынды.

— Больницагыз да, мәктәбегез дә — берсе дә бер тиенгә тормый! Сезнең ише гуманистларны юатыр өчен чыгарылган балалар уенчыгы гына алар, җәмгыять фикере алдында эшләнгән бер ташлама гына... Әгәр теләсәгез, мин сезгә үзебезнең чын фикеребезне әйтеп бирә алам... Финишның нәрсә икәнен беләсезме?

— Финишмы? Атларга бәйле ниндидер нәрсә бугай, щулаймы? Ат чабышларында була торган нәрсә...

— Әйе, ат чабышлары вакытында була торган нәрсә. Финиш дип чакрым баганасына барып җитәр алдыннан үтәсе соңгы йөз сажень араны әйтәләр. Ат бу араны иң кызу тизлектә чабып үтәргә тиеш — баганаңы узгач, егылып үлсә дә, аңа бер сүз юк. Финиш, димәк, көч-гайрәтне соңгы тамчысына кадәр сыгып бетерү дигән сүз. Шуңа күрә финишта атны канга батырганчы камчы белән каезлыйлар... Без дә шул фиништагы атлар шикелле. Ә финишны

үткәч, ат аякларын сындырып егыла икән, исебез китми — әйдә, шайтаныма олаксын. Ул бүтән бернигә яраксыз! Менә шунда финишта егылып үлгән атны мәктәп, больницаларыгыз белән юатып карагыз инде... Сезнең кайчан да булса кою яки прокатлау эшен күргәнегез бармы, доктор? Күргәнегез булса, сез бу эшнең нинди тәмуг газабы икәнен, аның кешедән нинди нерв, өлгерлек һәм корычтай нык мускуллар таләп иткәнлеген белергә тиешсез... Анда эшчене адым саен берәр төрле бәла-каза сагалап тора, бу бәла-казадан ул үзенең өлгерлеге, сабырлыгы аркасында гына котылып кала... Ә шул тәмугтагыдай газап өчен эшчегә күпме түләләр, беләсезме?

— Ә шулай да, завод эшләгәндә, эшчегә тиешлесен түләләр, — дип куйды Голдьберг, үз киресен куәтләп.

— Доктор, зинһар, шулкадәр беркатлы булмагыз! — диде Бобров, тәрәзә төбенә килеп утырып. — Хәзер эшченең хезмәте моңарчы һичкайчан булмаганча базар бәяләренә, биржа уеннарына һәм һәртөрле яшерен интригаларга бәйле. Һәрбер зур предприятие үзенең эшен башлап җибәргәнче үк инде өчме-дүртме хуҗасын теге дөньяга олактырган була. Безнең ширкәтнең ничек оешканын беләсезме? Аны кулдагы акча исәбенә кечерәк кенә бер компания оештырган. Баштарак хуҗаларның нияте зурдан кубарга булмаган. Әмма хуҗалар аны-моны абайлап өлгергәнче, инженер, директор, подрядчик кебек эшкуарлар бандасы акчаны сарыф итеп тә бетергән. Зур-зур корылмалар соңыннан яраксыз табылган. Зур-зур биналар динамит белән шартлатылган, ягъни, безнеңчә әйтсәк, «корбан» ителгән. Тик соңыннан гына, предприятие сумына ун тиен исәбеннән сатып җибәрелгәч кенә, эшнең хикмәте ачылган: әлеге кабахәт җаннар, алдан ныклап уйлаган планнары буенча хәрәкәт итеп, күпмедер түләү бәрабәренә бүтән бер баерак һәм хәйләкәррәк ширкәткә сатылган булганнар икән. Әлбәттә, хәзергесе көндә предприятиенең эше җәелә төште, ләкин миңа шунысы да билгеле: беренче хуҗа «шартлаган» вакытта сигез йөз эшче ике айлык хезмәт хакын алмый калган. Менә сезгә тиешлесе түләнгән хезмәт! Биржада акцияләрнең бәһасе кимедеме, бу шундук хезмәт хакына китереп бәрә. Ә биржада акция бәһаләренең ничек төшүен, күтәрелүен сез, шәт, беләсездер? Моның өчен, әйтик, Петербургка барасың да берәр таныш маклерның колагына пышылдыйсың: менә өч мең сумлык акцияләремне сатарга уйлыйм әле, «тик, зинһар, бу турыда беркем белмәсен, безнең арада гына калса, ярдәмегез өчен

акчаны кызганмам», — дисең... Аннан шуны ук «сер итеп» икенчесенә, өченчесенә әйтәсең... Нәтиҗәсе нәрсә була дисез? Акцияләрнең бәһасе шундук егерме-утыз сумга түбән тәгәри. Никадәр «сер итеп» әйтелсә, бәһаләр шулкадәр түбәнрәк төшә, җайлырак була... Хакы түләнгән хезмәт, имеш!

Бобров кискен хәрәкәт белән тәрәзәне иңеләй ачып җибәрде. Бүлмә эченә бөркелеп салкын һава керде.

— Карагыз әле, карагыз, доктор! — дип кычкырды Андрей Ильич, заводка таба бармагы белән төртеп күрсәтеп.

Голдьберг терсәкләренә таянып күтәрелә төште дә тәрәзәдән карап торган төнге караңгылык эченә күзләрен текәде. Еракта, гаять зур мәйданга җәелеп яткан үзәнлектә, утлы-ялкынлы, исәпсез-хисапсыз известняк өемнәре сибелгән иде. Алар өстендә әледән-әле зәңгәрсу-яшькелт төстәге ялкын телләре кабынып киткәли... Известь яндыру мичләре иде болар. Завод өстендә, һавада, зур кызыл шәүлә тирбәлә. Аның канлы яктысында аермачык булып төз моржаларның очлары караеп күренә; моржаларның түбәнге өлешләрен җирдән күтәрелгән соргылт томан сарып алган. Бу карачкыларның киң ачылган авызларыннан бертуктаусыз бөркелеп торган куе төтен баганалары, бергә тоташып, урыны-урыны белән мамык кисәкләредәй ап-ак яки соргылт тонык, урыны-урыны белән тимер тутыгыдай кызгылт-сары төстәге зур бер болыт хасил итәләр һәм әкрен генә көнчыгышка таба агылалар. Нәзек, озын төтен үткәргечләр өстендә, галәмәт зур факеллар сыман дерелдәп һәм ялкын телләре уйнатып, газ яна. Һавада асылынып торган төтен болыты, шул нурлы яктылыкта бер кабынып, бер сүнеп, әллә нинди сәер һәм шомлы төсләргә керә. Вакыт-вакыт сигнал чүкеченең чыңгылдавык тавышы ишетелеп китә дә, домна миче калпагы түбән шуыша, һәм шундук мич карыныннан, ерактагы күк күкрәведәй гөрселдәп, күк гөмбәзенә таба ялкын һәм корым өермәсе атыла. Андый чакта бөтен завод караңгылык эченнән аермачык һәм куркынычлы булып ялтырап куя, э бер-берсенә сыенышып утырган түгәрәк гөмбәзле кауперлар әкияттәге тимер замок башнялары сыман караеп күренәләр. Кокс мичләренең утлары тигез рәтләр булып ерак-еракларга сузылган. Кайчакны арадан берсе кисәк кенә дөрләп кабынып китә дә ниндидер зур кызыл күз сыман очкынланып җемелди башлый. Кызган тимердән чагылган кызгылт нурларга электр утларының үлек төседәй зәңгәрсу яктылыгы килеп кушы-

ла... Ул яктан берөзлексез тимер чыңы, тимер гөрелтесе ишетелеп тора.

Завод утлары шәүләсендә Бобровның йөзе ниндидер шомлы, бакыр төсе алды, күзләрендә кызгылт очкыннар кабынды; аның тузгыган чәчләре маңгае өстенә салынып төшкән, тавышы да ничектер әче яңгырап, ачулы ишетелә иде.

— Менә ул — кешенең җылы канын суручы Молóх, — дип кычкырды ул, нәзек кулын тәрәзәдән сузып. — У-у, әлбәттә монда прогресс та, машина хезмәте дә, культура уңышлары да бар... Ләкин, алла хакы өчен, уйлап кына карагыз — егерме ел! Тәүлегенә егерме еллык кеше гомере!.. Ант итеп әйтәм, кайчакта мин үземне кеше үтерүче итеп тоя башлыйм!..

«Йа аллам! Ул чыннан да акылыннан язган», — дип уйлады доктор, аркасында салкын бер кымыржу тоеп, һәм Бобровны тынычландырырга ашыкты:

— Сөеклем Андрей Ильич, йә, нигә кирәк инде сезгә мондый юк-бар өчен үзегезне газапларга, төкерегез барысына да. Карагыз әнә, тәрәзә ачык, ә тышта һава юеш, салкын тидерүегез бар... Менә бром эчеп җибәрегез дә ятыгыз. — Аның күңелен бер үк вакытта курку һәм кызгану хисе биләп алды. «Маниак, төзәлгесез маниак», — дип уйлады ул Бобров турында. Әле генә булып узган ярсудан тәмам хәлсезләнгән Бобров артык каршылык күрсәтә алмады, урынына барып ятты. Ләкин урынына ятуга ук, тыела алмыйча, үксеп еларга кереште. Доктор, карават читенә утырган килеш, аны бик озак юатты, яшь баланы йоклаткандай башыннан сыйпады һәм аңа тел очына килгән иркәләү, юату сүзләрен әйтергә тырышты.

VI

Икенче көнне Иванково станциясендә Василий Терентьевич Квашнинны каршылау тантанасы булды. Сәгать унберләргә анда бөтен завод идарәсе җыелган иде инде. Кылүчеләрдән һәрберсе үзен тынычсыз сизде шикелле. Завод директоры — Сергей Валерьянович Шелковников — стаканлап-стаканлап сельтер суы чөмерә, минут саен сәгатен чыгара да, циферблатына күз төшерер-төшермәстән, аны яңадан аңсыз рәвештә кесәсенә сала. Шушы таркаулыгы гына аның бик нык тынычсызлануын күрсәтә иде. Әболай йөзендә — югары катлау кешеләренә хас тәкәббер, шома, матур йөзендә — бернинди үзгәреш, борчылу сизелми. Шелковниковның директорлыгы бары рәсми кәгазьдә,

ягъни, икенче төрле итеп әйткәндә, сүздә генә булуын бик аз кеше белә иде. Гадәттә төзелештәге бөтен эшләрне милләтә ягыннан ярым поляк, ярым швед булган Андреа исемле бельгияле бер инженер алып бара. Аның заводтагы роле күбесенә аңлашылып җитми. Шелковников белән Андреаның эш кабинетлары да янәшә урнашкан булып, ике арада ишек тә бар иде. Берәр әһәмиятле эш кәгазенә кул куярга кирәк булса, Шелковников иң элек анда Андреаның карандаш белән билгеләнгән шартлы тамгасы бармыюкмы икәнлеген тикшерә һәм шул тамга булса гына, кәгазьне раслап яки кире кагып, имзасын сала иде. Киңәштабыш итәргә вакыт калмаган ашыгыч очракларда исә Шелковников, йөзенә борчылулы бер чырай чыгарып, йомышчы кешегә вәкарь белән генә әйтеп куя:

— Гафу итегез... сезнең белән аңлашырга һич вакытым юк... эшем муеннан... Йомышыгызны Андреа әфәндегә сөйләп бирегез дә, соңыннан ул миңа язып кертер, шуннан хәл итәрбез, — ди.

Андреаның идарә алдында эшләгән хезмәтләре санап бетергесез. Заводның беренче хуҗаларын бөлгенлеккә төшергән мәшһүр проект та тулысынча аның башында туган бер нәрсә икән. Соңыннан бу интриганы ул яшерен һәм нык кулы белән ахырынача үтәп чыккан. Аның завод эшенә кагылышлы проектлары да искиткеч гади, төгәл, шул ук вакытта фәннең соңгы казанышларына нигезләнгән була иде. Ул барлык Европа телләрен белә һәм — инженерлар арасында сирәк очрый торган хәл — фәннең башка өлкәләреннән дә яхшы ук хәбәрдар кеше иде.

Станциягә җыелган халык арасында чахотка белән авыручыларныкыдай чандыр гәүдәле, карт маймылныкыдай ямьсез йөзле шул бер кеше генә үзен гадәттәгечә тыныч тотты. Ул һәммәсеннән дә соңрак килгән һәм хәзер, таушалган, киң, салынкы чалбарының кесәләренә ике кулын терсәк тиңентен батырып тыккан килеш, аерылмас сигарасын чәйнәштерә-чәйнәштерә, платформа буйлап әкрен генә арлы-бирле йөренеп тора иде. Аның галим кеше һәм көчле ихтыярлы авантюрист икәнлеген ачык сиздергән акыллы соры күзләре шешенке күз кабаклары астыннан, һәрвакыттагыча, төбәлеп, искитмәүчән бер битарафлык белән карап торалар иде.

Зиненко ганләсенең вокзалга төшүенә беркем дә гаҗәпләнмәде. Ни өчендер һәммә кеше аларны завод тормышының асылгысыз бер кисәге итеп санарга күнеккән иде. Зиненко кызлары күңелсез тынлыкка чумган ярым ка-

раңгы һәм салкын станция залына үзләренең гайре табигый көлү-шаркылдаулары белән ниндидер бер җанлылык кертеп җибәргәндәй булдылар. Шундук аларны тик торудан алҗыган яшьрәк инженерлар чолгап алды. Кызлар да, һәрбер һөҗүмне кире кайтарырга әзер торган гадәттәге кыяфәтләренә кереп, чытлыкланып, уңга-сулга уен-көлке — һәммәсен инде күптән туйдырып бетергән күңелсез шаяртуларын сибәргә тотындылар. Тәбәнәк буйлы, тик-тормас тере хәрәкәтле Анна Афанасьевна үзенең ыгы-зыгылы кызлары арасында борчылып, кайгыртып йөрүче чебеш анасын хәтерләтә иде.

Узган көннең ярсулы киченнән соң тәмам арып-талып, бөтенләй диярлек авыруга сабышкан Бобров станция залының аулак бер почмагында ялгызы утыра һәм бертуктаусыз тәмәке тарта иде. Зиненколар гаиләсе ишектән кереп, шаулашып-гөрләшеп өстәл тирәли утырышкач та, Андрей Ильичның күңелендә томанлы гына булып берьюлы ике төрле хис дулкыны күтәрелде. Бер яктан, Зиненколарның шулай, аның уенча, әдәпсез рәвештә монда килеп керүе өчен ул чын-чыннан оялды, башка берәү *кичерергә тиешле* үтергеч, газаплы оялу белән оялды. Икенче яктан, Нинаны күргәч, аны шатлык хисе биләп алды. Атта кызу килүдән бит алмалары алсуланган, күзләре очкынланып янган ыспай киемле Нина аңа бу юлы, — гадәттә, гел шулай була бит ул, — хыялында йөрткән Нинага караганда да матуррак, сөйкемлерәк булып күренде. Аның алҗып, телгәләнеп беткән авыру күңелендә кинәт кенә түзеп булгысыз бер теләк — кыз кешенең исерткеч саф мәхәббәтендә яну, әүвәлгечә иркәләну һәм шулар эчендә тынычланып калу теләге кабынды.

Бобров Нина белән күрешү җаен эзли башлады. Әмма кыз әле һаман ике яшь студент белән мәшгуль иде. Тау институтында укучы бу студентлар бер-берсен бүлә-бүлә кызга нәрсәдер сөйлиләр, аны көлдерергә тырышалар иде. Нина, әлбәттә, көлә, башка вакытларга караганда да чытлыкланыбрак, энҗе тешләрен елтырата-елтырата, күңелле итеп көлә. Шулай да ул берме, икеме тапкыр Бобровка күз ташлап алды. Аның аз гына өскә таба дугайланып килгән кашларында ниндидер яшерен, ләкин мәкерсез бер сорау бар кебек тоела иде.

Якындагы станциядән поезд кузгалып китүен белдереп, платформада сузып-сузып звонок шылтырады. Инженерлар арасында шундук ыгы-зыгы башланды. Андрей Ильич үзенең почмагыннан көлемсерәп карап торды: егер-

медән артык кешене, әйтерсең лә, берьюлы бер үк төрле курку хисе биләп алды, йөзләр кинәт җитдиләнде, сүрелде, куллар күнегелгән хәрәкәт белән тиз генә сюртук төймәләрен сыпырып узды, галстук, фуражкаларны капшады, күзләр платформадагы звонокка төбәлде. Озакламый залда берәү дә калмаган иде инде.

Андрей Ильич платформага чыкты. Егетләре ташлап киткән туташлар аптыраган кыяфәттә ишек төбендә, Анна Афанасьевна тирәсендә өелешкәннәр. Нина, Бобровның үзенә төбәлгән күз карашын тоеп, борылып басты да, аның икәүдән-икәү сөйләшергә теләвен аңлагандай, каршысына китте.

— Исәнмесез. Бүген сезнең бөтенләй чыраегыз юк. Авырыйсызмы әллә? — дип сорады ул һәм яратып, каты итеп аның кулын кысты да җитди, ягымлы күзләре белән күзләренә текәлде. — Кичә сез нигә бик иртә китеп бардыгыз? Хәтта саубуллашмадыгыз да! Берәр нәрсәгә ачуыгыз килдеме әллә?

— Килде дә, килмәде дә, — диде Бобров, елмаеп. — Юк, килмәде, ачуланырга минем бернинди хакым юк ич.

— Ачуланырга теләсә кемнең хакы бар анысы. Бигрәк тә ул үзенең фикеренә колак салучы кеше барын белсә. Шулай да ни өчен ачуыгыз килде?

— Беләсезме нәрсә, Нина Григорьевна, — диде Бобров, кинәт кенә кыюлыгы арта баруын тоеп. — Кичә, сезнең белән балконда утырганда, — исегездәме? — мин берничә минут эчендә искиткеч бер ләззәт кичердем. Шунда мин аңлап алдым: әгәр теләсәгез, сез мине дөньяда иң бәхетле кеше итә алыр идегез... Ah, нәрсәгә куркып, сузып торам соң әле... Сез үзегез дә беләсез бит, аңлыйсыз, күптән белеп торасыз: мин...

Ул сүзен әйтеп бетермәде... Кыюлыгы кинәт кенә сүрелеп калды.

— Сез нәрсә... ни булды? — дип, юри аңламагандай, кабатлап сорады Нина, ләкин тавышы, ихтыярыннан тыш, көтмәгәндә калтыранып чыкты, һәм ул күзләрен түбән төшерде.

Ул, әлбәттә, Бобровның «яратам» дип әйтүен көткән иде. Кызлар үзләре яратамы, юкмы — барыбер, ләкин егетләрнең «яратам» диюләре аларны һәрвакыт чиксез куандыра, йөрәкләрен дөп-дөп тибәргә мәҗбүр итә. Нинаның әйт алмалары җиңелчә агарынып китте.

— Хәзер түгел... соңыннан, — диде Бобров, буталып, тотлыгып. — Кайчан да булса бүтән бер вакытта, бүтән

шартларда әйтермен әле... Тик хәзер түгел, алла хакы өчен, кыстамагыз, — дип өстәде ул, ялварып.

— Ярый алайса. Шулай да, нәрсә өчен ачуланган идегез соң сез?

— Нәрсә өченме?.. Әлеге шул берничә минутлык ләззәт кичергәннең соңында мин аш бүлмәсенә... ничек дип әйтергә... күңелем нечкәргән бер халәттә барып кердем... Барып керүемә...

— Барып керүегезгә, Квашнинның күпме акча алуы турындагы сүзне ишетеп, сезнең күңел сүрелде дә калды, шулаймы? — диде Нина. акылга сай хатын-кызларда да очраи куя торган инстинктив бер сизенү белән. — Шулай бит? Мин дөрес әйттем бит? — Ул Бобровка таба борылып басты һәм аны тагын да үзенең сихерле, иркә күз карашында коендырды. — Йә, яшермичә сөйләп бирегез. Дус кешедән бернәрсә дә яшерен-батырын булырга тиеш түгел.

Өчме, дүртме ай элек, зур бер компания белән елгада көймәдә йөргәндә, җәйге җылы төннең гүзәллегенә тәмам әсәрләнгән, күңеле йомшарган Нина Бобровка үзара мәңгелек дус булырга тәкъдим ясаган иде. Бобров моны ул чакта бик җитди кабул итеп, шуннан соң алар атна буена бер-берсен гел «дустым» дип кенә атап йөргәннәр иде. Нина үзенең гадәттәгечә назлы тавышы белән ашыкмыйча һәм серле итеп *«дустым»* дип эндәшкәндә, Бобров тетрәнеп китә, йөрәге рәхәт бер ашкыну белән дөп-дөп тибәргә тотына иде. Хәзер ул шушы килешүне исенә төшерде һәм авыр сулап куйды.

— Яхшы, «дустым», сөйләве гәрчә авыррак булса да, мин сезгә дөресен әйтәм. Сезгә карата миндә ниндидер капма-каршылыклы, газаплы бер тойгы яши. Кайсыбер минутларда мин сезнең бер сүзегездән дә, хәтта бер күз карашыгыздан гына да үземне чиксез бәхетле итеп тоям! Ah, андый нечкә тойгыларны сүз белән әйтеп буламыни?.. Шулай да, әйтегез әле, моны сез үзегез дә сизенә идегезме?

— Сизенә идем, — диде Нина, ярым пышылдап, һәм, серле шуклык белән, калтыранган керфекләрен түбән төшерде.

— Ә аннан соң... аннан соң кинәт кенә, күз алдымда ук, сез гади бер провинциаль туташка әвереләсез дә, кыланып, чытлыкланып, ниндидер эчпошыргыч, таушалып беткән сүзләр сөйли башлыйсыз... Ачыкчан-ачык әйтүем өчен ачуланмагыз... Минем өчен артык газаплы булмаса, мин боларны сезгә сөйләп тә тормас идем...

— Мин монысын да сизендем...

— Менә күрәсез... Миһербанлы, саф күңелле, сизгер булуыгызга мин гел ышана идем бит. Алайса ни өчен сез һәрвакыт хәзерге кебек булырга теләмисез?

Нина янә Бобровка таба борылып басты, хәтта аның кулына орынырга теләгәндәй бер хәрәкәт тә ясап алды. Бу вакытны инде алар платформаның кешесез очында арлы-бирле киләп сарып йөренәләр иде.

— Сез мине беркайчан да аңларга теләмәдегез, Андрей Ильич, — диде Нина, шелтә белән. — Сез бик нервлы, сабырсыз, тынычсыз кеше. Миндәге яхшы якларны сез артык зурайтып җибәрәсез, шул ук вакытта мин яшәгән мохитка хас нәрсәләрне җен ачуы белән кире кагасыз. Ә бит мин бүтәнчә була алмыйм. Бүтәнчә булырга тырышу үзе үк көлке тоелыр, безнең гаиләнең иминлеген бозар иде. Мин артык көчсез кеше; ниндидер көрәш өчен, мәстәкыйль тормыш алып барыр өчен, дөресен әйтим, сәләтле кеше түгел мин... Башкалар кая барса, мин дә шунда барам, бөтен нәрсәгә аларча карыйм, бөтен нәрсә турында аларча фикер йөртәм. Үземнең шундый гадәти кеше икәнлегемне аңламыйдыр дип уйламагыз... Ләкин бүтәннәр белән аралашканда мин бу гадәтилегемне сизмим, ә менә сезнең белән... Сезнең белән булганда, бөтенләй каушап калам, чөнки... — ул тотлыгыбрак торды, — ярар инде, әйтсәм әйтим... чөнки сез бөтенләй икенче төрле кеше, чөнки сездәй кешене минем әле беркайчан да очратканым юк...

Нина үзенең сөйләгәннәренә үзе үк ышана язды. Көзге көннең дәртләндергеч саф һавасы, вокзал ыгы-зыгысы, үзенең чибәрлеген һәм Бобровның гашыйкларныкыдай назлы күз карашын тою — болар барысы да аны тәмам исертте, күңелен нечкәртеп, йомшатып җибәрде. Тиз тәэсирләнүчән табигатьле кешеләр мондый вакытларда үз-үзләрен белештермичә, илһамланып, сихерле итеп ялганлый торган булалар. Рухи ярдәмгә сусаган кызый ролен шундый оста уйнавы өчен үз-үзенә сокланган Нинаның Бобровка ягымлы сүзләр әйтәсе килде.

— Беләм, сез мине кыланчык дип уйлыйсыз... Зинһар, акланып маташмагыз... Килешәм, моңа мин үзем сәбәпче... Мәсәлән, мин еш кына Миллер белән сөйләшеп утырам, көләм, шаярам. Тик шул тал фәрештәсен ничек җенем сөймәгәнне белсә идегез! Яки теге ике студент... Ир кешенең үз чибәрлегенә гашыйк булуы үзе генә дә күңел кайтаргыч нәрсә... Ышанырсызмы-юкмы, тик сәеррәк булса да әйтим: ямьсез ирләр миңа күбрәк ошый төшә.

Иң назлы тавыш белән әйтелгән бу сүзләрне ишеткәч, Бобров сагышлы гына уфлап куйды. Аһ, чәнечкеле юату сүзләре! Хатын-кыз авызыннан күпме ишетте инде ул аларны! Хатын-кыз үзенә күз атып йөрүче ямьсез ирләрне шундый сүзләр белән юатудан беркайчан да баш тартмый шул.

— Мин дә кайчан да булса сезгә бер ошармын әле дип өметләнә алам икән алайса? — диде ул, шаяртулы, ләкин үз-үзеннән ачы көлү сизелеп торган аянычлы тавыш белән.

Нина үзенең арттырыбрак җибәрүен абайлап алды.

— Менә бит сез нинди, валлаһи. Сезнең белән иркенләп сөйләшеп тә булмый. Нигә сез гел комплиментлар әйткәнне генә көтәсез, хөрмәтле әфәндем? Оялыгыз!..

Аптырабрак калуына ул үзе дә беркадәр оялды, ахры, сүзне икенчегә бору өчен, шаяру катыш таләпчән тавыш белән:

— Ягез, бүтән шартларда сез миңа нәрсә әйтмәкче идегез? — дип сорады. — Хәзер үк җавап бирегез!

— Белмим... хәтеремдә юк, — диде дәрте сүрелә башлаган Бобров, тотлыгып.

— Алайса хәтерегезгә төшерим, серле дустым. Сез кичәге көн турында сөйли башладыгыз, аннары ниндидер искиткеч минутлар кичерүегез турында, минем, имеш, нәрсәдер сизенүем турында әйттегез... Ләкин нәрсә икәнен әйтеп бетермәдегез... Хәзер менә, рәхим итеп, шуны сөйләгез. Мин тәләп итәм, ишетәсезме!..

Ул көләч күзләре белән серле итеп Бобровка карады. Бу күз карашында шаян хәйләкәрлек тә, вәгъдә дә, мөлаемлык та бар иде... Бобровның йөрәге рәхәт бер тойгыдан кысылып куйды, һәм аңарда яңадан әүвәлге тәвәккәллеге кире кайткандай булды. «Белә торып, ачыктан-ачык әйтүемне үзе тели», — дип уйлады ул, батырлыгын җыеп.

Алар платформаның бөтенләй кеше йөрми торган почмагында тукталып калдылар. Икесе дә бик дулкынланган иде. Нина, үзенең тапкыр уеныннан үзе хозурланып, җавап көтте, ә Бобров, авыр-авыр тын алып, дулкынланып, кирәкле сүзләр эзләде.

Ләкин шул вакыт сигнал быргыларының әче тавышы ишетелде, платформада ыгы-зыгы башланды.

— Ишетәсезме... Мин көтәм, — дип пышылдады тагын Нина, Бобров янынан тиз генә читкә тайпылып. — Минем өчен бик мөһим нәрсә бу, сез уйлаганга караганда да мөһимрәк...

Тимер юл борылышыннан кара төтенгә уралып курьер

поезды атылып чыкты. Берничә минуттан ул, рельс күчергечләр өстеннән дөбер-шатыр узып, тизлеген әкренәйтте дә платформа янына ук килеп туктады... Поездның очына ялтыравык зәңгәр төскә буялган озын вагон — кунак вагоны тагылган иде. Каршыларга төшүчеләр барысы да шунда ябырылды. Кондукторлар ихтирамлы кыяфәт белән вагон ишеген ачарга ташланды; ишек ачылуга, эчтән шыштырдый-шыштырдый җыелма баскыч сүтелеп төште. Дулкынланудан һәм чабып йөрүдән тирләп чыккан, каушаган йөзле станция начальнигы кунак вагонын поезддан тизрәк ычкындыру турында эшчеләргә боерыклар бирергә тотынды. N тимер юлы акционерларының иң зурларыннан булган Квашнинга бу юлдан йөргәндә һичкем күрмәгән, хәтта иң югары түрәләргә дә бик сирәк элә торган бер хөрмәт-ихтирам күрсәтелә иде.

Вагонга Шелковников белән Андреа һәм йогынтылы инженеры гына керделәр. Квашнин, коточкыч юан аякларын як-якка ташлап һәм корсагын киереп, креслода утыра иде. Башында түгәрәк киез эшләпә, эшләпә астыннан уттай кызыл чәчләре күренеп тора. Салынкы яңаклы, өч кат иякле, актерларча шома итеп кырылган һәм эре сипкел баскан симез бите озак йоклаган кешенеке сыман шешенке һәм ачулы күренә; иреннәре, җирәнү белдереп, чак-чак кына көлемсери иде.

Инженерларны күргәч, ул көч-хәл белән генә аягына торып басты; нәзакәтле күрешү өчен аларның һәрберсенә юан, итләч кулын сузды һәм карлыккан калын тавыш белән:

— Исәнмесез, әфәнделәр, — диде. — Йә, заводыгызда ни хәлләр бар, эшләр барамы?

Шелковников эш кәгазьләре теле белән хәлне сөйләргә кереште. Заводта бөтенесе дә әйбәт, янәсе. Менә домна мичен ачарга торабыз, яңа биналарга нигез сала башларга да вакыт җиткән; сез килгәнне генә көтә идек, янәсе... Эшчеләр белән мастерларның эш хаклары яхшы, заказлар күп — шулкадәр күп, эшне тизрәк башлап җибәрәсе килеп тора.

Директорның сөйләгәннәрен Квашнин тәрәзәгә борылып баскан килеш гамьсез кыяфәт белән тыңлады. Аның йөзенә арыганлык галәмәте чыккан һәм таркау күз карашы вагон алдына җыелган халык төркеменә төбәлгән иде.

Кинәт ул директорга көтелмәгән сорау бирде:

— Э... ка... карагыз әле... Нинди кызчык ул анда?

Шелковников тәрәзәгә таба борылды.

— Әнә теге... эшләпәсенә сары каурый кадаганы, — диде Квашнин, сабырсыз төстә бармагы белән төртеп күрсәтеп.

— Ah, аны әйтәсез икән! — диде директор, куанып һәм, Квашнинның колагына иелеп, сер әйткәндәй, французча пышылдады: — Безнең склад мөдиренең кызы. Фамилиясе Зиненко.

Квашнин салмак кына баш какты. Шелковников өзелгән сүзен дәвам итәргә тырышкан иде дә, хуҗа кеше аны тагын бүлдерде.

— Зиненко... Зиненко... — дип сузды ул, күзен тәрәзәдән алмыйча, уйга калып. — Зиненко... Кем иде соң әле ул Зиненко?.. Кайда ишеткән идем соң ул фамилияне?.. Зиненко?..

— Ул бездә склад мөдире булып эшли, — дип, юри тыныч гавыш белән кабатлады Шелковников.

— Ah, белдем! — диде кинәт Василий Терентьевич, исенә төшереп. — Миңа аның турында Петербургта сөйләгәннәр иде бугай... Ягез, дәвам итегез, әфәндем.

Квашнинның үзенә төбәлеп карап торганлыгын һәм бу минутта аның хакында сүз алып барганлыгын Нина хатын-кызларга гына хас сизгерлек белән шундук аңлап алды. Ул беркадәр читкә борылыбрак басты, ләкин аның чытлыкланудан хозурланып алсу төскә кергән йөзе бөтен гүзәллеге белән, мицпәре белән әле һаман Василий Терентьевичка аермачык күренеп тора иде.

Ниһаять, директорның сүзе бетте, һәм Квашнин вагонның павильон сымак итеп эшләнгән пыяла стеналы арткы өлешенә узды.

Бу күренешне мәңгегә истә калдыру өчен, Бобровның уенча, бары фотография аппараты гына җитешми иде. Квашнин түбән төшәргә ни өчендер ашыкмады, вагон алдында җыелган халык төркеме өстеннән калкып торган япон сәнамыдай, йөзен чытып һәм аякларын аеры куеп, пыяла стена артында тораташтай басып торды. Аның шулай хәрәкәтсез торуы каршылаучыларны өнәндереп җибәрде булса кирәк: җырылган авызлар ничектер кинәт кенә ямьсез бер рәвештә катып калды, югарыга төбәлгән ялагай күз карашларында исә курку-өркүгә охшаш бернәрсә чагылып узды. Вагон ишегенең як-ягында басып торган кондукторлар да солдатларча үрә каттылар. Бераз алгарак киткән Нинага очраклы рәвештә генә күзе төшкәч, Бобров хәтта аның йөзендә дә шул ук катып калган ел-

маю һәм потка табынучы кыргый кешедә була торган шомлы өркү чагылуын күрде.

«Өч йөз мең сум еллык кереме булган кеше алдында эчкерсез, ихтирамлы бер соклану гынамы бу, әллә башка нәрсәме? — дип уйлады Андрей Ильич, ачынып. — Беркемгә һичкайчан игътибарлы күз карашы да төшермәс шушы кеше алдында мескенләнеп койрык болгап торырга аларны нәрсә мәҗбүр итә икән? Әллә, югыйсә, аңлавы да читен булган берәр психологик закон — ялагайлык законы сәбәпчеме?»

Шактый вакыт шулай хәрәкәтсез басып торганнан соң, Квашнин, ниһаять, урыннан кузгалды һәм корсагын тагы да киерә төшеп, үзен култыклаган поезд кондукторлары ярдәмендә баскычтан әкрен генә түбән төште.

Уңга-сулга тайпылып, уртадан юл ачкан халыкның ихтирамлы сәламенә сиздерер-сиздермәс кенә баш иеп җавап кайтаргач, ул аскы иренен ямьсез итеп бүлтәйтте дә тыңкыш тавыш белән:

— Әфәнделәр, иртәгәгә чаклы сез азат, — дип белдерде.

Вокзал ишегенә җитәр-җитмәс, директорга ишарә ясады, директор якынайгач, ярым пышылдап:

— Сергей Валерьянович, сез аны минем белән таныштырыгыз инде, — диде.

— Зиненконымы? — дип кабатлап сорады Шелковников, сүзнең кем турында баруын абайлап.

— Соң, аны булмый кемне булсын! — дип, ачу белән мөгердәп куйды Квашнин. — Тик монда түгел, монда түгел, — дип, боерыкны үтәргә омтылыш ясаган директорны җиңеннән тотып туктатты. — Заводка баргач таныштырырсыз...

VII

Таш эшләрен башлап җибәрү һәм яңа домнаны ачу тантанасы Квашнин килгәннән соң ике көн узгач булды. Бу ике вакыйганы мөмкин кадәр зуррак, шаулырак итеп уздырырга кирәк иде, шуның өчен күршедәге Крутая Гора, Воронино һәм Львов металлургия заводларына да ташка басылган чакыру кәгазьләре җибәрелде.

Василий Терентьевич артыннан янә бер төркем Петербург әһелләре килеп төште. Аларның икәвесе идарә әгъзасы, дүртесе белгияле инженер һәм берничәсе эре акционер иде. Завод халкы арасында: имеш, идарә тантаналы мәҗлес өчен ике мең сумга якын акча бүлеп бирә икән,

дигән озынколак хәбәре йөрсә дә, әлегә бу имеш-мимешләрнең нигезе юк шикелле тоела, чөнки эчемлек һәм азык-төлек алу бурычы тулысы белән подрядчикларга йөкләтелгән иде.

Тантана өчен көне дә бик килешле, матур туры килде. Көз башында гына була торган кояшлы һәм салкынча һавасы исерткеч хуш ис бөркеп, аяз күк йөзе үзенең куе зәңгәр төсе белән аерата төпсез булып тоелган гаҗәеп хозур бер көн иде бу. Эшчеләр, мәет күмәргә җыенгандай, яңа һава өрдергеч машинага һәм бессемер миченә нигез салу өчен казылган квадрат чокыр тирәсен әйләндереп алдылар. Шушы җанлы ихата уртасында, чокыр читенә үк терәп, өстенә ак эскәтер ябулы буялмаган гади агач өстәл куелды.

Өстәл өстендә Инҗил китабы, төре, изге су савыты һәм кропил [1] ята иде. Бер читтә, күмәкләшеп изге җыр башкару өчен сайлап алынган унбишләп эшче сафы алдында, алтын чигелгән яшел ризасын [2] киеп, священник басып тора. Ихатаның ачык ягына исә, ике йөз кешелек шау-шулы, чуар зур бер төркем булып, инженерлар, подрядчиклар, өлкән десятник һәм конторщиклар өелешкән иде. Чокырдан казып чыгарылган туфрак тавы өстенә фотограф менеп баскан; ул, үзен дә, аппаратын да кара шәльяулык белән каплап, рәсемгә төшерер өчен инде күптәннән бирле җайлы күренеш эзли иде.

Биш-ун минуттан төзелеш мәйданында һәйбәт юртак атлар җигелгән тройкада Квашнин килеп туктады. Коляскада ул үзе генә утыра иде. Хәер, аның янәшәсендә башка кеше утыртыр урын табып та булмас иде. Квашнин артыннан тагын бишме, алтымы экипаж килде. Василий Терентьевичның «иң баш түрә» икәнлеген сизенгән эшчеләр берьюлы баш киемнәрен салдылар. Квашнин эре генә атлап түргә узды һәм священникка таба сизелер-сизелмәс кенә баш какты.

Шул вакыт мәйдан өстендә священникның чәңгелдек нечкә тавышы калтырап ишетелде:

— Благословен бог наш, всегда, ныне и присно, и во веки веко-ов...

Хор аңа шактый тигез тавыш белән:

— Амин, — дип җавап бирде.

Эшчеләр — өч меңгә якын кеше, — бая Квашнинга баш

---

[1] *Кропил* — «изге» су бөркү өчен җайланма.

[2] *Риза* — священникларның гыйбадәт вакытында кия торган өс киеме.

игән кебек, куллары белән чукыну галәмәте ясый-ясый, барысы берьюлы түбән иелделәр, аннары озын чәчле башларын чайкап яңадан тураеп бастылар... Бобров ирексездән аларны күзәтә башлады. Алдагы ике рәттәгеләр ташчылар булып, һәммәсе дә ак алъяпкыч бәйләгән һәм барысы да диярлек җитен төсле сары чәчле, җирән сакаллы иде. Алар артында француз һәм инглиз эшчеләре кия торган киң блузалардан, бит-кулларына юылмас тимер корымы каткан тимерче һәм чуен коючы агайлар урын алган; арада кәкре борынлы чит ил кешеләре дә күзгә ташлана иде. Иң артта, тимерче һәм чуен коючылар башы өстеннән, онга буялгандай ап-ак йөзле, ялкынсынган, шешенгән кызыл күзле өченче бер төркем — известь миче эшчеләре күренә...

Хор беркадәр тыңкыш, ләкин шулай да каты һәм тигез тавыш белән: «Ходаем, үз бәндәләреңне бәла-казадан саклa», — дип әйткән саен, бу өч мең кеше, үзенә бертөрле кыштырдап һәм еш-еш чукына-чукына, бил бөгеп ала иде. Ниндидер стихияле көч, кодрәт һәм шул ук вакытта балаларча бер самими күңдәмлек чагылгандай тоелды Бобровка бу күмәк гыйбадәттә. Иртәгә алар һәммәсе дә эшкә чыгачак, һәркайсы үзенең ярты тәүлек буена сузыла торган авыр, интектергеч хезмәтен башлаячак. Кем белә, бәлки берәрсенә язмыш үлем дә әзерләп куйгандыр? Биек баскычтан егылу, металл эремәсенә пешү, вак таш яки кирпеч өеме астында калу — азмыни заводта андый фаҗигаләр!.. Һәм хәзер, аксыл чәчләрен җилфердәтеп, бөгелә-сыгыла гыйбадәт кылганда, ә хор алладан үз бәндәләрен бәла-казадан саклавын сорап җыр көйләгәндә, алар, бәлкем, язмышның әнә шул катгый карары турында уйлана торганнардыр. Чыннан да, сасы, салкын землянкаларыннан көн саен гадәттәгечә авыр хезмәткә ашыгучы батыр йөрәкле, сабыйлардай киң күңелле, гаскәриләрдәй күндәм табигатьле бу кешеләр алладан башка тагын кемгә сыенсыннар, кемнән мәрхәмәт сорасыннар?

Киң, шигъри күренешләргә һәвәс Бобров әнә шулай уйлады. Гыйбадәт шикелле нәрсәләрне үзе инде күптән онытkан булса да, священникның нечкә, калтыравык җырына бердәм килеп кушылган халык гөрелтесен ишеткән саен, Андрей Ильичның аркасы буйлап ниндидер салкын бер кымырҗык йөгереп уза иде. Авыр, хәтәр эштә бил бөгәр өчен туган йортын ташлап, ерак-ерак губерналардан һәм тагын әллә кайлардан җыйналган бу соры гавамның эч-

керсез гыйбадәтендә ниндидер көчле, күндәм һәм фидакарь нәрсә бар шикелле тоелды...

Гыйбадәт тәмам булды. Квашнин искитмәүчән бер кыяфәт белән чокыр төбенә алтын акча ыргытты, ләкин көрәген тотып бөгелә алмады — аның өчен туфракны Шелковников ташлады. Аннары түрәләр таш фундамент өстендә дәү кара башняларын һавага чөеп торган домна мичләренә таба юнәлделәр.

Яңа төзелгән бишенче домна, техника теле белән әйткәндә, «ходка салынган» иде инде. Домнаның нигездән бер аршын чамасы биеклегендә ясалган тишегеннән, як-якка күкерт очкыннары чәчрәтеп, аксыл-кызгылт төстәге шлак эремәсе атыла; авыш улак буенча шыбырдый-шыбырдый түбән агып, эремә мичнең текә фундаментына терәп куелган казаннарга коела һәм шунда, суынып, койка сыман яшькелт массага әверелә бара. Домна башнясының иң очына менеп урнашкан эшчеләр мичкә берөзлексез ташкүмер һәм руда өсти торалар; руда белән ташкүмерне анда кечкенә тимер вагонеткаларга төяп менгезәләр иде.

Священник домна миченә төрле яктан «изге су» бөркеп чыкты да, куркуыннан абына-сөртенә, картларча кыйшык-мыйшык атлап, читкә китеп басты. Горн [1] мастеры — сецердән генә торган чандыр гәүдәле, кара тут йөзле карт чуклыну галәмәте ясап учына төкерде, янында торучы дүрт ярдәмчесе дә шуны ук эшләде.

Аннары алар бишесе бергә җирдән гаять озын корыч лом алып, аны бик озак тирбәтеп-чайкап тордылар да, берьюлы сөрән салып, чын көч белән мичнең түбән өлешенә китереп төрттеләр. Лом балчык бөкегә бәрелеп чыңгылдап куйды. Курку катыш бер сабырсызлык белән күзәтеп торган халык күзен йомды; кайберәүләр хәтта артка чигенде. Эшчеләр ломны чайкап торып икенче кабат, аннары өченче, дүртенче кабат төрттеләр... Һәм кинәт лом очы астыннан, күз камаштыргыч якты очкыннар чәчрәтеп, сыек металл фонтаны атыла башлады. Горн мастеры ломын айкап әйләндерә-тулгандыра тишекне тагын да зурайта төшкәч, чуен эремәсе әкрен генә комлы ерганак буйлап агылды һәм җете кызыл төскә керә барды. Мич тишегеннән һавага берөзлексез эре-эре очкыннар атыла; алар, чытырдый-чытырдый төрле якка сибелеп, бераз җемелдәп торалар да, аннары сүрелеп, тоныкланып юкка чыгалар. Иренеп кенә агылган шушы сыек металлдан тирә-якка түгә-

[1] *Горн* — домна миченең түбәнге өлеше.

зеп булгысыз эссе бөркелә. Андый эссегә күнекмәгән кунаклар битләрен куллары белән каплыйлар һәм отыры артка чигенә баралар иде.

Домна мичен карап бетергәч, инженерлар төркеме һава өрдергеч машиналар бүлегенә юнәлде. Эшкуарлар психологиясен оста белүче Квашнин үзе белән бергә килгән акционерларга — ширкәт вәкилләренә заводның бөтен зурлыгын, ыгы-зыгысын күрсәтергә һәм шуның белән аларны шаккатырырга кирәклеген алдан ук кисәтеп куйган иде. Аның исәбе үтә гади: әлеге әфәнделәр монда күргән һәм үзләре өчен бөтенләй яңа булган нәрсәләрне кайткач ширкәт җыелышында зур бер могҗиза итеп сөйләячәкләр. Ул чакта инде Василий Терентьевичка, ширкәт җыелышының моңарчы булган каршылыгын җиңеп, үзе өчен шактый файдалы яңа акцияләр чыгарырга юл ачылачак иде.

Чыннан да, завод акционерларга башлары авыртыр, тез буыннары калтырар дәрәҗәдә гажәеп бер тәэсир ясады. Һава өрдергеч машиналар бүлегенә килеп кергәч үк, алар дулкынланудан тәмам телсез-өнсез калдылар. Ике сажень озынлыгындагы дүрт вертикаль пешкәк ярдәмендә һава, коточкыч гүелдәве белән таш стеналарны дер селкетеп, ике колач юанлыгы чуен торбалар аша кауперларга кудырыла һәм, андагы газ ялкынында алты йөз градуска хәтле кызгач, домна миченә үтеп кереп, үзенең кайнар сулышы белән руданы да, ташкүмерне дә сыек эремә хәленә китерә иде. Бүлек мөдире вазифасын башкаручы инженер кунакларга аңлатмалар бирергә кереште. Гәрчә ул һәрберсенең колагына иелеп, кычкырып сөйләсә дә, коточкыч машина гүелдәве эчендә аның сүзләре бөтенләй ишетелми, һәм ул иреннәрен көчәнә-көчәнә юри кыймылдатып торган кебек тоела иде.

Шуннан соң Шелковников кунакларны пудлинг мичләре урнашкан бинага — бер башыннан икенче башы чакчак кына төсмерләнеп торган гаять озын тимер сарайга алып керде. Сарайның бер як стенасы буйлап, таш платформалар өстендә, тышкы кыяфәтләре белән көпчәге салдырылган вагоннарны хәтерләткән пудлинг мичләре тезелеп киткән иде. Алар барысы егерме булып, бу мичләрдә сыек чуен белән руда катнашмасыннан корыч эретәләр. Озер корыч эремәсе, торбалар буенча түбән агып, югары башы тоткалы тимер штамбларга — төпсез биек чаннарга тула һәм шунда кырыгар потлы тоташ кисәкләр булып ката бара. Каршы як стенаның буеннан-буена чуен юлы сузылган; анда пошкыра-пошкыра чыжылдап, шаулап, сы-

гылма хортумлы күндәм, өлгер хәрәкәтле хайваннарга охшаш пар краннары тыз-быз йөренә. Бер кран штамбны тоткасыннан ыргагы белән элəктереп ала да югары күтәрә; штамб эченнән җете кызыл төстәге тигез кырлы озын борыс сыман корыч кисәге шуып чыгып, түбән ыргыла. Әмма ул җир өстенә төшеп җиткәнче, аста торучы эшче гадәттән тыш бер җитезлек белән аңа беләк юанлыгы чылбыр чорнап өлгерә; икенче кран ыргагы белән шул чылбырдан элəктереп, «тумранны» салмак кына итеп яңадан һавага күтәрә һəм өченче кранга беркетелгән платформага — башка шундый «тумраннар» янына китереп сала. Өченче кран исә үзенә төялгән йөкне сарайның аргы башына алып китә. Анда ыргак урынына кыскыч-каптыргыч белән коралланган дүртенче кран «тумраннарны» берəмләп-берəмләп вагоннан бушата һəм идән астында урнашкан газ мичләренең ачык люкларына ташлый бара. Ниһаять, күпмедер вакыттан соң, бишенче кран газ миченда тəмам ак төскə кергəнче кызган «тумраннарны» бер-бер артлы люк авызыннан сөйрəп чыгара да горизонталь күчəрдə зыр-зыр əйлəнеп торган үткен тешле пычкы-тəгəрмəч астына китереп куя. Ниндидер бишме-алтымы секунд эчендə пычкы кырык потлы корыч «тумранны», йомшак перəннек кискəндəй, ике кисəккə урталай яра. Шуннан һəрбер кисəк җиде йөз пот авырлыктагы пар чүкече — пресс астына җибəрелə, анда гадəттəн тыш көч һəм балавыз сыккандай бер җиңеллек белəн ялпакландырылганнан соң, эшчеләр аны кул арбасына салып, йөгерə-чаба һəм əйлəнə-тирəгə кызган тимер очкыннары бөрки-бөрки, тиз генə икенче урынга күчерəләр иде.

Шуннан соң Шелковников үзенең кунакларына рельс прокатлау цехын күрсəтте. Кып-кызыл булып кызган галəмəт зур металл борыс идəн астында салмак кына əйлəнгəн һəм иң югарыгы өлеше генə идəннəн чак-чак калкып торган валиклар өстеннəн арлы-бирле шуышып, əле бер станокка, əле икенче станокка таба чаба. Станокның бер-берсенə капма-каршы якка əйлəнүче параллель ике корыч цилиндры борысны ике арага суырып ала да, калтыранып-ухылдап, аны шул аралык аша уздыра. Борыс шуннан соң цилиндрларының арасы тагын да таррак булган икенче станокка барып керə. Һəр яңа станок аша узган саен борыс юкара һəм озыная бара һəм, ниһаять, цехтагы унбиш станокның берсеннəн икенчесенə шулай йөри торгач, əкренлəп, ун сажень озынлыгындагы кызыл рельс кыяфəтен ала. Барлык станоклар белəн нибары бер кеше идарə итə. Ул

пар машинасы өстендәге капитан күперчеге сымак калку урынга менеп баскан да идарә рычагын әле алга этәрә, әле үзенә таба тартып китерә. Әшче рычагны алга этәргәндә, барлык цилиндр һәм валиклар бер юнәлештә әйләнә башлыйлар, ә рычагны үзенә таба тартканда кире якка әйләнәләр. Борыс сузылып, тәмам рельс кыяфәтенә кереп беткәч, түгәрәк пычкы, колак тондыргыч тавыш белән чыжылдый-чыжылдый һәм тирә-якка аксыл-кызыл очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә, рельсны өч бертигез кисәккә кисә.

Аннары кунаклар кыру цехына күчтеләр. Монда башлыча вагон һәм паровоз көпчәкләре кырып эшкәртелә иде. Цехның бер башыннан икенче башына хәтле түшәм аслап сузылган юан корыч күчәргә исәпсез-хисапсыз каеш приводлар кигезелгән; алар төрле зурлыктагы һәм төрле фасондагы ике-өч йөзләп станокны хәрәкәткә китерәләр. Төрле юнәлешләрдә аркылы-торкылы сузылган бу приводлар шулкадәр күп, әйтерсең лә бөтен сарай эче калтыранып торган һәм чуалып беткән тоташ бер җәтмә белән сарып алынган. Кайбер станокларның көпчәкләре секундына егерме әйләнеш ясаса, бүтәннәренең әйләнү тизлеге бөтенләй юк дәрәҗәсендә — күзгә чак-чак кына сизелә иде. Идәндә кая карама анда озын-озын матур спиральләр булып бөтерелгән корыч, тимер, бакыр йомычкалары аунап ята. Бораулау станокларыннан һавада берәзлексез тешкә тигеч әче, нәзек тавыш яңгырап тора. Шушы ук цехта кунакларга корычтан эшләнгән һәм ике зур теш казнасыдай бер ачылып, бер йомылып торган авызлы икенче бер машина — гайка ясаучы машина да күрсәтелде. Ике эшче кып-кызыл булып кызган озын, юан тимер чыбыкны очы белән шул машина «авызына» китереп тыга да, машина, тимер чыбыктан тигез кисәкләр тешләп алып, бераздан җиргә әзер гайкалар төкерә.

Кыру цехыннан чыгып, Шелковников акционерларга (үзенең аңлатмалары белән ул гел аларга гына мөрәҗәгать итә иде) заводның мактанычы, горурлыгы булган тугыз йөз ат егәрлегендәге «Компаунд» машинасын кararга тәкъдим иткәндә, Петербург әһелләренең инде моңарчы күргән, ишеткәннәрдән дә тәмам башлары әйләнеп, зиһеннәре чуалган иде. Яңа тәэсирләр аларны бүтән кызыксындырмый, бәлки арытканнан-арыта гына бара иде. Аларның йөзләре рельс прокатлау цехындагы эсседән кызарып чыккан, куллары, киемнәре күмер тузанына, корымга буялган иде. Директор тәкъдименә алар эчтән бик сыкранып, бары

тик үзләрен вәкил итеп җибәргән ширкәт җыелышының абруен төшермәс өчен генә күнделәр бугай.

Тугыз йөз ат егәрлегендәге «Компаунд» машинасы бик чиста итеп җыештырылган һәм җиһазланган киң, якты тәрәзәле, мозаик идәнле аерым бинага урнашкан иде. Күләме белән гаять зур булса да, машина эшләгәндә бернинди шакылдау тавышы да чыгармый диярлек... Һәрбере дүрт сажень чамасы озынлыктагы ике пешкәк, ишетелер-ишетелмәс кенә чыжылдап, тышкы ягы такта белән төрелгән цилиндр эчендә тыз-быз йөри. Егерме фут[1] биеклеге зур көпчәк тә, сыртына кигезелгән уникеләп арканы белән бергә, шулай ук бик тиз һәм тавышсыз әйләнә; аның киң колачлы хәрәкәтеннән бина эчендәге коры, эссе һава көчле дулкын сыман талпынып-талпынып куя. Һава өрдергечләр, прокатлау станоклары һәм кыру цехы машиналары — һәммәсе дә шушы «Компаунд» машинасы ярдәмендә хәрәкәткә китерелә иде.

«Компаунд» машинасын карап бетергәч, акционерлар ялыктыргыч бу эштән инде котылдык дип уйлаганнар иде, ләкин шул вакыт Шелковников аларга яңа бер тәкъдим белән мөрәҗәгать итте:

— Әфәнделәр, хәзер мин сезгә заводның йөрәген — мондагы бар нәрсәгә җан кертүче төп үзәкне күрсәтергә телим, — диде ул.

Һәм акционерларны, әйдәп түгел, бәлки өстерәп дигәндәй, пар казаннары бүлегенә алып китте. Әмма моңарчы күргән-караганнардан соң «заводның йөрәге» — һәрбере биш сажень озынлыгындагы һәм сажень ярым биеклегендәге унике цилиндрик казан — арыган, алҗыган акционерларга әллә ни зур тәэсир ясамады. Күңелләре белән алар инде күптән аш өстәле янында утыралар иде, шуңа күрә хәзер алар әүвәлгечә сораштырмадылар, таркау һәм искитмәүчән бер кыяфәттә Шелковников сөйләгән һәрбер сүзне баш иеп җөплəп тордылар. Директор сөйләүдән туктагач исә, җиңел сулыш алып, ачыктан-ачык канәгатьләнү белән, рәхмәтләр әйтә-әйтә, аның кулын кысарга керештеләр.

Пар казаннары янында Андрей Ильич бер ялгызы калды. Топкалар урнашкан таш стеналы, ярым караңгы чокыр кырыена баскан килеш, ул, түбәнгә күзләрен төбәп, бил тиңентен чишенеп ташлаган алты эшченең авыр хезмәтен бик озак күзәтеп торды. Бу эшчеләр көнен дә, төнен дә

[1] *Фут* — озынлык үлчәве, 30,5 сантиметрга тигез.

мичләргә берөзлексез ташкүмер өстәп торырга тиешләр иде. Чуеннан коелган түгәрәк капкачлар әледән-әле чыңлап ачыла да, мич эчендә үкереп, үрсәләнеп уйнаган аксыл-зәңгәр ялкын көлтәсе күренеп китә. Ут-ялкыннан кипшергән һәм ташкүмер тузаны сеңеп кара-кучкыл төскә кергән шәрә тәннәр әледән-әле түбән иеләләр; андый чакта әшчеләрнең аркалары бөтен умыртка сөякләренә, бөтен мускулларына кадәр аермачык булып күренә. Көрәк сабын чытырдатып кысып тоткан ябык куллар әледән-әле көрәкләренә күмер тутырып алалар, аннары җитез, өлгер хәрәкәтләр белән аны ялкын дөрләгән мич авызына китереп тыгалар. Эшчеләрнең тагын икәвесе югарыда баскан; алары да, бернинди туктау, ял белмичә, пар казаннары бүлеге янына зур таудай өелгән ташкүмерне берөзлексез түбәнгә ташлыйлар. Чиге-чамасы булмаган бу хезмәт ниндидер хафалы, кеше түземе җитмәслек бер җәза булып тоелды Бобровка. Әйтерсең лә ниндидер илаһи көч эшчеләрне шушы ыржайган авызлы аждаһа янына гомерлеккә кадаклап куйган да, газаплы үлем белән куркытып, шул тирән корсакны ашатып, туйдырып торырга мәҗбүр иткән...

Шул чакны Бобров үз артында:

— Нәрсә, коллега, үз Молохыгызны ничек симертүләрен күзәтәсезме? — дигән мөлаем, шат тавыш ишетте.

Андрей Ильич, калтыранып китеп, чак-чак кына чокырга егылып төшмәде. Докторның шаяртулы сүзләре белән үз фикерләренең шулай тәңгәл килүе аны гаҗәпләндерде генә түгел, бәлки тетрәндереп җибәрде. Хәтта тетрәнү хисе сүрелгәч тә, бу сәер тәңгәллек бик озак аның күңелен биләп торды. Уйлаган уеның яисә эле генә китаптан укыганының кемдер тарафыннан шундук кычкырып кабатлануы Бобровта һәрвакыт кызыксыну уята һәм гадәттән тыш серле булып тоела иде.

— Мин сезне куркыттым, ахры, Андрей Ильич? — диде доктор, Бобровның йөзенә җентекле күз карашын юнәлтеп. — Гафу итегез.

— Әйе, бераз булды шул... бигрәк тавыш-тынсыз килдегез... мин бөтенләй көтмәгән идем.

— Их, кадерлем Андрей Ильич, нервларыгызны дәваларга кирәк, нервларыгызны. Бернигә яраксыз сезнең нервлар.., Тыңлагыз әле минем киңәшне: ял алыгыз да берәр кая чит илгә китегез... Йә, нигә кирәк монда үзегезне үзегез ярсытып ятырга? Ичмасам, ярты ел гына булса да үз рәхәтегез өчен яшәп карагыз әле: әйбәт аракылар эчегез,

озаклап-озаклап ат өстендә йөрегез, гыйшык-мыйшыклар табыгыз...

Доктор кочегарка базы кырыена килеп басты да, түбәнгә карап:

— Менә кайда икән ул җәһәннәм! — дип кычкырып җибәрде. — Ничә пот булыр икән бу самавырларның һәрберсе? Сигез йөз чамасы булыр бит, ә?..

— Юк, күбрәк. Мең ярым чамасы...

— Ай-яй-яй... Әгәр шул нәрсә, әйтик, нитсә... шартласа? Кызык булыр иде микән? Ә?

— Бик кызык булыр иде, доктор. Мондагы барлык йортларның көле күккә очар иде...

Гольдберг, башын чайкап, мәгънәле генә сызгырып куйды.

— Ә шартлауның сәбәбе нидән булырга мөмкин?

— Төрле сәбәптән... ләкин күбрәк болай килеп чыга: казанда су бик аз кала да, казан стенасы бик каты кыза... Әгәр шул чакны казанга су өстәсәң, кыска гына вакыт эчендә анда гаять күп су парлары хасил була, казан, пар басымына түзә алмыйча, шартлый, ярыла...

— Димәк, моны юри эшләргә дә була?

Әлбәттә, була... Сынап карарга теләмисезме? Сууылчәгечтәге су бөтенләй түбән төшкәч, вентильне генә борырга кирәк... күрәсезме әнә теге кечкенә түгәрәк рычагны. Шуннан бөтенесе вәссәлам!

Бобров шаяртып сөйләсә дә, аның тавышы ничектер бик җитди ишетелә, ә күз карашы моңсу һәм кырыс иде. «Шайтан белсен, сөйкемле генә кеше үзе, шулай да... психопат...» — дип уйлады Гольдберг.

Кочегарка яныннан кузгалып киткәч, ул Бобровтан:

— Ә ни өчен мәҗлескә бармый калдыгыз әле, Андрей Ильич? — дип сорап куйды. — Лабораториядән нинди кышкы бакча ясаганнарын күрер идегез, ичмасам. Ә табыннары — исең-акылың китмәле!..

— Кирәкләре юк! Инженерлар мәҗлесен женем сөймиме — диде Бобров, йөзен җыерып. — Бар белгәннәре — мактанышу да кычкырыну, бер-беренә ялагайлану. Кырыкмаса кырык мәртәбә ишеткән тостлар әйтәләр. Җитмәсә, сөйләгәндә үзләрен дә, күршеләрен дә аракыга коендырып бетерәләр... Чирканыч!..

— Әйе, әйе, анысын дөрес әйтәсез, — диде доктор, көлеп. — Мәҗлес башына мин дә эләккән идем. Квашнинның кыланышын аңлатып бетергесез. «Мөхтәрәм әфәнделәр, ди, инженерның бурычы бик жаваплы, бик бөек бурыч. Чуен

юлы белән бергә, домна миче, шахталар белән бергә инженер халкы илнең иң ерак почмакларына кадәр мәгърифәт орлыклары, цивилизация чәчкәләре тарата...» — ди. Тагын әллә нинди орлыклар, җимешләрне санап китте, рәтләп хәтердә дә калмаган... Менә нинди ата жулик бит ул! «Әфәнделәр, әйдәгез бердәм булыйк, үзебезнең игелекле сәнгатебезнең изге байрагын югары тотыйк!..» — ди. Шуннан инде үзен шашына-шашына алкышларга тотындылар...

Алар бераз җир сөйләшми генә бардылар. Кинәт докторның йөзе караңгыланып китте, һәм ул зәһәр тавыш белән әйтеп куйды:

— Әйе! Игелекле сәнгать! Ә менә эшче бараклары йомычкадан салынган. Авыруларның исәбе-хисабы юк... балалар чебен урынына кырыла. Мәгърифәт орлыгы дигәннәре менә шул инде! Иванковода корсак тифы котырына башлагач, ничек сайрарлар икән, күрербез әле!

— Ни сөйлисез, доктор? Авыручылар бармы әллә? Мондый кысан шартларда яшәүчеләр өчен коточкыч хәл булачак бит бу.

Доктор, туктап, авыр сулыш алды.

— Ничек инде булмасын? — диде ул, ачынып. — Кичә генә икәвесен китерделәр. Берсе бүген иртән үлде, икенчесе, әле үлмәгән булса, кичен, һичшиксез, үләчәк... Ә безнең дарулар да... бинабыз да, тәҗрибәле фельдшерларыбыз да юк... Бераз сабыр итегез, күрмәгәннәрен күрерләр әле алар!.. — дип өстәде Гольдберг ачулы төстә һәм, кулын күтәреп, кемгәдер йодрык янады.

VIII

Усал телләр бик тиз гайбәт тарата башлады. Квашнин хакында ул үзе килгәнче үк әле заводта күп мәзәк сүзләр йөри иде, ә хәзер ул көтмәгәндә генә Зиненколар гаиләсе белән якынаеп киткәч, моның сәбәбен һәрберсе Квашнинның гыйшык мажараларына бәйләп юрады. Ханымнар бу хакта кинәя белән серле елмаешып такылдадылар, ирләр исә үзара сөйләшкәндә һәммәсен ачыктан-ачык, тупас сүзләр катнаштырып телгә алдылар. Әмма дөресен беркем дә анык белмәде. Барысы да яшерен бер куану белән кызыксынып гауга чыкканын көтте.

Гайбәт сүзләрендә дөреслек тә юк түгел иде. Зиненколар гаиләсенә беренче визитын ясаганнан соң, Квашнин һәр кичне аларда уздыра торган булып китте. Иртәләрен,

сәгать унберләрдә, Шепетовка экономиясенә Квашнинның һәйбәт тройкасы килеп туктый; кучер, көндәге гадәтенчә:

— Барин барыня белән туташларны үзенә иртәнге ашка чакыра, — дип хәбәр бирә. Бу иртәнге ашка чит кешеләрдән бүтән беркем дә чакырылмый иде. Аш-суны да Василий Терентьевичның үз пешекчесе — бер француз әзерли; аны ул теләсә кая, хәтта чит илгә чыкканда да үзе белән алып йөри иде.

Квашнинның яңа танышларына карата игътибары гаять үзенчәлекле төстә чагыла иде. Кызларның бишесе алдында да ул үзен шат күңелле буйдак абзыйлары сыман бик тәкәллефсез тотты. Ике-өч көн узуга ук инде ул аларны, иркәләү исемнәренә этиләренең исемен кушып, берсен Шура Григорьевна, икенчесен Ниночка Григорьевна дип атый башлады. Ә иң кече кызны, Касяны, ул еш кына чокырлы йомшак иягеннән тотып, «сабый» яки «чебеш» дип үрти, кызый исә, күз яше чыкканчы кызарынса да, аңа каршылык күрсәтми иде.

Анна Афанасьевна, кызларымны кирәгеннән артык иркәлисез дип, Квашнинны ара-тирә шаяру катыш тиргәптиргәп тә алгалаган була иде. Чыннан да, кызлардан берәрсе юк кына теләк белдерсә дә, бу теләк шундук эшкә ашырылды. Бервакыт Мака, сүз иярә сүз чыгып кына, велосипедта йөрергә өйрәнсәң иде, дип ычкындыруы булды, икенче көнне үк почта хезмәткәре аңа Харьковтан кимендә өч йөз сум торырлык һәйбәт велосипед алып кайтып тоттырды... Ниндидер юк кына нәрсә турындагы бәхәстә оттырып, Квашнин Бетага бер пот конфет, ә Касяга, аның исемендәге хәрефләрне күздә тотып: коралл, аметист, сапфир һәм яшма ташларыннан тезеп ясалган брошка бүләк итте. Бервакыт ул Нинаның ат менеп йөрергә һәм, гомумән, ат яратуын белеп алды. Ике көн үткәч, Нинага хатын-кыз ияренә җайлап өйрәтелгән нәселле инглиз биясен китерделәр. Туташлар тәмам ис-акылларыннан яздылар. Әйтерсең лә аларның өенә һәрбер вак-төяк омтылышка, теләккә кадәр сизеп алып, аны шундук эшкә ашыра ала торган тылсымлы рух кереп урнашкан иде. Анна Афанасьевна чиктән ашкан бу юмартлыкта тәрбияле гаилә өчен килешмәстәй ниндидер нәрсә барлыгын сизенсә дә, бу турыда Квашнинга кинаяләп әйтергә кыюлыгы да, осталыгы да житмәде. Ялагайлы, шаяртулы тиргәүләргә исә Квашнин кул гына селтәде һәм гадәттәгечә тупас, калын тавышы белән:

— Әй, кадерлем, әллә нинди юк нәрсәләр уйлап баш ватмагыз әле, — диде.

Шулай да Квашнин үзе кызларның кайсысын күбрәк ошатканлыгын ачыктан-ачык сиздермәде; ул һәммәсенә дә бертигез карарга тырыша һәм барысыннан да тәкәллефсез көләргә, шаяртырга ярата иде. Моңарчы Зиненколарга килеп-китеп йөргән яшь егетләрдән әйтерсең лә җилләр исте. Аның каравы элек нибары икеме-өчме генә күренеп киткән Свежевский хәзер көн саен диярлек аларда була башлады. Аны беркем дә махсус чакырып китермәде, ул, кемнеңдер тылсымлы көченә буйсынгандай, бу өйгә үзе килеп керде һәм килеп керүенә үк гаиләнең иң кирәкле бер кешесенә әверелде.

Хәер, Зиненколарга килеп йөри башлаганчы ук инде Свежевский хакында бер мәзәк таралып өлгергән иде. Моннан дүртме-бишме айлар элек, хезмәттәшләре белән сөйләшеп утырганда, Свежевский үзенең хыялы миллионер булу икәнлеген һәм кырык яшенә җиткәндә хыялының тормышка ашачагын мактанып сөйләп ташлый.

— Сез моңа нинди юл белән ирешмәкче буласыз соң, Станислав Ксаверьевич? — дип сорыйлар аңардан.

Свежевский кеткелдәп көлә дә, дымлы учларын серле итеп бер-берсенә ышкый-ышкый:

— Барлык юллар Римга илтә, — дип җавап бирә.

Шепетовка экономиясендәге хәзерге хәлләрнең үз карьерасы өчен шактый уңайлы юнәлеш алганлыгын ул эчке бер сиземи белән бик тиз чамалады. Һәрхәлдә, кодрәтле хуҗага үзенең кирәге чыгуы ихтималын ул һәрвакыт истә тотты. Шуңа күрә, бөтен язмышын карта уенына салып, Свежевский тәвәккәл төстә һөҗүмгә күчте, көлеп, ялагайланып, Квашнин күзенә мөмкин кадәр күбрәк чалынырга тырышты. Ул аның янында нәселле усал эт тирәсендә бөтерелгән көчек баласыдай бөтерелде һәм кыяфәте белән дә, тавышы белән дә теләсә нинди әшәке эшне эшләргә әзер икәнлеген сиздерде. Тик хуҗа кеше — Василий Терентьевич — аңа ым гына каксын...

Хуҗа кеше исә аңа комачауламады. Завод директорларын, управляющийларны, сәбәбен дә аңлатмыйча, хезмәттән куарга гадәтләнгән Квашнин — шушы кодрәтле Квашнин үз янында бөтерелеп йөргән ниндидер Свежевскийга түзеп торды... Монда ниндидер мөһим эш яшеренгән булырга тиеш иде, һәм булачак миллионер сабырсызланып үз вакыты җиткәнен көтте.

Болар һәммәсе, телдән-телгә күчеп йөри торгач, Боб-

ровка да ишетелде. Ул гажәпләнмәде: Зиненколар гаиләсе турында аның инде ныклы, төгәл үз фикере бар иде. Аны тик бер генә нәрсә борчыды: гайбәт үзенең пычрак койрыгы белән, әлбәттә, Нинага да сугылып үтәчәк... Вокзалдагы сөйләшүдән соң бу кыз Бобров өчен тагын да сөйкемлерәк, кадерлерәк булып киткән иде. Ул бит үзенең гүзәл күңелен — барлык шик-шөбһәләре, җитешсезлекләре белән гүзәл булган күңелен — бары аңа гына ачып салды. Бобров уенча, бүтән кешеләр Нинаның тышкы кыяфәтен, киемен-салымын гына күреп беләләр иде. Кешенең мин-минлек хисләрен ярсытып, аны әллә нинди оятсыз шик-шөбһәләр, вакчыл бәйләнүләр һәм тупаслыклар өермәсенә дучар итүче көнләшү исә Бобровның ышанучан, йомшак табигатенә бөтенләй ят нәрсә иде.

Тугрылыклы, саф хатын-кыз мәхәббәте Андрей Ильичка таныш түгел иде. Артык кыюсыз булуы һәм үз-үзенә ышанып җитмәве сәбәпле, ул тормыштан үзенә тиешлесен алырга да җөрьәт итмәде. Шуңа күрә аның хәзер бөтен күңеле белән шатланып, яңа, көчле хисләр дөньясына баштанаяк чумуы бер дә гажәп түгел иде.

Соңгы көннәрдә ук вокзалдагы сөйләшү тәэсирендә яшәде. Қырыкмаса-кырык мәртәбә аны бөтен ваклыкларына кадәр күз алдына китерде, һәм күз алдына китергән саен Нинаның әйткән сүзләрендәге мәгънә аның өчен тирәнәйгәннән-тирәнәя барды. Иртәләрен йокыдан уянганда аның хыял күгендә күп төрле рәхәтлекләр вәгъдә иткән ниндидер зур, якты бернәрсә балкып торгандай тоела иде.

Ул березлексез Зиненколарга барырга кысталып торды; анда барып, тагын бер мәртәбә үз бәхетенең чын икәнлегенә ышанырга һәм Нинаның әле кыюсыз, әле беркатлы батыраю белән әйткән томанлы йөрәк серләрен кабат ишетергә теләде. Ләкин Қвашнинның анда булуы аны тыелырга мәҗбүр итә иде. Бары тик, хуҗа кеше Иванковода ике атнадан артык тормас, китеп барыр, дигән өмет кенә аңа беркадәр юаныч бирде.

Шулай да Қвашнин китеп барганчы ук аңарга Нина белән очрашырга туры килде. Яңа домна мичен ачу тантанасыннан соң өч тәүлек үткәч, якшәмбе көнне булды бу хәл. Бобров заводтан станциягә илтүче киң, такыр юл буйлап Фарватерына атланып бара иде. Салкынча аяз көн, вакыт көндезге икеләр чамасы. Фарватер, тузгак башын чайкап һәм йомры колакларын селкеткәләп, кызу адымнар белән бара. Склад янындагы чатны борылгач, Бобров эре бәдәнле туры ат өстендә каршы як үрдән төшеп килүче

амазонка киемендәге бер кызны һәм аңардан шактый арттарак икенче бер җайдакны күреп алды. Бераздан инде ул беренче җайдакның Нина икәнлеген таныды. Кызның өстендә озын, җилфердәвек итәкле куе яшел юбка, беләккә җиткән күн перчатка, башында ялтырап торган тәбәнәк эшләпә — цилиндр иде. Сөлектәй зифа сынлы инглиз биясе, муенын дугайландырып һәм нәзек, чандыр сыйракларын биектән алдыртып, сыгылмалы эре адымнар белән юыртып килә. Ак төстәге карсак кыргыз атына атланган икенче җайдак, Свежевский, әллә кайда калган; ул, бөгелә-сыгыла һәм терсәкләре белән һаваны айкый-чайкый, өзәнгедән ычкынган аякларын кире кигезмәкче булып маташа иде.

Бобровны күргәч, Нина атын кызулата төште. Эшләпәсен, җил очыртып китмәсен өчен, уң кулы белән читеннән тотып һәм башын иебрәк барырга мәҗбүр булды. Андрей Ильич турысына килеп җиткәч, капылт кына тезгенне тартты да, ат, туктап, киң борын тишекләрен куыкландырып, күбек тамып торган тимер авызлыкны тешләре белән шыкырдатып чәйни-чәйни, бер урында сабырсызланып биеп тора башлады. Нинаның үзенең дә атта йөрүдән бите кызарган, эшләпәсе астыннан чигә чәчләре чыгып, вак бөдрәле нечкә тасмадай, иңбашына салынып төшкән иде.

Бобров ярсып тыпырдый башлаган Фарватерын ничек кирәк алай тыя төште дә, ияр өстеннән ярым бөгелеп, кызның бармак очларын кысты.

— Каян таптыгыз сез мондый гүзәл малкайны?

— Чыннан да, бик гүзәл бит, әй? Квашнин бүләге ул.

Кызның ваемсыз гына әйткән бу җавабы инженерны кинәт чыгырыннан чыгарды.

— Мин андый бүләктән баш тарткан булыр идем, — диде ул, дорфа гына.

Нина кызарып китте.

— Ни өчен?

— Чөнки... чөнки... сезнең кемегез соң ул Квашнин?.. Абзагызмы?.. Булачак кияү егетеме?..

— Ah аллам, бүтәннәргә карата нинди вакчыл кеше сез! — диде Нина, зәһәрле елмаеп.

Ләкин, Бобровның йөзендә газап билгеләре күреп, зәһәрен йомшарта төште.

— Аның өчен бу берни тормый ич... Шундый бай кешегә...

Свежевский килеп җитәргә инде бер ун адым чамасы гына калган иде. Нина кинәт Бобровка таба иелде дә, камчы очын аның кулына йомшак кына тидереп, үз гаебен

үзе таныган бәләкәй кызчык тавышы белән, ярым пышылдап:

— Ярар, булды... булды, ачуланмагыз... Атын кире үзенә кайтарып бирермен, алай күңелегезгә бик тигәч!.. Күрәсезме, сезнең фикер белән мин ничек исәпләшәм! — диде.

Андрей Ильичның күзләрендә шундук шатлык нуры балкып китте, куллары ихтыярсыз Нинага таба сузылды. Ләкин ул үзе бер сүз дә әйтмәде, бары бөтен күкрәге белән тирән итеп бер сулыш кына алды. Ул арада аның янына, ерактан ук бөгелә-сыгыла исәнләшеп, Свежевский якынлашып килә иде.

— Бездә пикник буласын, шәт, беләсездер инде? — дип кычкырды ул, ат өстендә үзен бик иркен тотарга тырышып.

— Беренче ишетүем, — диде Андрей Ильич.

— Василий Терентьевич оештырып йөргән пикникны белмисезме? Котырган елгада буласы пикникны?..

— Юк, белмим.

— Әйе, әйе. Зинһар, килегез, Андрей Ильич, — диде Нина, сүзгә катышып. — Чәршәмбе көнне кичке сәгать биштә... җыелу урыны станциядә...

— Пикник исемлек буенча җыеламы?

— Шулай бугай. Тәгаен белмим.

Нина аптыраган кыяфәттә сораулы күз карашын Свежевскийга юнәлтте.

— Әйе, исемлек буенча, — диде Свежевский, раслап. — Василий Терентьевич миңа үзенең кайбер боерыкларын үтәп чыгарга кушты. Сезгә әйтсәм әйтим, пикник искиткеч шәп булачак. Шаккатарлык булачак... Тик әлегә болар барысы да сер. Күргәч үзегезнең дә исегез-акылыгыз китәр әле...

Нина, сабыры җитмичә, чытлыкланып өстәп куйды:

— Беләсезме, болар бөтенесе дә минем аркада килеп чыкты бит. Өченче көн шулай сөйләшеп утырганда мин урмангамы, берәр җиргәме компания белән чыгып керсәң шәп булыр иде дигән идем, Василий Терентьевич шундук...

— Мин пикникка бармыйм, — дип кырт кисте Бобров.

— Юк, барасыз! — диде Нина, күзләрен елтыратып. — Әфәнделәр, марш, марш! — дип кычкырды ул аннары һәм, атын камчылап, урыннан ук сикертеп чабып китте. — Андрей Ильич! Карагыз әле, минем сезгә сүзем бар.

Свежевский артта калды. Нина белән Бобров янәшә киттеләр. Кыз елмая һәм Бобровның күзләренә карарга тырыша, ә Бобров карасына кабынган һәм ачулы иде.

— Пикникны бит мин бары сезнең өчен генә уйлап чы-

гардым, аңлыйсызмы шуны, мәрхәмәтсез дустым минем! — диде Нина, гажәеп бер иркә тавыш белән. — Теге чакны вокзалда әйтеп бетермәгән сүзегезне дә бик беләсем килә... Пикникта безгә беркем комачауламас.

Һәм кинәт Бобровның күңелендә яңадан бөтенесе үзгәрде. Күзләренә мөлдерәп яшь тулуын тоеп, ул эчке бер хис белән:

— О, Нина! Мин сезне бик яратам! — дип кычкырып җибәрде.

Ләкин кыз аның йөрәк түреннән ургып чыккан бу сүзләрен гүя ишетмәде дә. Тезгенне тартып, атын тыя төште дә:

— Барасыз алайса? Әйеме? — дип сорады.

— Һичшиксез. Һичшиксез, барачакмын!

— Карагыз аны... Ә хәзер минем кавалерымны көтик тә хушлашыйк. Мин өйгә ашыгам...

Аерылышканда ул бик озак итеп, каты итеп Бобровның кулын кысты; Андрей Ильич хәтта перчатка аша да аның кайнар кул җылысын тойды. Нина аңа кара күзләре белән яратып, сөеп карый иде.

IX

Чәршәмбе көнне иртәнге сәгать дүрт тулар-тулмас ук станция пикникка баручылар белән шыгрым тулды. Һәрберсе үзен иркен һәм шат сизде. Василий Терентьевичның заводка килүе бу юлы һичкем уйламаганча, көтмәгәнчә яхшы тәмамланып килә иде. Бернинди дә күк күкрәүләр булмады, яшеннәр дә яшьнәмәде, беркемне дә эшеннән дә алып ташламадылар; хәтта, киресенчә, якын киләчәктә хезмәткәрләрнең күбесенә эш хакын күтәрәләр икән дигән хәбәрләр дә йөри әле. Аның соңында, менә бу пикник дигәне дә бик кызык булыр төсле тоела. Пикник буласы Котырган елгага кадәр, әгәр атка утырып барсаң, ун чакрымнан артык түгел икән. Юлы да бик матур, ди... Үткән атнада урнашып калган аяз, җылы көннәр әле булса дәвам итә, шулай булгач, пикникны күңелле уздырырга һичнәрсә комачаулый алмас кебек иде.

Пикникка туксанлап кеше чакырылган иде; алар төркеме-төркеме белән платформада җыелышып торалар, көләләр, шаулашалар. Русча сөйләшү арасында әледән-әле французча, немецча, полякча әйткән сүзләр яңгырап китә. Бельгияле өч инженер магний яктысында моменталь рәсемнәр төшерә ала торган фотография аппаратлары такканнар... Пикникның ничек буласын һичкем рәтләп белми,

шуңа күрә барысы да сорашып белергә тырышалар. Свежевский, серле һәм эре кыяфәт белән ниндидер «сюрпризлар» хакында кинаяләп әйтсә дә, аныклап аңлатып бирүдән гел кача иде.

«Сюрприз» дигәннәренең беренчесе махсус поезд булды. Нәкъ сәгать биштә паровоз депосы капкасында ун көпчәкле яңа паровоз — Америка паровозы күренде. Гаҗәпләнү һәм сокланудан хатын-кыз хәтта чыелдап кычкырып җибәрде: көпчәкләреннән алып моржасына кадәр паровоз флаг һәм чәчәкләр белән бизәлгән иде. Яшел яфраклы имән ботакларына кашкарый, дәлия, шеббуй һәм канәфер кебек чәчәк бәйләмнәре аралаштырып тезгән озын-озын үремнәр, паровозның бөтен корыч гәүдәсен сарып, моржа буенча югары үрмәли, аннан тагын түбән салынып, сигнал свистогы өслəтеп машинист будкасына күчә дә аны бөтенләй тоташ чәчәк, яфрак стенасы белән каплап ала. Паровозның корыч һәм бакырдан эшләнгән ялтыравык өлешләре исә, баеп барган кояшның яшел яфрак һәм чәчәк араларыннан үтеп кергән алтын нурларында чагылып, үзенә бер серле гүзәллек белән җемелдиләр иде.

Платформа кырында бер-берсенә тагылган беренче класслы алты вагон тора; пикникка катнашучылар шушы вагоннарга утырып «303 нче чакрым» дигән тукталышка кадәр барырга тиешләр. Аннан инде Қотырган елгага күп булса ярты чакрым чамасы юл кала, ди.

— Әфәнделәр, Василий Терентьевич сезгә әйтергә кушты: пикник оештырудагы чыгымнарны ул тулысы белән үз өстенә ала, — дип, яңа хәбәр таратып йөрде Свежевский, бер төркем кешеләр янынан икенче төркем янына йөгерә-йөгерә. — Әфәнделәр, Василий Терентьевич барлык чакырылган кунакларга әйтергә кушты...

Тиздән аны зур бер төркем чолгап алды. Свежевский аларга яңабаштан аңлатырга кереште:

— Василий Терентьевич безнең җәмәгатьчелекнең кунакчыл каршылавына бик канәгать булган. Шуңа күрә ул яхшылык белән җавап кайтарырга тели. Ул бөтен чыгымнарны үз өстенә ала...

Һәм, лакейны хуҗасының юмартлыгы белән мактанырга мәҗбүр итә торган бер хискә буйсынып, эре генә өстәп куйды:

— Без бу пикникка өч мең дә биш йөз туксан сум акча тоттык!

— Қвашнин әфәнде белән икегезгә урталай бүлепме? — дип сорады кемдер арттан зәһәрле тавыш белән.

Свежевский тиз генә артына борылып карады һәм бу

зәһәр сорауны бирүченең Андреа икәнлеген күреп алды. Андреа, ике кулын чалбар кесәләренә батырып тыккан килеш, бернигә исе китмәгән кыяфәттә Свежевскийга карап тора иде.

— Сез ни дидегез? — дип сорады Свежевский, колагына кадәр кызарынып.

— Мин димәдем, сез дидегез: «Без өч мең дә фәләнфәлән сум акча тоттык», — дидегез. «Без» дигәч, бу сүз астында сез Квашнин эфәнде белән үзегезне күздә тотасыздыр дип уйлый аламдыр ич. Әгәр алай икән, мин сезгә шуны әйтергә тиешлемен: Квашнин эфәнденең ярдәмен кабул итсәм дә, Свежевский эфәнденең андый ярдәменә мохтаҗ булмавым да мөмкин бит минем...

— Аһ, юк, юк... Сез мине дөрес аңламагансыз, — дип акланырга тотынды мәсхәрәгә калган Свежевский. — Бөтенесе Василий Терентьевич тарафыннан эшләнде. Мин болай гына... аның ышанычлы бер вәкиле буларак кына әйтәм... Приказчик кебегрәк дип әйтимме, — диде ул аннары, чытык кына елмаеп.

Махсус поезд бирелүгә үк вокзал каршына Квашнин, Шелковников һәм Зиненколар утырган коляскалар килеп туктады. Ләкин Василий Терентьевич коляскасыннан төшеп өлгермәде, шул вакыт һич уйламаганда көлке катыш аянычлы бер хәл булып алды. Әле иртәнге якта ук, пикник буласын ишетеп, вокзалга завод эшчеләренең хатыннары һәм аналары, сеңелләре һәм апалары җыела башлаган иде. Арада имчәк бала күтәргәннәре дә шактый. Җилдә, кояшта янып каралган, сулган йөзле бу хатыннар, вокзалның күләгәле стена буйларыннан һәм баскыч басмаларыннан урын алып, инде берничә сәгать буе сабыр гына кемнеңдер килүен көтеп утыралар иде. Алар барысы бергә ике йөздән артык кеше иде. Станция түрәләренең сорашуларына каршы хатыннар: «Безгә җирән чәчле юан начальник кирәк», — дип кенә җавап бирделәр. Сторож аларны куалап таратырга теләгән иде дә, бик каты шау-шу купкач, кул селтәде һәм аларга бүтән бәйләнеп маташмады.

Вокзал янына экипаж килеп туктаган саен, хатыннар арасында ыгы-зыгы куба, ләкин килүченең «җирән чәчле юан начальник» түгеллеген күргәч, алар шундук яңадан тынычланып калалар иде.

Василий Терентьевич, кузлага куллары белән тотынып, уфылдый-уфылдый, бер якка янтайган коляскадан әкрен генә төшә башлады. Ләкин ул җиргә аяк басып өлгермәде, аның каршысында кинәт хатыннар сафы калкып чыкты да чиный-чиный җиргә тезләнде. Ярсулы яшь атлар, кисәк

купкан бу шау-шудан өркеп, як-якка ыргылдылар; артка ята төшеп, бар көченә дилбегәне тартып тоткан кучер атларны чак-чак кына тыеп торды. Квашнин беравык берни аңышмады: хатыннар һәммәсе берьюлы кычкыралар һәм аңа таба имчәк балаларын сузганнар. Кара-кучкыл йөзләре исә күз яшенә чыланган иде...

Бу тере балдак эченнән ычкынып булмасын Квашнин, ниһаять, аңлап алды. Күк күкрәгәндәй калын тавыш белән бөтен чыр-чуны күмеп:

— Хатыннар, сабыр итегез. Шауламагыз! — дип кычкырды. — Базардагы кебек бөтенегез берьюлы акырасыз. Берни дә ишетелми. Берегез генә сөйләгез: ни булды?

Ләкин һәркайсының да сөйлисе килә иде. Тавыш тагын да көчәя төште, күзләр яшькә тагын да күбрәк чыланды.

— Туйдыручыбыз... атакаебыз... син безне кайгырт инде... Түзәр хәл юк... Коры сөяккә калдык!.. Үлем якадан тотты... сабыйларыбыз белән бергә үләбез... Салкын тәмам үзәкләребезгә үтте!

— Ни кирәк соң сезгә? Ни сәбәптән үләсез? — дип кычкырды Квашнин тагын. — Барыгыз беравыздан акырмагыз әле! Йә, менә син, сеңел, сөйлә әле, — диде ул, сулган йөзле, ләкин шулай да шактый чибәр күренгән озын буйлы бер яшь хатынга бармагы белән төртеп күрсәтеп. — Бүтәннәрегез дәшмәсен!

Күбесе, яшьле күз һәм лычкылдык борыннарын керле күлмәк итәге белән сөртколап, әле һаман сулкылдый-сулкылдый елавын дәвам итсә дә, тавыш туктагандай булды.

Шулай булса да егермеләп хатын берьюлы сөйли иде.

— Катып үләбез, салкыннан катып үләбез, атакай... Син инде рәхим-шәфкать ит, ничек тә бу бәладән коткар безне... Башка һич түзәр чамабыз калмады... Кышка каршы безне баракларга кертеп тутырдылар, анда ничек яшәмәк кирәк? Барак дисәң хәтере калыр, стеналары чырадан салынган шикелле... Индедән үк төннәрен теш тешкә тими... суык җәфалый... Ә кышын нишләрбез? Хет ичмасам сабыйларыбызны кызган, ярдәм ит безгә, мич кенә булса да чыгарт... Аннары пешерә алмыйча газап чигәбез... Ишегалда пешеренәбез... Ирләребез көнозын эштә... Туңып, лачма су булып кайталар... Кайткач киптереннер урын да юк.

Квашнин тозакка эләккән иде. Ул әле монда, әле тегендә ташланды, әмма һәркайда аның юлына җирдә аунаган яисә тезләнеп баскан хатыннар сафы аркылы төште. Ул шушы тере балдакны ерып үтмәкче булып караган иде дә, аякларына асылынып һәм соры пальтосының озын итәгеннән тартып аны янәдән туктаттылар. Ахырда тәмам гаҗиз

булган Кәшнин кулы белән ымлап үз янына Шелковниковны чакырды һәм, тегесе тыгыз сафны аралый-ера уртага узгач, французчалатып аңа җикеренде:

— Сез ишеттегезме? Ни дигән сүз бу?

Шелковников, аптыраган төстә кулларын җәеп, аклануга тотынды:

— Идарәгә яздым, җиткездем... эшче куллар юк... җәй вакыты... печән өсте... кыйммәтчелек... идарә рөхсәт итмәде... бернишләп булмый...

— Эшчеләрнең бараклары кайчан төзәтергә уйлыйсыз? — дип сорады Кәшнин, ачуланып.

— Аныкбилгеле түгел... Әлегә түзәргә туры килмәгәе... Безгә иң элек завод хезмәткәрләре өчен торак йортларын ашыктырырга кирәк.

— Шайтан белсен, ниләр эшләнәдер сезнең монда, — дип мыгырданды Кәшнин. Һәм, янә хатын-кыз төркеменә таба борылып, кычкырып әйтте: — Хатыннар, тыңлагыз! Иртәгедән башлап сезгә мичләр чыгарта башларлар, бараклары гызны такта белән тышлатырлар. Ишеттегезме?

— Ишеттек, атакай... Рәхмәт сиңа... Ничек инде ишетмәскә, — дигән шат тавышлар яңгырады. — Нәчәлник үзе әйткәч, булмый калмас, алла боерса... рәхмәт сиңа... Син инде, атакай, безгә төзелештән йомычка җыярга да рөхсәт ит.

— Яхшы, яхшы, йомычка җыярга да рөхсәт.

— Юкса, һәр почмак саен чиркәс бастырып куйганнар... Йомычка дип бардың исә, камчысы белән сыпырып алырга гына тора...

— Ярар, ярар... йомычка җыярга курыкмыйча йөрегез, сезгә беркем дә тимәс, — диде Кәшнин, аларны тынычландырып. — Ә хәзер, хатыннар, барыгыз, өйләрегезгә таралышыгыз да ашыгызны пешерегез! Ягез, тизрәк булыгыз, юкса мин сезне! — дип, егетләрчә дәртле тавыш белән шаяртыбрак кычкырды ул. Аннары, Шелковниковка таба борылды да, ярым пышылдап: — Ә сез иртәгә бараклар янына бер-ике йөк кирпеч китертеп куярга кушыгыз... Әйдә, юана торсыннар. Ул юаныч аларга бик озакка җитәр, — дип өстәде.

Хатыннар куанышып тарала башладылар.

Бая Кәшнин барысы исеменнән сөйләргә кушкан теге яшь, чибәр хатын, чытлыкланыбрак:

— Кара аны, эгәр мич чыгарттырмасаң, җылытырга без синең анженерларыңны чакырачакбыз, — дип кычкырды.

— Катып үликмени, — дип өстәде икенче бер шугы. —

Генерал үзе җылытса да сүз юк. Әнә, нинди юан, симез... Аның кочагы мич башыннан да җылырактыр әле.

Ахыры яхшы тәмамланган бу вакыйга һәммә кешенең күңелен күтәреп җибәрде. Моңарчы директорга күзен-кашын җимереп караган Квашнин үзе дә, хатын-кызларның шаяртулы сүзләрен ишеткәч, канәгать бер төстә көлеп-елмаеп куйды һәм Шелковниковны дусларча терсәгеннән алды.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, кадерлем, — дип сөйләнде ул, аякларын көчкә атлый-атлый, директор белән бергә станция баскычыннан югары күтәрелгәндә: — бу халык белән аңлаша белергә кирәк, аңлаша белергә. Сез аларга теләсә нәрсә вәгъдә итә аласыз — алюминнән салынган торак йортмы ул, сигез сәгатьлек эш көнеме, иртән табынга куелачак бифштексмы — һәммәсен дә. Тик моңа аларны ышандыра гына белегез. Ант итеп әйтәм: мин, шундый коры вәгъдәләр белән юатып, ун-унбиш минут эчендә теләсә нинди халык кузгалышын сүндерә алам...

Әле генә сүндерелгән хатын-кыз фетнәсен бөтен вагытөягенәчә янә бер кат күңеленнән кичереп, Квашнин шаркылдап көлә-көлә вагонга кереп утырды. Ике-өч минуттан поезд станциядән кузгалып китте. Өйгә кайтканда факеллар яндырып атта кайту күздә тотылганлыктан, кучерларга турыдан-туры Котырган елгага барырга кушылды.

Нинаның үз-үзен тотышы Андрей Ильичны тәмам аптырашта калдырган иде. Кызның станциягә килүен ул әле кичә үк үзендә кабынган дәртле бер ашкыну белән көтеп алды. Күңелдәге шик-шөбһәләрнең әсәре дә калмаган; бәхет бөтенләй янәшәдә генә кебек, дөнья моңарчы һичкайчан булмаганча матур, гүзәл; кешеләре дә искиткеч яхшы, миһербанлы, тормышы да шундый җиңел, шатлыклы тоела иде. Нина белән күңелле очрашу турында хыялланып, ул инде аны бөтен килеше-килбәте белән күз алдына китергән, аңа әйтәсе ялкынлы мәхәббәт һәм иркәләү сүзләрен алдан ук уйлап, әзерләп куйган иде. Соңыннан хәтта аның үзенә дә бу көлке тоелды... Нигә, янәсе, ниндидер мәхәббәт сүзләре эзләп, алдан ук баш катырырга? Кирәге чыккач, ул сүзләр үзеннән-үзе табылыр һәм алдан уйлап куйганга караганда да матуррак, кайнаррак булыр. Шул чакта Бобров кайсыдыр журналда укыган бер шигырьне хәтергә төшергән иде. Шагыйрь анда үзенең сөеклесенә әйтә, бер-береңә ант итәргә кирәкми, чөнки ант итүләр ике арадагы кайнар һәм саф мәхәббәтне кимсетә генә, ди.

Квашнин тройкасы белән Зиненколар утырган ике колясканың бер-бер артлы тезелешеп станциягә килеп тукта-

вын Бобров вокзал баскычы башыннан күзәтеп торды. Нина коляскаларның беренчесендә утыра иде. Башындагы киң читле ак итальян эшләпәсенә чәй розасы кадап, өстенә ярым түгәрәк изүле сыек төстәге матур челтәр каюлы юка сары күлмәк кигән Нина Бобровка гадәттәгегә караганда да агарынганрак һәм җитдиләнә төшкәнрәк кыяфәттә күренде. Бобровны ул ерактан ук таныды, ләкин, егет көткәнчә, аңа таба гадәттәгечә озак һәм серле итеп карап тормады. Киресенчә, күз карашын ул юри читкә алган шикелле тоелды. Андрей Ильич, кызга коляскадан төшәргә булышыйм дип, аның каршына йөгергән иде дә, Нина, гүя очрашырга теләмәгәндәй, экипажның икенче ягыннан тиз генә җиргә сикереп төште. Ниндидер усал, яман бер тойгыдан Андрей Ильичның йөрәге чәнчеп куйды, ләкин шундук ул үзен тынычландырырга ашыкты. «Бичаракай, үз гыйшкыннан ояла. Күз карашыннан күңелендәге иң яшерен серләрен укып белмәгәйләре дип курка... Йә хода, нинди самими, гүзәл беркатлылык!»

Андрей Ильич, вокзалда теге юлы очрашкандагы кебек, ничек тә җае табылыр да кара-каршы берничә сүз әйтешеп алу өчен Нина үзе аның янына килер дип өмет иткән иде. Ләкин кыз, Квашнин белән фетнәче хатыннар гаугасын кызыграк күреп, ахрысы, Бобров янына килергә ашыкмады... Ул хәтта аның ягына таба күтәрелеп тә карамады. Андрей Ильичның йөрәге кинәт шом һәм сагыш белән тибәргә тотынды. Ул Зиненколар гаиләсе янына барырга һәм, гомуми шау-шудан файдаланып, сүз беләнме яисә күз карашы беләнме, Нинадан аның ни өчен шундый игътибарсыз булуының сәбәбен сорарга теләде. Зиненколар, күрәсең, башка ханымнар үзләреннән читләшкәнгә, бөтенләй аерым рәвештә бер читтә басып торалар иде.

Анна Афанасьевна белән кулын үбеп исәнләшкәннән соң, Бобров аның йөзенә караштыргалап, анда үзенең шикшөбһәләренә җавап булырдай нәрсә күрергә тырышты. Әйе, әни кеше һичшиксез барысын да белә: аның кәкре почмак ясап сынган нәзек кашлары (кашның нәзеклеген Бобров еш кына ялганчылык билгесе ди иде) усалланып җыерылган, ә иреннәрендә тәкәбберлек чагыла. «Димәк, Нина аңа бөтенесен дә сөйләгән һәм шелтә алган», — дип уйлады Бобров һәм кызның янына килеп басты.

Әмма Нина аңа күтәрелеп тә карамады. Күрешкән чакта Андрей Ильич үзенең калтыраган учында бер хәрәкәтсез яткан салкын кулны гына тойды. Бобровның сәламенә җавап кайтарасы урында Нина Бетага таба башын борды да аның белән ниндидер юк-бар сүз сөйләшеп алды... Бу

ашыгыч маневрда туры җавап бирүдән качарга тырышу, куркаклык, гаеплелек бар шикелле иде. Андрей Ильич кисәк кенә үзенең авыз эче салкынаеп, аяклары хәлсезләнеп китүен сизде. Ул ни дип уйларга да белмәде. Гәрчә Нина Әнисенә бөтенесен сөйләгән булса да, ул аңа, Бобровка, моны белгертә алыр иде ич. Моның өчен күп тә кирәкми бит, һәммә хатын-кызга хас табигый осталык белән мәгънәле бер күз карашы ташлап алу да җитә. «Әйе, син дөрес сизенгәнсең, безнең сөйләшүне беләләр... ләкин мин үзем һич үзгәрмәдем, сөеклем, мин һаман әүвәлгечә, борчылма», — дисен иде. Ә ул әнә күтәрелеп тә карамый, башын читкә бора. «Пикникта мин барыбер аңардан җавап алачакмын, — дип уйлады Бобров, сагышланып, ниндидер авыр һәм әшәке бер күңелсезлек буласын тоеп. — Алаймы, болаймы, ул барыбер миңа җавап бирергә тиеш».

X

303 нче чакрым тукталышында сәйранчылар вагоннардан чыктылар һәм чуар озын бер сафка тезелеп, каравылчы алачыгы яныннан үттеләр дә Котырган елгага илтә торган тар юлдан түбән төшә башладылар... Кайнарланган йөзләргә ерактан ук көзге урманның җиләс саф һавасы һәм хуш исе килеп бәрелде. Юл һаман текәләнә барды-барды да гөмбәз сыман бер-беренә тоташып үскән зелпе һәм чикләвек куаклары арасына килеп керде. Аяк астында тәмам кипшереп, бөтерелеп беткән сары яфраклар кыштырдый; куе куаклар аркылы еракта кичке шәфәкъ алсуланып күренә иде.

Менә куаклык артта калды. Күз алдында кинәт һәр яктан урман белән чолгап алынган һәм вак ком сибелеп тапталган зур гына бер ачыклык пәйда булды. Аның бер очында әләм һәм яшел ботаклар белән бизәлгән сигез почмаклы павильон, ә каршы як башында музыкантлар өчен төзелгән өсте каплаулы ачык эстрада тора иде. Беренче кунаклар куаклык арасыннан килеп чыгуга, гаскәриләр оркестры эстрададан күңелле марш уйнап җибәрде. Җиз быргыларның дәртле, матур моңы, уйнаклап һәм агач кәүсәләренә бәрелә-сугыла чыңлап, урманга таралды да кайдадыр еракта яңгыраган икенче бер оркестр тавышына барып кушылды. Бу икенче оркестр дигәне, бер үк көйне көйләп, беренче оркестр тавышын әле узып китә, әле аңардан артта калып ишетелә шикелле иде. Сигез почмаклы павильонда исә, өр-яңа ак эскәтерләр ябып, буйдан-буйга те-

зеп куелган өстәлләр тирәсендә, савыт-саба шалтыратып, хезмәтче кызлар тыз-быз йөренә иде.

Музыкантлар марш уйнап бетергәч, кунаклар һәммәсе гөрләтеп кул чапты. Алар чын мәгънәсендә хәйран калган иде. Хәйран калырлык та иде шул, чөнки бер-ике атна элек кенә бу урман аланында анда-санда үсеп утырган сирәк куаклардан башка бүтән берни юк иде.

Оркестр вальс уйный башлады.

Свежевский үзенең янәшәсендә басып торган Нинаны чакырусыз-нисез биленнән эләктереп алды да вальс көенә әйләндерә-әйләндерә мәйданчык буенча биеп китте. Бобров исә бер читтә аларны күзәтеп торды.

Свежевский биеп бетерүгә, Нина янына тау институты студенты йөгереп килде, аннары аны тагын кемдер чакырды. Бобров үзе начар бии һәм биергә бик үк яратып та бетерми иде. Шулай да хәзер аның күңеленә Нинаны кадриль биергә чакырыйммы әллә дигән бер уй килде. «Бәлкем, шунда сөйләшергә, аңлашырга да берәр җай чыгар», — дип уйлады ул. Һәм Нина ике тур биюдән туктап, уттай янган битенә җилпәзәсе белән җилпи-җилпи, урынында хәл җыеп утырган арада, Бобров аның янына килеп басты.

— Нина Григорьевна, бер кадрильне сез, шәт, минем өчен дә калдыргансыздыр дип уйлыйм? — диде ул.

— Ah аллам... Нинди үкенеч! Бер генә буш кадрилем дә калмаган икән ләбаса, — диде Нина, күзләрен читкә юнәлтеп.

— Чынлап тамы? Ничек шулай бик тиз таратып бетердегез? — дип сорады Бобров төшенке тавыш белән.

— Таратылган икән шул, — диде Нина, көлемсерәп һәм җилкәләрен сикертеп куйды. — Нигә болай соңардыгыз соң? Кадрильләремне мин әле вагонда чакта ук өләшеп бетердем...

— Сез, димәк, мине бөтенләй оныткансыз! — диде Бобров, тәмам күңеле сүрелеп.

Аның сүрән тавышы Нинага тәэсир итте булса кирәк. Ул тынычсызланып җилпәзәсен бер җыйды, бер җәйде, ләкин Бобровка күтәрелеп карамады.

— Сез үзегез гаепле. Ник минем янга элегрәк килмәдегез?..

— Пикникка чыгуым да бары сезнең өчен генә иде бит минем... Бу шулай шаярту гына булдымыни соң, Нина Григорьевна?

Кыз аптырап калды һәм, ни әйтергә белмичә, җилпәзәсе белән уйнарга кереште. Яшь бер инженерның каршыга килеп басуы гына аны уңайсыз хәлдән коткарды. Нина,

тиз генә аягүрә торып, озын ак перчаткалы нәзек кулын инженерның иңбашына салды. Андрей Ильич күзен алмый аларның биегәнен күзәтә башлады... Бер тур беткәч, Нина янә хәл җыярга туктады. Әмма бу юлы, Бобров белән очрашасы килмәгәндәй, мәйданчыкның бөтенләй икенче башына барып утырды. Әллә инде күренергә курка, әллә оялa иде ул.

Андрей Ильичны яңадан элеккеге вакытларда була торган сүлпән һәм дәртсез бер сагыш биләп алды. Һәммә кеше аңа кинәт кенә кызганыч, җирәнгеч һәм хәтта көлке булып тоела башлады. Салмак агышлы музыка тавышы да берөзлексез колагында чыңлап, күңелдәге әүвәлге җәрәхәтләрне кузгатты. Ләкин шуңа да карамастан, ул өметен бөтенләй өзмәде, төрлечә юрап-чамалап үз-үзен юатырга тырышты. «Чәчәк бүләк итеп җибәрмәгәнем өчен үпкәлиме икән әллә? — дип уйлады ул. — Әллә, югыйсә, миндәй шыксыз кеше белән бинсе килмиме? Шулайдыр! Ни дим, бәлки ул хаклыдыр. Кызлар өчен андый вак-төякнең дә әһәмияте бар бит... Аларның бөтен шатлыгы, кайгысы, гормыш рәхәте шул вак-төяк нәрсәләргә бәйле түгелмени?»

Эңгер-меңгер куера башлагач, павильон тирәли чуарлап тезеп чыккан кытай фонарьларына ут кабыздылар. Ләкин фонарьлардан төшкән якты җитәрлек түгел иде: мәйданчык бөтенләй диярлек караңгыда кала бирде. Кинәт шул вакыт аланның баш-башындагы агачлар куелыгына күзгә күренмәслек итеп яшерелгән ике электр кояшы кабынып китте дә бөтен тирә-юньне зәңгәрсу якты нурга коендырды. Мәйданчык тирәли үскән каен һәм өянкеләр, гүя, каяндыр караңгыдан дәррәү генә калкып чыктылар. Аларның хәрәкәтсез тынып калган бөдрә ботаклары күз алдагыч электр нурында театр сәхнәсенең алгы планындагы декорацияне хәтерләтә иде. Каен, өянкеләр артында исә, дөм-караңгы күк йөзе фонында ниндидер түгәрәк һәм киртләч сыртлы соргылт-яшел таплар рәвешенә кереп, урман агачларының биек ябалдашлары төсмерләнеп күренде. Ул арада, музыка белән аралашып, даладан чикерткәләр сайравы ишетелде. Чикерткәләр шундый бердәм тавыш белән, шундый серле һәм каты итеп кычкыралар иде ки, әйтерсең лә алар күбәү түгел, ә бер генә бөртек; әмма бу бер бөртек дигән чикерткәнең җыры уңнан да, сулдан да һәм хәтта югарыдан да — һәр тарафтан ишетелә иде.

Мәҗлес кызганнан-кыза, шау-шулана барды. Бер танец бетүгә шундук икенчесе башланды. Оркестр бөтенләй диярлек ялсыз уйнады. Әкияттәгедәй бу хозурлык һәм моңлы музыка хатын-кызга тәмам исерткеч тәэсир ясады.

Дала ягыннан таралган әрем исе, урман дымы, шиңгән яфрак һәм кайдадыр ерак болыннан килгән курпы исе сәер рәвештә хушбуй һәм кайнар тән исе белән бергә кушылды. Күтәрелеп очып китәргә талпынган асыл кошларның чуар канатлары сыман, һәр җирдә әле кызу, әле әкрен генә чайкалып җилпәзәләр тирбәлде... Кычкырып сөйләшү, көлү, комлы җир өстеннән кыштырдый-кыштырдый шуышкан аяк тавышлары — һәммәсе бергә буталып, бертөрле тоташ, күңелле гүелдәү булып ишетелә; музыка тынып торган араларда бу гүелдәү аеруча бер көч белән яңгырый иде.

Бобров күзен алмый һаман Нинаны күзәтте. Бермеикеме тапкыр кыз аңа күлмәк итәге белән бәрелеп уза язды. Ул яннан үтеп киткәндә Бобровка хәтта җиңелчә генә җил дә исеп куйгандай булды. Биегәндә кыз сул кулын ниндидер нәзакәтле бер хәлсезлек белән сыгылдырып кавалерының иңбашына сала, ә башын егеткә таба шулкадәр яктайта, әйтерсең лә аның җилкәсенә сыенып ял итәргә тели иде... Кайчакны җилфердәгән итәге астыннан аның кара төстәге оек кигән тулы, нәфис аяк балтырлары һәм эчке күлмәгенең челтәрле очы күренеп китә. Андый чакта Бобров ирексездән кызарынып куя һәм Нинаны бу рәвешендә күргән барлык кешеләргә карата күңелендә ачу кабара башлавын тоя иде.

Оркестр мазурка уйнарга кереште. Вакыт кичке тугызлар чамасы иде инде. Свежевский белән биергә чыккан Нина үз кавалерының мазуркага дирижерлык итә-итә ниндидер үтә катлаулы фигура ясаган вакытын чамалады да, бии-бии бер читкә тайпылды һәм, тузгыган чәчләрен ике кулы белән җыеп тотып, йөгерә-чаба киенү бүлмәсенә ашыкты. Мәйданчыкның икенче башыннан барысын да күзәтеп торган Бобров шундук аның артыннан иярде һәм кыз кереп киткән ишек төбенә килеп басты... Әйләнә-тирә шактый караңгы; павильонның арткы стенасына сөяп юка тактадан эшләнгән кечкенә генә киенү бүлмәсе бөтенләй диярлек күләгәдә утыра иде. Бобров Нина чыкканчы ишек төбендә көтеп торырга һәм ничек кенә булса да аны сөйләштерергә карар кылды. Аның чәнчеп-чәнчеп авырткан йөрәге дөп-дөп тибә, чытырдатып йомарланган бармаклары дымлы һәм салкын иде.

Бер биш-алты минуттан соң бүлмә ишеге ачылып китте. Бобров шундук күләгә астыннан чыгып, Нинаның юлына аркылы төште. Кыз, өркеп, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән кычкырып куйды һәм артка чигенде.

— Нина Григорьевна, нигә сез мине шулай газаплыйсыз? — диде Андрей Ильич, үзе дә сизмәстән кулларын ял-

варулы төстә бер-берсенә кушырып. — Миңа ничек авыр икәнен сез белергә дә теләмисез. О! Минем шулай газап чигүем сезгә кызыклы бер тамаша гына, ахры... Сез миннән көләсез...

— Ни кирәктер сезгә, һич аңламыйм. Минем сездән көләргә уйлаганым да юк, — диде Нина, тавышына масаюлы катгый бер аһәң биреп.

Аңарда хәзер үз гаиләсенең тәкәбберлеге уянган иде.

— Юк дисезме? — дип сорады Бобров моңсу гына. — Алайса бүгенге мөгамәләгез нәрсә аңлата соң?

— Нинди мөгамәләм?

— Сез миңа бүген бик салкын, бөтенләй дошманнарча карыйсыз кебек. Миннән гел качарга тырышасыз... Сезгә хәтта минем монда — кичәдә булуым да ошамый шикелле...

— Миңа барыбер...

— Анысы инде бигрәк тә начар... Мин сездә минем өчен бөтенләй аңлаешсыз ниндидер коточкыч үзгәреш сизәм... Нина, зинһар, бернәрсәне дә яшермәгез, ачыктан-ачык әйтегез, моңарчы мин уйлаган туры сүзле Нина булыгыз... Хакыйкать ниқадәр генә коточкыч булса да, дөресен әйтегез. Бөтенесен берьюлы өзсәк, сезнең өчен дә, минем өчен дә яхшырак булыр...

— Нәрсәне өзсәк? Мин сезне аңламыйм...

Бобров кан тамырлары бүртеп чыккан чигәләрен куллары белән кысып тотты.

— Юк, сез аңлыйсыз. Тик хәзер генә аңламаган булып кыланасыз. Безнең арада өзәрдәй нәрсәләр бар. Безнең арада ачыктан-ачык диярлек шактый җылы, иркә сүзләр сөйләнде, бер-беребезне үзара якынайткан, ниндидер нәзакәтле, нечкә җепләр белән бәйләгән кадерле, күңелле минутлар булып узды... Беләм, сез мине ялгыша дип әйтергә телисез... Бәлкем, шулайдыр, мин чыннан да ялгышамдыр... Ләкин сез үзегез бит, икәүдән-икәү генә сөйләшергә мөмкинлек булсын дип, мине монда пикникка чакырдыгыз. Шулай түгелме әллә?

Нина Бобровны кызганып куйды.

— Әйе... Пикникка сезне мин үзем чакырдым... — диде ул, башын түбән иеп. — Минем сезгә әйтәсе сүзем бар иде... Мин сезгә... бөтенләй хушлашырга кирәк дип әйтергә теләгән идем.

Бобров, кемдер күкрәгенә китереп төрткәндәй, кинәт чайкалып китте. Хәтта караңгыда да аның бик нык агарынганлыгы сизелде.

— Хушлашырга... — диде ул, сулышына буылып. — Ни-

на Григорьевна!.. Хушлашу сүзе бик авыр, бик ачы сүз... Әйтмәгез ул сүзне...

— Мин аны әйтергә тиеш.

— Тиеш?

— Әйе, тиеш. Бу минем ихтыярым түгел.

— Кем ихтыяры соң?

Аларга таба кемдер якынлашып килә иде. Нина караңгыга күзен текәп торды-торды да әкрен генә:

— Әнә кем ихтыяры ул, — дип пышылдады.

Алар янына килүче кеше Анна Афанасьевна иде. Ул Бобров белән Нинага таба җентекле күз карашы ташлап алды да, кызын култыклап, шелтә белдергәндәй кырыс тавыш белән:

— Нина, нигә син алай танцыны ташлап киттең? — диде. — Кайдыр караңгыда юк-бар сүз лыгырдап торасың... Бик шәп эш, әйтәсе дә түгел... Ә мин сине дөнья бетереп эзләп йөрим... — Аннары кинәт кенә Бобровка таба борылып, ачу белән кычкырып өстәде: — Ә сез, хөрмәтле әфәндем, әгәр инде бии белмисез яки биергә яратмыйсыз икән, ичмасам туташларга биергә комачауламас идегез. Юкса, монда караңгыга кереп поскансыз да, tête-á-tête... [1] сөйләшеп, кыз кешенең абруен төшерәсез...

Анна Афанасьевна Нинаны, өстәп дигәндәй, үз артыннан ияртеп алып китте.

Бобров аларның артыннан:

— О! Борчылмагыз, ханым: кызыгызның абруен бернәрсә дә төшерә алмас! — дип кычкырып калды һәм кинәт ачыну, сәер көлү белән шаркылдап көләргә тотынды, моны ишетеп әни кеше дә, аның кызы да ихтыярсыздан борылып карарга мәҗбүр булдылар.

— Бу кеше үзе аңгыра, үзе тәрбиясез дип әйтмәдемме мин сиңа? — диде Анна Афанасьевна, кызының җиңеннән өстәп. — Хет аның күзенә төкер — барыбер көлә бирә... шатлана бирә... Хәзер кавалерларны дамалар үзләре сайлаячак, — дип өстәде ул аннары тынычрак тавыш белән. — Бар, Квашнинны биергә чакыр. Күрәсеңме әнә, беседка ишеге төбендә басып тора.

— Әнием! Карале, ул ничек биесен икән? Гәүдәсен дә, көчкә-көчкә генә өстәп йөри ич.

— Әйттемме мин сиңа, бар дип. Исең китмәсен: кайчандыр ул Мәскәүдә иң оста биючеләрдән булган... Һәрхәлдә, синең чакыруың аны куандырачак кына.

Бобровка бөтенесе дә, гүя, бик ерактан — тирбәлеп тор-

[1] tête-á-tête — аулакта.

ган соргылт томан эченнән күренгәндәй булды: Нина йөгерек, җиңел адымнар белән мәйданчык аша йөгереп узды да, чытлыклану-үтенү катыш мәһабәт бер кыяфәттә башын яитайтарак төшеп, көлә-елмая Квашнин каршысына килеп басты. Василий Терентьевич чак-чак кына иелеп аны тыңлап торды; кинәт ул, бөтен юан гәүдәсе белән калтыранып, шаркылдап көлеп җибәрде һәм башын чайкады. Нина яңадан нәрсәдер аңлатырга тотынды, тик тыңлата алмады булса кирәк, үпкәләгән төсле, чытлыкланып, кире борылды да китеп барды. Ләкин Квашнин, үзенә хас булмаган җиңеллек белән урыныннан кузгалып, Нинаны куып җитте һәм: «Ярар, нишләмәк кирәк... Сабыйлар теләгенә каршы килеп булмас», — дигәндәй бер кыяфәт белән иңбашын җыерды да кызга кулын сузды. Биючеләр, һәммәсе дә туктап, яңа парга кызыксынып карап тора башладылар. Квашнинның мазурка биюе барысы өчен дә көлкеле бер тамаша булыр шикелле тоела иде.

Василий Терентьевич беравык көйнең кирәкле тактын көтеп торды да кинәт, шактый салынкы, ләкин үзенчә гаять мәһабәт, сөклангыч хәрәкәт ясап, кызга таба борылды һәм беренче паны шундый оста итеп, ышаныч белән башкарды ки, һәммә кеше шундук аның кайчандыр бик яхшы биюче булганлыгын аңлап алды. Башта ул чынлап торып биемәде дә шикелле, җиңелчә көлемсерәү җәелгән горур, тәкәббер йөзен бер яккарак борып һәм Нинага югарыдан күзләрен төбәп, көй уңаена салмак кына тирбәлә-чайкала, әкрен генә йөрде. Озын буе, симезлеге аның йөреш-хәрәкәтен ямьсезләми генә түгел, киресенчә, бу минутта аңа ниндидер бер мәһабәтлек, күркәмлек өсти шикелле иде. Борылышка җиткәч, ул, бер генә секундка туктап, үкчәсен үкчәгә бәрде һәм кинәт Нинаны бер урында зыр-зыр әйләндерергә тотынды, аннары, йөзенә тагын да мәрхәмәтлерәк елмаю чыгарып, юан аякларында бөгелә-сыгыла биеп, аны мәйданчык аша киргә алып китте. Үзләре биергә чыккан җиргә җитәрәк, ул Нинаны янә бер мәртәбә зыр-зыр әйләндереп торды һәм, урынына утыртып, аның каршысына басты да рәхмәт белдереп башын иде.

Аны шундук дамалар чолгап алды. Алар аның тагын бер тур әйләнеп килүен үтенделәр. Ләкин юан, симез Квашнинга инде болай да бик җиткән — ул авыр-авыр тын ала һәм әлсерәгән йөзен яулыгы белән җилпи иде.

— Җитәр, mesdames... карт кешене кызганыгыз, — диде ул, көлеп һәм көчкә-көчкә тын алып. — Минем яшьтә нинди бию ди ул. Табынга утырсак яхшырак булыр...

Кунаклар, урындыкларны дөбер-шатыр күчергәләп,

өстәл тирәли утырыша башладылар... Бобров әле булса баягынак үзен Нина ташлап киткән урында басып тора иде. Аның йөрәген берөзлексез әле кимсенү, үпкә хисе телгәләде, әле аяныч лы, өметсез сагыш корты кимерде. Яшьсез булса да, аның күзләрен нидидер бик ачы нәрсә яндыра, ә тамагына, сулышын буып, чәнечкеле, коры бер төер тыгыла иде... Музыка исә, эчпошыргыч бертөрле һәм моңлы тавыш белән әүвәлгечә җанны әрнетеп, һаман колак төбендә чыңлап торды.

Шул вакыт Андрей Ильич үзенең янәшәсендә генә докторның шат тавышын ишетте:

— Атакай гынам! Ә мин сезне җан тиргә батып эзлим, һич таба алмыйм. Кая китеп югалдыгыз соң сез? Ә мине менә килеп җитүемә үк карта уйнарга утырттылар, көчкә ычкындым... Әйдәгез, ашарга киттек. Мин анда ике урын алып куйдым, бергә утырырга дип...

— Ah, доктор! Сез инде үзегез генә барыгыз. Мин бармыйм, ашыйсым килми, — диде Бобров, көч-хәл белән сүзен әйтеп.

— Бармыйсыз? Менә сиңа әкәмәт! — диде доктор һәм җентекле күз карашын Бобровның йөзенә юнәлтте. — Тук тагыз әле, тукта, ни булды сезгә? Бөтенләй җебеп төшкәнсез ләбаса, — диде ул, кинәт җитдиләнеп һәм дустының хәленә кереп. — Болай булгач, мин сезне ялгыз гына калдырмыйм да калдырмыйм инде. Әйдәгез, киттек, бернинди сүз булырга мөмкин түгел.

— Кыен миңа, доктор. Коточкыч кыен, — дип, ни сөйләгәнен үзе дә аңламастан, әкрен генә әйтеп куйды Бобров, ләкин үзе күндәм рәвештә Гольдберг артыннан иярде.

— Юк өчен борчылмагыз, кадерлем, киттек әйдә! Ир кеше булыгыз, төкерегез барысына... «Җәфалыймы күңел хастасы? Әллә бармы вөҗдан газабы?..» — дип, көтмәгәндә шигырь такмакларга тотынды доктор һәм Бобровны биленнән кысып кочаклады да аның күзләренә текәлде. — Хәзер мин сезгә һәрбер чир өчен яраклы бер дәва әйтәм: «Эчеп җибәрикме әллә, әй, Ваня, күңелдәге кайгы, салкыннан?..» Без Андреа белән, дөресен генә әйткәндә, шактый коньяк чөмердек инде... Ah, тәмен белеп эчә дә соң, каһәр суккыры! Төпсез мичкәгә агыза диярсең... Ну, ир кеше булыгыз, сөеклем... Беләсезме нәрсә, Андреа сезнең белән бик кызыксына. Әйдәгез киттек, киттек!..

Шул рәвешчә сөйләнә-сөйләнә, Гольдберг Бобровны павильонга таба әйдәде. Алар янәшә утырдылар. Андрей Ильичка икенче яктан күрше булып Андреа туры килде. Бобровны ерактан ук елмаеп каршы алган Андреа, урын

бушатып, аны аркасыннан кага-кага сөйде дә, дустанә тавыш белән:

— Бик шатмын, бик шатмын, әйдәгез безгә якынрак утырыгыз, — диде. — Күркәм кеше сез... яратам шундыйларны... әйбәт кеше... Коньяк эчәсезме?

Андреа исерек иде. Лиың йөзе агарына төшкән, пыяла сыман калку күзләре ничектер сәер рәвештә жанланып, ялт-йолт килә иде (искиткеч сабыр холыклы, эшчән һәм талантлы бу кешенең көн саен берьялгызы аяктан егылганчы эчкәнлеге бары ярты елдан соң гына билгеле булды)...

«Чыннан да, эчсәң жиңелрәк булып китмәс микән, — дип уйлады Бобров, — ни булса булыр, сынап карарга кирәк!»

Андреа, кулындагы шешәне яртайтыбрак тотып, стакан куелганны көтә иде. Бобров үзенең стаканын аңа таба этәрде.

— Шулаймы? — дип сузды Андреа, кашларын югары чөеп.

Бобров та аңа моңсу һәм күндәм елмаю белән:

— Шулай, — дип жавап бирде.

— Яхшы! Күпме салыйм?

— Стакан үзе күрсәтер.

— Бик шәп. Сезне швед флотында хезмәт иткән дип уйларга мөмкин. Житәрме?

— Салыгыз, сал.

— Шулай да сез, дустым, моның V.S.O.P. маркалы Martel икәнлеген истән чыгармагыз. Бик каты, иске, чын коньякларның берсе бу.

— Борчылмагыз, сала бирегез...

«Әйдә, егылганчы бер исерим әле. Карап баксыннар...» — дип уйлады Бобров, мәкерле бер шатлык хисе кичереп.

Стакан мөлдерәмә тулы иде. Андреа шешәне өстәл өстенә кире утыртты да кызыксынып күршесен күзәтә башлады. Бобров коньякны берьюлы авызына каплады һәм, аракы эчәргә гадәтләнмәгән кешеләрчә, бөтен гәүдәсе белән чытаеп, калтыранып куйды.

— Корт кимерәме әллә сезне, балакаем? — дип сорады Андреа, Бобровның күзләренә текәлеп.

— Әйе шул, корт кимерә, — диде Андрей Ильич, моңсу гына баш кагып.

— Йөрәктәме?

— Әйе.

— Һм!.. Алайса сезгә әле тагын салырга кирәктер?

— Салыгыз, — диде Бобров күндәм һәм моңсу тавыш белән.

Ул, үз-үзен онытырга тырышып. йотыла-какала коньяк чөмерде. Ләкин гаҗәп хәл: эчүнең аңа бернинди тәэсире сизелми иде. Киресенчә, күбрәк эчкән саен ул күңелсезләнә генә барды, ә ачы яшь күзләрен тагын да зәһәррәк яндырды.

Ул арада хезмәтчеләр табынга шампанский китерделәр. Квашнин, ике бармагы белән үзенең бокалын тотып һәм бокал аша югарыдагы канделябр утына карап, урыныннан торып басты. Һәммәсе тынып калды. Бары электр фонарьларында чырт-чырт итеп күмер янганы һәм тирәякта чырылдап-чырылдап тынгысыз чикерткә сайраганы гына ишетелә иде.

Квашнин беравык йөткереп торды да:

— Могтәбәр ханымнар һәм могтәбәр әфәнделәр! — дип сүзен башлады, аннары тагын шактый озак тынып торды. — Бу бокалны минем сезгә чын күңелдән рәхмәт әйтү теләге белән күтәрүемне берегез дә шик астына алмас дип уйлыйм! Иванковода миңа карата күрсәтелгән ихтирам, кунакчыллыкны мин беркайчан да онытмам, һәм гүзәл дамаларыбызның ризалыгы белән оештырылган бу кечкенә пикник минем күңелдә мәңге матур бер истәлек булып калыр. Сезнең исәнлеккә эчәм, mesdames!

Квашнин бокалын югары күтәрде, һавада ярым түгәрәк ясап әйләндерде дә эчемлектән аз гына авыз иткәч, өзелгән сүзен дәвам итте:

— Хезмәттәш дусларым, иптәшләрем, минем сезгә бер сүзем бар. Әгәр сүзем үгет-нәсихәт төсендәрәк булса, гаеп итмәссез: яшем буенча мин монда күбегездән олырак, картрак кеше, ә карт кешегә үгет-нәсихәт өчен ачуланмаска да мөмкин.

Андреа Бобровның колагына иелде дә:

— Карагыз әле тегеңә, Свежевскийга — кыланышын гына күрегез, — дип пышылдады.

Чыннан да, Свежевскийның йөзенә ачыктан-ачык ялагайлану, үтә зур игътибарлылык галәмәте чыккан иде. Василий Терентьевич үзенең картаюы турында телгә алгач, ул килешмәвен белдереп кулларын бутый-бутый башын чайкарга кереште.

— Газета баш мәкаләләрендә язылa торган иске, таушалган фикер булса да, минем сезгә кабатлап әйтәсем килә, — диде Квашнин, сүзен дәвам итеп: — Байрагыбызны югары тотыгыз, әфәнделәр. Дөньяның тоткасы һәм киләчәгә безнең кулда икәнен онытмагыз... Җир шарын аркы-

лыга да торкылыга тимер юллар белән кем сарып чыкты? Без! Җир карынын актарып, аның хәзинәләрен пушка, күперләргә, паровозларга, рельс һәм зур-зур машиналарга әверелдерүчеләр кемнәр? Без түгелмени? Без, үзебезнең даһилык көченә таяныш, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән гаҗәеп эшләр башкарабыз, меңәрле-миллионлы капиталлар белән идарә итәбез... Тик шуны белегез, эфәнделәр: акыллы табигать үзенең бетмәс-төкәнмәс иҗади көчен бөтен бер милләт файдасына сарыф итсә дә, ул аның эченнән икеме-өчме дистә кешене генә иң югары ноктага куя. Әфәнделәр, менә шул югары ноктага омтылу өчен үзегездә көч һәм кыюлык тәрбияләгез! Ура!

— Ура! Ура! — дип кычкырдылар кунаклар. Арада Свежевскийның тавышы һәммәсеннән дә катырак ишетелде.

Барысы да урыннарыннан кубып, Василий Терентьевич белән чәкешеп эчәргә ашыкты.

— Кабахәт нотык! — дип куйды доктор, пышылдап.

Квашниннан соң Шелковников сүз алды.

— Әфәнделәр! Безнең хөрмәтле химаячебез, кадерле остазыбыз һәм хәзерге вакыттагы амфитрионыбыз [1] — Василий Терентьевичка сәламәтлек телик! Ура! — дип кычкырды ул.

— Ура-а! — дип бердәм рәвештә элеп алды кунаклар һәм тагын барысы да урыннан кузгалып Квашнин белән чәкешергә юнәлде.

Аннан соң инде сүз артыннан сүз, тост артыннан тост китте. Заводның уңышлары өчен дә эчтеләр, пикникка килә алмаган акционерлар саулыгына да эчтеләр, шулай ук табында утыручы дамаларның һәм, гомумән, барлык хатын-кызларның исәнлеге-саулыгы өчен дә аерым-аерым тостлар әйтеп эчелде. Арада кинаяле-шаярулы әдәпсезрәк тостлар да булды.

Шешәләп-шешәләп эчелгән шампанский тәэсирсез калмады, билгеле: бераздан бөтен павильонны тоташ гүелдәү басты; һәрбер тост әйтүчегә, сүзен башлап җибәрер өчен, бик озаклап пычак белән стаканга шакылдатып торырга туры килде. Бер читтә, үзенә аерым торган кечкенә өстәл янында, чибәр Миллер зур көмеш савытка ниләрдер салакуша жженка ясап утыра иде.

Шул вакыт, сер катыш мөлаем бер елмаю белән елмаеп, тагын Квашнин торып басты.

— Әфәнделәр, бәйрәмебезнең шәхси характердагы икенче бер тантанага туры килүе мине бигрәк тә куанды-

---

[1] *Амфитрион* — кунакчыл хуҗа.

ра, — диде ул, түбәнчелек белән башын иеп. — Әйдәгез, бергәләп кияү егете белән ярәшелгән кызны тәбрик итик. Мин Нина Григорьевна Зиненко белән... — Квашнин, Свежевскийның тулы исемен онытып, тотлыгып торды... — дустыбыз Свежевский әфәнде исәнлегенә тост күтәрергә тәкъдим итәм...

Бу хәбәр бөтенләй көтелмәгән булганлыктан, аны бигрәк тә каты кычкырып, шаулашып каршы алдылар. Андреа, үзенең янәшәсендә сыкранып ыңгырашуга охшаш сәер бер тавыш ишетеп, борылып карады һәм Бобровның эчке газаптан чалышайган чытык йөзен күрде.

— Коллега, сезгә һәммәсе дә билгеле түгел ахрысы әле, — дип пышылдады ул. — Тыңлап торыгыз, мин аларга хәзер берничә җылы сүз әйтәм.

Андреа, кискен хәрәкәтләр ясап һәм шул хәрәкәте белән урындыгын аударып һәм бокалындагы ярты эчемлеген түгеп, аягүрә торып басты.

— Могтәбәр әфәнделәр! Безнең хөрмәтле хуҗабыз, тыйнаклык саклап булса кирәк, үзенең тостын ахыргача әйтеп бетермәде... Без кадерле дустыбыз Станислав Ксаверьевич Свежевскийны яңа, җаваплы урынга күчүе белән дә котларга тиешбез: киләсе ай башыннан ул ширкәт идарәсенең эш башкаручысы постын алачак... Бу постны, үзенә күрә, хөрмәтле Василий Терентьевич тарафыннан яшьләргә бирелгән туй бүләге дип бәяләргә мөмкин... Мин мөхтәрәм химаячебез йөзендә ризасызлану күрәм... Ялгыш аның серен әйтеп ташладым булса кирәк, моның өчен ул мине гафу итсен. Шулай да, дуслык һәм хөрмәт йөзеннән, әйтмичә кала алмыйм: безнең кадерле дустыбыз Станислав Ксаверьевич Свежевский үзенең Петербургтагы яңа урынында, мондагы кебек үк, эшлекле һәм яхшы иптәш булып танылсын иде... Ләкин мин беләм, әфәнделәр, безнең арада Станислав Ксаверьевичка көнләшеп караучылар табылмастыр. — Андреа сүздән туктап, зәһәр елмайган күзләрен Свежевскийга төбәде. — Чөнки без барыбыз да аңа шундый бердәм рәвештә яхшы теләкләр телибез ки...

Көтмәгәндә аның сүзләрен җан-фәрманга чабып килгән атның тояк тавышы бүлде. Ул да булмады, урман куелыгыннан күбеккә баткан ат өстендә бер җайдак атылып чыкты. Йөзендә курку-өркү галәмәте катып калган яланбашлы бу җайдак подрядчик Дехтеревта хезмәт итүче десятник иде. Ул, тәмам хәлдән тайган, бөтен гәүдәсе белән калтыранган атын мәйдан уртасында калдырып, Василий Терентьевич янына йөгереп килде дә, аның колагына иелеп, нәрсәдер пышылдарга тотынды... Павильонда кинәт кенә

коточкыч тынлык урнашты; һавада яңадан, теге вакыттагы кебек, чырт-чырт күмер янганы һәм тынгысыз чикерткә сайраганы ишетелде.

Квашнинның күп эчүдән кызарынган йөзе кинәт агарына башлады. Ул кулындагы бокалын нервлы бер хәрәкәт белән өстәл өстенә куйды; аракы чайкалып эскәтергә түгелде.

— Ә бельгиялеләр кайда? — дип сорады ул, кискен һәм карылдык тавыш белән.

Десятник башын чайкады һәм Квашнинның колагына иелеп тагын нәрсәдер пышылдарга кереште.

— Аһ, шайтан! — диде кинәт Квашнин һәм кулындагы тастымалын йомарлап, аягүрә сикереп торды. — Һич уйламаган җирдән... Тукта, сабыр ит, станциягә телеграмма илтә барырсың, хәзер үк губернаторга хәбәр бирергә кирәк... Әфәнделәр, — дип кычкырды ул аннары, мәҗлестәгеләргә мөрәҗәгать итеп: — заводта чуалыш... Чаралар күрергә кирәк... безгә моннан тизрәк китү хәерлерәк булыр...

— Шулай булыр дигән идем дә аны, — диде Андреа, зәһәрле көлү сизелеп торган тыныч тавыш белән.

Павильонда ыгы-зыгы купты. Бары Андреа гына, әүвәлге тынычлыгын саклап, ашыкмыйча кулына яңа сигара алды һәм кесәсендәге шырпысын капшап, стаканына коньяк тутырды.

XI

Чыр-чу, ыгы-зыгы башланды. Һәммә кеше урыннан кубып, бәрелә-сугыла павильон буенча чабарга тотынды; урындыклар ауды, кайсыларыдыр сөртенеп егылды. Хатын-кызлар калтыраган куллары белән кабалана-кабалана эшләпәләрен киярга ашыктылар. Җитмәсә, кемнеңдер боерыгы белән, электр фонарьларын сүндерделәр. Бу исә гомуми ыгы-зыгыны тагын да көчәйтә төште... Караңгыда берөзлексез чәрелдәп кычкырган хатын-кыз тавышлары яңгырап торды.

Иртәнге сәгать бишләр чамасы иде. Кояш әле чыкмаган, шулай да көн якынлашып килүен белдереп, күк йөзендә инде таң алдының соргылт яктылыгы җәелә башлаган иде. Электр балкышына шулай кисәк һәм көтмәгәндә генә алмашка килгән бу соргылт, тонык яктылык гомуми ыгы-зыгы күренешен аеруча куркынычлы, хафалы итеп күрсәтә, аңа ниндидер фантастик бер төс өсти иде. Кешеләрнең килеш-килбәтләре әллә нинди куркынычлы әкиятләрдә генә була торган өрәкләрне хәтерләтә. Аларның йокысызлыктан таушалган, йончыган йөзләрен курку баскан. Аш өстәле

гүя ниндидер коточкыч гыйш-гыйшрәттән соң торып калган: анда тәртипсез рәвештә савыт-саба, шешәләр өелеп ята, эскәтер тәмам аракы табына буялып беткән иде.

Экипажлар тирәсендә тавыш-гауга тагы да котырынкырак иде. Анда, йөгән киргә теләмичә хырылдый-хырылдый дулап, куркынган атлар үрле-кырлы сикерешә; тәгәрмәч тәгәрмәчкә эләгеп, арба күчәрләре шарт-шорт сына. Һавада әледән-әле кучерларның үзара әрепләшеп сүгенгән әшәке сүзләре һәм инженерларның үз кучерларына исемнәре белән дәшеп кычкырган чакыру авазлары яңгырап китә. Гомумән, монда бөтен нәрсә төнге зур янгыннар вакытында гына була торган бәла-казалы, миңгерәүләткеч бер мәхшәр төсен алган иде. Әнә кайсысындыр бәрепме, таптапмы уздылар бугай: кинәт кенә ачыргаланып кычкырган яман тавыш ишетелде.

Бобров үзенең кучерын таба алмыйча тәмам гажиз булды. Өсте-өстенә өелешкән экипажлар арасында берме, икеме тапкыр Митрофанның җавап авазы ишетелгәндәй тоелса да, анда һичничек тә үтеп кererлек түгел, чөнки әйләнә-тирәдәге ыгы-зыгы, этеш-төртеш һаман саен хәтәррәк була бара иде.

Шул вакыт кинәт гөжләгән халык төркеме өстендә кызыл ялкынлы керосин факелы балкып китте. Ул да булмады, кемнәрдер сөрән салып: «Юл бирегез! Читкә китегез, әфәнделәр! Юл бирегез!» — дип кычкырып җибәрде. Көчле басым астында ябырылып барган халык дулкыны Андрей Ильичны эләктереп алды да әйләндерә-тулгандыра үзенә ияртеп китте һәм бераздан аны бер пролетканың арткы стенасы белән икенчесенең тәртәсе арасына кертеп кысрыклады. Шуннан торып, Бобров экипажлар уртасыннан ничек юл ачылуын һәм шул юлдан тимеркүк атлар җигүле Квашнин тройкасының чаптырып узуын карап калды. Коляска өстендә җилфердәп барган факелдан Василий Терентьевичның иләмсез симез гәүдәсенә кан төсле кызыл, дерелдәвек һәм шомлы яктылык бөркелә иде.

Коляскаңың як-ягында исә, түзеп булгысыз кысрыклаудан, курку һәм ачудан тәмам шашу дәрәҗәсенә җитеп, халык төркеме улый иде... Бобровның чигәсен кинәт нидер чәнчеп алгандай булды. Бер генә мизгелгә аңа коляскада утырып баручы Квашнин Квашнин булып түгел, ә ниндидер дәһшәтле һәм канга манчылган шыксыз кыяфәтле илаһи зат — кайбер Шәрекъ халыкларының табына һәм шашынулы дини бәйрәмнәре вакытында кеше корбаннары китерүне сорый торган сәнамнарыдай куркынычлы бернәрсә бу-

лып күренде. Һәм Бобров үзенең күңелендә кайнаган чарасыз ярсудан калтыранып куйды.

Квашнин узып киткәч, шундук бераз иркенәеп калгандай булды. Бобров артына әйләнеп карады һәм аркасын кысып торган тәртәнең үз пролеткасыныкы икәнен күрде. Митрофан кузла янында басып тора һәм факел кабызып маташа иде.

— Тизрәк заводка ку, Митрофан! — дип кычкырды Андрей Ильич, пролеткага менеп утырып. — Бер ун минуттан барып җитәрлек булсын, ишетәсеңме!

— Тыңлыйм, — диде Митрофан, караңгы чырай белән.

Һәрбер яхшы кучерга хас булганча, ул, пролетканы тирәли әйләнеп узып, кузлага уң яктан менеп утырды, дилбегәне кулына алды да, артка таба башын бора төшеп:

— Тик атларны яндырсак, гаепләштән булмасын, барын, — дип өстәде.

— Аһ, әйдәсәнә, ни булса шул булыр...

Бер урынга өелешкән экипаж һәм атлар төркеменнән ничек кирәк алай котылып, тар урман юлына чыккач, Митрофан дилбегәне шартлатып куйды. Тик торып алҗыган һәм әсәрләнгән атлар җан-фәрманга чабарга тотындылар. Юлга аркылы сузылган агач тамырларына очраганда пролетка сикереп-сикереп куя, сикәлтәле урыннарда әле уңга, әле сулга янтаеп, кучерны да, пролеткада утыручыны да чайкалып барырга мәҗбүр итә иде.

Чатыр-чотыр чапкан уцайга факел ялкыны айкалып-айкалып җилферди. Аның белән бергә пролетка әйләнәсендә агачлардан сузылган сәер һәм озын күләгәләр тирбәлеп кала. Нечкә билле, озын буйлы, төссез-җисемсез өрәкләрдәй, алар тыгыз сафка тезелеп һәм ниндидер аңлаешсыз, мәгънәсез биюләр биеп, пролетка янәшәсеннән чабалар; әле атларны узып китеп, чиксез зураялар, әле җир өстенә сузылып яталар да, бик тиз кечерәя барып, пролетка артында күздән югалалар; әле берничә секундка урман куелыгына кереп китәләр һәм көтмәгәндә генә тагын пролетка янына атылып чыгалар; яки, бер-берсенә якын ук килеп, чайкалыша-тирбәлешә, үзара сер сөйләшергә тотынгандай булалар... Юл буена елышып утырган куакларның нечкә ботаклары, куллар сыман алга сузылып, берничә тапкыр Бобров белән Митрофанның битенә үк сугып калды.

Менә урман артта калды. Атлар чупыр-чапыр атлап ниндидер күлдәвек судан бара башлады; су өстендә, сикеренеп-тирбәлеп, факел ялкынының кызгылт күләгәсе ял-

тырап чагылды. Аннары атлар юыртып, элдертеп кенә үргә менделәр. Алда кап-караңгы буш кыр җәелеп ята иде.

Пролетка кыр буйлап сулыш кысылырлык тизлектә чаптырып барса да, Бобров сабырсызланып Митрофанга кычкырды:

— Атларны куалачы, Митрофан, болай әкрен барсак, без беркайчан да заводка җитә алмабыз!..

Кучер авыз эченнән генә нидер мыгырданды да мичәүдә сыртын дугайландырып чапкан Фарватерга чыбыркысы белән сыздыртты. Моңарчы атларны гел кызганып караган бариннең шулай кинәт кенә үзгәреп китүе Митрофанны тәмам аптырашта калдырган иде.

Офык читендәге йөзмә болытларда чагылып тирбәлгән ниндидер зур ялкын шәүләсе Бобровның игътибарын үзенә җәлеп итте. Ул шул шәүләгә текәлде һәм күңел төбеннән усал бер куаныч хисе калка башлавын тойды. Андреаның зәһәрле, кыю тостыннан соң аның өчен барысы да: Нинаның бүгенге мәҗлестә ни өчен шулай сөйләшергә теләмәве дә, мазурка вакытында әнисенең нидән ачулануы да, Свежевскийны Василий Терентьевичка якынлаштырган сәбәпләр һәм Квашнинның Нина артыннан үзе өстерәлеп йөрүе хакында заводта таралган имеш-мимешләр дә берьюлы ачыкланып, аңлашылып калгандай булды... «Шул кирәк ул җирән аждаһага, шул кирәк, — диде Бобров, үзалдына пышылдап. Ул үзен чиксез кимсетелгән итеп санады һәм шул кимсетелүе өчен үзендә шундый ачу кабаруын тойды ки, аның хәтта авызындагы төкереге кипте. — Ух, хәзер аның белән йөзгә-йөз очрашсам, мин ул мактанчыкка, кеше каны белән сату итүче шул ит бүкәненә, акча капчыгына ни әйтергә белер идем. Бакыр маңгаена шәп кенә мөһер чәпәп, мин аны бик озакка тынычлыгыннан мәхрүм итәр идем!..»

Артык күп эчкән булса да, Андрей Ильич исерек түгел иде. Әмма бүгенге эчү аңарда гадәттән тыш бер көч-куәт дулкыны күтәрелүгә сәбәп булды, аны сабырсыз һәм әрнүле бер халәткә салып, нидер эшләргә җилкендерде. Ул бөтен гәүдәсе белән туңып калтыранды, теше тешкә бәрелүдән котылу өчен хәтта теш казнасын чытырдатып кысты; күңелендә исә, кызышып саташкандагы кебек, ниндидер буталчык уйлар алышынып торды. Андрей Ильич, үзе дә сизмәстән, әле ыңгырашты, әле үзалдына кычкырып сөйләште, әле шаркылдап-шаркылдап көлеп җибәрде, шул ук вакытта үзеннән-үзе аның куллары йомарланды.

— Барин, сез авырыйсыздыр, ахры? Өйгә кайтсак әйбәтрәк булмасмы икән, — диде Митрофан кыюсыз гына.

Бу сүзләр Бобровны тәмам чыгырыннан чыгарды, ул ярсып:

— Лыгырдама, ахмак!.. Куыңны бел!.. — дип җикерде.

Озакламый үр өстеннән уч төбендәге кебек бөтен завод күренә башлады. Ул бөтенләе белән аксыл-алсу төтен эченда иде. Арттарак, гаять зур учак сыман, агач склады дөрләп яна. Янгын яктысында ыгы-зыгы килеп исәпсез-хисапсыз кечкенә кара күләгәләр — кешеләр кайнаша. Коры бүрәнәләрнең чырт-чырт шартлап ануы ерактан ук ишетелеп тора. Каупер һәм домна мичләренең түгәрәк башнялары әле яктырып китәләр, әле яңадан караңгылык эченә чумалар. Текә ярлы буаның коңгырт-соры суы өстендә дәһшәтле булып кызгылт янгын шәүләсе чагыла. Буа яры өсте кешеләр белән шыгрым тулы; алар кайнап торган кара бер ташкын кебек әкрен генә алга хәрәкәт итәләр. Һәм дүрткел ярны тәмам тутырып, кысылышып барган шушы коточкыч халык ташкынынннан тирә-якка ерак диңгез шавы сыман шомлы, фетнәле бер гөрелте тарала иде.

Шул вакыт кемдер берәү тупас тавыш белән:

— Кая чабасың, башың беткере! Күзең юкмы әллә, кеше өстенә киләсең, сволочь, — дип кычкырды.

Каршыда, гүя атлар астыннан калкып чыккандай, озын буйлы һәм ялан башын ак чүпрәк белән чорнаган сакаллы бер ир кеше күренде.

— Әйдә куала, Митрофан! — дип кычкырды Бобров.

— Барин! Ут төртеп яндырганнар! — диде Митрофан, калтыравык тавыш белән.

Ул да булмады, алар артында кемдер таш атып җибәрде. Таш кисәге, сызгырып килеп, Бобровның уң як чигәсен яндырып алды. Бобров капылт кына чигәсенә тотынды һәм учы астыннан җылы, ябышкак кан саркуын тойды.

Пролетка әүвәлге тизлеге белән һаман оча бирде. Янгын шәүләсе куерганнан-куера бара иде. Җан-фәрманга чапкан атларның җиргә яткан озын күләгәләре юлның әле бер ягына, әле икенче ягына йөгереп чыгалар. Ара-тирә Бобровка алар гүя ниндидер текә тау астына таба чабалар төсле тоелып китә; менә-менә яр кырына килеп җитәрләр дә утырган экипажлары, атлары белән бергә тирән упкынга капланырлар шикелле. Бобров бөтенләй исен-акылын җуйган һәм инде үзләренең кайсы тирәдән баруларын да аера алмый башлаган иде. Кинәт атлар туктап калды.

— Йә, ни булды анда, нигә туктадың, Митрофан? — дип җикеренде Бобров, сабырсызланып.

— Туктамый нишлим, алда халык ич! — диде Митрофан, ачу белән мыгырдап.

Таң атып җитмәгән иде әле. Бобров, никадәр генә текәлеп карамасын, кызгылт янгын шәүләсе фонында киртләч стена сыман калкып торган ниндидер кара таптан башка бүтән берни дә шәйли алмады.

— Нинди кешеләр күрәсең соң син анда, шайтан алгыры! — диде ул, ачуланып, һәм пролеткадан сикереп төште дә ак күбеккә баткан атлары алдына чыкты.

Ләкин ул биш-алты адым алга киткәч тә әлеге кара стена булып күренгән нәрсәнең чыннан да юл тутырып каядыр баручы зур халык төркеме икәнлеген аңлады. Эшчеләр артыннан аңсыз рәвештә тагын бер илле адым чамасы ияреп барганнан соң, Андрей Ильич заводны икенче башыннан әйләнеп узарга кирәк дигән карарга килде һәм, кире борылып, Митрофан торып калган урынга китте. Ләкин юлда Митрофан да, атлар да юк иде инде. Митрофан үзенең хуҗасын эзләп икенче якка китеп бардымы, әллә Бобров үзе адаштымы — моны һичничек тә аңлап булырлык түгел иде. Андрей Ильич кучерына кычкырырга тотынды, әмма аңа җавап кайтаручы булмады. Шуннан соң ул, яңадан әлеге эшчеләр төркемен куып җитәргә уйлап, кырт борылды да тагын кире йөгерә башлады. Тик — гаҗәп хәл! — эшчеләр төркемен әйтерсең лә җир йоткан иде; төркем урынына Бобров чабып барган уңайга ниндидер тәбәнәк такта коймага килеп тәртелде.

Бу койманың уң ягыннан да, сул ягыннан да очы-кырые күренми иде. Бобров аны аркылы сикереп чыкты да каракура һәм чүп үләне каплаган текә, озын яр буйлап югары менә башлады. Андрей Ильич тиргә батты; авызы кибеп, теле агач кисәге шикелле бөтенләй хәрәкәтләнмәс булды; сулыш алган саен аның күкрәгендә нәрсәдер чәнчеп-чәнчеп куя, еш-еш типкән кан тамырлары баш түбәсенә дың-дың сугып тора, ә җәрәхәтле чигәсе түзеп булмас дәрәҗәдә әрнеп сызлый иде...

Үр аңа очы-кырые булмаган биек бер тау булып тоелды, күңелен шик-шөбһә, өметсезлек хисе билəп алды. Ләкин үзе, куллары белән чәнечкеле куакларга тотынып, минут саен абына-сөртенә һәм тез башларын сыдырта-сыдырта һаман югары үрмәләде. Кайчагында Андрей Ильичка гүя ул үзенең элеккеге вакытлардагыча саташулы төшләр күрә-күрә йоклап ята кебек тоела башлый иде. Пикниктан соң булган ыгы-зыгылы тамаша да, юлда бик озак адашып йөрү һәм менә хәзер кичергән тау менү газабы да — һәммәсе дә аның өчен шул саташулы төшләрендәге куркыныч, авыр, мәгънәсез һәм көтелмәгән хәлләрне хәтерләтә иде.

Ниһаять, үр артта калды, һәм Бобров шундук бу үр

дигәннең тимер юл өеме булганлыгын аңлап алды. Әле биш-алты көн элек кенә, тантаналы гыйбадәт вакытында, фотограф шушы биек урынтан эшче һәм инженерлар төркемен рәсемгә төшереп йөргән иде. Андрей Ильич тәмам хәле бетеп шпал өстенә утырды һәм шул минутта ук үзендә ниндидер сәер бер үзгәреш сизде: аның аяклары кисәк кенә әрнеп авыртырга тотынды, күкрәге һәм эче турысыннан бөтен тәненә күңел болгаткыч һәм сызландыргыч бер кымыржу таралды, маңгае белән яңаклары ничектер берьюлы салкынаеп китте. Аннары күз алды караңгыланып, бөтен нәрсә зырылдап әйләнә һәм гадәттән тыш бер тизлек белән каядыр төпсез упкынга оча башлады...

Андрей Ильич бер ярты сәгатьтән соң гына һушына килде. Түбәндә, үр итәгендә, гадәттә көн-төн зур завод гөрелтесе яңгырап торган уйсулыкта, хәзер сәер һәм шомлы бер тынлык урнашкан иде. Бобров көч-хәл белән аягына торып басты да домна мичләренә таба атлады. Ул үзенең чуендай авырайган башын көчкә генә тотып тора иде; җәрәхәтле чигәсе кымшанган саен үтереп-үтереп сызлый. Капшап карагач, ул бармакларының яңадан җылы һәм ябышкак канга тиеп китүен тойды. Шулай ук авызы, иреннәре дә канлы иде булса кирәк: телдә гел тимер тәмедәй төчкелтем, тозлы кан тәме сизелеп торды. Бобров әле бөтенләй үк айнып җитмәгән иде, шуңа күрә ул үзе кичергән хәлләрне исенә төшерергә, ачыкларга тырышты, ләкин киренке уйланудан башы тагын да катырак авырта башлады. Аның күңелен кемгәдер тирән ачу һәм өметсез бер сагыш биләп алган иде...

Таң инде беленеп килә иде. Әйләнә-тирәдәге бөтен нәрсәдән: җирдән һәм күк йөзеннән, саргайган ябык үлән яфракларыннан һәм юл кырыйларында тәртипсез рәвештә өелеп яткан ташлардан — һәммәсеннән дә бертөрле юеш, салкын, сагышлы моң сирпелә. Бобров бернинди максатсыз-нисез заводның буш биналары арасында каңгырып йөрде һәм бик зур рухи борчулар кичерүче кешеләргә хас онытылу белән үзалдына кычкырып сөйләшергә кереште. Шул рәвешчә ул үзенең чуалган фикерләрен эзгә салырга, аларны тәртипкә китерергә теләде.

— Нишләргә соң миңа, йә әйт, нишләргә? Алла хакы өчен әйт, — дип ялварды ул, кемгәдер — гүя үз эчендә утырган *икенче берәүгә* мөрәҗәгать итеп. — Ah, шундый авыр миңа! Шундый кыен!.. Бөтенләй түзеп булгысыз кыен!.. Мин үз-үземә кул салырмын ахры... Мондый газапка бүтән түзәрлегем калмады...

Ә тегесе, *икенче берәү* дигәне, шулай ук кычкырып, лә-

кин мыскыл катыш тупасрак тавыш белән күңел төбеннән аңа җавап бирде:

— Юк, син үз-үзеңә кул сала алмыйсың. Нигә инде үз-үзеңне шулай алдап маташырга?.. Үз-үзеңә кул салыр өчен син артык йомшак, ихтыярсыз кеше ич, тормыш рәхәте, ләззәте сиңа кадерлерәк. Аның соңында, син физик авыртуга түзә алмыйсың, аңардан куркасың. Син артык күп уйланасың.

— Алайса нишләргә соң миңа? Нишләргә? — дип пышылдады Андрей Ильич тагын, ярсый-ярсый үзенең кулларын боргычлап. — Ул, минем Нинам, — шундый нәфис, шундый саф кыз иде! Дөньяда аңардан башка минем бүтән беркемем дә юк иде бит! Шул кыз менә хәзер үзенең яшьлеген, гыйффәтле тәнен акчага сата!.. Бу бит коточкыч кабахәтлек!..

— Кыланмачы, зинһар, кыланма! Бу купшы сүзләрең нигә кирәк! — дип һаман үзенекен җөпләде әлеге *икенче берәү,* мыскыллап. — Әгәр Квашнинны алай бик яратмыйсың икән инде, тот та үтер соң аны.

— Һәм үтерермен дә! — дип кычкырып җибәрде Бобров, туктап һәм йодрыкларын югары күтәреп. — Әллә үтермәмме! Үзенең нәҗес сулышы белән намуслы кешеләрне бүтән агулап йөрмәс ичмасам. Үтерермен шул!

Ләкин күңелдәге *икенче берәү* зәһәрле көлемсерәп әйтеп куйды:

— Ә син аны үтермәячәксең... Моны үзең дә бик яхшы беләсең, Квашнинны үтерерлек көч тә, батырлык та юк синдә... Әүвәлге күндәмлегең, юашлыгың сиңа иртәгә үк яңадан кире кайтачак...

Күңелдәге шушы коточкыч каршылыклы уй-фикерләр талашыннан айнып торган араларда, Бобров, тирә-ягына аптыраулы күз карашы ташлап, үзенә үзе сорау бирде: ни булды соң әле миңа? Ничек соң әле мин монда килеп эләктем? Нишләргә җыенган идем соң әле?.. Нәрсәдер эшләргә кирәклеген һәм бу эшләргә җыенганы ниндидер зур һәм мөһим эш булырга тиешлеген белсә дә, ул аның нинди эш икәнлеген онытkан иде. Һәм хәзер никадәр генә кашын-күзен җимереп уйламасын, Бобров бу эшен һич тә хәтереннә төшерә алмады. Шундый акылы аек чакларының берсендә ул үзен кочегарка чокыры янында басып торган килеш күрде һәм шундук аермачык итеп эле күптән түгел генә нәкъ шушы урында доктор белән үзе арасында булган сөйләшүне исенә төшерде.

Чокырда кочегарлардан беркем дә юк иде: һәммәсе дә каядыр качып беткән. Пар казаннары да инде күптән

суынырга өлгергән. Тик кырыйдагы ике топкада гына чакчак кызарып торган ташкүмер калдыгы күренә... Шул чак Андрей Ильичның миендә яшен чаткысыдай акылсыз бер уй ялтырап китте. Ул тиз генә түбән иелде, куллары белән чокыр читенә таянып, аякларын салындырды да кочегаркага сикереп төште.

Ташкүмер өеменә көрәк кадап куелган иде. Бобров көрәкне суырып алды да ашыга-кабалана ике топкага да күмер тутыра башлады. Ике-өч минуттан инде топкаларда гөрли-гөрли аксыл ялкын телләре сикерешә, ә казанда быгырдап су кайный иде. Бобров ару-талуны белмичә мичләргә һаман күмер ташлады да күмер ташлады. Шул ук вакытта ул мыек астыннан гына елмая, хыялындагы нинди-дидер кешегә эндәшкәндәй, башын кагып куя һәм әллә нинди мәгънәсез, кискен сүзләр кычкыра иде. Әле анда, юлда килгәндә үк, күңелендә туган коточкыч мәкерле, саташулы уй хәзер аны бөтенләе белән үзенә буйсындырган иде. Быгырдый-быгырдый гүелдәгән һәм кызудан тәмам утлар чагылдырып жемелдәгән зур казанга ул күзен алмый карап торды. Казан аңа тере, жанлы булып тоелды һәм Бобровтагы нәфрәт хисен үстергәннән-үстерә барды.

Аңа беркем дә комачауламый иде. Суүлчәгечтәге су күзгә күренеп кими, су кимегән саен казанның быгырдавы һәм топкалар гүләве дә катырак һәм шомлырак була бара иде.

Ләкин күнегелмәгән эш Бобровны тиз арытты. Аның чигә тамырлары, бүртеп-кабарып, саташкан чактагы бер кызышу белән леп-леп тибәргә тотынды, жәрәхәттән саркыган жылы кан әкрен генә яңагы буйлап тәгәрде. Шашкын күңеленең көче-куәте сүрелде, ә теге эчке тавыш, *икенче берәү,* мыскыллап һәм үртәп, янә сүз башлады:

— Йә, сиңа тагын бер генә нәрсә эшлисе калды! Тик син аны эшләмәячәксең... Basta... Болар һәммәсе дә көлке генә бит; иртәгә бу ниятеңне — төнлә пар казаннарын шартлатырга уйлап йөрүеңне син хәтта искә төшерергә дә ояласың.

Андрей Ильич завод больницасына барып кергәндә офык читеннән инде тонык-аксыл төстәге зур тап сыман кояш күтәрелеп килә иде.

Докторның, яраланучы һәм имгәнүчеләргә ярдәм күрсәтү эшеннән беразга гына аерылып, жиз кулъюгычтан юынып торган чагы иде. Аның янәшәсендә, сөлге тотып, фельдшер баскан иде. Бобровны күргәч, доктор гажәпләнүдән хәтта артка чигеп куйды.

— Ни булды сезгә, Андрей Ильич? Сезне танырлык та түгел! — диде ул, тәмам куркуга калып.

Чыннан да, Бобров коточкыч бер кыяфәттә иде. Аның агарынган һәм күмер тузаны кунып пычранган ала-кола йөзенә укмашып кан каткан; өс-башы юеш, җиң һәм тез башлары теткәләнеп, чүпрәктәй салынып тора; тузыган чәчләре оеш-оеш булып маңгаена төшкән иде.

— Алла хакы өчен әйтегез, ни булды сезгә, Андрей Ильич? — дип кабатлады тагын Гольдберг һәм, юеш кулларын аннан-моннан гына сөлгегә сөрткәләп, Бобров янына килде.

— Ah, искитәрлек берни дә юксана... — дигән булды Бобров, ыңгырашып. — Алла хакы өчен, морфий бирегез миңа, доктор... Тизрәк бирегез, югыйсә мин акылдан шашам!.. Мин чиксез газапланам!..

Гольдберг Андрей Ильичны кулыннан җитәкләп тиз генә икенче бүлмәгә алып керде дә ишекне эчтән ныгытып ябып куйды.

— Тыңлагыз әле, Андрей Ильич, сезне нәрсә газаплавын мин бераз сизенәм... — диде ул. — Ышаныгыз, мин сезне бик кызганам һәм сезгә ярдәм итәргә әзермен... Тик сез... кадерлем, — докторның тавышы калтыранып китте, — сөекле Андрей Ильич... сез моны морфийсыз гына уздырып җибәрә алмассызмы икән соң? Хәтерегездә булса, шул әшәке гадәттән бизү өчен безгә никадәр көч-хезмәт куярга туры килде бит! Сезгә хәзер морфий бирсәм, эшләр бик хәтәр төс алачак... ул чакны сез инде бүтән беркайчан да... ишетәсезме, бүтән беркайчан да морфийдан бизә алмаячаксыз...

Бобров клеенка тышлы киң диванга йөзтүбән капланды да, бөтен тәне белән дерелдәп, чытырдатып кыскан тешләре арасыннан:

— Барыбер... миңа барыбер, доктор... Минем бүтән түзәр чарам калмады, — дип мыгырданды.

Доктор, уфтанып, иңбашын җыерды һәм дарулар шкафыннан шприцлар тартмасын чыгарды...

Биш-алты минуттан инде Бобров клеенка тышлы диван өстендә бөтен дөньясын онытып йоклап ята иде. Андрей Ильичның бер төн эчендә ябыгып, сулып калган аксыл йөзенә тәмле бер елмаю җәелгән. Доктор исә бик зур саклык белән генә аның башын юа иде.

1896





ОЛЕСЯ

I

Минем хезмәтчем, аш-су хәзерләүчем һәм сунардагы юлдашым — урман каравылчысы Ярмола, зур бер кочак утын күтәреп, иелә-сыгыла бүлмәгә керде дә утынын гөрселдәтеп идәнгә ташлады һәм күшеккән кулларына җылы сулышын өрә-өрә мич авызы каршына чүгәләде.

— У-у, тышта яман салкын җил кузгалган, паныч, — диде ул. — Һәйбәтләп мичкә ягып җибәрергә кирәк булыр. Кая, ут кабызгыч бирегез әле, паныч.

— Иртәгә куянга чыгып булмасмыни инде алайса, ә? Син ничек уйлыйсың, Ярмола?

— Юк... булмастыр... ишетәсезме, әнә ничек ыжгыра. Куян хәзер шым гына шыңкаеп ята... Иртәгә аның эзен дә күрә алмассыз.

Язмыш мине ярты елга Волынь губернасының Полесье читендәге карацгы бер авылына китереп ташлаган иде. Монда минем бердәнбер шөгылем һәм юанычым әнә шул сунарчылык иде. Дөресен әйткәндә, баштарак, юлга чыгар алдыннан, мин монда бу кадәр үк күңелсез булыр дип һич тә уйламаган идем. Киресенчә, юлга мин шатланып чыгып киткән идем. «Полесье... кеше аягы басмаган урманнар... кыргый табигать... тәкәллефсез кешеләр... алар арасында-

гы гади, саф мөнәсәбәтләр, — дип уйланып бардым мин юлда, вагон тәрәзәсеннән карап. — Таныш булмаган халык, аның сәер гореф-гадәтләре, үзенчәлекле сөйләме... аннары соң, әлбәттә, күп кенә шигъри легендалар, риваять һәм җырлар!» Сөйли башлагач, шәт, бөтенесен сөйләргә кирәктер, мин бу вакытта инде, кечкенә генә бер газетада ике үтереш һәм бер үз-үзен үтерүче турында хикәя бастырып чыгарган кеше буларак, халыкның гореф-гадәтләрен өйрәнүнең язучы өчен файдалы икәнен белеп өлгергән идем.

Ләкин... әллә инде Переброд авылы крестьяннары артык киребеткән, йомыкый халык булып чыкты, әллә үзем эш рәтен белмәдем — һәрхәлдә, минем алар белән аралашуым үзара очрашканда аларның ерактан ук бүрекләрен салып килүеннән һәм минем турыга җиткәч караңгы чырай белән: «Гай буг», ягъни үзләренчә: «Алла ярдәм бирсен» дип исәнләшүеннән ары узмады. Мин сөйләшергә ымсынып сүз катсам, алар миңа гажәпләнеп карыйлар, иң гади сорауларымны да аңламаган булып кыланалар һәм кайчандыр бик күптән, поляклар чорында ук сеңеп калган иске гадәтләре буенча, һәммәсе дә тизрәк кулымны үбәргә үреләләр иде.

Мин янымда булган китапларымны тиз арада бер-бер артлы укып бетердем. Баштарак бик ук теләгем булмаса да, тора-бара урындагы интеллигенция белән — авылдан унбиш чакрым читтә яшәүче ксендз[1], аның кул астында эшләүче «пан әргәнче», авылдагы урядник һәм күрше имениедә конторчы хезмәтендә торучы отставкадагы бер унтер-офицер белән танышырга тырышып карадым. Ләкин бу тырышуымнан да берни чыкмады.

Ахырда мин Переброд крестьяннары арасында дәвалау эше белән шөгыльләнергә уйладым. Минем карамакта дәвалау өчен кулланырдай нәрсәләрдән касторное май, карболка, бор кислотасы һәм йод бар иде. Ләкин бу эштә мәгълүматым аз булу өстенә, тагын бер кыенлык килеп өстәлде: мин авыруларга анык кына диагноз куя алмый җәфа чиктем. Ни өчен дигәндә, миңа ярдәм сорап килгән авыруларның зарлары һәммәсенеке дә бертөсле була; алар үзләренең чирләре турында «эчем авырта» яисә «ни ашамак, ни эчмәк чара юк» диюдән башканы белмиләр иде.

Әйтик, минем янга бетерешкән берәр әби килеп керә. Уң кулының имән бармагы белән оялып кына борынын сыпырып алганнан соң, ул, куенына тыгылып (шул чакта

[1] *Ксендз* — поляк рухание (католик динендә).

миңа аның коңгырт-сары төстәге ябык тәне күренеп китә), ике күкәй чыгара да өстәл өстенә китереп куя. Аннары, үбәргә дип, минем кулымны кармаларга тотына. Мин кулымны яшерәм, карчыкны тынычландырырга тырышып:

— Кирәкми, әбекәй... мин поп түгел ич... миңа андый нәрсә ярамый... Синең кай җирең авырта соң? — дим.

— Эчем авырта, пан углым, чат үзәгендә менәтерә, ни ашамак, ни эчмәк чара юк.

— Күптәнме авырта?

— Мин каян белием аны? — ди әби кеше, сорауга сорау белән җавап биреп. — Яндырышмы яндыра инде менәтерә. Ни ашамак, ни эчмәк чара юк.

Һәм, никадәр генә төпченсәң дә, чирнең аныграк бүтән билгеләре табылмый.

— Ә сез алар өчен артык борчылмагыз, — диде берваклыт конторчы унтер-офицер, миңа кичәш биреп. — Үзләре терелер әле, пычагым да булмас. Эт җәрәхәте шикелле кибәр дә бетәр. Мин үзем, дөресен әйтим, дарулардан бары нашатырь спиртын гына кулланам. Әйтик, миңа берәр мужик килә. «Ни кирәк сиңа?» — дип сорыйм моннан. «Чирлим», — ди бу... Шундук тегенең борын төбенә нашатырь спирты салынган шешә китереп төртәм. «Иснә!» — дим. Исни... «Тагын иснә... катырак иснә!» — дим. Тагын исни... «Ничек, җиңеләйдеме?» — дип сорыйм. «Бераз җиңеләйде шикелле...» — ди бу. «Алайса, бар, юлыңда бул». Шуның белән вәссәлам!

Аның соңында мине әлеге кул үбүләр бик җирәндерде. Кайсыберләре хәтта аякка егылып, бөтен көче-куәте белән итекләремне үбәргә тырыша иде. Бу омтылышта, әлбәттә, күңелдәге рәхмәт хисен белдерү теләге түгел, ә бәлки күп гасырлар буена коллык, көчләү тәэсирендә ныгый килгән әшәке бер гадәт үзен сиздерә иде. Шул ук вакытта мин әлеге шул конторчы унтер-офицер белән урядникка гаҗәпләнеп бетә алмадым: алар, берни булмагандай, эре кыяфәт саклап, ялагай мужикларга үптерү өчен зур кызыл кулларын үзләре үк сузып торалар иде...

Ниһаять, мин сунарчылык белән мавыгып киттем. Ләкин гыйнвар ахырларында һавалар бик бозылып, ауга чыгарга бөтенләй мөмкинлек калмады. Көндезләрен күз ачкысыз җил исә, ә төннәрен, җил туктап торса да, карның өске катламы шакырдап ката да, бернинди куян-фәлән эзе калырлык булмый иде. Җил улавын тыңлый-тыңлый, мин үз бүлмәмдә моңсу уйларга батып берьялгызым шулай утыра бирдем. Шундый күңелсез уйлар кичергән берва-

кытта Ярмоланы укырга-язарга өйрәтү кебек гөнаһсыз эшкә дәртләнеп тотынуым, шәт, табигыйдер.

Әйтергә кирәк, бу эш бик кызык кына башланып китте. Көннәрдән беркөнне, хат язып утырганда, миңа артымда кемдер басып тора шикелле тоелды. Әйләнеп карасам — Ярмола. Ул, йомшак чабата кигән аяклары белән, гадәтенчә, шыпырт кына атлап минем янга килгән дә, хат язуымны карап тора икән.

— Ни кирәк, Ярмола? — дип сорадым мин.

— Менә сезнең язу язганны карап торам әле. Гаҗәп бит, шулай булдыралсамие мин дә... Юк, юк, сезнең шикелле дип әйтмим, паныч, — диде ул, минем елмая башлавымны күреп. — Миңа фамилиямне яза алсам да җитәрие...

— Нигә кирәк соң ул сиңа? — дидем мин, гаҗәпләнеп... (Монда шуны да әйтергә кирәк: Ярмола бөтен Перебродта иң ярлы, иң ялкау мужик санала; жалуньясын һәм хуҗалыктан алган табышын ул бөтенләе белән эчеп бетерә; аныкыдай арык йөк үгезләре бөтен төбәктә юк. Минем уемча, укый-яза белүнең аңа бернинди очракта да кирәге булмас шикелле иде.) Мин икеләнү катыш яңадан сорадым: — Сиңа соң фамилия яза белү нигә кирәк?

— Хикмәте бар аның, паныч, — диде Ярмола, гадәттән тыш йомшак тавыш белән,— безнең авылда язу танучы адәм юк бит. Берәр кәгазьгә кул куясы булса, волостька эш төшсә яисә тагын шундыйрак эш чыкса... берәвесе дә булдыралмый... Староста мөһер генә баса, ә үзе мөһердә ни язылганын да белми... Берәвесе язу таныса, авылда барыбыз өчен әйбәт булырие дим.

Авыл җыенында беркем беркайчан сүзе, фикере белән исәпләшмәстәй ялкау, гамьсез һәм ачыктан-ачык браконьер бер сукбайның — шушы Ярмоланың шулай туган авылын, җәмәгать эшләрен кайгыртуы ничектер минем күңелемне нечкәртеп җибәрде. Аңа сабак укытырга мин үзем теләк белдердем. Йа ходай, аны аңлы рәвештә укырга-язарга өйрәтү өчен мин никадәр генә көч куймадым да никадәр генә җәфа чикмәдем! Урмандагы һәрбер яшерен сукмакны, һәрбер агачны диярлек белгән, урманның теләсә кай почмагында адашмыйча көндезен дә, төнен дә йөри алган, хәтта әйләнә-тирәдәге барлык бүре, куян һәм төлке ише җанварларны эзләре буенча таныган Ярмола — менә шул зирәк акыллы сунарчы, әйтик, «м» хәрефенә «а» хәрефен кушкач ни өчен «ма» дигән кушма аваз килеп чыгуын берничек тә аңлый алмады. Андый чакта ул, газаплы кыяфәттә сөмсере коелып, ун-унбиш минут чамасы берни эндәшмичә үз эченә йомылып утыра; аның кара сакалы һәм озын

мыегы астына яшеренгән кара-кучкыл чандыр йөзе һәм эчкә баткан күзләре гадәттән тыш бер киеренкелек белән уйлаганлыгын күрсәтеп тора иде.

— Йәле, Ярмола, әйтеп кара әле: «ма». Тик шул ике хәрефне генә әйт — «ма» диген, — дип йөдәттем мин аны. — Кәгазьгә карамыйча, менә миңа карап әйт, менә шулай. Йә, кабатла — «ма» диген...

Ярмола, авыр сулап, күрсәткеч таякны өстәл өстенә ташлый да моңсу тавыш белән, ләкин катгый төстә:

— Юк... булмый... — дип куя.

— Ничек инде булмый? Шундый җиңел нәрсәне дә белмәгәч. Бернинди көчәнүсез-нисез әйт то бир: «ма» диген, менә мин әйткәнчә.

— Юк... булмый, паныч... оныттым.

Бөтен ысуллар, алымнар һәм чагыштырулар шушы коточкыч аңгыралыкка очрап челпәрәмә килә торды. Ләкин Ярмоланың мәгърифәткә омтылышы барыбер кимемәде.

— Миңа үз фамилиемне яза алсам, шул җитә! — дип үтенә бирде ул оялчан төстә. — Башка берни дә кирәкми. Тик фамилиемне генә: Ярмола Попрожук — башка берни дә кирәкми.

Ярмоланы аңлы рәвештә укырга-язарга өйрәтә алмавыма тәмам ышангач, мин аны үз имзасын яттан куярга өйрәтмәкче булдым. Һәм, чиксез гажәпләнүемә каршы, бу ысул Ярмола өчен иң кулае булып чыкты. Ике ай дигәндә без инде фамилияне язарга өйрәнеп бетә яздык. Исем мәсьәләсенә килгәндә, анысын без, эшне җиңеләйтү максаты белән, бөтенләй өйрәнмәскә карар кылдык.

Кичләрен, мич ягылып, эшләр беткәч, Ярмола, сабырсызланып, үзен чакырып алганны көтә башлый.

— Йәле, Ярмола, әйдә укуны башлыйк әле, — дим мин аңа.

Ул, яны белән генә өстәл кырына якынлашып, ике терсәгенә таяна да, каралып, бирчәеп беткән бөгелмәс бармаклары арасына каләм кыстыра, аннары кашларын югары чөеп:

— Язаргамы? — дип сорый.

— Яз.

Ярмола беренче хәрефне — «п» хәрефен шактый җиңел язып куя (бу хәреф бездә «өстенә аркылы таяк салынган ике багана»дип йөртелә иде); аннары сораулы күз карашын янә миңа юнәлтә.

— Ник язмыйсың инде? Тагын оныттыңмы әллә?

— Оныттым шул... — дип җавап бирә Ярмола, үкенечле кыяфәттә башын селкеп.

— Их, син! Ну, көпчәк сурәтен яса.

— Ә-ә! Көпчәк бит әле, көпчәк!.. Беләм... — ди Ярмола, кинәт җанланып китеп һәм кәгазьгә бик тырышып Каспий диңгезе сурәтенә охшаш озынча түгәрәк ясый башлый. Бу эшен бетергәч, башын әле уңга, әле сулга янтайтып һәм күзләрен кыса төшеп, берникадәр вакыт үз эшенә сокланып карап тора.

— Нәрсә туктап калдың? Әйдә, дәвамын яз.

— Бераз сабыр итегез әле, паныч... хәзер язам.

Берме-икеме минут чамасы шулай уйланып торганнан соң, ул янә миңа таба борыла һәм оялып кына:

— Беренчесе шикелле итеп язаргамы? — дип сорый.

— Әйе. Яз әйдә.

Шулай әкренләп-әкренләп без соңгы хәрефкә — «к»га барып җиттек (катылык билгесен без кирәк санамадык[1]); бу хәреф бездә «урта җиреннән бер якка ике кәкре койрык сузылган таяк» дип йөртелә иде.

Язып бетергәч Ярмола, үз эшеннән үзе хозурланып, кайчак сөйләнергә тотына:

— Ә бит мин, паныч, тагын биш-алты ай шулай сабак алсам, бөтенләй әйбәт белә башларием, — ди. — Сез ни дисез, ә?

II

Ярмола, мич авызы каршына чүгәләп утырган килеш кыскычы белән мичтәге күмерне болгата, ә мин үз бүлмәмнең бер почмагыннан икенче почмагына кыйгачлатып киләп сарып йөрим. Зур алпавыт йортындагы унике бүлмәдән бары берсе — элеккеге диван бүлмәсе генә минем карамакта. Калганнары барысы да бикле. Тантаналы-шомлы тынлык хөкем сөргән ул бүлмәләрдә борынгыдан калган штофлы мебель, әллә нинди гаҗәеп бронза әйберләр һәм XVIII йөз портретлары тын гына бурсып яталар иде.

Урамда, стена артында, туңып калтыранган шәрә карт пәриләр туй иткәндәй, җил-буран котырына. Аның улавында әле ыңгырашу, әле чинау, әле кыргый бер көлү ишетелә кебек. Кичкә таба буран тагы да көчәйде. Тышкы яктан кемдер ярсып-ярсып тәрәзә пыялаларына вак, коры кар сибәргә тотынды. Янәшәдәге урман, ниндидер яшерен, шомлы дәһшәте белән янагандай, бертуктаусыз шаулап, гүелдәп тора иде.

---

[1] Революциягә кадәрге рус орфографиясендә Ярмоланың фамилиясе «Попрожукъ» дип, ягъни ахырына катылык билгесе кушылып язылган.

Җил буш бүлмәләргә һәм гүләп торган моржа куышларына барып керә дә, ярым җимерек, тишек-тошык иске йорт, кинәт кенә җанланып, әллә нинди сәер тавышлар белән шаулый башлый. Мин, шомланып, ул тавышларга ихтыярсыз колак салам. Менә кунак бүлмәсендә нәрсәдер, өзек-өзек сулыш алгандай, тирән сагыш белән уфылдап куя. Менә кайдадыр ераста, гүя кемдер тавышсыз гына, салмак кына атлап йөргән сыман, коргакеып һәм череп беткән идән сайгаклары кыштыр-кыштыр килә. Ул да булмый, минем бүлмә янәшәсендә генә, коридорда, кайсыдыр зур саклык һәм үҗәтлек белән ишек тоткасын кымтырыклый башлый; аннары кинәт кенә ярсып китеп, бөтен ишек, тәрәзә капкачларын тетрәтә-тетрәтә, өй эче буйлатып шашынып чабарга тотына яисә моржа куышына бәреп керә дә, әле еламсык нечкә, әле җанвар ырылдавыдай шомлы калын тавыш белән, берөзлексез чиный һәм үкерә башлый. Кайчакны бу дәһшәтле кунак, — алла белсен, нинди юллар белән, — минем бүлмәгә дә үтеп керә, салкын кымыр-җык булып аркамны куырып уза һәм өске өлеше көйрикөйри корымланып беткән яшел кәгазь абажурлы лампаның болай да тоныk янган ялкынын җилфердәтергә тотына.

Мине ниндидер билгесезлек, сәер сагыш биләп ала. Менә мин хәзер, карлы-буранлы шушы төндә, дип уйлыйм, урман арасында, көрт күмеп киткән аулак бер авылның ярым җимерек өендә ялгыз башым каңгырып утырам; шәһәрнең шаулы тормышы, күнегелгән мохиты, кешеләре, сүзләре-бәхәсләре һәм хатын-кызларының күңелле көлүләре — болар барысы да кайдадыр бик-бик ераста, йөзәр чакрымнар ераста калган... Һәм миңа карлы-буранлы бу төн бик озакка, уннарча елларга сузылыр, мин үлгәнчегә хәтле дәвам итәр шикелле; тәрәзә артында җил мәңге шулай улап ыжгырыр, көйгән яшел абажурлы лампа һаман шулай тоныk нурларын сирпеп мәңге янар шикелле; мин үзем дә, борчулы уйларга чумып, һаман шулай бүлмә буенча әрле-бирле киләп сарып йөрермен, ә Ярмола, — дөньяда бернәрсәгә дә: өендә бер кабым ризык юклыкка да, җил котырынуына да, минем болай әрнеп сагышлануыма да исе китмәгән, үтә гамьсез, сәер һәм минем өчен бөтенләй чит-ят булган Ярмола, — үз-үзенә йомылган хәлдә, гомере буе әнә шулай мич каршында дәшмичә утырыр шикелле.

Кинәт миндә шушы алҗыткыч, эчпошыргыч тынлыкны кеше авызыннан әйтелгән нинди дә булса бер сүз белән бозарга иде дигән тыелгысыз бер теләк туды.

— Син ничек уйлыйсың, Ярмола, бу җил каян чыкты икән? — дидем мин.

— Җилне әйтәсезме? — диде Ярмола һәм иренеп кенә башын күтәрде. — Каян чыкканын паныч әллә белмиме?

— Әлбәттә, белмим. Каян белим ди мин аны?

— Чынлап та белмисезме? — диде Ярмола, кинәт җанланып китеп. Аннары, тавышына бер серлелек өстәп, дәвам итте: — Алайса, мин сезгә әйтим. Кайдадыр, димәк, җен туган яисә убырлар туй итә. Менә каян чыга ул җил!

— Кем ул убыр? Сезнеңчә сихерче дигәнне аңлатамы?

— Ие, ие... сихерче, убырлы карчык.

Мин комсыз бер өмет белән Ярмолага ябырылдым. «Кем белә аны, — дип уйладым мин эчемнән, — бәлкем, ул миңа хәзер төрле сихер, күмелгән хәзинә һәм өрәкләр хакында берәр кызыклы вакыйга сөйләп бирер?..»

— Соң сезнең монда, Полесьеда, убырлар бармы? — дип сорадым мин.

— Белмим... Бәлки, бардыр да, — диде Ярмола гамьсез генә һәм янә мич каршына чүгәләде. — Картлар сөйлиләр, элегрәк барые, диләр... Бәлки, дөрес тә түгелдер...

Минем шундук күңелем сүрелде. Аз сүзлелек Ярмоланың үзенә генә хас бер сыйфаты иде, шуңа күрә мин әлеге кызыклы мәсьәлә хакында аңардан ни дә булса сөйләттерә алырмын дигән уемнан өметемне өздем. Ләкин ул, минем чиксез гаҗәпләнүемә каршы, кинәт яңадан сүз башлады:

— Биш-алты ел элек бездә шундый бер убырлы карчык булганые... Тик егетләр аны авылдан сөрделәр, — диде ул иренеп кенә, миннән битәр гүләп торган мичкә мөрәҗәгать иткәндәй.

— Кая сөрделәр?

— Кая булсын!.. Урманга инде... Тагын кая сөрсеннәр? Өен дә җимереп ташладылар, кәһәр суккырының оясы да калмасын дип... Ә үзен акулчадан муен тамырына тамызып озатып җибәрделәр.

— Нигә шулай бик яман кыландылар соң?

— Кара эшләре күп булды аның: кешеләр белән бик тиргәшә иде, өй нигезләренә әллә нинди сихерле, агулы сулар сибә, игеннәрне корыта иде... Бер заманны бу авылдагы бер киленкәйдән злот, ягъни унбиш тиен акча сораган. Теге әйтә икән моңа: «Бернинди злотым юк, бәйләнмә әле», — ди икән. «Ярар алайса, — ди икән бу, — миңа злот бирмәгәнең өчен кайчан да булса бер үкенерсең әле», — ди икән. Шуннан шул булды, паныч: әлеге киленкәйнең оланы бер заман авыруга сабышты. Шулай чирләде-чирлә-

де дә үлеп тә китте. Менә шул чакны сөрделәр дә инде ул убырлы карчыкны, күзе чыккырыны...

— Ә хәзер кайда соң ул убырлы карчык дигәнең? — дидем мин, кызыксына биреп.

— Убырлы карчыкмы? — дип, гадәтенчә, кабатлап сорады Ярмола әкрен генә. — Мин каян белием аны?

— Авылда аның берәр кардәше калгандыр бит? — дидем мин.

— Юк, беркеме калмады. Ул үзе читтән килгән кешеие, кацапмы [1] шунда, чегәнме... Ул безнең авылга килгәндә, мин малай гына идем әле. Аңа бер кыз олан да ияреп килгәние, әллә үз кызы, әллә оныгы шунда... Иковесен дә сөрделәр...

— Ә хәзер аның янына барып йөрүче бармы соң: әйтик, багарга яисә берәр төрле сихерле су сорарга?

— Хатын-кыз баргалап йөри бугай, — дип әйтеп куйды Ярмола, кимсетүле бер тавыш белән.

— Әһә! Димәк, аның торган җире билгеле, шулаймы?

— Мин үзем белмием... Болай сөйләвен сөйлиләр, кайдадыр Шайтан Чокыры тирәсендә тора диме шунда... Беләсезме икән, Ириновка юлыннан ары бер сазламык җир бар, менә шунда яшәп ята, ди, каһәр суккыры!

«Чын, тере сихерче — Полесье сихерчесе — минем өйдән нибары тугыз-ун чакрымда гына яшәсен, имеш. Бик кызык бит бу!» — дип уйладым мин, гадәттән тыш бер дулкынлану белән.

— Карале, Ярмола, — дидем аннары, урман каравылчысына эндәшеп, — миңа шул убырлы карчык белән танышырга мөмкин булмасмы икән?

— Тфү! — диде Ярмола нәфрәт белән. — Тапкансыз танышыр кеше!

— Тапканмынмы-юкмы, мин барыбер аның янына барырга тиеш. Бераз көннәр генә җылына төшсен, чыгам да китәм менә. Син мине озата барырсың бит?

Минем соңгы сүзләрем Ярмоланы шулкадәр гажәпләндерде ки, ул хәтта идәннән сикереп торды.

— Минме?! — дип кычкырды ул, тәмам бусарынып. — Үтерсәгез дә бармыйм! Ходаның үз әмере булса да бармыйм!

— Сөйләмәче юкны, барасың.

— Юк, паныч, бармыйм дигәч бармыйм... Үтерсәгез дә бармыйм менә... Шунда барыргамы?! — дип кычкырды ул тагын, күңелендә күтәрелгән нәфрәт хисеннән нишләргә

---

[1] *Кацап* — Полесьеда русларга бирелгән кушамат.

белмичә. — Шул сихер оясына барыргамы? Ходай җанымны алам дисә дә аяк атламыйм. Шулай ук сезгә дә барырга киңәш итмим.

— Теләсәң нишлә алайса... ә мин барам. Аны күреп сөйләшү минем өчен бик кызык булачак.

— Анда бернинди кызык та юк, — дип мыгырданды Ярмола һәм ачу белән мич капкачын шапылдатып япты.

Бер сәгатьтән, табынны җыеп, караңгы чоланда чәй эчеп алганнан соң, Ярмола үз өенә кайтырга җыена башлады. Шунда мин аңардан:

— Ә ул убырлы карчык ни атлы? — дип сорадым.

— Мануйлиха, — диде Ярмола караңгы чырай белән, дорфа гына итеп.

Ярмола үзенең уй-хисләрен беркайчан да ачыктан-ачык белдермәи, шулай да аның мине бик якын күрүе, үз итүе ачык сизелеп тора иде; аның миңа шулай якынаюында безнең икебезнең дә сунарчы булуыбыз, минем аңа булган гади мөгамәләм, гел ач яшәгән гаиләсенә ара-тирә ярдәм иткәләвем һәм, бигрәк тә, Ярмоланы аның күңеленә иң тия торган гадәте — эчкечелеге белән битәрләмәвем сәбәпче иде булса кирәк. Шуңа күрә минем үҗәтләнеп сихерче карчык белән танышырга теләвем аны тәмам рәнҗүле бер халәткә кертте; ачудан ул бертуктаусыз борынын тарткалады, ә болдыр баскычына чыккач, аягы белән бөтен көченә селтәнеп, искәрмәстән этенең корсагына тибеп җибәрде. Мескен эт — Рябчик — чинап читкә сикерде, әмма үзе шундук чиный-чиный Ярмола артыннан иярде.

III

Ике-өч көннән һавалар җылына төште. Беркөнне иртән, таң белән үк, минем бүлмәгә Ярмола килеп керде дә гадәттәгечә гамьсез бер чырай белән:

— Паныч, мылтыгыгызны чистартырга кирәк булыр, — диде.

— Нәрсә бар? — дидем мин, юрган астында киерелгәләп.

— Төнлә куян бик йөренгән: эзләре күп, бәлки, пан урманына чыгып керербез?

Аучыларга хас сабырсызлыгын тышкы ваемсызлык астына яшерергә тырышса да, Ярмоланың тизрәк урманга китәргә ашкынуын мин шундук шәйләп алдым. Чыннан да, аның бер көпшәле ау мылтыгы алгы якта әзер тора икән инде. Көпшәсенең авызы тутыккан һәм, дары газларыннан тәмам ашалып, аңа берничә урыныннан кургашын ямау

салынган булса да, бу иске мылтыктан бер генә чуллыкның да качып китә алганы юк иде әле.

Урманга килеп керүгә үк без куян эзенә юлыктык: алгы ике тәпи янәшә, ә арттагы икесе — аллы-артлы. Куян, юлга чыгып, берничә йөз сажень чамасы җир барган да, кырт тукталып, юлдан яшь наратлар куелыгына сикергән.

— Болай булгач, без аның каршысына әйләнеп чыгабыз инде, — дип куйды Ярмола. — Димәк, куян кайдадыр шушы тирәдә генә шыңкаеп ята. Сез, паныч... — дип дәвам итте ул аннары һәм, мине кая җибәрергә кирәклеген үзенә генә таныш ниндидер билгеләр буенча чамалагандай, бераз уйланып торды... — Сез теге иске алачыкка хәтле барыгыз. Ә мин аны Замлын ягыннан урап узам. Куянны эт өркетеп чыгаргач та, мин сезгә аваз бирермен.

Ярмола, гүя суга чумгандай, шундук куе әрәмәлек арасына кереп югалды. Мин колак салып тыңларга керештем. Ул браконьерларча бөтенләй тавышсыз-тынсыз атлый, ә озын кунычлы юкә итек кигән аягы астында бер генә дә чыбык-чабык сынган тавыш ишетелми иде.

Мин ашыкмыйча гына ылыслы урман читендәге иске алачыкка киттем. Ярым җимерек һәм кешесез бу өйгә барып җиткәч, озын, төз һәм шәрә кәүсәле бер нарат агачы астына кереп постым. Бөтен тирә-як кышкы җилсез урманда гына була торган хозур бер тынлыкка чумган. Ботаклар, ылысларына кунган кабарынкы авыр кар япмасыннан сыгыла төшеп, агачларга ниндидер бәйрәмчә сокланғыч һәм салкын бер төс биреп торалар. Ара-тирә агач башыннан нечкә генә берәр ботак ычкынып китә дә, һавада аермачык яңгырап, аның аскы ботакларга шарт-шорт бәрелә-сугыла түбән очканы ишетелә. Кояш төшкән урыннарда кар япмасы алсуланып, ә күләгәдә зәңгәрсу нурлар чәчеп җемелди. Тантаналы һәм салкын бу тынлык үзенең изрәткеч хозурлыгы белән мине тәмам үзенә буйсындырды; мин хәтта үз янымнан әкрен генә, тавыш-тынсыз гына вакыт узып барганын да тойгандай булдым...

Кинәт ераста, куе агачлар арасында, эт өргән тавыш ишетелде. Бу — Рябчик иде: аның вакыт-вакыт бөтенләй диярлек чинауга күчә торган үртәлүле һәм калынлы-нечкәле бер тавыш белән өрүе ниндидер җәнлек артыннан куып барганлыгын аңлата иде. Шундук мин Ярмоланың сөрән салып кычкыруын да ишеттем. Анысы, беренче ижекне хатын-кызларча нечкә, әче тавыш белән сузып, ә икенчесен улагандай калын тавыш белән кистереп, эте артыннан: «У-бый! У-бый!» — дип кычкыра иде (күп вакытлар үткәннән соң гына мин Полесье аучылары арасында нык тарал-

ган бу сүзнең «убивать» — «үтерү» фигыленнән бозылып ясалганын белдем).

Тавышның юнәлеше буенча фикер йөрткәндә, эт җәнлекне миннән сул яктарак куып бара шикелле иде. Аларның каршыларына чыгу өчен мин урман ачыклыгы аша тиз генә шунда йөгердем. Әмма унбиш-егерме адым да китеп өлгермәгәнмендер, шул чакны кинәт каршыдагы бер агач төбе артыннан соргылт йонлы зур гына бер куян атылып чыкты; атылып чыкты да, әллә ни ашыгырга теләмәгәндәй, колакларын шомартып, биек һәм салмак сикерешләр ясый-ясый, юл аша чыкты һәм яшь агачлар куелыгына кереп югалды. Аның артыннан җан-фәрманга куып килгән Рябчик мине күреп чак кына туктагандай итте, сизелер-сизелмәс кенә койрыгын болгап, берме-икеме тапкыр кар тешләп алды да тагын куян артыннан ташланды.

Ул да булмады, куе агачлар арасыннан бернинди тавыш-тынсыз Ярмола үзе килеп чыкты.

— Паныч, нишләп сез куянның юлына аркылы төшмәдегез? — дип кычкырды ул, шелтәләгәндәй, телен шартлатып.

— Ара ерак иде бит... аңа хәтле әле ике йөз адым чамасы бар иде.

Минем гаепле кеше сыман кызара башлавымны күреп, ул бераз йомшара төште.

— Ярар, зарар юк, паныч... Безнең кулдан барыбер ычкына алмас. Ириновка юлына барыгыз — ул хәзер шунда чыгачак, — диде.

Мин Ириновка юлына таба юнәлдем һәм бер-ике минуттан соң ук якында гына янә эт өргән тавыш ишеттем. Миндә кинәт аучылык җене кузгалды. Мылтыгымны әзер тоткан хәлдә, битемә чыбык-чабык сугуга да игътибар итмәстән, ботакларны сындыра-аера, куе куаклык аша алга йөгердем. Шулай шактый озак йөгергәнмендер, күрәсең, чөнки минем сулышым кысыла башлады, һәм кинәт шул вакыт эт өргән тавыш та тукталды. Уңга-сулга борылмый гел шулай туры барсам, Ириновка юлында Ярмола белән очрашмый калмам дигән өметем бар иде минем. Ләкин, юлыма аркылы төшкән агач төпләрен һәм куе әрәмәлекләрне урый-урый эйләнеп чаба торгач, мин бөтенләй читкә тайпылганмын икән. Үземнең адашуымны аңлап, мин Ярмоланы дәшеп карадым. Әмма миңа җавап кайтаручы булмады.

Ул арада мин, аны-моны уйламастан, һаман бардым да бардым. Озакламый урман сирәгәя төште, җир сөзәкләнгәннән-сөзәкләнә барып, түмгәкләр күренә башлады. Кар-

га уелып кергән аяк эзе шундук караеп китә һәм су белән тула иде. Берничә мәртәбә инде миңа тез тиңентен чаклакка батарга туры килде. Янә андый хәтәр хәлгә юлыкмас өчен, мин түмгәктән түмгәккә сикереп бара башладым. Соргылт төстәге куе мүк капланган бу түмгәкләр аяк баскан саен йомшак келәм сыман уелып-уелып керә иде.

Куаклыклар тиздән бөтенләй бетте. Ниһаять, мин зур гына бер түгәрәк сазлыкка килеп чыктым. Сазлык тоташ кар җәймәсе белән капланган булып, бу ак җәймә астыннан әле анда, әле монда карасу түмгәкләр калкып тора иде. Сазлыкның аргы ягында, агачлар ышыгында, ак стеналы ниндидер өй күзгә чалынды. «Ириновка урманы каравылчысының өедер, — дип уйладым мин. — Кереп, юлны сорашып чыгарга кирәк булыр».

Ләкин ул өйгә алай бик җиңел генә барып җитеп булмады. Моның өчен миңа адым саен сазга батарга туры килде. Итекләремә тулган су чупыр-чупыр килә, аякларны өстерәү авырайганнан-авырая бара иде.

Азаплана торгач, ниһаять, сазлыкны кичеп, калкурак урынга күтәрелдем дә әлеге йорт каршына килеп туктадым. Йорт дигәннән, ул чын мәгънәсендә йорт та түгел, ә тылсымлы әкиятләрдә сөйләнелә торган уенчык өй сыман бернәрсә иде. Язын бөтен Ириновка урманын су баскангадыр, күрәсең, өй субайлар өстенә, идәнен җирдән шактый югары күтәртеп салынган иде. Ләкин, вакыт үтү белән, аның бер як стенасы иңә төшкән, шуның аркасында ул хәзер чатан кеше сыман бер якка янтаеп, моңсуланып утыра иде. Тәрәзәләрендә дә берничә өлгесенең пыяласы юк, пыяла урынына ул тишекләрне тышкы якка бүлтәеп торган әллә нинди керле чүпрәкләр белән томалап куйганнар иде.

Мин келәне ычкындырдым да өй ишеген ачып эчкә кердем. Өй миңа бик караңгы булып тоелды, чөнки иртәдән бирле җемелдәвек ак карга карап йөри-йөри минем күз алдымда инде әллә нинди шәмәхә таплар уйнаклый башлаган иде. Мин өй эчендә кеше бармы, юкмы икәнен дә бик озак аера алмый тордым.

— Әй, өйдә кеше бармы соң? — дип сорадым мин, сабырсызланып.

Мич янында нәрсәдер кыймылдап куйды. Мин якынрак килдем һәм идәндә утырган бер кортканы күрдем. Аның каршында бер өем тавык каурые ята иде. Кортка каурыйларны берәм-берәм кулына алып, йонын сыпырып төшерә дә, йонны кәрҗингә, ә шәрә каурыйларын идәнгә ташлый бара иде.

Кортканы тагын да җентекләбрәк караштыра торгач, минем күңелдә кинәт: «Тукта әле, бу теге Ириновка сихерчесе Мануйлиха түгелме соң?» — дигән бер уй чагылып узды. Гадәттә, халык риваятьләрендә убырлы карчыкларны сурәтли торган барлык билгеләр бу корткада да аермачык ярылып ята иде. Шундый ук эчкә баткан ач яңак; алга таба очлаеп китеп, салынкы кәкре борыны белән тоташа язган озын, ләпердәвек ияк; эчкә убылган тешсез авыз; ул авыз, нәрсәдер чәйнәгәндәй, гел кыймылдап, йөреп тора; кайчандыр зәңгәр төстә булган, хәзер инде зәңгәрлеге шактый уңа төшкән түгәрәк, калку күзләре исә, куркынычлы кош күзләре сыман, салкын-нурсыз шом белән карыйлар.

— Исәнме, әби! — дидем мин, мөмкин кадәр ягымлырак булырга тырышып. — Син Мануйлиха әби буласыңмы әллә?

Җавап урынына карчыкның күкрәгендә нәрсәдер бытырдап, хырылдап куйды; аннары тешсез авыздан, әле сулышы кысылган карт карга карылдавына охшап, әле өзек-өзек чәрелдәүгә күчеп, шыш-шыш иткән әллә нинди сәер авазлар ишетелде:

— Әүвәле заманнарда игелекле адәмнәр, шаять, шулай, Мануйлиха дип тә йөрткәннәрдер... Ә хәзер исемем кук, хәл белүчем юк. Сиңа ни кирәк? — дип сорады ул тәкәллефсез генә, үзенең эчпошыргыч эшен дәвам итеп.

— Менә адашып килеп чыктым әле, әбекәй. Синдә сөт табылмасмы икән дип кергән идем.

— Бернинди сөтем юк, — дип кырт кисте карчык, ачу белән. — Күп булыр монда сездәй адашып йөрүчеләр... Һәммәгезне ашатып-эчертеп бетерә алмассың...

— Син, әби, кунакларга бик үк ягымлы түгел икәнсең.

— Хак сүз әйтәсең: бөтенләй дә ягымлы түгелмен. Сезнең өчен аерым сый-нигъмәт тотмыйбыз. Арыгансың икән, утырып ял ит, сине өйдән беркем кумый. Ничек диләр әле: «Теләсәгез, өй эргәбезгә килеп утырыгыз, безнең бәйрәмнең чыңын тыңлагыз, ә сыйлануын без үзебез дә сыйлана белербез». Менә шулайрак, егет.

Карчыкның сөйләү рәвеше аның чыннан да монда читтән килгәнлеген күрсәтә иде. Төньяк кешеләренә хас тасма теллелекне, сирәк очрый торган үткер сүзләр кушып сөйләүне бу якта яратмыйлар гына түгел, аңламыйлар да иде. Ул арада карчык, үз эшен туктаусыз дәвам иткән хәлдә, авыз эченнән һаман нидер мыгырдануында булды. Тик аның тавышы торган саен әкренәйгәннән-әкренәя бара иде. Мин аның бәйләнешсез, буталчык сүзләреннән берни дә

аңламадым диярлек: «Менә сиңа Мануйлиха әбекәй... Ә кем ул — беркем белми... Яшем зур инде минем, яшь түгелмен... Аягын болгый, такылдапмы-такылдый — кыбырсык саескан диярсең...»

Күпмедер вакыт аның шулай үзалдына сөйләнүен тын гына тыңлап тордым; һәм кинәт: каршымда — акылыннан язган хатын, ахры, дигән уй мине җирәнү катыш бер өркү хисе белән тетрәндереп җибәрде.

Шулай да мин өй эчен тиз генә күздән кичерергә өлгердем. Бүлмәнең яртысын диярлек акшары кубып беткән гаять зур мич били иде. Почмакта тәре-фәлән юк. Стеналарга гадәттәге яшел мыеклы аучы, шәмәхә йонлы эт сурәтләре һәм беркем белмәгән әллә нинди генералларның портретлары урынына бәйләме-бәйләме белән кипкән үлән, бөрешкән тамырлар эленгән, шүрлекләргә савыт-саба куелган. Сихерчеләр өендә була торган кара песи дә, мәче башлы ябалак та күренми, аның каравы мич башыннан миңа таба дәү генә ике чуар сыерчык гажәпләнеп карап тора иде.

— Әби, һич югы су гына булса да бардыр бит инде сездә? — дип сорадым мин, тавышымны күтәрә төшеп.

— Әнә шунда, кисмәктә, — диде карчык, башы белән ымлап.

Судан ниндидер сөрсегән нс, саз тәме килә иде. Су өчен карчыкка рәхмәт әйткәч (рәхмәтне ул колагына да элмәде), мин аңардан олы юлга ничек чыгарга икәнен сорадым.

Ул кинәт башын күтәрде, миңа таба карчыганыкыдай салкын, үткен күз карашын юнәлтте дә, ашыгып, сабырсызланып, мыгырданырга тотынды:

— Бар, бар... Бар, юлыңны кара, егеткәй. Сиңа монда берни калмаган. Кунакның вакытында китә белгәне хәерле. Бар, балакай, үз юлыңда бул...

Чыннан да, чыгып китүдән башка чара калмаган иде миңа. Ләкин шул чакны миндә, кортка күңелен акча белән йомшартып булмасмы, дигән бер уй туды. Мин кесәмнән өр-яңа егерме биш тиенлек көмеш чыгарып, аны Мануйлихага таба суздым. Ничек дөрес юраганмын диген: акчаны күрүгә, кортка кинәт кыймылдап куйды, күзләрен зур ачып, дерелдәп торган кәкре һәм буынлы-буынлы бармаклары белән кабаланып акчага үрелде.

— Э-э, юк, Мануйлиха әбекәй, бушка бирмим, — дигән булдым мин, үртәп, һәм көмеш тәңкәне учыма йомарладым. — Син башта миңа багып күрсәт.

Сихерче карчык ачыктан-ачык канәгатьсезләнү белән

җыерчыклы, бөрешкән йөзен чытты. Ул, икеләнгәндәй итеп, минем акча яшерелгән учыма ничектер шикләнеп һәм кырын күз белән карап алды. Ләкин комсызлык, күрәсең, көчлерәк иде.

— Ярый, әйдә алайса, багып карыйк, — диде ул, сүзләрен көчкә әвәләп, һәм авырлык белән идәннән торып басты. — Мин бит хәзер беркемгә дә карта бакмыйм, балакаем... Андый эшләр онытылды инде... Картаелды, күзләрем күрми. Тик синең өчен баксам гына...

Бөкре гәүдәсе белән калтырана-калтырана, ул стенага тотынып өстәл янына килде һәм күп файдаланудан тәмам таушалып, калынаеп беткән соргылт уен карталарын кулына алды да, аларны бик һәйбәтләп аралаштыргач, колодасы белән миңа таба сузды.

— Яле, шудырт... Сул кулың белән шудырт... Йөрәккә якыны белән...

Аннары, бармакларына төкереп, карталарны берәмтекләп-берәмтекләп үзенә бер тәртиптә таратырга кереште. Карталар өстәл өстенә камыр җәймәседәй шапылдап барып төшәләр һәм сигез почмаклы йолдыз сурәте сыман тезелә баралар иде. Соңгы картаны сурәтле ягы белән король өстенә каплагач, Мануйлиха әби кулын миңа таба сузды һәм чегәннәрчә көйләп-вәземләп теләнергә тотынды:

— Игелегеңне күрсәт, мәрхәмәтле егет... Бәхет-сәгадәткә ирешерсең, мал-мөлкәтле булырсың...

Мин аңа учымдагы көмеш акчаны төрттем. Кортка, маймылча өлгер бер хәрәкәт белән, шундук аны алып уртына яшерде.

— Сине алда озын юл һәм зур бәхет көтә, — дип тезеп китте ул. — Син буби дамасы белән очрашырга һәм зур йортта ниндидер күңелле сөйләшү алып барырга тиешсең. Озакламый треф короленнән көтелмәгән хәбәр килер. Алда тагын ниндидер мәшәкать-борчулар чыгасы бар, аннары кулыңа күпмедер акча да керәчәк. Зур мәҗлескә юлыгырсың, анда эчеп исерерсең. Аяктан егылганчы ук түгел түгелен, шулай да исерәчәгеңне карта ачык әйтә. Гомерең бик озын булыр. Әгәр дә алтмыш җиде яшеңдә үлмәсәң, ул чакны...

Мануйлиха әби, кинәт сөйләүдән туктап, ниндидер тавышка колак салгандай, башын күтәрде. Мин дә сагаеп калдым. Бераздан җырлый-җырлый өйгә якынлашып килгән ниндидер кызның көчле һәм яңгыравыклы тавышы ишетелде. Сүзләренә караганда, ул дәртле малорус җырын башкара иде:

Ой чи цвит, чи не цвит
Калиноньку ломит.
Ой чи сон, чи не сон
Головоньку клонит [1].

— Инде син кит, егеткәй, бар кит, — диде карчык борчулы төстә һәм, кабаланып, тизрәк мине өстәл яныннан эткәләргә тотынды. — Кеше бусагасын таптап йөрисе юк. Бар, үз юлыңда бул...

Ул хәтта, курткам җиңеннән элөктереп, мине ишеккә таба өстери үк башлады. Аның йөзендә нинди кыргый бер шом, борчу чагыла иде.

Әлеге җыр җырлап килүченең моңлы тавышы кинәт бөтенләй якында, өй янында гына өзелеп калды да, тимер келә шалтырап, ишек иңләй ачылып китте һәм бусагада озын зифа буйлы, көләч йөзле бер кыз күренде. Ике кулы белән ул бик сакланып кына үзенең буй-буй төшкән бизәкле алъяпкыч итәген кайтарып тоткан иде. Итәк кырыннан исә, нечкә кызыл муеннарын сузып, чем-кара, елтыр күзле өч кошчык карап тора иде.

— Карале, әбекәем, бу кызылтүшләр тагын миңа тагылып кайттылар, — диде ул, шаркылдап көлеп. — Күр инде, нинди сөйкемлеләр... Бөтенләй ачыкканнар, мескеннәр. Ә минем, үч иткәндәй, янымда ипием булмады.

Ләкин шулчак мине күреп, кыз кинәт сүзеннән туктады, һәм бөтен бите комачтай кызарынды. Аның нечкә кара кашлары ачулы төстә җыерылып куйды, күзләре сорау белән карчыкка текәлде.

— Менә барин кергән... Юл сораша, — дип аңлатты карчык. Аннары, миңа таба борылып, кискен итеп өстәп куйды: — Ярый, чибәр егет, юкны бушка аударып утырма, юлыңда бул. Су эчтең, сөйләштең, инде чама белергә дә кирәктер. Без сиңа иш кешеләр түгел...

— Карале, чибәркәй, — дип эндәштем мин кызга, — зинһар өчен, миңа Ириновка юлын гына күрсәтеп бирче, юкса, сезнең бу сазлыктан гомергә чыга алмассың.

Сүзләремне шундый йомшак һәм үтенечле бер аһәң белән әйтүем кызга тәэсир итте булса кирәк. Ул, үзенең кызылтүшләрен саклык белән генә мич башына — сыерчыклары янәшәсенә утыртып, элек үк салып кулына тоткан кыска җиләнен ян сәкегә ыргытты да, бер сүз эндәшмичә, тышка чыгып китте.

---

[1] Әллә чәчәк, әллә түгел
Баланнарны сындыра.
Әллә йокы, әллә түгел
Башымны салындыра.

Мин аның артыннан иярдем.

— Синең ул кошларың кулга ияләшкәнмени? — дидем мин, кызны куып җитеп.

— Әйе, кулга ияләшкән, — дип җавап бирде кыз, миңа бөтенләй күз төшермәстән. — Менә, карагыз, — диде ул аннары, читән янында туктап. — Күрәсезме сукмакны, әнә, әнә тегендә, нарат агачлары арасыннан сузылып киткән? Күрәсезме?

— Күрәм...

— Шул сукмактан туп-туры барыгыз да барыгыз. Имән түмәренә барып җиткәч, сулга борылырсыз. Аннары урман эчләтеп тагын туп-туры барыгыз. Шуннан инде Ириновка юлына килеп чыгарсыз.

Уң кулын алга сузып, миңа юл юнәлешен аңлаткан арада, мин кызга ирексездән сокланып карап тордым. Аңарда бу як кызларын — башларына шыксыз яулык урап, маңгайларын, ияк һәм авызларын томалап йөрүче, куркынган йөзләре белән һәммәсе дә бер үк төрле тәэсир калдыручы җирле халык кызларын хәтерләткән бернәрсә дә юк иде. Минем яңа танышым егерме-егерме биш яшьләр чамасындагы озын буйлы, коңгырт-кара чәчле бер кыз булып, ул үзен гаять табигый һәм нәзакәтле тота иде. Өстенә кигән иркен ак күлмәге яшь таза күкрәкләренә гаҗәеп матур рәвештә ятып тора. Бер күргәч, аның үзенчәлекле чибәр йөзен һич онытырлык түгел, шул ук вакытта аны, никадәр генә күп күзәтсәң дә, тасвир итеп булмас шикелле иде. Урталай сыныбрак торган нәзек кашлар аның елтыр зур кара күзләренә ниндидер серле шаянлык, боеручанлык һәм самимилек өсти; алсуланып торган кара тутлы бит алмалары һәм үзенә бертөрле тәвәккәллек, кыланчыклык белән турсаебрак торган килешле иреннәре — болар һәммәсе дә сокланғыч, үзенчәлекле иде.

— Шундый аулак җирдә ялгыз яшәргә сез ничек курыкмыйсыз? — дип сорадым мин, читән янында тукталып.

Кыз ваемсыз гына иңбашын җыерып куйды.

— Нәрсәдән куркырга? Монда бүреләр килеп йөрми.

— Хикмәт бүредә генәмени... Көрт басып китүе бар, янгын чыгуы бар... Аэмыни шундый күңелсезлекләр. Сез монда берьялгызыгыз, сезгә ярдәмгә килергә дә өлгермәячәкләр.

— Өлгерәүләре шөкер! — дип кулын селтәде кыз, исе китмичә генә. — Әби белән икебезне бөтенләй тынычлыкта калдырсалар, бигрәк тә яхшы булыр иде әле, юкса...

— Нәрсә юкса?

— Күпне белсәгез, тиз картаерсыз, — дип кырт кисте

кыз, аннары борчулы кыяфәттә сорап куйды: — Ә сез үзегез кем буласыз соң?

Шулчак мин, карчык та, бу чибәр кыз үзе дә «тәртип нияләренең» берәр төрле җәбере төшүдән куркалардыр, ахрысы, дип уйлап алдым һәм кызны тизрәк тынычландырырга ашыктым:

— О! Зинһар өчен, борчылма! Мин урядник та, писер да, салым җыючы да түгел — кыскасы, мин бернинди түрә түгел.

— Юк, сез чынлап әйтәсезме?

— Чын менә, ант итеп әйтәм. Мин бит бөтенләй мондагы кеше түгел. Бары кунакка дип кенә килдем... берничә айга... аннары тагын китәм. Әгәр теләсәң, мин хәтта монда булуымны, сезне күрүемне беркемгә әйтми алам. Син миңа ышанасыңмы?

Кызның йөзе бераз ачылып киткәндәй булды.

— Әгәр сүзегез ялган түгел икән, дөресен әйтәсез булыр. Сез ничек соң: безнең хакта электән ишетеп килдегезме, әллә болай гына кердегезме?

— Сиңа ничек дип әйтергә инде... Ишетүен ишеткән идем, хәтта кайчан булса да бер сезгә килеп чыгарга да уйлаган идем. Тик бүген мин сезгә бөтенләй көтмәгән җирдән адашып кердем... Ә хәзер син әйт инде: нигә сез кешеләрдән куркасыз? Аларның сезгә нинди зыяны тия?

Кыз, шикләнгәндәй, миңа сынаучан күзләре белән төбәлеп карады. Ләкин мин, вәжданым саф булганга, аның бу күз карашын керфек тә какмыйча күтәрдем. Шуннан соң ул көчәя барган эчке бер сагыш белән сүзгә кереште:

— Алар безне гел җәберлиләр... Гадирәк халык дигәне ярый әле, ә менә түрә-мүрәсе... Уряднигы килсә — анысы зыян итеп китә, становое килсә — тагын шул ук хәл. Җитмәсә, зыян итеп кенә дә калмый, әбине мыскыл итә: син, янәсе, убырлы карчык та теге-бу, иблис токымы, каторжанка... Их! Сөйлисе генә бармы!

— Ә сиңа тимиләрме соң? — дип, аны-моны уйламастан, сорап куйдым мин.

Кыз, үз-үзенә нык ышанулы бер тәкәбберлек, масаю белән, башын астан өскә таба капылт кына чөеп җибәрде дә, кысыла төшкән күзләрендә тантаналы усал очкыннар уйнатып:

— Юк, тимиләр... — диде. — Бер тапкыр нинди дер землемер тыкшынып караган иде каравын... Иркәләнәсе килгән, күрәсең... Шул, минем иркәләвемне хәзергә хәтле оныта алмый торгандыр әле...

Үзенә бертөрле горурлык белән әйтелгән бу мыскыл

сүзләрендә шундый тупас, буйсынмас бәйсезлек сизелеп китте ки, мин ихтыярсыз: «Син юкка гына Полесье урманында үсмәгәнсең икән, синең белән шаярту чыннан да куркыныч булырга охшый», — дип уйлап куйдым.

— Ә безнең кемгә дә булса зыяныбыз тиямени! — дип дәвам итте кыз, миңа карата булган ышанычы артканнан арта барып. — Безгә кешенең һич кирәге юк. Авылга да мин елга бер мәртәбә — сабын белән тоз алырга кирәк булганда гына барып киләм... Аннары менә әбигә чәй кирәк булганда, — чәй эчәргә бик ярата ул. Ә болай адәм затын гомер күрмәсәк тә исебез китәсе түгел.

— Әйе, күрәм, син дә, әбиең дә кеше килеп йөргәнне яратмыйсыз икән... Ә шулай да беразга гына мин килеп чыксам... каршы килмәссезме соң?

Кыз көлеп җибәрде, һәм аның нәфис йөзе ничектер сәер рәвештә берьюлы үзгәреп китте. Әүвәлге кырыслыкның әсәре дә калмыйча, ул кинәт кенә яктырып, сабыйларныкыча көләч, оялчан бер төс алды.

— Ә сез бездә нишләрсез? Без бит әби белән бик кызыксыз кешеләр... Хәер, шундый яхшы күңелле кеше булгач, килеп чыгыгыз соң. Тик менә... безгә киләсе итсәгез, зинһар, мылтыксыз гына килегез...

— Куркасыңмы әллә?

— Нишләп куркыйм? Бернидән дә курыкмыйм, — диде кыз, һәм аның тавышында янә үз көченә нык ышанганлык сизелде. — Мылтык асып йөрүчеләрне яратмыйм мин. Кошларны нигә үтерергә? Яки менә куяннарны? Алар беркемгә бернинди начарлык эшләмиләр ич, аларның да дөньяда яшиселәре килә, сезнең белән безнең кебек үк. Мин үлеп яратам аларны: шундый кечкенә, шундый беркатлы бит алар... Шулай да, миңа өйгә керергә вакыттыр, хушыгыз, — диде ул кинәт, кабаланып. — Тик менә олылап әйтергә исемегезне генә белмим икән... Әби ачулана башламагае.

Һәм ул, җил чуалткан толымнарын кулына җыеп тотып һәм башын ия төшеп, җиңел, кызу адымнар белән өйгә таба йөгереп китте.

— Әй, туктале, тукта! — дип кычкырдым мин. — Үзең ни атлы соң син? Танышкач инде исемебезне әйтеп танышыйк.

Кыз, бер мизгелгә генә туктап, миңа таба борылды.

— Алена минем исемем. Мондагыча әйтсәк — Олеся.

Мин мылтыгымны иңбашыма астым да күрсәтелгән юнәлеш белән китеп бардым. Урманның беленер-беленмәстәй тар сукмагы башланып киткән кечкенә калкулык өсте-

иә менеп җиткәч, мин артыма борылып карадым. Өй болдыры баскычында басып торган Олесяның кызыл юбкасы, күз камаштыргыч ак кар җәймәсендәге ачык бер тап сыман, әле һаман талгын җилдә җилфердәп күренә иде.

Мин өйгә кайтып бер сәгать чамасы үткәннән соң, Ярмола да кайтып керде. Юк-бар сөйләшүләр белән баш катырырга яратмаган гадәте буенча, ул минем кайда, ничек адашып йөрүем турында берни дә сорашмады. Тик сүз юктан сүз булсын дигәндәй генә, битараф бер кыяфәттә әйтеп куйды:

— Анда... кухняда куян түше ята... кыздырабызмы, әллә кемгә дә булса бирергә кушасызмы?

Мин, хәбәрем белән аны шаккатырырга теләп һәм шаккатырачагыма тәмам ышанып:

— Ә син, Ярмола, бүген минем кайда булганымны белмисең бит әле? — дидем.

— Нигә белмәскә? — диде Ярмола, ачулы мыгырдап. — Убырларга баргансыз...

— Каян белдең?

— Ничек инде белмәскә? Аваз бирмәгәч, мин кире борылдым да сезнең эзгә чыктым... Их, паны-ыч! — дип өстәде ул, аяныч катыш шелтә белән. — Кирәкмәс иде сезгә, паныч, андый эшләр белән маташырга... язык бит!..

IV

Бу елны яз иртәрәк һәм — Полесьеда һәрвакыт булгандагыча — көтмәгәндәрәк килде. Тиз арада авыл урамнары әле монда, әле тегендә елтырап аккан болганчык, йөгерек гөрләвекләр белән сызгаланды. Гөрләвекләр, үз юлларында очраган һәрбер таш-түмгәкләргә ачулы ташланып, күбекләнә-күбекләнә һәм йомычка, каз йоны ише чүп-чарларны айкый-чайкый, туктаусыз алга йөгерәләр; күл булып җыелган сулар өстендә, бөтерчектәй түгәрәк ак күчмә болытлары белән бергә, зәңгәр күк йөзе чагылып күренә; өй кыекларыннан тып-тып тамчы тама. Юл кырыйларындагы өянкеләргә өерләре белән кунаклаган чыпчыклар исә шундый каты итеп, шундый дәртләнеп чырылдыйлар ки, аларның ул чыр-чуы аша бүтән бернәрсәне дә ишетерлек түгел. Һәркайда язгы, шатлыклы, ашкынулы бер җанлану сизелә иде.

Менә кар да эреп бетте. Тик уйсу урыннарда һәм күләгәле урман ешлыкларында гына ара-тирә утраучыклар булып көпшәк һәм шакшы кар түтәрәмнәре торып калды. Кыш буе ял иткән һәм хәзер, кардан чистарынып, кары-

нын шифалы дымга туендырган шәрә, юеш җир яңа тереклек яралгылары тудыру дәрте белән яши башлады. Каракучкылланып яткан яланнар өстеннән, көйрәгендәй, җиңелчә бу күтәрелә иде. Бөтен тирә-як туңы кайткан җылымса җир исе — хәтта шәһәр шартларында да мең төрле исләр арасыннан сизелеп тора торган куәтле, дәртләндергеч, исерткеч яз исе белән тулды. Бу хуш ис белән бергә **минем күкрәгемә, гүя,** тынгысыз өметләр, томанлы шик-шөбһәләр белән сугарылган татлы, моңлы яз сагышы — гадәттә барлык хатын-кызларны чибәр итеп күрсәтә һәм моңарчы булып узган язларны сагындырып искә төшерә торган шигъри бер сагыш кереп урнашты. Төннәр җылына төште. Аларның дымлы, куе караңгылыгында табигатьнең яшерен һәм ашкынулы иҗади эше кайнаганлыгы сизелә иде...

Бу язгы көннәрне минем күңел күгендә гел Олеся әйләнеп йөрде. Мин, бүлмәмдә ялгыз калып, еш кына аның турында уйланырга ярата идем. Караватыма чалкан ятам да, уй-хисләрне бер ноктагарак туплар өчен күзләремне йомып, хыялымны эшкә җигәм: Олесяның әле кырыс, әле хәйләкәр, әле мөлаем көләч йөзен, ирекле карурман кочагында үскән һәм шул карурманның яшь чыршылары шикелле үк зифа, кодрәтле булган яшь гәүдәсен, ара-тирә бәрхеттәй аһәңнәр чыгарып яңгыраган ягымлы, шат тавышын күз алдына китерергә тырышам... «Аның һәрбер хәрәкәтендә, кыланышында, сөйләгән сүзендә, — дип уйланам мин, — ниндидер асыл затлылык, тумыштан килгән ниндидер нәфислек, тыйнаклык бар...» Аның соңында мине Олесяның беркадәр серлелек сөреме астына яшеренгән булуы, сихерче дигән яманаты чыгуы, карурман уртасындагы сазлык эчендә ялгыз яшәве һәм, бигрәк тә, теге вакытта миңа әйткән сүзләрендә чагылып калган горурлыгы, үз-үзенә гаять дәрәҗәдә ышанганлыгы бик нык җәлеп итә иде.

Шуңа күрә, урман сукмаклары аз-маз кипшерү белән, минем туп-туры әлеге «тавык кетәгенә» юл тотуым һич тә гаҗәп түгелдер. Шыгырдавык карчыкны юмаларга кирәксә-нитсә дип, мин үзем белән ярты кадак чәй һәм берничә уч шикәр дә алган идем.

Кыз да, карчык та өйдә иделәр. Карчык ялкынланып янган мич каршында нидер эшләп йөри, ә Олеся ян сәкедә җеп эрләп утыра иде. Мин бусаганы атлап, ишекне шапылдатып ябуга, кыз кинәт миңа таба борылып карады, һәм аның кулындагы җебе өзелеп, орчыгы идәнгә төшеп китте.

Карчык, мич эссесеннән саклану өчен учы белән йөзен

каплап, күзен-кашын җимергән килеш, берникадәр вакыт ачулы төстә миңа карап торды.

— Исәнме, әбекәй! — дидем мин, көр тавыш белән. — Әллә мине танымыйсың да инде? Хәтереңдәме, моннан бер ай элек мин сезгә адашып кергән идем? Син әле ул чакта миңа картада багып та күрсәткән идең?

— Никтер хәтеремдә юк шул, егеткәй, — диде карчык, ризасыз кыяфәттә башын чайкап, бернәрсә дә хәтерләмим. Бездә ниең калгандыр һич зиһенем җитми. Без сиңа нинди иш булыйк инде, йә? Без гади, надан кешеләр... Сиңа монда йөрисе юк. Урман зур, кин, юллары күп... шулай булгач...

Мондый караңгы йөз белән каршылауны күреп, мин бөтенләй аптырап калдым. Нишләргә? Карчыкның тупаслыгын шаяртуга борып җибәрергәме, әллә тупаслыкка тупаслык белән җавап бирергәме? Әллә, бер сүз әйтмичә, борылып чыгып китәргәме? Шулай нишләргә белмичә берникадәр вакыт басып торгач, мин ихтыярсыз Олесяга таба борылдым. Ул эчкерсез бер көлемсерәү белән чак-чак кына елмаеп куйды, кабасы яныннан торды да карчык каршына килеп басты.

— Син, әбием, курыкма аңардан, — диде ул, карчыкны тынычландырып. — Явыз кеше түгел ул, безгә яманлык кылмас. Әйдәгез, түргә узыгыз, — дип өстәде ул аннары һәм, карчыкның ачулы мыгырдануына игътибар итмәстән, миңа түр почмактагы яп сәкедәи урын күрсәтте.

Аның җылы, ягымлы сүзләреннән күңелем күтәрелеп, мин үземнең иң көчле коралымны сынап карарга булдым.

— Ай-һай, усал да инде син, әбекәй... Кунак кеше бусаганы атлап керергә өлгермәгән, ә син аңа ачулана да башлыйсың. Ә мин тагы күчтәнәч алып килгән булам...

Мин сумкадан төргәкләремне чыгара башладым. Карчык аларга йөгерек күз карашы ташлап алды да яңадан мич авызына таба борылды.

— Миңа синең бернинди күчтәнәчең кирәкми, — дип мыгырданды ул, кисәү агачы белән мичтәге күмерләрне болгаткалап. — Синең ише кунакларны яхшы беләбез... Башта авызыңа бал да май булып керәләр, аннары... Нәрсә ул төенчегеңдә? — дип сорады ул кинәт, миңа таба борылып.

Мин шундук аның кулына чәй белән шикәр тоттырдым. Күчтәнәч карчыкның күңелен ярыйсы гына йомшартып җибәрде булса кирәк: ул үзалдына мыгырдануын дәвам итсә дә, аның тавышында хәзер әүвәлгечә нәфрәт, дошманлык сизелми иде инде.

Олеся яңадан үзенең кабасы янына барып утырды, ә мин аның катындагы тәбәнәк, кыска һәм аяклары кылтаеп торган эскәмиядән урын алдым. Сул кулы белән Олеся тәрәш тарагына эленгән ефәктәй йомшак ап-ак сүсне бөтерә-бөтерә җеп ката, ә уң кулында, җиңелчә генә тавыш чыгарып, орчык зырылдый иде. Орчыкны ул бармаклары белән бөтереп җибәрә дә, аңа идәнгә кадәр диярлек төшәргә мөмкинлек бирә, аннары аны күтәртеп алып, тагын зырылдатып бөтерә. Беренче карашка гади генә булып тоелган, әмма асылда күп гасырлык тәҗрибә һәм зур осталык таләп иткән бу эш Олеся кулында уйнап тора иде. Мин ихтыярсыздан кызның кулларына игътибар иттем. Аның куллары эшли-эшли кытыршыланып, каралып беткән, ләкин зур түгел; формасы белән гажәеп килешле һәм аларның матурлыгына хәтта иң яхшы тәрбия алган аксөяк кызлар да көнләшеп карар иде шикелле.

— Ә сез теге чакны миңа әйтмәдегез дә: әби сезгә карта ачкан булган икән ич, — диде Олеся һәм, минем куркынган кыяфәттә әбигә таба борылып каравымны күргәч, өстәп куйды: — Курыкмагыз, курыкмагыз, ул начар ишетә, колакка катырак. Ул бары мин сөйләгәнне генә аңлый.

— Әйе, карта ачкан иде шул. Ә нәрсә?

— Бернәрсә дә түгел... Болай гына соравым... Ә сез соң ышанасызмы? — диде ул кинәт, ялт кына миңа таба карап алып.

— Нәрсәгә ышанаммы? Әбиеңнең миңа карта ачуынамы, әллә гомумән багугамы?

— Юк, гомумән багуга...

— Ничек дип әйтергә, дөресе — ышанмыйм, ә шулай да, кем белгән аны? Чынга чыккан очраклары да була диләр бит... Хәтта акыллы китапларда да бу хакта язалар... Ә менә әбиең юраганнарга, дөресен әйтим, бөтенләй ышанмыйм мин. Алай гына теләсә нинди авыл хатыны да бага ала.

Олеся елмаеп куйды.

— Әйе, ул хәзер чыннан да начар бага. Картайды, аннары ул бераз гына шүрли дә. Ә карта сезгә нәрсә әйтте соң?

— Искитәрлек берни дә әйтмәде. Мин инде онытып та бетердем. Гадәттә ни диләр әле: озын юл, треф дама, фәлән-фәсмәтән... Хәтердән дә чыккан инде.

— Әйе, әйе, әби хәзер начар бага башлады. Картлыктан күп кенә сүзләрен дә онытган... Кая инде аңа? Аннары курка ул. Акчага кызыгып риза булса гына инде.

— Кемнән курка соң ул?

— Кемнән булсын — түрәләрдән инде. Урядник килгән саен гел аңа янап тора: «Мин сине, ди, теләсә кайчан өтермәнгә яптыра алам, ди. Беләсеңме, синең ишеләрне сихер өчен нишләтәләр? Катр сөрәләр, Лачын атавына сроксыз эшкә җибәрәләр», — ди. Сезнеңчә нинчек, дөрес әйтәме ул, әллә ялганлыймы?

— Юк, ялганлавын ялганламыйдыр; сихер өчен чыннан да ниндидер җәза бирәләр бугай, ләкин ул җәза, минемчә, андый ук куркынычлы булмаска тиеш... Ә син үзең бага беләсеңме соң, Олеся?

Олеся беразга гына аптырап калгандай булды, аннары ашыгып:

— Багам... Тик акчага түгел, — диде.

— Бәлкем, син миңа да карта ачып карарсың?

Кыз катгый төстә башын чайкап куйды.

— Юк, теләмим, — диде ул әкрен генә.

— Ни өчен теләмисең? Мин хәзер үк димим бит, миңа соңыннанрак булса да ярый... Миңа, ничектер, син дөресен әйтерсең шикелле тоела.

— Юк. Бакмыйм. Үтерсәгез дә бакмыйм.

— Алай яхшы түгел ич инде, Олеся. Беренче танышу хакына булса да ризалык бирергә иде... Йә, ник багарга теләмисең?

— Чөнки мин сезнең турыда карта ачып карадым инде, икенче кат ярамый.

— Ярамый? Ни өчен ярамый? Мин һич аңламыйм.

— Юк, юк, ярамый... ярамый, — дип пышылдады кыз, ниндидер хорафатлы бер шомлану белән.— Тәкъдирне ике мәртәбә сынап карарга ярамый... Тиеш түгел... Тәкъдир моны беләчәк, тыңлап торачак... Ул кабат сораштырганны яратмый. Шуңа күрә дә әнә барлык багучылар бәхетсез булалар.

Мин Олесяга шаяртыбрак җавап бирергә теләгән идем дә, батырлыгым җитмәде: аның сүзләрендә шулкадәр эчкерсез, саф ышанганлык сизелде ки — ул, тәкъдир турында телгә алып, ниндидер сәер курку белән ишеккә таба борылып карагач, мин дә аның артыннан шул якка әйләнеп карарга мәҗбүр булдым.

— Ярар, әгәр хәзер багарга теләмисең икән, алайса син миңа теге юлы ни чыкканын сөйлә, — дидем мин.

Олеся, җеп эрләвеннән кинәт кенә туктап, кулы белән минем кулга орынды.

— Юк, сөйләмим... сөйләмәвем яхшырак, — диде ул, һәм аның күзләре миңа, ничектер, балаларча мөлдерәп,

ялварып карады. — Зинһар өчен, сорамагыз... Сезгә бик яман хәлләр чыкты... Ирексезләмәгез мине...

Ләкин мин һаман кыстый бирдем. Аның шулай баш тартуы һәм тәкъдир турындагы серле кинаяләре багучыларга хас бер кызыксындыру ысулы гына булгандырмы, әллә ул чынлап та үзе сөйләгәннәргә үзе ышана идеме икән — мин берни аңламадым. Һәрхәлдә, бу минутта мине куркуга якын ниндидер шомлы бер хис билән алды.

— Ярар, сөйлим алайса, — диде Олеся, ниһаять, килешеп. — Тик, карагыз аны, вәгъдә акчадан кыйммәтрәк: сезгә ни дә булса ошамаса, ачуланырлык булмасын. Менә нәрсә чыкты сезгә: игелекле булсагыз да, сез бик йомшак холыклы кеше... Сездәге игелеклелек әйбәт түгел, ихлас күңелдән түгел. Сез үз сүзегезгә үзегез хуҗа була алмыйсыз. Бүтән кешеләрдән өстен чыгарга яратасыз, шул ук вакытта, үзегез дә теләмичә, аларга буйсынасыз. Аракы эчәргә яратасыз, аннары тагын... Барыбер инде, бер сөйли башлагач, бөтенесен сөйләргә кирәктер... Аннары сез хатын-кызга бик һәвәс кеше икәнсез, шуның аркасында тормышыгызда күп яман хәлләр булачак... Акчаны җыя да, саклый да белмисез — шуңа күрә сез беркайчан да байый алмаячаксыз... Бөтенесен сөйләргәме?

— Сөйлә әйдә, сөйлә! Ни беләсең, һәммәсен дә сөйлә!

— Аннары карта тагын шуны әйтте: сез бик күңелсез гомер кичерәчәксез, диде. Йөрәгегез салкын, иренчәк, диде. Шуның аркасында сез беркемне дә чын күңелдән яратмаячаксыз, ә үзегезне яратучыларга күп кайгы-хәсрәт китерәчәксез, диде. Сез беркайчан да өйләнмәссез, соңгы көннәрегезгә кадәр шулай буйдак булып яшәрсез. Тормышыгызда зур шатлык-куанычлар булмас, аның каравы күңел бизүләр, кыенлыклар күп булыр... Хәтта үз-үзегезгә кул салырга теләгән чагыгыз да булыр... Андый эш сезгә бер мәртәбә чыга... Тик сезнең аңа кыюлыгыгыз җитмәс, аны болай гына уздырып җибәрерсез... Алда сезне зур мохтаҗлык көтә; әмма гомерегез соңында ниндидер якын бер кешегезнең үлеме аша сезнең язмыш көтмәгәндә генә үзгәреп куячак. Әмма болар барысы да киләчәктә буласылары, ә менә хәзер, быел буласысы... Мин, әлбәттә, төгәл вакытын әйтә алмыйм, тик карта бик тиздән булыр дип күрсәтә... Бәлкем, ул шушы ук айда булыр...

Олесяның сүздән туктап торуыннан файдаланып, мин:

— Йә, быел миңа нәрсә буласы? — дип сорап куйдым.

— Анысын инде сөйләргә дә куркыныч. Кыскасы, ниндидер треф дамасы сезгә зур мәхәббәт вәгъдә итә. Кыз ке-

шеме ул, ир хатынымы — анысын әйтә алмыйм, тик коңгырт чәчле икәнен генә беләм.

Шул чакны мин ихтыярсыздан Олесяның чәченә күз төшереп алдым. Ул үзе дә, кайбер хатын-кызларга хас бер сизгерлек белән, шундук минем бу хәрәкәтемнең мәгънәсенә төшенде.

— Сез нәрсә карыйсыз? — дигән булды ул, кызарынып. Аннары аңсыз рәвештә чәчләрен рәтләп: — Әйе, минеке сымаграк коңгырт чәчле, — дип өстәде һәм тагын да катырак кызарынды.

— Алайса мин, димәк, тиздән ниндидер треф дамасының мәхәббәтенә тап буласы кеше, әйеме? — дидем мин, шаяртып.

— Ә сез көлмәгез, көләргә кирәкми, — диде Олеся, җитди һәм шактый кырыс тавыш белән. — Мин бит сезгә чынлап сөйлим.

— Ярар, булды, булды, башка көлмим. Шуннан соң карта ни ди?

— Шуннан соңмы?.. Ой! Ул треф дамасын бик яман хәлләр, үлемнән дә яманрак хәлләр көтә. Сезнең аркада ул үз өстенә гомере буе онытa алмаслык зур хурлык алачак, гомерлек кайгы-хәсрәткә дучар булачак... Ә сезгә треф дамасы аша бернинди яман хәлләр дә күренми.

— Карале, Олеся, монда карта үзе алдашуы мөмкин түгелме соң? Нигә инде мин треф дамасына шундый яманлыклар эшлим ди? Мин бит тыныч, тыйнак кеше, ә син минем турыда шулхәтле коточкыч нәрсәләр әйтеп ташладың.

— Анысын инде мин белмим. Картада шулай чыкты: ул яманлыкларны сез юри, ягъни үзегез теләп эшләмәячәксез бит, алар сезнең ихтыярдан башка, тәкъдир кушуы буенча эшләнәчәк... Сүзләрем чынга чыккач, мине искә төшерерсез әле.

— Олеся, боларның барысын да карталар гына әйттеме?

Олеся шактый көттереп һәм, гүя, теләр-теләмәс кенә җавап кайтарды:

— Карталар да әйтте... Аннары мин картасыз да күреп торам... кешенең йөзенә карап күрәм. Әгәр, әйтик, кем дә кем озакламый яман чир белән үләчәк икән, мин аны шундук аның йөзеннән беләм; миңа аның белән сөйләшеп торасы да юк.

— Нәрсә күрәсең соң син аның йөзендә?

— Анысын мин үзем дә аныk әйтә алмыйм. Миңа кинәт ничектер бик куркыныч булып китә, әйтерсең лә минем

алда мәет басып тора. Әнә әбидән сорагыз, ул әйтер, мин юраган гел дөрескә чыга. Өченче ел Трофим дигән бер тегермәнче асылынып үлде. Ә мин аны шуңа хәтле ике көн генә элек күреп, әбигә: «Әбекәй, карале, бу Трофим озакламый яман үлем белән үләчәк», — дигән идем. Шул, көне-сәгате белән дигәндәй, үлде дә китте тегермәнче. Ә өченче ел, нардуган бәйрәмендә, әбидән карта ачтырырга дип, безгә ат карагы Яшка кергән иде. Әби карталарны таратып салды да багарга кереште тегеңә. Ә Яшка, шаяртып, сорый әбидән: «Син, ди, әби, миңа шуны әйт: мин нинди үлем белән үләрмен икән?» — ди. Ә үзе көлепме-көлә. Шул чакны аңа таба борылып караган идем, тораташтай каттым да калдым: тегенең бөтенләй чырае калмаган, күмкүк булып утыра, йөзенә үлек төсе кергән... Күзләре йомык, ә иреннәре күгәреп чыккан... Шул, атна узгач ишеттек: ат урлап качканда мужиклар кулына эләккән... Төне буе кыйнаганнар үзен... Безнең монда халык бик усал, рәхимсез бит... Табаннарына кадаклар кагып, күсәк белән кабыргаларын сындырып бетергәннәр. Иртәгесен жан биргән, мескен.

— Син соң ник аңа шундый бәла буласын әйтмәдең?

— Әйтеп ни файда? — диде Олеся, каршы килеп. — Тәкъдирдән качып буламыни? Әйтсәм дә, ул бары үзенең соңгы көннәрен файдасызга борчылып кына уздырган булыр иде... Кеше язмышын шулай алдан күрә белүемә мине газап чикми дисезмени?! Кайчакны хәтта үз-үземне күралмый башлыйм... Нишләмәк кирәк? Тәкъдирем шундый минем. Яшь вакытында минем әби дә үлемне әнә шулай алдан күрә белгән, әнием дә, әбинең әнисе дә шундый булганнар — бу безгә бәйләнмәгән... хикмәт безнең нәселебездә, каныбызда.

Олеся, эрләвеннән туктап, башын түбән иде, кулларын әкрен генә тезе өстенә куйды. Аның киң ачылган һәм хәрәкәтсез катып калган коңгырт күзләрендә ниндидер шомлы курку, күңелен биләп алган ниндидер серле һәм табигатьтән өстен көчләргә ихтыярсыз буйсыну чагыла иде.

V

Ул арада Мануйлиха әби өстәлгә чиккән башлы зур тастымал жәеп, аның өстенә бу бөркеп торган чүлмәк китереп куйды.

— Олеся, кызым, әйдә ашарга утыр, — диде ул, онығын табын янына чакырып, аннары, бераз икеләнеп торгач, миңа эндәште: — Бәлкем, сез дә, барин, безнең белән ашарга

утырырсыз? Рәхим итегез... Әллә ни шаккатырырлык ризык булмас булуын — нибары карабодай өйрәсе... Без бит бүтән төрле ашлар-шулпалар пешермибез...

Әйтергә кирәк, карчыкның тәкъдимендә артык кыстау, өндәү сизелмәгәнгә, мин башта аштан баш тартырга да уйлаган идем. Ләкин Олеся, үз нәүбәтендә, миңа таба иркә күз карашын юнәлтеп, үтә сөйкемле бер садәлек һәм мөлаем елмаю белән шул ук тәкъдимне кабатлагач, мин ихтыярсыз риза булдым. Олеся үзе үк миңа тәлинкәне тутырып өйрә бүлеп бирде. Дуңгыз мае, суган, бәрәңге һәм тавык ите салып, карабодай ярмасыннан пешерелгән бу өйрә ифрат та тәмле һәм туклыклы ашамлык булып чыкты. Табынга утырыр алдыннан әби дә, онығы да чукынып-төртенеп мәшәкатьләнмәделәр. Кешенең холкы иң беренче чиратта ашаганда күренәдер дигән ныклы һәм хәзерге көнгә кадәр үзгәрешсез карашымны күздә тотып, мин ике хатынның да табын янында кыланышларын күзәтеп утырдым. Карчык өйрәне комсыз бер ашыгычлык белән, кабаланып, авызына зур-зур ипи кисәкләре кабып, чупылдый-чупылдый ашый, шуңа күрә аның лепердәвек яңак тирелә-ре ничектер бүлтәеп, эчендә әллә нинди кабарынкы нәрсәләр йөргән кебек тоела иде. Олесяның исә хәтта ашавында да ниндидер табигый әдәплелек, садәлек күренә иде.

Ашап-эчкәннән соң тагын берәр сәгать чамасы утыргач, мин ялгыз урман алачыгының хуҗалары белән саубуллаштым да китәргә җыендым.

— Теләсәгез, мин сезне бераз озата барам, — диде Олеся.

— Ниткән озатулар инде ул тагын! — дип кыштырдап куйды карчык, ачулы тавыш белән. — Һич тик кенә урынында утыра белмәс, чикерткә...

Ләкин Олеся инде башына кызыл кәшимир яулыгын бөркәнеп өлгергән иде. Ул кинәт әбисе янына йөгереп килде дә, аны кысып кочаклап, битеннән чупылдатып үбеп алды.

— Әбием! Җанкисәгем, кадерлем, алтыным... мин беразга гына, шундук кире борылып керәм.

— Ярар, бар инде, бар, җан көеге. — диде карчык, онығы кочагыннан көчкә котылып. — Сез, барин, зинһар, гаеп итә күрмәгез: шундый иләс-миләсрәк инде ул.

Тар сукмактан без урман эчләтеп сузылган пычрак юлга чыктык. Юл тояк эзләре белән чуарланган булып, тирән тәгәрмәч эзләрендәге кар сулары өстендә кичке шәфәкънең кызгылт шәүләсе чагыла иде. Без юл кырыйлатып — әле

генә кардан арчылган һәм үткән елгы яфраклар түшәлгән дымлы сырт буйлап әкрен генә атлап киттек. Чери башлаган соргылт-кара яфраклар юрганы астыннан ара-тирә Полесьеның беренче язгы чәчәге — шәмәхә төстәге эре кыңгырау чәчәкләр баш төртеп чыккан иде.

— Карале, Олеся, — дидем мин, сүз башлап, — минем синнән кайбер нәрсәләр турында сорыйсым килә, тик син ачуланмагае дип кенә куркам... Кешеләр әйтәләр, имеш, синең әбиең... ничек дип әйтим икән?

— Сихерче диләрме? — диде Олеся тыныч кына, миңа ярдәмгә килеп.

— Юк, сихерче үк түгел... — дигән булдым мин, буталып. — Хәер, телисең икән, әйдә, сихерче дип әйтик... Әлбәттә, кеше ни сөйләмәс. Әбиеңнең нинди дә булса шифалы үләннәр җыюы яисә им-том белүе гаепмени?.. Соң, әгәр соравым ошамаса, син миңа җавап та бирми аласың.

— Юк, нигә ошамасын, — диде Олеся, һич тә кәефе кырылмыйча. — Ошамаслык бернәрсә дә юк монда. Әйе, әби минем чыннан да сихерче. Тик хәзер бик картайды инде ул, әүвәлге вакытлардагыча оста эшли алмый.

— Элек ниләр эшли ала иде соң ул? — дидем мин, кызыксынып.

— Төрлесен эшли ала иде. Дәвалый, теш сызлавын баса, зәхмәт кайтара, котырган эт тешләгән яки елан чаккан кешеләрне әфсенләп терелтә, хәзинә яткан җирләрне эзләп таба иде — кыскасы, эшләгән эшләрен санап чыгарлык та түгел...

— Беләсеңме нәрсә, Олеся? Туры әйткәнем өчен гафу ит: мин боларның берсенә дә ышанмыйм бит. Йә, сер итеп кенә әйт миңа: болар һәммәсе дә күз буяу, алдашу гына бит, әйеме?

Олеся искитмәүчән бер кыяфәттә җилкәсен җыерып куйды.

— Ихтыярыгыз, теләсәгез ничек уйлагыз. Авыл хатынының башын катыру — анысы бер хәл, ләкин сезнең алда мин алдашып маташмас идем.

— Димәк, син сихергә чынлап торып ышанасың, шулаймы?

— Ничек инде ышанмаска? Безнең гомумән бөтен нәселебез тылсым көченә ия... Мин үзем дә күп нәрсәләр эшли алам.

— Олеся, җанкисәгем... шуларның ичмасам берсен генә булса да күрсәт әле...

— Ник күрсәтмәскә? Теләсәгез, күрсәтермен дә шул, — диде Олеся. — Хәзер үкме?

— Әйе, мөмкин булса, хәзер үк күрсәт.

— Курыкмассызмы соң?

— Анысы тагын ниткән сүз. Төнлә, бәлкем, курыккан да булыр идем, хәзер якты ич әле.

— Ярар алайса. Бирегез миңа кулыгызны.

Мин, буйсынып, аңа таба кулымны суздым. Олеся минем пальто җиңен тиз генә кайтарып куйды, манжет каптырмасын ычкындырды да, үзенең кесәсеннән өч вершок чамасы озынлыктагы фин пычагын алып, аны күн кынысыннан суырып чыгарды.

Кинәт мин үземдә ачу китергеч бер курку хисе уяна башлавын тойдым.

— Син нишләмәкче буласың? — дидем мин, шикләнеп.

— Үзегез күрерсез... Сез бернәрсәдән дә курыкмыйм дидегез ич!

Кинәт Олеся кулы белән сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәт ясап алды, һәм шулчак мин үземнең беләгемдә, кан тамырын тотып карый торган җирдән бераз өстәрәк, йомшак тирегә үткен пәке йөзе сызылып үткәнен тойдым. Җәрәхәттән шундук кан саркып чыкты һәм җиргә еш-еш тама башлады. Кычкырып җибәрүдән мин чак кына тыелып калдым; шулай да бик нык агарындым булса кирәк, чөнки Олеся, көлемсерәп:

— Курыкмагыз, исән калырсыз, — дип куйды.

Ул беләгемне җәрәхәтле урыннан югарырак кысып тотты да, йөзен җәрәхәткә якын ук китереп, аның өстенә кайнар сулышын бөрки-бөрки, ниндидер аңлаешсыз сүзләр пышылдарга тотынды. Олеся кулымны ычкындырып тураеп басканда инде канлы җәрәхәт урынында беленер-беленмәс кызгылт сызык кына торып калган иде.

— Йә, ничек? Шул җитеп торырмы? — диде ул, хәйләле елмаеп, һәм пәкесен кесәсенә яшереп куйды. — Тагын теләмисезме?

— Телим, билгеле. Тик, зинһар, алай бик куркынычлы булмаса иде, аннары кан да акмасын иде.

— Тагын нәрсә күрсәтергә икән соң сезгә? — диде Олеся, уйга калып. — Ярар алайса, менә болай эшлик: сез ялгызыгыз гына юлдан алга атлагыз... Тик, ишетсен колагыгыз, артыгызга борылып карамагыз.

Бу билгесез сынаудан шүрләвемне яшерер өчен, мин үземне көчләп елмаерга мәҗбүр иттем һәм юри уенчак тавыш белән:

— Синең ул мәзәгең бик куркыныч түгелме соң? — дигән булдым.

— Юк, юк... Куркырдай бернәрсәсе юк... Барыгыз, — диде Олеся.

Мин, тәҗрибәнең нәтиҗәсе белән чиктән тыш кызыксынып, алга таба атладым. Шул ук вакытта мин аркамда Олесяның миңа төбәлгән киеренке күз карашын тойгандай булдым. Ләкин унбиш-егерме адым да китеп өлгермәгәнмендер, кинәт тип-тигез урында сөртенеп киттем дә йөзтүбән җиргә капландым.

— Барыгыз, бар! — дип кычкырды Олеся. — Артка борылып карамагыз! Егылудан да курыкмагыз, туйга хәтле төзәлер әле... Егылганда җиргә ныграк тотыныгыз.

Мин юлымны дәвам иттем. Бер ун адым чамасы баргач, тагын йөзтүбән җиргә капландым.

Олеся шаркылдап көлә-көлә кулларын чәбәкләргә тотынды.

— Йә, ничек? Күңелегез булдымы инде? — диде ул, ак тешләрен хәйләле елтыратып. — Хәзер ышанасызмы инде? Зарар юк, зарар юк!.. Һавага очмадыгыз бит, җир өстенә генә төштегез.

— Ничек эшләдең соң син моны? — дип, гаҗәпләнеп сорадым мин, киememә ябышкан чүпне сыпырып. — Әллә серме, югыйсә?

— Нишләп сер булсын. Теләсәгез, мин сезгә рәхәтләнеп сөйләп бирәм. Тик менә аңлашылырмы икән... сез аңларлык итеп сөйли алырмынмы икән дим...

Дөрестән дә, ул сөйләгәннәрдән кайбер нәрсәләрне мин ахырынача аңлап җиткермәдем. Ләкин, ялгышмасам, аның кызыклы бу фокусы шуннан гыйбарәт иде: минем арттан аякны аякка, адымны адымга атлап барган хәлдә, ул бер үк вакытта минем һәрбер хәрәкәтемне дә төгәл рәвештә кабатларга тырышкан, ягъни үзенең бөтен килеш-килбәте белән мин булып кыланган. Шулай күпмедер адым җир киткәч, ул минем барасы юлымда, янәсе, җирдән бер аршын югары күтәрелеп торган һәм юлга аркылы сузылган бау бар дип фараз итәргә керешкән. Аннары, мин шул фараз ителгән бауга аягым белән орынам дигәндә генә, кинәт сөрлегеп егылгандай бер хәрәкәт ясаган... Андый чакта, Олесяның әйтүенчә, иң таза, иң нык кеше дә аягында басып кала алмаска тиеш икән... Миңа Олесяның әлеге буталчык аңлатмасын күп еллар үткәч тагын бер мәртәбә искә төшерергә туры килде. Сальпетриер шифаханәсендә истериядән газапланучы ике профессиональ сихерче хатынга ясалган тәҗрибәләр турында Шарко язган отчетны укыгач искә төште ул. Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды: гади француз халкы арасыннан чыккан күз буяучылар да

мондый очракларда нәкъ менә Полесьеның чибәр сихерчесе кулланган бер үк ысуллар ярдәмендә эш иткәннәр икән.

— О-о! Ул гынамы әле, мин тагын күп нәрсәләр беләм, — дип куйды Олеся, үз көченә нык ышанган көр тавыш белән. — Мәсәлән, мин сезне бик куркак кеше итә алам.

— Анысы тагын ни дигән сүз!

— Сез тиктомалга курка торган кешегә әвереләсез. Әйтик, сез бер ялгызыгыз үз бүлмәгездә утырасыз, ди. Кинәт бер заман сезне тиктомалдан гына курку биләп ала, һәм сез калтырана үк башлыйсыз, артыгызга борылып карарга да куркасыз. Тик моны эшләү өчен миңа иң элек сез торган урынны белергә, бүлмәгезне күрергә кирәк.

— Алайса бик җиңел инде бу, — дидем мин, шигемне белдереп. — Урам яктан тәрәзә төбенә килеп, пыялага чиртәсең дә ни дә булса кычкырасың.

— О, юк, алай түгел... Бу вакытны мин урманда булам, үз өемнән беркая да чыкмыйм... Ләкин мин күңелемнән үземнең нишләргә тиешлегемне гел уйлап, фараз итеп утырачакмын. Әйтик, мин урамнан барам, сезнең өйгә керәм, ишегегезне ачып булмәгезгә узам... Сез бу вакыт кайда да булса... әйтик, өстәл янында утырасыз, ди... мин акрын гына арттан сезнең янга киләм... сез мине күрмисез дә, ишетмисез дә... шулай киләм дә, кулларымны иңбашыгызга куеп, аска таба баса башлыйм... торган саен катырак басам иңбашыгызга... ә үзем сезнең күзләрегезгә карыйм... менә болай — карагыз әле...

Олеся, нечкә кара кашларын җыерып, сихерләүчән дәһшәтле бер шом чагылган күзләрен миңа юнәлтте. Аның күз бәбәкләре ничектер зураеп, күгелҗем төскә кергән иде. Моны күргәч, мин шундук кайчандыр Мәскәүдә, Третьяков галереясында караган һәм хәзер инде рәссамының исеме дә онытылган бер рәсемне — Медуза башы рәсемен искә төшердем. Олесяның миңа төбәлгән көе катып калган сәер күз карашы, илаһи бер көч сыман, мине тәмам тетрәндереп җибәрде.

— Йә, булды сиңа, Олеся... җитәр, — дидем мин, ясалма бер көлү белән көлеп. — Елмайган чагың миңа күбрәк ошый — андый чакта синең сабыйларча мөлаем йөзеңә карап туймаслык була.

Без юлыбызны дәвам иттек. Барган шәпкә минем күңелдә кинәт бер сорау туды: Олеся сөйләмендәге тәэсирлелек, укымаган гади кыз өчен бөтенләй ят булырга тиешле нәфислек, нәзакәтлелек каян килде икән?

— Беләсеңме, мине нәрсә гаҗәпләндерә, Олеся? — ди-

дем мин, үземне борчыган сорауга җавап алырга тырышып. — Менә син, беркем белән дә диярлек аралашмыйнитми, урманда ялгыз башың үскәнсең... Шулай ук синең китап укырга да әллә ни чамаң булмагандыр...

— Мин бөтенләй язу танымыйм.

— Алайса, бигрәк тә... Шул ук вакытта синең сөйләшүең барышнялар сөйләшүеннән бер дә ким түгел. Әйт әле, Олеся, каян килде бу сиңа? Нәрсә турында сораганымны аңлыйсыңдыр бит?

— Әйе, аңлыйм. Боларның һәммәсе дә әбидән килә... Сез аның шыксыз кыяфәтле булуына карамагыз. У-у! Беләсезме, ул нинди акыллы! Ияләшә төшкәч, бәлкем, сезнең алда да аның теле ачыла башлар әле, менә шунда үзегез дә күрерсез... Дөньяда аның һич белмәгән нәрсәсе юктыр, чын менә, ни сорасаң шуны әйтә дә бирә. Дөрес, хәзер картайды инде ул.

— Алайса синең әбиең үз гомерендә бик күпне күргәндер, шулаймы? Элек кайда торган соң ул?

Бу сораулар Олесяга бик үк ошап бетмәде булса кирәк. Ул җавабын шактый көттереп һәм теләр-теләмәстән әйтте:

— Белмим... Ул үзе дә бу турыда күп сөйләргә яратмый. Әгәр ара-тирә сүз кузгаткаласа да, сөйләгәнен шундук онытырга, бүтән искә төшермәскә куша... Ярар, миңа кайтырга вакыт, — диде Олеся, кинәт ашыга башлап, — әбием ачуланыр. Хушыгыз... Гафу итәсез, мин исемегезне белмим бит әле.

Мин аңа исемемне әйттем.

— Иван Тимофеевич? Бик шәп. Алайса, хушыгыз, Иван Тимофеевич! Безне читләтеп узмагыз, керә йөрегез.

Мин аңа кулымны суздым. Олеся кечкенә, ләкин көчле кулы белән дусларча каты итеп минем кулымны кысты.

VI

Шул көннән башлап, мин әлеге субайлар өстендәге йортка бик еш барып йөри башладым. Килгән саен Олеся мине гадәттәгечә сабыр, горур йөз белән каршылады. Ләкин мин ишектән керүгә, ул ниндидер сизелер-сизелмәс хәрәкәт ясап куя һәм шуның белән минем килүемә эчтән шатланганлыгын күрсәтә иде. Карчык исә, авыз эченнән һаман нидер мыгырдануын дәвам итсә дә, миңа булган дошманлыгын ачыктан-ачык белгертмәде. Монда, әлбәттә, оныгы Олесяның уңай тәэсире сизелде булса кирәк. Аннары, күрәсең, ара-тирә минем күчтәнәч, бүләкләр: йон яулык, банкалы варенье, чия шәрабы ише нәрсәләр алып ки-

лүем дә карчыкның күңелен йомшартмый калмагандыр. Ә менә Олеся белән минем арада үзенә күрә сүзсез бер килешү барлыкка килде: кайтырга җыенгач, ул мине Ириновка юлына кадәр озата чыга иде. Шул озату вакытында безнең арада кызыклы, җанлы эңгәмәләр кабынып китә, һәм без, юлны озайтыр өчен, прексездән әкренрәк барырга тырышабыз, тын урман алашарын урап үтәбез. Ириновка юлына килеп җиткәч, мин Олесяны янә бер ярты чакрым чамасы кире озата барам; аннан соң да әле, аерылышмас өчен, без берәр нарат агачының җәенке һәм хуш исле күгелҗем ботаклары астында озаклап сөйләшеп торабыз.

Олесяда мине җәлеп иткән нәрсә, әлбәттә, аның матурлыгы гына түгел иде. Моннан башка мине тагын аның гадәттән тыш үзенчәлекле, эчке каршылыклардан, икеләнүләрдән азат булган ирекле, самими табигате сокландырды; нәселдән килгән какшамас бер хорафат белән өртелгән, шул ук вакытта сабыйларныкыча беркатлы да, чибәр хатын-кызларныкыча хәйләле, наян да булган ачык, саф акылы сокландырды. Аның бозылмаган һәм хыялга бай күңелен дөньядагы барлык нәрсә кызыксындыра, дулкынландыра иде шикелле. Ул миннән әллә нинди чит-ят илләр, күз күрмәгән халыклар турында, кыргый табигать күренешләре, җир һәм галәм төзелеше, галимнәр, зур шәһәркалалар турында туктаусыз сораштырды. Мин сөйләгәннәрнең күбесе, әлбәттә, аңа кеше ышанмастай могҗиза, әкият булып тоелды. Әмма беренче танышкан көнебездән үк үзара сөйләшүдә мин тоткан эчкерсез, җитди, гади тон Олесяга минем һәрбер сүземне бернинди икеләнүсез, ышанып кабул итәргә ярдәм итә иде. Дөрес, кайчакта Олесяның ярым кыргый акылына барып җитмәстәй (еш кына хәтта үзем өчен дә ахырынача ачык булмаган) берәр кыен мәсьәлә килеп чыга да, аны ничек аңлатырга белмичә, мин кызның комсызланып сорашуларына каршы: «Беләсеңме нәрсә... Мин моны сиңа төшендереп бирә алмам... Син мине аңламассың», — дип аклана башлый идем.

Андый чакта ул ялварырга керешә:

— Юк, зинһар, зинһар, сөйләгез, мин ничек тә аңларга тырышырмын... хәтта аңларлык булмаса да... барыбер сөйләгез... — ди.

Ул мине әллә нинди коточкыч чагыштырулар ясарга, хәтәр-хәтәр мисаллар белән эш кылырга мәҗбүр итә, һәм әгәр мин кирәкле тәгъбирне таба алмый кыенсынып торсам яки берәр сүздә төртелеп калсам, тотлыгып сөйләшүче кешегә булышкандай, сабырсызланып, миңа сораулар яуды-

ра башлый иде. Һәм, чыннан да, аның йөгерек, зирәк акылы, табигый күзаллау сәләте ахыр чиктә минем педагогик зәгыйфьлегемне җиңеп чыга иде. Мин ирексездән аның үз мохитында, үзенекедәй тәрбия алган (яки, дөресрәге, бернинди тәрбия алмаган) кешеләр арасында искиткеч сәләтле бер кеше булганлыгын көннән-көн ачыграк күрә бардым.

Бервакытны мин сүз арасында ничектер Петербургны телгә алдым. Олеся шундук кызыксынып сорашырга кереште.

— Нәрсә ул Петербург? Авылмы?

— Юк, авыл түгел. Петербург ул Россиянең иң зур шәһәре.

— Иң зурымы? Иң-иң зуры, әйеме? Шуннан да зуррагы юкмы? — дип сораша бирде Олеся, сабый баладай каныгып.

— Соң, әйе инде... Баш түрәләрнең һәммәсе шунда тора... зур хуҗалар ягъни... Анда барлык йортлар таштан салынган, агач йортлар бөтенләй юк.

— Алайса ул безнең Степаньнан зуррак инде, шулаймы? — диде Олеся.

— Бераз зуррак булыр шул... бер биш йөз мәртәбәгә. Андагы өйләрнең кайберсендә Степаньдагыдан ике тапкыр күбрәк халык яши.

— Йа аллам! Нинди өйләр соң алар? — дип куйды Олеся, курка калып.

Аңлашылсын өчен мин, гадәттәгечә, чагыштырулар ясарга мәҗбүр булдым.

— Коточкыч зур өйләр. Биш катлы, алты катлы, хәтта җиде катлылары да бар. Әнә, күрәсеңме теге наратны?

— Иң биегенме? Күрәм.

— Менә шундый биек йортлар инде. Һәммәсе өстән аска хәтле кеше белән шыгрым тулы. Ул кешеләр, читлектәге кошлар сыман, бәләкәй-бәләкәй бүлмәләрдә торалар; һәркайсында бер унлап кеше урнашкан, хәтта сулыш алырга һава да җитми. Ә кайберәүләр бөтенләй түбәндә, җир астында ук яши, юештә, салкында; андагы бүлмәләргә елның ел буе кояш нуры төшмәгән чаклар да була.

— Алайса, мин урманымны сезнең ул шәһәрегезгә гомеремдә дә алыштырмас идем, — диде Олеся, башын чайкап. — Степаньга базарга баргач та тыным кысыла башлый. Этеш-төртешләрдән гажиз буласың, шау-шу, кычкырышудан колаклар тона... Урманнан читкә чыктыммы, күңелемне шундый сагыш баса — барысын калдырып, уңгасулга карамыйча ташлап качасым килә башлый... Җәһән-

нәмгә китсен ул шәһәр дигәнегез, мин анда бер көн дә тормас идем.

— Ә киявең шәһәрдән булса, нишләтерсең? — дидем мин, хәйләле көлемсерәп.

Олесяның кашлары җыерылды, юка борын яфраклары дерелдәп куйды.

— Шул гына калган иде! диде ул, йөзен чытып. — Миңа бернинди дә кияү кирәкми.

— Син хәзер генә алай дисең, Олеся. Һәммә кызлар башта шулай диләр, ә соңыннан барыбер кияүгә чыгалар. Бераз сабыр ит: менә берәрсен очратырсың, яратырсың, шул чакта инде аның белән шәһәргә генә түгел, дөнья читенә китәргә дә риза булырсың.

— Ah, сөйләмәгезче булмаганны... зинһар, кирәкми, — диде Олеся, үпкәләгәндәй кулын селтәп. — Йә, нигә юкны сөйләргә?.. Үтенәм сездән, башка сөйләмәгез.

— Кызык та инде син, Олеся. Гомерең буе бер егетне дә яратмам дип уйлыйсыңмыни? Син бит шундый яшь, шундый чибәр, көчле. Йөрәгеңдә гыйшык ялкыны кабынса, алай антлар белән генә котыла алмассың.

— Котылмасам соң — яратырмын! — дип җавап бирде Олеся, күзләрен очкынландырып. — Кешедән киңәш сорап тормам...

— Алай булгач, димәк, кияүгә дә чыгарсың, — дидем мин, үртәп.

— Сез нәрсә, чиркәүдә никах укытуны әйтәсезме әллә? — диде Олеся, шикләнә калып.

— Әлбәттә, шуны... Поп сезне мөнбәр тирәли җитәкләп йөртер, дьякон никах җыры җырлар, синең башыңа таж, кигезерләр...

Олеся керфекләрен түбән иде һәм, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, башын чайкап куйды.

— Юк, җанкисәгем... сүзем ошамаса ошамас, тик сезгә яшермичә әйтәм: безнең нәселдә беркем дә никах укытмаган. Әни дә, әби дә никахсыз гына яшәгәннәр... Безнең нәселгә хәтта чиркәүгә барып йөрергә дә ярамый...

— Әлеге шул сихергә табынуыгыз аркасындамы?

— Әйе, шул сихергә табынуыбыз аркасында, — диде Олеся, тыныч бер җитдилек белән. — Әгәр минем җаным туганда ук *аңа* сатылган икән, ничек инде мин чиркәүдә күренә алыйм?!

— Олеся... Акыллым... Ышан сүземә, син үзеңне үзең алдыйсың... Син адәм ышанмаслык кыргый, көлке нәрсә сөйлисең бит.

Олесяның йөзенә тагын теге вакытта бер мәртәбә бул-

ган һәм үзенең шул серле тәкъдиренә инануын һәм буйсынуын күрсәткән шомлы, сәер бер чырай калыкты.

— Юк, юк... Сез моны аңлый алмыйсыз, ә мин аны ачык сизәм... Менә шушында, — Олеся кулы белән күкрәген кысты, — йөрәгемдә сизәм. Без мәңге-мәңгегә каһәрләнгән нәсел. Соң үзегез уйлап карагыз: безгә *ул* булышмыйча, тагын кем булышсын икән?! Гади кеше мин эшли алганны эшли аламыни? Безнең нәселнең бөтен көч-кодрәте *аңардан* килә.

Һәм сүз чак кына шушы четерекле мәсьәләгә кагылдымы, безнең сөйләшү һәрвакыт шулай бәхәс белән тәмамлана иде. Мин Олесяга үземчә аның өчен аңлаешлы булырдай күп төрле дәлилләр китереп карадым, гади генә сүзләр белән аңа гипноз турында, инандыру кодрәте, психиатр докторлар һәм фокусчы һинд дәрвишләре турында сөйләдем; хәтта аның үзе башкарган кайбер могҗизалы тәҗрибәләрен физиологиягә нигезләп аңлатырга тырыштым; мәсәлән, аның канны әфсенләү дигән тәҗрибәсенең нибары кан тамырын кысып тотып, канның йөрешен туктатудан гыйбарәт икәнлегенә төшендермәкче булдым. Әмма минем бу дәлилләрем аңа тәэсир итмәде. Бүтән һәммә нәрсәдә миңа тулы ышаныч белән караган Олеся сихер мәсьәләсендә минем барлык дәлил, аңлатмаларымны катгый төстә кире какты... «Ярар, яхшы, яхшы, канны әфсенләү мәсьәләсендә, әйдә, сезнеңчә булсын, — ди иде ул, бәхәс кызуында тавышын шактый күтәрә төшеп, — ә калганнары ничек туа соң? Минем бар белгәнем әллә кан әфсенләү генә дисезме? Телисезме, бер көн эчендә мин сезнең өйдәге бөтен таракан, тычканнарны кырдырып бетерәм? Яки сезнең бернинди докторыгыз да жиңә алмаган иң хәтәр бизгәкне ике көн эчендә гади су белән дәвалап бирәм? Яки сезгә менә үзегез белә торган берәр сүзне гомер гомергә онытырга куша алам. Ә төш юравымны кая куясыз? Күрәзәлек итүемне ничек аңлатасыз?»

Бәхәсебез һәр юлы бертөсле тәмамлана: без икебез дә, бер-беребезгә жиңелчә үпкәләп, сүздән туктап калабыз. Чыннан да, Олесяның кара сихер сәнгатенә кагылышлы күп нәрсәләрне мин үземнең чикләнгән акылым белән берничек тә аңлатып бирә алмый идем. Олеся беркатлы самимилек белән үзе инанып сөйләгән ул сихри серләрдән ичмасам яртысын гына булса да анык белгәндерме, юктырмы — анысын тәгаен әйтүе читен, әмма үзем еш кына шаһит булган кайбер тәҗрибәләрдән күренгәнчә, аның ниндидер серле, томанлы бер гыйлемгә ия булганлыгы минем өчен көн кебек ачык иде. Очраклы тәҗрибәләр нигезендә

барлыкка килеп, үз-үзенә йомылып яшәүче кара халык арасында буыннан буынга күчә-күчә, төрле кыргый, сәер ышанулар, хорафатлар белән бергә туплана барган һәм асылда үзенең сәер казанышлары белән төгәл фәннәрне дә йөзләрчә елларга узып киткән бу серле гыйлемне Олеся, күрәсең, аңсыз һәм инстинктив рәвештә үзләштергән иде.

Шушы бердәнбер мәсьәләдә кискен каршылык булуга карамастан, без бер-беребезгә торган саен ныграк якыная бардык. Мәхәббәт хакында әлегә бер генә авыз сүз әйтелмәсә дә, даими очрашып тору безнең өчен инде зарури бер ихтыяҗга әверелгән иде. Еш кына, үзара берни сөйләшмичә тын гына утырган чакларда, безнең күз карашларыбыз көтмәгәндә генә очрашып куя да, мин шул чакны Олесяның керфекләре дымлануын һәм чигәсендә күгелҗем, нечкә кан тамырларының бүртеп тибәргә тотынуын күрә идем...

Аның каравы Ярмола белән минем арадагы мөнәсәбәтләр бөтенләй үзгәреп китте. Ярмола өчен, күрәсең, минем субайлар өстендәге өйгә барып йөрүем һәм Олеся белән кичке очрашуларым сер түгел иде; ул, гомумән, үзенең урманында ниләр булганын һәрвакыт гадәттән тыш бер төгәллек белән белеп тора иде. Соңгы вакытларда исә ул миннән бөтенләй читләште, минем белән күзгә-күз очрашмаска тырышты. Үзенең уйларын-хисләрен ачыктан-ачык әйтмәсә дә, мин урманга барырга җыенган саен, ул миңа таба, ерактан кара күзләрен елтыратып, шелтә белән карап тора иде. Безнең ярым көлке, ярым җитди төстә барган уку дәресләребез дә тукталып калды. Кайчакта кичләрен Ярмоланы сабагына утырырга кыстый башласам, ул җирәнеп кулын гына селти һәм иренчәк бер нәфрәт белән:

— Нигә кирәк ул! Юк эш ул, паныч, — дип кенә куя иде.

Шулай ук ауга йөрүләр дә тукталды. Бу турыда сүз кузгатсам, Ярмола һәрвакыт нинди дә булса сәбәп эзләп таба: йә аның мылтыгы төзек түгел, йә эте сырхау, я үзенең вакыты юк. Еш кына ул минем чакыруыма каршы: «Җаем юк, паныч... бүген җир җыртасым бар», — дип җавап кайтара иде. Шул ук вакытта мин яхшы белә идем: ул бу көнне бернинди «җир җыртырга» да бармаячак, ә берәрсеннән сый-фәлән эләкмәсме дип, иртәдән кичкә хәтле монополия тирәсендә йөриячәк. Ахыр чиктә, аның сүзсез, яшерен бу дошманлыгы мине ялыктыра башлады, һәм мин инде, берәр сәбәп табып, Ярмоланы әллә хезмәтеннән азат итәргәме икән дип тә уйлана башлаган идем... Тик

аның дүрт тәңкә жалуньясенә ачлы-туклы яшәгән ишлегаиләсен кызгану хисе бу ниятемне эшкә ашырудан тыеп торды.

VII

Көннәрдән бер көнне, кичкә таба, гадәтемчә, субайлар өстендәге өйгә килгәч, миңа өй хуҗалары ничектер бик кәефсез, хафалы булып күренделәр. Карчык, аягын бөкләп, ятагында бөкрәеп утыра һәм, куллары белән башын тотып, чайкала-чайкала, авыз эченнән генә үзалдына нидер мыгырдана иде. Ул хәтта минем сәлам бирүемә дә илтифат итмәде. Олеся исә, һәрвакыттагыча, минем белән бик көләч исәнләште, ләкин безнең арада сүз әүвәлгечә җиңел генә ялганып китә алмады. Ул мин сөйләгәнне бөтенләй игътибарсыз тыңлый һәм шул сәбәпле, күрәсең, жаваплар-ны да урынлы-урынсыз кайтара иде. Аның гүзәл йөзендә ниндидер җуелмас эчке бер сагыш, хәсрәт бар иде.

Мин, кызның сәке өстендәге кулына сак кына орынып:

— Олеся, сездә ниндидер яман хәл булган, ахрысы, — дидем.

Олеся, нәрсәдер кararга теләгәндәй, йөзен тиз генә тәрәзәгә таба борды. Ул үзен тыныч тотарга тырышса да, җырылган кашларының калтырануы һәм аскы иренен әледән-әле тешләп-тешләп алуы аның нәрсәгәдер бик борчылганын күрсәтә иде.

— Юк... нинди яман хәл булсын бездә? — диде ул, саңгырау тавыш белән. — Бөтенесе дә искечә, бернинди үзгәреш юк.

— Олеся, нигә инде шулай ялганлап торырга?.. Сиңа бер дә килешми бу... Мин инде синең белән бөтенләй дуслашып беттек дип уйлаган идем.

— Чынлап менә, берни юк... Болай... үз мәшәкатьләребез генә... төрле юк-бар, кысыр хәсрәт...

— Юк, Олеся, монда алай кысыр хәсрәт кенә булмаска тиеш. Әнә үзеңә карачы — бөтенләй чыраең калмаган.

— Сезгә шулай тоела гына ул.

— Зинһар дим, алдашма, Олеся. Дөресен әйт. Сиңа ярдәм итә аламмы, юкмы — анысын хәзер үк әйтә алмыйм, әмма файдалы киңәш бирү ихтималым бар... Кайгыңны уртаклашсаң, синең үзеңә үк җиңел булып китәчәк ич.

— Ah, калдырыгызчы, зинһар, бу турыда сүз озайтуның һич хаҗәте юк, — дип куйды Олеся, сабырсызланып. — Бу эштә сез безгә бернинди ярдәм күрсәтә алмаячаксыз.

Шул чакны карчык гадәттән тыш кайнарлык белән сүзгә кушылды:

— Син нәрсә әле шулай кәпәренәсең, тиле! Аңа эш турында әйтәләр, ә ул борынын чөйгән була. Дөньяда синнән дә акыллырак кеше юк диярсең... Рәхим итегез, эфәнде, мин сезгә бөтенесен тәртибе белән сөйләп бирәм, — диде ул аннары, миңа таба борылып.

Мәсьәлә горур Олеся сүзләреннән аңлашылганга караганда шактый яманрак булып чыкты. Кичә кичен аларга көтмәгәндә төбәк урядниры килеп төшкән икән.

— Әүвәле ул җайлап-мачлап түргә кереп утырды да аракы сорады, — диде Мануйлиха әби, сүзен дәвам итеп. — Аннары әй тотынды безне куарга, әй тотынды. Егерме дүрт сәгать эчендә өйдән чыгып кит, монда эзең дә булмасын, ди. Әгәр, ди, киләсе килүемә сине монда күрсәм, ятап белән сөрдерәчәкмен, белеп тор, ди. Як-ягыңа ике солдат бастырам да туган җиреңә озаттырам син мәлгуньне, ди. Ә минем туган җирем бик ераста шул, Амченск каласында, атакаем... Анда инде минем таныш-белешләрем дә калмаган, аның соңында пачпортларыбыз да тәртипле түгел, вакыты чыкканга биш былтыр узган... Йа ходай, ничек кенә котыласы бу бәладән!

— Урядникны әйтәм, нигә соң ул элек сиңа монда яшәргә рөхсәт иткән дә, хәзер киреләнә? — дип сорадым мин.

— Анысын кем белә инде... Нәрсәдер такылдап маташкан иде дә маташуын, мин, ихлас менә, анламый калдым. Хикмәте бардыр, күрәсең. Менә бу без тора торган йорт безнең үз өебез түгел бит, алпавыт өе. Без Олеся белән элек авылда тора идек, аннары гына монда күчтек...

— Беләм, әби, беләм, ишеткәнем бар иде... Ул чакта әле сиңа мужикларның бик каты ачулары да булган бугай...

— Булды андый хәлләр, булды... Ул чакта мин карт алпавыттан, Абросимов әфәндедән, менә шушы алачыкны сорап алдым. Ә хәзер бу урманны ниндидер яңа алпавыт үзенә сатып алган, ди; ул, имеш, сазлыкларны киптерергә йөри, ди. Белмим инде, мин аларга нәрсәм белән комачау иткәнмендер?

— Әби, бәлкем, болар әле барысы да ялгандыр? — дип куйдым мин, аны юатып. — Бәлкем, урядникның «кызыл кәгазь» аласы гына килгәндер?

— Биреп карадым, улым, биреп карадым. А-алмый! Менә бит хикмәт нәрсәдә... Егерме бишлекне төрттем, алмады... Кай-я ул! Миңа шундый итеп җикеренде, кая басып торганымны оныттым. Өзми-куймый, һаман бер сүзне кабатлый: «Чыгып кит тә чыгып кит!» — ди. Без бичара-

ларга нишләргә кала инде хәзер! Җанкисәгем, ичмаса син булышса идең, шул бирән корсакка әйтәсен әйтеп, аны оялтып караса идең. Шуның өчен үзеңә гомерем буе дога кылырга әзермен.

— Әби! — дип, шелтә белән әйтеп куйды Олеся.

— Нәрсә — әби! — диде карчык, бусарынып. — Мин сиңа әби булганга егерме бишенче ел китте инде. Әллә капчык асып хәер эстәргә чыгу яхшырак булыр дисеңме? Юк инде, сез аның сүзен тыңламагыз, барын. Зинһар, ярдәм итегез, кулыгыздан килгәнне берүк эшли күрегез.

Мин артык аныкламыйча, гомуми сүзләр белән генә, аңа ярдәм итәргә вәгъдә бирдем, әмма, дөресен әйткәндә, нинди дә булса уңышка ирешүемә өмет бик аз иде. Әгәр инде безнең урядник та «алмый» икән, димәк, эш монда шактый катлаулырак. Бу кичне Олеся минем белән бик салкын хушлашты, хәтта үзенең моңарчы булган гадәтенә каршы килеп, мине озатырга да чыкмады. Горур кыз үзләренең тормышларына тыгылуым өчен миңа эченнән генә ачулана һәм әбисенең зарланулары өчен беркадәр ояла да иде булса кирәк.

VIII

Болытлы, соргылт җылы иртәләрнең берсе иде. Инде берничә мәртәбә эре тамчылы, кыска вакытлы, күз алдында үлән, чирәмнәрне яшәртеп җибәрә һәм яңа шытымнар шыттыра торган шифалы яңгыр да явып узды. Яңгырдан соң беразга гына кояш чыга да, минем өй алды бакчасындагы әле яңа яфрак яра башлаган һәм яңгыр суына чыланган куе сирень куаклары өстендә алтын нурлар җемелди башлый; көпшәк түтәлләрдә чыпчыклар чыр-чуы көчәйгәннән-көчәя; тупыл агачларының куе сары төстәге ябышкак бөреләреннән тирә-якка хуш ис тарала.

Мин үз бүлмәмдәге өстәл янында урман дачасының планын сызып утыра идем. Шул вакыт бүлмәгә Ярмола килеп керде һәм караңгы чырай белән:

— Врядник килде, — дип белдерде.

Моннан ике генә көн элек Ярмолага: әгәр урядник килә калса, миңа хәбәр итәрсең, дип боерып куюымны мин бу минутта ничектер онытып җибәргәнмен, шуңа күрә ул власть иясенең миңа нинди эше төште икән дигән уй мине башта сәерсендерә калды.

— Ни булды? — дип сорадым мин, аптырабрак.

Ярмола, соңгы вакытларда гомумән минем белән сөйләшкәндә гадәт итеп алган дошманнарча тонын үзгәртмичә, сүзен кабатлады:

— Врядник килде, дим... Әле генә буа аша чыкканын күрдем. Монда таба килә.

Чыннан да, күп тә үтми урам ягыннан тәгәрмәчләр дыңгырдавы ишетелде. Мин ашыгып тәрәзәгә ташландым һәм аны иңелә ачып куйдым. Урам уртасыннан, салмак кына юртып, озын, ябык гәүдәле, салынкы иренле, кимсенгән боек танаулы куе-көрән төстәге алашасына сыңар тәртә һәм юан бау ярдәмендә генә жигелгән биек, дыңгырдык читән тарантаста урядник узып бара иде. (Төбәкнең зәһәр телләре сөйләвенә караганда, урядник, үзен юк-бар гайбәтләрдән саклау өчен, йөрергә чыкканда атын юри шулай сыңар тәртәле тарантаска жиктерә, имеш.) Ул өстенә һәйбәт офицер поставыннан тегелгән шинель кигән һәм коточкыч симез гәүдәсе белән тарантастагы ике кешелек урынны берүзе алып утыра иде.

— Сәлам бирдек, Евпсихий Афрыканович! — дип кычкырдым мин, тәрәзәдән башымны сузып.

Урядник, дилбегәне тартып, атын тыя төште, учын фуражкасының козырёгына тидереп, авыр, симез гәүдәсе белән алга табарак бөгелеп куйды да, ихтирамлы, түрәләрчә яңгыравыклы калын тавыш белән:

— А-а, сәлам, сәлам! Исәнлек-саулыклар ничек? — дип, җавабын кайтарды.

— Бер генә минутка өйгә кереп чыкмассызмы икән? Сезгә бер йомышым бар иде.

Урядник, кулларын киң жәеп, башын чайкады.

— Юк, керә алмыйм. Хезмәт вазифам буенча Волошага барышым. Анда мине мәет көтә — суга батып үлүче мәете.

Ләкин мин Евпсихий Афрыкановичның холкындагы йомшак якларны яхшы белә идем инде, шуңа күрә юри искитмәгән тавыш белән:

— Кызганыч, бик кызганыч... Юкса, граф Ворцель экономиясеннән бик шәп ике шешә алдырткан идем... — дигән булдым.

— Керә алмыйм шул. Хезмәт вазифасы...

— Таныш буфетчыдан гына сатып алдым. Үз баласын саклагандай, базында саклап тоткан булган... Керер идегез... Бер уңайдан атыгызга солы бирергә кушармын.

— Менә бит сез нинди бәйләнчек кеше, валлаһи, — диде урядник, шелтә белән. — Иң беренче чиратта хезмәт, шуны да белмисезме әллә?.. Ә ул шешәләрдә нинди нәрсә соң? Сливянкамы?

— Нишләп сливянка булсын инде! — дип кул селтәдем мин. — Старка, атакаем, менә дигән карт старка!

— Без юлда бераз эчеп-ашап алган идек шул инде, — диде урядник, үкенгәндәй, йөзен җыера-җыера, муенын кашып.

Мин әүвәлгечә тыныч кыяфәт белән сүземне дәвам иттем:

— Белмим инде, хак сүзме-юкмы, шулай да буфетчы антлар итә-итә ул аракыны ике йөз еллык дигән булып маташты. Исе инде менә — чын коньяк диярсең, төсе дә гәрәбәдәй сары.

— Эх! Нишләтәсездер сез мине! — дип, көлкеле бер ачыргалану белән кычкырып куйды урядник. — Кая, атны кемгә тапшырыйм?

Чыннан да, минем өйдә берничә шешә старка бар иде. Ул, мактаганымча, бик үк борынгыдан сакланган аракы булмаса да, шулай да минем үтереп мактавым аңа бер егерме-утыз ел өстәр дип уйладым мин... Һәрхәлдә, бөлгән алпавытның аракы базында иң яхшы эчемлекләрдән саналып йөргән һәйбәт, көчле, каты старка — өйдә төнәтелгән старка иде ул. (Чыгышы белән рухани булган Евпсихий Африканович, салкын тидерү ихтималына дигән булып, аның бер шешәсен шундук үзенә сорап алды...) Эчкәндә кабар өчен дә ярыйсы гына шәп закуска — әле генә язылган атланмай да яшь редиска табылды.

Бишенче рюмканы авызга каплап куйгач, урядник авыр гәүдәсе астында болай да шыгыр-шыгыр тирбәлгән борынгы кәнәфинең аркасына ятарак төште дә:

— Йәгез, тыңлап карыйк, йомышыгыз ниндирәк соң? — диде.

Мин ашыкмыйча гына Мануйлиха әбинең кызганыч язмышы турында сөйләргә керештем; аның хәзерге вакытта ярдәмчесез калуын, өметсезлеккә бирелүен әйттем, аңа күрсәтелгән формаль мөнәсәбәт турында да сүз арасында искә төшереп алдым. Урядник минем сүзләрне башын түбән иеп, эре, итләч кызыл редисканы җай белән генә кабыгыннан чистарта-чистарта һәм аны авыз эчендә бик тәмләп, кыштырт-кыштырт чәйни-чәйни тыңлады. Ара-тирә ул, капылт кына башын күтәреп, миңа таба үзенең искитмәүчән бер битарафлык чагылып торган гаҗәеп кечкенә, тонык зәңгәр күзләрен юнәлтә, ләкин шул ук вакытта зур кызыл йөзендә аның бернинди теләктәшлек яки каршылык билгесе күренми иде. Мин, сүземне бетереп, тынып калгач, ул бары:

— Ярый, монысын ишеттек, ләкин сез миннән нәрсә телисез соң? — дип сорап куйды.

— Нәрсә булсын... — дидем мин, шомлана калып. —

Аларның хәлләренә керсәгез иде диюем. Бичара ике җан иясе бернинди ярдәмчесез калган, моңарчы алар тыныч кына яши бирә иделәр...

— Өстәвенә, шуларның берсе гөлбакчадагы чәчәк бөресе кебек тәмам өлгереп җиткән! — дип куйды урядник, хәйләләе елмаеп.

— Өлгереп җиткәнме, җитмәгәнме — анысы инде безнең эш түгел. Ләкин шулай да, әйтегез әле, ни өчен сез аларга ярдәм итүдән баш тартасыз? Аларны урыннарыннан сөрү шулай бик ашыгыч эшләнергә тиешле нәрсәмени? Соңра мин үзем дә алпавыт янына барып сөйләшә алам, тик шуңарчы аларны кузгатмый торасы иде. Берәр айга сабыр итсәгез, аңардан гына сезгә берни булмыйдыр ич?

— Ничек инде берни булмасын?! — дип, урыныннан ук сикереп торды урядник. — Була шул менә, була! Иң элек минем хезмәт урынымнан коры калуым бар. Нинди кешедер бит әле ул Ильяшевич дигән әфәнде, әлеге яңа алпавыт ягъни. Анысын бер алла белә. Бәлки, ул бик тә тавышгаугалы адәмдер... чак кына бер хәл була калса, кәгазькаләмгә тотынып, шундук Петербурга донос язарга яратучыларның берседер? Бездә андыйлар да еш булгалый бит!

Мин артык каударланып киткән урядникны тынычландырырга тырыштым:

— Юкка баш ватмасагыз сана, Евпсихий Африканович. Сез бу эшне артык күпертеп җибәрәсез бугай. Йәгез, ни шлибез? Тәвәккәллек бер нәрсә, әмма бу эшнең рәхмәт дигәне дә бар бит әле.

Урядник кулларын чалбар кесәләренә тыкты да:

— Фью-ю-ю! — дип сызгырып җибәрде. — Ичмасам рәхмәт дип әйтерлек булса иде! Сез нәрсә, мине әллә егерме биш тәңкә өчен хезмәттәге абруен сатар дип уйлыйсызмы? Юк, хөрмәтлем, сез мине җачар беләсез икән әле.

— Кызмагызчы, Евпсихий Африканович. Хикмәт бит акчаның күләмендә түгел, анысын болай гына әйтүем... Хикмәт кешечә мөнәсәбәттә...

— Ке-ше-чә? — дип, һәр ижекне, мыскыллагандай, аерым-аерым басым ясап әйтте урядник. — Беләсегез килсә, менә кайда утыра ул сезнең кеше дигәнегез!

Һәм ул күлмәк якасы өстеннән төксез симез җыерчык булып салынып төшкән юан кызыл муенына шапылдатып бер сугып алды.

— Ну, монысын инде сез бөтенләй арттырып җибәрдегез, Евпсихий Африканович.

— Бер тамчы да арттырмадым. Мәшһүр мәсәлче Кры-

лов әфәнде нәрсә дигән әле: «Алар — һәр төбәкнең яман шешләре», дигәнме? Менә шул яман шешләр инде сезнең ул ханымнарыгыз! Аннан соң, сезнең князь Урусов галиҗәнапларының «Полиция уряднигы» дигән һәйбәт бер китабын укыганыгыз бармы?

— Юк, туры килмәде шул.

— Бик кызганыч. Гаять тә әйбәт, югары әхлаклы китап. Берәр буш вакытыгызда укып чыгарга киңәш итәм...

— Яхшы, яхшы, рәхәтләнеп укып чыгармын. Шулай да, мин аңламыйм әле, ул китапның әлеге ике бичара хатынга нинди катышы бар соң?

— Ниндиме? Турыдан-туры катышы бар. Беренче пункт (Евпсихий Африканович сул кулының юан, йонлач имән бармагын бөкләде): «Урядник җәмәгать халкының һичбере калмыйча гыйбадәтханәгә йөрүен һәмишә күзәтеп торырга тиеш, әмма бу хосуста мәҗбүрләү тыеладыр...» Хәзер инде сездән сорарга рөхсәт итегез, теге... кем әле ул, Мануйлиха атлымы?.. Шул карчыкның кайчан да булса чиркәүгә барганы бармы?

Мин, сүзнең көтмәгәндә мондый четрекле юлга борылып китүенә гаҗәпләнеп, тынып калдым. Урядник исә миңа таба тантаналы бер кыяфәт белән күз ташлап алды да икенче бармагын бөкләде:

— Икенче пункт: «Һәмишә урында ялган күрәзәлек итүләр вә ялган юраулар тыеладыр...» Сизенәсезме инде? Аның соңында менә өченче пункты: «Үз-үзеңне күрәзәче яки сихерче итеп таныту вә шул юлда ялган эш кылу тыеладыр». Сез моңа ни дисез? Әгәр шушы нәрсә фаш ителеп, начальствога барып җитсә? Җавабын кем бирер? Мин. Кемне хезмәтеннән алырлар? Мине. Күрәсезме, хикмәт нәрсәдә!

Ул янә үзенең урынына кире утырды. Аның чепи күзләре, югарыга карап, гамьсез бер битарафлык белән бүлмә стеналарын капшый, ә бармаклары шак та шок өстәлне шакылдата иде.

— Шулай да, әгәр мин сездән үтенеп сорасам, Евпсихий Африканович? — дип, янә сүз башладым мин, юмакайрак тавыш белән. — Әлбәттә, сезнең эшегез катлаулы, мәшәкатьле, ләкин, белүемчә, сез үзегез дә гаять киң күңелле, мәрхәмәтле кеше бит. Шул ике хатынга тимәскә дип сүз бирү сезнең өчен авыр эшмени?

Урядникның күз карашы кинәт минем баш өсте аша каядыр стенага юнәлде. Аннары ул, бармаклары белән өстәлне шакылдатуын дәвам иткән хәлдә, гамьсез генә әйтеп куйды:

— Мылтыгыгыз шәп сезнең, искиткеч мылтык. Үткән юлы да, сез өйдә юк чакта монда кергәч, сокланып карап торган идем... Бик шәп мылтык!

Мин дә, артыма борылып, стенадагы мылтыгыма күз төшереп алдым.

— Әйе, мылтык ямаларлык түгел, — дидем мин, мактап. — Борынгы мылтык, Гастин-Реннет фабрикасыныкы. Әле үткән елны гына чакмасын яңадан үзгәртеп эшләттем. Сез аның көпшәләренә генә игътибар итегез.

— Соң инде, соң... шул көпшәләренә сокланып карап торам да инде мин. Искиткеч шәп мылтык... Просто менә хәзинә диярлек була.

Искәрмәстән безнең күзләребез очрашты. Миңа урядникның иреннәре җиңелчә калтырап, мәгънәле генә елмаеп куйгандай күренде. Мин урынымнан тордым да, стенадан мылтыкны алып, Евпсихий Африканович янына кире килдем.

— Чиркәсләрдә шундый бер әйбәт гадәт бар: алар кунак мактаган нәрсәне бүләк итеп бирәләр, — дидем мин, ихтирам белән. — Без сезнең белән чиркәсләр булмасак та, шулай да мин сездән, Евпсихий Африканович, бу мылтыкны истәлек итеп алуыгызны үтенер идем.

Урядник юри генә баш тарткан булды.

— Карагыз әле, шундый хәзинәне бирергә! Юк, юк, бу артык юмарт гадәт!

Ләкин урядникны озак кыстарга туры килмәде. Ул мылтыкны алып, ике тезе арасына кыстырды да, бик зур саклык белән, кадерләп, аның чакма атламасына кунган тузанны чиста кулъяулыгы белән сыпырып төшерде. Мылтыгымның корал кадерен белүче шундый сизгер кешегә күчүен күргәч, мин беркадәр тынычланып калгандай булдым. Бүләкне кулына алуга ук диярлек, Евпсихий Африканович урыныннан торды һәм китәргә җыенды.

— Анда эш көтеп тора, ә мин монда сезнең белән такылдап утырамын, — диде ул һәм идәнгә катып тибенә-тибенә галошларын киярга тотынды. — Безнең якларга килеп чыксагыз, рәхим итеп, миңа да керегез.

— Ярар, чакыруыгыз өчен рәхмәт. Ә Мануйлиха әби мәсьәләсе ничек соң, начальник әфәнде? — дидем мин түбәнчелек белән, аның исенә төшереп.

— Карарбыз, күрербез... — диде Евпсихий Африканович, фикерен бик үк ачык әйтмичә генә. — Ә минем сезгә тагын бер үтенечем бар әле... Редискагыз бик шәп сезнең...

— Үзем үстердем.

— Ис-кит-кеч шәп редиска! Ә минем җәмәгатем, әйтсәм

әйтим, яшелчә өчен үлеп китә инде менә. Әгәр мөмкин булса, шуны дим... бер генә учма булса да бирмәссезме икән?..

— Бик рәхәтләнеп, Евпсихий Африканович. Үземне сезнең алда бурычлы итеп саныйм... Бүген үк хезмәтче аша кәрҗине белән биреп җибәрермен. Шунда бер юлы атланмай да җибәрергә рөхсәт итегез... Миндә май да бик тәмле була бит.

— Яхшы, анысыннан да баш тартмыйбыз... — диде урядник, ризалыгын белдереп. — Ә теге хатыннарга әйтегез, әлегә мин аларны кузгатмыйча торырмын. Тик исләрендә тотсыннар, — дип дәвам итте ул, тавышын күтәрә төшеп, — алай коры рәхмәт белән генә миннән котыла алмаслар. Ә хәзергә сезгә исәнлек-саулык телим. Бүләк, сыегыз өчен тагын бер кат мерси.

Урядник хәрбиләрчә үкчәсен үкчәгә бәреп алды да тук тормышлы барлык түрә кешеләргә хас салмак адымнар белән экипажы янына чыкты. Анда инде аны, түбәнчелекле кыяфәттә баш киемнәрен салган килеш, сотский, авыл старостасы һәм Ярмола көтеп тора иде.

IX

Евпсихий Африканович үз вәгъдәсендә торды һәм кечкенә урман алачыгында яшәүче ике хатынны күпмедер вакытка кадәр тынычлыкта калдырды. Ләкин шул ук вакытта минем белән Олеся арасындагы мөнәсәбәтләрдә ниндидер сәер һәм кискен бер үзгәреш сизелде. Олесяның миңа булган хәзерге мөгамәләсендә әүвәлге беркатлы, ышанучан иркәлек, матур кыз чаялыгы белән тиктормас сабый бала шуклыгы бергә кушылган мөлаем җанлылык, самимилек ничектер сүнде, юкка чыкты. Әңгәмәләребезне ниндидер ясалмалык, уңайсызлану чорнап алды... Элекке чакта хыялыбызны җилкендереп, чиксез кызыксыну, дәрт уята торган нәрсәләр хәзер Олесяны өркеттеләр генә, ул күп вакыт алар турында сүз кузгатудан читләшергә тырышты.

Мин килгәч, ул киеренке-кырыс бер үҗәтлек белән һәрвакыт үзенең кул эшенә тотына иде. Ләкин мин еш кына аның эш арасында кинәт куллары түбән салынып төшүен һәм күзләренең идәнгә карап хәрәкәтсез катып калуын күрә идем. Андый чакта Олесяга исеме белән дәшсәм яисә нинди дә булса берәр сорау белән мөрәҗәгать итсәм, ул сискәнеп китә дә өркү чагылган һәм минем сүзләремнең мәгънәсен аңларга тырышып үзалдына аптырап калган йөзен әкрен генә миңа таба бора иде. Кайчакларда мин: әллә соң ул минем монда килеп йөрүемне яратмыймы, дип

уйлап куя идем; әмма кызның әле берничә көн элек кенә һәрбер сүземә, һәрбер фикеремә зур кызыксыну, теләктәшлек белән колак салуы минем бу уемны ничектер расламый шикелле иде... Димәк, монда бердәнбер фараз итәрдәе шул иде: урядник белән килеп чыккан гаугада минем якыннан катышуым Олесяның бәйсез, горур табигатен, күрәсең, бик каты рәнҗеткән булырга тиеш. Ләкин, алай дисәң, карурман эчендә ялгызы үскән гади бер кызда шундый горурлык, шундый нәзбереклек каян килде икән соң?

Болар һәммәсе дә ачыклауны, аңлашуны сорый иде, Олеся исә аңлашу өчен уңай булырдай очракларның һәммәсеннән кача-читләшә килде. Кичләрен урманда бергәләп йөрүләр бөтенләй тукталды. Көн саен, өйгә кайтып китәр алдыннан, мин Олесяга ялварулы күз карашымны юнәлтәм, аңа үземнең ачыктан-ачык сөйләшәсе килүемне сиздерәм, ә ул минем теләгемне аңламаганга сабыша иде. Карчык алдында исә, чукрак булуына карамастан, мин бу турыда сүз башларга ничектер кыймадым.

Үземнең ихтыяр көчсезлеге өчен, көн саен Олеся янына барырга әйдәп торган йомшак холкым өчен минем кайчакны хәтта үз-үземә ачуым килә иде. Бер үк вакытта сокланғыч та, серле-аңлаешсыз да булган бу кызга йөрәгемнең нинди нечкә, нык, яшерен җепләр белән бәйләнә баруын мин үзем дә сизенмәдем. Бу вакыт әле миндә мәхәббәт турында сөйләрдәй бернинди уй юк иде, әмма мәхәббәт алдыннан була торган томанлы борчулар, зарыгулы моңсу хис-шөбһәләр инде минем күңелне бөтенләе белән биләп алган иде. Кайда гына булсам да, нинди генә эшкә тотынсам да, минем бөтен уй-хисләрем Олеся тирәсендә бөтерелә; бөтен җаным-тәнем аңа омтыла, аның сөйләшкәндә әйткән юк кына сүзен, кул һәм баш хәрәкәтен, елмаюын искә төшерү дә минем йөрәкне тынычсыз, татлы бер кысылу белән кысылырга мәҗбүр итә иде. Ләкин кичләрен, аның янында какшаган аяклы тәбәнәк эскәмиядә утырганда, мин үземне көннән-көн кыюсызрак, уңайсызрак сизә барам, сөйләшергә сүз таба алмыйм һәм шуның өчен үз-үземне аяусыз битәрләргә тотынам.

Бервакытны шулай Олеся янында көннең-көнозын утырырга туры килде. Әле иртәнге якта ук мин үземдә нинди-дер хәлсезлек сизгән идем. Башта мин моның сәбәбенә һич тә төшенә алмадым. Кичкә таба хәлем бөтенләй начарланды. Баш чуендай авырайды, кемдер аның түбәсенә йомшак, ләкин көчле кулы белән басып торгандай, авырттырып сызларга тотынды, колаклар бераздан чыңлап, шаулап торды. Авызым кипте, бөтен тәнем буенча ниндидер

сүлпәнлек, минут саен иснисене, киереләсене китереп торган талгын бер хәлсезлек таралды. Күз алмалары, гүя әле генә күз камаштыргыч якты бер нәрсәгә карап алгандай, әрнеп-әрнеп сызларга кереште.

Кичен соң гына өйгә кайтып барганда, юлның нәкъ яртысына җиткәч, мине кинәт көчле бизгәк тота башлады һәм тыелгысыз рәвештә калтыратырга тотынды. Мин, бөтенләй диярлек юл-сукмакны күрмичә һәм кая барганымны да аңышмыйча, исерек кеше кебек атлавымны белдем, шул ук вакытта минем теш казналарым бертуктаусыз ачылып ябыла һәм тешләрем тешкә шак-шок бәрелә иде.

Мине өйгә кем кайтарып җиткергәндер — әлегә кадәр белмим... Коточкыч Полесье бизгәге алты көн буе мине үзенең дәһшәтле тырнагыннан җибәрмәде. Көндезләрен бизгәк беркадәр басылгандай була да, мин аңыма киләм. Андый чакта, авыртудан хәлсезләнгән аякларым белән гәүдәмне көчкә күтәреп, мин сызлана-сызлана әкрен генә бүлмә буенча йөренәм: адымнарны кызулый төшсәм, кайнар бер дулкын булып башка шундук кан йөгерә һәм күз алдында бөтен нәрсә караңгылык эченә чума иде. Кичләрен исә, гадәттә сәгать җиделәр тирәсендә, бизгәк давыл сыман кисәк кенә янә минем өскә ябырыла, һәм мин төннең-төн буе юрган астында әле туңудан калтыранып, әле эсседән үземне кая куярга белмичә газапланып чыгам; бу төннәр миңа гасырларга сузылгандай коточкыч озын булып тоела иде. Әз генә йокымсырап киттем исә, кайнарланган сырхау башта әллә нинди сәер, мәгънәсез һәм алҗыткыч чуар төшләр уйнаклый башлый. Минем ул тынгысыз саташуларымда бөтен нәрсә ничектер бергә бутала, бик кечкенә, бик вак әйберләр, күренешләр дә, берсе артыннан икенчесе ияреп, ниндидер чуалчык, ыгы-зыгылы йомгакка урала бара иде. Әле мин, имеш, ниндидер чуар төстәге, әкәмәт формадагы ящикларны барларга тотынам: алар эченнән икенче бер кечерәк ящиклар бушатам, ә ул кечерәк дигәннәреннән тагын да кечерәкләрен алам. Бу эш мине тәмам җиләтеп бетерсә дә, аның һич очы-кырые юк шикелле: ящиклар берсе икенчесе эченнән һаман чыга торалар. Яки менә, имеш, минем күз алдымнан миңгерәүләткеч бер тизлек белән чуар төстәге озын кәгазь тасмалар — обойлар очына башлый; аларның бизәкләре урынында мин тәлгәштәлгәш тезелгән кеше башларын аермачык күрәм, имеш; берләре аларның матур, ягымлы, көләч йөзле; икенчеләре ямьсез, чытык чырайлы; алар миңа телләрен чыгарып, тешләрен ыржайтып һәм галәмәт зур бәбәкләрен уйната-уйната узалар, имеш. Шуннан соң мин Ярмола белән әллә нин-

ди буталчык, катлаулы мәсьәләләр хакында бәхәс башлап җибәрәм, имеш. Безнең бер-беребезнең фикеренә каршы китергән дәлилләребез бәхәс куерган саен нечкәрә, тирәнәя бара; аерым сүзләр, хәтта сүзләрнең аерым авазлары да көтмәгәндә генә ниндидер серле, томанлы мәгънә ала; мин, бу ми корыткыч буш сүзләрне бер-бер артлы сөйләп торудан тәмам туеп, бәхәсне туктатырга телим, әмма табигый булмаган ниндидер яшерен көч миңа моны эшләргә ирек бирми, һәм бу көчкә карата миндә җирәнүле курку хисе үскәннән-үсә бара, имеш...

Кеше һәм җанвар шәүләләре, табигать күренешләре, төрле төстәге һәм формадагы гаҗәеп әйберләр, барлык сизү әгъзаларына берьюлы тәэсир итә торган серле сүзләр һәм тәгъбирләр барысы бергә кушылып, өермәдәй бөтерелгән ниндидер шомлы, саташулы бер төш иде бу... Ләкин шул ук вакытта — гаҗәп хәл! — мин төннең-төн буе корымланган яшел абажурлы лампадан түшәмгә төшкән түгәрәк якты шәүләне күреп ятам. Һәм шушы тонык читле соргылт шәүлә эчендә минем котырынкы, саташулы төшләремә караганда да хәвефлерәк һәм газаплырак булган серле һәм дәһшәтле чынбарлык яшеренеп ятканын ни рәвешледер аңлыйм, төшенәм шикелле.

Аннары мин уянып китәм яки, дөресрәге, уянмыйм, ә кинәт кенә үземне уяу бер хәлдә тоя башлыйм. Мин үземнең урын-җирдә сырхау булып ятуымны һәм саташулы төшләрдән әле генә айныган булуымны яхшы аңлыйм, әмма шулай да караңгы түшәмдәге якты шәүлә миңа үзенең яшерен дәһшәте белән һаман әле янап тора шикелле. Мин хәлсез кулым белән сәгатькә үреләм, аңа карыйм да, әле генә очсыз-кырыйсыз булып тоелган мәгънәсез саташуларымның нибары ике-өч минут кына дәвам иткәнлеген күреп, тәмам аптырашта калам. «Йа ходай! Кайчан соң таң атар!» — дип уйлыйм мин ачыргаланып һәм башым белән кайнар мендәр өстендә ауный башлыйм. Минем өзек-өзек алган авыр, кайнар сулышым иреннәремне пешерә. Ләкин озакламый мине яңадан җиңелчә йокымсырау биләп ала, башым янә буталчык саташулар мәйданына әверелә; ә бер-ике минуттан мин яңадан чиксез сагышлы уйлар белән уянып китәм...

Алтынчы көн дигәндә, минем табигый тазалыгым һәм хинин белән бака яфрагы төнәтмәсе эчүем, нихаять, яман чирне җиңеп чыкты. Әмма түшәктән мин аяк та атлап йөри алмаслык дәрәҗәдә хәлсезләнеп, ябыгып тордым. Шулай булса да сәламәтләнү комсыз бер тизлек белән алга барды. Алты көн буена дәвам иткән кызышу-саташулардан

алҗыган күңелгә уй-хиссез бер ялкаулык, талгын рәхәтлек кереп урнашкан иде. Ашавым икеләтә арта төште, тәнем, һәрбер күзәнәге белән үзенә тормыш ямен сеңдереп, күзгә күренеп тазара һәм ныгый барды. Шул ук вакытта тыелгысыз яңа бер көч мине урманга, авыш алачыкка барырга әйдәде. Нервларым әле сәламәтләнеп җитмәү сәбәпле, Олесяның йөзен һәм тавышын күз алдына китергәч, аны сагынудан минем хәтта елыйсыларым килә иде.

X

Янә биш көн узды, һәм мин, бөтенләй диярлек тазарып җитеп, ниһаять, беркөнне урмандагы әлеге субайлы алачыкка барырга булдым. Мин анда җәяү генә чыгып киттем һәм юл ахырында үземдә бернинди ару-талу да сизмәдем. Йорт болдырына менүгә үк, минем йөрәгем шомлы бер курку белән дөпелдәп тибәргә тотынды. Олеся белән күрешмәгәнгә ике атна узган иде инде. Аның үзем өчен нинди якын, кадерле кеше булуын мин бу минутта аеруча нык аңладым. Мин, эчкә керергә кыюлыгым җитмичә, ишек тоткасына тотынган килеш, берничә секунд чамасы авыр сулыш алып ишек төбендә басып тордым, каушаудан хәтта күзләремне йомдым...

Мин ишекне ачып өйгә кергәч тә булган беренче тәэсирне, кавышуның беренче минутларын анык хәтерләмим. Гомумән, андый чакта ни дә булса истә калдырырга да мөмкин түгелдер... Улы белән әни кешенең, ир белән хатынның яисә ике гашыйкның очрашканда бер-берсенә әйткән тәүге сүзләрен истә калдырып буламыни? Андый чакта бит көн дә сөйләнелә торган иң гади сүзләр әйтелә. Әгәр ул сүзләрне түкми-чәчми кәгазьгә теркәп барсаң, аларның хәтта көлке булып тоелулары да бик мөмкин. Ләкин дөньяда иң кадерле кешең авызыннан әйтелгән булуы гына да ул сүзләрне кавышу вакытында гаять урынлы һәм сөйкемле итә.

Мин бары шуны гына бик ачык хәтерлим: бусагадан атлап керүемә, Олеся ялт итеп миңа таба борылды, һәм аның агарынган, яңача бер рәвешкә кергән гүзәл йөзендә күз иярмәстәй тизлек белән бер-бер артлы әле аптырау, әле курку, борчылу, әле мәхәббәт ялкыны белән өртелгән нурлы, мөлаем елмаю чагылып узды... Мануйлиха әби минем янымда авыз эченнән генә шыш-шыш сөйләнә-сөйләнә кыбырсынып йөри иде. Ләкин мин аның сәлам биреп исәнләшүен ишетмәдем. Олесяның тавышы исә минем колакка татлы бер музыка булып ишетелде:

— Ни булды сезгә? Авырдыгызмы әллә? Йа ходай, сез шундый ябыккансыз!

Мин аңа бик озак бернидип тә җавап бирә алмадым, һәм без шулай, кара-каршы баскан килеш, һичбер сүз дәшмәстән, кулны кулга тотынып, тирән мәгънә һәм шатлык тулы күз карашларыбызны бер-беребезгә текәп, тораташтай катып тордык. Шушы сүзсез карашып торган берничә секундны мин үз гомеремдә кичергән иң бәхетле, иң шатлыклы бер мизгел итеп саныйм; шуңа хәтле дә, шуннан соң да — беркайчан да, бервакытта да минем бүтән андый бөтен җанны-күңелне биләп ала торган саф, тулы куанычны кичергәнем булмады. Бу минутта мин Олесяның зур коңгырт-кара күзләрендә бөтенесен-бөтенесен дә: кавышу шатлыгын да, озак килми торуым өчен миңа белдергән шелтәсен дә, кайнар мәхәббәтен дә ачык күрдем... Шушы ялкынлы күз карашы белән ул, гүя, бернинди шарт-таләп куймыйча һәм икеләнмичә, шатланып, үзенең бөтен җаны-тәне белән минем иркемә тапшырылуын әйтергә тели иде.

Олеся, күзе белән әкертен генә әбисенә таба ымлап күрсәтеп, әлеге тылсымлы мизгелне беренче булып өзде. Без янәшә утырыштык; һәм ул үтә кайгыртучан бер кыяфәттә, ваклап, җентекләп, миннән авыруым хакында сораштыра башлады. Мин нинди дарулар эчкәнмен, доктор нилләр сөйләгән — Олеся боларның һәммәсе белән дә кызыксынды. Төбәк үзәгеннән мине дәваларга дип килгән доктор хакында ул кайта-кайта сорашты. Ара-тирә мин Олесяның авыз кырыйларында сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәү чагылып китүен дә күрдем.

— Ah, авырганыгызны ничек белми калдым соң мин? — дип ачыргаланды ул үкенеч белән.— Белгән булсам, мин сезне бер көн эчендә аякка бастырган булыр идем бит... Алар бернәрсә, бер-нәр-сә дә аңламыйлар лабаса, ничек инде шуларга ышанмак кирәк? Ник сез мине чакыртмадыгыз?

Мин беравык сүз таба алмый тордым.

— Хикмәт бит менә нәрсәдә, Олеся... бизгәк мине бик кинәттән эләктереп алды... аның соңында, сине дә борчыйсым килмәде. Соңгы вакытларда син, әллә инде ачуланып, әллә миннән туеп, үзеңне ничектер бик сәер тота башлаган идең... Карале, Олеся, — дип өстәдем мин, тавышымны түбәнәйтә төшеп, — безгә синең белән бик күп, бик күп нәрсәләр хакында сөйләшергә кирәк иде... тик икәүдән-икәү генә... аңлыйсыңмы?

Олеся, ризалыгын белдереп, керфек какты, аннары Мануйлиха әбигә таба куркынган күз карашы ташлап, тиз генә пышылдап әйтте:

— Әйе... минем үземнең дә сезнең белән бик сөйләшәсем килә... тик соңрак... аз гына сабыр итегез...

Кояш баюга, Олеся мине ашыктыра башлады.

— Тизрәк җыеныгыз, тизрәк, — диде ул һәм, кулымнан тотып, мине сәкедән торгызды. — Һаваның дымы арткан чакка калсагыз, бизгәк чире сезгә янә әйләнеп кайтачак.

Онытының ашыга-ашыга башына зур йон шәлъяулык урап торуын күреп, Мануйлиха әби шикләнә калды.

— Ә син кая җыендың, Олеся?

— Чыгам әле... бераз озатып киләм, — диде Олеся.

Бу сүзләрне ул ничектер ваемсыз бер кыяфәт белән, әбисенә карап түгел, тәрәзәгә карап әйтте, ләкин миңа аның тавышында сизелер-сизелмәс кенә ризасызлык аһәңе яңгырагандай булды.

Мануйлиха әби, сүзләренә аеруча бер басым ясап, кабатлап сорады:

— Чыгарга булдың, алайса?

Олеся очкынланып янган күзләре белән әбисенең йөзенә текәлде.

— Әйе, чыгарга булдым! — диде ул, тәкәббер генә. — Бу турыда инде сөйләнәсе сөйләнгән, әйтеләсе әйтелгән. Үз ихтыярым, үз җавабым.

— Их, син! — дип куйды карчык, көрсенеп, шелтә белән.

Ул янә нәрсәдер өстәп әйтергә теләгән иде дә, ни өчендер әйтми калды, бары кулын гына селтәде, аннары калтыравык зәгыйфь аякларын чалыш-чолыш атлап өй почмагына юнәлде һәм анда авыз эченнән генә сукрана-сукрана ниндидер кәржин янында булашырга тотынды.

Кыска гына вакыт эчендә күз алдымда кабынып сүнгән шушы сөйләшүдән мин Олеся белән Мануйлиха әби арасында күптәннән бирле ниндидер бәхәс, низаг яшәп килүен аңладым. Әлеге сөйләшү дә әнә шул бетмәс низагларның дәвамы иде булса кирәк. Мин, наратлыкка төшә-төшешли, янәшәмдә атлап барган Олесядан сорамыйча түзә алмадым:

— Олеся, синең минем белән болай чыгып йөрүеңне әбиең өнәмиме әллә? Шулаймы?

Олеся күңелсез генә иңбашын җыерып куйды.

— Зинһар, андый юк-барларга игътибар итмәгез.

Бәлкем, теләмидер дә... Теләмәсә соң!.. Минем дә үземә ошаганны эшләргә хакым бардыр ич?

Шул чакны кинәт минем күңелдә тыелгысыз бер теләк — әүвәлге кырыслыгы өчен Олесяга үпкәмне әйтү теләге туды.

— Димәк, син элек тә, мин авырганчыга хәтле дә, минем белән икәүдән-икәү йөри алгансың, тик теләмәгәнсең генә... Аһ, Олеся җаным, ул чакта мине ничек газаплаганыңны белсә идең... Мин бит сине һәр кич саен менә озата чыгарсың, менә озата чыгарсың дип өмет иттем... Ә син соңгы вакытта миңа гел игътибарсыз булдың, гел караңа кабынып, ачуланып утыра бирдең... О-о, нинди авыр газаплар кичердем мин синең аркада, Олеся!..

— Ярый, ярый, җитәр, җаныем... Онытыгыз ул рәнҗүләрне, — диде Олеся, гафу үтенгәндәй, йомшак тавыш белән.

— Юк, бу бит сиңа рәнҗүдән әйтүем түгел, болай сүз уңаеннан гына әйтүем... Хәзер инде мин синең ул чакта ни өчен шулай ачулы булганыңны аңлыйм... Ә бит баштарак, — чын менә, хәзер аны искә төшерергә дә оят, — син миңа урядник өчен үпкәлисеңдер дип уйлаган идем. Шул шик мине зур хафага салды. Мин инде үземне сиңа ярдәм кулы сузарга да хакы булмаган, синең өчен бөтенләй чит-ят булган бер кеше итеп саный башлаган идем... Бу хәл минем өчен бик аянычлы иде... Боларның һәммәсе дә әбиең аркасында гына булуын мин белмәдем...

Олесяның йөзенә кинәт куе кызыллык йөгерде.

— Әби аркасында түгел шул менә!.. Мин үзем теләмәдем! — диде ул, кайнар, дәртле бер тавыш белән.

Мин атлап барган көйгә Олесяга борылып карадым. Ул башын беркадәр аска таба иебрәк бара, аның йөзе гүзәл, нәфис иде. Соңгы ике атна эчендә аның да шактый ябыккан һәм күз төпләренә күгелҗем күләгәләр кунган булуын мин тик хәзер генә шәйләп алдым. Үзенә таба төбәлеп каравымны тоеп, ул күзләрен күтәрде, ләкин шундук кире төшерде дә, оялып, йөзен читкә борды.

— Ни өчен теләмәдең, Олеся? Ни өчен? — дип сорадым мин, дулкынланудан тәмам тавышым үзгәреп, һәм Олесяны, кулыннан тотып, тукталырга мәҗбүр иттем.

Без ук сыман төз булып сузылган озын һәм тар аланның нәкъ уртасында туктап калдык. Безнең ике ягыбызда да рәт-рәт тезелеп утырган биек, зифа нарат-

лар, хуш исле яшел ябалдашлары белән үзара тоташып, ерак-еракларга сузылып киткән гаять озын коридор хасил итә иде. Кабыклары суерылган ул агачларның шәрә кәүсәләрендә кичке шәфәкънең кызгылт шәүләсе чагылып җемелди иде.

Мин, Олесяның кулын тагы да катырак кыса төшеп, басынкы тавыш белән соравымны кабатладым:

— Ни өчен? Ни өчен теләмәдең, Олеся?

— Мин курыктым... — диде Олеся, ишетелер-ишетелмәс кенә. — Мин тәкъдирдән качып булыр дип уйлаган идем... Ә хәзер... хәзер...

Ул, суларга һава җитмәгәндәй, сүздән бүленеп калды да кинәт кискен, ашыгыч бер хәрәкәт белән муенына сарылды, һәм минем иреннәремне тиз-тиз пышылдап әйткән калтыравык, татлы сүзләр яндырып алды:

— Хәзер миңа барыбер инде, барыбер! Чөнки мин сине яратам, аңлыйсыңмы, яратам, кадерлем минем, бәхетем, күз нурым минем!..

Ул миңа тагын да сыенарак төште. Мин үз кочагымда аның кайнар, көчле, таза тәненең ничек калтыравуын тойдым, күкрәгем турысында йөрәгенең дөп-дөп тибүен ишетеп тордым. Аның дәртле үбүе авырудан ныгып җитмәгән хәлсез башыма каты шәраб шикелле тәэсир итә, мине үз-үземне белешмәстәй бер халәткә ташлый иде.

— Олеся, алла хакы өчен, кирәкми... кочаклама минс, — дип ялвардым мин, аның кочагыннан ычкынырга тырышып. — Аңлыйсыңмы, хәзер инде мин үзем дә куркам... үземнән үзем куркам... Җибәр, Олеся.

Ул аз гына башын калкытты да, талгын, назлы бер елмаю белән елмаеп, күзләремә сөзеп карады.

— Курыкма, сөеклем, — диде ул, аңлатып булмастай гаҗәеп бер тәвәккәл, мөлаем тавыш белән. — Мин сине беркайчан да шелтәләмәм, беркемнән дә сине көнләмәм... Тик дөресен генә әйт: яратасыңмы мине?

— Яратам, Олеся, өзелеп-өзелеп яратам. Күптәннән бирле яратам. Тик, зинһар... бүтән үпмә мине... Минем зиһенем томаланды, башым әйләнә, сабырым җитмәс дип куркам...

Ул газаплы-татлы бер ашкыну белән, гасабиланып, тагын да иреннәремне үбәргә тотынды. Мин аның пышылдап әйткән иркә сүзләрен, ишетүдән бигрәк, болай күңелем белән генә чамаладым шикелле:

— Алайса бернәрсәдән дә курыкма, башка бүтән бернәрсә турында да уйлама... Бүген безнең көн, без аны беркемгә дә бирмәбез.

. . . . . .

Һәм бу төң, ниндидер тылсымлы, соклангыч бер әкият сыман, минем күңелдә мәңге-мәңгегә сеңеп калды. Күк йөзендә тулы ай йөзә иде. Аның көмеш нурлары, бөтен аланны ала-кола, чуар, сихри бер төскә манып, караңгыда тын гына утырган агачларның кәкре-бөкре кәүсәләренә һәм җәенке ботакларына, шулай ук хәтфәдәй йомшак мүк каплаган җир өстенә тонык күгелҗем таплар булып яткан. Нәзек, зифа буйлы каеннар ерактан үк агарып, үтә ачык булып күренәләр; аларның сирәк яфраклы башлары, үтә күренмәле һава бөркәнчекләре ябынгандай, чаларып җемелдиләр. Урыны-урыны белән ай яктысын куе нарат ботаклары каплый. Андый урыннарда күзгә төртсәң күренмәслек дөм караңгылык хөкем сөрә, бары тик бу караңгылыкның нәкъ урта бер җирендә генә ара-тирә әллә каян нур көлтәсе бәреп керә дә, рәт-рәт тезелеп торган агачларны аермачык яктыртып, җир өстенә сукмак сыман тар, төз юл сызып куя; бу юл шундый сихри, матур, якты, тигез ки, гүя аны Оберон белән Титаниянең тантаналы сәяхәте өчен тылсымлы урман адәмчекләре — эльфлар үзләре җиһазлаган. Һәм без, бер сүз сөйләшмичә, үз бәхетебезгә һәм урманның шомлы, сихри тынлыгына буйсынып, кочаклашкан килеш, шушы хозур, көләч чын әкият дөньясыннан әкрен генә атлап барабыз.

Олеся кинәт туктап калды.

— Карале, бөтенләй онытканмын икән ләбаса: син бит инде күптән өеңә кайтырга тиеш кеше, — диде ул. — Менә бит нинди әшәке мин! Син әле генә авырудан терелгәнсең, ә мин сине шушы вакытка хәтле урманда тоткарлап торам.

Мин аны кочагыма алдым да, куе кара чәчләре өстеннән бөркәнгән шәлъяулыгын артка таба шудырып куеп, колагына иелдем һәм чак ишетелерлек тавыш белән:

— Олеся, син үкенмисеңме? — дип сорадым.

Ул әкрен генә башын чайкады.

— Юк, үкенмим... Ахыры ни генә булса да, мин үкенмәячәкмен. Хәзергә әле миңа шундый рәхәт...

— Син нәрсә, ахыры яман булыр дип уйлыйсыңмыни?

Олесяның күз карашында теге вакыттагы кебек тагын серле, хорафатлы курку чагылып узды.

— О, ахыры һичшиксез яман булып бетәчәк... Исеңдәме, мин сиңа треф дамасы турында сөйләгән идем?

Треф дамасы — ул мин үзем бит, карта әйткән бәхетсезлек тә минем үземә киләчәк... Белөсеңме, мин теге вакытны сиңа: безгә бөтенләй килеп йөрмә, дип әйтмәкче булган идем. Ә син ул арада авырып киткәнсең, ярты ай чамасы безгә килми тордың... Менә шул чакта мин сине шулкадәр сагындым, шулкадәр сагындым, сине бер күрер өчен дөньядагы бөтен нәрсәне бирергә әзер идем... Әнә шул сагышлы көннәрдә ныклы бер карарга килдем дә инде мин. Әйдә, мәйтәм, ни булса шул булыр, ә үз бәхетемне беркемгә дә бирмим, дидем...

— Дөрес, Олеся. Мин дә нәкъ шулай бит, — дидем, аның чигәсенә иреннәрем белән орынып. — Сиңнән аерылганчы мин үземнең яратканымны белмәдем. Кемдер берәү: мәхәббәт өчен аерым яшәү учак өчен җил кебек ул, дип юкка гына әйтмәгән, күрәсең: кечкенә мәхәббәтне ул сүндерә, ә зурысын тагын да дөрләтебрәк җибәрә.

— Ничек дидең әле? Зинһар, тагын бер кабатлачы, — дип элеп алды Олеся, тирән бер кызыксыну белән.

Кем тарафыннандыр әйтелгән бу хикмәтле сүзне мин тагын бер мәртәбә кабатларга мәҗбүр булдым. Шуннан соң Олеся уйга калды, һәм мин иреннәренең кыймылдавы буенча аның шул ук сүзләрне эчтән генә кабатлавын һәм истә калдырырга тырышуын аңладым.

Миңа Олесяның агарынган һәм бераз артка ташланган йөзе, ай шәүләсе чагылып җемелдәгән зур кара күзләре озакламый ниндидер афәт буласын сизеп торадыр шикелле тоелды, һәм шул уйдан минем эчкә кинәт өшеткеч бер салкын йөгерде.

XI

Безнең чиксез нур һәм ямь тулы бу самими мәхәббәтебез бер айга якын дәвам итте, һәм әлеге шәфәкъ нурлары белән өртелгән тын кичләр, энҗе чәчәкләре һәм бал исе аңкытып, кош-корт чыр-чуыннан яңгырап торган чыклы, дәртләндергеч саф иртәләр, әлеге талгын, изрәткеч, эссе июнь көннәре — һәммәсе дә, Олесяның гүзәл йөзе-сыны белән бергә, минем күңелдә хәзергә кадәр мәңге җуелмас җанлы истәлек булып саклана... Шул вакыт эчендә мин бер генә мәртәбә дә үземдә нинди дә булса күңелсезләнү, арыганлык хисе яки сукбайлык һәвәслеге кузгалуын сизмәдем. Мин, мәҗүсиләр алласы яисә көч-куәте ташып торган яшь, таза җанвар кебек, дөньяның яме, җылысы белән, аң-

лы яшәү дәрте, куанычы һәм тыныч, сәламәт табигый мәхәббәт ләззәте белән хозурланып яшәдем.

Мин терелгәннән бирле Мануйлиха әби бөтенләй ачу китергеч бер мыгырдавыкка әверелде; ул мине хәзер шундый ачыктан-ачык нәфрәт белән каршылый һәм мин аларда утырган чакта мичендәге чуен чүлмәкләрен шундый ачу белән дөбер-шатыр күчереп йөртергә тотына иде ки, ахырда без Олеся белән һәр кичне өйдән читтә, урман эчендә генә очраша торган булдык. Һәм яшеллеккә чумган мәһабәт урман, затлы, кыйммәтле бер кыса сыман, безнең самими мәхәббәтебезне үз канаты астына сыендырды.

Мин көннән-көн бер нәрсәгә гаҗәпләнә бардым: Олеся — кыргый урманда ялгызы үскән, хәтта укый-яза да белмәгән гади бер кыз — тормышның күп кенә мәсьәләләрендә гаҗәеп сизгерлек, тумыштан килгән табигый бер әдәплелек күрсәтә иде. Мәхәббәтнең, — әгәр аны туры, тупас мәгънәсендә алсаң, — һәрвакыт ниндидер ямьсез яклары, нечкә табигатьле тынгысыз кешеләрдә ояльлу һәм газаплану тудыра торган нечкәлекләре була. Ләкин Олеся үзенә хас самими сафлыгы белән мәхәббәттәге андый четерекле якларны ничектер оста гына читләтеп үтә белә иде. Шуңа күрә безнең үзара мөнәсәбәтне бернинди тупаслык, әдәпсезлек тә ямьсезли алмады.

Ул арада минем китәр вакытым да якынлашты. Дөресен генә әйткәндә, Перебродта минем инде хезмәтем буенча барлык эшләрем тәмамланган иде, аннан китүне бары үзем генә тоткарлап тора идем. Ләкин китү турында мин Олесяга әлегә кадәр бер сүз дә әйтмәдем, чөнки аның бу хәбәрне ничек кабул итәчәген күз алдына китерергә дә курка идем. Гомумән, минем хәл шактый кыенлашып калды. Мондагы тормышка артык ияләшеп киткән идем мин. Көн саен Олесяны күреп тору, аның сөйкемле тавышын, яңгыравыклы көлүен ишетү, назлы иркәләүләрен тою — минем өчен хәзер болар гади бер ихтыяҗ гына түгел иде инде. Мин, гомумән, ансыз тора алмас бер хәлгә килгән идем. Әллә нигә бер, көннәр бозылып, очрашмый калсак, мин, тормышымдагы иң мөһим, иң кадерле нәрсәмне югалткандай, бөтенләй өметсезлеккә батам; бер эшкә дә кулым бармый, бөтен күңелем белән бары анда гына — җылы, якты табигать кочагына, көләч йөзле Олесям янына гына ашкына идем.

Беренче вакытларда Олесяга өйләнү уе минем баш-

ка килеп тә карамады диярлек. Аңа өйләнү ихтималы миңа безнең үзара мәнәсәбәтләребезне намуслы хәл итү юлындагы иң соңгы бер чара гына булып тоела иде. Ләкин тора-бара бу уй минем күңелне бик еш кымтырыклый башлады. Мине тик бер генә нәрсә куркытты: шушы ияләшкән гүзәл карурманыннан аерылып китеп, чит-ят шәһәр мохитына килеп эләккәч, Олеся үзен ничек хис итәр? Аның затлы, модалы киемнәрдән кунак бүлмәсендә хезмәттәшләремнең хатыннары белән юк-бар сүз сөйләшеп утыруын мин күз алдына китерергә дә курка идем.

Әмма китәр вакытым якынлашкан саен, миндәге сагыш, ялгызлык хисе дә, куркыныч бер төс алып, һаман киңәя, зурая барды. Өйләнү уе көннән-көн үсте, ныгыды, ахырда ул бөтенләй төпле бер карарга әверелде. Олесяга өйләнү хәзер инде миңа югары җәмгыятьне тетрәндерерлек кыю бер адым булып тоелмый иде. «Кайбер яхшы гына кешеләр, галимнәр тегүче кызларга, асрауларга өйләнеп, менә дигән итеп тора-лар ич әле,— дип уйладым мин, үз-үземне юатып.— Алай гына да түгел, шундый гади кызларга өйләнүләре өчен алар гомерләре буе язмышларына шөкер кылып яшиләр. Мин шул кешеләрдән дә бәхетсезрәк булмамдыр ич инде?»

Бервакыт июнь урталарында, кичкырын, шау чәчәккә күмелгән дүләнә куалары арасыннан сузылган тар сукмак борылышында мин, гадәтемчә, Олесяны көтеп тора идем. Аның җиңел адымнар белән җил-җил атлап килүен мин ерактан ук күреп алдым.

Килеп җитүенә, ул мине кочаклап алды да, кызу йөрүдән сулышына кабынып:

— Исәнме, сөеклем, — диде. — Озак көттермәдемме? Ә мин, беләсеңме, көчкә-көчкә генә ычкындым... Һаман әби белән тарткалашам.

— Шушы көнгә хәтле тынганы юкмы?

— Кая ул! «Ул, ди, синең башыңа бер җитәр әле, ди... Туйганчы көләр-мыскыллар да ташлап китәр, ди. Ул сине тамчы да яратмый...» ди.

— Минем турыда шулай диме?

— Синең турыда, сөеклем, синең турыда... Әйдә такылдасын, мин барыбер аның бер генә сүзенә дә ышанмыйм бит.

— Ул безнең турыда бөтенесен беләме?

— Тәгаен әйтә алмыйм... шулай да, белә шикелле. Хәер, минем бу хакта аның белән беркайчан да сөйләш-

конем юк — ул үзе сизенә булса кирәк. Ярар, ни булса шул булыр, баш ватмыйк әле... Киттек.

Ул ак чәчәк сарган дүләнә ботагын сындырып алды да үзенең чәченә кадап куйды. Без баеп барган кичке кояшның кызгылт нурлары астында чак-чак кына алсуланып яткан сукмак буйлап әкрен генә алга атладык.

Мин әле үткән төнне үк Олесяга бөтенесен ачыктан-ачык сөйләп бирергә дип үз-үземә сүз биреп куйган идем. Ләкин хәзер ниндидер сәер бер кыюсызлык минем телемне бәйләп торды. Әгәр Олесяга үземнең тиздән китәргә тиешлегемне һәм өйләнергә ниятем барын әйтсәм, ул миңа ышанырмы? Өйләнергә дигән ниятем аңа беренче хәбәрдән туган яра-җәрәхәтне кечерәйтү, йомшарту өчен әйтелгән бер юату сүзе генә булып тоелмасмы? Мин шулай уйладым һәм: «Әнә теге умырылган кәүсәле өрәңге агачы янына барып җиткәч тә сөйли башлыйм», — дип, эчемнән генә үз-үземә сүз биреп куйдым. Менә без өрәңге агачы турысына да килеп җиттек; мин инде, дулкынланудан агарына баруымны тоеп, сүз башлар өчен авызымны да ачкан идем, ләкин шул чакны кинәт мине тагын әлеге кыюсызлык хисе биләп алды; авыз эче ничектер оеп, салкынаеп китте, йөрәгем тынгысыз бер тибү белән чәнчеп-чәнчеп тибәргә тотынды. «Егерме җиде — минем бәхетле саным, — дидем мин, берничә минут үткәннән соң, — шуңа хәтле саныйм да, аннары башлыйм!..» Һәм мин әкрен генә күңелемнән санарга керештем. Әмма егерме җидегә җиткәч, миндә янә икеләнү туды, янә телем әйләнмәс булды. «Юк, — дидем мин үземә үзем, — алтмышка хәтле санарга кирәк, ни дисәң дә алтмыш — бер минут ул, аннары инде курыкмыйча сөйли башларга да була...»

— Ни булды соң әле сиңа бүген? — дип сорады кинәт Олеся. — Син ниндидер күңелсез уйларга баткансың. Әйтче, ни булды?

Шуннан соң мин, ниһаять, сүземне башлап киттем, ләкин аны иң гади бер нәрсә турында сөйләгәндәй, үземә дә җирәнгеч тоелган әллә нинди чит-ят, гайре табигый, ваемсыз бер тавыш белән башлап киттем.

— Син дөрес сизенгәнсең, Олеся... Чынлап та, күңелсезрәк бер хәл бар иде шул... Хикмәт шунда: хуҗалар мине, монда эшләремнең бетүен белеп, кире шәһәргә чакыралар.

Мин күз кырыем белән генә Олесяга карап алдым. Аның йөзендә янган кызыллык кисәк кенә юкка чыкты, иреннәре дерелдәп куйды. Берничә минут чамасы без

дәшмичә генә янәшә атлап бардык. Үләннәр арасында чикерткәләр сайраша, каяндыр бик еракта шыңгырдап тартар тавышы ишетелә иде.

— Син үзең дә аңлыйсың булыр, Олеся, — дидем мин, янә сүзгә керешеп, — миңа монда калырга уңайсыз, аннары торыр җирем дә юк. Шулай ук хезмәт урынымны ташлау да ярап бетмәс шикелле...

— Соң... алай булгач инде... монда сөйләп торасы да юк,— диде Олеся, тыныч-сабыр күренергә тырышып, ләкин тавышы шундый җансыз, саңгырау булып чыкты ки, минем шундук эчем жу итеп китте. — Алай хезмәт урынығыз да көткәч... кайтырга кирәк, элбәттә.

Ул бер агач төбендә туктады да аркасы белән аның кәүсәсенә сөялде. Олесяның бөтенләй чырае качкан, куллары җансыз рәвештә түбән салынып төшкән, ә иреннәренә, газап пәрдәсе аша, кызганыч елмаю җәелгән иде. Аның бу кыяфәте мине тәмам куркуга салды. Мин ашыгып аның янына килдем һәм кулларыннан кысып тоттым.

— Олеся... нәрсә булды? Олеся... бәгърем!..

— Әллә ни юк... гафу итегез мине... хәзер бетә ул. Ничектер... башым гына әйләнеп китте.

Ул, үз-үзен кузгалырга мәҗбүр итеп, кулын минем кулдан алмыйча гына, берничә адым алга атлады.

— Олеся, син хәзер генә минем турыда бик начар уй уйлап алдың, әйе бит? — дидем мин шелтә белән. — Ничек оят түгел сиңа! Син нәрсә, мин шулай сине ташлап китеп барыр дисеңмени? Ялгышасың, җанкисәгем. Мин бүген үк әбиең янына барып, үземнең сиңа өйләнергә теләвемне әйтәчәкмен. Минем хәзер сүз башлавым да сиңа шуны әйтү өчен генә иде бит.

Минем гаҗәпләнүемә каршы, бу хәбәрем Олесяны аз гына да гаҗәпләндермәде шикелле.

— Синең хатының булыргамы? — диде ул, моңсу төстә әкрен генә башын чайкап. — Юк, Ваня җаным, бу һич мөмкин түгел!

— Ни өчен, Олеся? Ни өчен мөмкин түгел?

— Юк, юк... Бу турыда уйларга да көлке — моны син үзең дә бик яхшы беләсең. Йә, нинди хатын була алыйм ди инде мин сиңа? Син — барин, акыллы, гыйлемле кеше, ә мин кем? Шыр надан бер кыз, кая ничек аяк басарга икәнен дә белмим. Минем аркада син оятыңнан гына да җир тишегенә керердәй булачаксың...

— Юк сүз сөйлисең, Олеся! — дидем мин, каршы килеп. — Бер ярты елдан син үзеңне үзең танымаслык

булачаксың бит. Үзеңдә күпме табигый сәләт, күпме акыл яшеренеп ятканын син әле аңламыйсың гына. Без синең белән бергәләп бик күп яхшы китаплар укырбыз, бик күп акыллы, әйбәт кешеләр белән очрашырбыз, без синең белән, Олеся, дөньяны бөтен киңлегендә күрербез әле... Без картлык көнебезгә кадәр, үлгәнчегә кадәр, менә шулай кулга-кул тотынышып бергә атлап барырбыз, һәм миңа беркайчан да синең өчен оялырга туры килмәс, киресенчә, мин гомерем буе синең белән горурланып, сиңа шөкер кылып яшәрмен!..

Бу ялкынлы, дәртле сүзләрем өчен Олеся каты итеп кулымны кысты, әмма үз фикереннән кире чигенергә теләмәде.

— Эш анда гынамыни? — диде ул. — Бәлки, син белмисеңдер әле?.. Моңарчы әйткәнем юк иде бугай... Мин бит әтисез бала... Никахсыз туганмын.

— Шуннан ни булган, Олеся... Аңа минем әз генә дә исем китми. Син минем өчен ата-анамнан да, дөньяның үзеннән дә кадерлерәк кеше, шулай булгач синең атаңның кем булуында минем ни эшем бар? Юк, болар барысы да бик вак нәрсәләр, нигезсез сылтаулар!..

Олеся оялчан бер иркәләнү белән әкрен генә минем иңбашыма сыенды.

— Акыллым... Бу турыда бөтенләй сүз башламаска иде сиңа... Син яшь, ирекле кеше... Ничек инде мин гомер-гомергә синең кул-аягыңны бәйләп куйыйм ди... Әгәр син соңра бүтән кешене яратсаң ничек? Ул чакта бит син мине бөтенләй күрәлми башлаячаксың, мин сиңа кияүгә чыгарга ризалык биргән көнне-сәгатьне гомерең буе каһәрләп яшәячәксең. Юк, ачуланма, жаным! — дип, ялварулы тавыш белән өстәде ул, минем йөземдә ризасызлык шәүләсе куера баруын күреп. — Сине һич тә рәнҗетәсем килми. Мин бары синең бәхетең турында гына уйлыйм бит. Аннары син әби барын да онытма. Йә, үзең уйлап кара, аны ташлап китү килешер идеме?

— Соң... әбигә дә бездә урын табылыр. (Дөресен генә әйткәндә, әби мәсьәләсе минем шактый кәефемне кыра иде.) Бездә торырга теләмәсә, һәрбер шәһәрдә әнә картлар өчен махсус химая йортлары бар... шунда урнашыр. Анда аларны карап-ашатып торалар.

— Юк, юк, син нәрсә! Урманнан ул беркая китмәячәк. Кешеләргә күренергә курка ул.

— Алайса син үзең әмәлен тап инде, Олеся, ничек яхшы, шулай эшлә. Сиңа икенең берсен — мине яисә

әбине сайларга туры килəчәк. Тик шуны исеңдә тот: синнән башка минем тормышым тормыш булмаячак.

— Күз нурым минем! — диде Олеся, тирән бер хис белән. — Шушы сүзләреңә өчен генә дә зур рәхмәт сиңа... Күңелемне җылыттың син минем... Шулай булса да мин сиңа кияүгә чыкмаячакмын... Куып җибәрмәсәң, болай гына ияреп китүем мөмкин, ə кияүгә чыгу — юк... Тик син, зинһар, бераз сабыр ит, ашыктырма мине. Уйларга бер-ике көн вакыт бир, мин бөтенесен һəр яклап үлчəп-чамалап карарга тиеш... Əби белән дə сөйләшергə кирəк.

— Карале, Олеся, — дидем мин, башыма яңа бер уй килеп. — Бəлкем, син тагын теге нидəн... чиркəүдəн шүрлисеңдер?

Ихтимал, миңа сүзне мондый сорау белəн башларга кирəк булмагандыр. Көн саен диярлек мин Олеся белəн бəхəс алып бара идем, аның үз нəселлəрен каһəрлəнгəн нəсел һəм сихри көчкə ия булган нəсел дип йөрүенең ялгыш икəнлеген исбатларга тырыша идем. Асылда, һəрбер рус интеллигентының табигатендə теге яки бу дəрəжəдə тəнкыйтьчелек хасияте бар. Бу хасият безнең каныбызга сеңгəн, ул бездə соңгы берничə ун ел эчендəге рус эдəбиятының көчле йогынтысы нəтиҗəсендə барлыкка килгəн. Кем белə? — əгəр Олеся бөтен күңеле белəн дингə ышанган булса, кырыс диндарлык күрсəтеп, чиркəүдəге гыйбадəтлəргə йөрсə, — ул вакытта, ихтимал, мин нəкъ менə аның шул диндарлыгыннан көләр идем (ләкин җиңелчə генə көләр идем, чөнки мин үзем һəрвакыт дингə ышанып яшəдем) һəм аңарда бар нəрсəгə тəнкыйть карашы үстерергə тырышкан булыр идем. Ләкин ул үзенең серле кара көчләр белəн аралашуына ихлас күңеленнән һəм ныклы рəвештə ышана, алланы читкə кага һəм аның турында хəтта телгə алып сөйləргə дə курка иде.

Мин, никадəр генə тырышсам да, Олесяның бу хорафатлы ышанычын какшата алмадым. Минем барлык гаклый дəлилләрем, ара-тирə шактый тупас, усал яңгыраган барлык шаяру сүзләрем аның шушы сер томаны белəн өртелгəн хəвефле тəкъдиренə булган ныклы ышанычы алдында коры куыктай шартлап ярыла торды.

Мин соравымны кабатладым:

— Син чиркəүгə барудан куркасың, шулаймы, Олеся?

Ул сүзсез генə башын түбəн иде.

— Үзеңне аллаһы тəгалə кичермəс дип уйлыйсың, əйеме? — дип дəвам иттем мин, тагын да дəртлəнебрəк. —

Синең өчен аның мәрхәмәте җитмәс дип шикләнәсеңме? Миллионлаган фәрештә өстеннән хакимлеге була торып, адәмнәрне коткару өчен күктән җиргә иңгән һәм шул юлда хурлыклы үлем кабул иткән; түбәнлеккә төшкән азгын хатынның гөнаһын кичергән һәм җан кыючы юлбасарга көне-сәгате белән ожмах вәгъдә иткән илаһи затның синең өчен мәрхәмәте җитмәс дисеңме?

Боларны Олесяга беренче сөйләвем түгел иде инде, әмма бу юлы ул мине хәтта тыңларга да теләмәде. Өлгер бер хәрәкәт белән башыннан яулыгын йолкып алды да, йомарлап, минем битемә ыргытты. Уен-тарткалаш башланды. Мин Олесяның чәченнән чәчәген суырып алмакчы булдым. Тарткалаша торгач, ул җиргә егылды һәм, шаркылдап көлә-көлә, үзе артыннан мине дә өстерәде. Шул ук вакытта ул еш-еш сулыш ала һәм бераз гына ачыла төшкән дымлы нәфис иреннәре белән һаман саен миңа таба үрелә иде...

Без бик соң, төн урталарында гына аерылыштык. Саубуллашып, кайтыр юлга борылгач, һәм инде шактый җир киткәч, мин кинәт үз артымда Олесяның кычкырып дәшкән тавышын ишеттем:

— Ванечка! Туктале... Әйтәсе сүзем бар!

Мин, туктап, кире борылдым да Олесяга таба киттем. Ул үзе дә ашыга-ашыга минем янга йөгереп килде. Яңа айның вак тешле, нәзек көмеш урагы күкнең түрендә үк балкый иде инде. Аның тонык яктысында мин Олесяның керфек очларыннан тәгәрәп төшәргә торган эре яшь бөртекләрен күрдем.

— Олеся, ни булды тагын? — дип сорадым мин, шомлана калып.

Олеся мине кулларымнан тотып алды да алмаштилмәш үбәргә кереште.

— Сөеклем... әйбәтем, мәрхәмәтлем! — ди иде ул калтыраган тавышы белән. — Мин хәзер генә уйланып бардым: син бит мине бик яратасың, әйеме?! Беләсеңме нәрсә, минем дә сиңа нинди дә булса берәр яхшылык эшлисем килә.

— Олеся... бәгърем, матурым, тынычлан...

— Юк, син миңа шуны әйт, — диде Олеся, сүзен дәвам итеп: — әгәр мин чиркәүгә барсам, бу сиңа ошар идеме? Тик алдашма, дөресен әйт.

Мин уйга калдым. Кинәт минем күңелдә хорафатлы бер шик кузгалып куйды: Олесяның чиркәүгә баруы берәр хәвефле хәл китереп чыгармасмы соң?

— Ник дәшмисең? Йә, тизрәк әйт: чиркәүгә баруым сине шатландырыр идеме, әллә бу синең өчен барыберме?

— Ничек дип әйтергә икән сиңа? — дидем мин икеләнебрәк. — Ихтимал, мин моңа шатланган булыр идем. Моңарчы да әйткәнем бар иде бит: ир кешенең дингә ышанмавы, аңа шикләнеп, хәтта көлеп каравы мөмкин. Әмма хатын-кыз... хатын-кыз дингә бернинди икеләнүсез, бөтен җаны-тәне белән бирелгән булырга тиеш. Аның шулай ихлас күңелдән ышанып аллага сыенуы миндә һәрвакыт соклану тудыра, бу ышануда ниндидер гүзәллек, хатын-кызга гына хас бер нәфислек бар шикелле.

Мин тынып калдым. Олеся да, башы белән минем күкрәгемә сыенган хәлдә, шактый вакыт дәшми торды.

— Ник әле син бу турыда сорыйсың? — дидем мин, кызыксынып.

Олеся кинәт бөтен гәүдәсе белән сискәнеп куйды.

— Болай гына... Телемә килде дә сорадым... Син аңа артык игътибар итмә. Ярый, хуш, сөеклем. Иртәгә дә кил, ярыймы?

Ул караңгылык эченә кереп югалды. Мин, аның ераклаша барган аяк тавышына колак салып, әле бик озак шул караңгылыкка күзләремне текәп тордым. Кинәт коточкыч бер сизенү мине тетрәндереп җибәрде. Миндә инде: Олесяны куып җитәргә дә, ялварыпмы яисә таләп итепме, аны чиркәүгә бармаска күндерергә кирәк, дигән тыелгысыз бер теләк тә туган иде. Әмма мин үз-үземне тыеп калдым һәм хәтта, — әле дә исемдә, — сукмактан олы юлга чыгып барышлый үземә үзем кычкырып әйтеп тә куйдым:

— Карале, Ванечка иптәшкәем, син үзең дә хорафат сөреме белән агулана башладың бугай, — дидем.

Йа хода! Нигә мин шул чакта, күңелемнең томанлы сизенүенә буйсынып, Олесяны куып җитмәдем икән?! Йөрәк үзенең серле, яшерен сизенүләрендә беркайчан да ялгышмый бит — моңа минем хәзер иманым камил!..

XII

Икенче көнне изге Троица бәйрәме иде. Өстәвенә, бу бәйрәм быел изге Тимофей көненә туры килә икән. Ә халык рнваятьләренә караганда, ачлык буласы елны изге Тимофей көнендә күк йөзендә төрле шомлы галәмәтләр күренүчән, имеш. Дин эшләре мәсьәләсендә Переброд авылы төбәктәге Волчье дигән авылга беркетелгән иде, ягъни ул, үзендә чиркәү булса да, махсус

поп тота алмый, һәм попның кирәге чыккан сирәк-мирәк очракларда,— әйтик, ураза шикелле зур бәйрәмнәрдә,— ул Перебродка шул ук Волчье авылыннан килеп йөри иде.

Бу көнне миңа кайбер вак-төяк эшләр белән якындагы шәһәрчеккә барып кайтырга кирәк иде. Шуңа күрә мин көн эсселәнмәс борын, иртәнге сәгать сигезләрдә үк, атка атланып юлга чыгып киттем. Ат дигәннән, юл йөрү өчен мин үземә күптән инде алты-җиде яшьлек бер айгыр сатып алган идем. Элекке хуҗасы — өяз землемеры — аны кече яшьтән бик карап, тәрбияләп үстергән булган, күрәсең, — чөнки минем бу айгырым, чыгышы белән урындагы карсак нәселле атлар токымыннан булса да, төскә-кыяфәткә шактый сылу, чибәр күренә иде. Таранчик кушаматлы иде ул. Коеп куйгандай төз, нечкә, нык аяклы, куе озын маңгай ялы астыннан шик һәм ачу белән карап торган елтыр күзле, кысып йомылган иренле бу атны мин тиз арада яратып өлгердем. Төсе аның сирәк очрый торган сәер бер төс — тоташ соры, бары сырты өстеннән генә, койрыктан ялга җиткәнче, тәңкә-тәңкә ак һәм күгелҗем таплар сибелгән иде.

Миңа атка атланып бөтен авыл аша узарга туры килде. Чиркәү белән кабак арасындагы зур яшел мәйдан буеннан-буена олаулар белән шыгрым тулган иде. Волоша, Зульня, Печаловка кебек тирә-юнь авыллардан бала-чагаларын, хатыннарын төяп кунакка килгән крестьян олаулары иде болар. Вакыт иртә булуга һәм аракы эчү катгый тыелуга карамастан, крестьяннар арасында инде исерекләр дә күренгәли башлаган иде (төннәрен һәм бәйрәм вакытларында аракы белән монда, яшерен рәвештә, элегрәк заманда кабак тоткан Сруль атлы бер кеше сату итә иде).

Җилсез, бөркү бер иртә иде бу. Һавада, көйрәгәндәй, рәшә тирбәлә, һәм көн төшлеккә таба бик нык эсселәнер шикелле тоела иде. Кызган һәм көмеш тузаны йөгертелгәндәй аксылланып торган күк йөзендә ичмасам бер генә болыт әсәре дә күренми иде.

Авылда башкарасы эшләремне башкаргач, мин мөсафирханәдә пешекче яһүд әзерләгән чуртан фаршын аннан-моннан капкалап, болганчык судай тәмсез сыра белән сусынымны бастым да кайтыр юлга чыктым. Ләкин, тимерче алачыгы яныннан узып барышлый, Таранчигымның алгы аягындагы бер дагасы какшаган булуын исемә төшереп, туктап калдым һәм берочтан

тимерчелеккә кереп атымны дагалатып чыгыйм дидем. Бу эш тагын сәгать ярым вакытымны алды. Переброднын басу капкасына кайтып җиткәндә инде вакыт кичке дүрт белән биш арасы иде.

Авыл мәйданы исерек тавышлардан шаулап-гөрләп тора иде. Кабак йортының койма буен һәм баскыч башын аракыга чират торучы халык сырып алган; һәммәсе дә кычкыра, берсен берсе төртә; Переброд крестьяннары арба-олаулар күләгәсендә, чирәмдә, чит авылдан килгән кунаклар белән сыйланышып утыралар. Кая карама анда артка ташланган башлар һәм югары күтәрелгән аракы шешәләре күренә. Арада ичмасам бер генә аек кеше дә юк. Гомуми исерешү шул дәрәҗәгә барып җиткән ки, мужиклар инде былагайлана, үзара мактаныша башлаганнар. Андый чакта мужик үзен башкалардан күбрәк эчкән итеп күрсәтергә тырыша бит ул. Йәргәндә ничектер чамадан тыш изрәп, ава-түнә, аякларын авыр атлап, кулларын болгап йөри. Сөйләшкән чакта, әйтик, әңгәмәдәшенә баш иеп җавап бирәсе урында бөтен гәүдәсе белән сыгылып түбән чүгә, аннары кинәт, тигезлеген югалтып, чайкала-чайкала артка чигеп куя. Шунда ук, кырт-кырт печән ашап торган ваемсыз атлар тирәсендә, бала-чага чыр-чу килә иде. Икенче бер урында үзе дә аягы өстендә көчкә басып торган бер хатын, елый-елый сүгенеп, киреләнеп маташкан дөм исерек ирен җиңеннән тоткан да өенә таба өстери... Койма күләгәсендә, иңне иңгә терәп, бер егермеләп ир һәм хатын-кыз түгәрәкләнеп утырган. Түгәрәк уртасында сукыр лирник, үзе уйнаган лирасының гел бертөрле зыңгылдап жуылдавына кушылып, калтыравык, тыңкыш, нечкә тавышы белән «думка» әйтә. Җырның халык гөжелдәвен басып яңгыраган таныш сүзләре ерактан үк минем колагыма килеп керде:

Ой зійшла зоря, тай вечирняя,
Над Почаевым стала.
Ой вышло війско турецкое,
Як та черная хмара... [1]

Шуннан соң «думка»да төрекләрнең, Почаев монастырен турыдан-туры сугышып ала алмагач, хәйләгә керешүләре турында сөйләнә. Алар, үзләреннән монахларга бүләк дигән булып, монастырьга эченә дары ту-

[1] Кичке офык, кичке офык
Почаево өстендә.
Төрек гаскәрләре чыкты
Караңгы болыт кебек.

тырылган зур бер шәм җибәрәләр. Бу шәм шулкадәр зур була ки, аны тарттырып кайту өчен унике пар үгез җигәргә туры килә. Монахлар, билгеле, бу бүләккә бик шатланалар һәм шәмне Почаев монастырендагы Мәрьям ана иконасы каршына куеп, кабызмакчы булалар. Ләкин алла, имеш, төрекләрнең бу явыз ниятләрен эшкә ашырырга ирек бирми.

А приснилося старшему чтецу:
Той свичи не брати,
Вывезти еи в чистое поле,
Сокирами зрубати...

Вывезли еи в чистое поле,
Сталы еи рубати,
Кули и патроны на вси стороны
Сталы — геть! — роскидати... [1]

Көн түзеп булгысыз эссе иде. Һава әйтерсең лә берьюлы бөтен сасы исләрне үзенә сеңдергән: аракы, суган исе, сөрсегән тире толыплар исе, каты бакун тәмәкесе һәм тирләгән шакшы тән исе, бөтенесе бергә буталып, күңелне болгандыра. Башын чайкый-чайкый атлаган атымны дулап китүдән көч-хәл белән тыеп, кешеләр арасыннан сак кына узып барганда, миңа тагын бер нәрсә ачык күренде: һәр яктан мине ачулы, тәкәллефсез, кызыксынучан күз карашлары озатып кала иде. Бу юлы беркем дә миңа баш киемен салып сәлам бирмәде, әмма, мин күренгәч, мәйдандагы шау-шу ничектер басыла төшкәндәй булды. Кинәт шул вакыт кайдадыр кешеләр төркеме уртасында хырылдап кычкырган исерек бер тавыш ишетелде. Ул нәрсә әйткәндер — анысын мин аңламый калдым, ләкин аның сүзләреннән барысы да ничектер тыелып кына көлешеп алдылар. Икенче бер хатын-кыз тавышы исә, куркынып, әлеге кушбугазны тиргәргә кереште:

— Әкренрәк син, тиле... Нәрсә акырасың! Ишетүе бар...

— Ишетсә соң! — диде мужик, тагын да ярсый төшеп. — Нәчәлнигем түгел, нәрсә миңа аннан куркырга? Әнә урмандагы үзенең...

. . . . . .

[1] Өлкән догачы төш күрде:
Шәмне кабул кылмаска,
Кырга чыгарырга
Һәм балта белән чабарга...
Кырга да чыгардылар,
Балта белән чаптылар —
Янчыкларны, патроннарны
Төрле якка аттылар...

Коточкыч әшәке, җирәнгеч сүзләр тезмәсе кайтаваздай һавада эленеп калды һәм шуның артыннан ук котырынып көлгән тавышлар гөрелтесе яңгырады. Мин атымны киредә бордым да үз-үземне белешмәстәй шашынулы бер ярсу белән камчы сабын чытырдатып кыстым. Шул чакны кинәт минем башымнан сыкрандыргыч, сәер, моңсу бер уй чагылып узды: «Тукта әле, кайчандыр, бик күп, бик күп еллар моннан элек, минем тормышымда бер мәртәбә шушындый ук хәл булган иде түгелме соң? ...Кояш та хәзерге кебек шулай аяусыз кыздыра иде... Зур мәйданда шундый ук котырынган халык диңгезе шаулый иде... Ул чакта да мин шулай, шашынулы ярсу хисенә бирелеп, кире борылган идем... Ләкин кайда булды соң шундый хәл? Кайчан булды?..» Мин камчым белән атыма селтәндем дә җан-фәрманга өйгә таба чаптырып киттем.

Кухнядан әкрен генә атлап каршы алырга чыккан Ярмола атны тезгененнән тотты да шактый дорфа тавыш белән әйтеп куйды:

— Паныч, сезне анда, бүлмәгездә, Мариновка экономиясеннән килгән приказчик көтеп утыра.

Ярмоланың миңа тагын да нәрсәдер өстәп әйтергә — минем өчен бик мөһим һәм күңелсез хәбәр әйтергә теләге бар иде шикелле. Хәтта аның йөзендә усал, мыскыллы бер елмаю да чагылып китте шикелле. Мин, шуны сизеп, ишек төбендә тоткарланып калдым һәм таләпчән күз карашымны Ярмолага таба юнәлттем. Ләкин ул, миңа борылып та карамастан, муенын сузып, сакланып кына атлаган Таранчикны тезгененнән өстери-өстери, үз юлы белән китеп барды.

Бүлмәмдә мин, чыннан да, күрше алпавыт утарындагы конторчы Никита Назарыч Мищенканы күрдем. Ул өстенә зур-зур җирән шакмаклы күк пиджак, аксыл-зәңгәр төстәге тар балаклы чалбар кигән, муенына җете кызыл галстук бәйләгән, ә майлаган елтыр чәчләрен, баш уртасыннан юл калдырып, як-якка тарап куйган иде. Аның үзеннән Иран сирене — хушбуй исе аңкып тора иде.

Мине күргәч, ул урындыгыннан сикереп торды да, башын иеп кенә дә түгел, ничектер бөтен гәүдәсе белән урталай бөгелеп һәм аксыл теш казналары күренерлек дәрәҗәдә авызын ерып, минем алда бөтерелергә кереште.

— Сезне күрү шәрәфенә ирешүемә бик шатмын, — диде ул мөлаем-ялагай, төче тавыш белән. — Мин инде

сезне монда көндезге гыйбадәт вакытыннан бирле көтеп утырам. Күптән күрешкән юк иде, бик сагындырылды. Нигә бер дә килеп чыкмыйсыз безнең якларга? Безнең Степань кызлары инде сездән көлә үк башладылар.

Кинәт ул, нәрсәнедер исенә төшереп, ахры, үз-үзен белештермичә шаркылдап көләргә тотынды.

— Ух, белсәгез иде, шундый кызык бер тамаша булды бүген! — диде ул, ихахайлап. — Ха-ха-ха-ха... Көлә-көлә шартлыйм дип торам, валлаһи менә!..

Мин, кәңәлем төбеннән ачу кабарына башлавын тоеп, конторщиктан дорфа гына:

— Нәрсә булды? Нинди кызык тамаша ул? — дип сорадым.

Никита Назарыч, сүз аралаш шаркылдап көлә-көлә, сөйләвен дәвам итте:

— Көндезге гыйбадәттән соң булды бу хәл... Переброд кызлары... Юк, валлаһи, көләсе килә, түзәр хәл юк... Переброд кызлары монда, чиркәү мәйданында, бер сихерче хатынны тоттылар... Хәер, сихерче дип, аны мондагы надан мужик халкы гына шулай атый инде... Шул, тотып алдылар да тетмәсен теттеләр тегенең!.. Үзен дегеткә буямакчы да булганнар иде дә, шайтан нәмәрсә, ничектер ычкынып, качып өлгерде.

Коточкыч бер уй мине тетрәндереп җибәрде. Үз-үземне белештермәс бер хәлдә, мин конторщикның янына атылдым һәм каты итеп аның иңбашыннан эләктереп алдым.

— Сез ни сөйлисез! — дип кычкырып җибәрдем мин, шашынкы тавыш белән. — Алла хакы өчен туктагыз әле шул көлүегездән! Нинди сихерче хатын турында сөйлисез сез?

Конторщик кинәт кенә көлүдән туктады һәм, күзләрен шарландырып, куркынган төстә миңа текәлде.

— Мин... мин... аны рәтләп белмим дә, чын менә, — дип куйды ул тотлыга-тотлыга. — Ниндидер Самуйлиха диме шунда... Мануйлиха диме... әллә... Әйе, әйе... Ниндидер Мануйлиха кызы ди бугай... Мужиклар сөйләнеп маташты, шул үзе булырга тиеш, шулай хәтеремдә калган.

Мин конторчыны күргән-ишеткәннәре турында тәртибе белән яңабаштан сөйләп чыгарга мәҗбүр иттем. Ләкин аның сөйләве бик буталчык, бәйләнешсез иде, һәм мин үземнең сабырсыз сорауларым, ачулы эндәшләрем белән аны минут саен диярлек сүзеннән бүлә-бүлә тыңладым. Шулай да аның сөйләгәннәреннән миңа

бик аз нәрсә аңлашылды, бары тик ике ай чамасы вакыт узып, шушы көнне чиркәүдә гыйбадәттә булган һәм бөтенесен үз күзе белән күргән икенче бер кеше — казна урманы лесничиенең хатыны сөйләгәч кенә мин әлеге җирәнгеч вакыйганы бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бастыра алдым.

Минем шикләнүем дөрескә чыкты. Олеся чыннан да, үзенең куркуын җиңеп, чиркәүгә барган булган икән; гәрчә ул чиркәүгә гыйбадәт башлангач кына килеп, эчкә үк кермичә, алгы якта гына басып торса да, чиркәүдәге крестьяннарның һәммәсе дә аны шундук күреп алалар. Хатын-кызлар, артларына борылып карый-карый, гыйбадәт беткәнче үзара нәрсәдер пышылдашып сөйләшәләр.

Ләкин Олеся, сабырын җыеп, гыйбадәт беткәнче үз урынында басып тора. Бәлкем, ул үзенә таба төбәлгән усал күз карашларының чын мәгънәсен аңлап та җиткермәгәндер яисә, горурлыгын саклап, аларга юри әһәмият бирергә теләмәгәндер. Һәрхәлдә, чиркәүдән чыгуга ук, ихата янында аны бер төркем хатын-кызлар чолгап ала; бу төркем минут саен зурайганнан-зурая һәм Олесяны уртага кысрыклый бара. Баштарак хатыннар түгәрәк эчендә куркынган кыяфәт белән як-якка карангалап басып торган ярдәмчесез кызны сүзсез генә күзәтәләр. Аннары әкренләп-әкренләп аның исеменә төрле яктан мыскыллау сүзләре, сүгенгән һәм шаркылдап көлгән тавышлар яудыра башлыйлар. Ахырда бу аерым кычкыру-сүгенү тавышлары барысы бергә буталып, мәйданда беркем бернәрсә аңламастай гомуми чыр-чу, гауга куба. Тавыш көчәйгән саен, хатын-кызлар да котырына баралар. Олеся берничә мәртәбә бу коточкыч тере балдакны ерып чыкмакчы да булып карый, әмма аны яңадан уртага төртеп кертәләр. Шул вакыт кинәт кайндыр арттагы рәтләрдән берәү карчыкларча карылдык-эче тавыш белән: «Дегеткә буярга кирәк үзен, дегеткә буярга, сөйрәлчекне!» — дип кычкырып җибәрә. (Билгеле булганча, Малороссиядә кызлы йортның капкасын гына дегеткә буяу да бу кыз өчен коточкыч һәм җуелмас бер хурлык булып санала.) Шул ук минутта диярлек котырынган төркем өстендә дегет савыты белән пумала калкып чыга һәм, кулдан кулган тапшырылып, уртага җибәрелә.

Тәмам изаланып беткән һәм коты алынган Олеся, ниһаять, үз-үзен белештермичә, ярсып-җенләнеп газаплаучылары өстенә ташлана һәм юлында очраган беренче хатынны төртеп җиргә капландыра. Шундук ыгы-зыгы башлана, хатыннар, чырылдый-чырылдый, берсе өстенә берсе өелешәләр. Олеся шул тере йомгак эчен-

нән ниндидер могҗиза белән шуышып чыга да җанфәрманга юл буйлап йөгерә. Яулыгы югалган, өс киеме ертылып-теткәләнеп беткән; урыны-урыны белән шәрә тәне дә күренеп-күренеп китә. Һәммәсе дә аны, артыннан әшәке сүзләр кычкыра-кычкыра, көлеп-шаулашып һәм ташлар атып озатып калалар. Куа чыгучылар бик аз була, алары да тиздән артта калалар... Бер кырыкилле адым җир чабып үткәч, Олеся, туктап, шашынып гөжләгән халык төркеменә таба үзенең агарынган һәм тырналып беткән канлы йөзе белән борылып баса да, мәйдандагы һәр кешегә ишетелерлек итеп, бар көченә кычкырып җибәрә:

— Ярар, шулай да булсын!.. Тик сез моны искә төшерерсез әле! Моның өчен сезнең елый-елый күзегездән яшегез кибәр әле!

Соңыннан лесничий хатынының сөйләвенә караганда, Олеся бу сүзләрне шундый шашкын бер нәфрәт, шундый шомлы кискенлек белән әйтә ки, җыелган халык берничә секундка — бары берничә секундка гына — сихерләнгәндәй тынып кала, әмма шундук айнып, һаваны дер селкетерлек тавыш белән яңадан сүгенү сүзләре кычкыра.

Кабатлап әйтәм: бу вакыйга бөтен вагы-төягенәчә миңа шактый вакыт узгач кына мәгълүм булды. Хәзер исә Мищенканың сөйләвен ахыргача тыңлап бетерергә минем сабырым да, көчем дә җитмәде. Ярмола, шәт, атның иярен салдырып өлгермәгәндер әле дип уйлап, мин урынымнан кузгалдым һәм, гаҗәпкә калган конторчыга бер сүз дә әйтеп тормастан, ишегалдына йөгереп чыктым. Чыннан да, Ярмола койма буенда әле һаман Таранчикны атлатып йөри иде. Мин атны тиз генә авызлыклап, ияр бавын кысыбрак бәйләдем дә, янә исерекләр төркеменә юлыкмас өчен кабак йортын читләтеп үтеп, туп-туры урманга таба чаптым.

XIII

Ат өстендә җан-фәрманга чабып барганда кичергән уй-хисләремне мин үзем дә аңлатып бирә алмыйм. Вакыт-вакыт мин үземнең кая һәм нинди максат белән баруымны да онытып җибәрә идем; күңелдә бердәнбер уй, томанлы бер уй бөтерелә; ниндидер коточкыч, мәгънәсез һәм төзәтеп булгысыз хәл килеп чыккан. Каты бизгәк белән авырып ятучы кешенең шомлы, борчулы саташуы кебек бер халәт иде бу. Шул ук вакыт-

та — гаҗәеп хәл! — минем колакта, тояклар тавышына кушылып, сукыр лирникның тыңкыш, калтыравык тавыш белән көйләгән җыры яңгырап торды:

Ой вышло війско турецкое,
Як та черная хмара...

Мануйлиха өенә туп-туры илтүче тар сукмакка килеп җиткәч, мин иярдән төштем дә Таранчикны тезгененнән җитәкләдем. Атның ияр тиеп торган урыннары манма су булган, ияр киезе тирәли ап-ак күбек куыклары калкып чыккан иде. Көндезге эссе һавадан һәм җан-фәрманга ат өстендә чабып килүдән минем үземнең дә башым чатнап шаулый, әйтерсең лә аның эченә ниндидер галәмәт зур насос белән туктаусыз кан кудырып торалар иде.

Мин Таранчикны читәнгә бәйләп куйдым да өйгә кердем. Башта миңа Олеся өйдә юк шикелле тоелды, һәм бу уйдан минем бөтен күкрәгем, авызым ничектер салкынаеп киткәндәй булды. Ләкин бераздан мин аны үз караватында күрдем. Ул, башын мендәрләр белән каплап, стенага таба борылып яткан иде. Ишек ачылып-ябылган тавышка ул хәтта игътибар да итмәде шикелле.

Олесяның ятагы янында идәндә утырган Мануйлиха әби, мине күреп, авырлык белән генә аягүрә торып басты да янап кулын болгарга кереште.

— Шаулама! Нәрсә дөбер-шатыр йөрисең, мәлгунь, — дип пышылдады ул, минем янга якын ук килеп. Аннары нурсыз, салкын күзләре белән минем йөземә туп-туры текәлде дә, ачулы ысылдап: — Йә, нәрсә? Ирештеңме инде теләгеңә? — дип сорады.

— Карале, әби, — дидем мин, шактый кырыс тавыш белән, — хәзер шелтә белдерү яисә эрепләшү вакыты түгел. Син шуны әйт: ни булды Олесяга?

— Тсс... шаулама! Олеся һушсыз ята — менә нәрсә булды Олесяга... Әгәр син сорамаган җиргә тыкшынып, юк-бар сүзләреңә белән кызның башын катырмаган булсаң, ах-вах итәрлек берни дә булмаган булыр иде.... Мин дә инде, шыр җүләр, шуңа юл куеп тордым бит... Бәла-каза чыгасын күңелем күптән сизенгән иде, югыйсә... Беренче тапкыр безнең өйгә бәреп кергән көнендә үк сизенгән идем аны. Нәрсә? Аны чиркәүгә барырга котыртучы син түгелме әллә? — дип, йөзен ачулы чалшайтып, кинәт минем өскә ябырылды карчык. — Йә әйт: син түгелме аны котыртучы, башың беткере барчук?

Койрык болгап, алдашып маташма, оятсыз! Нигә кирәк булды сиңа оны чиркәүгә барырга котырту?

— Аны мин котыртмадым, әби... Чын менә, ант итеп әйтәм. Ул үзе барырга теләде.

— Ах, ниләр генә эшлим, ниләр генә эшлим! — дип үрсәләнде Мануйлиха әби. Кайтып керүенә имәнеп киттем: йөзендә кан эсәре юк, күлмәге ертылып, тетелеп беткән... Үзе яланбаш... Үзе ничек булганын сөйли, үзе шундук көлә дә, җылый да... Бума зохмәте эләккән диярсең... Урынга яткач та бик озак җылады... Аннары, ни күрим, йокымсырап киткән шикелле булды... Мин инде, карт җүләр, бөтенләй тынычланып калган идем: йоклы белән узар да китәр, мәйтәм, тазарып уяныр. Аннары, ни күрим, кулы түбән салынып төшкән бәбекәчемнең: ойый күрмәсең, күтәреп куярга кирәк, мәйтәм... Шулай дип кулын тотсам, куркып киттем: кулы кап-кайнар... Бизгәк башланган, димәк... Бер сәгать буе саташты, кызганыч тавыш белән гел нәрсәләрдер бытыр-бытыр сөйләнеп ятты... Менә әле генә туктады. Нишләттең син аны? Йә, әйт, нишләттең? — диде тагын карчык, ачыргаланып.

Кинәт аның коңгырт-сары йөзе, елаганда гына була торган ямьсез бер җыерылу белән җыерылып, коточкыч җирәнгеч төс алды: авызы як-якка ерылып, иреннәренең почмак кырыйлары түбән салынып төште, бөтен бит мускуллары кабарып, дерелдәп куйды, кашлары, маңгаена тирән буразналар сызып, югары күтәрелде, күзләреннән исә борчак-борчак эре күз яшьләре тәгәрәде. Ул учлары белән башын кысып тотты да, терсәкләрен өстәл кырыена куеп, аллы-артлы тирбәнергә һәм тавышын артык күтәрмичә генә көйли-көйли улап еларга кереште:

— Кызыкаем мине-е-м! Бердәнбере-е-м, җанкисәге-е-ем!.. Ох, ба-а-ашымны хәсрәткә салдың, дөньядан бизде-е-е-ердең!

Мин, шактый тупас тавыш белән:

— Улама әле ачу китереп! — дип, аны елавыннан бүлдердем. — Уятасың ич!

Мануйлиха әби, улавыннан туктаса да, әүвәлгечә куркыныч, җирәнгеч кыяфәттә чайкалуын дәвам итте. Шул ук вакытта аның эре күз яшьләре бертуктаусыз өстәл өстенә тамып торды... Шул рәвешчә бер ун минут чамасы вакыт үткәндер. Мин үзем дә, тәрәзә пыяласына бәрелә-бәрелә безелдәгән чебеннең бертөрле еламсык,

өзек-өзек тавышына колак салып, Мануйлиха әби янында моңаеп утыра бирдем.

Шул чакны Олеся яткан карават ягыннан зәгыйфь, хәлсез тавыш ишетелде:

— Әби!... Әби, кем бар бездә?

Мануйлиха аякларын чалыш-чолыш атлап Олеся янына ашыкты һәм шундук тагын улый башлады:

— Ох, кызым, бер-дән-бе-ре-ем! Ох, карт башымны хәсрәткә са-а-ал-дың ла, дөньяның ямен бе-тер-де-ең лә...

Олеся ялварулы, газаплы һәм кызганыч бер тавыш белән әбисенә:

— Ах, әби, зинһар, тукта, елама!.. Кем бар бездә? — диде.

Гадәттә, таза, сәламәт кеше үзен авыру янында һәрвакыт гаепле итеп, дорфа итеп сизә торган була. Мин дә шулай, үземне гаять уңайсыз һәм гаепле итеп сизгән бер хәлдә, аяк очларына гына басып Олесяның караваты янына килдем.

— Бу мин, Олеся, — дидем мин, тавышымны мөмкин кадәр йомшаграк итәргә тырышып. — Әле генә авылдан килеп төштем... Иртәнге якта шәһәргә барган идем... Хәлең ничек соң, Олеся?

Йөзе белән стенага карап яткан Олеся, башын мендәрдән күтәрмичә генә, артка каерылып, шәрә кулын сузды һәм, һавада нәрсәнедер капшарга теләгәндәй, бер хәрәкәт ясады. Мин, бу хәрәкәтнең мәгънәсенә төшенеп, Олесяның кайнар кулын шундук учларыма алдым. Кызның нәфис, йомшак, ап-ак кулында — берсе беләзектән өстәрәк, икенчесе терсәктән югарырак — ике зур күгелҗем тап күренә иде.

— Сөеклем, — диде Олеся һәм тотлыга-тотлыга сүзен дәвам итте: — Беләсеңме нәрсә... минем... минем сиңа бик карыйсым килә... тик менә карый гына алмыйм... Мине бит бөтенләй... чуарлап бетерделәр... Исеңдәме... син... минем йөземне бик ошата торган идең?.. Ошата идең бит, шулаймы, кадерлем?.. Мин үзем дә моңа бик куана торган идем... Ә хәзер синең... минем йөзгә карыйсың да килмәс инде... Йә, менә... мин... инде теләмим дә...

— Олеся, кичер мине, — дидем мин, аның колагына иелеп.

Олеся уттай янган кайнар учы белән озаклап минем кулымны кысып торды.

— Син ни сөйлисең!.. Нәрсә өчен, сөеклем?.. Алай уйларга ничек оят түгел сиңа?.. Монда синең нинди гаебең булсын? Барысына да мин үзем гаепле... Чынлап да, ник бардым инде мин анда, юләр? Юк, күз нурым, син үзеңне гаеплэп маташма инде...

— Олеся, сиңа зур бер үтенечем бар... Тик башта аны үтим дип сүз бир...

— Үтәрмен, сөеклем, үтәрмен... Нәрсә телисең, бөтенесен үтәрмен... вәгъдә бирәм...

— Алайса, мин синең яныңа доктор чакыртам. Рәхсәт итәсеңме?.. Үтенеп сорыйм! Теләмисең икән, доктор кушканнарның берсен дә эшләмәссең, тик аны чакыртыйк кына. Минем хакка риза бул, Олеся.

— Ох, менә бит син нинди хәйләкәр, җаныем... Тозакка оста эләктердең мине! Шулай да син инде миңа вәгъдәмне үтәмәскә рөхсәт ит. Чынлап торып авырган очракта да, хәтта үлем түшәгендә яткanda да, мин докторны барыбер үз яныма кертмәс идем. Хәзер мин авыраймымыни? Хәзерге хәлем минем куркудан гына булды, кичкә мин тереләчәкмен. Терелеп җитмәсәм, әбием миңа энҗе чәчәгеннән төнәтмә ясап бирер яисә кура җиләге кайнатып эчерер. Докторның монда ни хаҗәте бар? Минем өчен иң әйбәт доктор — син. Менә килдең генә, миңа шундук җиңел булып китте... Ах, бер нәрсә генә яман: сыңар күзем белән генә булса да сине күрәсем килә, тик менә борылып карый алмыйм, куркам...

Мин, иркәләү катыш бер көч кулланып, Олесяның башын мендәрдән аердым. Аның йөзе бизгәк тоткандагы кебек янып тора, коңгырт-кара күзләре ничектер сәер рәвештә очкынланып җемелди, ә кипкән иреннәре берөзлексез дерелди иде. Маңгаен, муенын һәм яңакларын аның кызыл төстәге озын, нечкә җәрәхәт эзләре сызгалаган иде.

— Син минем битемә карама, йәме... Үтенеп сорыйм... Мин бик ямьсез, шыксыз инде хәзер, — диде ул пышылдап һәм учы белән минем күзләремне капламакчы булды.

Аны кызганудан минем күңелем тулды, күзләрем яшьләнде. Мин аның юрган өстендә хәрәкәтсез яткан кулына иреннәремне тидердем дә озаклап үбә башладым. Элегрәк Олесяны кулыннан үбә башласам, ул, ничектер ятсынып, кулын тиз генә тартып ала торган иде. Хәзер исә ул бернинди каршылык күрсәтмәде, бәлки, икенче, буш кулын чыгарып, минем чәчемнән иркәләп сыйпарга кереште.

— Син бөтенеһесен дә беләсеңме? — дип сорады ул әкрен генә.

Мин сүзсез генә баш актым. Дөрес, Никита Назарыч сөйләгәннәрдән мин әллә ни күп нәрсә аңламаган идем. Мин хәзер бары Олеся, иртәнге вакыйганы искә төшереп борчылмагае дип кенә курыктым. Ләкин Олесяны анда ничек мыскыллауларын күз алдына китергәч, минем күңелдә кинәт ярсулы бер дулкын күтәрелде һәм мин тураеп бастым да, йодрыкларымны кысып:

— Их, әгәр анда мин булган булсам! — дип кычкырып жибәрдем. — Мин аларны... мин аларны...

— Ярар, булды, булды... тынычлан, сөеклем, — диде Олеся сабыр гына, мине сүземнән бүлеп.

Инде күптән бугазыма тыгылып, күзләремне әчеттереп торган күз яшьләрен артык тыеп торырлык чамам калмаган иде. Мин Олесяның иңбашына йөзем белән капландым да, бөтен тәнем белән калтыранган хәлдә, тавышсыз гына үкси-үкси еларга керештем.

— Син жылыйсың түгелме? Жылыйсың түгелме? — диде Олеся, бер үк вакытта кызгану да, гажәпләнү дә сизелгән иркә тавыш белән. — Кадерлем минем... Йә, булды, житәр сиңа... Үзеңне алай газаплама, жаным... Синең минем янда булуың үзе бер рәхәт бит... Бергә чакта безгә һич тә жыларга кирәкми. Соңыннан, аерылган вакытта, артык авыр булмасын дисәң, ичмасам шушы актыккы көннәребезне генә булса да күңелле итеп уздырыйк.

Мин тирән бер гажәпсенү белән башымны югары күтәрдем. Томанлы бер сизенү минем йөрәкне кинәт акрын-акрын гына кысылырга мәжбүр итте.

— Актыккы көннәребез дисеңме? Ни өчен актыккы көннәребез, Олеся? Нигә безгә аерылышырга?

Олеся, күзләрен йомып, беравык дәшмичә ятты. Аннары катгый, кискен тавыш белән сүзен башлады:

— Әйе, Ванечка, безгә синең белән хушлашырга кирәк булыр. Мин чак кына сәламәтләнгәч тә, без әби белән моннан китәргә тиешбез. Безгә монда калырга ярамый.

— Син берәр нәрсәдән куркасыңмы?

— Юк, кадерлем, кирәк икән — мин бернәрсәдән дә курыкмыйм. Тик кешеләрне гөнаһлы эшкә котырту нигә кирәк? Син эле, бәлки, белми торгансыңдыр... Мин бит анда... Перебродта... алардан үч алачакмын дип янадым... ачудан, оятымнан шулай янадым. Хәзер берәр яман хәл килеп чыкса, бөтенесен безнең өскә ябачак-

лар. Терлек кырыла башласа да, берәрсенең өе янса да — барысы өчен без гаепле булачакбыз. Әбием, — дип өстәде Олеся, тавышын күтәрә төшеп, — мин дөрес әйтәммә?

Мануйлиха карчык, оныгы янына килеп, учын колагына куйды да:

— Нәрсә әйтәсең, кызым? Ихлас менә, ишетми калдым! — диде.

— Мин әйтәм, Переброда бераз төрле бәла-каза була калса, барысы өчен дә безне гаепләячәкләр, дим.

— Ох, дөрес әйтәсең, кызым, бик дөрес әйтәсең: барысы өчен дә без бичараларны гаепле итәчәкләр... Алар безгә монда якты көн күрсәтмәячәкләр, теңкәбезгә тиеп бетәчәкләр, синең белән мине тереләй кабергә тыгачаклар... Ә теге вакытта соң, мине авылдан сөргән чакта ничек булды?.. Шундый ук хәл булды ич. Мин дә шулай... ачуыма чыдый алмыйча... шундагы бер ахмагына каргыш сүзләре әйтеп ташлаган идем, ә аның, үч иткәндәй, кинәт кенә баласы вафат булды. Төш юраудамы, күрәзәлектәме — берәрсәдә бернинди гаебем булмаса да, шул вакытта бит мине чак-чак кына үтереп ташламадылар, каһәр суккырылары... Ташлар белән бәрә-бәрә кудылар... Үзем йөгерәм, алардан качам, ә күңелемдә бер генә уй — ничек тә сине саклап калу... Син ул чакта бәләкәй идең әле... Мин әйтәм, тисә миңа тисен, ниго гөнаһсыз баланы рәнжетергә?.. Бер сүз белән әйткәндә — һәммәсе дә кыргый, явыз, әшәке кешеләр!

— Сез кая күчеп китмәкче буласыз соң? Сезнең бер җирдә дә кардәш-танышларыгыз юк бит... Аның соңында яңа җирдә урнашыр өчен акча да кирәк, — дидем мин.

— Ничек тә бер җае чыгар әле, — дип куйды Олеся гамьсез генә. — Акчасы да табылыр, әбиемнең бераз җыйган акчасы булырга тиеш.

Әби кеше канәгатьсез бер кыяфәт белән караватяныннан читкәрәк китте.

— Акча дип әйтерлеге булса иде! — диде ул, зарланып. — Ниндидер тиеннәр, күз яшенә чыланган ятимә тиеннәре...

Шул чакны мин күңелем төбеннән әшәке, ачы бер хис — Олесяга карата үпкә, рәнҗү хисе күтәрелә башлавын тойдым.

— Олеся... Мин соң нишләрмен? Син минем турыда хәтта уйларга да теләмисең, ахры!

Олеся, ятагыннан күтәрелә төшеп, минем башымны куллары белән кочаклап тотты да, эбисеннән дә ятсынмыйча, берничә мәртәбә маңгаемнан һәм битемнән үбеп алды.

— Мин күбрәк синең турыда уйлыйм да инде, кадерлем... Тик... шунысы бар... тәкъдир безгә бергә булырга кушмый... менә бит хикмәт нәрсәдә!.. Хәтерендәме, бервакыт мин сиңа карта ачкан идем? Ул чакта карта әйткәннәрнең бөтенесе дә дөрескә чыкты. Димәк, тәкъдир безнең бергә бәхетле тормыш коруыбызны теләми... Әгәр тәкъдир каршы килмәсә, мин нәрсәдән дә булса куркып торыр идеммени?

— Олеся, син тагын бөтен нәрсәне шул кара тәкъдиргә сылтап калдырмакчы буласың, әйеме? — дидем мин, сабырлыгымны җуя башлап. — Шуны бел: мин бернинди тәкъдиргә дә ышанырга теләмим... Һәм беркайчан ышанмаячакмын да!..

— Ох, юк, юк... зинһар, алай сөйләнмә, — диде Олеся, тәмам шүрли калып.— Мин бит үзем өчен түгел, синең өчен борчылам, сөеклем. Юк, син инде бу турыда сөйләп тә торма.

Юкка гына мин Олесяны бу карашларыннан ваз кичтерергә тырышып карадым, юкка гына аңа бернинди көнчелек, явыз язмышлар, бернинди әшәке, тупас кешеләр комачау итә алмый торган бәхетле, ваемсыз киләчәк турында сөйләнеп маташтым. Олеся бары минем кулларымны үпте дә башын гына чайкады.

— Юк... юк... юк... мин беләм, мин күрәм, — дип кабатлый бирде ул, үз сүзендә нык торып. — Киләчәктә безне кайгы-хәсрәттән башка бүтән бернәрсә дә көтми... бернәрсә дә... бернәрсә дә...

Мин, аның бу хорафатлы кирелегеннән тәмам гажиз булып, аптырап, аңардан:

— Һич югы, китәсе көнеңне миңа хәбәр итәрсеңме соң? — дип сораргамәҗбүр булдым.

Олеся уйга калды. Кинәт аның иреннәре буйлап сизелер-сизелмәс елмаю йөгереп узды.

— Җавап урынына мин сиңа кечкенә генә бер әкият сөйлим, ярыймы... Шулай бервакытны бүре урманнан узып бара икән. Юлында моңа бер куян очраган. Бүре әйтә икән куянга: «Әй, озынколак, мин сине хәзер ашыйм бит!» — ди икән. Куян ялынырга тотынган, ди: «Әй, мәрхәмәтле бүре, син мине кызган инде, минем әле дөньяда торасым килә, өемдә кечкенә балаларым бар», — ди икән. Бүре һаман риза түгел, ди. Шуннан

куян тагын әйткән: «Син миңа өч кенә көн гомер бир, аннары ашарсың; ичмасам үлемем үкенечле булмас», — дигән ди. Биргән бүре моңа бу өч көнне, куянны ашамый, ди, бары саклап кына тора, ди. Шулай бер көн узган, ике көн узган, меңә өченче көне дә үтеп бара икән. «Ярый, озынколак, сиңа озерләнә башласаң да вакыттыр, хәзер мин сине ашарга тотынам», — дигән бүре. Шул чакны куяным кайнар күз яшьләрен агызып җылый башлаган, ди. Үзе әйтә икән: «Ах, ни өчен син, бүре, миңа бу өч көнне бүләк иттең? Күргәч тә мине ашаган булсаң, миңа җиңелрәк булыр иде бит. Юкса, бу өч көндә минем яшәвем яшәү булмады, мин бары газап кына чиктем!» — дигән ди. Шул, сөйкемле, куян бик дөрес әйткән бит. Син ничек уйлыйсың?

Мин дәшмәдем. Алда үземнең ялгызлык көткәнлеген мин ачык сиздем, һәм шул уйдан минем бөтен күңелемне тирән бер сагыш биләп алды. Ул арада Олеся кинәт башын калкытты да ятагына торып утырды. Йөзе аның шундук җитдиләнеп китте.

— Ваня, тыңлале, — диде ул салмак-сабыр тавыш белән. — Әйт әле, минем белән бергә булган чакларыңда син үзеңне бәхетле тойдыңмы? Сиңа рәхәт идеме?

— Олеся! Нигә син сорап торасың!

— Сабыр ит... Мине шулай якынлап белгәнең өчен үкенмәдеңме син? Минем белән кавышкан чакларыңда башка берәр хатын-кыз турында уйламадыңмы?

— Андый уй башыма да килмәде! Бергә чакта гына түгел, синнән аерылып ялгызым калгач та мин бары синең турыда гына уйладым, Олеся.

— Син мине көнләмәдеңме? Миңа ачуың килгән чакларың булмадымы? Сиңа минем янда күңелсез түгел идеме?

— Беркайчан да, Олеся! Беркайчан да!

Олеся ике кулын минем иңемә куйды да чиксез мәхәббәт балкып торган кара күзләрен күзләремә текәде. Аннары, минем күз карашымда киләчәкнең ачык билгеләрен күргәндәй, үз-үзенә ышанган нык тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Алайса шуны белеп тор, кадерлем: беркайчан да син мине әшәке яки явыз кеше итеп күз алдыңа китермәссең. Аерылышкач, беренче вакытларда сиңа бик авыр булыр; һай, бик авыр булыр... Син җыларсың, үз-үзеңә урын тапмый аптырап йөрерсең.. Аннары барысы да узар, барысы да эзсез җуелып бетәр. Ул чакта инде син мине кайгылы-хәсрәтле уйлар кичереп түгел,

болай гына, җиңел шатлык-куаныч белән генә хәтереңә төшерә торган булырсың.

Олеся янә башын мендәргә куйды һәм, хәлсез тавыш белән миңа пышылдап:

— Инде син кит, сөеклем... — диде. — Бар, өеңә кайтып кит, җаныем... Минем бераз гына хәлем бетте шикелле. Тукта... үп мине... син әбидән шикләнмә... ул бер сүз дә әйтмәс. Әйтмәссең бит, әбием?

— Ни диясең инде сезгә, хушлашасы булгач, әйдә, әйбәтләп хушлашыгыз инде, — диде Мануйлиха карчык, ачулы мыгырдап. — Минем алда нәрсә яшереп торырга?.. Күптән беләм...

— Мине менә моннан үп, аннары моннан... аннан соң менә моннан, — дип тезеп китте Олеся, үзенең күзләренә, яңагына һәм авызына бармагы белән күрсәтеп.

— Олеся, син минем белән шундый итеп саубуллашасың, әйтерсең лә без инде бүтән очрашмаска тиеш! — дидем мин, каушый калып.

— Белмим, белмим, сөеклем. Бернигә дип тә әйтә алмыйм. Ярый, бар инде, аллага тапшырдык. Юк, тукта әле... тагын бераз гына сабыр ит... Колагыңа әйтәсе сүзем бар, иел әле... Беләсеңме, минем өчен нәрсә кызганыч, — дип пышылдады ул, иреннәре белән минем яңагыма орынып. — Синнән балам булмавы кызганыч миңа. Ах, балага узган булсам, ничек шатланган булыр идем мин!

Мануйлиха әби мине болдырга хәтле озата чыкты. Көнбатышка авыша башлаган кояш әле һаман нурларын мул сипсә дә, күк йөзенең ярты лаш өлешен инде чит-читләре агарып, бөдрәләнеп торган галәмәт зур кара болыт каплап алган иде. Яктылык белән бу убылып килгән куе караңгылыкның шулай бергә кушылуында миңа ниндидер шомлы бер нәрсә бар шикелле тоелды. Мануйлиха әби, учын маңгае өстенә зонтик сыман куеп, югарыга күтәрелеп карады да мәгънәле генә итеп башын чайкады.

— Переброд өстендә бүген давыл буласы, — диде ул, ышанычлы тавыш белән. — Хәтта боз яву ихтималы да бар.

XIV

Мин Перебродка җитеп килә идем инде. Шул вакыт кинәт кенә көчле җил исеп куйды да, бөтерелеп-уйнаклап, юл өстеннән тузан өермәләре тузгытып алып китте. Шуның артыннан ук җир өстенә давыллы яңгырның беренче эре һәм сирәк тамчылары шыбырдап төште.

Мануйлиха карчык ялгышмаган иде. Түзеп булгысыз эссе, бөркү һавада көннең-көн буе әкренләп көч туплый барган табигать стихиясе, берьюлы шартлап ярылгандай, гадәттән тыш бер дәһшәт белән Переброд өстенә ябырылды. Күк йөзендә берөзлексез диярлек яшен чыбыркылары уйнаклады, дөбер-шатыр күк күкрәгән тавышлардан тәрәзә пыялалары зыңгылдап калтыранды. Кичке сигезләр тирәсендә давыл беркадәр басылып торгандай булды, әмма берничә минуттан соң ук ул тагы да дәһшәтлерәк көч белән янә дулый башлады. Көтмәгәндә генә, иске йортның түбә, стеналарына ниндидер авыр әйбер шыбырдап коелгандай, колак тондыргыч каты тавышлар ишетелде. Мин ашыгып тәрәзә янына ташландым. Кузы чикләвегедәй эре-эре боз кисәкләре томырылып җиргә төшәләр дә, шак-шок бәрелә-бәрелә, яңадан югарыга сикерәләр иде. Мин йорт каршындагы тут агачына күз салдым: ул, коточкыч боз яңгыры астында барлык яфракларыннан мәхрүм калып, хәзер шәп-шәрә килеш утыра иде.

Тәрәзә турысында, аста, караңгылык эченнән чакчак кына төсмерләнеп, башына нәрсәдер бөркәнгән бер күләгә күренде. Тәрәзә капкачларын ябарга дип кухнядан атылып чыккан Ярмола иде бу. Ләкин ул капкачларны ябарга өлгерә алмый калды: зур гына бер боз кисәге тәрәзә өлгесенә килеп бәрелде дә, чылтырап ватылган пыяла кисәкләре, зыңгырдый-зыңгырдый, бүлмә идәненә коелып төште.

Мин бөтен тәнемә ниндидер арыганлык таралуын сиздем һәм, чишенеп тә тормастан, караватыма барып яттым. Чишенмәвемнең үзенә күрә бер сәбәбе дә бар иде. Мин үземнең күңелне биләп торган сагыш-борчулардан йокыга китә алмыйча төне буе урын өстендә аунап чыгармын дип курыктым һәм, шул йокысызлык чире артык җәфалый башласа, ара-тирә урынымнан торып, үз-үземне ардыру өчен бүлмә эчендә әрле-бирле йөргәләрмен дип уйладым. Ләкин бу юлы миңа ниндидер сәер хәл булды: бер ике-өч минутка гына дип йомган күзләремне янәдән ачып җибәргәндә инде, төн узып, тәрәзә капкачларындагы ярыклар аша иртәнге кояш, һавада очкан исәпсез-хисапсыз тузан бөртекләрен алтынга манчып, бүлмә эченә үзенең якты кыйгач нурларын сузган иде.

Караватым янында исә Ярмола басып тора. Аның кырыс йөзе борчулы, күзләре сабырсыз карый: күрәсең, мин уянганны ул инде күптәннән бирле көтә иде.

Ул гадәттәгечә саңгырау, борчулы тавышы белән әйтеп куйды:

— Паныч, сезгә моннан китәргә кирәк...

Мин караваттан аякларымны салындырып торып утырдым да Ярмолага таба гаҗәпләнеп карадым:

— Китәргә? Кая китәргә? Ни өчен китәргә? Әллә акылыңнан яздыңмы?

— Бер дә язмадым, — диде Ярмола дорфа гына. — Кичәгенәк яуган боздан нәрсә булганын белмисездер шул? Ярты авылның иген басуы аяк белән таптагандай тап-такыр булып калган әнә. Кәкре Максим җире дә, Кәҗәнеке дә, Чаяныкы да, Прокопчук белән Гордый Олефирларныкы да... Тәки зәхмәтен йоктырмый калмады бит шул убырлы карчык... башы астына килгере!

Минем күңелемнән шундук кичәге көн вакыйгалары, Олесяның чиркәү мәйданында хатыннарга янап кычкырган каргыш сүзләре һәм соңыннан миңа әйткән шик-шөбһәләре бер-бер артлы чагылып узды.

— Инде әнә бөтен авыл дулый, — диде Ярмола, сүзен дәвам итеп. — Иртәдән барысы да эчеп исерешкәннәр дә акырыпмы-акыралар. Сезнең хакта да яман сүзләр сөйләнәләр, паныч... Монда андый дулаулар, беләсезме, ни белән бетә?.. Убырларга янап кычкырулары бер хәл, анысы кирәкле, гадел эш, э менә сезгә, паныч, тиз генә моннан таю ягын карарга кирәк булыр...

Шулай итеп, Олесяның бөтен шик-шөбһәләре дөрескә чыкты. Хәзер үк, кичекмәстән, Олеся янына барып, аның үзенә һәм Мануйлиха әбигә нинди куркыныч янавы турында кисәтеп өлгерергә кирәк иде. Ярты сәгать тә үтмәгәндер, мин битемне-күземне аннан-моннан гына чылатып, өстемә киендем дә, атка атланып, Шайтан Чокырына илтә торган юл буйлап чаптырып китеп бардым.

Субайлар өстендәге тавык кетәгедәй кечкенә йортка якынлашкан сен, миндәге томанлы сагыш, борчылу хисе дә артканнан-арта барды. Менә-менә хәзер, анда килеп керү белән үк, минем өскә ниндидер бөтенләй көтелмәгән яңа бер авыр хәсрәт убылып төшәр төсле тоелды миңа.

Комлы сөзәклектәге борылмалы тар сукмакны мин бер тын алуда диярлек йөгереп уздым. Йортның тәрәзәләре дә, ишеге дә шыр ачык иде. Шундук минем йөрәгем туктагандай кысылып куйды.

— Йа ходай! Нәрсә булган соң монда? — дидем мин, пышылдап, һәм өйалдына кердем.

Өйдә беркем дә юк иде. Анда ашыгыч ташланган өйләрдә генә була торган пычрак, күңелсез бер тәртип-

сезлек хөкем сөрә: идәндә төрле чүп-чар, чүпрәк-чапрак өемнәре ята, почмакта исә караватның шәрә агачлары гына торып калган иде...

Күңелем тулып, йөрәгем авыртып кысылган бер хәлдә, мин инде өйдән чыгып китәргә дә теләгән идем, шул чакны кинәт минем игътибарымны тәрәзә рамының почмагында эленеп торган ялтыравык бер әйбер җәлеп итте. Кызыл төстәге сәйләп бөртекләреннән җепкә тезеп ясалган һәм Полесьеда «мәрҗән» исеме белән йөртелгән арзанлы муенса иде бу. Мин күрсен өчен, Олеся аны юри тәрәзә рамына элеп куйган иде булса кирәк. Ни генә булмасын, миңа Олесядан, аның эчкерсез саф, назлы мәхәббәтеннән бердәнбер истәлек булып шул муенса гына калды.

1898





АТЫШУ

Бу повестемны эчкерсез дуслык һәм тирән ихтирам хисләре белән Максим Горькийга багышлыйм.

Автор.

I

Алтынчы ротаның гарнизон хезмәте уставын практик өйрәнү буенча кичке занятиеләре ахырга якынлашып, кече офицерлар инде сабырсыз кыяфәттә сәгатьләренә караштыра башлаганнар иде. Солдатлар бөтен плац өстенә сибелгән: шоссе буенда үскән тупыллар төбендә, гимнастик машиналар янында, рота мәктәбе каршында, прицел станоклары кырында — һәр җирдә шулар күзгә ташлана. Фараз ителгән хәрби постлар иде болар. Берәүләре, янәсе, дары базы янына куелган пост, икенчеләре — байракны саклый, өченчеләре караул йортын яки акча ящигын саклап тора. Алар арасында, сакчыларны алыштырып, разводящийлар тыз-быз йөри; унтер-офицерлар постларны тикшерәләр һәм солдатларның уставны белү дәрәҗәләрен сыныйлар. Моның өчен алар, сакчы янына килеп, хәйлә белән аның винтовкасын алырга яки үзен урынынан кузгатырга, йә булмаса, вакытлыча саклап торырга дигән булып, кулына берәр әйбер,— күп очракта үзләренең кигән

фуражкаларын,— биреп калдырырга тырышалар. Хәрби уенның четерекле хикмәтләрен яхшы белгән тәҗрибәле солдат мондый чакта югалып калмый, үтә бер кырыс тавыш белән җавап бирә: «Читкә кит! Патша хәзрәтләренең үзеннән боерык булмыйча, мылтыкны чит кеше кулына бирергә минем бернинди тулы хакым юк!» — ди. Әмма яшьрәк солдатлар буталалар. Алар теге яки бу шаяртуны устав таләпләреннән аера белмиләр әле, шуңа күрә чамадан тыш беркатлы җавап кайтаралар.

— Хлебников! Чулак шайтан! — дип җикеренде бәләкәй, түгәрәк гәүдәле һәм елгыр хәрәкәтле ефрейтор Шаповаленко; аның тавышында начальникларча шелтә катыш бер сыкрану ишетелә иде.— Тинтәк, мин сине күпме өйрәттем, ә! Кем боерыгын үтәдең син хәзер? Арестованныйныкынмы? Их, башың беткере!.. Җавап бир: постка нәрсә өчен куелган син?

Өченче взводта шактый җитди чуалыш булып алды. Русча рәтләп ни аңлый, ни сөйләшә белмәгән яшь солдат Мөхәммәтҗанов, татар егете, гамәлдәге һәм фараздагы начальникларының мәкерле сорауларыннан тәмам башы катып, кинәт шундый дулап китте, кулындагы винтовкасын күтәрде дә теләсә нинди үгеткә һәм боерыкка:

— З-заколу! [1] — дигән бердәнбер янау сүзе белән җавап кайтара башлады.

— Туктале, җүләр... син нәрсә дулыйсың... — дип үгетләргә тырыша иде аны унтер-офицер Бобылев.— Йә, мин кем сиңа? Үзеңнең үк караул начальнигың лабаса, шулай булгач, димәк...

Ә Мөхәммәтҗановның үз туксаны туксан: куркынган һәм ачулы-тәвәккәл кыяфәттә, каң баскан күзләрен алартып, янына якынлашкан һәр кешене штыгы белән каршылый һәм бертуктаусыз:

— Заколу! — дип кабатлый иде.

Аны солдатлар чолгап алган; алар өчен бер мәзәк бу, шулай ук җиләткеч хәрби уеннардан туктап, бераз ял итеп алу өчен бер сылтау да.

Бу эшне тикшерергә, нигаять, рота командиры капитан Слива үзе юнәлде. Ул, ялкау-салмак адымнар белән, бөкрәя биреп, плацның икенче башына таба өстерәлгән арада, кече офицерлар бер җиргәрәк җыелдылар да, тәмәке көйрәтеп, гәп сатарга керештеләр.

Алар өчәү иде: берсе — утыз-утыз өч яшьләрдәге такыр башлы, мыеклы, шат күңелле, тел бистәсе, җырчы

[1] *Заколу (заколю)!* — Чәнчим!

һәм исерекбаш поручик Веткин; икенчесе — хезмәт итә башлавына әле икенче ел гына киткән подпоручик Ромашов; өченчесе — малай сымак кыяфәтле, бик терчә, зифа гәүдәле, шаян-ахмак күз карашлы, калын-хәйләсез иренһәреннән беркайчан елмаю төшми торган һәм офицерлар турындагы иске анекдотлар белән гүя бөтен эче тулган подпрапорщик Лбов.

— Дуңгызлык бу! — диде Веткин, мельхиор сәгатенә күз төшереп, һәм аның капкачын ачу белән шапылдатып ябып куйды.— Ротаны бу кадәр тинтерәтеп тоту ни пычагымадыр? Эфиоп!

— Ә сез шуны аның үзенә аңлатып бирсәгез иде, Павел Павлыч, — дип киңәш итте Лбов, хәйләле бер елмаю белән.

— Аңлатырсың, бар. Бик теләсәгез, әнә үзегез аңлатыгыз. Иң ачу китергәне — нәрсә? Юкны бушка аудару — менә шул. Смотр җитәрәк алар гел шулай дөнья куптаралар. Һәм һәрвакыт кирәгеннән артык кыланалар. Җәфалапмы-җәфалыйлар солдатны, төмам тинтерәтеп бетерәләр, ә смотр җиткәч солдат, мескен, бүкән кебек тик басып тора. Шәт, ишеткәнегез бардыр, ике рота командиры үзара бәхәсләшкән ди бит: янәсе, кайсысының солдаты әпәйне күбрәк ашый ала? Зурдан бәхәсләшкәннәр — йөз сум акчадан диме. Шул, иң бирән корсак ике солдатны сайлап алганнар болар. Берсе җиде кадак ипине ничек кирәк алай ашап бетергән дә чалкан ауган — бүтән һич тамагына үтми икән тегенең. Ротный фельдфебельгә ябырыла: «Син нәрсә мине хурлыкка калдырдың, фәлән дә төгән?» — ди. Ә фельдфебель аптыраган кыяфәттә күзләрен мелт-мелт китерә: «Һич аңлый алмыйм, вашескородие, нишләгәндер ул, — ди. — Иртә белән репетиция ясадык — бер утыруда сигез кадак ипине ашап бетергән иде...» — ди. Безнекеләр дә нәкъ шулай... Бер файдасызга репетитрилләр, репетитрилләр дә, смотрда тишек калошка утыралар.

— Кичәгенәк... — дип сүз башлады Лбов һәм үзе үк шаркылдап көлеп җибәрде.— Кичәгенәк, роталарда занятиеләр бөтенләй тукталгач, фатирга кайтып барам; ну, сәгать сигезләр тирәсе булгандыр, инде тәмам күз бәйләнгән чак. Кинәт ишетәм: унберенче ротада сигналлар өйрәнеп яталар. Хор белән. «Наве-ди, до гру-ди, по-пади!» [1] Поручик Андрусевичтан сорыйм: «Нигә, мәйтәм, сездә кара төнгәчә уен уйныйлар?» — дим. Ә ул әйтә: «Эт кебек, без шулай айга өрәбез»,— ди.

---

[1] Күтәр, күкрәккә кадәр, төшер.

— Һәммәсе туйдырып бетерде, Кука! — диде Веткин һәм авызын зур ачып иснәп алды.— Карагыз әле, ат өстендә кем бара ул? Бек димме?

— Шул үзе. Бек-Агамалов,— дип раслады Лбов.— Кара, ничек матур утыра.

— Әйе, бик матур,— дип килеште Ромашов та.— Минемчә, кавалеристың бер якта торсын. О-о-о! Биеп үк китте. Кылана.

Шосседан атка атланган бер офицер бара иде. Өстендә адъютантлар мундиры, кулларына ак перчатка кигән. Сөлектәй озын, эре гәүдәле алтынсу-соргылт төстәге аты, инглизчә кыска итеп киселгән койрыгын еш-еш болгап һәм мөштек сыман текә, нәфис муеныи боргалый-боргалый, түземсезләнеп атлый. Нечкә аяклары, биегән шикелле, тиз-тиз басалар.

— Павел Павлыч, аны чын чиркәс диләр, дөресме икән шул сүз? — дип сорады Ромашов Веткиннан.

— Минемчә, дөрестер. Кайчак әрмәшкәләр дә үзләрен чиркәс яки лезгин дип танытырга яраталар яратуын, әмма бу очракта Бек, гомумән, алдашмый шикелле. Әнә үзегез күрәсез, ат өстендә ничек матур утыра бит!

— Кая, чакырыйк әле үзен,— диде Лбов.

Ул ике учын авызына бүрәнкә сыман итеп куйды да рота командиры ишетмәслек тоныk-саңгырау тавыш белән җайдакка карап кычкырды:

— Поручик Агамалов! Бек!

Ат өстендә барган офицер, тезгенне тартып, бер секундка гына тукталды да, уңга борылып карады. Аннары, атны да шул якка таба борып һәм ияр өстеннән чак кына алга иелә төшеп, атны канау аша пружинадай сикереп чыгарга мәҗбүр итте һәм артык куаламыйча гына офицерлар торган җиргә чаптырып килде.

Уртачадан кечерәк буйлы, сөяк-сенердән генә торган чандыр гәүдәле, ифрат көчле бер кеше иде бу. Сөзәк маңгайлы, нәзек, бөкре борынлы, юка-кискен иренле матур йөзендә гайрәт уйный, шул ук вакытта аңарда шәрекъ кешеләренә генә хас аксыллык — кара-тут катыш бер тоныk төстә әле булса чалымлана иде.

— Нихәл, Бек,— диде Веткин.— Кем алдында шулай кукраеп йөрүең? Кызкайларга юлыктыңмы әллә?

Бек-Агамалов, ияр өстеннән җидегә бөгелеп, әмма әллә ни исе китмәгән бер кыяфәттә, офицерлар белән кул биреп күреште. Иреннәренә елмаю җәелде, һәм аның кысылып ябылган җете ак тешләреннән, гүя нур чагылып,

йөзенең бөтен аскы өлеше һәм нәзек шома мыек очлары берьюлы яктырып киткәндәй булды.

— Чибәр генә ике яһүдә күзгә чалынды чалынуын. Тик ни файда? Мица игътибар да итмәделәр.

— Беләбез без сезнең шашкада ничек уйнавыгызны! — диде Веткин, башын чайкап.

— Тыңлагыз әле, әфәнделәр,— дип сүз башлады Лбов һәм сөйлисе мәзәгеннән үзе үк янә көлеп җибәрде.— Беләсезме, генерал Дохтуров пехотадагы адъютантлар турында нәрсә әйткән? Бу сиңа кагыла, Бек. Дөньядагы иң тәвәккәл җайдаклар дигән ул аларны...

— Ялганлама, фендрик! — дип тешен ыржайтты Бек-Агамалов. Өзәңге тимере белән атының корсагына типте дә, подпрапорщикны таптатырга теләгәндәй бер кыяфәт алды.

— Валлаһи менә! Атлары ат түгел, ә ниндидер гитара, шкаплар — запаллы, җенле, кыек күзле, аксаклар ди икән. Әмер бирдеңме — ак-кара дип тормый имеш: теләсәң кая бара, бөтен карьерыңны айкый; коймаң ни дә аңа, чокырың ни! Урман, әрәмәлегең аша турыдан сыпырта! Тезгенне ташлый, өзәңгене ычкындыра, бүрекне — җилгә очырта! Менә нини башсыз җайдаклар!

— Нинди яңалыклар бар соң, Бек? — дип сорап куйды Веткин.

— Яңалык? Берни юк. Менә әлерәк кенә офицерлар җыенында полк командиры подполковник Лех өстенә килеп керде. Аңа шулкадәр җикеренде, тавышы, шәт, собор мәйданына ишетелгәндер. Ә Лех үз-үзен белешмәс дәрәҗәдә исерек, тел әйләндереп сүз әйтә алмый. Кулларын артка куеп баскан да тик чайкалып тора. Ә теге, Шульгович, җикерепме-җикеренә: «Полк командиры белән сөйләшкәндә кулыгызны арт саныгыздан алсагыз әдәплерәк булыр иде!» — ди. Шунда ук хезмәтчеләр дә бар иде.

— Каты эләккән икән! — диде Веткин, әллә шатлыктан, әллә көенечтән усал көлемсерәп.— Кичәгенәк дүртенче ротада да бик яман кычкырынган диләр аны. «Сез нәрсә минем алда устав белән акланып маташасыз? Сезнең өчен — мин үзем устав, лыгырдавыгызны бүтән ишетәсе булмыйм! Мин монда патша да, алла да!» — ди икән.

Лбов хәтеренә төшкән ниндидер уйдан тагы шаркылдап көлеп җибәрде.

— Әфәнделәр, N полкында бер адъютант белән булган кызык хәлне сөйлим әле...

— Лбов, зинһар туктап торсагызчы, — диде Веткин

җитди төстә. — Бүген сезнең мәзәк капчыгыгыз тишелгән ахрысы.

— Тагы бер яңалык,— диде Бек-Агамалов, сүзен дәвам иттереп. Атын күкрәге белән яңа Лбовка таба борды да, юрамалый, аның өстенә килә башлады. Ат туктаусыз башын чайкый һәм, пошкыра-пошкыра, як-якка күбекләр чәчрәтә иде.— Тагы бер яңалык. Командир барлык рота-ларда офицерларның карачкы чабу уены оештыруларын таләп итә икән. Тугызынчы ротадагыларның төмам котла-рын алган. Епифановны, кылычын кайратмаган дип, сак астына утырткан... Син нәрсә коелып төштең, фендрик! — дип кычкырды кинәт Бек-Агамалов подпрапорщикка.— Әй-дә, күнегә тор. Кайчан да бер үзең дә адъютант буласы бәндә бит. Табада кыздырылган чыпчык кебек, ат өстендә бөрешеп утырасы көннәрең алда әле!

— Саграк син, азиат!.. Бу үләксәңне читкәрәк ал,— дип, өстенә килгән атка кулларын болгый-болгый артка чигенде Лбов.— Син ишеттеңме икән әле, N полкында бер адъютант үзенә цирк аты сатып алган ди бит? Сатып алган да, шул атта смотрга чыккан, ди. Бер заман, нәкъ командующий турысына җиткәч, әлеге ат тотынган ди испанча адым белән биеп-кыландырып барырга! Менә болай: аякны әле югарыга, әле алмаш-тилмәш бер яктан икенче якка. Ахырдан бу иң алда барган рота уртасына бәреп кергән — и башланган, ди, шул чак ыгы-зыгы, кычкырыш-буталыш. Ә атның үз туксаны туксан — испанчалатып һаман атлый бирә, ди. Шул, Драгомиров учын бүрәнкә сы-ман — менә болай — кушырып кычкырган, ди: «Поручи-ик, шул ук әллүрең белән туп-туры гауптвахтага, егерме бер тәүлеккә, ма-арш!..» — дип боерган, ди.

— Әй, ташлачы юкны,— диде Веткин, йөзен чытып.— Карале, Бек, синең бу карачкы чабу турындагы хәбәреңбезнең өчен чыннан да көтелмәгән яңалык булды бит әле. Ниткән эш инде бу? Буш вакытлары бөтенләй калмасын диләр микәнни? Кичә безгә дә менә шушы гарип-горабаны китереп ташладылар.

Шулай дип, ул плац уртасына ымлап күрсәтте; анда юеш балчыктан кеше гәүдәсенә охшатып ясалган, әмма кул-аяклары булмаган бер сын утыртып куелган иде.

— Йә, ничек соң? Чабып карадыгызмы? — дип кызык-сынды Бек-Агамалов.— Ромашов, э сез?

— Юк әле.

— Кирәге бар иде! Шундый юк-бар белән вакыт әрәм итәргә! — дип мыгырданды Веткин.— Иртәнге тугыздан кичке алтыга хәтле шушында аяк өсте йөрисең, каян буш

вакыт табасың ди? Аракы эчеп, тамак ялгап алырга да чак кына өлгерәсең. Мин аларга малай түгел инде, аллага шөкер...

— Җүләр. Офицер кеше кылыч уйната белергә тиештерләбаса.

— Ә ни пычагыма? Сугышта кирәк булыр диюме? Хәзерге утлы корал сугышында сине йөз адымга да якын җибәрмәячәкләр. Нигә ди миңа синең ул кылычың? Мин атлы гаскәр түгел. Ә инде бик кирәге чыкса, мин мылтык, приклад белән дә эш итә алам: башына бер-икене тондырдыңмы — вәссәлам дигән сүз. Шулай хәерлерәк тә.

— Ярар, анысы сугыш кырында булсын, ә сугыш кырында булмаганда ничек? Тормышта төрле хәлләр булуы мөмкин бит. Әйтик, фетнәме, чуалышмы яки тагын берәр шундый нәрсәме килеп чыкты, ди...

— Чыкса соң, шуннан нәрсә? Монда кылычның ни катышы бар? Берәмләп, кылыч белән кеше башын кыеп йөрергә димәгәндер ич? Андый кара эш белән шөгыльләнгәнче: «Рота, ут ач!» — дип бер боерасың да — беттекитте...

Бек-Агамалов ризасыз төстә чыраен чытты.

— Әй, һаман җүләр сатасың, Павел Павлыч. Юк, син шаяртмыйча җавап бир. Сине, әйтик, берәр җирдә йөргәндә яки, мәсәлән, театрдамы, ресторандамы чагында нинди дә булса шпак мыскыл итте... ну, тагы да яманрагы — берәр штатский яңагыңа менеп төште, ди. Менә шул чакта нишләрсең?

Веткин, иңбашын җыерып, җирәнгән кебек иренен турсайтты.

— Н-ну! Беренчедән, миңа бернинди шпак кул күтәрмәячәк, чөнки андый чакта гадәттә кыйналудан курыккан кешене генә кыйныйлар. Ә икенчедән... ну, нишләр идемме? Револьвердан шалт берне маңгаена төзәп!

— Ә револьверың өйдә калган булса? — дип сорады Лбов.

— Ну, шайтан... ахыр чиктә, өйгә кайтып, алып килгән булыр идем... Менә сафсата. Ишеткәнсездер, шәт, шундый хәл булган ди ич: кафешантанда бер корнетны мыскыл иткәннәр. Шуннан ул, извозчик яллап, өеннән револьверын алып килгән дә ниндидер ике шалапайны теге дөньяга олактырган. Менә шул!..

Бек-Агамалов сабырсызланып башын чайкады.

— Беләм. Ишеткәнем бар. Әмма соңыннан суд аны хөкем итә, чөнки аның бу эшен алдан уйланылган явыз ният

дип таба. Нәрсәсе күңелле? Юк инде, кем дә булса мине мыскыл итә яки миңа суга икән, ул чакта мин...

Бек-Агамалов сүзен әйтеп бетермәде, әмма тезген тоткан кулын ачу белән шундый чытырдатып йодрыклады ки, кулы хәтта дерелдәп куйды.

Лбов кинәт, тыела алмыйча, яңа шаркылдап көләргә тотынды.

— Тагы! — диде Веткин, кырыс тавыш белән.

— Әфәнделәр... зинһар... Ха-ха-ха! N полкында шундый бер хәл була. Подпрапорщик Краузе Благородное собраниедә гауга куптарган икән. Шуннан буфетчы моның иңбашына килеп ябыша, погонын чак кына аерып төшерми. Шуннан Краузе нишли дисез: револьверын тартып чыгара да — шалт тегенең башына! Басып торган урынында ук! Ул да булмый, арага ниндидер адвокат кисәге килеп тыгыла — Краузе монысын да бах! Ну, калганнары шундук качып бетәләр, билгеле. Ә Краузе үзе тыныч кына лагерьга кайта, часть байрагы торган линейкага юнәлә. «Кем килә?» — дип сорый сакчы. «Мин, подпрапорщик Краузе,— ди бу,— байрак янына ятып үләргә телим!» — ди. Ята да револьвердан атып үзенең кулын чәрдәкли. Соңыннан суд аны аклаган, ди.

— Молодчина! — дип куйды Бек-Агамалов.

Шуннан соң алар, гадәттәгечә, яшь офицерлар арасында бик яратып сөйләнелә торган төрле үч алулар, баскан урында тиктомалдан атып үтерүләр турында һәм бу канлы җинаятьләрнең күп вакыт җәзасыз калулары турында гәп сатарга керештеләр. Ниндидер бер шәһәрчектә әле мыек та чыгып өлгермәгән яшь корнет ничек, имеш, «бәйрәм ясап йөрүче» яһүдләрне пыран-заран китергән, араларына бәреп кереп, аларны уңга-сулга кылычы белән чапкан. Киевтагы танцы залында пехотада хезмәт итүче бер подпоручик буфет янында терсәге белән кагылып киткәне өчен студент егетне ничек, янәсе, теге дөньяга озаткан. Икенче бер зур шәһәрдә — әллә Мәскәүдә, әллә Петербургта — бер офицер ресторанда утырганда штатскийлардан берәүне, юньле кеше хатын-кызга тиктомалдан бәйләнми дигәне өчен, «эттәй» атып үтергән.

Моңарчы әңгәмәгә катышмый тын гына басып торган Ромашов кинәт кыбырсынып, тамагын кырып куйды һәм уңайсызланудан кызарына-кызарына, һич кирәксезгә күзлеген төзәткәләп, сүзгә кушылды:

— Әфәнделәр, үз ягымнан мин менә нәрсә әйтергә телим. Буфетчыны, ярар, исәпкә алмыйк... анысы шулай да булсын... әйе... Тик штатскийларга килгәндә... ничек дип

әйтим икән?.. Әйе... Ну, әйтик, ул абруйлы кеше, дворянмы анда яки башкамы шундый кеше икән... нигә, ди, мин аңа, коралсыз кешегә, кылыч күтәреп ташланыйм? Мин бит аны әдәпле рәвештә дуэльгә чакыра алам. Ни дисәгез дә, культуралы кешеләр ич инде без...

— Әй, тузга язмаганны сөйлисез, Ромашов,— дип, аның сүзен бүлде Веткин. — Сез аны дуэльгә чакырырсыз, ә ул әйтер: «Юк... э-ээ... мин, дияр, беләсегез килсә, дуэльне гомумән танымыйм.— дияр.— Мин кан коюга каршы... Аның соңында, э-э... моның өчен мировой судья бар...» — дияр. Шуннан соң инде сезгә гомер буе җимерек танау белән йөрергә кала.

Бек-Агамалов гадәттәге ачык-көләч, елмаюы белән авызын ерды:

— Әһә, шулаймы? Минем белән килешәсең, димәк? Шуңа әйтәм дә мин сиңа, Веткин: кылыч чабарга өйрән. Бездә, Кавказда, бу эшкә һәммә кеше бала чактан ук керешә. Чыбык, бәрән түшкәсе, шарламас су чабып өйрәнәләр...

— Ә кеше чабып өйрәнмиләрме? — дип сүз кыстырды Лбов.

— Алай да өйрәнгәлиләр,— диде Бек-Агамалов, исе китмичә.— Ничек кенә әле! Бер сугуда кешене иңбашыннан ботына кадәр кыйгачлап ярып төшерәләр. Менә ичмасам көч! Юкса нәрсә пычранып маташырга!

— Ә син, Бек, шулай булдыра аласыңмы?

Бек-Агамалов үкенеч белән авыр сулап куйды.

— Юк, булдыра алмыйм... Яшь бәрәнне урталай чабып өзә алам алуын... хәтта бозау түшкәсен дә чабып караганым бар... әмма кешене урталай чабып өзәргә... юк, көч җитмәс кебек... Ә менә минем атай моны бик җиңел эшли торган иде...

Лбовның күзләрендә очкыннар ялтырап китте.

— Әфәнделәр, әйдәгез әле, без дә сынап карыйк,— диде ул ялварган тавыш белән.— Бек, җанкисәгем, зинһар, әйдәгез әле...

Офицерлар балчыктан әвәләнгән карачкы янына килеп бастылар. Беренче булып Веткин чабарга булды. Гадиәчкерсез, бераз гыйбатрак чыраена усал, кыргый бер төс бирергә тырышып, ул кылычлы кулын югары күтәрде һәм ничектер җайсыз хәрәкәт белән бөтен көченә селтәнеп, карачкыга сукты. Шул ук вакытта аның күкрәге төбеннән, үз ихтыярыннан тыш дигәндәй, итченең бүкәндә ит чапкандагы әһелдәвек хәтерләткән бер аваз өзелеп чыкты.

Кылыч йөзе балчыкка чирек аршин чамасы эчкә баткан иде, Веткин аны көч-хәл белән кире суырып алды.

Бек-Агамалов, башын чайкап:

— Начар! — дип нәтиҗә ясады һәм Ромашовка эндәште: — Ягез, сез...

Ромашов кыныдан кылычын чыгарды, уңайсызланып, янә күзлеген төзәтте. Урта буйлы, чандыр һәм үз гәүдәсенә күрә шактый көчле кеше иде ул, әмма артык оялчан булуы аркасында, ничектер үшән һәм инсез-авыр хәрәкәтле иде. Кылыч уенына ул училищеда чагында да өйрәнә алмыйча, ел ярымлык хезмәт чорында белгән кадәресен дә онытkан иде. Шуңа күрә хәзер, баш өстенә кылычын күтәргәч, ул буш сул кулын аңсыз рәвештә алга сузды.

— Ал кулыңны! — дип кычкырды Бек-Агамалов.

Ләкин соң иде инде. Балчык карачкыга кылычның бары очы гына тиеп, каршылык өмет иткән Ромашов үзе, тигезлеген югалтып, алга таба сөрлекте; кылыч йөзе исә, сузылган кулга бәрелеп, имән бармакның аскы буыны тирәсеннән бер кыйпылчык тирене кыеп төшерде. Ярадан шундук кан чәчрәде.

— Их! Акылсыз! — дип ачуланып кычкырды Бек-Агамалов һәм тиз генә аты өстеннән сикереп төште.— Болай бөтенләй кулсыз калуың да ихтимал. Кем инде шулай эшли? Ярар, артык куркынычлы түгел икән, яулык белән кысыбрак бәйләгез. Аксөяк. Мә, тот әле атны, фендрик. Менә карагыз. Сугуның хикмәте иңбашында яки терсәктә тә түгел, ә менә монда, кул чугы буынында.— Бек-Агамалов, кул чугын тиз-тиз хәрәкәтләндереп, баш өстендә кылычын айкалдырып алды; кылычның йөзе, ялтырап, һавада тоташ бер түгәрәк хасил итте.— Хәзер карагыз инде: сул кулны артка, арка ягынарак каера төшәм. Суккан чакта сез, утын агачына суккандай, ярам дип түгел, ә кисәм, теләм дип сугыгыз, ягъни әйбергә барып тиюгә, кылычны капылт кына үзеңә таба тартып җибәрегез. Аңлашыламы? Аннары шуны истә тотыгыз: кылыч йөзе әйбергә беркадәр кыек почмак ясап төшәргә тиеш. Монысы — мәҗбүри шарт. Менә, карагыз.

Бек-Агамалов балчык карачкыдан ике адым артка чигенеп, аны үлчәп-чамалап карагандай, үткен күз карашын беравык аңа текәп торды һәм кинәт кылычын күзгә күренмәс коточкыч бер тизлек белән һавада айкап алды да, бөтен гәүдәсен алга ташлап, карачкыга китереп сукты. Ромашов кылычның һаваны ярып сызгырган тавышын гына ишетеп калды; карачкының югаргы өлеше, нигезеннән аерылып, авыр-салмак бер тавыш белән җиргә шапылдап

төште. Киселгән җир, махсус шомартылгандай, тип-тигез булып, ялтырап тора иде.

— Шайтан алгыры! Менә моны осталык дисәң дә ярый! — дип куйды Лбов, таң калып.— Бек, җаныкаем, тагы бер чабып күрсәтче, ә!

— Чынлап, Бек, күрсәт булмаса,— дип үтенде Веткин да.

Әмма Бек-Агамалов, үзе ясаган эффектны, тәэсирне бозып куюдан курыккандай, серле генә елмайды да кылычын кынысына яшерде. Ул авыр сулыш ала, зур ачылган күзләрендә усал очкыннар уйный, тешләре ыржайган, кәкре борыны тагы да очлая төшкән — гомумән, бу минутта аның кыяфәте ниндидер явыз, горур бер ерткыч кошны хәтерләтә иде.

— Һы, исең киткән! Осталыкмыни бу? — дип сөйләнде ул, ясалма бер көпәренү белән.— Кавказдагы минем атайга алтмыш яшь тулган иде инде, ә ул бер сугуда атның муенын чабып өзә торган иде. Әйе, урталайга! Өзлексез күнегү ясарга кирәк, балакайларым! Беләсезме, бездә ничек эшлиләр: тал чыбыгын беркетеп куялар да, шуны чабалар, яисә югарыдан нәзек булып аккан шарлама суны кистереп уйныйлар. Тирә-якка тамчы чәчрәмәсә, сугу дөрес булган дигән сүз. Йә, Лбов, хәзер сиңа чират.

Веткин каршысына куркынган кыяфәтле унтер-офицер Бобылев килеп басты.

— Ваше благородие... Полк командиры килә!

Ул да булмады, мәйданның икенче башында капитан Сливаның сузып һәм кабаланып кычкырган кискен командасы ишетелде:

— Сми-ирррна!

Офицерлар ашыга-ашыга үз взводларына таралыштылар.

Шоссе үреннән плацка таба зур, иләмсез коляска төшеп килгәне күренде. Килеп туктагач, аның бер ягыннан, авырлыгы белән бөтен кузовны янтайта-янтайта, полк командиры төште, ә икенче ягыннан озын буйлы, фырт кыяфәтле, җитез хәрәкәтле офицер — полк командирының адъютанты штабс-капитан Федоровский җиргә сикерде.

— Здорово, алтынчы! — дип, куе-калын тавышы белән сабыр гына исәнләште полковник.

Плацның һәр ягыннан аңа:

— Здравия желаем, ваш-о-о-о! — дип, тәртипсез рәвештә җавап кайтардылар.

Офицерлар исә, кулларын фуражка козырекларына тидереп, честь биреп исәнләштеләр.

— Өйрәнүне дәвам итегез,— диде полк командиры һәм якындагы взводка таба атлады.

Полковник Шульговичның ифрат кәефсез чагы иде булса кирәк. Взвозларны эйләнеп йөргәндә, ул солдатларга гарнизон хезмәте турында төрле-төрле сораулар бирде һәм ара-тирә, кызып китеп, күпне күргән карт сугышчыларга гына хас бер җорлык-осталык белән, эшәке сүгенү сүзләре дә ычкындыргалады. Полковникның картлыктан уңып, төссезләнеп калган күзләренең чәнечкеле, кырыс карашы солдатларны әйтерсең ләо гипнозлый, зиһеннәрен чуалта: алар, сулыш алырга, керфек кагарга да кыймыйча, аның каршысында, тораташтай төбәлеп, катып торалар иде. Зур, таза, мәһабәт гәүдәле иде полковник. Чыгынкы яңаклы, киң, итләч битенең өске өлеше, маңгай турысы, тарая барып, аскы өлеше көмеш төсендәге куе, көрәк сакал белән чикләнгән; шулай итеп, йөзнең формасы ниндидер авыр, күләмле ромбны хәтерләтә иде. Чаларган куе-тузгак кашлары дәһшәт белән тырпаеп торалар. Сөйләшкәндә ул тавышын бөтенләй диярлек күтәрмичә сөйләшә, әмма дивизиядә дан тоткан бу тавышның һәр авазы (дөресен әйткәндә, хәрби хезмәттәге карьерасына ул шушы тавышы аркасында ирешкән дә иде) зур-киң плацның иң аулак почмагында гына түгел, хәтта шоссе буенда да ачык ишетелә иде.

Полковник барган җиреннән кинәт туктады да, гимнастик койма янында басып торган яшь татар солдаты Шәрәфетдиновка йөзен борып, кискен-өзек тавыш белән:

— Син кем буласың? — дип сорады.

Шәрәфетдинов бөтен көченә тырышып, карлыкканрак тавыш белән җавап бирде:

— Алтынчы рота рядовое Шәрәфетдинов, ваша высокоблагородия!

— Дурак! Нинди постка куелгансың, мин синнән шуны сорыйм?

Командирының ачулы кыяфәте һәм җикеренүеннән аптырап калган солдат, күзләрен җем-җем йомып, тик басып торды.

— Йә-ә? — диде Шульгович, тавышын күтәрә төшеп.

— Часовой, кайсы ки... кагылгысыз... — дип, уйлапнитеп тормастан, ятлаганын сөйләргә тотынды солдат, аннан кинәт әкрен, әмма тәвәккәл бер тавыш белән сүзен тәмамлады: — Белмим, ваша высокоблагородия!

Карт командирның тулы-итләч битенә кирпеч төсендәге куе-кызыл тимгелләр бәреп чыкты, тузгак кашлары дәһ-

шәт белән җыерылып, бер-беренә тоташты. Ул як-ягына күз атты да, кистереп-өзеп:

— Монда кече офицер кайсыгыз була? — дип сорады.

Ромашов бер адым алга атлап, кулын козырегына тигезде:

— Мин, господин полковник.

— Э-э! Подпоручик Ромашов. Солдатны өйрәтүегез харап шәп икән болай булгач. Аякларны тезгә-тез! — дип җикерде ул кинәт, күзләрен акайтып.— Полк командиры каршында ничек басып торасыз? Капитан Слива, кисәтү ясыйм: сезнең субалтерн-офицерыгыз хезмәт вазифаларын башкарганда начальниклары алдында үз-үзен тиешенчә тота белми... — Шулай дип, Шульгович янә Шәрәфетдиновка таба борылды: — Син, эт җан, әйт әле, кем синең полк командиры?

— Белә алмыйм,— дип, үкенечле, әмма тәвәккәл тавыш белән ашыгып җавап бирде Шәрәфетдинов.

— У-у! Мин сиңнән сорыйм, полк командирың кем дим? Йә, мин — кем? Аңлыйсыңмы, мин, мин, мин! — Һәм Шульгович берничә тапкыр учы белән бөтен көченә үзенең күкрәгенә сугып алды.

— Белә алмыйм...

— ... — ... — дип, егермеләп оятсыз сүздән торган озын, буталчык җөмлә белән сүгенеп куйды Шульгович.— Капитан Слива, хәзер үк бу адәм актыгын мылтык астына куярга боерыгыз — бөтен ачысын татырлык булсын, чересен, башы бетсен шунда канальяның! Ә сез, подпоручик, хезмәттән бигрәк хатын-кыз итәген күбрәк кайгыртасыз, ахры. Вальс биисез, Поль де Кокларны укыйсыз, шулаймы?.. Сезнеңчә, солдат шушындый буламыни? — Полковник бармагын Шәрәфетдиновның иренә үк китереп төртте.— Солдат түгел, ә оят, хурлык, ниндидер җирәнгеч нәрсә бу! Үзеңнең полк командиры кем икәнен белмә, имеш... И-с-сем-акылым китә минем сезгә, подпоручик!..

Ромашов кызарган, бүртенгән, чал сакаллы йөзгә төбәлеп тик басып торды һәм рәнҗү, дулкынланудан йөрәгенең дөп-дөп сугуын, күз аллары караңгылана башлавын тойды... Һәм кинәт, үзе дә шәйләп өлгермәстән, тоныкланып-саңгырау тавыш белән әйтеп ташлады:

— Татар егете ул, полковник әфәнде. Русча берни аңламый, аннан соң...

Шульговичның йөзе секунд эчендә ап-ак булды, сәлперәйгән яңаклары дерелдәп китте, күзләре исә, тагы да тоныкланып, куркыныч төс алды.

— Нәрсә?! — дип акырып җибәрде ул, сабырлыгын тә-

мам жуеп. Колак тондыргыч гайре табигый бу тавыштан шоссе буендагы койма өстенә кунаклаган яһүд малайлары, куркытылган чыпчык өрердәй, шундук төрлесе төрле якка сибелделәр.— Нәрсә? Әле сөйләнеп тә торасызмы? Ма-ал-чать! Авызында сөте дә кипмәгән бер малай, прапорщик кисәге, өлкәннәр алдында шулай... Поручик Федоровский, бүгенге приказда игълан итегез: хәрби дисциплинаны аңламаганы өчен подпоручик Ромашовны дүрт тәүлеккә өй арестына алырга боерам. Э капитан Сливага, үз кулы астындагы кече офицерларны хезмәт бурычларын үтәү рухында тәрбияли белмәгәне өчен, каты шелтә белдерәм.

Адъютант түбәнчелек һәм битараф бер чырай белән кулын козырегына тигезде. Бөрешеп басып торган Сливаның чырае исә агач сыман катып калган — бернинди хис чагылдырмый, тик баядан бирле фуражкасы янында тоткан кулы гына өзлексез калтырый иде.

— Оят кирәк сезгә, капитан Слива,— дип мыгырданды Шульгович, бераз тынычлана төшеп.— Полкта иң әйбәт офицерларның берсе, карт солдат — шул кеше яшьләрне шулай азындырсын, имеш. Боргычлагыз сез аларны, желекләрен суырыгыз, уңайсызланып тормагыз. Алар белән кәнфитләнергә кирәкми. Туташлар түгел, җебемәсләр әле...

Шулай дип, ул кырт борылды да, адъютантын иыртеп, коляскасына таба атлады. Аңа менеп утырып, коляска кузгалып киткәнче һәм шоссе буендагы рота мәктәбе бинасының артында күздән югалганчы, бөтен плац шомлы, аптыраулы бер тынлыкка чумды.

Берничә минуттан соң офицерлар өйләренә таралыша башладылар. Слива, Ромашов янында тоткарланып, аны битәрләргә кереште.

— Их, е-гет-кәй! — диде ул ачыктан-ачык дошманлык һәм мәсхәрә сизелеп торган тавыш белән.— Нигә кирәк булгандыр сезгә сүзгә тыгылу! Алла акыл бирмәгән икән, дәшмичә тик кенә бас та тор инде! Хәзер менә сезнең аркада миңа приказ белән шелтә чәпәделәр. Сезне минем ротага җибәрергә кайсы уйлап тапкандыр, шайтан алгыры! Сезнең миңа кирәгегез эткә бишенче аяк кирәккән кебек кенә. Сезгә ими суырып ятарга иде әле, ә монда килеп...

Слива сүзен әйтеп бетермәде, арыган кыяфәттә кулын селтәп, яшь офицерга аркасы белән борылды да, аякларын сөйрәп атлый-атлый, үзенең күптәннән бирле ялгыз яши торган пычрак квартирына юнәлде. Ромашов аның бөкрәйгән, сузынкы, тар, моңсу аркасыннан күзен алмыйча,

арттан карап озатып калды һәм кинәт күңеле төбендә, әле генә кичергән рәнҗү һәм бөтен халык алдында хурлыклы мәсхәрәгә калу ачысына кушылып, ниндидер яңа бер хис кыймылдап куюын тойды. Беркем сөймәгән, ялгызлыктан мүкләнеп, тупасланып беткән һәм бөтен дөньясыннан фәкать ике нәрсәне генә — ротасының строй белән матур йөрүен дә һәр кичне бүлмәсенә бикләнеп, полктагы тәҗрибәле карт сәрхүшләр әйтмешли, «мендәренә авып төшкәнче» аулакта аракы эчәргә яраткан капитан Сливага карата уянып куйган кызгану хисе иде бу.

Ромашовның күп очракта яшүсмерләргә генә хас сәер, көлке бер гадәте бар: үзен ул һәрвакыт өченче затка куеп уйлый һәм уй-хисләрен белдергәндә, романнардан укыган шаблон тәгъбирләрне еш куллана иде. Менә хәзер дә күңеленнән үзе турында әйтеп куйды:

«Аның акыллы, мөлаем күз карашын сагыш пәрдәсе каплады...»

II

Солдатлар взвод-взвод булып квартирларга таралыштылар. Плац бушап калды. Ромашов күпмедер вакыт шоссе өстендә уйланып басып торды. Аны янә газаплы ялгызлык, ташланганлык хисе биләп алды; мондагы барлык кешеләр аңа чит-ят, миһербансыз яки битараф-гамьсез булып тоела башлады. Ел ярымлык хезмәт дәверендә бу ялгызлык хисен беренче тапкыр гына кичерүе түгел иде инде аның. Бүгенге кичне кая куярга, нишләтергә соң? Квартирга кайту яисә офицерлар җәмгыятенә бару турындагы уй үзе генә дә җирәнү уята. Җәмгыятьтә кеше аздыр, мөгаен; күп булса ике подпрапорщик, сыра чөмерә-чөмерә, тәмәке пыскыта-пыскыта, кечкенә генә, хәрти генә бильярд өстәлендә шар тәгәрәтәдер. Шарга суккан саен алар кызып-кызып карганалар яки әшәке сүгенү сүзләре яудыралар, билгеле. Бүлмәләрдә гомер бетми торган тынчу ис — начар әзерләнгән ризык исе аңкый. Эчпошыргыч, күңелсез!..

«Вокзалга юл тотыйм булмаса,— диде Ромашов үзүзенә.— Барыбер түгелмени».

Яһүдләр яшәгән ул фәкыйрь төбәктә бер генә ресторан да юк. Хәрбиләр клубымы, гражданскийларныкымы — һәммәсе ташландык, кызганыч хәлдә, шуңа күрә вокзал шәһәр мещаннарына күңел ачу өчен бердәнбер аулак урын санала; алар анда типтереп алырга, күңел бушатырга, хәтта карта уйнарга дип бик еш барып йөриләр иде. Моның өстенә, пассажир поездлар килешенә анда ханым-

нар да күп җыела,— бу исә тирән эч пошу хөкем сөргән провинциаль шәһәр тормышына кечкенә генә булса да бер яңалык, күңеллелек кертеп җибәргәндәй була иде.

Ромашов вокзалга бигрәк тә кичләрен, курьер поезды килешенә барырга ярата иде. Курьер поезды монда Пруссия чигенә җитәрәк иң соңгы тукталышын ясый. Нибары биш кенә бөртек вагоннан, әмма, өр-яңа, ялтыравык вагоннардан торган бу поездның, борылыштан атылып чыгып, пар бөркү-бөркү ничек станциягә якынлашуын, якынлашкан саен, рельслар өстенә нур көлтәләре сузган утлы күзләренең бик тиз зурая һәм күзне камаштыргыч дәрәҗәдә яктыра баруын, аннары, станцияне узып китте дигәндә генә, кинәт, бер мизгел эчендә, каты пошкырып һәм дөбердәп, шып туктап калуын,— Ромашов уенча, «томырылып чапкан уңайга кыяга ябышкан әзмәвердәй» туктап калуын — ул, Ромашов, үзенә бер сәер, сихри соклану, рәхәт җилкенү-дулкынлану белән күзәтә иде. Шуннан соң бәйрәмчә утлар белән үтәли җемелдәгән, балкыган вагоннардан пассажирлар төшә башлый: күз явын алырлык нәфис-купшы күлмәк, гаҗәеп эшләпәләр кигән чибәр ханымнар чыга; шундый ук һәйбәт киемле, гамьсез-ваемсыз, тәкәббер чырайлы ирләр чыга. Бу әфәнделәр байларча кычкырып сөйләшәләр, иренеп кенә көләләр, телләре — французча яки немецча булыр; йөреш-хәрәкәтләре иркен, табигый. Аларның берсе-бер һичбер вакытта, ичмасам ялгыш кына булса да, Ромашовка күз салмас, әмма ул үзе аларга күзен алмый карый, алар йөзендә үзгә бер дөньяның — тормыш гел бәйрәм һәм тантана-күңел ачудан гына торган, хыял җитмәс, нәзакәтле, илаһи дөньяның бер кисәген күргәндәй була...

Шулай сигез минут вакыт үтә. Кыңгырау чыңы яңгырый, паровоз сыбызгысын сызгырта, һәм утлар эчендә балкыган поезд янә урыныннан кузгала. Перрон һәм буфеттагы утлар шундук бер-бер артлы сүнә башлыйлар. Әйләнә-тирәгә яңадан гадәттәге караңгылык иңә. Ромашов исә кузгалып киткән поездның койрыктагы вагонына тагылган кызыл фонарьдан күзен алмыйча, моң катыш бер хыял тәэсиренә бирелеп, перронда бик озак басып тора әле. Ниһаять, әкрен генә тирбәлеп барган кызыл фонарь, тәмам кечерәеп, төн караңгылыгында бөтенләй эреп югала...

«Әйе, вокзалга барам»,— дип карар кылды Ромашов. Ләкин шул вакыт аягындагы тирән эчле авыр резин калошына (полкта барлык офицерлар шундый калошлардан йөри иде) күзе төште дә, йөрәге чәнчеп, оялудан кып-кызыл булды. Калошлары кунычына кадәр камыр кебек үз-

ле, куе кара былчыракка — ләпеккә ябышып каткан иде. Аннары ул, ихтыярлы-ихтыярсыз дигәндәй, өстендәге шинеленә карады. Ьылчыракка буямас өчен тез тиңентен чабуы киселгән һәм киселгән җирләре сизрәп, җепләре асылынып торган, элмәк-каптырмалары сузылып, каешланып беткән бу шинель дә аңарда шулай ук матур хис уятмады. Үткән атнаны, әлеге курьер поезды туктаган платформадан узып барышлый, Ромашов беренче класслы вагон ишеге бусагасында басып торган кара күлмәкле, озын, зифа буйлы, ифрат чибәр бер ханымга игътибар иткән иде. Эшләпәсез, яланбаш иде ханым, шуңа күрә Ромашов аның бөтен йөз чалымнарын ул көнне бик тиз күреп, хәтеренә сеңдереп өлгерде. Нечкә төз борын, уймактай кечкенә авыз, кабарынкы, тулы-нәгыз иреннәр, ике толым итеп уртадан як-якка тигезләп таралган һәм чигә, колакларын, каш очларын каплап, дулкын-дулкын булып түбән салынып төшкән чем-кара чәч. Ханымның җилкә артында, аның иңбашы аша платформага тәкәббер күз карашын текәп, өстенә аксыл костюм кигән озын буйлы, император Вилһелмныкыдай тырпы мыеклы, хәтта сыныкыяфәте белән дә беркадәр аңа охшаган ир кеше басып тора иде. Ханым Ромашовка шулай ук игътибар итте шикелле, һәрхәлдә, егетнең үзенә ханым бик җентекле, кызыксынучан күз белән карагандай тоелды, һәм ул, вагон яныннан уза-узышлый, гадәтенчә, үзалдына әйтеп куйды: «Таныш булмаган чибәр ханым, ачыктан-ачык ләззәтләнү белән, яшь офицерның төз, чандыр гәүдәсенә яратып карады». Әмма тугыз-ун адым китеп, чибәр ханымның күз карашын янә бер күрү өчен кисәк кенә артына борылып карагач, Ромашов бөтенләй бүтән тамашаны күрде. Ханым белән ир кеше, үзара рәхәтләнеп сөйләшә-көлешә, аңа мыскыллап карап торалар иде. Шул чакта Ромашов, үзүзен читтән күзәтеп торган бер кешедәй, кыяфәтенең бөтен шыксызлыгын — аягындагы пычрак калошларын, өстендәге иске шинелен, якыннан гына күрә торган ярым сукыр күзләрен, аптыраулы, чырае качкан кызганыч йөзен, йөреш-хәрәкәтләренең ипсезлеген — һәммәсен гаҗәп ачык рәвештә күз алдына китереп бастырды; бер үк вакытта әлерәк кенә авыз эченнән тәкрарлаган матур сүзләре дә исенә төште. Аны шул чак йөрәк өшеткеч оялу хисе биләп алды, аксыл чыраена газаплы кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Хәтта менә хәзер дә, язгы кичнең эңгер-меңгерендә шоссе буйлап ялгызы атлап барган көйгә, ул шул вакыттагы оялу хисен күңеленнән кичереп, ирексездән янә бер мәртәбә кызарынырга мәҗбүр булды.

— Юк, кая инде хәзер вокзал,— дип, өметсезлек белән үзалдына ачынып пышылдады Ромашов.— Бераз шушы тирәдә йөрештерим дә, өйгә кайтырмын...

Апрель башы көннәренең бере иде. Кичке эңгер-меңгер күзгә сизелер-сизелмәс кенә күера барган вакыт. Шоссе буендагы тупыл агачлары, юлның ике ягына сибелеп утырган чирәп түбәле ак, карсак йортлар, сирәк-мирәк кенә очрап куйган узгынчылар — һәммәсе дә инде анык төсләрен югалтканнар; әйберләр ниндидер яссы кара тапларга әверелгән, әмма эңгәр-меңгер аша аларның силуэт сызыклары гаҗәеп бер ачыклык белән күренә иде әле. Көнбатышта, шәһәр артында, шәфәкъ ялкынланып ята. Авыр-салмак күгелҗем болытлар гүя ниндидер сыек алтын кайнаган янар тау авызына убылып төшәләр дә шәфәкъ нурында куе-кызыл, гәрәбә, шәмәхә төсләргә кереп җемелдиләр. Янар тауның нәкъ өстендә исә, фирүзәдәй яшелләнеп, язгы кичнең тымызык күк гөмбәзе асылынып тора иде.

Зур, шыксыз калошларын көчкә сөйрәп, Ромашов шоссе буйлап әкрен генә атлап барды һәм әлеге сихерле яңгыннан күзләрен алмады. Һәрвакыт, әле бала чактан ук, аңа кичке шәфәкъның ялкынлы шәүләсе артында ниндидер үзгә, серле бер тереклек бардыр сыман тоела торган иде. Гүя анда, бик ераста-ераста, әлеге болытлар һәм офык сызыгының аргы ягында, моннан күренми торган бүтән кояш нурлары астында үзалдына балкып, могҗизаи гүзәл бер шәһәр җәйрәп утыра. Бу шәһәрдә әллә нинди сәер гөмбәзле йортлар, куе-кызыл түбәле башнялар, имеш; урамнарга җәелгән алтын плитәләрдән күзләр чагыла; йортлар тәрәзәләренә хәтле асыл ташлар белән бизәлгән, һавада төрле төстәге әламнәр җилферди. Һәм бу әкияттәгедәй гүзәл, ерак шәһәрдә һәммә кеше бәхет, шатлык эчендә яши, имеш. Аларның тормышлары колакны иркәли торган талгын музыкага охшаган. Монда хәтта кешенең сагышлануы, хәсрәтләнүе дә үзенә бертөрле ямьле, матур, имеш. Аларның көләч йөзләрендә беркайчан кайгы-хәсрәт, хурлык-рәнҗү, тормыш мәшәкате сизелмәс, алар, әйтеп биргесез эчке бер куанычтан илаһи балкып, шәһәрнең нурлы урам-мәйданнары, чәчәккә күмелгән һәм фонтаннар белән бизәлгән тын бакчалары буйлап сәйран кылып йөриләр. Кыскасы, аларның теләк-омтылышлары, бәхетләренә бернинди киртә дә, чик тә юк, имеш...

Кинәт шул вакыт күз алдына бая плацта булган тамаша килеп басып, Ромашов полк командирының тупас акырынуын һәм шул чакта үзенең рәнҗү катыш нинди

гарьлек хисе кичерүен исенә төшерде. Полк командирының тупас акырынуына никадәр рәнҗесә, солдатлары каршында бала-чагадай уңайсыз хәлдә калуына ул шулкадәр үк ныклы гарьлэнгән иде. Иң хурландырганы шул: полк командиры аны, Ромашовны, нәкъ менә ул үзе кайчакларда солдатларны сүгеп ташлаган кебек, тупас, ямьсез сүзләр белән сүгеп ташлады бит. Җитмәсә әле, шушы ук солдатлар алдында сүкте. Тыштан сиздермәсәләр дә, алар һәммәсен күреп тордылар, билгеле. Бу хәл, Ромашов уенча, солдатлар белән үзе арасындагы аерманы юкка чыгару, аның офицерлык, ахыр чиктә — кешелек дәрәҗәсен мәсхәрәләү булып тоелды.

Һәм аны шундук малай-шалайга гына хас үтә фантастик, үч алуга бәйле исерткеч хыяллар ташкыны билэп алды. Хәер, малай-шалайлык Ромашовта болай да шактый күп иде әле. «Һәммәсе чүп! Минем яшисем алда! — дип уйланды ул һәм, шул уй-хыяллары белән җилкенеп, адымын кызулата төште, сулышын иркенрәк ала башлады.— Һәммәсенә үч итеп, иртәгә үк менә китапка тотынам, академиягә әзерләнә башлыйм! Монда ич мөһиме — тырыш хезмәт! Тырышсаң, бөтенесенә ирешеп була. Әйе, үз-үзеңне мәжбүр итәргә кирәк. Бернигә карамый, жен кебек укырга, ятлый башларга кирәк... Аннан, карыйсың, һичкем көтмәгәндә генә полкта шундый бер хәбәр тарала: Ромашов искиткеч шәп билгеләр белән академиягә имтихан тоткан, имеш... Ул чакта инде бөтенесе әйтер: «Ник гажәпләнергә? Шулай буласын без алдан ук белгән идек. Егете бит нинди: үзе акыллы, сәләтле, үзе шундый сөйкемле дә»,— диярләр.

Һәм Ромашов гажәеп җанлы рәвештә үзен генераль штабның ифрат зур өметләр баглаган бер галим офицеры сыйфатында күрде... Аның исеме академиянең алтын тактасына теркәлгән, имеш. Профессорлар аңа данлы киләчәк юрыйлар, аны академиядә бөтенләйгә калырга димлиләр, әмма ул якын да бармый; хәзергә аның бердәнбер теләге — хәрби хезмәт срогын үз полкында, нәкъ менә үз ротасында тәмамлау, имеш. Менә бервакыт ул монда кайтып төшә. Күз явын алырлык күркәм, мәһабәт кыяфәт; үз-үзен тотышы — горур-игътибарсыз, сөйләшүе ихтирамлы, түбәнчелекле, шул ук вакытта аңарда мәсхәрә катыш бер эрелек барлыгы да сизелә. Нәкъ менә теге, үткән елдагы зур маневрлар вакытында күргән генераль штаб офицерлары сыман. Полкка кайткач, Ромашов мондагы офицерлар белән артык аралашмас, билгеле. Армия тормышының тупас гадәтләре, тәкәллефсез мөгамәлә, карта

уены, эчүләр — юк инде, болар аңа һич иш түгел! Мондагы хезмәт алда яулаячак карьера һәм дан юлында үтелергә тиешле бер этап кына ул.

Менә, әйтик, көннәрдән бер көнне маневрлар башлана. Ике яклы зур сугыш уены. Полковник Шульгович диспозиция дигәнне һич аңламый, бутый-буташтыра, кешеләрне кабаландыра, үзе дә кабалана,— корпус командиры аңа инде ординарецлары аша ике тапкыр шелтә белгертте. «Ну, капитан, коткарыгыз мине,— дип, ярдәм сорап, Ромашовка ялына, имеш, Шульгович.— Һич югы, эүвәлге дуслык хакына. Хәтерегездәме, безнең арада нинди ачуланышулар була торган иде, ә? Хе-хе-хе... Зинһар, ярдәм итегез»,— ди, имеш. Йөзендә — аптырау, ялагайлык. Ләкин Ромашов, ияреннән иелә төшеп, тел-теш тидергесез бер осталык-пөхтәлек белән аңа честь бирә дә, сабыр гына, эре генә әйтә: «Гафу итәсез, полковник әфәнде... Полкның хәрәкәтенә җитәкчелек итү сезгә йөкләнгән. Минем бурыч — сездән боерык алу да шуны үтәп чыгу...» — ди. Ә ул арада корпус командирыннан яңа шелтә белән өченче ординарец килеп җитә, имеш...

Генераль штабның талантлы офицеры Ромашов хезмәт баскычыннан әнә шулай һаман югарырак күтәрелә бара. Менә зур бер корыч кою заводында эшчеләр фетнә чыгарганнар. Фетнәне бастыру өчен ашыгыч рәвештә Ромашов ротасын чакыртып алалар. Төн, янгын шәүләсе, ыгы-зыгылаган шаулаган фетнәчеләр өере; баш өстендә ташлар оча... Рота каршысына төз буйлы, чибәр капитан чыгып баса. Бу — Ромашов. «Туганнар,— дип мөрәҗәгать итә ул фәтнәчеләргә,— өченче һәм соңгы тапкыр кисәтәм: тыңламасагыз — атачакмын!..» — ди. Мәсхәрәләп кычкырган тавышлар, сызгыру, көлү... Ул да булмый, Ромашовның иңбашын таш кисәге көйдереп ала, әмма аның тәвәккәл, ачык йөзе тыныч. Ул солдатларына таба борыла, тегеләренең исә, сөйгән командирлары рәнҗетелүен күрү ачуыннан күзләре ут яна, имеш. «Фетнәчеләр өренә төзәп, атарга әзерләнергә... Рота, ут ач!..» Йөз мылтыктан аткан тавыш, бергә кушылып, һаваны дер селкетә... Коточкыч тамаша башлана. Дистәләгән мәет һәм яраланучылар өсте-өстенә җиргә авалар... Исәннәре тәртипсез рәвештә як-якка ташлана, кайберәүләр мәрхәмәт сорап тезләренә чүгәләр. Фетнә шулай бастырыла. Ромашовка исә, һәркемгә үрнәк батырлыгы өчен, түрәләрдән рәхмәт һәм берәр төрле бүләк көтәргә генә кала.

Аннары, имеш, чын сугыш башланыр... Юк, сугыш башланганчы Ромашов иң әүвәл Германиягә шпион булып

китәр әле. Немец телен тәмам камил дәрәҗәдә үзләштерер дә китәр дә барыр. Бу үзе генә дә һуш китәрерлек батырлык бит! Берьялгызы, бернинди иптәшсез, кесәсенә немец паспорты салып, аркасына шарманка асып китәр. Әйе, әйе, нәкъ менә шулай — шарманка асып. Анда, ярым җүләргә сабышып, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрер, шарманка әйләндерер, пфеннинглар җыяр, бер үк вакытта шыпырт кына немец хәрби ныгытмаларының, склад, казарма, лагерьларының планын рәсемгә төшерер. Бөтен яктан аңа өзлексез куркыныч янап тора, имеш. Үз хөкүмәте аңардан ваз кичкән, аны законнан тыш саный. Әгәр кыйммәтле мәгълүматлар таба алса, ул — акчалы да булды, шөһрәткә дә иреште дигән сүз; инде таба алмый икән,— аны судсыз-нисез, бернинди рәсмилекләргә юл куймыйча, иртә таң белән берәр тау итәгендә урнашкан капонир чокырына алып төшәчәкләр дә җанын кыячаклар. Әнә, имеш, аны, хәленә кереп, яулык белән күзләрен бәйләргә итәләр, әмма ул горур төстә яулыкны җиргә атып бәрә дә әйтә: «Чын офицер үлем каршында куркып калыр дип уйладыгызмы әллә?» — ди. Карт полковник, кызганып, аны үгетләргә тотына. «Акылыгызга килегез, сез бик яшь бит әле, миннем үземнең улым да нәкъ сезнең яшьтә,— ди.— Һич югы, исемегезне, милләтегезне генә булса да әйтегез, әйтсәгез, үлем җәзасын төрмә белән алыштырырбыз»,— ди. Әмма Ромашов аңа салкын бер нәзакәтлек белән җавап бирә: «Үгетләү кирәкми, полковник, рәхмәт сезгә. Әйдәгез, эшегезне эшләгез»,— ди. Шуннан ул, укчы солдатлар взводына табан борылып, шундый ук горур, нык тавыш белән,— әлбәттә инде, саф немец телендә,— болай ди: «Солдатлар, сездән иптәшләрчә үтенәм: атканда йөрәк турысына төзәп атыгыз!» Нечкә күңелле лейтенант, керфегенә кунган яшь тамчысын яшерергә тырышып, ак кулъяулыгын болгап җибәрә. Залп...

Бу күренеш хыялда шулкадәр ачык, җанлы булып күзалланды ки, инде шактый вакыттан бирле тирән сулый-сулый, зур һәм ашыгыч адымнар белән атлап барган Ромашов кинәт, бөтен тәнендә салкын бер калтырау тоеп, коты алынудан шып туктады. Йодрыкларын чытырдатып кыскан, э йөрәге чыгам дигәндәй дөп-дөп тибә иде. Әмма күп тә үтми ул, караңгыда үзалдына гаепле генә елмаеп куеп, гәүдәсен җыя төште дә янә юлын дәвам иттерде.

Бераздан шарлавыктай җитез агышлы, тыелгысыз хыял ташкыны аны кабат үз кочагына бөтереп алды. Пруссия һәм Австрия белән канлы, аяусыз сугыш башланган, имеш. Күз җиткесез сугыш кыры, мәетләр, гранаталар, кан,

үлем! Кампаниянең бөтен язмышын хәл итәргә тиешле иң мөһим бәрелеш! Сугыш кырына соңгы резерв көчләр тартыла, дошман тылында менә-менә рус гаскәренең урау колоннасы күренергә тиеш. Ләкин дошманның ярсулы һөҗүмен тоткарлап торырга, позицияне ничек кенә булса да кулда тотарга кирәк. Җитмәсә, дошманның иң аяусыз ут, көч белән һөҗүм итү юнәлеше нәкъ менә Керенский полкы өстенә төшә. Солдатлар арсланнардай сугыша, дошман пулялары астында сафлары сирәгәйгәннән-сирәгәя барса да, алар нык торалар. Хәлиткеч тарихи момент! Тагы бер-ике минут чыдасалар, җиңү безнең якта дигән сүз. Ләкин полковник Шульгович тәмам аптырашта калган; батыр, кыю солдат ул үзе — анысы бәхәссез, әмма коточкыч сугыш тамашасы аның нервларын какшаткан. Ул күзләрен йома, куркынып дерелди, кызарына-агарына... Менә ул инде быргычыга ым кага, чигенү сигналын уйнарга куша; тегесе, командир боерыгын үтәргә дип, быргысын иреннәренә китерә, ләкин нәкъ шул секундта калкулык артыннан, күбеккә баткан гарәп атын җан-фәрманга чаптырып, дивизия штабы начальнигы — полковник Ромашов атылып чыга. «Полковник, бер адым да чигенмәскә! Монда Россиянең язмышы хәл ителә!» — ди ул. Шульгович ачуыннан тәмам бүртенә: «Полковник! Монда мин командир, алла һәм патша хәзрәтләре каршында да үзем җавап бирермен! Быргычы, уйна!» — дип боера. Ләкин Ромашов быргычы кулыннан быргыны тартып алып өлгергән инде. «Егетләр, алга! Падишаһыбыз һәм ватаныбыз сезгә зур өмет белән карый! Ура!» — дип кычкыра ул. Солдатлар, колак тондыргыч «ура!» белән һаваны яңгыратып, Ромашов артыннан ярсулы төстә һөҗүмгә ташланалар. Бөтен нәрсә бергә бутала, төтен белән каплана, каядыр упкынга тәгәри. Дошман сафлары, чыдамыйча, тәртипсез рәвештә чигенә башлыйлар. Ә алар артында ераста, калкулыклар буенда, өстәмә көч — урау колоннасы солдатларының штыклары ялтырап күренә инде. «Ура, туганнар, җиңү безнең якта!..»

Атлап кына түгел, дәртле бер куаныч белән кулларын уңлы-суллы болгап, инде бөтенләй йөгерә-чаба алга томырылган Ромашов кинәт тагы туктады һәм исен-акылын җыярга тырышты. Кием астында, арка һәм аяк-куллары буйлап, шәрә тәнне чымырдатып, кемнәндер салкын бармаклары йөри сыман, чәч бөртекләре гүя үзләреннән-үзләре селкенеп-селкенеп куялар, ә керфекләр ниндидер ачытатлы күз яшенә манчылган иде. Өенә ничек кайтып җиткәнен Ромашов үзе дә сизми калды һәм, хыялый күренеш-

ләрдән тәмам айнып, күз алдында ачылган таныш капкага, капка артындагы сирәк агачлы җиләк-җимеш бакчасына һәм аның түрендә агарып күренгән кечкенә флигельгә үтә бер гаҗәпләнү белән карап куйды.

— Менә бит, күңелгә нинди чүп-чар кереп азаплый! — дип үзалдына пышылдады ул, оялып. Һәм башы якасы эченә тагы да сеңә төште.

III

Өйгә кергәч, Ромашов, өс киемен дә салмыйча, хәтта биленнән кылычын да ычкындырмыйча, караватка ауды һәм шунда, мәгънәсез күз карашын түшәмгә текәгән көе, бернинди хәрәкәтсез бик озак ятты. Аның башы авырта, арка сөякләре сызлый, күңеле-җаны исә, гүя моңарчы беркайчан бернинди уй-хисләргә, истәлек, хатирәләргә урын бирмәгән сыман, буп-буш: ичмасам, аз гына ярсыну яки эч пошу дигәне дә юк,— анда фәкать ниндидер иңләп алмастай зур, караңгы, битараф бер авыр нәрсә генә ята кебек иде.

Урамда апрель аеның күгелҗем-яшькелт төсләргә төренгән ямансу эңгер-меңгере инде тәмам сүнеп бара. Өй алдында, тавыш-тын чыгармаска тырышып, ниндидер тимер-томыр әйберләр белән булашып, әкрен генә денщик йөренә.

«Кайдадыр укыганым бар: кеше, имеш, бер генә секунд та уйламый тора алмый,— дип, үзалдына сөйләнде Ромашов.— Ә менә мин берни турында да уйламый ятам. Сәер бит! Ләкин уйламыймы соң? Юк, уйлыйм ахры, чөнки менә әле генә үземнең берни уйламый ятуым турында уйлап куйдым, — димәк, минең бер почмагында ниндидер көпчәк барыбер әйләнеп алды дигән сүз. Менә хәзер үзүземне тикшереп фикер йөртүем дә шул ук уйлау лабаса...»

Ромашов бу күңелсез, буталчык фикер сөрешенең очын табарга тырышып бик озак азапланды, ахырда, тәмам алҗып, физик бер җирәнү белән йөзен чытты: үрмәкүч авыдай ниндидер соргылт, чиркангыч җепләр сузылды да, аның бар уй-фикерләрен ычкындырмаслык итеп шул пәрәвезгә сарып алды. Ромашов мендәрдән башын күтәрде һәм денщигына эндәште:

— Гайнан!..

Өйалдында нәрсәдер, самавыр торбасымы шунда, идәнгә төште дә шаңгырдап тәгәрәп китте. Аннары, артыннан кемдер кугандай, ишекне гөрст итеп ачып һәм ябып, бәрелә-сугыла, бүлмәгә денщик атылып керде.

— Мин, ваше благородие! — дип кычкырды Гайнан куркынган тавыш белән.

— Поручик Николаевлардан килүче-китүче булмадымы?

— Юк, ваше благородие! дип кычкырды тагын Гайнан.

Ромашов белән денщик арасында инде күптәннән бирле бер-беренә ышанучан, гади, хәтта, әйтергә мөмкин, беркадәр дусларча, яратучан мөнәсәбәт яшәп килә иде. Әмма эш-хезмәт вазифасына бәйле «нәкъ шулай», «юк», «здравия желаю», «белә алмыйм» кебек рәсми җавапларга килеп терәлгәндә, Гайнан бу сүзләрне, хәрби сафта басып торган солдат сыман, күкрәге төбеннән буылып чыккан ниндидер мәгънәсез, агач тавыш белән, каты кычкырып әйтә иде. Хезмәтенең беренче көннәреннән күнегелгән һәм, күрәсең, гомере буена калып сеңеп калган аңсыз бер гадәте иде бу аның.

Гайнан чыгышы белән чирмеш булып, дине буенча потка табынучы, ягъни мәҗүси санала иде. Соңгысы белән Ромашов ни өчендер аеруча нык горурлана иде. Полктагы яшь офицерлар арасында, малай-шалайларча дигәндәй, шундый бер көлке, беркатлы уен таралган: үз денщикларын алар акылга сыймастай төрле гаҗәеп, кыргый нәрсәләргә өйрәтергә тырышалар иде. Веткин, мәсәлән, өенә дус-ишләрне кунакка килгәч, үзенең денщигы молдаванпан гадәттә болай дип сорый: «Бузескул, безнең подвал хәле ничегрәк анда, шампански калмадымы икән?» — ди. Тегесе бернинди икеләнүсез, җитди йөз белән җавап кайтара: «Һич юк, ваше благородие, кичәгенәк соңгы дүжинасын эчеп бетердегез»,— ди. Икенче бер офицер, подпоручик Епифанов, денщигына әллә нинди катлаулы, күп вакыт, ихтимал, үзе дә аңлап җиткермн торган сораулар бирергә ярата. «Әйт әле, дустым, бүгенге Франциядә монархияне яңадан торгызу башлангычы хакында син ни уйлыйсың?» — ди ул аңа. Денщик, күзен дә йоммыйча, шундук җавабын әйтә: «Нәкъ шулай, ваше благородие, бу яхшы булырга тиеш»,— ди. Поручик Бобетинский үз денщигын бик тырышып катехезиска өйрәтә, тегесе исә теләсә нинди тозсыз, мәгънәсез сорауга да шартлатып җавап бирә: «Өченчедән, ушбу ни өчен мөһим?» — «Өченчедән, ушбу һич мөһим түгел», яки: «Ушбу тугърында изге чиркәү ни уйлый?» — «Ушбу тугърында изге чиркәү дәшми». Шул ук Бобетинскийның денщигы көлкеле трагик бер чырай белән «Борис Годунов»тан Пимен монологын яттан сөйли. Офицерлар арасында шулай ук денщикларны французча

сөйләтү гадәте дә нык таралган: бонжур, мусьё; бонн нюит, мусьё; вуле ву дю те, мусьё,— һәм башка шуның ише сүзләр. Болар, әлбәттә, эч пошудан вакытны кая куярга белмәү, фикри тарлык, хәрби хезмәттән кала бүтән шөгыль булмау аркасында килеп туган нәрсәләр иде.

Ромашов еш кына Гайнаннан аның табынган аллалары турында сораштыра, барыннан да бигрәк дөнщикның тәхет һәм ватан каршында тугрылык анты бирү вакыйгасын сөйләттерә иде. Мәҗүси аллалары хакында Гайнан артык җәелеп китә алмый, бу мәсьәләдә аның үзенең дә мәгълүматы аз, ә менә ант бирү вакыйгасын ул бик теләп сөйли иде. Бу вакыйга чыннан да кызыклы, оригиналь килеп чыккан иде. Тоткан диннәренә карап, солдатлардан ант сүзләрен төрле кешеләр әйттергән: православныйдан — священник, католиктан — ксендз, яһүдтән — раввин, протестантлардан — пастор булмау сәбәпле, штабс-капитан Диц, мөселманнардан — поручик Бек-Агамалов. Ә менә Гайнан һәм аның ике якташыннан ант әйттерү бөтенләй икенче төрле була. Полк командиры адъютанты, кылыч очына тоз сибелгән икмәк кисәге кадап, бер-бер артлы аларның каршысына килеп баса, һәм тегеләр икмәк кисәген, кул тидерми генә авызлары белән алып, шундук ашап бетерергә тиеш булалар. Бу йоланың символик мәгънәсе шундыйрак бугай: янәсе, мин менә, яңа хуҗага хезмәткә ялланып, аның ипи-тозыннан авыз иттем, инде хәзер аңа тугрылыклы булмыйм икән — мине теләсә нинди тимер җәзасына хөкем итәргә хаклылар. Гайнан бу сәер йола белән, күрәсең, бик горурлана һәм җае чыккан саен аны сөйләргә ярата иде. Җитмәсә, һәр сөйләгәндә хикәясенә яңадан-яңа тәфсилләр өсти, нәтиҗәдә әлеге вакыйга аның сөйләвендә ниндидер фантастик, гайре табигый һәм чыннан да көлкеле бер әкыяткә әверелеп, Ромашов өчен дә, аның өенә килеп йөрүче башка поручиклар өчен дә үзенә бер төрле күңел ачу чарасы булып хезмәт итә иде.

Менә хәзер дә Гайнан, мәҗүси аллалары һәм ант бирү вакыйгасына бәйле гадәти сүз башланыр дип, хуҗасы каршында хәйләкәр елмайган хәлдә көтеп басып торды. Ләкин Ромашов сүлпән генә әйтеп куйды:

— Ярар, бар... Үз эшеңдә бул...

— Яңа сюртугыңны әзерләп куярга кирәкмиме соң, ваше благородие? — диде Гайнан, хуҗасын кайгыртып.

Ромашов, икеләнеп, бераз дәшми торды. Башта: кирәк, аннан: кирәкми, дип әйтергә теләде ул... аннан тагын: кирәк, диясе килде. Ниһаять, сулышын сабый балаларча

берничәгә бүлеп, тирән итеп сулады да боек тавыш белән җавап бирде:

— Ярар, мәшәкатьләнмә, Гайнан... нигә кирәк... качмас әле... Син, туганкай, булмаса, самавыр куеп җибәр, аннан җәмгыятькә барып кичке ашны алып кайтырсың. Кая инде хәзер!

«Бүген үч итеп бармыйм үзләренә,— дип, көчсез бер үҗәтлек белән үзалдына уйланды ул.— Көн саен барып, кешене ничек туйдырып бетермәк кирәк, җитмәсә... анда минем килүне бигүк яратмыйлар да бугай».

Акылында бу карар шактый нык шикелле тоелса да, кайдадыр тирәндә, күңеле төбендә, аңга әлегә үтеп керә алмыйча дигәндәй, икенче бер көчле хис тә кымырҗый иде. Соңгы өч айның һәр көнендәгечә, узган көндәгечә үк, мин бүген дә барыбер Николаевларга барачакмын, дигән күңел ышанычы иде монысы. Ромашов Николаевлардан көн саен төнге уникеләрдә чыгып китә һәм, үзенең йомшак характерлы булуына хурланып, ачуы килеп, анда бүтән бармыйм яки, һич югы, бер-ике атна күренми торам, дип, юл буе үз-үзенә ант итеп кайта иде. Кайтып, урынга яткач та, йокыга киткәнче, бу антны ул бик җиңел генә үти алыр шикелле тоела. Ләкин төн уза, ялыктыргыч озын көн кичеп, эңгер-меңгер төшә,— һәм Ромашовны янәдән тыелгысыз теләк биләп ала: аның яңадан әлеге якты, пөхтә йорттагы, җайлы-җыйнак бүлмәләрендә, шат күңелле, мөлаем кешеләр арасында буласы, аннан да бигрәк, чибәр ханымның чытлык катыш иркәләүле бытылдавын тыңлап, үз-үзен оныткан хәлдә ләззәтләнеп утырасы килә.

Ромашов караватына торып утырды. Эңгер-меңгер инде тәмам куерган, әмма бүлмә эчендәге әйберләр шактый ачык күренә иде әле. У-у, тормышының бу ярлы җиһазлы «обстановка»сын көн саен күреп гарык булды инде ул! Кечкенә генә язу өстәле өстендә тюльпан чәчәгенә охшатып ясалган алсу калпаклы лампа тора; янәшәсендә — каядыр ашыгып текелдәгән түгәрәк будильник белән мопс сурәтле кара савыты; карават буенда, стенада,— ат менгән сөңгеле сунарчы һәм юлбарыс сурәте төшерелгән киез келәм; почмакта — калтыравык аяклы этажерка, аның бер почмагына китаплар өелгән, икенче почмагында виолончель футлярын хәтерләткән ниндидер фантастик силуэт күзгә ташлана; бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсендә — югарыга тәба көпшә сыман түгәрәкләп төреп куелган салам штор; ишек янында — чаршау каплаулы кием элгече. Виолончельне исәпләмәгәндә, һәрбер буйдак офицерның, һәрбер подпрапорщикның өй җиһазы, кагыйдә буларак, нәкъ менә шу-

шындый әйберләрдән гыйбарәт иде. Виолончельне исә Ромашовка, кирәксез бер нәрсә итеп, кайчандыр полк оркестрыннан биреп җибәргәннәр иде, ләкин ул аның белән озак юанмады, мажор гаммасын да өйрәнеп җитәр-җитмәс, виолончельнең үзен дә, музыканы да әле моннан бер ел элек үк бөтенләй ташлады.

Бу эчпошыргыч, зәвыксыз әйберләрнең һәммәсен ул вакытта Ромашов нинди ләззәтле, нинди горур бер шатлык хисе белән алып кайткан иде бит югыйсә! Хәрби училищены тәмамлап, хезмәткә килгән беренче көннәре иде аның. Үз квартирында тору, үз әйберләрең булу, үзең теләгәнне сатып алу, кыскасы, тормышны ничек телисең, шулай кора алу мөмкинлеге — бу хөрлек әле кичә генә укучылар эскәмиясендә утырган һәм ашарга, чәй эчәргә дә иптәшләре белән бергә гомуми сафта ашханәгә барып йөргән егерме яшьлек малай өчен әйтеп бетергесез бер куаныч булган иде. Һәм бу кызганыч җиһаз әйберләрен сатып алып йөргән ул вакытларда аның өметләре нинди зур иде дә, планнары нинди киң иде!.. Киләчәк тормышның һәрбер ягы бөтен вагы-төягенәчә алдан исәпләп-уйлап куелган иде! Беренче ике ел дәвамында — классик әдәбият белән ныклап танышу, системалы рәвештә француз, немец телләрен өйрәнү, музыка белән шөгыльләнү. Соңгы елында — академиягә керергә әзерләнү. Шулай ул ижтимагый тормыштагы хәлләрне, әдәбият һәм фән яңалыкларын да даими күзәтеп барырга кирәк,— моның өчен Ромашов газетага һәм аена бер тапкыр чыга торган популяр журналга язылган иде. Болар өстенә ул үзендә Вундтның «Психология»сен, Льюисның «Физиология», Смайльсның «Үзешчәнлек» дигән китапларын булдырган иде...

Менә тугыз ай инде — китаплар әнә этажеркада кузгалмыйча ята, Гайнан аларның тузанын сөртергә дә оныта; газеталар, бандероль баулары да киселмәгән килеш, өстәл астында ауныйлар, журналны исә, нәүбәттәге ярты елга алдыру хакы түләнмәгән өчен, бөтенләй җибәрми башладылар. Ә ул үзе, подпоручик Ромашов, офицерлар җәмгыятендә аракы чөмерә, полктагы бер ханым белән, аның чахоткалы, көнче иреннән яшерен рәвештә, дәвамлы, алдашулы, пычрак, күңелсез элемтәдә яши, карта уйный һәм хезмәтеннән, хезмәттәге иптәшләреннән, үз тормышыннан торган саен туя бара.

Кинәт өйалдында янә нәрсәдер дөбер-шатыр килде, һәм ишек бусагасында денщик калкып чыкты.

— Гаеплемен, ваше благородие! — дип яңгыратты ул бүлмәне, аннан, кисәк кенә сүрелеп, гади генә, дусларча

мөлаем гына тавыш белән сүзен дәвам иттерде: — Әйтергә онытканмын. Сиңа Петерсон ханымнан хат килгән иде. Денщигы китерде, сиңа җавап язарга кушты.

Ромашов, чыраен чытып, бер почмагына хат кабып очып барган кош сурәте төшерелгән озынча, тар конвертны ерты да эчендәге кәгазьне сурып чыгарды.

— Лампаны кабыз, Гайнан,— дип боерды ул денщикка.

«Сөеклем, кадерлем, мыеклы Жоржигым,— дип укыды Ромашов, кыеклатып түбән тәгәрәгән тәртипсез таныш юллар өстеннән күзен йөртеп.— Менә бер атна була инде, синең бездә күренгәнең дә юк, ә мин сине шундый сагындым, кичә төне буе елап чыктым. Исеңдә тот: әгәр син миннән көләргә теләсәң, мин синең андый хыянәтеңне кичерә алмаячакмын. Морфий эчәм дә газапларыма чик куям, ә сине гомерең буе вәждан корты кимерер. Бүген кичен 7 $^1/_2$ сәгатьтә безгә кил. Кара аны, килми калма. Ул өйдә булмаячак, тактик занятиеләргә китә. Мин сине, көчемнән килгәнчә, кысып-кысып кочаклармын. Кил, яме. Сине 1000 000 000... тапкыр үбеп калам. Җаны-тәне белән синең Раисаң.

P. S. Помнишь ли, милая, ветки могучие
Ивы над этой рекой,
Ты мне дарила лобзания жгучие,
Их разделял я с тобой [1].

P. P. S. Киләсе шимбә көнне сез җир упса да җәмгыять кичәсендә булырга тиешсез. Мин сезне алдан ук өченче кадрильгә чакырам. Бу бик әһәмиятле!!!!!!

R. P.»

Ниһаять, дүртенче битнең аскы почмагында шакмак эченә шундый сүзләр язылган иде:

Мин бу төшне үптем

Хаттан таныш ис — Персия гөлсирине исе аңкый; кәгазь битендә ислемай тамчыларыннан анда-санда саргылт

[1] Исеңдәме, иркәм, мәгърур тирәк
Ботакларын җәйгән иде бу ярда.
Кайнар үбүеңне бүләк иттең миңа,
Мин дә үптем сине шул чакта.

таплар утырып калган, ул урыннардагы күп хәрефләр җәелеп-таралып тора иде. Күңел болгаткыч бу ислемай исе, оятсыз киная катыш шаярту тоны белән язылган бу хат һәм аны укыгач та күз алдында калкып чыккан җирән чәчле, кечкенә битле, алдакчы чырайлы ханым сурәте — болар һәммәсе, бергә кушылып, Ромашовның күңелендә әйтеп бетергесез җирәнү хисе уяттылар. Ул, ачулы бер ләззәт-тантана белән тешләрен ыржайтып, хатны башта урталай ертты, аннары бөкләп, янә дүрт кисәккә, аннары сигез кисәккә бүлде,— кулының ертыр әмәле беткәнче хатны шулай тәмам ваклады-тураклады да бөтенесен берьюлы өстәл астына атып бәрде. Шул ук секундта, гадәтенчә, үзен өченче затка куеп, эченнән генә нәтиҗә ясарга да өлгерде:

«Ул ачыну һәм җирәнү белән көлемсерәп куйды».

Бер үк вакытта Ромашов шуны аңлады: әйе, ул бүген дә Николаевларга барачак! «Ләкин бу баруым соңгы, иң соңгысы булыр!» — дип, үз-үзен юатырга маташты ул. Һәм аның кәефе шундук күтәрелеп, күңелс тынычланып китте.

— Гайнан, киемнәремне бир!

Ромашов тиз-тиз юынды да яңа сюртугын киде, чиста ак кулъяулыгына ислемай бөркеде. Шулай киенеп-ясанып чыгып китәргә генә торганда, аны кинәт Гайнан туктатты.

— Ваше благородие! — диде чирмеш гадәттәгедән үзгә, йомшак, ялваручан тавыш белән һәм баскан урынында кыбырсынып бии башлады.

Артык дулкынланган яисә уңайсызланган чагында ул гел шулай кыбырсынып биергә тотына: әле бер тезен, әле икенчесен алга ташлап, иңбашларын сикертә, муенын катырып турайта, түбән салынып төшкән кул бармакларын нервлы калтыратып ала.

— Тагын нәрсә сиңа?

— Ваше благородие, зинһар, син минем үтенечне тыңла. Миңа ак әфәндене бүләк ит.

— Нәрсә дидең? Нинди ак әфәнде ул?

— Теге, чыгарып ташла дигәнне. Менә моны, менә...

Гайнан бармагы белән мич аралыгына таба төртеп күрсәтте. Анда, идәндә, Ромашов кайчандыр узгынчы кырык тартмачыдан сатып алган бер бюст ята иде. Язуында Пушкин дип әйтелсә дә, асылда бөек рус шагыйрен түгел, ә ниндидер карт яһүд маклерын сынландырган бу бюст шулкадәр тупас эшләнгән һәм, чебен шакшысына буялып, шулкадәр шыксыз кыяфәткә кергән иде ки, Ромашов аны, инде тәмам күрәсе килмичә, шушы көннәрдә генә чыннан да урамга чыгарып ташларга кушкан иде.

— Нигә ул сиңа? — дип көлемсерәде подпоручик.— Соң, алай бик кирәге булгач, ал әйдә. Шат кына булырмын. Миңа аның һич хаҗәте юк. Тик сиңа нәрсәгә дип кенә соравым?

Гайнан баскан урыныңда янә кыбырсынып биеп алды.

— Ярар, үзеңә кара,— диде Ромашов.— Тик син аның кем икәнен беләсеңме соң?

Гайнан, оялып, йөзен читкә борды һәм баягыдан да җәһәтрәк биергә тотынды.

— Мин... белмим... — диде ул, җиңе белән авызын сөртеп.

— Белмисең икән, бел алайса: бу — Пушкин. Александр Сергеевич Пушкин. Аңладыңмы? Кабатла артымнан: Александр Сергеич...

— Бесиев [1],— дип кабатлады Гайнан, нык итеп.

— Бесиев? Ярар, Бесиев икән, әйдә Бесиев булсын,— дип килеште Ромашов.— Шулай да миңа китәргә вакыт. Әгәр Петерсоннардан сорап килсәләр, чыгып китте диген, ә кая икәнен белмим диярсең. Аңладыңмы? Инде хезмәт буенча кирәгем чыкса, туп-туры минем янга, поручик Николаевлар квартирына чап. Сау булып тор, картлач!.. Җәмгыять йортыннан кичке ашны алып кайт, теләсәң, үзен ашарсың.

Шулай дип, Ромашов чирмешнең аркасына дустанә шапылдатып алды, тегесе аңа авызын киң ерып, шатлыклы, үз иткән елмаю белән җавап бирде.

IV

Урамда күзгә төртсәң дә күренмәслек дөм-караңгы иде, шунлыктан Ромашовка башта, сукыр кешедәй, аяклары белән юлны кармалый-кармалый барырга туры килде. Иләмсез зур калошлар, атлаган саен, рәхәтлокым [2] сыман куе, үзле ләпек-пычракка кереп баталар да, аякны тартып алганда ниндидер сызгыру, су чапылдавына охшаш сәер аваз чыгаралар. Еш кына ике калошның берсе баткакта бөтенләй ябышып-суырылып кала, һәм андый чакта Ромашов, сыңар аягында алпан-тилпән чайкалып, икенче аягы белән караңгыда әлеге юкка чыккан калошны эзләргә мәҗбүр була иде.

Урамда, әйтерсең, кабер тынлыгы, хәтта эт өргән тавыш та ишетелми. Анда-санда карсак өйләрнең кечкенә тәрә-

---

[1] Сүз уйнату: *бес* — пәри, җен дигән сүз.

[2] *Рәхәтлокым* — торт сыман ашамлык.

зәләре аша урамга тоник яктылык саркыла; алардан соры-күгелҗем төстәге җир өстенә озын, тигез шәүләләр сузылып яткан иде.

Ромашов койма буеннан, йортлар кырыннанрак атлап барырга тырышты. Юеш, ябышкак бу коймалардан, дым сеңгән тупыл кайрыларыннан, урам пычрагыннан инде үзенә бертөрле ис — күңелне кытыклап, җанга ниндидер рәхәтлек, шатлык бөрки торган язгы хуш ис аңкый иде. Хәтта урам тутырып гизеп йөргән көчле җил үзе дә, яз көненә карамастан, бер әкренәеп, бер талпынып, ничектер тигезсез исә, кабалана, уйный-уйнаклый сыман.

Николаевлар яшәгән йорт турысына җиткәч, подпоручик, минутлык шөбһәләнү, икеләнү хисенә бирелеп, беравык туктап торды. Беләкәй тәрәзәләр коңгырт калын пәрдәләр белән капланган, әмма эчтә тигез, якты ут янганлыгы урамнан ук сизелә иде. Җитмәсә, бер урында пәрдә җыерылып, ачылыбрак та тора. Ромашов, өй эчендәгеләр ишетә күрмәсен дигән сыман, тәмам сулышын кысып, тәрәзә пыяласына маңгае белән терәлде дә, тирән бер дулкынлану эчендә, әлеге озынча нәзек ярык аша бүлмәгә күз ташлады.

Бераз бөкрәя биреп, яшел рипс тышлы таныш диван эченә чумып утырган Александра Петровнаның йөзен һәм иңбашларын шундук күреп алды ул. Гәүдә тотышы, йомшак-сабыр хәрәкәтләре, башының түбән иелгән булуы ханымның ниндидер кул эше белән утыруын ачык күрсәтә иде.

Менә ул кинәт кенә тураеп, башын югары күтәрде һәм тирән итеп сулыш алды... Әнә иреннәре дә кыймылдый... «Нәрсә сөйли икән ул? — дип уйлап куйды Ромашов.— Әнә елмайды да. Сәер — тәрәзә аша кешенең сөйләгәнен карап тор, ә сүзләрен ишетмә, имеш!»

Александра Петровнаның йөзендәге елмаюы кинәт юкка чыкты, маңгай-кашы җыерылып килде. Иреннәре таләпчән төстә тагы тиз-тиз кыймылдый башладылар, аннары йөзендә кисәк кенә яңадан елмаю — үртәүчән, мыскыллаучан елмаю пәйда булды. Менә ул ризасызлык белән әкрен генә башын чайкап куйды. «Бәлки, минем турыда сөйлидер?» — дип уйлады Ромашов, кыяр-кыймас өмет белән.

Аңа бу яшь ханымнан һәрвакыт ниндидер талгын, гамьсез-сабыр бер сафлык, пөхтәлек бөркелә сыман тоела торган иде, һәм хәзер, үзенә күптән таныш бер җанлы, сөйкемле картинага карагандай, ул аңа сокланып, яратып

карады. «Шурочка!» — дип иркәләп пышылдады Ромашов.

Александра Петровна кул эшенә җелгән башын янә югары күтәрде дә борчулы йөзен капылт кына тәрәзәгә таба борды. Әйтерсең лә күз карашы туп-туры егетнең күзләренә текәлде. Ромашов, куркудан бөтен тәне салкынаеп һәм йөрәге кысылып, тиз генә йорт почмагына таба чигенде. Күпмедер вакытка аны оялу хисе биләп алды. Хәтта күңелендә әлло кайтып китәргәме икән дигән уй да ялтырап куйды, әмма бераздан, шик-шөбһәләреннән арынып, калитканы ачты һәм кухняга керде.

Николаевлар денщигы аның пычрак калошларын салдырып, күн итекләрен чистарткан, ә ул үзе, ярым сукыр күзләрен җем-җем йома-йома, җылыга кергәч тә парланып киткән күзлек пыялаларын борын яулыгы белән сөртеп маташкан арада, кунак бүлмәсеннән Александра Петровнаның яңгыравык тавышы ишетелде:

— Ни бар анда, Степан, әллә приказ китергәннәрме?

«Көн дә нәкъ шушы вакытта килгәнемне белә югыйсә, ә шулай да сорый, юри сорый!» — дип, үз-үзен җәзалагандай, эченнән генә уйлап куйды подпоручик.

— Юк, бу мин, Александра Петровна! — дип кычкырды ул ясалма тавыш белән, кунак бүлмәсенең ишегенә таба башын борып.

— Ә! Ромочка! Ну, керегез, кер. Нәрсә анда тоткарландыгыз? Володя, бу — Ромашов килгән.

Ромашов, һич кирәксезгә учларын ышкый-ышкый, уңайсызланган кыяфәттә ничектер җилкәсен җыера төшеп, бүлмәгә узды.

— Мин сезне тәмам туйдырып бетердем бугай инде, Александра Петровна.

Моны ул үзенә бертөрле тәкәллефсез, күңелле сүз булыр дип әйтте, әмма чынында бу ничектер уңайсыз чыкты һәм, шундук үзе искәрүенчә, артык ясалма, гайре табигый булып тоелды.

— Ниткән сүз ди ул! — диде Александра Петровна, килешмичә.— Утырыгыз, хәзер чәй эчәрбез.

Ромашовның йөзенә игътибарлы, ачык күз карашын текәп, ул үзенең бәләкәй, йомшак, кайнар кулы белән, гадәттәгечә каты итеп, егетнең салкын кулын кысты.

Николаев әллә нинди сызым кәгазьләре, атласлар, китаплар өелгән өстәл янында аларга аркасын куеп утырган иде. Быел ул генераль штаб каршындагы хәрби академиягә имтихан тотарга тиеш, шуңа күрә ел буе бернинди ялсыз, бик тырышып, шуңа әзерләнә. Бу инде аның өченче

тапкыр имтихан тотуы, моңарчы ике ел рәттән ул уңышсызлыкка очрап кайткан иде.

Башын да борып карамыйча, алдындагы ачык китап битенә күзен текәгән килеш, Николаев җилкә аша гына Ромашовка кулын суздыһәм сабыр, калын тавыш белән:

— Исәнмесез, Юрий Алексеич. Яңалыклар юктыр бит? Шурочка! Чәй белән сыйла үзен. Гафу итегез инде, укыйсым бар,— диде.

«Их, шыр җүләр мин! Нигә килергә иде инде монда!» — дип, янә ачынып уйлап алды Ромашов.

— Юк, нинди яңалык булсын... Центавр гына җәмгыятьтә подполковник Лехның тетмәсен теткән, диләр. Тегесе дөм исерек булган, ди. Аннары һәрбер ротада карачкы чабу уены оештырырга куша... Епифанны арестка утыртты.

— Шулаймыни! — дигән булды Николаев гамьсез генә.— Кара син аны, ә?..

— Миңа да чәпәде — дүрт тәүлек... Кыскасы, бары да иске яңалыклар.

Тамагына төер тыгылгандай, Ромашов үз тавышын үзе танымады, ул ничектер кысылып, зәгыйфь булып чыкты. «Мин бик кызганыч күренәмдер, мөгаен!» — дип уйлап алды подпоручик, әмма шундук оялчан кешеләргә генә хас бер ышану белән күңеленнән үзен-үзе юатырга ашыкты: «Һай, оялган чакта гел шулай тоела бит ул: кеше синең уңайсызлануыңны күреп тора кебек, ә чынында ул синең халәтеңнең нинди икәнен бөтенләй күрми».

Ромашов, кыюланып, Шурочка янәшәсендәге креслога барып утырды. Шурочка, тамбур инәләрен ялт-йолт айкап, ниндидер челтәр бәйли иде. Гомумән, ул беркайчан эшсез утырмый, өйдәге эскәтер, тастымал, абажур, челтәр пәрдә ише нәрсәләрнең һәммәсе аның оста кулы белән бәйләнгән иде.

Егет йомгактан хатынның кулына таба сузылган җепне бармагы белән сак кына элеп алды да:

— Бу нинди бәйләү дип атала? — дип сорады.

— Гипюр — күпертеп бәйләү. Сез моны инде унынчы кат сорыйсыздыр.

Шурочка, башын калкытып, подпоручикка тиз һәм игътибарлы күз карашы ташлап алды да янә эшенә иелде. Ләкин шундук аңа яңадан күтәрелеп карады һәм көлеп җибәрде.

— Ә сез алай уңайсызланмагыз, Юрий Алексеич... утырыгыз, тынычлана төшегез. Ничек диләр әле сездә... «Төзәтенегез!» дип боералармы?

Ромашов, авыр сулап, Николаевның күк төстәге тужурка якасынан чыгып торган ап-ак таза муенына күз төшереп алды.

— Менә Владимир Ефимыч бәхетле кеше ичмасам,— диде ул.— Җәен Петербургка барыр... академиягә укырга керер.

— Һи, анысы билгесез әле! — дип, шукланып-чытлыкланып әйтеп куйды Шурочка.— Инде ике тапкыр хур булып полкка кире әйләнеп кайтты. Монысы инде — соңгы тапкыр.

Николаев җәлт кенә артына борылып карады. Аның кабарынкы мыеклы, мөлаем, хәрбиләрчә гайрәтле йөзе кызарынып чыккан, ә зур коңгырт күзләрендә усал очкыннар ялтырый иде.

— Җыен тузга язмаганны сөйләмәче, Шурочка! Сүзем сүз: мин академиягә барыбер керәчәкмен! — Николаев учының кырые белән каты итеп өстәлгә сукты.— Кирегә юрап утырма! Әйттем бит: сүзем сүз булыр!..

— Сүзем сүз булыр, имеш! — дип үчекләде хатыны һәм кара-кучкыл учының кыры белән, ире кебек үк, каты итеп үзенең тез башына сугып алды.— Ярый, алайса, әйт әле миңа: гаскәрнең сугышчан тәртибе нинди шартларга җавап бирергә тиеш? — Шулай дип, Шурочка көлемсерәгән шук күзләре белән Ромашовка карап куйды: — Беләсезме, тактика дигән нәрсәне мин аңардан яхшырак беләм бит. Йә, Володя, син, генераль ный штаб офицеры, әйт әле: нинди шартларга җавап бирергә тиеш?

— Зинһар, юкка бәйләнмәче, Шурочка,— дип, ризасыз төстә үзалдына мыгырданды Николаев.

Һәм кинәт урындыгы-ние белән берьюлы хатынына таба борылып утырды. Киң ачылган матур, бераз ахмаграк карашлы күзләрендә аптырау катыш бер курку галәмәте чыгылып китте.

— Туктале, тукта, кызкаем, мин бит чыннан да бөтенесен хәтерләмим шикелле. Гаскәрнең сугышчан тәртибе дисең? Гаскәрнең сугышчан тәртибе шулай төзелергә тиеш: ягъни, ул дошман утыннан мөмкин кадәр азрак зарарланырлык булсын, аннан аның белән җитәкчелек итү уңайлы булсын... Аннан... тукта...

— Туктаган атка чыбыркы төшә,— дип, Шурочка тантаналы төстә аны сүзеннән бүлде. Һәм, иң өлгер, алдынгы укучы бала кебек, керфекләрен түбән төшерде дә, чайкала-чайкала, тиз-тиз тезеп китте: — гаскәрнең сугышчан тәртибе таләп иткән шартлар түбәндәгеләр: тизлек-өлгерлек, хәрәкәтчәнлек, сыгылмалылык, җитәкчелек итүдә уңайлык,

җирле шартларга ярашучанлык; гаскәр дошман утыннан мөмкин кадәр азрак зыян күрергә, тиз арада фронт буенча җәелә яки бер урынга җыела белергә һәм кирәк тизлектә поход йөрү тәртибенә күчә алырга тиеш... Бетте!

Шурочка керфекләрен югары күтәрде дә, тирән сулыш алып, көләч, хәрәкәтчән йөзен Ромашовка таба борды:

— Ничек? Шәпме? — диде.

— Шайтан, хәтер дисәң дә хәтер! — дип, көнләшү катыш соклану белән әйтеп куйды Николаев һәм янә үзенең дәфтәрләренә чумды.

— Без бит һәммәсен бергә өйрәнәбез,— диде Шурочка, аңлатып.— Кирәксә, мин хәзер үк имтихан тота алыр идем. Иң мөһиме,— дип дәвам итте ул, тамбур инәсе белән һаваны ярып,— иң мөһиме — система. Безнең система — минем горурлыгым, аны мин үзем уйлап таптым. Һәр көнне без кисәкләп-кисәкләп аерым бер фәнне өйрәнәбез: бүген, әйтик, математикадан бер кисәк, иртәгә — хәрби фәннәрдән, тик менә артиллерия, бигрәк тә баллистика дигәнен генә яратмыйм: әллә нинди күңелсез формулалар, һич аңлый алмыйм,— аннары, әйтик, хәрби уставтан бер кисәк. Аннан көн аша ике чит телне өйрәнергә керешәбез, тагы бер көннән — тарих белән география.

— Ә рус теле? — дип сораган булды Ромашов ихтирам белән.

— Рус теле? Анысы — чүп. Грот китабыннан имла кагыйдәләрен җиңеп чыктык инде. Ә инша белән баш катырасы да юк. Һәр елны — бер үк темалар. «Para pacem, para bellum».[1] «Онегин образы һәм ул яшәгән чор»...

Һәм, кинәт, көтмәгәндә, ул, тәмам җанланып китеп, подпоручикның кулыннан, гүя Ромашов юк белән юанып маташмасын дигән сыман, җепне тартып алды да үзенең бүгенге тормышында иң мөһим, иң төп мәсьәлә итеп саналган кайгы-хәсрәтләре турында рухланып сөйләргә тотынды.

— Минем түземем бетте, бүтән мин монда кала алмыйм, Ромочка! Аңлагыз мине! Монда калу — ул, димәк, түбән тәгәрәү, гади бер полк дамасына әверелү дигән сүз; сезнең кыргый кичәләрегезгә йөреп, гайбәт сатып, интригалар оештырып, ниндидер тәүлекләр, юллар исәбенә бирелә торган юк-бар тиеннәр өчен талашып гомер уздыру... бррр... дус хатыннар белән чиратлашып әлеге җирәнгеч «бал-мәҗлесләр»дә, карта уеннарында көч түгү дигән сүз... Менә сез бездә бик уңай, рәхәт дисез. Ярый, әйләнә-тирәгездәге

[1] Тынычлык теләсәң, сугышка әзерлән.

бу мещан рәхәтлегенә җентекләбрәк бер карагыз әле! Менә бу үзем бәйләгән филе да гипюрлар, яңабаштан үзем үзгәртеп теккән менә бу күлмәк, менә бу җонлач корама келәм... Һай, һәммәсе дә косасыны китерә, косасыны китерә! Бернәрсәне аңлагыз, Ромочка, җаныем: минем бөтенләй бүтәнчә яшисем килә, миңа бүтән төрле тормыш — зур, чын тормыш, нурлы, музыкалы тормыш кирәк; анда табыну булсын, ихтирамлы-нәфис мөгамәлә, күңелле, акыллы сөйләшүче кешеләр булсын. Үзегез дә беләсез: Володя ниндидер дары-порохлар уйлап табардай кеше түгел, әмма ул — намуслы, тәвәккәл, эшсөяр, тырыш кеше. Генеральный штабка гына үтеп керә алсын, валлаһи дим, мин аңа менә дигән карьера ясап бирәм. Мин телләр беләм, теләсә нинди җәмгыятьтә үз-үземне тиешенчә тота беләм, миндә — ничек дип әйтим икән — үзенә бер төрле рухи сыгылмалылык бар, шуңа күрә мин теләсә кайда үз-үземне күрсәтә, теләсә нинди шартларга яраша алачакмын... Ниһаять, Ромочка, җаныем, бер миңа күтәрелеп кенә карагыз, игътибар белән карагыз. Шәхес буларак шундый кызыксыз, хатын-кыз буларак шундый ямьсез кешемени инде мин? Мин шушы фәкыйрьлек базында, бернинди географик картага да тамгасы төшмәгән шушы ташландык, хәшәрәт урында гомерем буе шулай пыскып яшәргә тиешмени?!

Шулай дип, Шурочка яулыгы белән йөзен каплады да горур, усал, үчле күз яшьләрен коя-коя үксеп еларга кереште.

Ире, хафага калып, аптыраулы кыяфәттә шундук аның янына йөгереп килде. Ләкин Шурочка ул арада үз-үзен тыеп өлгерде һәм йөзен ачты. Күзләрендә әле һаман усал, дәртле очкыннар ялтыраса да, ул инде еламый иде.

— Берни юк, Володя, берни, кадерлем,— диде ул, ирен кулы белән читкә этәреп.

Һәм, Ромашов кулыннан янә җеп сапламын тартып алып, чытлыклы, үртәүчән бер көлү белән аңа эндәште:

— Ягез, үшән аю, ник әйтмисез: чибәрме мин, әллә юкмы? Хатын-кыз мактау сүзе теләгәндә аны әйтмәү — бу чиктән ашкан әдәпсезлек!

— Шурочка, ничек оят түгел сиңа,— дип куйды Николаев өстәле янында утырган җиреннән. Ромашовның йөзенә оялчан-газаплы бер елмаю чыкты; аннан кинәт аз гына калтыравык һәм җитди, моңсу тавыш белән җавап бирде:

— Искиткеч чибәрсез!..

Шурочка чытырдатып күзләрен йомды да шукланып ба-

шын чайкап җибәрде. Аның чәчләре, маңгаена төшеп, сикерешеп куйдылар.

— Ро-омочка, нинди кызык кеше сез! — дип, балаларча нәзек тавыш белән көйләп әйтте ул.

Ә подпоручик, комачтай кызарынып, гадәтенчә, узалдына уйлап алды: «Аның йөрәгенә мәңге төзәлмәс яра салдылар...»

Күпмедер вакыт өчесе дә дәшми утырдылар. Шурочка иңәләрен ялт-йолт хәрәкәтләндереп бәйләвен бәйли. Владимир Ефимович, борын астыннан гына мыгырданып, Туссен һәм Лангеншейдт дәреслеге буенча немецчага җөмләләр тәрҗемә итеп маташа. Сары ефәк тукымадан шалашка охшатыбрак ясалган абажур астында тоныкъ кына чытырдап һәм чыжылдап лампа мае яна. Ромашов йомгак җебен бармагы белән янә элеп алды да, үзенә дә сизелмәслек итеп, аны хатын кулыннан әкрен-әкрен генә тарткаларга тотынды. Шурочка аңсыз хәрәкәт белән җепне һаман кулыннан ычкындырмаска тырыша — бу исә Ромашовның күңелендә нәзакәтле, рәхәт бер хис уята, гүя бу нечкә җеп буенча алар арасында бер-берсен бәйләп торган ниндидер серле, дулкынландыргыч ток йөри иде.

Шул ук вакытта ул берөзлексез, ләкин сиздермичә, кырыйдан хатынның бераз иелә төшкән йөзенә карап утырды һәм, иреннәрен чак кына кыймылдатып, гүя Шурочка белән хиссиятле, интим әңгәмә алып баргандай, үзалдына дәртле сүзләр пышылдады:

«Нинди кыю сорый: «Мин чибәрме?» ди. У-у, ничек кенә әле! Гүзәлнең гүзәле син! Бәгырькәем минем. Мин менә сиңа карап утырам — бу үзе генә дә чиксез зур бәхет! Тыңла алайса: мин сиңа синең нинди чибәр икәненне сөйлим. Тыңла. Син аксыл чырайлы, кара-тут йөзле. Дәртле йөз. Янып торган алсу иреннәр — аларның үбүе нинди татлы булырга тиеш! Ә күзләрең? Тирәли саргылт шәүлә яткан бу күзләреңнең агы, туры караганда, чак кына күкселләнеп тора, ә зур түгәрәк бәбәкләре, гүя тирән диңгез өстедәй, күгелҗем, куе-болганчык төскә керә. Сине брюнет дип әйтеп булмый, шулай да синдә ниндидер чегән кыяфәте бар. Аның каравы баш артына балаларча эшлеклелек белән бер төенгә пөхтәләп җыйналган чәчләреңнең шундый чиста, шундый нәфис ки,— иректән, аларга кул белән орынып аласы килә. Кечкенә генә, җиңел генә син үзең, мин сине сабый баладай кулыма күтәреп йөртә алыр идем. Әмма көчле икәнлегең сизелеп тора, гәүдәң сыгылмалы, күкрәгең кызларныкы кебек калку,— гомумән, бөтен барлыгың белән ашкынулы, җитез-дәртле бер хатын син. Сул як чи-

гәндә, колагың астындарак, алка эзе сыман, бер миңең бар,— белəсеңме, ничек килешə ул сиңа...»

— Офицерлар арасындагы атышу турында газетадан бер хəбəр укыган идегезме? — дип сорап куйды кинəт Шурочка.

Ромашов, сискəнеп, күз карашын хатыннан теләр-телəмəс читкə күчерде.

— Юк, укымадым. Ләкин ишеттем. Ə нəрсə?

— Шулай инде, гадəттəгечə, сез берни укымыйсыз. Чынлап, Юрий Алексеевич, сез һаман түбəн тəгəри барасыз. Минемчə, монда ниндидер мəгънəсезлек килеп чыккан булырга тиеш. Əлбəттə, офицерлар арасында атышу — зарури, акылга сыя торган күренеш. Анысын мин аңлыйм.— Шурочка кул эшен тəэсирле бер кыяфəттə күкрəгенə кысты.— Ләкин дорфалык нигə? Уйлап карагыз: бер поручик икенче бер офицерны дорфа сүз белəн рəнжеткəн. Бик каты рəнжеткəн: офицерлар җəмгыяте шундук атышу турында карар чыгарган. Ләкин менə шул моменттан башлана да инде иң мəгънəсез дигəне. Атышу шартлары — чын-чыннан үлем карары диярсең: ара — унбиш адым, атышу бер як каты яра алганчыга кадəр дəвам итəргə тиеш. Ягъни атышучыларның икесе дə аяк өсте басып калса, дуэль яңадан кабатлана. Белмим, нəрсəдер бу... хайван сую белəн бер бу! Ләкин, сабыр итегез, болары чəчəкләре генə əле. Дуэль урынына полкның бар офицерлары җыела, кайберләренең хатыннарына хəтле килə, рəсемгə төшерер өчен əрəмəлеккə хəтта бер фотограф та кереп поса. Коточкыч хəл бит бу, Ромочка! Шуннан шул: мескен подпоручик, Володя əйтмешли, фендрик, менə сезнең кебек яшь кенə бер егет, җитмəсə əле рəнжетүчесе түгел, рəнжетелүчесе, өченче тапкыр атышудан соң корсагына төзəлгесез каты җəрəхəт ала да шул көннең кичендə үк газап эчендə җан бирə. Ə өендə əни-карчыгы белəн кыз туганы — кияүгə чыкмаган апасы ялгыз утырып кала. Алар өчесе бергə яшəгəн булалар, менə безнең Михиннар кебек үк... Йə, əйтегез, зинһар: дуэльне шундый канлы тамашага əверелдерү кемгə кирəк тə, нəрсəгə кирəк? Шунысын да истə тотыгыз: бу əле хəзер, дуэльгə рөхсəт бирелүнең беренче көннəрендə шулай. Менə мин əйтте диярсез,— дип сүзен дəвам итте Шурочка, күзləреннəн очкыннар чəчрəтеп,— дуэльне тыю тарафдарлары, əлеге куркак җанлы, сентименталь либераллар — о, мин ул хəшəрəтлəрне яхшы беләм! — озакламый тагы гауга куптарачаклар: «Кыргыйлык бу! Вəхшилек калдыгы! Үз туганыңның канын кою!» — дип ахвах киләчəкләр.

— Шулай да сез шактый аяусыз кеше, Александра Петровна! — дип сүз кыстырды Ромашов.

— Юк, аяусыз түгел, юк! — диде Шурочка, килешмичә.— Мин кызганучан кеше. Мин муенны кытыклап йөргән бөҗәкне дә рәнҗетмичә, саклык белән алып ташларга тырышам. Ләкин сез, Ромашов, шуны аңлагыз: монда логика бик гади. Офицерлар нәрсә өчен кирәк? Сугыш өчен. Сугышта кешедән беренче чиратта нәрсә таләп ителә? Кыюлык, горурлык, үлемгә туры карый белү. Тыныч заманда бу сыйфатлар кайда ачыграк гәүдәләнә соң? Дуэльдә, әлбәттә. Менә шул. Аңлашыладыр, шәт. Дуэльнең нәкъ менә француз офицерларына кирәге юк,— чөнки намус төшенчәсе, җитмәсә әле, күпертелгән төшенчәсе, һәрбер французның канына сеңгән; дуэль шулай ук немец офицерына да зарури түгел, чөнки немецлар тумыштан ук һәммәсе намуслы һәм тәртипкә күнеккән булалар. Дуэль ул безгә, безгә кирәк! Ул чакта офицерлар арасында Арчаковский кебек карта шулерлары да яки сезнең Назанскиегыз шикелле дөм исерек бәндәләр дә очрамас иде. Офицерлар җәмгыятендәге бер-береңне үртәү, хезмәтчеләр алдында тәкәллефсез сүз көрәштерү — әлеге сезнең үзара дорфалыкларыгыз, сүгенүләрегез, бер-берегезгә төбәп тә, әмма тидермәскә тырышып, графиннар белән атышуларыгыз — һәммәсе, һәммәсе үзеннән-үзе бетәр, юкка чыгар иде. Ул чакта инде сез тегендә дә, монда да бер-берегезне сүгеп, яманлап йөрмәс идегез. Офицерның һәр сүзе уйлап әйтелгән булырга тиеш. Офицер — ул әдәплелек үрнәге. Ахыр чиктә, каян килгән иркәлек — атышудан курык, имеш! Сезнең кәсеп — тәвәккәллек, гомерне уенга салу! Аһ, нигә сөйләп торам соң!

Шулай дип, Шурочка чытлыкланып сүздән туктады һәм яңадан эшенә чумды. Бүлмә тагы тынып калды.

Бераздан түрдә өстәл янында утырган Николаев башын китаптан калкытты да сорап куйды.

— Шурочка, «көндәш» сүзен немецчага ничек дип тәржемә итәргә?

— «Көндәш»? — дип кабатлады Шурочка уйчан төстә, бәйләү инәсе белән үзенең йомшак чәчләренә орынып.— Ә син бөтен җөмләсен әйт.

— Монда ул болай... хәзер, хәзер... «Безнең чит ил көндәшебез...»

— Unser ausländischer Nebenbuhler,— дип, шундук тәржемә итеп бирде Шурочка.

— Унзер, унзер,— дип шыпырт кына кабатлады Ромашов, лампа утына таба хыялый күзләрен тегәп.— «Дулкын-

ланган чагында аның сүзләре гел шулай ачык яңгырап, тиз-тиз чыга,— дип уйлады ул.— Көмеш поднос өстенә вак ядрә коела диярсең». Унзер — нинди көлке сүз... Унзер, унзер, унзер...

— Сез нәрсә анда пышылдыйсыз, Ромочка? — диде кинәт Александра Петровна кырыс тавыш белән.— Саташып сөйләнүләрегезне ташлагыз минем алда.

Ромашов битараф бер елмаю белән елмаеп куйды.

— Саташып сөйләшүем түгел бу... Әлеге сүзне кабатлап утырдым: унзер, унзер. Нинди көлке сүз мәйтәм...

— Монысы ни тагы?.. Унзер? Аның нәрсәсе көлке?

— Ничек дип аңлатыйм икән,— диде Ромашов, сүзен башларга белмичә.— Әйтик, нинди дә булса сүзне кат-кат кабатлап, аның мәгънәсен уйлый башласаң, ул кинәт кенә асыл мәгънәсен югалта да... сезгә ничек дип әйтергә?..

— Ah, беләм, беләм! — дип, ашыгып аның сүзен бүлде Шурочка шатлыклы тавыш белән.— Тик хәзер ул алай җиңел бирелми шул, ә менә элегрәк, бала чакта,— ah, нинди күңелле була торган иде!..

— Әйе, әйе, нәкъ менә бала чакта. Шулай шул.

— Соң, бик яхшы хәтерлим. Аеруча гаҗәеп тоелган бер сүз әле дә хәтеремдә. «Бәлки» сүзе иде ул. Утырган җиремдә тирбәлә-тирбәлә, күземне йомып, гел шул сүзне кабатлый торган идем: «Бәлки, бәлки...» Шулай кабатлый торгач, сүзнең асыл мәгънәсе бөтенләй онытыла, теләсәң дә һич искә төшереп булмый. Ике койрыклы ниндидер кызтылт-көрән тап сурәтендә килеп баса иде ул минем күз алдыма. Шулай бит, ә?

Ромашов аңа сөеп-иркәләп карап куйды.

— Нинди сәер: безнең икебездә дә бер үк төрле фикерләр икән,— диде ул әкрен генә.— Ә унзер миңа, беләсеңме, чага торган угы булган ниндидер озын, чандыр бер җан ияседәй тоела. Әйтик, озынча, нәзек бер бөҗәк сыман. Үзе бик усал, зәһәрле дә, имеш.

— Унзермы? — диде Шурочка, башын күтәреп, һәм Ромашов сөйләгән сурәтне хыялында сынландырырга телә-тәндәй, күзләрен кыса төшеп, беравык бүлмәнең түрге, караңгы почмагына текәлеп торды.— Юк, сабыр итегез: бу ниндидер яшел төстәге, чәнечкеле нәрсә. Әйе, әйе шул, нәкъ үзе — бөҗәк! Чикерткә сымаграк нәрсә, тик аңардан күп мәртәбә хәшәрәтрәк һәм яманрак. Фу, икебез дә шулкадәр хыялый булырбыз икән, Ромочка.

— Ә тагын менә болай да була,— дип, серле тавыш белән янә сөйләп китте Ромашов.— Анысы да бала чакта ачыграк, тәэсирлерәк күренә торган иде. Мәсәлән, нинди

дә булса бер сүзне аласың да, аны мөмкин кадәр озаграк сузып әйтергә тырышасың. Һәр авазын, хәрефен шулай чиксез сузарга тырышасың. Кинәт шундый сәер, шундый сәер бер мизгел җитә ки, синең әйләнә-тирәңдә гүя бөтен нәрсә юкка чыга. Дөньяда яшәвем, сөйләшүем, уйлавым — һәммәсе миңа шул чакта гаҗәеп, гайре табигый булып тоела торган иде.

— У-у, андый хисне мин дә беләм! — дип элеп алды Шурочка, дәртләнеп.— Тик миндә ул икенче төрлерәк була иде. Мин, әйтик, көчем җиткәнчә сулышымны кысам да, үзалдыма болай дип уйлыйм: менә, янәсе, мин суламыйм, менә хәзер дә суламыйм, тагы суламыйм, фәлән вакыткача, фәлән вакыткача суламыйм... Әнә шул чакта сез әйткән теге хис туа да инде. Мин вакытның үз янымнан узуын тоям. Юк, алай түгел: гүя, вакыт дигәне үзе дә юк кебек. Моны сүз белән аңлатып булмый.

Ромашов, сокланулы күз карашын Шурочкага төбәгән килеш, бәхетле, тонык-әкрен тавыш белән аның сүзләрен җөпләп кабатлады:

— Әйе, әйе... моны аңлатып булмый... Бик сәер бу... Аңлатырлык түгел...

— Әй, сез анда... кем дим... психолог әфәнделәр димме... җитәр шикелле, кичке ашны ашарга вакыт,— диде кинәт Николаев, өстәле яныннан торып.

Озак утырудан аның аяклары оеп, биле авырта башлаган иде. Ул тураеп басты да, күкрәген киереп, кулларын бөтен көченә югары сузып җибәрде, һәм шушы гайрәтле хәрәкәт-киерелүдән аның зур, таза гәүдәсенең барлык буыннары берьюлы шартлап, шыгырдап куйды.

Кечкенә булса да, шактый күркәм, пөхтә җыештырылган һәм аксыл-тонык төстәге асылмалы лампа нурларына чумган аш бүлмәсендә салкын закускалардан табын әзерләнгән иде. Николаев үзе эчми, шулай да өстәл өстендә Ромашов өчен дип бер графин аракы да куелган иде. Шурочка, сөйкемле йөзен чытып, һәрвакыттагыча, Ромашовтан сүз аралый гына сорап куйды:

— Сез инде, әлбәттә, бу юньсез нәрсәдән башка һич булдыра алмыйсыз, әйеме?

Ромашов гаепле төстә елмайды, кабаланудан аракысы ялгыш юлга китеп, ютәлләргә тотынды.

— Ничек оят түгел сезгә! — дип, акыл өйрәткәндәй, янә сүзгә башлады хуҗа хатын.— Үзегез әле эчә дә белмисез, ә шулай да... Ярар, сезнең әлеге яраткан Назанскиегыз эчсен дә дию, ул барыбер беткән кеше инде, ләкин сезгә нигә кирәк? Үзегез шундый яшь әле, әйбәт, сәләтле егет,

ә шулай да аракысыз табынга утырмыйсыз... Йә, ни өчен? Назанский боза булса кирәк сезне.

Николаевка әлерәк кенә приказ китергәннәр иде. Ул, шуны укыган җиреннән бүленеп, кинәт сүзгә кушылды:

— Назанский дигәннән, ул шәхси сәбәпләр аркасында бер айга ялга китә икән. Тю-тю-у! Димәк — эчүгә сабышкан. Сез, Юрий Алексеич, аны күргәлисез бугай бит? Нәрсә ул, әллә ычкынганмы?

Ромашовның уңайсызланудан керфекләре җем-җем йомылды.

— Юк шикелле, мин сизмәдем. Хәер, эчкәли бугай...

— Сезнең ул Назанскиегыз — сөйкемсез кеше! — диде Шурочка тамак төбеннән чыккан калын, ачулы тавыш белән.— Миннән торса, мин андыйларның һәммәсен эттәй атып үтерер идем. Андый офицерлар — полк өчен хурлык, җирәнгеч!

Николаев, фәннәр белән шөгыльләнгәндәге кебек үк, ризыкны да тырышып һәм күп итеп ашады. Ашап бетергәч тә авызын зур ачып иснәргә тотынды, ахырда ачыктан-ачык күңелендәге уен әйтеп салды:

— Әфәнделәр, бераз йоклап алсак ничек булыр икән? Борынгы күңелле романнарда әйтмешли, аз гына «черем» итсәк диюем.

Ромашов аның тәкъдимен шундук,— үзенә калса, артык ашыгычлык һәм ялагайлык белән элеп алды шикелле.

— Ифрат дөрес фикер, Владимир Ефимыч,— диде ул. Үзе күңеленнән уйлап куйды: «Әйе, монда минем белән бигүк исәпләшеп тормыйлар шул. Нигә дип килеп йөрим икән мин аларга?»

Николаев аны ничектер куана-куана куып чыгарадыр төсле тоелды аңа. Шулай булса да, саубуллашкан чагында кулын юри беренче аңа сузды һәм менә хәзер Шурочканың иркәләүле, каты кул кысуын тоячакмын дигән татлы уйдан күңелендә чиксез ләззәт кичерде. Николаевлардан чыгып киткәндә аны гел шундый уйлар биләп ала иде. Инде, көткән мизгел җитеп, Шурочка аның кулына орынгач, ул шулкадәр онытылып ләззәтләнде ки, хәтта Шурочканың әйткән сүзләрен дә ишетмәде:

— Карагыз аны, безне оныта күрмәгез. Без сезгә һәрвакыт шатбыз. Назанскиегыз янында аракы чөмереп утырганчы, безгә килүегез хәерлерәк. Тик исегездә тотыгыз: без сезнең белән бик хәтер саклап тормабыз.

Бу сүзләрнең асыл мәгънәсен Ромашов бары урамга чыккач кына аңлап алды.

— Әйе, минем белән бик хәтер саклап тормыйлар шул,— диде ул, үзалдына пышылдап.

Мин-минлеге көчле һәрбер яшь кешегә хас булганча, бу сүзләр ачынулы, тирән бер рәнҗү белән әйтелделәр.

V

Ромашов болдырга чыгып басты. Төн гүя тагы да куера, караңгылана төшкән һәм баягыдан җылырак тоела иде. Ромашов, кулы белән капшана-капшана, читән коймага тотынгалап алга атлады һәм күзе караңгыга ияләшкәнче туктап бераз басып торды. Ул арада Николаевлар кухнясының ишеге ачылып, бер генә мизгелгә төнге караңгыда томандай соргылт зур яктылык шәүләсе күренеп алды. Кемнеңдер лач-лоч пычрак ерып атлаган аяк тавышы ишетелде. Ул да булмады, Николаевлар денщигы Степанның ачулы тавышы яңгырады:

— Йөри шунда көн саен эч пошырып. Нәмәстәгә йөри, шайтан белсен!..

Подпоручикка ят икенче тавыш исә, озак итеп иснәнеп торганнан соң, һичнәрсәдә гаме булмагандай, иренеп кенә җавап бирде:

— Эше төшкәндер, нигә исең китә... Майларына чыдый алмыйлар. Ярар, хуш иттек, Степан туган.

— Сау бул, Баулин. Кергәлә.

Ромашов читәнгә сыенып катты. Караңгы булса да, хурланудан ул бөтен бите кызарып кызышуын тойды. Тәненә эссе тир бәреп чыкты, аяк һәм арка тиресенә меңләгән инә кадалгандай, берьюлы тетрәнеп куйды. «Җитәр! Хәтта денщикларына хәтле көлә!» — дип уйлады ул, ачынып. Күз алдына шундук бүгенге кичә килеп басты, һәм анда сөйләнгән сүзләрдә, ул сүзләрнең әйтелү рәвешләрендә, үзара бер-берсенә төбәлеп-төбәлеп алган күз карашларында моңарчы Ромашовка сизелмәгән әллә ничаклы яңа вак мәгънәләр ачылып киткәндәй булды. Бу соңгылары аны бу өйдә һич яратмауларын, киресенчә, туйдырып бетергән кунак буларак, аңа үртәлүле сабырсызлык белән көлеп, мәсхәрәләп карауларын раслаучы бер дәлил булып тоелдылар.

— Нинди хурлык, нинди хурлык! — дип пышылдады подпоручик, урынныннан кузгалмыйча.— Шундый хәлгә кал инде: синең күзгә күренүеңне дә яратмасыннар!.. Юк, җитте. Хәзер миңа бөтенесе ачык: бүтән монда килмим!

Николаевларның кунак бүлмәсендә ут сүнде. «Хәзер алар йокы бүлмәсенә кергәннәрдер»,— дип уйлап алды Ромашов һәм ятар алдыннан аларның, күптән өйләнешкән

кешеләргә хас гадәти оятсызлык белән, бер-бере каршында ничек гамьсез генә чишенүләрен, һәм шул чакта үзара сөйләшүләрен ап-ачык итеп күз алдына китереп бастырды. Әнә Шурочка юбкадан гына килеш көзге каршында төнгә чәчләрен рәтли. Владимир Ефимович бер кат эчке күлмәктән караватта утыра һәм, кызарына-бүртенә көчәнеп, итекләрен салып маташа, үзе ачу катыш йокылы тавыш белән Ромашовны сүгә: «Беләсеңме, Шурочка, синең ул Ромашовыңнан мин мең болай гарык булдым. Гажәпләнәм, аның белән нигә вакыт уздырып маташасыңдыр син?» — ди. Ә Шурочка, авызына капкан шпилькаларын алмыйча һәм иренә таба борылып карамыйча гына, көзгегә төбәлеп, үртәлүле тавыш белән җавап бирә: «Ул минем Ромашов түгел, ә синең Ромашовың!..» — ди.

Ромашов шушындый ачынулы, газаплы уйлар эчендә әле тагын биш минут чамасы басып торды, шуннан соң гына урыныннан кузгалды. Николаевлар йорты каршындагы читән койма буеннан ул бик сагаеп, ниндидер яман эштә тотылудан курыккан кеше сыман, аяк астындагы пычракны чупырдатмыйча, тавыш чыгармыйча гына узарга тырышты. Өйгә кайтасы килми иде: үзенең бер тәрәзәле тар, озынча бүлмәсен, андагы эчпошыргыч, җирәнгеч әйберләрне күз алдына китерү генә дә аның күңелен болгатты, йөрәктә коточкыч курку тудырды. «Ярар алайса, *үзенә үк үч итеп,* тотам да Назанский янына барам, — диде ул кинәт, катгый бер карарга килеп, һәм үзендә шундук ниндидер үчлекле бер канәгатьләнү хисе тойды. — Назанский белән дуслыгым өчен битәрләгән идең, инде менә үзеңә үпкәлә! Юри үч итеп барам!..»

Күзләрен күккә төбәп һәм кулын күкрәгенә куеп, ул эчке бер ялкын белән үзалдына өстәп әйтте: «Ант итәм: бу минем аларга соңгы килүем. Бүтән мондый мәсхәрәгә калырга теләмим. Ант итәм!»

Һәм шундук, гадәте буенча, күңеленнән уйлап куйды: «Аның тәэсирле, матур кара күзләрендә тәвәккәллек һәм нәфрәт очкыннары ялтырады!»

Гәрчә аның күзләре бөтенләй кара түгел, ә гап-гади күзләр — яшькелт каймалы соргылт күзләр иде.

Назанский үзенең дусты поручик Зегржт квартирында аерым бүлмә алып тора иде. Хезмәттә үрнәк тәртипле һәм төрек сугышында катнашкан булуына карамастан, бу Зегржт бөтен рус армиясендә, шәт, бердәнбер иң карт поручик булгандыр. Явыз язмыш аркасындамы, нәрсәдәндер, ул дәрәҗә баскычында шул поручиклыктан һич югары күтәрелә алмаган. Үзе ул тол, янында дүрт яшь баласы бар;

шулай булса да, кырык сигез сум жалованьесына тормышын ничектер очын-очка ялгап бара. Ул, йорт хуҗалары белән зур-зур квартирлар килешеп, шуларның һәр бүлмәсенә буйдак офицерлар кертеп тота, тавык һәм күркә үрчетә, ягар өчен утынны да ничектер арзан бәягә һәм вакытында сатып алу җаен таба иде. Балаларын ул үзе карый: аларны тагараста коендыра, авырган чакларында өй аптечкасындагы дарулар белән дәвалый, тегү машинасында алар өчен күлмәк-штан ише нәрсәләр тегә. Әле өйләнгәнчегә кадәр үк, буйдак офицерларның күбесе кебек, ул хатынкыз һөнәрләре белән мавыккан һәм күп кенә кул эшенә өйрәнгән булган. Хәзер аны ул эшләр белән шөгыльләнергә мохтаҗлык мәҗбүр итә иде. Явыз теллэр: ул үзенең кул эшләрен яшерен рәвештә каядыр сатар өчен дә озата икән дип сөйлиләр иде.

Әмма хуҗалык итүдәге бу вак шөгыль-хәйләләрнең ярдәме бик аз иде. Кош-кортны төрле үләт авырулары кыра, бүлмәләрнең күбесе буш, сирәк-мирәк кереп торучылар исә ашау-эчү начар булуга зарланалар, фатир хакын түләмиләр. Һәм әледән-әле, елына дүрт-биш мәртәбә, шәһәр урамнары буйлап тирли-пешә акча эзләп йөргән озын-чандыр гәүдәле Зегржтны күрергә була иде. Аптыраулы йөзен сакал баскан, башында — козырегы ян якка авышкан белен сыман фуражка, ә өстендә — Николай заманы фасонында сугышка кадәр үк тегелгән борынгы шинель; аның җилбәгәй ачылган чабулары, кош канатлары сыман, арттан җилфердәп бара.

Хәзер аның квартир бүлмәләрендә ут булып, Ромашов тәрәзәләрнең берсе янына килде дә эчкә карады. Асылмалы лампа астындагы өстәл янында, пеләш башын түбән иеп, җыерчыклар сызгалаган йөзле, юаш-күндәм чырайлы Зегржт утыра, кулында — киндер кисәге, ул аңа кызыл җеп белән ниндидер бизәкләр чигә иде. Малорус күлмәге өчен изү-күкрәкчә иде ахрысы бу.

Ромашов тәрәзә пыяласын шакыды. Зегржт, сискәнеп китеп, эшен бер читкә куйды да тәрәзә каршына килде.

— Бу мин, Адам Иванович. Бер генә секундка ачыгызчы,— диде Ромашов.

Зегржт, тәрәзә төбенә менеп, форточка аша урам якка ямьшәйгән сирәк сакаллы пеләш башын чыгарды.

— Сезме, подпоручик Ромашов? Ни кирәк иде?

— Назанский өйдә микән?

— Өйдә булмый, кая китсен? Өйдә, өйдә. Ай, ул Назанскиегыз сезнең, тәмам башымны катырды,— диде Зегржт, сакалын селкеп.— Икенче ай инде аңа ашарына

бирдерәм, ә аның түләрмен дигәненнән башка берни эшләгәне юк. Монда күчеп килгәч тә мин әйттем аңа, күңелсезлекләр чыгуын теләмәсәң, мәйтәм...

— Әйе, әйе, әйе... чыннан да... шулай... — дип, Зегржтның сүзен бүлде Ромашов, артык игътибар итмичә, — ә ни хәлдә ул үзе, әйтегез әле? Аны күрергә мөмкин булыр микән?

— Булыр, минемчә, бик булыр... Бүлмәсендә туктаусыз килеп сарып йөри.— Зегржт бер генә мизгел тыңланып торды.— Әнә хәзер дә йөренә. Аңлыйсызмы, теге чакны мин аңа ачыктан-ачык әйттем: түләүне, мәйтәм, күңелсезлекләр чыкмас борын...

— Гафу итегез, Адам Иванович, мин ашыгам,— дип, Ромашов аны яңа сүзеннән бүлде.— Рөхсәт итсәгез, бүтән бер вакыт керермен. Бик ашыгыч эш иде.

Ромашов, ары узып, йорт чатыннан өй арты бакчасына борылды. Түрдә, Назанский бүлмәсендә, ут яна иде. Бер тәрәзә төбенә кадәр үк ачып куелган. Назанский үзе, сюртуксыз-нисез, изүе ачык эчке күлмәктән, бүлмәсендә ишекле-түрле йөри; аның ак гәүдәсе һәм җирән чәчле башы тәрәзә уентыгы аша әле күренеп китә, әле тәрәзә ара стеналары артында күздән югала иде. Ромашов тәрәзә каршындагы койма аркылы эчкә узды да хуҗага исеме белән дәште.

Назанский, үзенә дәшүләрен инде күптән көтеп торгандай, ачык тәрәзәдән гәүдәсен ярым тышка чыгарып, тыныч-сабыр тавыш белән:

— Кем ул анда? — дип сорады.— Ә, сезме, Георгий Алексеич? Туктагыз: ишеккә барып йөрү ерак та, караңгы да. Әйдәгез, тәрәзәдән генә керегез. Бирегез кулыгызны.

Назанскийның бүлмәсе Ромашовныкыннан да фәкыйрьрәк иде. Стена буенда, тәрәзәгә терәлеп, уртасы дуга сыман түбән сыгылып төшкән тар, тәбәнәк карават тора, ул шундый арык-ябык ки, аның тимерләре өстендә алсу төстәге юка киже-мамык юрганнан башка берни дә юк дип уйларга мөмкин. Икенче як стена буенда — гади агач өстәл белән шундый ук шыксыз ике урындык. Бер почмакка, кивотка охшатып, озынча шкаф сыман нәрсә уеп куелган. Карават астында ян яклары тимер юл кәгазьләре белән чуарланып беткән сары күн чемодан ята. Өстәл өстендәге лампаны исәпләмәгәндә, бүлмәнең бөтен җиһазы менә шушы әйберләрдән гыйбарәт иде.

Назанский, җете зәңгәр, матур, моңсу күзләре белән туп-туры Ромашовның күзенә текәлеп, аның күрешергә сузылган кулын озак кына кысып-селкеп торды.

— Исәнмесез, кадерлем. Әйдәгез, менә монда — караватка утырыгыз. Ишеткәнсездер инде, мин бит, авыруым сәбәпле, ял сорап рапорт бирдем?

— Ишеттем. Бу турыда миңа әле генә Николаев әйтте.

Ромашов, бая денщик Степан әйткән коточкыч сүзләрне янә исенә төшереп, газапланган төстә чыраен чытты.

— Э! Николаевларда булдыгызмыни? — дип сорады Назанский, үтә кызыксынучан дәртле тавыш белән.— Сез аларга еш барып йөрисезме?

Назанскийның бу сорауны гадәттәгедән үзгә тон белән бирүе Ромашовны ничектер инстинктив рәвештә сагайта калды, һәм ул ирексездән ялганларга мәҗбүр булды:

— Юк ла, кая ул еш барып йөрү! Болай, очраклы гына кереп чыккан идем,— дип, юри гамьсезрәк итеп җавап кайтарды.

Әле һаман бүлмә буйлап киләп сарып йөргән Назанский кинәт почмактагы озынча шкаф каршында туктады да аның капкачын ачты. Шкаф шүрлегендә графин белән аракы һәм юка итеп, матурлап киселгән алма телемнәре күзгә чалынды. Назанский, кунакка аркасы белән басып торган килеш, рюмкага ашыга-ашыга аракы салды һәм эчеп җибәрде. Аркасының юка тукыма күлмәк эченнән көзән җыергандай ничек калтыранып куюын Ромашов бик ачык күрде.

— Теләмисезме? — диде Назанский, шүрлеккә таба ымлап.— Закускасы рәтле түгел түгелен, шулай да, ачыккан булсагыз, йомырка тәбәсе әмәлләргә мөмкин. Борынгы кешегә — Адәм галәйәссәламгә йогынты ясарга мөмкин.

— Рәхмәт. Мин соңыннанрак.

Назанский, кулларын кесәгә тыгып, бүлмәне бер әйләнеп килде дә, өзелгән әңгәмәне дәвам иттергәндәй, янә сүз башлады:

— Эйе. Һаман менә шулай уйлана-уйлана бүлмәдә киләп сарып йөрим. Һәм, беләсезме, мин бәхетле. Иртәгә полкта һәммәсе: Назанский эчә башлаган, фәлән дә төгән дип сүз куертачаклар. Ни дим, ихтимал, шулай сөйләүләре дөрес тә булыр, ләкин хикмәт анда гына түгел. Мин авырмыйм да, газап та чикмим, мин бәхетле. Көндәлек тормышта минем акыл һәм ихтыярым басылып яши. Андый чакта мин урталык дип йөртелгән ач, куркак гавам белән тәмам кушылып бетәм, үз-үземә әшәке, күңелсез тоелам, алны-артны карап эш итүчән, салкын канлы бер кешегә әвереләм. Мәсәлән, хәрби хезмәтне җенем сөймәми минем, шулай да хезмәт итәмен. Ни өчен дисезме? Ни өчен икәнен шайтан белсен! Ихтимал, шуңадыр: бала чагымда минем колакка

гел бер нәрсәне тукыдылар,— хәер, хәзер дә бөтенесе шуны ук сөйли,— янәсе, тормышта төп максат — ул хезмәт итү, тук яшәү, киенү-ясану! Ә фәлсәфә, диләр алар, чүп нәрсә, ул эшсез кешегә, әнисеннән зур мирас алып калган җилкуарга гына килешә, диләр. Менә шуңа күрә дә мин тормышымда күңелем бөтенләй ятмаган әллә нинди нәрсәләрне эшлим, хайвани курку хисенә буйсынып, кайчак үземә артык рәхимсез яки хәтта мәгънәсез тоелган боерыкларны да күндәм рәвештә үтәп барам. Минем яшәвем — солдат сукносыдай тоташ соры, койма тактасыдай җансыз, бертөрле. Мәхәббәт, матурлык, кешелек дөньясына мөнәсәбәт, табигать, адәмнәр арасындагы тигезлек, шигърият, алла — менә болар турында кая ул кычкырып сөйләү, хәтта күңелемнән уйларга да җөрьәт итә алмыйм мин. Чөнки алар көләчәкләр: ха, ха, ха, бу бит — фәлсәфә, диячәкләр!.. Гаскәри пехота офицерына югары материяләр хакында баш вату көлке яки килешми генә түгел, бөтенләй ярамый, диячәкләр! Шулай итеп, бу фәлсәфә дигәнең, шайтан алгыры, бөтенләй кирәксез чүп, мәгънәсез лыгырдау булып чыга.

— Ләкин тормышның мәгънәсе шунда лабаса,— дип куйды Ромашов уйчан төстә.

— Әнә шул чакта инде минем яшәешемдә алар шундый шәфкатьсез исем белән атаган әлеге чор башлана,— дип дәвам иттерде Назанский, Ромашовның сүзенә колак та салмыйча. Ул һаман бүлмәнең кара-каршы ике почмагы арасында әрле-бирле йөренә һәм вакыт-вакыт, Ромашовтан бигрәк шул почмакларга карап, куллары белән мәгънәле ишарәләр ясап ала иде.— Бу — минем азатлык чорым, рухи, ихтыярый, гаклый азатлык чорым, Ромашов! Әнә шундый чакта гына мин тыштан, бәлки, сәер тоелган, әмма эчтән ифрат мәгънәле, гүзәл, тулы тормыш белән яши башлыйм! Күз күргән, колак ишеткән, китаптан укыган бөтен нәрсә миндә кинәт кенә җанланып китә, гадәттән тыш бер нур белән балкып, иксез-чиксез тирән мәгънәгә ия була. Хәтерем — гүя сирәк ачышлар, уй-фикерләр музее диярсең! Аңлыйсызмы — мин Ротшильд! Хәтеремә төшкән беремче уй-фактны эләктереп алам да, аның турында озак итеп, җентекләп, тәмләп-тәмләп фикер йөртә башлыйм. Әйтик, аерым шәхесләр турында, очрашулар, холыклар, китаплар, хатын-кызлар турында — ах, бигрәк тә әнә шул хатын-кызлар, хатын-кыз мәхәббәте турында!.. Кайчакта минем уйны үткәндәге бөек кешеләр, фән юлында газап чигүчеләр, хакимнәр һәм хәкимнәр, аларның әйтеп калдырган гаҗәеп сүзләре биләп ала. Мин аллага ышанмыйм,

Ромашов, шулай да кайчакны бик дәртләнеп төрле дини шәхесләр — әүлиялар, пәйгамбәрләр, дин өчен газап чигүчеләр турында уйланам, хәтерем күгендә дини канунарны, күңел нечкәрткеч акафистларны тергезәм. Мин бит, кадерлекәем, бурсада укыган кеше, хәтерем коточкыч шәп минем. Шулай уйлана торгач, бер заман күңелем шулкадәр йомшара ки, чит кешенең шатлыгы яки кайгысы, яки тарихтагы берәр үлемсез батырлыкның гүзәллеге белән тәмам тәэсирләнеп, менә хәзергечә, ялгыз башым бүлмәдә ишекле-түрле йөри башлыйм һәм... җылыйм — кайнар, дәртле күз яшьләре коя-коя җылыйм...

Ромашов караваттан әкрен генә торды да, ачык тәрәзә төбенә күчеп, аркасы белән тәрәзә яңагына сөялеп утырды, ә аяк табаннарын каршы як яңакка терәде. Моннан, яктыртылган бүлмә эченнән караганда, төн тагы да караңгырак, тагы да тирәнрәк һәм серлерәк булып күренә иде. Бер әкренәеп, бер көчәеп, әмма тавышсыз искән җылы җил тәрәзә каршындагы ниндидер тәбәнәк куакларның кара яфракларын кәлтырата. Һәм язгы хуш исләр белән тулы бу йомшак һава, бу тынлык, караңгылык, утлы күмер сыман ничектер артык җете балкыган бу йолдызлар — болар һәммәсе туфракта, үсемлекләр, агачлар арасында, гомумән бөтен табигатьтә барган серле, дәртле бер кузгалышны, тудыру-яңаруга бәйле комсыз сусауны, бетмәс-төкәнмәс юмартлыкны сиздереп тора иде.

Назанский исә бүлмә буйлап өзлексез йөренде дә йөренде һәм, Ромашовка игътибар итеп тормастан, фәкать почмак-стеналар белән генә әңгәмә куерткандай, дәртләнеп сөйли бирде:

— Андый чакта фикернең агышы ничектер бормалысырмалы, чуар һәм көтелмәгәнчәрәк була. Акыл үткенләнә, яктыра, хыял — ташкын сыман ургыла! Хәтергә китергән бар әйберләр, кешеләрнең йөзләре күз алдына шундый искиткеч ачык сурәттә килеп баса ки, әйтерсең лә мин аларны камеробскур эчендә берьюлы күрәм. Аңлыйм, аңлыйм, кадерле дустым, бу рухи яктыру, хисләрнең бу киеренке төгәллеге — кызганычка каршы! — бары алкогольнең нерв системасына ясаган физиологик тәэсире генә, шуның нәтиҗәсе генә. Башта, беренче тапкыр үземдә шундый сәер рухи күтәренкелек халәте кичергәндә, мин моны чынчын илһамлану дип уйлаган идем. Баксаң, һич алай түгел икән: монда иҗади башлангычның әсәре дә юк, хәтта фикер дәвамлылыгы да юк. Гадәти хасталык, саташу гына бу. Кисәк-кисәк ярга китереп бәргән һәм, бәргән саен, яр

астын күбрәк ашый барган дулкын шикеллерәк нәрсә. Әйе. Ләкин шулай булса да бу саташу миңа татлы... шуңа күрә менә әйтәм дә: җан асрап, киләчәккә өмет баглап яшәүләр шайтанга олаксын дим... Озак яшәү үрнәге дигән булып, берәр газета почмагына йөз ун яшькә җитеп үлде, фәлән дә төгән дип язып чыгуларының миңа һич хаҗәте юк... Мин бәхетле — хикмәт менә шунда!

Назанский янә почмактагы шүрлек янына килеп, араҡы салып эчте һәм капкачын ипләп ябып куйды. Ромашов, аңсыз рәвештә дигәндәй, иренеп кенә урыныннан торып, Назанский эшләгән эшне кабатлады. Аннан тагы тәрәзә төбенә барып утырды да:

— Мин килер алдыннан сез нәрсә турында уйлый идегез соң, Василий Нилыч? — дип сорады.

Ләкин Назанский аның соравын бөтенләй ишетмәде диярлек, түрге почмакка таба атлап китте дә, шул почмакка гына эндәшкәндәй, куллары белән киң, мәгънәле ишарә ясап, дәртләнеп кычкырды:

— Мәсәлән, хатын-кыз турында хыяллану — бу үзе генә дә нинди ләззәт бит! Пычрак уй белән хыяллану түгел, юк! Анысы нигә? Кешене беркайчан да, хәтта уйда-фикердә дә, явызлыкка катнашучы, бигрәк тә пычрак эшкә катнашучы итеп күрергә ярамый. Хатын-кыз турында хыялланганда мин күбрәк саф йөрәкле, иркә-назлы, нәфис хатын-кызлар, аларның чиста, самими күз яшьләре, мөлаем елмаюлары турында уйланам, тугрылыклы, тотнаклы яшь аналар, мәхәббәт өчен үлемгә барган сөяркәләр, һәрнәрсәдән хәбәрдар булып, бернидән дә курыкмаган, әмма гыйффәтлекләрен саклаган инсафлы, кардай ак җанлы, горур, чибәр кызлар турында уйланам. Андый хатын-кызлар юк. Хәер, дөрес түгел. Андый хатын-кызлар, мөгаен, бардыр, әмма без сезнең белән, Ромашов, аларны беркайчан да күрмәячәкбез. Сез, бәлки, күрерсез дә, ләкин мин үзем — юк, күрмәячәкмен.

Назанский хәзер Ромашовның каршысына ук килеп басып, туп-туры аның йөзенә текәлеп сөйли, ләкин күз карашының үтә хыялый, иреннәренә кунган елмаюының артык серле, билгесез булуыннан Назанскийның үз әңгәмәдәшен һич кенә дә шәйләми икәнлеген абайлап була иде. Ромашов аны әле беркайчан да, хәтта иң аек, иң саф дигән минутларында да, бу кадәр матур, сөйкемле кеше итеп күргәне юк иде. Саргылт чәчләре, эре, тоташ учмаларга аерылып, биек, чиста-ак маңгае тирәли салынып төшкән, дүртбүкәл формадагы зур булмаган куе, җирән сакалы исә, бәләк

сыры сыман, тигез дулкынланып, күкрәге өстенә яткан. Гомумән, аның зифа, ачык муенлы зур-салмак нәфис башы Ромашов кайдадыр гравюраларда гына күргән борынгы грек геройлары яисә хәкимнәренең гүзәл бюстларын хәтерләтә иде. Чак-чак кына дымланып торган саф, зәңгәр күзләренең карашы җанлы, акыллы һәм тыйнак-сабыр. Бу чибәр йөз хәтта үзенең тигез яткан нечкә-нәфис алсу төсе белән дә гажәпләндерә, һәм бары тик бик тәҗрибәле күз генә аның беркадәр шешенке булуын һәм әлеге тышкы алсулыкта алкогольдән ялкынсынган бозык кан тәэсирен күрә алыр иде.

— Мәхәббәт! Хатын-кызга мәхәббәт! Бу төпсез хисләр упкынында нинди генә серләр юк! Нинди генә ләззәт-бәхет, нинди генә ачы, татлы газап юк! — дип, тәмам рухланып, кычкырып җибәрде кинәт Назанский.

Ул, чиксез дулкынланудан ике кулын баш очына чөеп, чәчләрен учлап тотты да почмакка ташланды, анда барып җиткәч, туктап, йөзе белән Ромашовка таба борылып басты һәм шаркылдап көлеп җибәрде. Подпоручик шөбһә эчендә аны күзәтә иде.

— Көлке бер вакыйга исемә төште әле,— дип, ачык чырай белән, гади генә сөйләп китте Назанский.— Их, фикерләремне әйтәм, ничек сикерешәләр!.. Бервакыт миңа Рязаньның «Ока» станциясендә пароход көтеп утырырга туры килде. Шәт, тәүлеккә якын көткәнмендер,— язгы ташу вакыты иде бу,— шуңа күрә,— әлбәттә, сезгә аңлашыла инде, — мин буфет тирәсенәрәк оя кордым. Ә буфетта унсигез яшәрлек бер кызый эшли — ямьсез, шадра битле, әмма үзе ифрат кыю, өлгер, күзләре кара янып тора, матур итеп елмая белә, ахыр чиктә — шактый сөйкемле кызый. Станциядә без өчәү генә — әлеге кыз, мин һәм аксыл чәчле, кечкенә буйлы бер телеграфист. Хәер, кызның атасы бар икән әле,— кызыл, симез битле, чал чәчле бер кеше, нәкъ менә карт, усал бурзай этенең танавы диярсең. Ләкин ул буфетта бөтенләй күренми диярлек. Күренсә дә, буфет өстәле артында бер-ике минут йокылы кыяфәттә, жилеты астыннан корсагын кашый-кашый, иснәнеп басып тора да тагы йокларга кереп китә. Ә менә телеграфчы егет гел шунда. Әле дә күз алдымда: терсәкләре белән өстәл кырыена таянган да дәшмичә тик басып тора. Кыз да дәшми, күзләрен тәрәзәгә текәгән, ташкын суларны тамаша кыла. Кинәт егет ярым көйләп җыр сүзләре әйтеп куя:

Лю-юбовь — что такое?
Что тако-ое любовь?

Это чувство неземное,
Что волнует нашу кровь [1].

Аннан тагын дәшми. Ә биш минуттан шул ук җыр сүзләрен авыз эченнән кызый көйли башлый: «Любовь — что такое? Что такое любовь?..» Үтә зәвыксыз бер көй инде, чамалыйсыздыр. Күрәсең, сәхнәдәме, берәр опереттадамы җырлаганны отып алган булганнардыр... Шуны тыңлар өчен, бәлки, шәһәргә җәяү барып йөргәннәрдер әле... Шул. Җырлап-җырлап алалар да тагы тыналар болар. Ахырда кызый, күзен әле һаман тәрәзәгә текәгән килеш, гүя ялгыш кына, абайламастан, кулын өстәл өстендә онытып калдыргандай итә, ә тегесе аны учларына җыеп ала да әкрен генә бармаклары белән уйный башлый. Тагы «Любовь — что такое?..» кабатлана. Урамда — яз, ташу, моңсу талгынлык. Кыскасы, бу тәүлек буе шулай дәвам итте диярлек. Ул чакта бу «мәхәббәт» мине шактый җиләткән иде җиләтүен, әмма хәзер, беләсезме, аны хәтергә төшерү дә күңелне ничектер нечкәртеп җибәрә. Алар бит мин килгәнче үк атналар буе шул манерда сөешеп юанган булганнардыр. Ихтимал, мин киткәч тә айлар буе шулай дәвам иткән булуы мөмкин. Моның нинди зур бәхет икәнлеген мин соңыннан гына аңладым. О, безнең мәгънәсез тормышыбыз белән чагыштырганда йөз мәртәбә чикләнгәнрәк тормышта — мин әлеге яшьләрнең фәкыйрь, тар-кысан, караңгы тормышын әйтәм,— бу балкып торган искиткеч бер нур бит!.. Хәер... Сабыр итегезче, Ромашов. Зиһенем бутала. Телеграфист турында нәрсә дип башладым соң әле сүзне?

Назанский янә шкаф каршына барып туктады. Ләкин эчмәде, Ромашовка аркасы белән баскан килеш, уң кулын югары күтәреп, чигәсенә терәде дә, сул кулының учы белән, гасабиланып, маңгаен ышкырга тотынды. Бу нервлы хәрәкәттә ниндидер кызганыч көчсезлек, мескенлек ачык сизелә иде.

— Сез хатын-кызга булган мәхәббәт турында — хисләрнең төпсез упкыны, серләр, бәхет-шатлыклар турында сөйли идегез,— диде Ромашов, аның исенә төшереп.

— Әйе, мәхәббәт турында! — диде Назанский тантаналы тавыш белән. Ашыга-кабалана рюмканы авызына каплады да, уттай янган күзләрен елтыратып, Ромашовка таба борылып басты һәм күлмәк җиңе белән тиз генә авызын

---

[1] Мәхәббәт — ул нәрсә,
Нәрсә ул мәхәббәт?
Безне яндырган-көйдергән
Илаһи бер хис ул.

сөртеп алды.— Әйе, мәхәббәт турында! Аны хәзер кем аңлый соң? Мәхәббәтне хәзер ташландык судай шакшы, җирәнгеч оперетталар, оятсыз рәсемнәр, тозсыз анекдотлар, чиркангыч шигырьләр белән бергә бутап бетерделәр. Моны без, офицерлар, эшләдек. Кичә миндә Диц булды. Нәкъ менә сез утырган урынга — тәрәзә төбенә утырган иде ул. Алтын кысалы пенснесе белән шаяра-уйный, гел хатын-кызлар турында сөйләнде. Ромашов, җаныкаем, әгәр дә этләр, әйтик, кеше телен аңлый торган булып, шуларның берсе кичә Дицның сүзләрен тыңласа, ул эт, валлаһи дип әйтәм, оялуына түзә алмыйча шундук бүлмәдән чыгып чабар иде. Сез беләсез — Диц әйбәт кеше; хәер, без һәммәбез дә әйбәт, Ромашов: асылда әшәке кешеләр юк. Ләкин Диц хатын-кыз турында башкача сөйләргә ояла, чөнки үзенең циник дигән, азгын, җиңүче дигән данын югалтудан курка. Монда ниндидер уртак бер ялгыш караш бар, ниндидер ясалма егетлек, хатын-кызны санга сукмауны ирлек дип санаган ниндидер мактанчыклык бар. Һәм моның сәбәбе шунда дип уйлыйм: күпчелек өчен мәхәббәттә, хатын-кыз белән кушылуда,— аңлыйсыздыр, мин монда чын мәгънәсендәге кушылуны әйтәм,— ниндидер хайвани тупаслык, үземнеке генә дигән ниндидер эгоистик хис,— әй, шайтан! ничек дип әйтергә дә белмим,— ниндидер үтә түбән, хурлыклы, азгын бер теләк яшеренеп ятадыр төсле. Шуңа күрә дә күпчелек ирләр кушылудан соң күп тә үтми салкынаеп калалар, аларның күңелләрендә кинәт җирәнү, нәфрәт хисе барлыкка килә. Шуңа күрә дә кешеләр мәхәббәт өчен, шулай ук караклык-угрылык өчен дә, тәүлекнең төнге вакытын сайлап алганнар. Бу мәсьәләдә, җаныкаем, табигать үзе үк кешеләр өчен җим һәм элмәк белән ниндидер яшерен капкын әзерләп куйган.

— Дөрес,— диде Ромашов әкрен, моңсу тавыш белән.

— Юк, дөрес түгел! — дип кычкырды Назанский, килешмичә.— Ә мин әйтәм: дөрес түгел дим. Табигать, һәрбер мәсьәләдәге кебек, монда да дәһиларча дөрес уйлаган. Хикмәт тик шунда: Диц өчен мәхәббәтнең нәтиҗәсе — күңел кайту, тую, җирәнү, ә менә Данте өчен ул — мәңгелек яз, соклану, бәйрәм! Юк, юк, сез ялгыш уйламагыз: мин нәкъ менә туры мәгънәсендәге, тәнви мәхәббәт турында әйтәм. Ләкин андый мәхәббәт — сирәк шәхесләр өлеше. Менә сезгә бер мисал: һәрбер кешедә музыкаль сизем бар, әмма миллионлаган күпчелектә ул сизем дәрәҗәсе, әйтик, треска балыгындагы яки безнең штабс-капитан Васильченкодагы кебек кенә, ә шул миллионнарның берсе — Бетховен... Һәрнәрсәдә шулай: поэзиядә, рәсем сәнгатендә, хә-

кимлектә... Мәхәббәтнең дә, мин сезгә әйтим, шундый биеклек дәрәҗәләре бар, аның иң югары ноктасына миллионнардан бик сирәк шәхесләр генә менеп җитә ала.

Назанский тәрәзә яшына килеп басты, чигәсе белән тәрәзә яңагына сөялде дә, уйчан күзләрен төнге җылы караңгылык эченә тегәп, күкрәк төбеннән калтырап чыккан тәэсирле тавыш белән яңа сөйләп китте:

— Их, мәхәббәтнең күзгә күренмәс яшерен, нечкә-нәфис ләззәтләрен кадерли белмибез шул әле без. Тупаслар без, тар карашлы, иренчәк кешеләр без. Беләсезме, җавапсыз, өметсез мәхәббәттә генә дә никадәр төрле-төрле шатлык-бәхетләр, никадәр татлы газаплар яшеренгән? Яшьрәк чагымда минем бер хыялым бар иде: үземнән буй җитмәс өстен, гадәттән тыш затлы бер хатын-кызга гашыйк булам да, имеш, гомеремне дә, бөтен уй-эшләремне дә аңа багышлыйм, имеш. Әлбәттә, минем аның белән бернинди уртаклыгым юк һәм булырлык та түгел. Аңа көнлекче, лакей, кучер булып ялланаммы, хәйләлимме, кыяфәтемне үзгәртәммме — миңа барыбер, тик мәгъшукамны елына бер мәртәбә генә булса да күрә алыйм, баскыч басмасына аның аягы баскан эзне үбә алыйм! Йа ходай, гомеремдә бер мәртәбә аның кигән күлмәгенә орына алу — бу үзе генә дә әйтеп бетергесез бәхет, ләззәт бит!

— Алай бик тиз акылдан язуың да мөмкин,— дип куйды Ромашов караңгы чырай белән.

— Аһ, җаныкаем, барыбер түгелмени! — диде Назанский, дәртләнеп, һәм нервлы адымнар белән янә бүлмә буйлап атлап китте.— Кем белә, нәкъ менә шул чакта сез, бәлки, әкияттәгедәй тылсымлы тормыш белән яши башларсыз. Ярар, яхшы: сез әлеге гажәеп, тиңдәшсез гыйшык утында янып акылдан шаштыгыз, ә поручик Диц үзенең акылын көчәя барган параличы һәм төрле яман авырулары аркасында югалтты, ди. Кайсысы хәерлерәк? Аның каравы, уйлап кына карагыз, нинди зур бәхет бит: сез, урамның бер ягына яшеренеп, төне буе мәгъшукагызның йорт тәрәзәсен күзәтеп чыгасыз. Менә йортта ут алына, пәрдәдә кемнәндер күләгәсе тирбәлә. Бәлки, аның күләгәседер? Нәрсә эшли икән ул? Ни уйлый икән? Менә ут сүнә. Тыныч йокы сиңа, сөеклем, тыныч йокы, җанкисәгем!.. Сезнең көн мәгънәле узды — бу җиңү түгелмени! Хәйлә, тапкырлык, сабырлык тулы шундый тырыш хезмәттә көннәр, айлар, еллар үтә, һәм менә, ниһаять, күз алды караңгыланырдай тиңсез бөек шатлык: синең кулыңда — аның кулъяулыгы, ул ташлаган конфет кәгазе яки ул төшереп калдырган афиша! Ул үзе синең турыда берни белми, синең

хакта беркайчан ишетмәячәк тә, аның күзләре, игътибар итмичә, синең йөзеңнән шуып кына уза, ләкин син шунда, аның янында басып торасың — аның өчен,— юк, ник аның өчен булсын,— аның капризы өчен, ире, яраткан кешесе, сөйгән эте өчен гомереңне, намусыңны, кыскасы — бирә алырдай бөтен нәрсәңне дә корбан итәргә әзер булып янында басып торасың! Ромашов, мондый гүзәл шатлык хисен әлеге жиңү яулаучылар, тәти егетләр беркайчан да татый алмыйлар.

— Һай, шулкадәр дөрес сүзегез! — диде Ромашов, тәэсирләнеп. Ул инде тәрәзә төбеннән күптән торып, озынча тар бүлмә буенча Назанский сыман ишекле-түрле йөри башлаган иде.— Башыгызга нинди генә уйлар килми! Сезгә үзем турында да сөйлим әле. Мин бер... хатынга гашыйк булган идем. Мондагы хәл түгел, юк... Мәскәүдә чакта әле... юнкер чагымда. Тик хатын үзе минем гыйшык тотуымны белмәде. Аның янында утыру искиткеч рәхәт була торган иде миңа. Берәр нәрсә бәйли башласа, жебен эләктереп алам да, аны әкрен генә үземә таба тарткалый-тарткалый, тик утырам шулай. Бөтен булганы шул. Ә ул үзе берни тоймый да, күрми дә. Минем исә бәхеттән башлар әйләнә...

— Әйе, әйе, аңлыйм,— дип, күңелле һәм көләч елмая-елмая, баш какты Назанский.— Бик яхшы аңлыйм сезне. Бу — ниндидер тимер чыбык, электр тогы сымаграк нәрсә, шулаймы? Ниндидер нечкә, назлы бер аралашу чарасы кебек? Их, Ромашов, жаныем, тормыш дигәнең шәп нәрсә шул ул!..

Назанский, үз фикерләренә үзе тәэсирләнеп, бер мәл тынып торды; зәңгәр күзләре, мөлдерәмә яшь тулып, елтырап киттеләр. Ромашовны да, күңеле тулып, кызгану сымаграк ниндидер талгын-йомшак бер хис биләп алды. Бу хис бер үк дәрәҗәдә аның үзенә дә, Назанскийга да карый иде.

— Василий Нилыч, гажәпләнәм мин сезгә,— диде ул, Назанскийның ике кулын да учларына алып кысып.— Сез шундый сәләтле, сизгер йөрәкле, киң күңелле кеше, шул үк вакытта үзегезне әнә... юри харап итәргә тырышасыз шикелле. О, юк, сезгә ниндидер эч пошыргыч үгет-нәсихәтләр бирергә теләмим, һич юк... Мин үзем дә... Ләкин еш кына минем башка шундый уй килә: әгәр тормыш юлыгызда сезне кадерли белә торган, сезгә лаек хатын-кыз очраган булса, нишләр идегез икән дим?

Назанский, йөренүеннән туктап, бик озак ачык тәрәзәгә төбәлеп торды.

— Хатын-кыз димсез... — дип сузды ул уйчан кыяфәт-

тә.— Ярар! Сөйлим алайса! — диде кинәт, катгый бер карарга килеп.— Әйе, гомерем юлында миңа чыннан да бер мәртәбә шундый искитмәле, гадәттән тыш хатын-кыз белән очрашырга туры килде. Кыз кеше белән... Ләкин, беләсезме, һейнедә ничек диелә әле: «Кыз мәхәббәткә лаек, шуңа егет тә аны ярата иде; әмма егет үзе мәхәббәттән түбән, шуңа кыз аны яратмады». Әлеге кыз да мине эчкәнем өчен яратмады... хәер, кем белә, мин, бәлки, нәкъ менә кыз мине яратмаганы өчен эчә башлаганмындыр. Ул... ул шулай ук мондагы кеше түгел... күптән булган хәл бу. Сез үзегез дә беләссез бит: өч ел хезмәт иткәннән соң, мин запаска чыктым, аннары, моннан өч ел элек, тагы полктагы хезмәтемә кайттым. Кыз белән безнең арада роман дигән нәрсә булмады. Нибары унбиш-унбишәр тапкыр очрашу, бишмеалтымы тапкыр күзгә-күз сөйләшеп утыру. Ләкин шулар күңелдә мәңге сүнмәс хатирә булып калыр дип кем уйлаган? Менә шулай, минем бөтен байлыгым — үткәннең шул гөнаһсыз хатирәләреннән гыйбарәт. Ул кызны мин әле булса яратам. Сабыр итегез, Ромашов... Сез ышанычка лаек кеше. Мин сезгә аның миңа язган бердәнбер хатын — беренче һәм соңгы хатын укып бирим.

Назанский чемоданы каршына чүгәләде дә андагы ниндидер кәгазьләр арасыннан ашыга-ашыга кирәкле хатны эзләргә кереште. Шул ук вакытта сөйли торган сүзен дә дәвам итте:

— Ихтимал, ул үзеннән башка беркемне дә, беркайчан да сөймәгән булгандыр. Аңарда ниндидер горур бер усаллык, чиксез бер хакимдарлык бар сыман иде. Шул ук вакыт кеше белән мөгамәләдә — искиткеч әйбәт, ягымлы, ифрат мөлаем. Берүзендә ике кеше сыйфатларын сыйдырган диярсең: бер якта — кырыс, эгоистик акыл, икенче якта — ашкынучан, дәртле, нечкә күңел. Менә аның хаты, укыгыз, Ромашов. Өстә язылганы сезгә кирәкми.— Назанский өстәге берничә юлны аска таба бөкләп куйды.— Менә бу төшеннән. Укыгыз.

Әйтерсең, Ромашовның башына ниндидер ят нәрсә белән китереп суктылар — бөтен бүлмә эче аның күз алдында берьюлы чайкалып куйды. Хатның кемнеке икәнен таныды ул. Эре, нечкә сызыклы, тигезсез нервлы хәрефләр белән бормалап-сырмалап язылган, үтә үзенчәлекле, нәфис бу почерк бары Александра Петровнаныкы гына булуы мөмкин иде. Ромашов аңардан еш кына аш табынына яки карта уйнарга чакырып язган запискалар алгалый, шуңа күрә ул әлеге почеркны мең хат арасыннан да секунд эчендә танып алган булыр иде.

«...ул хакта тел әйләндереп әйтергә дә кыен һәм газаплы,— дип укыды Ромашов, Назанскийның кулы астыннан хатка күзен тегәп.— Ләкин безнең танышлыкның шундый аянычлы нәтиҗәгә килүенә сез үзегез гаепле. Дөньяда мине иң хурландырган нәрсә — алдашу; кешенең куркаклыгыннан, йомшаклыгыннан килә ул. Шуңа күрә мин сезнең алда алдашырга теләмим. Мин сезне ярата идем һәм хәзер дә яратам — бу хистән котылу алай тиз һәм минем өчен җиңел булмаячагын да яхшы беләм. Ләкин ахыр чиктә мин аны барыбер җиңеп чыгачакмын. Минем өчен башка юл юк. Ни өченме? Әлбәттә, әхлакый яктан түбән тәгәрәгән, бозылган, ихтыяр көчен югалткан бер ир янында шәфкать туташы, нәнә, тәрбияче булып торырга миндә җитәрлек куәт, фидакарьлек тә табылган булыр иде булуын, ләкин андый кызгану, андый хурлыклы, берьяклы шәфкатьлелек хисен минем җенем сөйми, шулай ук сезнең дә андый хисне минем күңелдә уятуыгызны теләмим. Сезнең эттәй тугрылык, күндәмлек һәм кызгану сәдакасы исәбенә сыенып яшәвегезне теләмим. Ә сез, никадәр генә акыллы, яхшы күңелле кеше булсагыз да, бүтәнчә эшли алмыйсыз. Дөресен әйтегез, ихластан әйтегез: бүтәнчә эшли алмыйсыз бит, шулаймы? Эх, Василий Нилыч, жаныкаем, әгәр сез моны эшли алсагыз иде шул, эшли алсагыз иде! Минем бөтен йөрәгем, бөтен хыялларым сезгә ашкына, мин сезне үлеп яратам. Әмма мине сез үзегез теләмәдегез. Яраткан кешең өчен бөтен дөньяны астын өскә әйләндерергә мөмкин, ә сездән мин бик аз нәрсә сораган идем. Сез булдыра алмыйсыз, шулай бит?

Хушыгыз. Сезне... мәетне үпкән сыман... маңгаегыздан үбәм, чөнки сез минем өчен үле инде. Киңәшем шул: бу хатны ертып ташлагыз. Мин кемнәндер курка дип түгел, ә бу хат киләчәктә сезнең үзегезнең күңелдә газаплы, юксынулы истәлекләр уятмасын дип ертып ташлагыз. Тагы бер мәртәбә кабатлыйм...»

— Калганы сезнең өчен кызык түгел,— диде Назанский, хатны читкә алып.— Бу аның миңа язган бердәнбер хаты.

— Шуннан соң ни булды соң? — диде Ромашов, телен көчкә әйләндереп.

— Шуннан соңмы? Шуннан соң без аның белән очрашмадык. Ул... ул каядыр китеп барды, аннары кемгәдер... бер инженергамы шунда... кияүгә чыккан бугай. Алары — вак мәсьәлә...

— Һәм шул минуттан бирле сезнең Александра Петровналарга бүтән барганыгыз да юкмы?

Моны Ромашов ишетелер-ишетелмәс тавыш белән пы-

шылдап кына әйтте, әмма ике офицер да бу сүзләрдән сискәнеп китеп, бер-берсенә бик озак карашып тордылар. Шул берничә секунд эчендә алар арасындагы барлык киртәләр — хәйлә, кылану, яшеренлек киртәләре гүя берьюлы юкка чыкты һәм үзара бер-берсенең күңел хисләрен иркенләп укырлык бер мөнәсәбәт урнашты. Моңарчы сер итеп саклаган күп нәрсәләрне алар шундук аңлап алдылар, нәтиҗәдә аларның бүгенге сөйләшүләре дә кисәк кенә бөтенләй икенче төрле мәгънә — тирән, үзгә, фаҗигый бер мәгънә белән өретелгәндәй булды.

— Ничек? Сез дә — шулай ук мәллә? — диде ниһаять Назанский, куркынган, шашынкы күз карашын Ромашовка төбәп.

Ләкин, шундук исенә килеп, ясалма бер көлү белән сүзне икенчегә борды:

— Фу, әллә ниләр сөйли башладык! Каядыр читкә кереп киттек. Әлеге сезгә күрсәткән хат бик күптән язылган хат ул, аны язучы хатын үзе дә хәзер әллә кайда ераста,— ялгышмасам, Кавказ таулары артында яши бугай инде... Хуш, без нинди сүздә туктаган идек әле?

— Миңа кайтырга вакыт, Василий Нилыч. Соң инде,— диде Ромашов, урыныннан торып.

Назанский кыстап маташмады. Бер-берсеннән оялгандай, алар, артык салкын да, коры да түгел бер чырай белән, тизрәк хушлашырга ашыктылар. Әлеге хатны Шурочка язган икәненә Ромашов хәзер бигрәк тә инанган иде. Юлда кайтканда ул гел шул хат турында уйланды һәм аның үзендә нинди хисләр уятканын аныкларга тырышты. Монда Назанскийдан, дөресрәге, аның үткәненнән көнләшү дә, бүгенге аянычлы хәленә бәйле нинди мәкер-тантана катыш кызгану да бар иде, ләкин бер үк вакытта Ромашов үзенең күңеле төбендә ниндидер яңа бер хис — әлегә томанлы, карангы, әмма гаять татлы һәм өмсендергеч өмет хисе кыймылдап куюын да ачык тойды. Гүя әлеге хат аның кулына да киләчәк бәхеткә илтә торган ниндидер тылсымлы, күзгә күренмәс бер җеп тоттырган иде.

Җил басылган. Төн тирән тынлыкка чумып, аның караңгылыгы ничектер бәрхет сыман һәм җылы тоела. Әмма мәңге уяу һаваның үзендә, күзгә күренмәс агачларның талгын сабырлыгында, җир сулышында серле, ижади тереклек хәрәкәте сизелә. Ромашов юлны күрми атлап барды һәм аяк атлаган саен каршысында кинәт нинди дә булса кодрәтле, илаһи, ягымлы бер нәрсә күтәрелеп чыгар да аның йөзенә кайнар сулышын бөркеп җибәрер дип көтте. Аның

җаны сагыш белән тулы иде. Ул ерак-еракта, бала чакларда мәңгегә калган нурлы язлар турында сагышланып уйлады, эчкерсез бер көнләшү хисенә бирелеп, назлы сабыйлык вакытларын күз алдына китерде...

Өенә кайтса, өстәл өстендә Раиса Александровна Петерсоннан килгән икенче записка ята иде. Хатын анда, мәгънәсез сүзләр һәм чиктән ашкан һавалану белән, үзенең мәкерле рәвештә алдануы, мәсхәрә ителүе һәм хәзер, шулай алдануын белгәч, аяусыз төстә үч алырга керешәчәге турында бәян итә иде.

«Хәзер нәрсә эшләргә икәнен мин яхшы беләм! — диелгән иде хатта.— Сезнең бу кабахәт тотышыгыз мине чәхоткалап, кабергә кертми калса, белегез: минем үчем аяусыз булыр! Кичнең-кич саен кая барып йөргәнегезне беркем дә белмидер дисез мәллә? Юк, ялгышасыз! Стеналарның да колагы бар. Миңа сезнең һәр адымыгыз мәгълүм. Ләкин барыбер: сез үзегезнең телегез һәм кыяфәтегез белән *анда* берни дә майтара алмаячаксыз, аның соңында, N сезне өеннән көчек баласын тибкәләп чыгаргандай куалап чыгарачак. Ә минем белән сак кыланырга киңәш итәм. Рәнҗетелүне кичерә торган хатыннардан түгел мин!

Владеть кинжалом я умею,
Я близ Кавказа рождена!!![1]

Әүвәл сезнеке булган, хәзер
беркемнеке дә түгел
Раиса.

P. S. Киләсе шимбәдә җәмгыять җыенына килми калмагыз. Безгә аңлашырга кирәк. Сезнең өчен өченче кадрильне калдырам, тик бу юлы ул инде *туры мәгънәсендә булмас.*

Р. П.»

Надан, буталчык бу хаттан Ромашовка провинция сазлыгы, әшәкелек һәм явыз гайбәтнең бөтен сасы исләре бөркелеп киткәндәй булды. Шушы чит-ят, сөйкемсез хатын белән ярты елга якын сузылган шакшы элемтә гүя аның үзен дә баштанаяк әлеге юып бетергесез пычракка буяп куйган иде. Ромашов, бүген кичергәннәреннән тәмам мәнсезләнгән хәлдә, караватка барып ятты да, йокыга китешли, кичен Назанскийдан ишеткән сүзләрне үз шәхесенә кайтарып, үзалдына уйлап куйды:

---

[1] Хәнҗәр белән эш итә беләм,
Чөнки Кавказ буенда туган кыз мин.

«Аның фикерләре солдат сукносыдай тоташ соры иде».

Тиздән ул каты, авыр йокыга талды. Һәм, ачынулы кичерешләрдән соң һәрвакыт булгандагыча, төшендә үзен бәләкәй малай итеп күрде. Гүя пычрагы да, сагышы да, эчпошыргыч тормыш бертөрлелеге дә — һичбере юк; бөтен нәрсә пакь, тәндә дәрт кайный, күңел якты, саф, анда аңсыз бер куаныч хисе уйный. Дөнья үзе дә саф һәм нурлы, ә шул дөньяның нәкъ урта бер җирендә — Мәскәү, аның сөйкемле, таныш урамнары; алар төштә генә була торган ниндидер тылсымлы, үзгә бер нур белән балкыйлар. Ләкин кайдадыр ераста, элеге нурлы дөньяның офыкка барып терәлгән чигендә, шомлы, дәһшәтле бер зур тап караеп күренә. Бу — шулай читтә посып утырган ямьсез, күңелсез бер шәһәрчек, имеш. Анда — эчпошыргыч һәм авыр солдат хезмәте, рота мәктәпләре, эчкече офицерлар җәмгыяте, сөймәгән хатын белән җирәнгеч элемтә, ялгызлык һәм сагыш. Бөтен дөнья шатлык нурына коенып шаулый, әмма элеге шомлы, дәһшәтле тап, кара өрәк сыман, яшертен генә Ромашовны сагалый, аны эләктерер өчен үз чиратын көтә, имеш. Менә ул аны инде эләктереп тә алган, үзенә таба өстери. Фәкать бәләкәй Ромашов — саф күңелле, гөнаһсыз, кайгы-хәсрәтсез сабый Ромашов кына,— үзенең өлкән җисемдәшенең ераклаша һәм шомлы караңгылык эчендә эрегәндәй югала баруын күреп, ачы күз яшьләре белән үксеп елап кала, имеш.

Төн урталарында Ромашов, уянып, башын күтәреп карады һәм мендәренең күз яшеннән дымлануын күрде. Уянгач та ул бик озак елавыннан туктый алмый ятты: кайнар яшь тамчылары, бер-беренә тоташып, аның юеш яңаклары буйлап бертуктаусыз тәгәриләр дә тәгәриләр иде.

VI

Кайбер карьерист һәм шөһрәт сөючеләрне исәпләмәгәндә, полкта офицерларның һәммәсе диярлек гаскәри хезмәтне яратмый һәм аңа җаннарын тәмам биздереп бетергән, эчпошыргыч, мәҗбүри бер барщинага караган кебек карый иде. Кече офицерлар, нәкъ мәктәп балалары сыман, занятиеләргә соңгарып киләләр яки, җәза-мазар алу куркынычы булмаганда, бөтенләй бармыйча да калалар. Күпчелеге зур гаилә белән яшәгән, өйләрендәге низаг-гаугаларга һәм үз хатыннарының гыйшык мажараларына кереп баткан, күтәрә алмаслык тормыш чыгымнары һәм фәкыйрьлектән иза чиккән рота командирлары исә акча табу да вексель түләү кайгысы белән мәшгуль. Ямау өстенә ямау

салган сыман, алар бер җирдән бурычка акча алып тора-лар да шуны икенче җиргә илтеп түлиләр; кайберәүләре,— гадәттә, хатыннарының таләпләренә буйсынып — әлеге әҗәт акчасын гомуми рота кассасыннан яки солдатларга ирекле эш өчен түләнергә тиешле хезмәт хакыннан алалар; икенче берләре акча салып җибәрелгән солдат хатларын, шундук ачып, ияләренә тапшырырга тиеш булсалар да, айлар, хәтта еллар буе үзләрендә яшереп яткыралар. Берәүләр бөтен гомерен винт, штосс, ландскнехт кебек комарлы уеннарга багышлаган; араларында алдашып уйнаучылары да очрый,— моны бөтенесе дә белә, әмма сүз әйтүчесе юк. Болар өстенә, һәммәсе дә эчә; офицерлар җәмгыятенә җыелыпмы, бер-берсенә кунакка барыпмы — һәркайда эчә. Слива кебек, өендә бикләнеп эчүчеләре дә бар.

Шул рәвешчә, офицерларның үз вазифаларына җитди карарга вакытлары да калмый. Гадәттә ротаның бөтен эчке механизмын хәрәкәткә китерү һәм көйләү фельдфебельгә тапшырылган; бер үк вакытта ул канцелярия эшләрен дә алып бара һәм рота командирын, сиздермичә генә, ләкин нык итеп, үзенең тәҗрибәле, каты кулы астында буйсындырып тота. Рота командирлары, субалтерн-офицерлар кебек үк, хезмәт урынына күңел бирмичә, җирәнеп йөриләр; аларның «фендрикларны өйрәтүләре» дә бары престиж саклау яки, сирәгрәк очракта, шөһрәт сөюгә бәйле дуамаллыктан гына чыгып эшләнә иде.

Батальон командирлары елның-ел буе, бигрәк тә кыш айларында, берни дә эшләмиләр. Армиядә ике арада, урталыкта торган ике начальник бар: берсе — батальон командиры, икенчесе — бригада командиры. Боларның хезмәт вазифалары анык билгеле түгел, шуңа күрә алар күп вакыт эшсез булалар. Шулай да җәй айларында аларга гомуми батальон өйрәнүләре алып барырга, полк һәм дивизия күләмендә уздырылган занятиеләрдә катнашырга һәм беркадәр маневр кыенлыкларын татырга туры килгәли иде. Башка вакытта исә алар көннәр буе җәмгыятьтә утыралар, «Инвалид»ны тырышып укыйлар, дәрәҗә, чин алу мәсьәләләре турында бәхәсләшәләр, кече офицерлар исәбенә, кыстатмыйча гына, сыйланырга яраталар, үз өйләрендә мәҗлес, кичәләр оештыралар һәм күп санлы кыз балаларын вакытында кияүгә бирергә тырышалар иде.

Әмма зур смотрлар вакыты җиттеме, кече офицерлар булсын, өлкәннәре булсын — һәммәсе үз-үзен һәм берсе-берсен тәртипкә китерә башлый. Бу чакта инде ял дигән нәрсәне күрмисең: барысы да, занятие сәгатьләрен арттырып һәм катлауландырып, каударлы, нәтиҗәсез бер гайрәт

белән, элек эшләнми калган эшләрне тизрәк җиренә җиткерергә керешә. Солдатның көче-хәле белән исәпләшү юк; ул тәмам аяктан егылыр дәрәҗәгә җитә. Рота командирлары аяусыз рәвештә кече офицерларны изалый, кече офицерлар, үз нәүбәтләрендә, белер-белмәс эшәке, гайре табигый сүзләр белән түбән дәрәҗәдәгеләрне сүгә, талашкычкырынулардан тамаклары карлыгып беткән унтер-офицерлар турыдан-туры сугыша ук башлыйлар. Хәер, бер унтер-офицерлар гына түгел, башкалары да сугыша.

Бу — урак өсте кебек тынгысыз көннәр; командирдан башлап иң түбән, иң алама денщигына хәтле — һәр кеше, бөтен полк, бу көннәрдә берничә сәгать артык йокы вәгъдә иткән якшәмбе ялын нәкъ менә ахирәт ләззәтен көткәндәй зарыгып, тилмереп көтә.

Быел яз якынлашуга ук полкта ныклап торып май парадына әзерлек башланган иде. Төгәл мәгълүматларга караганда, парадны таләпчән, сугышчан бер генерал — корпус командиры кабул итәргә тиеш икән. Бу генерал карлчылар сугышы һәм 1870 елгы Франция — Пруссия кампаниясе (соңгысында ул үзе дә волонтер булып катнашкан) турындагы язмалары белән дөнья хәрби әдәбиятында да билгеле кеше иде. Ләкин аннан да бигрәк ул үзенең Суворовча кыска, ачык итеп язылган приказлары белән данлыклы иде. Бу приказларында ул гаепле кешеләрне үзенә генә хас үтергеч тупас сарказм ярдәмендә тәмам бетереп ташлый, шуңа күрә офицерлар аның приказларыннан дисциплинар җәза алуга караганда да ныграк куркалар иде. Шунлыктан роталарда, менә ике атна инде, ашыга-кабалана смотрга әзерләнәләр, һәм якшәмбе көнен һәммәсе — арыган офицерлар да, шашыр дәрәҗәгә җитеп тинтерәгән солдатлар да бер үк төсле түземсезлек белән көтәләр иде.

Әмма арест астына эләккән Ромашов өчен бу татлы ялның инде бернинди рәхәте дә калмаган иде. Ул ял көнне бик иртә уянды һәм, никадәр генә тырышса да, бүтән йокыга китә алмады. Шуннан иренеп кенә өстенә киенде, җирәнә-җирәнә чәен эчте һәм хәтта бер мәртәбә нәрсә өчендер үзенең денщигына — һәрвакыттагыча, көләч йөз белән, көчек баласыдай ава-түнә, кабаланып йөргән Гайнанга — тупас рәвештә кычкырынып та алды.

Ромашов, изүе ачык соры тужуркадан, аяклары белән карават аягына, ә терсәкләре белән тузанлы, калтыравык этажерка почмагына бәрелә-сугыла, бәләкәй бүлмәсендә ишекле-түрле эйләнергә тотынды. Ел ярымлык хезмәт дәверендә — анысы да әле бәхетсез бер очрак аркасында гына — ул шулай беренче тапкыр үз-үзе белән ялгыз калды.

Моңарчы төрле хезмәт вазифалары, дежур тору, офицерлар җәмгыятендә яки Николаевлар өендә кич утыру, карта уйнау шикелле нәрсәләр, ниһаять — Петерсон ханым артыннан өстерәлү моңа гел комачаулый килә иде. Кайчакны, буш вакыт чыгып, ялгыз калу мөмкинлеге туса да, ул бу мөмкинлектән файдаланмый — эшсезлеккә һәм эч пошуга түзә алмыйча, гүя үз-үзеннән курыккандай, тизрәк кая да булса чыгып чабу ягын карый: клубка, танышлары янына бара яки, ничүгы, бернинди максатсыз-нисез урамда йөри; шулай каңгырып йөри торгач, буйдак иптәшләреннән берәрсен очратып, аның белән караңгы төнгәчә аракы эчә иде. Хәзер исә ул хәсрәтләнеп уйлап куйды: алда — башланмаган һәм ялгызлыкта үтәсе озын көн, ә башта — әллә нинди сәер, ипсез һәм ничүк кирәге булмаган фикерләр өере.

Шәһәрдә иртәнге гыйбадәткә дәшеп чаң какты лар. Әлегә эчке рамы алынмаган ике катлы тәрәзә аша бүлмәгә, калтырап һәм бере икенчесенә үрелеп, яз чыңыдай моңлы дәртле авазлар таралды. Тәрәзә каршында ук зур бакча; анда, көтүдәге ап-ак йонлы бәрәннәр янсә төркем-төркем җыелышып торган ак күлмәкле кызчыклар сыман, шау чәчәккә күмелгән йомры-бөдрә тәбәнәк чияләр үсеп утыра. Алар арасында, әле монда, әле тегендә, гыйбадәт кылучылардай, ботакларын югарыга, күккә таба сузган зифа, төз топольләр һәм гөмбәз сыман җәенке ябалдашлы, мәһабәт карт каштаннар калкып күренә. Агачлар әлегә ялангачрак, шулай да аларның һавада караеп шәүләләнгән шәрә ботакларында бөреләр ачылып, язгы бер дәрт-шатлык белән беренче яфраклар яшелләнеп килүен төсмерләргә мөмкин инде. Күк йөзе аяз, якты, һава дымлы. Агачлар талгын гына калтырый, тирбәләләр. Сизелеп тора: алар арасында, салкынча, йомшак, ягымлы җил йөри; ул шаяра, уйный, чәчәкләрне түбән таба иеп, күзләреннән үбеп-үбеп уза.

Тәрәзәдән караганда уң кулда, ачык капка аша, кара, пычрак урамның бер өлеше һәм аргы яктагы йорт коймасы күренә. Койма буеннан, аякларын корырак җиргә басарга тырышып, ашыкмыйча гына кешеләр үтеп-сүтеп йөри. «Аларның көне башланып кына килә әле,— дип уйлап куйды Ромашов, узгынчылар артыннан көнче күзләрен йөртеп.— Шуңа әнә ашыкмыйлар да. Искитмәле: көне буе вакытлары буш!»

Һәм аның күңелендә хәзер үк киенергә дә урамга чыгып китәргә дигән дәртле, күздән яшь атылып чыгардай ашкынулы бер теләк кабынды. Башка вакыттагыча, җәмгыятькә барырга түгел, нәкъ менә урамга, саф һавага чы-

гып китәргә теләде. Әйтерсең, хөрлек дигән нәрсәнең кадерен элек бөтенләй белмәгән дә. Аягы атлаган җиргә курыкмыйча бару, күңеле тарткан тыкрыкка борылу, мәйданга юл тоту, чиркәүгә керү - кыскасы, ахыр нәтиҗәләрен һич уйлап тормыйча, күңеле теләгәннең барысын да эшли алу мөмкинлеге аны тәмам исертеп җибәрде, бу аңа чиксез зур бәхет, ниндидер олы бер рухи бәйрәм булыр кебек тоелды.

Шушы хисләргә нисбәтән, аның хәтере төбеннән сабый чакның бер истәлеге калкып чыкты. Бәләкәй чагында, корпуска китәрдән әле күп элек, әнисе аны җәза төсендә нечкә җеп белән карават аягына бәйләп куя да үзе өйдән чыгып китә торган иде. Ә бәләкәй Ромашов, җепне өзәргә кыймыйча, күндәм кыяфәттә сәгатьләр буе карават янында тик утыра. Әлеге шул җеп булмаса, Ромашов, әлбәттә, секунд та уйлап тормас, тегеләйме-болаймы, һич югы, икенче каттан тәрәзә аша яңгыр торбасы буйлап төшеп булса да, шундук өйдән чыгып качар һәм көнозын кайдадыр югалып йөрер иде. Шулай качып чыгып, хәрби музыка яки җеназа артыннан Мәскәүнең аргы читенә барып җиткән чаклары аз булдымыни аның! Һәрхәлдә, ул әнисе яшереп куйган шикәр-вареньеларны урлаганда бик кыю эш итте, өлкәнрәк иптәшләре өчен өйдән папиросларны да шактый ташыды. Әмма җеп! — менә бу нәрсәнең аңа гипноз сыман сәер бер тәэсире бар иде. Үзен бәйләп куйган җепне ул, өзүдән куркып, хәтта бераз гына тарткалап карарга да кыймый иде. Өзгән өчен әнисе янә җәза бирер дип шүрләүдән түгел һәм, әлбәттә, намуслы булып кыланудан яки үкенүдән дә түгел иде бу, бу нәкъ менә әлеге гипноз дигәннең нәтиҗәсе иде, вәхшинең шаман им-томнарына ихтирам катыш коты алынып караганы сыман бер нәрсә, өлкәннәрнең кодрәтле һәм акыл җитмәс эш-хәрәкәтләре алдында хорафатлы курку сыман нәрсә иде.

«Менә хәзер дә мин, мәктәп баласы сыман, аягы бәйле әлеге малай сыман, өйдән чыгалмый утырам,— дип фикер йөртте Ромашов, ишекле-түрле йөренеп.— Ишегем ачык, үземнең күңел теләгән җиргә барасым, күңел теләгән эшне эшлисем, теләгән сүзне сөйлисем, теләгәнчә көләсем килә,— ә менә мин җеп арканда бәйләнеп утырам. Әйе, бу *мин* утырам. Мин. Башка берәү түгел — Мин! Ләкин мин шулай утырырга тиеш дип ул хәл иткән бит. Мин аңа ризалык бирмәдем ләбаса!»

— Мин! — диде Ромашов, бүлмә уртасында туктады да, аякларын аера төшеп баскан хәлдә, башын түбән иде һәм тирән уйга калды. Аннары кинәт, әлеге бер ижекле

«мин» сүзенең асыл мәгънәсен хәзер генә аңлап алгандай, гаҗәпсенгән, каты тавыш белән үзалдына кычкырып җибәрде: — Мин! Мин! Мин! Менә монда, башын түбән игән килеш, идәндәге караңгы ярыкка төбәлеп, кем карап тора соң? Бу — Мин! Һай, нинди сәер бу!.. Ми-ин,— дип суздыра, бөтен зиһене белән шушы өч авазның мәгънәсенә төшенергә тырышып.

Ул, нидәндер уңайсызланган сыман, таркау гына көлемсерәп куйды, аннан шундук кашларын җыерды һәм киренке фикер агышыннан агарынып килде. Соңгы биш-алты елда мондый хәл аның белән шактый еш кабатлана иде. Рухи өлгерү чорында һәрбер яшь егетнең башыннан кичә торган гадәти хәл иде бу. Кайчак Ромашовны әнә шундый бер эчке яктыру — илһамлану биләп ала да, моңарчы туры, механик мәгънәсендә аңлашылып килгән күп кенә төшенчәләр — әйтик, гади хакыйкать сүзе, мәкаль, гомумтаныш тәгъбир — кинәт кенә аның зиһенендә бөтенләй яңа, тирән фәлсәфи мәгънәдә ачылып китәләр. Андый чакта ул аларны беренче ишетә кебек, хәтта үзе ачкан кебек хис итә иде. Үзенең беренче тапкыр *шундый халәткә* таруын ул әле дә хәтерли. Корпуста чакта, дин дәресендә, священник аларга бер урыннан икенче урынга таш күтәреп ташучы кешеләр турында борынгы бер риваятьне сөйләгән иде. Риваятьтә әйтелгәнчә, таш ташучыларның берсе үз эшен башта вак ташларны күчерүдән башлый, аннан эрерәкләренә тотына, әмма ахыргы иң эре ташларны күтәреп илтергә аның инде көче калмый. Икенче берәве исә эшне, киресенчә, иң эре ташларны күчерүдән башлый һәм үз йөкләмәсен уңышлы гына үтәп чыга. Ромашов бу риваятьне әле бала чактан, беренче укырга өйрәнгән вакытыннан ук белә иде. Ләкин священник сөйләвеннән соң, шушы беркатлы гына күренгән риваятьтә Ромашов өчен кинәт гаҗәеп тирән акыллылык, иксез-чиксез гыйбрәтле хикмәтләр дөньясы ачылып киткәндәй булды. Шул ук хәлне ул тиздән «Җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән халык мәкале белән дә кичерде. Ниндидер үтә кыска, бәхетле, илаһи бер мизгел эчендә ул шушы биш-алты гына сүзле мәкальнең нигезенә салынган гаять зур тормыш тәҗрибәсе авазын ачык тойды. Монда алдан күрүчәнлек тә, хәстәрле саклык та, акыллы уй-исәп тә — һәммәсе дә бергә тупланган иде.

Шул вакытлардагыча, менә бүген дә ул, кинәт кенә үзенең шәхси асылына төшенеп, бу көтелмәгән һәм гаять гыйбрәтле ачыштан тәмам шашып, тетрәнеп калды.

«Мин — ул фәкать эчтәге мин,— дип уйлады Ромашов,— ә калган барысы — Мин түгел, ә чит-ят нәрсә, тышкы ча-

гылышлар гына. Менә бу бүлмә, урам, агачлар, күк йөзе, полк командиры, поручик Андрусевич, хезмәт, байрак дигән нәрсәләр, солдатлар — берсе дә Мин түгел. Юк, юк болар Мин түгел. Менә минем кул-аякларым,— диде Ромашов, тирән бер гаҗәпләнү белән үзенең кулларына текәлеп, һәм, гүя беренче тапкыр күргәндәй, аларны җентекләп карарга тотынды,— юк, болар Мин түгел. Ә менә чеметсәм... менә шулай итеп... ул чакта бу — Мин. Кулны күрүем, югары күтәрүем — монысы да Мин. Хәзерге минутта уйлаган нәрсәм — анысы да Мин. Кайдыр барырга телим икән, бу — Мин. Менә хәзер йөрүдән туктадым — бу да Мин.

Һай, болардың һәммәсе нинди сәер дә нинди гади һәм нинди искитмәле. Бәлкем, бу Мин дигән нәрсә һәркемдә бардыр, ә? Ә бәлкем, һәммәсендә түгел, бары миндә генәдер, башка беркемдә дә юктыр? Әгәр дә була калса? Әйтик, менә минем алда йөз солдат тора, мин аларга кычкырам: «Башны уңга борырга!» — дим, һәм алар,— һәркайсының үз Мине булган, минем шәхестә исә Мине түгел, ә ниндидер чит-ят нәрсәне генә күргән әлеге йөз солдат,— шундук башларын берьюлы уң якка таба боралар. Ләкин мин аларны берсен икенчесеннән аера алмыйм, минем өчен алар — тоташ масса. Әгәр шулай икән, полковник Шульгович өчен, әйтик, без үзебез кем соң? Шульговичка, бәлкем, без дә — мин, Веткин, Лбов, бүтән барлык поручик, капитаннар — һәммәбез дә шундый ук тоташ бер масса булып күренәбездер, ул да, бәлки, безне бер-беребездән аера алмыйдыр?»

Шул чак ишек дөбердәп ачылды һәм бүлмәгә Гайнан атылып керде. Иңбашларын сикертә-сикертә, бер урында биегәндәй таптанып торганнан соң, ул кычкырып әйтте:

— Ваша благородия. Буфетчы папирос бүтән бирмәй. Әйтә, поручик Скрябин сиңа бурычка бирмәй кушты, ди.

— Аһ, шайтан!— дип, ирекле-ирексез кычкырып җибәрде Ромашов.— Ярар, бар, үз ягыңа чык... Папироссыз ничлим инде мин хәзер?.. Ярар, үлмәм әле, чыгарга мөмкин, Гайнан.

«Ни турында уйлый идем әле мин? — дип, үз-үзенә сорау бирде Ромашов, бүлмәдә ялгызы калгач. Ул эзлекле уйлый белми һәм хәзер, гадәтенчә, фикеренең җебен югалтып, көчәнә-көчәнә шуны искә төшерергә тотынды.— Чыннан да, ни турында соң? Ниндидер бик мөһим, кирәкле нәрсә турында иде бугай... Тукта, сабыр: фикерне башыннан башлыйк... Мин арест астында утырам... урамда кешеләр үтеп-сүтеп йөри... бала чакта әни мине бәйләп куя иде... *Мине* бәйләп куя иде... Әйе, әйе... Солдатның да үз Мине

бар... Полковник Шульгович... Әйе, исемә төште... Инде хәзер алга таба, алга таба барыйк...

Мин бүлмәдә утырам. Ишек бикле түгел. Урамга чыгарга телим, әмма кыюлыгым җитми. Нигә җитми икән? Әллә берәр төрле җинаятем бармы? Бәлки, урлашканмындыр? Кеше үтергәнмендер? Юк; миңа чит-ят икенче берәү белән сөйләшкәндә, мин аякларымны аерыбрак басып тордым һәм ул кешегә ниндидер сүз әйттем. Бәлки, мин чыннан да аякларымны тезгә-тез кушырып куярга тиеш булганмындыр? Ни өчен? Бу шулкадәр әһәмиятле нәрсә микәнни? Яшәүнең мәгънәсе шуннан гыйбарәт микәнни? Менә тагы егерме-утыз ел узып китәр, бу — миңа кадәр булган һәм миннән соң да булачак вакыт үлчәвенең нибары бер секундын тәшкил итә. Нибары бер секундын! Минем Мин, кысып куелган лампа филтәсе сыман, бер заман пыскып сүнәр. Ләкин лампаны кабат кабызырлар, анысы сүнгәч, тагы, тагы кабызырлар, ә Мин инде бүтән булмам. Минем аяк-кулларым да булмас, алай гына да түгел — менә бу бүлмә дигәнне, күк йөзе, полк, бөтен гаскәр, йолдыз, җир шары дигәннәре дә булмас... чөнки ул вакытта Мин булмам...

Әйе, әйе... бу шулай... Ярый, хуш... шуннан нәрсә... тукта... монда эзлеклелек кирәк... Мин юкка чыктым. Мәңге караңгылык эчендә кемдер минем тормыш шәмемне кабыза да шундук сүндереп тә куя, тагы караңгылык, мәңге караңгылык дәвам итә... Тормыш шәмем янган шул кыска мизгел эчендә мин нәрсә эшләдем соң? Үкчәне үкчәгә, кулларны яктыкка куеп, үрә катып тордым, марш йөргәндә аяк очларын мөмкин кадәр түбәнрәк каратып атларга тырыштым, бугазымны киерә-киерә: «На плечо!» — дип хәрби командалар акырдым, «приклад очын яктыкка кысыбрак тотмаган» өчен җен ачуларым чыгып, кемнәрнедер эт итеп сүктем, йөзләгән түрәләр алдында кан калтырап тордым... Ни өчен шулай? Минем Мин белән бергә үләчәк бу өрәкләр миннән йөзләрчә кирәкмәгән һәм күңелемә ятмаган эшләр эшләттерделәр, җитмәсә шуның өчен *Мине* мәсхәрәләп, түбәнсетеп желегемне корыттылар. Әйе, *Мине* мәҗбүр иттеләр!!! Нигә соң минем Мин шул өрәкләргә буйсынды икән?»

Ромашов өстәл янына килеп утырды да, терсәкләрен өстәлгә терәп, учлары белән башын кысып тотты. Башында кайнаган гаҗәеп фикерләр өермәсен ул бөтен көченә аныкбер эзгә салырга тырышты.

«Һы... ә син оныттың дамыни? Ә ватан кая? Туган бишек? Ата-бабалар хакы? Дин, тәхет хакы?.. Хәрби намус белән дисциплина дигән нәрсә кая? Чит ил дошманнары

ватанына бәреп керсә, аны кем яклар?.. Анысы шулай, ләкин мин үлгәч, минем өчен ватан да, дошманнар да, намус дигән нәрсә дә булмаячак бит. Алар минем акылым тере чакта гына яшиләр. Ә менә шул ватан, намус, мундир һәм барлык бөек дигән нәрсәләр юкка чыкса да, минем Мин барыбер калачак, барыбер яшәячәк. Димәк ки, минем Мин әлеге барлык төшенчәләрдән — бурыч, намус, мәхәббәт дигән төшенчәләрдән өстенрәк, әһәмиятлерәк булып чыга, шулаймы? Менә мин хезмәт итәм... Кинәт минем Мин әйтер: кирәкми, теләмим! дияр. Юк, минем Мин генә түгел, ә күбрәк Миннәр... армияне тәшкил иткән миллион Миннәр, юк, тагы да күбрәк — бөтен җир йөзендә яшәүче Миннәр берьюлы әйтте, ди: кирәкми, теләмим! — диде, ди. Шуннан ни булыр иде икән? Шул: сугыш ихтималы шундук мәгънәсезгә әйләнер, «ике рәтле сафка тезел!», «уңга таба ярым борыл!» кебек ахмак командалар, мәгънәсез саналып, телдән мәңгегә төшеп калыр иде. Әйе, әйе, нәкъ шулай булыр иде! Нинди дөрес фикер бу, нинди дөрес фикер! — дип җөпләде Ромашовның күңеле төбеннән нинди дер тантаналы тавыш.— Барлык бу сугышчан батырлык, хәрби дисциплина, чинга табыну, мундир намусы дигән нәрсәләр һәм, нихаять, хәрби фән үзе дә бары тик кешелек дөньясының «кирәкми, теләмим!» дип әйтергә теләмәве яки әйтә белмәве яки әйтергә куркуы аркасында гына яшиләр.

Сугыш һөнәре дип йөртелгән һәм шулкадәр хәйләләп корылган бу бина асылда нәрсә соң? Берни дә түгел. Артсыз урындык, һавада асылынып торган терәксез бина ул! Аны хәтта «кирәкми, теләмим!» дигән ике кыска сүз нигезендә корылган бина дип тә әйтеп булмый, аны тотып торган бердәнбер нигез — кешеләр тарафыннан әлеге «кирәкми, теләмим!» сүзләренең моңарчы ни өчендер әйтелми килүендә генә. Минем Мин беркайчан да «ашыйсым килми, сулыйсым килми, күрәсем килми» дип әйтмәячәк. Ләкин әгәр дә аңа үләргә тәкъдим итсәләр, ул һичшиксез әйтәчәк: «теләмим!» диячәк. Алайса һәрвакыт котылгысыз үлемнәр белән бара торган сугыш үзе нәрсә соң? Остарак итеп үтерү юлларын өйрәтә торган хәрби фән дигәне нәрсә? Дөньякүләм бер ялгышумыни? Әллә мәнсезлек, сукырлыкмы?

Юк, син тукта, сабыр ит... Күрәсең, мин үзем дә ялгышамдыр. Шулай булмыйча һич мөмкин түгел, чөнки әлеге «кирәкми, теләмим» сүзләре шундый табигый, шундый гадиләр ки, алар һәркемнең башына килергә тиеш иде кебек. Ярар, хуш, тикшереп бетерик. Әйтик, иртәгә, юк, хәзер үк, шушы секундта үк, әлеге фикер барлык кешенең — русларның да, немец, инглиз, япончарның да — берьюлы ба-

шына килде, ди... Һәм менә сугыш бөтенләй гамәлдән чыкты, офицерлар, солдатлар юк, барысы да өйләренә таралыштылар, ди. Шуннан ни булыр иде икән? Чыннан да, ни булыр иде икән? Беләм, Шульгович минем бу соравыма болай дип җавап бирер: «Ул чакта безнең илгә көтмәгәндә генә дошман бәреп керәчәк тә, йорт-җирләребезне тартып алып, игеннәребезне таптап, хатын һәм сеңел-апаларыбызны коллыкка алып китәчәк»,— дияр иде. Ә фетнәчеләр ни кылыр? Социалистлар? Революционерлар? Хәер, ни кылсыннар! Бөтен, бөтен кешелек дөньясы әйтте бит: кан коюны теләмим, диде. Шулай булгач, кем инде корал күтәреп, яман уй белән күршесенә каршы чыксын? Юк, алай эшләмәсләр. Ләкин шуннан нәрсә булыр соң? Һәркайсы үзара тату яши башларлармы? Бер-берсенә юл куярлармы? Бүлешерләрме? Гафу итешерләрме? Йа хода, ни булыр, ни булыр?»

Үзенең уй-хисләренә батып утырган Ромашов ишектән Гайнан килеп керүен бөтенләй сизмәде. Тегесе, әкрен генә арттан килеп, подпоручикның җилкәсе аша өстәлгә таба кулын сузды. Көтелмәгән бу хәлдән Ромашов сискәнеп китте һәм куркынган төстә кычкырып җибәрде:

— Сиңа ни кирәк тагы, шайтан!..

Гайнан өстәл өстенә куе коңгырт төстәге кәгазь тартма ташлады.

— Сиңа! — диде ул ягымлы бер тәкәллефсезлек белән, һәм Ромашов үзенең артында аның дустанә елмаеп басып торуын тавышыннан ук аңлады.— Сиңа — папирос. Тарт әйдә!

Ромашов тартмага күз төшерде. Тартманың тышында: «Трубач» папиросы, бәясе 3 сум. 20 данә» дигән язуы бар иде.

— Бу ниткән эш? Нәрсәгә? — диде ул, гаҗәпләнеп.— Каян алдың моны?

— Карыйм, синдә папирос юк. Үз акчага сатып алдым. Тарт әйдә, пажалюста, тарт. Зыянсыз. Бүләк иттем сиңа.

Гайнан, үз сүзләреннән үзе уңайсызланып, урынынан купты да, ишекне каты ябып, бүлмәдән чыгып сызды. Подпоручик папирос алып кабызды. Бүлмә эченә сургуч һәм көйгән каурый исе таралды.

«Һай, рәхмәт төшкерене! — дип уйлап куйды тәэсирләнгән Ромашов.— Мин аңа кычкырынам, ачуланам, кичләрен аңардан итекләремне генә түгел, оекбашымны, чалбарымны да салдыртам. Ә ул менә үзенең соңгы, кызганыч тиеннәрен җыйнап, миңа папирос алып кайткан. «Тарт, пажалюста!» — ди бит әле. Нинди яхшылыгым өчен?»

Ул урынныңнан торды һәм, кулларын артка куеп, янә ишекле-түрле атлап китте.

«Менә шундыйлар безнең ротада йөзәү. Һәрберсенең, әлбәттә, үз уй-хисләре бар, үзенә генә хас холкы, тормыш тәжрибәсе, күңел багланышлары, яраткан-яратмаган нәрсәләре бар. Алар турында ни дә булса беләмме мин? Юк, тышкы кыяфәтләреннән кала, берни дә белмим. Менә алар уң флангта басып торалар: Солтыс, Рябошапка, Веденеев, Егоров, Ящишин... Төссез, чырайсыз йөзләр. Күңелем белән алар күңелен, үз Минем белән алар Минен чагыштырып карардай нинди эш майтардым соң мин? — Берни дә».

Шул чак Ромашов гыйбрәтле бер вакыйганы исенә төшерде. Көз ахырындагы яңгырлы бер кичне берничә офицер, шул җөмләдән Ромашов та, җәмгыять клубында аракы эчеп утыралар иде. Кинәт ишектән 9 нчы ротаның фельдфебеле Гуменюк атылып керде дә, ахылдый-ахылдый, үзенең командирына эндәште:

— Ваше высокоблагородие, яшьләрне куалап китерделәр!..

Әйе, нәкъ менә куалап китергәннәр. Бу яшьләр, өркетелгән сарык көтүе сыман, бер-беренә елышып, полк ишегалдында, яңгыр астында, дәшми-тынмый бөрешеп басып торалар иде. Маңгай астыннан төбәлеп караган күзләрендә шомлану, курку галәмәте. Әмма йөз-кыяфәтләре һәрберсенең төрле-төрле. Кем белә, бәлки, бу аларның артык чуар киемле булуыннан гына шулай тоелгандыр? «Менә бусы, мөгаен, слесарь егеттер,— дип, төркем алдыннан уйланып узган иде ул чакта Ромашов, яшьләрнең йөзләренә текәлеп карый-карый.— Ә менә монысы шат күңелле кеше һәм оста гармунчы булырга тиеш. Ә менә бу егет половой булып хезмәт итмәдеме икән? Ник дисәң, бик өлгер, белдекле күренә, кыяфәте дә жуликныкы сыман, сөйләшкәндә теле телгә йокмый, үзе ыспай». Гомумән, ул чакта боларның бөтен торыш-кыяфәтләрендә мәҗбүри рәвештә куалап китергәнлек әллә каян күренеп тора иде. Күрәсең, берничә көн элек кенә ул яшьләрне әниләре, әне-сеңелләре елый-елый озатып калган булгандыр, алар үзләре дә ул чакта рекрут исереклеге белән генә, батыраеп, чак-чак еламыйча түзгән булганнардыр... Шуннан бирле менә бер ел узды, әлеге яшьләр хәзер аның каршысында озын, үле шеренгага тезелеп торалар — төссез чырай, агач йөз; шәхси үзлек, элекке мөстәкыйльлекнең әсәре дә юк, һәммәсе бертөрле: алар — солдатлар! Теге чакта алар гаскәри хезмәткә барырга теләмәгәннәр. Аларның Миннәре теләмәгән. Йа аллам, бу коточкыч ялгышлык, гаделсезлекнең сәбәбе нәрсәдә

соң? Бу төеннең очы кайда? Әллә бу теге әтәч белән булган мәгълүм тәжрибә сымаграк бер нәрсәме? Әтәчне өстәл өстенә менгереп бастырганнар да шундый тәжрибә ясаганнар, ди, бит: башын түбән идерәләр икән — әтәч тыпырчына, дулый. Ахырда әтәчнең томшыгына акбур белән сызык сызалар да, дәвамы рәвешендә, сызыкны өстәл тактасы буйлап ары сузалар: әтәч шундук шып булган, ди, күзләрен гайре табигый бер курку белән шарландырып, тик утыра, ди; ул үзен җепкә бәйләп куйдылар дип уйлый икән.

Ромашов караваты кырына барып җитте дә бөтен гәүдәсе белән шунда ауды.

«Алайса миңа нишләргә кала соң? — дип сорады ул үзүзеннән, усал диярдәй кырыс бер тавыш белән. — Әйе, миңа нишләргә кала? Хезмәтне ташлап китәргәме? Тик синең башка нинди һөнәрең бар соң? Нәрсә эшли беләсең? Башта пансион, аннары кадетлар корпусы, хәрби училище, үзенә аерым тормышлы офицерлык хезмәте... Көрәш дигән нәрсәне яисә мохтаҗлыкны татыганың булдымы? Юк, син гомерең буе әзергә хәзер булып яшәдең; институткалар сыман, күмәчне агач башында үсә дип уйладың. Йә, китеп кара хезмәтеңнән. Сине шундук чукып-талап бетерәчәкләр, син эчүгә сабышачаксың, син мөстәкыйль тормышка атлаган беренче адымыңда ук сөртенеп егылачаксың. Тукта, сабыр ит. Син белгән кайсы офицерның үз ирке белән хезмәттән киткәне бар? Юк андый офицер. Аларның барысы да офицерлык хезмәтенә чытырдап ябышканнар, чөнки алар шуннан гайре бернәрсәне дә белмиләр, бернигә дә ярамыйлар. Хезмәттән китсәләр дә, соңыннан гомерләре буе башларына каешланып беткән офицер фуражкасы киеп йөриләр: «Эйе ла бонте... затлы рус офицеры... компрене ву...», янәсе. Аһ, нишләргә соң миңа? Ни эшләргә?!.»

Шул чак ишегалды якка караган бердәнбер тәрәзә аша тыштан яңгыравык хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Арестантик, арестантик!

Ромашов караватыннан сикереп торды да тәрәзәгә ташланды. Яктылык төшмәсен өчен күзләрен ян яктан учлары белән томалап һәм көләч елмаюлы алсу иреннәрен тәрәзә пыяласына ук терәп, анда Шурочка басып тора иде. Үзе сөйли, көйли-вәзенли:

— Би-ичара то-откынга садака бирмәссезме...

Ромашов ачарга дип тоткага сузылган иде дә, тәрәзәнең әле алынмаган булуын исенә төшереп, туктап калды. Аннары кинәт, ашкынулы шаян бер теләккә буйсынып, рамны ике куллап ныгытып тотты да үзенә таба тартты. Рам чытырдап урыныннан кузгалды һәм Ромашов башына кат-

кан известка, замазка кисәкләре коеп, бөтенләй каерылып чыкты. Беренче язгы чәчәкләрнең исерткеч, шат, нәфис хуш исе белән өретелгән салкынча һава ташкын сыман бүлмә эченә бәреп керде.

«Менә шулай! Үз юлыңны менә шулай ачарга кирәк аны!» — дип, куанып-көлеп, тантана белән кычкырды Ромашов күңелендәге яшерен тавыш.

— Ромочка! Шаштыгызмы әллә! Бу нишләвегез?

Ромашов хатынның тәрәзә аша сузылган һәм коңгырт перчатка кигән бәләкәй кулын эләктереп алды да, бик тәвәккәл төстә, башта арка, аннары уч ягыннан — перчатка каптырмасы өстендәге түгәрәкләнеп торган ачык урыныннан — шашып-шашып үбәргә тотынды. Моңарчы Ромашов белән мондый хәлнең һич булганы юк иде, әмма хатын ни өчендер карышырга җөрьәт итмәде, аңсыз бер рәвештә, гүя Ромашов күңелендәге бу кисәк күтәрелгән дәрт дулкынына буйсынып, уңайсызлану катыш гажәпсенү белән, аңа күзләрен төбәп тик торды.

— Александра Петровна! Җанкисәгем! Мин сезгә нинди рәхмәтләр әйтергә дә белмим!

— Туктагыз әле, Ромочка, ни булды сезгә? Нидән бу куаныч? — диде Шурочка, көлеп, әмма үзе җитди, тирән кызыксыну белән һаман Ромашовка каравында булды.— Сезнең күзләрегез яна. Тынычланыгыз әле, менә мин сезгә, тоткындагы кешегә, күмәч алып килдем. Бүген бик тәмле, баллы сумсалар пешергән идек... Степан, кая, кәрҗинеңне китер әле монда.

Ромашов, сөю-мәхәббәт тулы, нурлы күзләрен аңа төбәп, аның әле һаман каршылык күрсәтергә базмаган бәләкәй кулын иркәләп кысты һәм ашыга-ашыга сөйли бирде:

— Аһ, бүген иртәдән бирле нилләр уйлаганымны белсәгез иде сез... Тыңлап кына карасагыз иде! Ярар, анысын соңыннан сөйләрмен...

— Әйе, әйе, соңыннан сөйләрсез... Әнә, ирем — минем хакимем килә... Кулымны җибәрегез. Гажәеп тә кызык кеше сез бүген, Юрий Алексеевич. Хәтта чибәрләнеп тә киткәнсез димме.

Тәрәзә каршына Николаев килеп басты. Кәефе югарак, ахрысы: Ромашов белән бик коры гына исәнләште.

— Бар кит, Шурочка, кит,— дип ашыктырды ул хатынын.— Ходай белсен, ни нәрсәдер бу. Икегез дә акылдан шашкансыз, валлаһи! Командирга барып җитсә — яхшылык көтмә! Арест астындагы кеше ич ул. Сау булыгыз, Ромашов. Кергәләгез.

— Кергәләгез, Юрий Алексеевич,— дип кабатлады Шурочка.

Ул, киткән җиреннән кире борылып, янә төрөзә янына килде дә шыпырт кына ашыгып әйтте:

— Чыннан да, Ромочка: безне онытмагыз, ярыймы. Дус күргән бердәнбер кешем — ул да булса сез. Ишетәсезме? Тик, зинһар, миңа алай күзләрегезне акайтып карамагыз. Юкса күрәсем килми башлавы бар. Чынлап, Ромочка, үзегезне әллә кем дип хыялланып йөрмәгез. Дөресендә сез бөтенләй ир кеше түгел.

VII

Сәгать дүртенче яртыларда Ромашов янына полк командиры адъютанты поручик Федоровский килеп керде. Полк дамалары арасында мәһабәтле дигән даны чыккан озын буйлы, кырыс-салкын күз карашлы, сузынкы мыеклы бер егет иде бу. Полкта ул беркем белән дә дуслык итми, кече офицерлар белән үзен үтә әдәпле, шул ук вакытта кырыс-рәсми тота һәм үз хезмәт вазифасын гаҗәеп югары саный иде. Рота командирлары исә аның алдында гел куштанланырга тырышалар иде.

Керә-керүенә үк ул, кысык күзләрен йөртеп, бөтен бүлмә эчен берьюлы айкап алды. Караватында яткан Ромашов шундук урынныннан сикереп торды һәм, бурлаттай кызарынып, ашыга-кабалана, тужуркасының төймәләрен каптырырга тотынды.

— Мин сезгә полк командиры кушуы буенча килдем,— диде Федоровский рәсми, кырыс тавыш белән.— Тизрәк киенеп, минем белән баруыгызны үтенәм.

— Гафу... мин хәзер... көндәлек формадан барсам ярармы? Гафу итәсез, кыяфәтем бераз өйдәгечәрәктер.

— Көндәлек формадан да ярый, уңайсызланмагыз, зинһар. Сюртук. Рөхсәт итсәгез, мин утырыр идем.

— Аһ, кичерегез. Утырыгыз, утыр. Чәй китертмәскәме? — диде Ромашов, кабаланып.

— Кирәкми, рәхмәт. Тик, зинһар, тизрәк җыеныгыз.

Федоровский пальто, перчаткаларын салмыйча гына урындыкка барып утырды һәм Ромашов киенеп беткәнче шул урыныннан күзгалып та карамады. Катырып куйгандай төз гәүдә, бер кулын кылыч сабына куйган, йөзен таш сын дип уйларсың.

Ул арада Ромашов, керләнгәнрәк күлмәге өчен оялудан үзен кая куярга белмичә, ашыга-кабалана киенүендә булды.

— Белмисезме, ни өчен чакыралар икән? — диде ул, сүз катып.

Адъютант чак кына иңбашын сикертеп куйды.

— Сәер сорау. Кайн белим дә мин? Бу хакта сез үзегез миннән яхшырак белерго тиешсездер дип уйлыйм... Сез әзерме? Портупея каешын погонның өстеннән түгел, ә астыннан уздырып бәйләргә кирәш иттем. Үзегезгә мәгълүм, полк командиры мондый төгәлсезлекләрне бер дә яратмый. Менә шулай... Ягез, китик.

Капка төбендә эре гәүдәле, таза ике ат җигелгән полк коляскасы көтеп тора иде. Офицерлар коляскага менеп утырдылар да кузгалып киттеләр. Ромашов, адъютантка кысан булмасын дип, ихтирам йөзеннән, яны беләнрәк утырып барырга тырышты, тегесе исә моны гүя сизмәде дә. Юлда аларга Веткин очрады. Ул адъютант белән честь биреп исәнләште, ләкин коляска узып китүгә үк, артка борылып караган Ромашовка «Нәрсә, дускай, тетмәкне тетәргә алып баралармыни?» дигәнрәк мәгънәдә кулы белән, телдән аңлатып булмастай, үтә юмористик бер ишарә ясап күрсәтте. Веткиннан башка да офицерлар очраштыргалады. Берәүләр Ромашовка тирән игътибар белән карап, икенче берләре йә гажәпсенүле, йә мыскыллы күз карашы ташлап уздылар. Аларның бу күз карашларыннан Ромашов ихтыярсыз рәвештә бөрешеп-бөрешеп куйды.

Полковник Шульгович Ромашовны килеп җитүенә үк кабул итмәде: аның кабинетында кемдер бар иде әле. Шуңа күрә Ромашовка ярым караңгы алгы бүлмәдә күпмедер вакыт көтеп торырга туры килде. Монда алма, нафталин, яңа буялган лак исе аңкый, шуңа тагын, пөхтә, тәртипле, бай немец өйләрендәгечә, кием-салым, әйбер-җиһаз исен хәтерләткән ниндидер үзгә, күңел болгаткыч ят бер ис тә килеп кушыла иде. Бер урында таптангалый-таптангалый, Ромашов стена буена куелган ачык-сары өрәңге рамлы трюмо көзгедән берничә тапкыр үз-үзенә карап алды, һәм караган саен аңа үз чырае ничектер гайре табигый, кирәгеннән артык агарынган, ямьсез, сюртугы чамадан тыш искергән, погоннары тәмам таушалып беткән кебек тоелды.

Баштарак кабинеттан командирның бер тонда аккан тонык, калын бас тавышы гына ишетелеп торды. Аерым сүзләре аңлашылмый, әмма әледән-әле ачулы яңгырап куйган аваз төсмерләренә караганда, полковник үтә бер үҗәтлек һәм нәфрәт белән кемнедер сүгеп маташа иде булса кирәк. Бу шулай биш минут чамасы дәвам итте. Аннары кинәт Шульгович тынып калды; кемнеңдер ялварулы, калтыравык тавышы ишетелде. Ул да булмады, янә Шульгович сүз алды. Ләкин бу юлы аның тавышына шулкадәр ачы нәфрәт, һавалану, усаллык салынган иде ки, Ромашов ул

әйткән һәр сүзне иң нечкә аваз тирбәлешләренә кадәр апачык ишетте.

— Сез нәрсә миңа күз буяп маташасыз? Бала-чага, имеш! Хатын, имеш! Төкерәм мин сезнең балаларыгызга! Бала ясаудан элек сезгә аларны ничек туйдыру хакында уйларга кирәк иде. Нәрсә дисез? Һы, хәзер гаеплемен, имеш, полковник әфәнде! Беләсегез килсә, полковник әфәнденең сезнең эштә бернинди гаебе юк. Сез, капитан, шуны истә тотыгыз: әгәр полковник әфәнде сезне хәзер судка бирми икән, ул, димәк, үзенең хезмәттәге вазифасына җинаять эшли дигән сүз. Нәр-сә-ә? Дәшмәгез! Хата, имеш! Хата түгел, ә җинаять. Сезнең урыныгыз полкта түгел, ә башка җирдә — кайда икәнен үзегез беләсез. Нәрсә дисез?

Тагы баягы ялваручан, кыюсыз тавыш калтырап ишетелде. Ул шулкадәр мескен, кызганыч иде ки, гүя бөтенләй кеше тавышы да түгел. «Йа ходай, нинди афәт соң бу? — дип ачынып уйлады Ромашов. Ул, ябыштырып куелгандай, һаман көзге каршында үзенең агарынган чыраена төбәлеп карап тора, әмма аны күрми, фәкать йөрәгенең күкрәк эчендә сулык-сулык авыртып типкәнен генә тоя иде.— Йа ходай, нинди хурлык!..»

Ялварулы тавыш шактый озак сөйләде. Ул бетергәч, янә командирның әлеге тирән, калын басы сөйләргә тотынды. Әмма бу юлы ул беркадәр йомшара, басыла төшкән, гүя Шульгович, баягы җикерү һәм мыскыллаулары белән власть сөючән җанын тынычландырып, үз-үзеннән канәгать булып калган иде.

Ул сүзләрен кистереп-кистереп әйтте:

— Ярар. Соңгы тапкыр. Ишетәсезме? Бу иң соңгысы. Моны колагыгызга, сәрхуш колагыгызга киртләп куегыз. Эчеп йөргәнегезне тагы бер ишетсәм... Нәрсә? Ярар, булды, беләм мин сезнең ул вәгъдәләрегезне. Карагыз аны: ротагыз смотрга әзер булсын. Әлегә ул рота түгел, ә б...! Бер атнадан үзем карап-тикшереп китәрмен... Аннан шул, сезгә киңәш итеп әйтүем: иң элек исәп-хисап һәм дә солдат акчасыннан алган бурычларыгыз белән эшне бетерегез. Ишетәсезме? Иртәгә үк барысы төгәлләнгән булсын. Нәрсә дисез? Ә минем анда ни эшем? Хет үзегез тудырыгыз... Ниһаять, актык сүзем: мин сезне, капитан, бүтән тоткарламыйм. Сау булыгыз.

Кабинетта ыгы-зыгылы кыюсыз бер шыштырдау һәм, аяк очларына гына басып, шыгыр-шыгыр ишеккә таба юнәлгән тонык күн итек тавышы ишетелде. Әмма командирның үтә кырыс һәм хәтта беркадәр ясалма усаллык

белән яңгыраган сүзләре аны ишеккә җитәр-җитмәс үк туктатып калды.

— Туктале, тукта, алла бәндәсе, кире борыл... Хәзер син, акча эзләп, жидлар каршысына барырга исәплисеңдер, шулаймы? Вексельләр язарга, ә? Их син, хөрәсән, акылга зәгыйфь, тинтәк баш... Ярый, мә инде, ал, бавырыңа шайтан кергере нәрсә... Берәү, икәү... бер, ике, өч, дүрт... Өч йөз. Артыгын бирә алмыйм. Акчаң булгач түләрсең. Фу, чорт, бу кадәр дә әшәкелеккә төшәрсез икән, капитан! — дип җикеренде полковник, тавышын һаман күтәрә барып.— Беркайчан да андый хурлыкка төшмәгез! Түбәнлек бу!.. Ярый, бар, атла, атла! Шайтанның үзенә, үзенә үк олак! Хөрмәтемне белдерәм!..

Кабинеттан алгы бүлмәгә бөтен йөзе-бите ямьшәйгән, кызарынган, борын очы һәм чигә-яңакларына бөрчек-бөрчек тир тамчылары кунган бәләкәй бер кеше — капитан Световидов атылып чыкты. Аның кесәгә тыгылган һәм түземсезләнеп калтыранган уң кулында өр-яңа кәгазь акчалар шыштырдый иде. Ромашовны күргәч ул, вак-вак атлап, аның каршысына юнәлде һәм калтырап торган дымлы, кайнар учы белән подпоручикның кулын эләктереп алды да шамакайларча гайре табигый бер төстә шыркылдап көлеп җибәрде. Аның оялу катыш бер киеренкелек белән тегендәмонда йөгереп йөргән күзләре бер уңайдан Ромашовны да капшап алды шикелле: янәсе, кабинетта сөйләнгән сүзләрне ишеттеме ул, әллә юкмы?

— Котырган! Юлбарысмыни! — дип пышылдады Световидов беркадәр кимсенгән, тәкәллефсез тавыш белән, кабинетка таба ымлап.— Шөкер, узып китте! — Ул нервлы кыяфәттә ике тапкыр чукыну галәмәте ясап алды.— Узып китте. Аллага шөкер, аллага шөкер!

Ул да булмады, стена аръягында полк командирының:

— Бон-да-рен-ко! — дип кычкырган каты тавышы бөтен йортка яңгырап, алгы бүлмәнең юка стеналары гүя дерелдәп куйды. Полковник гадәттә звоноктан беркайчан да файдаланмый, берәрсен чакырырга кирәк булганда, фәкать үзенең гөрелдәвек бугазын гына эшкә җигә иде.— Бондаренко! Тагы кем бар анда? Керсен.

— Валлаһи, котырган! — дип пышылдады Световидов, елмайган төстә авызын ямьшәйтеп.— Сау булыгыз, поручик. Сезгә мунчаның җиңелрәк парлысын телим.

Ишек бусагасында денщик пәйда булды. Башының бер ягындагы майлы чәчен, юл ясап, чигәсенә таба каратып тараган, кулларына ак җеп перчатка кигән тук чырайлы, комсыз-оятсыз карашлы чын түрә денщигы иде бу. Ул, күз-

ләрен кыса төшеп, подпоручикның йөзенә туп-туры кадалды да, ихтирамлы, әмма бер үк вакытта мыскыл да сизелгән тәкәллефсез тавыш белән:

— Полковник галиҗәнапләре сез җәнапләрнең керүен үтенә,— диде. Ишекне ачты һәм, яны белән борылып, подпоручикны уздырып җибәрер өчен бераз артка чигенде.

Ромашов кабинетка керде.

Полковник Шульгович, итләч, кызыл кулларын агач кәнәфиенең киң култыксалары өстенә куеп, ишектән сул якта, почмактагы өстәл янында утыра иде. Өстендә — елкылдап торган һәйбәт күлмәк һәм соры тужурка. Чаларган очлы сакал һәм щетка сыман тырпы, кыска чәч белән каймаланган карт чырайлы зур-киң битеннән үзенә бер төрле салкын кырыслык бәреп тора. Төссез, нурсыз күзләре исә ачыктан-ачык дошманлык белән карыйлар. Подпоручикның сәламенә каршы ул башын чак кына иеп җавап кайтарды. Шул чак Ромашов аның колагында ярым ай суретенә охшатып ясалган тәреле көмеш алка күреп алды һәм эченнән генә: «Карале, элек бер дә күзгә чалынганы юк иде бит моның?» — дип уйлап куйды.

— Яхшы түгел, сударь,— дип, корсагы эченнән ырылдап чыккандай калын тавыш белән сүзен башлады командир һәм беравык тын алып торды.— Хурлык! — диде аннары, тавышын тагы да күтәрә төшеп.— Гаскәри хезмәткә әле аягыгыз да кереп җитмәгән, инде койрык болгый башладыгыз. Сездән канәгать булмаска минем күп дәлилләрем бар, сударь. Йә, ни булып чыга инде бу? Полк командиры аңа искәртү ясый, ә ул, йолкыш, бер прапорщик кисәге, фендрик,— үзенең әллә нинди буш сафсаталары белән телләнеп маташсын, имеш. Безобразие! — дип, полковник кинәт шундый каты кычкырып җибәрде ки, Ромашов хәтта сискәнеп куйды.— Акылга сыймаслык хәл! Бозыклыкның чиге!

Ромашов, бер читкә күзен тегәп, караңгы чырай белән тик басып торды. Полковникның йөзенә күтәрелеп карарга үзен бернинди көч тә мәҗбүр итә алмас шикелле тоелды аңа. «Мин» дигәнем кайда соң? — дип кинәт үз-үзенә сорау бирде ул, мәсхәрәле елмаеп.— Менә күр инде: син бер сүз дәшмичә үрә катып торырга мәҗбүрсең».

— Миңа бу хәбәрнең нинди юллар белән килеп җитүен аңлатырга кирәк санамыйм, әмма шунысы ачык мәгълүм: сез эчәсез икән. Коточкыч хәл бу! Мәктәптән әле генә чыккан бер маңка малай — чыпчык баласы — җәмгыять клубында иң соңгы чиккә җиткән итекче өйрәнчеге кебек лаякыл исереп йөрсен, имеш! Мин, егеткәй, бөтенесен белеп

торам; миннән бернәрсәне дә яшерә алмассыз. Миңа хәтта сез үзегез бөтенләй башыгызга китермәгән нәрсәләр дә билгеле. Ни дим, әгәр сөзәк юлдан шулай түбән тәгәрәргә телисез икән,— әйдә соң, тәгәри бирегез — анысы сезнең ихтыярда. Ләкин соңгы тапкыр әйтүем: минем сүзләргә колак салыгыз. Ул эш, дустым, һәрвакыт шулай башланып китә: әүвәл — бер рюмка, аннары — ике, ахырда, карыйсың, кеше үз гомерен койма буенда төгәлли. Моны ныклап колагыгызга киртләп куегыз, сударь. Аннан соң тагы шуны да исегездә тотыгыз: без сабыр кешеләр, әмма фәрештә сабырлыгының да бер чиге була — карагыз аны, шартламагае ул сабыр дигәнең... Безне соңгы чара кулланырга мәҗбүр итмәгез. Сез — берәү, ә офицерлар җәмгыяте.— зур бер семья ул. Андый-мондый хәл була калса, димәк... койрыктан эләктереп, компаниядән бөтенләй чыгарып ташлаулары да бик ихтимал.

«Менә шулай авыз йомып тик басып тор инде,— дип, хәсрәт эчендә тагы уйлап куйды Ромашов, полковникның колагында ялтыраган көмеш алкадан күзен алмыйча.— Ә бит югыйсә әйтергә кирәк иде, сезнең ул семьягыздан мин инде тәмам туеп беттем, бүген үк запаска куып чыгарсагыз да бер сүзем юк, диярга иде. Әллә әйтим микән? Кыюлыгым җитәрме?»

Ромашовның йөрәге, сулыгып, дөп-дөп тибәргә тотынды, ул хәтта әйтергә дип төкереген йотты, иреннәре белән ниндидер көчсез бер хәрәкәт тә ясады, әмма сүзе чыкмады — әүвәлгечә кымшанмыйча тик басып торуында булды.

— Гомумән, тәртибегез бернигә ярамый... — диде Шульгович, аяусыз төстә сүзен дәвам иттереп.— Үткән елны, мәсәлән, хезмәт итә башлавыгызга ел тулыр-тулмас үк, сез миннән ял сорап йөдәттегез. Имеш, әниегез авырый, фәлән дә төгән, шуны исбатларга теләп, ниндидер кәгазьләр, әниегез язган хатны да күрсәттегез шикелле әле... Йә, мин үз офицерыма ничек ышанмыйм инде, аңа ышанмаска ничек җөрьәт итә алыйм? Әнкәй дисез икән, әйдә соң әнкәй булсын. Ник? Андый хәлләр дә булгалый. Ләкин аңлыйсызмы — болар һәммәсе бере өстенә бере өелә бара бит, аннан соң...

Ромашов инде бая үк уң аягының тез турысы башта сизелер-сизелмәс кенә, аннары көчәйгәннән-көчәя барган тизлек белән калтырый башлавын тойган иде. Ирекле-ирексез башланып киткән бу калтырау, ниһаять, бөтен гәүдәне чолгап алып, Ромашовны тәмам хафалы, хурлыклы уйларга батарга мәҗбүр итте. Шульгович калтыравымны күрер дә, мине үзеннән шүрли икән дип уйлар дип курыкты

ул. Әмма әнисе турында сүз кузгалгач, кан тамырлары буенча ургып югары күтәрелгән кайнар ачу дулкыны аның миен томалады, һәм тәндәге калтырау да шундук бетте. Ул беренче мәртәбә башын югары күтәрде һәм ачыктаначык нәфрәт, усаллык чагылган күз карашын,— Ромашов моны үзе дә сизенде,— туп-туры Шульговичның борыны төбенә китереп төрәде. Бу исә, үз чиратында, дәһшәтле түрә белән кечкенә кеше арасындагы дәрәҗә аерымлыгын аңлаткан гаять зур, озын баскычны да берьюлы юкка чыгаргандай булды. Бүлмә эче, берьюлы тәрәзә пәрдәләре төшерелгәндәй, кисәк кенә караңгыланып китте. Командирның калын, куе тавышы каядыр өнсез-төпсез упкынга төшеп югалды. Әйләнә-тирәне һәртөрле фикер, ихтыярый теләкләр, хис-тойгылардан, хәтта аңның үзеннән үк диярлек азат булган ниндидер коточкыч караңгылык һәм тынлык чолгап алды. Монда бары бер генә нәрсә — менә хәзер, менә шушы мизгелдә үк, нинди дә булса мәгънәсезлек, төзәлмәстәй куркыныч хата эшләнәчәк дигән шомлы бер ышаныч кына торып калган иде. Ромашов кинәт үзенең колагы төбендә гүя чит-ят, сәер бер җан иясенең: «Хәзер мин аңа сугып җибәрәм»,— дип пышылдаган тавышын ишетте һәм күз карашын әкрен генә Шульговичның симез-итләч табак битенә һәм колагындагы айлы-тәреле көмеш алкасына күчерде.

Аннары ул, төшендә күргән сыман, Шульговичның күз карашында бер-бер артлы гаҗәпсенү, курку, борчылу, кызгану галәмәтләре чагылып узуын шәйләде... Һәм Ромашовның күңелен әлерәк кенә шундый стихияле көч, дәһшәт белән биләп алган котылгысыз, шашынкы дулкын кинәт сүрелде, таралып, читкә тайпылды. Ул үзе исә, йокыдан уянгандай, бөтен көченә күкрәген киереп, тирән итеп сулыш алды. Аның күз карашында бөтен нәрсә берьюлы элекке гади, көндәлек хәленә кире кайтты. Шульгович аңа ашыга-кабалана урын күрсәтте һәм һич көтелмәгән ярым тупас, ярым иркәле тавыш белән янә сөйләргә тотынды.

— Фу, шәйтан... бу кадәр дә үпкәчел булырсыз икән... Иә, утырасызмы сез, әллә юкмы, шәйтан алгырысы! Хәер, нишләмәк... сез барыгыз да әнә шундый инде. Миңа ерткыч җанварга карагандай карап торасыз. Янәсе, бу картлач, күптән дөмеккересе нәрсә, һич мәгънәсезгә, файдасызга нигә шулай кычкырына икән? Ә мин бит сезне, жаныкаем, һәммәгезне дә үз балаларым шикелле үлеп яратам, валлаһи менә,— диде полковник, нечкәрә, ягымлылана төшкән үзгә бер тавыш белән.— Мине әллә сезнең өчен борчылмыйдыр, газап чикмидер дип уйлыйсызмы? Их, әфәнделәр,

әфәнделәр, аңламыйсыз шул сез мине. Ну, ярар, бәлки артыграк кызып, чыгырдан чыгыбрак киткәнмендер — шуның өчен генә карт кешегә үпкәләргә ярыймыни? Их сез, яшьләр, яшьләр. Ярый, булды: татулаштык. Бирегез кулны. Аннан ашарга китәбез.

Ромашов сүзсез генә баш какты һәм үзенә таба сузылган йомшак, салкын кулны учына алып кысты. Күңелдәге рәнҗү хисе бетсә дә, кәеф шәптән түгел иде. Бүген иртән зиһенендә кайнаган мөһим, горур фикерләрдән соң ул хәзер үзен кеше типкәсенә калган ниндидер сөйкемсез, ятим, зәгыйфь, бичара бер бәләкәй малай, мәктәп баласы хәлендә хис итте. Бу үзгәреш, күчеш аның өчен ифрат хурлыклы иде. Шуңа күрә полковник артыннан ашханәгә керә-керешли, гадәте буенча, үзен өченче затка куеп, күңеленнән тагы уйлап алды. «Караңгы уйлар аның бөтен җисемен ермачлый иде».

Шульгович бала-чагасыз кеше иде. Шунлыктан табынга аның хатыны белән карт әнисе генә кереп утырдылар. Хатыны эре гәүдәле, юан, симез бер ханым; ияклəре катлы-катлы, муены бөтенләй юк диярлек. Күз карашы тәкәббер һәм борынына пенсне элгән булса да, йөзе аның бик гади күренә, әйтерсең аны камырдан ашык-пошык кына әвәләгәннәр дә күзләре урынына ике бөртек йөзем төртеп куйганнар иде. Хатын артыннан аякларын чыштыр-чыштыр атлап, көчкә өстерәлеп кергән карт ана исә гәүдәгә бәләкәй генә, үзе чукрак, әмма кыяфәтендә дәрт тә, зәһәрлек тә, буйсындыручан үҗәтлек тә үзләрен сиздереп тора әле. Күзлек өсли астан югарыга — Ромашовка таба тәкәллефсез, чәнечкеле күз карашын юнәлтеп, ул мәетнекенә охшаш кара-кучкыл тиреле, бөрешеп беткән бәләкәй кулын туп-туры аның иреннәренә китереп төртте. Аннары, полковник улына таба борылып, икәүдән-икәү сөйләшкәндә генә була торган тәкәллефсез бер аһәң белән:

— Нинди адәм бу? Никтер хәтерләмим,— диде.

Шульгович учларын торба сыман кушырып кортканың колагына куйды да шуның аша кычкырып әйтте.

— Бу — порпоручик Ромашов, әнкәй. Бик шәп офицер... фронтовик, менә дигәне... Кадетский корпусны тәмамлап килгән... Ах, онытканмын да! — диде ул кинәт, исенә төшереп.— Сез, Ромашов, безнең яктан, ягъни Пенза ягыннан бугай бит әле?

— Нәкъ шулай, полковник әфәнде, Пенза ягыныкы.

— Шулай шул, шулай шул... Хәзер генә исемә төште. Димәк, якташлар булабыз. Ялгышмасам, Наровчат өязеннән шикелле?

— Нәкъ үзеннән. Наровчат өязеннән.

— Шулай шул... Ничек онытканмындыр? Наровчат, Наровчат, казыгың булса да шат. Ә без — Инсарныкылар. Әнкәй! — дип кычкырды ул янә кырчыкның колагына: — Подпоручик Ромашов — безнең як кешесе. Пенза ягыныкы!.. Наровчаттан!.. Якташ, димәк!..

— Ә-ә! — дип сузды кортка, мәгънәле төстә кашларын җыерып.— Алай икән, алай... Әйтәм аны, таныш кебек... Димәк, сез Сергей Петрович Шишкинның улы буласыз, әйе?

— Әнкәй! Ялгышасыз! Подпоручикның фамилиясе Шишкин түгел, ә Ромашов!..

— Әйе, әйе... Мин дә шулай дим... Сергей Петровичны күреп белми идем... Ишетеп кенә белә идем. Ә инде Петр Петрович — менә аның белән шактый еш очрашырга туры килде. Чөнки, фараз итсәк, утарлары янәшә иде. Сезгә бик тә, би-ик тә шатмын, хөрмәтле егеткәй... Сезнең тарафтан мактаулы адым бу...

— Ну, башлады хәзер шыгырдарга, карт тел бистәсе,— диде әкрен генә полковник, тупас үз итү белән ризасызлыгын белдереп.— Утырыгыз, подпоручик... Поручик Федоровский! — дип кычкырды аннары, ишеккә карап.— Эшегезне бетерегез дә аракы эчәргә керегез!..

Адъютант шундук кереп тә җитте. Күпчелек полкларда куелган тәртипкә иярәрәк, монда да адъютант үз командиры белән бер бүлмәдә утырып ашарга гадәтләнгән иде. Федоровский, шпорларын йомшак кына чыңлата-чыңлата, бер читтә аерым әзерләнгән майолик өстәл янына килеп утырды да, рюмкасына аракы салып, ашыкмыйча гына эчеп җибәрде һәм ашарга кереште. Ромашовта шундук аңа карата көнләшү һәм ихтирам шикеллерәк ниндидер вак, сәер бер хис кыймылдап куйды.

— Ә сезгә аракы кирәкмимени? — дип сорады Шульгович.— Эчәсездер бит?

— Юк. Рәхмәт. Никтер күңелем тартмый,— диде Ромашов карлыкканрак тавыш белән һәм йөткереп алды.

— Һә-әм бик дөрес э-эшлисез. Иң яхшысы — эчмәү. Киләчәктә дә шулай булыгыз.

Ризык туклыклы һәм тәмле әзерләнгән иде. Сизелеп тора: бала-чагасыз полковник һәм аның хатыны үзләренең күңел дәртләрен бөтенләе белән гөнаһсыз бер эшкә — тәмле ашау эшенә салганнар булса кирәк. Төрле азыктамыр һәм яшел тәмләткечләр салып пешерелгән хуш исле кайнар шулпа, кыздырылган корбан балыгы белән ботка, симертеп суелган йорт үрдәге, әспе —болар һәммәсе табынга

бер-бер артлы килә генә торды. Өстәл өстендә өч шешә эчемлек тә куелган; берсе — мадера, калган икесе — ак һәм кызыл вино. Алар инде башланып, үз бөкеләре фигуралы көмеш бөкеләр белән алыштырылган булса да, һәммәсе дә әйбәт, кыйммәтле, чит ил эчемлекләре иде. Полковник, баягы дулавыннан аппетиты гүя тагы да ачыла төшкәндәй, ризыкны аеруча тәмләп, соклангыч рәвештә матур итеп ашап утырды. Үзе туктаусыз шаярты, беркатлы тупас, күңелле мәзәкләр сөйләде. Әспе китерелгәч, мәсәлән, җете ак, каты җепле салфетканы тужурка якасына кыстыра-кыстыра, көлеп:

— Әгәр мин патша булсам, гел шушы әспене генә ашап торыр идем! — диде.

Әмма әспе китерелгәнче, балык ашап утырганда, ул түзмәде, Ромашовка түрәләрчә бер кычкырынып та алды:

— Подпоручик! Пычакны, рәхим итеп, бер кырыйга алып куегызчы. Балык, котлет ише ризыкны фәкать чәнечкедән генә кабып ашыйлар. Болай яхшы түгел, сударь! Офицер ашау рәтен белергә тиеш. Чөнки һәрбер офицерның иң югары даирә мәҗлесләренә чакырылуы мөмкин. Моны исегездә тотыгыз.

Ромашов табын янында үзен ифрат кыен, уңайсыз хис итте; кулларын куяр урын тапмады, аларны күбрәк өстәл астына яшереп, эскәтер чугын бөтәрли-бөтәрли бау үреп утырды. Яхшы гаилә мохитыннан, әйбәт җиһазлы, затлы бүлмәләрдән, табын тәртипләреннән бизеп беткән иде инде ул. Аның күңелен һаман бер үк төрле уй борчыды: «Нигә мин бу хурлыклы аш табыныннан бая ук баш тартмадым, йомшаклык, куркаклык күрсәттем икән? Коточкыч түбәнлек бит бу! Әллә менә хәзер чыгып китәргәме? Торырга да, барысына берьюлы рәхмәт әйтеп, чыгарга да китәргә. Теләсә ни уйлап калсыннар шунда. Моның өчен Шульгович мине тотып асмас ич? Җанымны кыеп, уй-хисләремнән, акылымнан мәхрүм итмәс ич? Ләкин мин чыгып китә аламмы соң?» Һәм ул, йөрәге куркып кысылган, чырае эчке дулкынлану һәм үз-үзенә ачуы килүдән агарынган бер хәлдә, үзалдына икърар итәргә мәҗбүр булды: юк, ул моны эшли алмаячак.

Кофе китергәндә эңгер төшә башлаган иде инде. Баеп барган кояшның кыйгач нур көлтәсе тәрәзә аша бүлмәгә ургып керде дә коңгырт стена обоенда, эскәтер, хрусталь өстендә, ашап-эчеп утыручыларның йөзләрендә бакыр шәүләләрдәй җемелдәп уйнарга кереште. Һәммә кеше, кичке вакытның шушы гүзәл манзарасына хозурланып, моңсу халәттә тынып калды.

Кинәт тынлыкны Шульговичның калын тавышы бозды.

— Мин әле прапорщик булып хезмәт иткән чагында, бездә Фофанов дигән бер генерал, бригада командиры бар иде,— дип сөйләп китте ул.— Чыгышы кантонистлардан, ә үзе шундый сөйкемле карт, карап туймассың менә. Күпне күргән сугышчан офицер. Әле дә исемдә, смотрлар вакытында барабанчы янына килә иде дә: «Яле, туган, берәр моңлы нәрсә уйнап күрсәтсе миңа»,— ди торган иде. Барабанны үлеп ярата иде инде. Әйе. Аның тагын бер гадәте бар иде: кичке унбер життеме — ул йокларга китеп бара. Үзендә мәҗлес-мазар жыелганда да, сәгать унбер тулуга, кунакларына әйтә иде: «Ну, әфәнделәр, ашагызэсегез, күңел асыгыз, ә мин Нептун косагына киттем»,— ди торган иде. Берәрсе шунда шаяртып куя: «Бәлки, Морфей кочагынадыр, ваше превосходительство?» — ди. «Э, барыбер: икесе дә бер үк минералогиядән...» — дип жавап бирә торган иде генерал. Шуның кебек, хәзер мин дә, әфәнделәр,— Шульгович торып басты һәм түшендәге салфеткасын урындык аркасына элде,— әйе, мин дә Нептун кочагына китеп барам. Сез азат, офицер әфәнделәр.

Ике офицер да, урыннарыннан сикереп торып, үрә каттылар.

«Аның нәзек иреннәрендә аяныч катыш мәсхәрәле елмаю пәйда булды»,— дип уйлап куйды Ромашов. Әмма бу күңелдәге уй гына иде шул, чынында аның агарынган һәм түбәнчелекле ихтирам белән катып калган йөзе бу минутта ифрат мескен, ямьсез булып күренә иде.

Юлда кайтканда Ромашов үзен янә чиксез ялгыз, ниндидер чит-ят, караңгы урында, дошман арасында адашып калган бәхетсез бер кеше итеп тойды. Көнбатышта, йортлар һәм кырлар аръягында, авыр-салмак, күгелҗем болытлар катламы эченнән, куе-кызыл, гәрәбә төсендәге шул ук сихерле шәфәкъ ялкынланып яна иде. Һәм шушы шәфәкъ шәүләсе янган офык сызыгы артында, ераста-ераста, Ромашовка тагы теге тылсымлы шәһәр — бәхетле, гүзәл, тулы тормыш белән яшәгән әкият шәһәре бардыр сыман тоелып китте.

Кичке энҗер-меңгер күзгә күренеп куера бара иде. Шосседа чыр-чу килеп яһүд балалары йөгерешә. Каяндыр, якындагы йортлар тарафыннан — капка төбе, бакча эчләреннән, берөзлексез, дәртле һәм фәкать язгы кичләрдә генә була торган ниндидер хайвани калтырау-чың белән өретелгән кайнар, шатлыклы бер чыркылдашу — хатын-кыз көлүе ишетелә. Һәм шуңа бәйле рәвештә Ромашовның күңеле төбеннән, талгын һәм моңсу уй-сагыш белән арала-

ша-аралаша, үткәндәге гамәлгә ашмаган бәхетләр, хәзергедән дә гүзәлрәк язларны күз алдына китереп бастырган әллә нинди сәер, томанлы хатирәләр һәм үкенечле хисләр ташкыны күтәрелде. Бер үк вакытта йөрәк түрендә киләчәктән Ромашов өмет иткән олы мәхәббәтнең татлы авазы да үзен сиздертеп куйды шикелле.

Өенә кайтып керүгә, Ромашов сәер бер тамашага тап булды. Гайнан үзенең караңгы чоланында, аякларын төрекчә бер-берсенә кушырып, өч тактадан әмәлләштерелгән карават-сәкесе өстенә менеп утырган да, аллы-артлы тирбәлгән уңайга, бертөрле тонык тавыш белән көйләп-сузып, ниндидер аңлашсыз сүзләр мыгырдана. Каршысында — Пушкин бюсте. Ул тоташ майга буялган булып, аның сеңерле муенына, борын һәм калын иреннәренә янәшәдә янган шәм яктысыннан ялтыравык шәүләләр төшкән иде.

— Гайнан! — дип дәште Ромашов.

Денщик, сискәнеп, сәкесеннән сикереп төште дә үрә катты. Чыраена курку һәм аптырау галәмәте чыкты.

— Алламы? — дип сорады Ромашов дусларча.

Чирмешнең малайларныкыча төксез бите як-якка җәелеп, шәм яктысында җете ак тешләре ялтырап күренде.

— Алла, ваша благородия!

— Соң, бик әйбәт, бик әйбәт... Әйдә, утыра бир,— диде Ромашов, денщигын аркасыннан сөеп.— Барыбер бит, Гайнан, синдә алла, миндә алла. Барлык кешеләрнең алласы бер, туганкай.

«Шәп егет бу Гайнан,— дип уйлады подпоручик, бүлмәсенә таба атлап.— Ә менә мин шундый егетнең кулын алып кысарга да кыенсынам. Әйе, булдыра алмыйм, җөрьәтем җитми. Ух, шайтан алгырысы! Бүгеннән үк үзем киенә, үзем чишенә башларга кирәк булыр, ахры. Шундый эшне кешедән башкарту — бу бит чын дуңгызлык!»

Ул кичне Ромашов җәмгыять клубына бармады, өстәл тартмасыннан буй сызыклы, калын һәм тигезле-тигезсез вак хәрефләр белән яртылаш язып тутырылган бер дәфтәр тартып чыгарды да караңгы төнгәчә шуңа ниләрдер язып утырды. Ромашовның үзе язган һәм сан ягыннан өченчесе исәпләнгән «Соңгы хәлиткеч дебют» дигән повесте иде бу. Әдәби ижат эше белән шөгыльләнүенә подпоручик үзе дә оялып карый һәм бу турыда кемгә дә булса белгертү ихтималын күз алдына да китерми иде.

VIII

Полк өчен казарма һәм торак йортлары эле төзелә генә башлап, алар шәһәрчек читендә, тимер юл артындагы утлавык дип йөртелгән ялан, аулак бер урында булырга тиешләр иде. Аңарчы полк үзенең барлык ашханәләре белән вакытлыча төрле хосусый квартирларда таралып яшәде. Офицерлар җәмгыяте ике өлештән торган һәм икесе бергә «Г» хәрефен хәтерләткән бер катлы, зур булмаган бер бинаны били иде. Бу бинаның урамга каратып салынган озынча өлешендә — бию залы һәм кунак бүлмәсе, ә пычрак ишек алды түренә таба сузылган кыскарак өлешендә ашханә, кухня һәм читтән килгән офицерлар өчен торак бүлмәләре — «номерлар» урнашкан иде. Һәр ике өлеш үзара ниндидер буталчык һәм күп санлы култыкларга тармакланган бормалы, тар коридор белән тоташкан; култык саен ишек, ул ишекләр вак-вак бүлмәләргә алып керә. Шундыйлардан монда буфет, бильярд, карта уйнау, хатын-кызлар өчен киенү-бизәнү бүлмәләре бар. Ләкин ашханәдән кала бу бүлмәләрнең берсенә дә кеше кереп йөрми диярлек, шулай ук һавасы да алыштырылмый, шунлыктан алар эчендә үзенә бер төрле үле-җансыз ис — иске мебель келәме исе белән катнаш тынчу, ачыган, дымлы һава исе аңкый иде.

Ромашов сәгать тугызда җәмгыятькә килеп кергәндә, анда инде бишме-алтымы буйдак офицер тулганып йөри, әмма ханымнардан берәү дә күренми иде әле. Гомумән, югары тон, әдәп мәсьәләләрендә ханымнар белән офицерлар арасында күптәннән бирле ярыш сыман сәер бер тартышу бара, һәм, әйтик, бүгенгедәй бал-кичәгә ирләрдән иртәрәк килүне һәрбер хатын-кыз үзе өчен ифрат хурлыклы эш итеп санарга гадәтләнгән иде. Залга вак өлгеле зур тәрәзәсе карап торган пыяла галереяда инде музыкантлар утырышканнар. Калтыравык хрусталь асмалы түшәм люстрасы һәм тәрәзәара стеналардагы өч җәпле бралар яктысында бөтен зал эче балкып тора һәм шул яктылыкта үзенең ак обойлы шәрә стеналары, ян якларга тезеп куелган артлы урындыклары һәм тәрәзәләрендәге челтәр пәрдәләре белән аеруча буш-яланғач булып күренә иде.

Бильярд бүлмәсендә батальон адъютантларыннан поручик Бек-Агамалов белән поручик Олизар, нибары биш шар куеп, бильярд уйныйлар. Уен шарты — сыра эчерү. Полкта күбрәк граф Олизар кушаматы белән йөргән Олизар — нечкә, озын буйлы, сакал-мыегы кырулы һәм, битен җыерчык баскан булса да, буянып-ясанып ыспайланган

яшь чырайлы карт — уен барышында туктаусыз шаярта, бильярдка бәйле мәзәк сүзләр сибә, ә тегесе, Бек-Агамалов, һаман оттыра һәм оттырган саен җенләнә бара иде. Аларның уенын күзәтеп, тәрәзә төбендә штабс-капитан Лещенко утыра. Монысы — кырык биш яшьләр тирәсендәге һәм үзенең бер кыяфәте белән үк саруны кайнатырлык күңелсез бәндә. Аның бөтен җире тирән бер меланхолиягә чумган төстә түбән салынган: кызыл борыч кузагы сыман салынкы, озын, итләч һәм көпшәк борын; коңгырт төстәге нечкә ике җептәй, иякка кадәр җиткән сәлпе мыек; күзләр өстеннән ике як яңак сөягенә таба бөгелеп төшкән һәм хуҗасының чыраена җуелмас еламсык бер төс биреп торган салынкы каш; хәтта өстендәге иске сюртугына хәтле аның эчкә суырылган күкрәкле, тар, янтык иңбашлы арык гәүдәсендә элгечтәге кебек лыпыртдап асылынып тора. Ул үзе эчми дә, карта да уйнамый, хәтта тәмәке дә тартмый. Әмма аның һичкемгә аңлаешсыз сәер бер гадәте бар: бүтәннәр карта яки бильярд уйный башласа, яисә ашханәдә берәр төрле эчү мәҗлесе оештырылса, ул шуларны карап, боек чырай белән, дәшми-тынмый, бер урында сәгатьләр буе кымшанмый басып торырга да әзер. Полкта моңа инде күнегеп беткәннәр, һәм әгәр Лещенко карап-күзәтеп тормаса, җәмгыятьтәге карта уеннары, мәҗлесләр һәммәсе дә ничектер өтек килеп чыгар төсле тоела иде.

Офицерларның өчесе белән дә баш иеп исәнләшкәч, Ромашов туп-туры Лещенкога таба атлап китте. Тегесе, бер кырыйга сыенарак төшеп, янәшәсеннән подпоручикка урын бушатты һәм авыр сулап куйды да этнекедәй тугры, күндәм-моңсу күзләре белән яшь офицерның йөзенә текәлде.

— Мария Викторовна ни хәлләрдә, исән-саулармы? — дип сорады Ромашов. Моны ул тәкәллефсез тавыш белән, чукрак яки акылга таман кешеләргә эндәшкәндәй, юри катырак кычкырып әйтте. Хәер, полкта һәммәсе, хәтта прапорщиклар да Лещенко белән гадәттә шулай санга сукмыйчарак сөйләшәләр иде.

— Рәхмәт, кадерлем, ярыйсы,— диде Лещенко, авыр сулап.— Тик менә нервылары гына... Заманы шундый бит хәзер...

— Ә ник Мария Викторовна сезнең белән килмәде соң әле? Әллә ул бүген монда күренмәскә уйладымы?

— Юк. Һич алай түгел. Киләчәк ул. Киләчәк, кадерлем. Фаэтонда урын булмау сәбәпле генә шулай килеп чыкты. Алар Раиса Александровна белән уртакка экипаж яллаганнар да, шуннан әйтәләр миңа: «Синең, диләр, итекләреңә

бик пычрак, безнең күлмәк итәкләрен буяп бетерерсең», диләр. Менә, шулай, кадерлем, үзегез дә аңлыйсыздыр.

— Урта лузага! Нечкә генә кистереп. Лузадан шарны алып куй, Бек! — дип кычкырды Олизар.

— Син башта шарны төшер, аннан алырмын,— дип җавап бирде Бек-Агамалов ачу белән.

Лещенко салынкы мыек очларын авызына суырып алды да бик җитди кыяфәттә чәйнәргә кереште.

— Минем сезгә бер үтенечем бар иде,— диде ул, ялварулы, тотлыкканрак тавыш белән.— Сез бүген биюгә җитәкчелек итәсез бугай бит?

— Шулайрак шул. Шәйтан алгырлары. Мине билгеләделәр. Полк адъютантына тегелә дә, болай да әйтеп карадым, хәтта авыруым дип рапорт язмакчы да булган идем. Алар белән кешечә сөйләшеп буламыни? «Авырсагыз, врачтан язу китерегез», ди.

— Мин сездән шуны үтенмәкче идем,— дип, юмакайланып сүзен дәвам итте Лещенко.— Күңеле булсын дим, аны, зинһар, урынында артык озаклап утыртмагыз инде. Аңлыйсыздыр, моны мин сездән иптәшләрчә үтенәм.

— Марья Викторовнаны әйтәсезме?

— Шуны инде. Зинһар, сүземне тыңлагызчы.

— Сары шарны дуплет белән почмак лузага, — диде Бек-Агамалов, алдан ук ниятен әйтеп.

Буе кыскарак булу сәбәпле, аңа уйнарга шактый җайсыз, һәм ул шарга үрелеп җитү өчен корсагы белән тәмам өстәл өстенә ятарга мәҗбүр иде. Артык тырышудан аның бите кып-кызыл булган, ә кашлары өстеннән ике яклап борыны төбенә килеп кушылган кан тамырлары бүртеп чыккан иде.

— Җамаис! — дип, мәсхәрәле төстә үчекләп әйтте Олизар. — Анысын хәтта мин дә булдыра алмыйм.

Кий таягының чырт итеп шар өстеннән шуып узган тавышы ишетелде, әмма шар үзе урыныннан кузгалмады.

— Кикс! — дип, куанычыннан кычкырып җибәрде Олизар һәм бильярд өстәле тирәли шашынкы бер бию биеп алды. — Кайчан йоклайсың да гырылдайсың сән, җаным-җәнәшем?

Агамалов кий таягының юан башы белән каты итеп идәнгә сукты.

— Ә син кул астына сөйләнеп торма! — диде ул, кара күзләрен елтыратып.— Юкса чыгармын да китәрмен!

— Кайкайларыңны бузма, җәнәшем, зәхмәти үзиңә түшәр. Модистканы туп-туры почмак лузага!..

Ул арада Ромашов янына ишек төбе бүлмәсендә ха-

нымнарны каршы алу һәм өс киемнәрен салырга булышу өчен дежур куелган вестовойларның берсе йөгереп килде.

— Ваше благородие, залда сезне бер ханым күрергә тели.

Залга керүгә, Ромашов ишекле-түрле әкрен генә киләп сарып йөргән өч ханымны күрде. Өчесе дә өлкән яшьтәгеләр. Иң өлкән дигәне, полкның хуҗалык эшләре мөдире Мигуновка хатын тиешлесе, Анна Ивановна, югары катлау хатын-кызлары кыланышына охшаш үтә бер эрелек, ясалма назлылык белән башын чайкап һәм сүзләренең ахырларын юри суза биреп, Ромашовка эндәште:

— Подпоручик Ромашо-ов, колак ялы өче-ен ни дә булса-а уйнарга кушы-ыгызчы-ы. Үтенә-әбез...

— Тыңлыйм, ханым-әфәнделәр,— диде Ромашов, башын иеп, һәм музыкантлар утырган галерея тәрәзәсе каршына килде дә оркестр башлыгына кычкырды: — Зиссерман, әйдә, колак ялы өчен уйнатып җибәр булмаса!

Галереяның ачык тәрәзәсе аша залга «Гомеремне патшага багышлыйм» увертюрасының яңгыравык беренче авазлары таралды һәм көй тактына шәмнәрнең ялкын телләре югарыга сикерешеп куйды.

Хатын-кыз җәмәгате әкренләп ишәя барды. Моннан бер ел элек, үзенә бүгенгечә дирижерлык вазифасы тапшырылган чакларда, Ромашов бал мәҗлесе башланыр алдыннан алгы бүлмәдә ханымнар каршылауны үлеп ярата торган иде. Аларның залдагы балкыштан, музыканың беренче тавышларыннан ук күңелле кичә буласын өмет итеп, дәртле бер куаныч белән ишектән ябырылып керүләре, капор, боа, туннарын салганда ыгы-зыгы, чыр-чу килеп кабалану, көлешүләре — болар һәммәсе Ромашовка искиткеч серле һәм гүзәл тоела иде. Күңелле көлү, сөйләшү тавышлары белән бергә кысан бүлмәгә салкын һава һәм бал мәҗлесенә дип киенгән-ясанган бу чибәр туташ, ханымнарның күңелне кытыклый торган үзенә бер төрле хуш исе — ислемай, пудра, затлы кием исләре дә бөркелеп керә иде. Э инде аларның көзге алдында төзәтенеп торулары! Нинди шашкын мәхәббәт ялкыны ялтырый сыман иде ул чакта аларның күзләрендә! Күлмәк итәкләренең шыштырдавы нинди илаһи музыка булып ишетелә иде! Бәләкәй куллары, шарф, җилпәзәләренең тәнгә аз гына сыйпалып китүе дә күңелдә нинди ләззәтле хисләр уята иде!

Хәзер бу юанычлар берсе дә юк, һәммәсе мәңгегә артта калган. Ромашов моны үзе дә яхшы белә. Хәзер ул, беркадәр оят хисе белән булса да, үз-үзенә икърар итәргә мәҗбүр: үткәндәге бу соклану-куанычларның күп өлеше

төрле Густав һәм Арманнарның, рус илчелегенә кичәгә килгәч, вестибюль аша ничек залга узып керүләре турында тәфсиллəп язган француз романнарын уку тәэсиреннән генә булган икән. Шулай ук ул полк дамаларының еллар буе бер «затлы» күлмәктән йөрүләре, аеруча тантаналы кичәләргә озерләнгәндә бу «затлы» күлмәкне бер файдасызга тегеннән-моннан сиплəп маташулары, ә перчаткаларын бензин белән чистартулары хакында да хәзер бик яхшы белә инде. Аларның төрле бизәнү әйберләре: эгретка, шарфик, зур-зур ясалма ташлар, каурый, тасмалар белән мавыгуы көлке һәм артык дәгъвалы беркатлылык булып тоела; бу мавыгуда ниндидер арзанлы, зәвыксыз бер купшылык — чүпрәк купшылыгы ярылып ята. Алар майлы кершән-иннекләр ягыналар, әмма бу эшнең һич рәтен белмиләр: кайберләренең йөз-битләре чамасыз кершән-иннек ягынудан тәмам зәңгәрләнеп, куркыныч бер төскә кергән. Ләкин Ромашовны иң җирәндергәне болар түгел, ә икенче әйбер: ул, полктагы һәммә кеше кебек, һәрбер бал мәҗлесенең, хатын-кыз өстендәге һәрбер «затлы» күлмәкнең, һәрбер әйтелгән кыланчык сүзнең дигәндәй артында нәрсә ятканын ачык белә. Өметсез фәкыйрьлек, тырышу-тырмашу, хәйлә, гайбәт, үзара дошманлык, көче-чамасы җитмәсә дә, провинциаль бер үҗәтлек белән аристократлык уены уйнау һәм, ниһаять, күңелсез, пычрак гыйшык мажаралары — менә нәрсәләр ята алар артында...

Ул арада ишек төбе бүлмәсенә капитан Тальман белән аның хатыны килеп керде. Икесе дә тулы, озын буйлылар; хатыны — аксыл чәчле, юан, ишелгән-лыпырдык гәүдәле; ире — кара-тут тәнле, юлбасарныкыдай дәһшәтле чырайлы, карылдык тавышлы, үзе өзлексез ютәлли, йөткеренә. Ромашов аның кергәч үк үзенә нинди сорау белән мөрәҗәгать итәсен белә иде инде. Чыннан да Тальман, чегән күзләрен елтыратып, керә-керүгә үк:

— Карточныйда ни хәлләр, подпоручик, карта суга башладылармы инде? — дип сорады.

— Юк әле. Барысы да ашханә ягында.

— Шулаймыни? Алайса мин, Сонечка, шунда... ашханәгә таба киттем — «Инвалид»ны караштырырга. Сез, Ромашов, хөрмәтлем, аны, хатынны диюем... онытмагыз инде, берәр кадриль-мадриль белән күңелен табыгыз шунда.

Аннары ишектән бер оя чибәр йөзле, сакау, шаркылдык кызларын нәртеп, аналары җитәкчелегендә, Лыкачевлар гаиләсе килеп керде. Әни кеше дигәне кырык яшьләрдә булып, шул яшендә дә ул ару-талу белми биергә ярата һәм,

полк тел бистәсе Арчаковский әйтмешли, икенче белән өченче кадриль арасында «бала табарга»да өлгерә иде.

Туташлар, төрлесе төрле авазларны бозып шаркылдаша һәм берсен-берсе бүлә-бүлә, шундук Ромашовка ябырылдылар:

— Ник сес бесгә кеьеп чыкмыйсыс?

— Явыс, явыс, явыс!

— Әсәке, әсәке, әсәке!

— Явыс, явыс!

— Сесне беьенче кадьильгә чакыьам.

Ромашов исә, үзен түбәнчелекле кавалер хәленә куеп, аларның сүзләренә ирексездән:

— Mesdames!.. Mesdames!.. — дип торырга мәҗбүр булды.

Шул чакны аның күзләре ишеккә төште, һәм ишекнең пыялалы өлгесе артында эшләпәсе өстеннән тартма сыман почмаклап ак яулык бәйләгән Раиса Александровна Петерсонның калын иренле, ябык йөзен күрде. Ромашов, малайларча каударланып, тиз генә кунак бүлмәсенә кереп шылды. Күз ачып йомган арада булды бу хәл, подпоручик хәтта Раиса аны күрмәгәндер дип тә уйлады, шулай да күңелендә шом уянды: мәгъшукасының чырае ничектер үзгә, артык борчулы, ә бәләкәй күзләре ниндидер явыз, аяусыз дәһшәт белән янап, кисәтеп карыйдыр шикелле тоелды аңа.

Ул ашханәгә юл тотты. Анда инде шактый халык җыелган иде. Клеенка ябулы озын өстәл тирәсендә бер генә буш урын да калмаган диярлек. Бүлмә эчен зәңгәр тәмәке төтене сарган. Кухня ягыннан көйгән май исе килә. Икеме, өчме җирдә офицерлар, төркем-төркем җыелып, эчә һәм ашый ук башлаганнар. Кайберәүләр газета укый. Кешеләрнең үзара сөйләшкән куе, чуар гөрелтесе эчендә әледән-әле пычак чыңлавы, бильярд шарларының шалт-шолт бәрелүе һәм кухня ишегенең шапылдап ябылуы яңгырап китә. Аяк астында өйалды ягыннан кергән салкынча җил уйный иде.

Ромашов Бобетинскийны күзләре белән эзләп тапты да аның янына килде. Тегесе, папирос төтененә күзләрен кыса төшеп, кулларын чалбар кесәләренә тыккан хәлдә, үкчә һәм аяк очларында үзалдына чайкала-чайкала, өстәл янында басып тора иде. Ромашов җиңенә орынуга, ул:

— Нәрсә бар? — дип, җәһәт кенә борылды да, бер кулын кесәсеннән чыгарып, терсәген югары чөйде, күзен һаман кыса биреп, бармаклары белән бик ыспай кыяфәттә озын җирән мыек очларын бөтереп алды һәм Ромашовка

кырын гына карап: — Ә-ә! Сиз эфәндиләрмени әли бу? Ифрәт шәтмыш... — диде.

Ул һәрвакыт шулай тел ватып, кыланчыкланып сөйләшә һәм моны гвардиянең алтын яшьләре сөйләменә охшаш бер әйбәт сыйфат дип уйлый иде. Үзе турында ул гаять югары фикердә, үзен хатын-кыз һәм атлар белгече итеп, оста биюче,— юк, алай гына да түгел, аристократлар арасында гына була торган тиңдәшсез биюче итеп саный һәм, егерме дүрт яшьтә генә булуына карамастан, дөньядан тәмам бизгән, күңеле кайткан бер кеше рәвешендә күренергә тырыша иде. Шунлыктан аңарда бөтен нәрсә тамаша өчен эшләнә: иңбашлары кирәгеннән артык югары чөелә, теле белер-белмәс французчалаштырыла, аяк атлаулары — экрен, салмак, ә сөйләгән вакыттагы кул-бит хәрәкәтләре таркау, иренчәк була.

— Петр Фаддеевич, җаныкаем, минем бүгенге дирижерлык вазифасын үз өстегезгә алмассызмы икән,— дип үтенде Ромашов.

— Ме, моң ами! — диде Бобетинский, җилкә, кашларын җыерып, һәм Ромашовка таба җүләр сыман бер караш ташлап алды да:— Әмма ликин... дюстым,— дип, әлеге сүзләрен ана теленә күчерде.— Нигә әле мин алырга тиеш? Пуркуа? Чынлап, сез мине... ничек диләр әле?.. Сез мине ифрәт гаҗәпләндерәсез!..

— Җаныкаем, зинһар дип сорыйм...

— Сабыр итегез... Беренчедән, зинһарсыз гына сөйләшик. Ягъни мәсәлән, нәмәкәй димәкче булясыз сез, кадерлекәем, фәлян-төгян е цетера?

— Ну, үтенеп сорыйм, Петр Фаддеич... Башым бик авырта... тамагым да... чынлап, булдыра алмыйм.

Ромашов үзенең иптәшен бик озак күндереп маташты. Хәтта, тәмле телен эшкә җигеп, Бобетинскийны мактап та алды.

— Полкта сездәй бүтән кешесе дә юк бит аның, Петр Фаддеевич, биюне җиренә җиткереп бары сез генә оештыра аласыз. Аннан соң, моны сездән бер ханым да үтенгән иде...

— Ханым?.. — Бобетинскийның йөзенә искитмәүчән, меланхолик бер күләгә ятты.— Һе, ханым дисез, ә? Минем яшьтәге кешегә, дюстым... — Ул ясалма үкенү, өметсезлек белән көлемсерәп куйды.— Ни нәрсә ул хатын-кыз? Ха-ха-ха... Юн энигм![1] Ну, ярар, сездән котылып булмастыр, ахры... Мин риза.

---

[1] Табышмак.

Һәм шундый ук дөньядан бизгән, өметсез тавыш белән кинәт өстәп куйды:

— Мон шер ами[1], ә сездә табылмасмы икән... ничек диләр әле... өч тәңкә?

— Юк шул, кызганычка каршы!.. — диде Ромашов, авыр сулап.

— Ә бер тәңкә?

— Мм!..

— Дезагреабль...[2] Бернәмәстәкәй дә эшләп булмый, димәк. Ярар, алай булгач, утырыйк аракы эчәргә.

— Анысы да булмый! Кредит бетте, Петр Фаддеевич.

— Кит әле? О, повр анфан!..[3] Барыбер, әйдәгез,— диде Бобетинский, юмартлыгын күрсәткәндәй бер кыяфәт белән кулларын җәеп җибәреп.— Сезгә ихтирамымны белдерәм.

Ул арада ашханәдәге гәп тагы да кыза, көчәя төште һәм тыңлар өчен дә кызыклырак юнәлеш алды. Сүз күптән түгел генә рөхсәт ителгән офицер дуэльләренә күчеп, һәркайсы бу мәсьәләдә үз карашын якларга тырыша иде.

Бигрәк тә поручик Арчаковский күп сөйләде. Шулер диярдәй кара тарихлы бер шәхес иде бу. Әйтүләренә караганда, аны кайчандыр, әле полкка килгәнче үк, запаста чакта, ниндидер почта станциясендә смотритель булып хезмәт иткән һәм шунда бер ямщикны йодрыгы белән сугып үтергән, имеш, диләр иде.

— Дуэль ул гвардиядә, төрле җилкуар, эшсез, шамакай бәндәләр арасында гына яхшы,— дип сөйләнде ул тупас төстә.— Ә бездә... Ну, ярый, мин, буйдак кеше... җәмгыятьтә икәүләп эчеп утырган чакта... әйтик, артык исереп китеп, Василь Василич Липскийның яңагына менеп төштем, ди. Шуннан ни эшләргә инде безгә? Әгәр Василич минем белән атышырга теләмәсә, аны, димәк, полктан куачаклар; ул чакта аның бала-чагасы ни нәрсә ашап торыр? Ә инде атышырга уйласа, мин аның корсагына бер пуляны тамызам да куям,— балалары тагы ач кала дигән сүз... Юк нәрсә бу.

— Ни... тукта... сабыр ит син,— дип бүлдерде аны карт һәм исерек подполковник Лех. Бер кулына рюмка тоткан килеш, ул икенче кулы белән һавада зәгыйфь-көчсез бер хәрәкәт ясап алды.— Мундир намусы дигәннең ни нәрсә икәнен аңлыйсыңмы син?.. Ни... туганкай, шу-ундый нәрсә ул... Намус ул, беләсең килсә... Хәтеремдә, 1862 елны без-

---

[1] Кадерле дустым.
[2] Нинди үкенеч.
[3] Мескен малай.

нең Темрюк полкында, мәсәлән, шундый бер хәл булган иде...

— Ну, сезнең ул хәлләрегезне тыңлап бетерә алмассың,— дип, аның үзен сүздән бүлдерде Арчаковский.— Сез алайса саламторхан заманыннан да берәр нәрсә сөйләп ташлагыз булмаса.

— Ни-ни, туган... артык әче телләнәсең әле син... Малай гына әле үзең, ә мин синең алда, ни... Әйтәм бит, шундый бер хәл булган иде дим...

— Бу мыскылны фәкать кан белән генә юарга мөмкин,— дип сүз кыстырды поручик Бобетинский күпшы тавыш белән һәм әтәч сыман иңбашларын кабартты.

— Ни, бездә Солуха дигән бер прапорщик бар иде,— диде Лех, сүзен дәвам итмәкче булып.

Шул чак буфеттан беренче рота командиры капитан Осадчий чыкты да болар янына килеп басты.

— Ишетүемчә, сез дуэльләр хакында сөйләшәсез бугай. Кызык, тыңлап карыйк әле,— диде ул, бүлмәдәге бөтен гөрелтене күмәрдәй калын, куе бас тавыш белән.— Здравия желаю, господин полковник. Исәнмесез, әфәнделәр.

— Ә, Родос һәйкәле,— дип, көлөч елмаеп каршы алды аны Лех.— Ни... утыр әле яныма, тере һәйкәл... Аракы эчәсеңме минем белән?

— Эчәм, әлбәттә! — дип җавап бирде Осадчий, гөрелдәп.

Бу офицер Ромашовның күңелендә һәрвакыт курку катыш кызыксыну сымаграк ниндидер сәер һәм ачу китергеч бер хис уята иде. Полковник Шульгович кебек үк, Осадчий да полкта, алай гына түгел, бөтен дивизиядә, үзенең гадәттән тыш гайрәтле, матур яңгырашлы тавышы, шулай ук әзмәвердәй буй-сыны һәм коточкыч зур физик көче белән дан тота иде. Моның өстенә ул — менә дигән строевой офицер. Кайчак аны, хезмәт файдасын күздә тотып, ротадан ротага күчереп йөртәләр, һәм ул ниндидер ярты ел вакыт эчендә иң тәртипсез, иң хөрти саналган команданы да аякка бастыра, аны башлыклар алдында гайре табигый тетрәнү белән калтырап торырлык күндәм, төзек зур бер машина хәленә китереп җиткерә. Каян ала ул мондый көч, гайрәтне — ипташләренә һич аңлашылмый, чөнки Осадчий табигате белән болай шактый сабыр кеше: дуэльдә сугышу түгел, аның кеше белән чынлап торып эрепләшкәне дә юк; тупаслыкны аңардан бик сирәк, гадәттән тыш очракларда гына ишетергә мөмкин. Осадчийның коңгыртқара, хәтта чем-кара дип әйтердәй чәче фонында тагы да агарыбрак күренгән аксыл-соры, матур, шомлы, караңгы

чыраенда Ромашовка һәрвакыт ниндидер яшерен-сабыр, кешегә түгел, фәкать көчле җанварларга гына хас үтә киреңке, рәхимсез, аяусыз бер нәрсә чагыладыр сыман тоела иде. Еш кына ул, Осадчийны ераклан сиздермичә генә күзәтә-күзәтә, ачуланган вакытында бу кеше нинди була икән, дип уйлап куя һәм шуны күз алдына китергәч, куркудан шундук бармак очларына хәтле суыгаеп китә, ә чырае тәмам агарынып чыга иде. Менә хәзер дә ул аның үз көчен, үз кадерен яхшы белгән бер кыяфәттә урындыкка ашыкмыйча, тыныч кына килеп утыруын күзен дә алмый карап торды.

Осадчий аракы салып эчте, кытыр-кытыр редис чәйнәде дә әллә ни исе китмәгән кыяфәттә:

— Йә, шуннан, мөхтәрәм җәмәгать әһле нинди нәтиҗәгә килде соң? — дип сорады.

— Ни, энекәшкәем, мин әле бер вакыйга сөйли идем... Темрюк полкында хезмәт иткән чагымда, ягъни, бездә шундый бер хәл булды. Шулай бервакыт җәмгыять клубында фон Зоон дигән бер поручик — аны солдатлар «Под-Звон» дип атап йөртәләр иде,— менә шул кеше...

Ләкин аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәделәр. Яше кырыкка җитүенә карамастан, үзен һәркем яратырга тиешле иркә, мәзәк бер малай сыман кыланып сөйләргә гадәтләндергән һәм офицерлар җәмгыятендә шамакай ролен уйнаган юан гәүдәле, кызыл битле штабс-капитан Липский кинәт сүз алды:

— Кыскача эш болай тора, капитан әфәнде. Менә поручик Арчаковский әйтә, дуэль — ул юк нәрсә, ди. «Җәнҗәл чыга икән, безнең бурсадагы кебек, көндәшеңнең яңагына берне күндырасың да — шуның белән вәссәлам!» — ди. Аңа поручик Бобетинский каршы төште; ул әйтә, мондый чакта кан кирәк, ди. Аннан менә полковник әфәнде үзенең үткән тормышыннан анекдот сөйләргә тырышып карады, тик һаман әле аны сөйләп чыга алганы юк шикелле. Аннары, бәхәснең башында ук, подпоручик Михин шау-шу арасында үз фикерен мәйданга куймакчы булган иде дә, әмма, беләсез, ул артык оялчан кеше, аннан тавышы да бик чамалы, шуңа күрә аның фикеренә колак салмадылар.

Коңгырт-кара матур күзләре һәрвакыт ниндидер эчке бер өркү, курку белән караган, сипкел аралаш шадра битле, зәгыйфь күкрәкле, тәбәнәк буйлы подпоручик Михин кинәт бурлаттай кызарынып чыкты.

— Мин, әфәнделәр, фәкать... Мин, әфәнделәр, бәлки ялгышамдыр,— дип, тотлыга-тотлыга, уңайсызланудан са-

кал-мыексыз шадра битен учлары белән ышкый-ышкый, сөйләп китте ул.— Ләкин, минемчә, ягъни мин болай уйлыйм... монда һәр очракны аерым алып карарга кирәк. Кайвакыт дуэль файдалы булырга мөмкин, бу — һичшиксез шулай, һәм безнең һәркайсыбыз андый чакта атышу мәйданына курыкмый чыгып басарга тиеш, әлбәттә. Һичшиксез шулай. Ләкин кайвакытны, үзегез аңлыйсыз, ни... әлеге... иң югары намуслылык, бәлки... нидән... Һичшиксез гафу итүдән гыйбарәттер... Ну, мин барлык очракларны да санап китә алмыйм, шулай да... менә, әйтик...

Арчаковский дорфа төстә кулын селтәп, аны сүзеннән бүлде.

— Их, Декадент Иванович, сезгә әле тастар суырып ятарга иде.

— Ни, туганнар, сүземне әйтеп бетерергә бирегез инде!

Шул чак, бүлмәдәге бөтен тавышларны каплап, Осадчийның гайрәтле гүелдәве ишетелде:

— Дуэль, әфәнделәр, һәрвакыт фаҗига белән бетәргә тиеш, шунсыз аның мәгънәсе юк! Шунсыз ул кызгану, гафу итү, мәрхәмәт дигән ахмак нәрсәгә, ягъни комедиягә кайтып кала. Илле адым ара, берәр пуля — хикмәт менә шунда. Юкса, әйтәм бит, ул әлеге, без газеталардан укый торган француз дуэльләре сыман җирәнгеч уенга әверелә. Киләләр дә, имеш, пистолетларыннан аткан булып кылаланалар, ә икенче көнне газетада бу атышуның хәбәрен укыйсыз. Янәсе: «Дуэль, бәхеткә каршы, фаҗигасез тәмамланды. Көндәшләр, үзләрен гаять батыр тоткан хәлдә, кара-каршы атыштылар, әмма икесе дә исән калды. Иртәнге аш табыны янында алар дусларча бер-беренең кулларын кысыштылар». Мондый дуэль, әфәнделәр, чепуха. Аның безнең җәмгыятькә бернинди файда китерүе дә мөмкин түгел.

Шундук аңа берьюлы берничә тавыш җавап бирде. Осадчий сөйләгәндә баягы хикәясен бәян итәргә берничә тапкыр ымсынган Лех: «Ә менә мин, туганнар, ни... тыңлыйсызмы инде сез, әллә юкмы, сабырсыз айгырлар»,— дип тагы тотынган иде дә, сүзенә беркем дә колак салмагач, теләктәшлек эзләп, күзләрен бер офицердан икенче офицерга күчереп йөртә башлады. Ләкин тегеләр, бәхәс белән мавыгып, аңа илтифатсыз булдылар, шуңа күрә Лехка авырайган башын хәсрәтле төстә чайкап утырудан башка чара калмады. Ниһаять, аның күзе Ромашовка төште. Яшь офицер игътибарсызлык, санламауның ничек авыр булганын үз тәҗрибәсеннән дә белә иде. Мондый чакта кеше хурланудан үзен кая куярга белми, үҗәтләнеп, һаман сөйләргә

омтыла, ләкин аның кат-кат әйткән сүзләре, таяныч тапмагандай, һавада асылынып калалар. Подполковникның шундыйрак хәлгә таруын төшенеп, Ромашов аңа ачык йөз күрсәтте, тегесе исә шатлыгыннан аны шундук җиңеннән эләктерде дә өстәл янына өстерәде.

— Ни... ичмасам син тыңла, прапор,— диде ул хәсрәт белән,— утыр әйдә, аракы эчеп җибәр... Алар һәммәсе бушбугазлар, туганкаем,— диде аннары, бәхәсләшүче офицерларга таба кул чугы белән әкрен генә селтәп куеп.— Һау да һау, э үзләрендә бер тиенлек тәҗрибә юк. Бая мин үзебездә булган бер очракны сөйләмәкче идем...

Һәм ул, бер кулына рюмка алып, э икенчесен хорга җитәкчелек иткәндәй, болгап-тулгандырып, түбән иелгән башын чайкый-чайкый, үзенең чираттагы кыйссасын сөйләргә кереште. Гадәттә, мондый кыйссалар Лехта меңләгән, алар белән ул гүя эчәк-бавыр колбасасыдай дыңгычлап тутырылган, ләкин хикәясенә һәрвакыт төрле чигенешләр, өстәмәләр, озын-озын чагыштырулар, табышмаклар кертүе сәбәпле, аның әле беркайчан да теге яки бу кыйссасын ахыргача сөйләп чыга алганы юк. Хәзерге анекдоты исә аның шуннан гыйбарәт иде: имеш, кайчандыр,— бик күптән, Лехның яшь чагында ук, әлбәттә,— бер офицер икенче бер офицерга америкача дуэль тәкъдим итә. Җирәбә итеп болар бер тәңкәлек кәгазь акча алалар: анда сугылган санның суммасы җөпме, такмы, янәсе. Ләкин ике офицерның берсе,— Под-Звонымы, әллә Солухасымы шунда, төгәл кайсы икәне аңлашылмый иде, — алдашырга уйлый: «Ни, туганкай, ала да бу ике кәгазь акчаны, бер-беренә ябыштырып, акчаның бер ягында җеп, э икенче ягында так саннар китереп чыгара. Шуннан жирәбә тарта башлыйлар... Монысы әйтә тегеңә...»

Әмма полковник бу юлы да, гадәте буенча, үзенең анекдотын сөйләп бетерә алмады, чөнки нәкъ шул чакны буфетка Раиса Александровна Петерсон атылып керде дә, ашханә бусагасында туктап (ашханә эченә үк узу әдәпсезлек санала иде), наз, ярату эчендә үскән кыз балаларга хас кыланчык, шат-чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Әфәнделәр, нинди оятсызлык инде бу! Ханымнар җыелып беткәненә биш былтыр, э сез һаман монда сыйланып утырасыз! Безнең биисебез килә!

Икеме, өчме офицер, залга чыгарга дип, өстәл яныннан күтәрелде, әмма күпчелек, кыланчык ханымның сүзләрен колакка да элмичә, әүвәлге рәвешләрендә гәп сатып, тәмәке тартып утыруларында булдылар. Аның каравы карт полковник Лех вак-вак атлап, исерек адымнары белән тиз

генә ханым каршысына килеп басты да, кулын күкрәгенә кушырып, рюмкасыннан түшенә аракы түгә-түгә, сәрхүшләрчә тәэсирләнеп кычкырды:

— Йа, нинди илаһи зат! Бу кадәр гүзәллекне бер үзегезгә җыярга начальство ничек рөхсәт бирә сезгә! К-кулыгызны!.. Үбимче!

— Юрий Васильевич,— дип, үзенекен такылдый бирде ул арада Петерсон,— сезгә бүген дирижерлык вазифасы тапшырылган иде түгелме соң? Ай-яй, шәп дирижер икәнсез, әйтәсе дә юк!

Шул чак өстәл яныннан Бобетинский күтәрелде, нинди-дидер күңелле балет биюенең беренче башлангыч хәрәкәтләрен ясарга керешкән кыяфәт белән, салынкы кул очларын уйната-уйната гәүдәсен чайкалдырып, чүгәләп һәм аякларын чаш-чош китереп, бии-бии китте дә күз ачып йомган арада Петерсон ханым каршысына килеп туктады.

— Миль пардон, мадам. Се ма фот!.. Минем гаеп! Кулыгызны бирегезче! Вотр мэн, мадам. Офәнделәр, залга чыгыгыз, залга!

Шулай дип, ул Петерсон ханымны кулыннан җитәкләде һәм башын горур чөеп, залга таба атлады. Бераздан анда аның үзенчә бик мәһабәт, затлы дип уйлаган дирижерлык боерыклары ишетелде:

— Месьё, туташ-ханымнарны вальска чакырыгыз! Музыкантлар, вальс уйнагыз!

— Гафу итегез, полковник әфәнде, мине анда хезмәт вазифаларым көтә,— диде Ромашов.

— Эх, туганкай, туганкай,— дип куйды Лех, хәсрәтле төстә башын иеп.— Син дә шул ук борыч кузагы, бөтенесе кебек... Ни... тукта әле, сабыр ит, прапорщик... Мольтке турында ишеткән бармы синең? Әлеге теге, гомере буе аз сөйләшкән бөек кеше, фельдмаршал... теге, ни... стратег Мольтке турында?

— Полковник әфәнде, чынлап менә...

— Ә син сабырсызланма... Кыйссасы аның озын түгел... Шул, әлеге аз сүзле бөек адәм еш кына офицер җәмгыятьләренә кереп йөри икән. Керә дә икән шунда, ашаган чагында... ни... алтын тулы янчыгын гел, малай, үзенең каршысына, өстәл өстенә куя икән. Нәзере булган аның: әлеге алтын янчыгын ул акыллы сүз әйткән беренче офицерга бирергә теләгән. Ләкин, мескен, бу дөньяда туксан яшькә җитеп тә, янчыгын беркемгә бирә алмыйча үлеп киткән. Нәрсә? Хикмәтенә төшендеңме? Ярар алайса, хәзер инде юлында бул, туганкай. Бар, бар, чыпчык баласы... сикеренә бир...

IX

Колак тондыргыч музыка тавышына дүрт як стенасы дигәндәй дерелдәп торган залда ике пар кеше вальс биеп йөри иде. Бобетинский, терсәкләрен кош канатыдай җәеп, таш монумент сыман талгын гына, мәһабәт кенә хәрәкәтләнгән озын буйлы Тальман ханым әйләнәсендә бөтерелә. Биек, чандыр Арчаковский исә Лыкачевларның алсу битле, бәләкәй, йомры гәүдәле төпчек кызларын эләктереп алган; ул башын кызга таба чак кына ия төшеп, күзләре белән аның ачылып торган чәч юлына төбәлгән; үзе, бию фигуралары ясап маташмыйча, сабый бала белән биегән кебек, аякларын иренеп, шудырып кына йөртә. Калган унбишләп хатын-кыз стена буена тезелешеп утырганнар. Чырайларында ясалма ваемсызлык: янәсе, аларга барыбер. Полкның җәмәгать җыеннарында һәрвакытта булганча, бүген дә кавалерлар саны хатын-кыз җенесеннән бер дүрт мәртәбәгә кимрәк, шуңа күрә кичәнең баш өлеше шактый күңелсез булачагы әллә каян сизелеп тора иде.

Петерсон ханым, кичәне ачып, шуның белән барлык хатын-кыз җәмәгатендә, гадәттәгечә, үзенә бер төрле горурлык хисе кузгаткач, нәзек, зифа буйлы Олизар белән беренче булып биергә чыкты. Олизар аның бер кулын, кадакка беркеткәндәй, үзенең сул як ботына кысып тотты, ә икенче кулын Петерсон ханым егетнең иңбашына салган һәм шул кулы өстенә яге белән терәлеп, башын шактый һавалы һәм гайре табигый төстә артка, залга таба борган иде. Биеп бетергәч, ул юри Ромашовка якынрак җиргә — хатын-кызларның киенү-бизәнү бүлмәләренә керә торган ишек янына барып утырды. Утырды да, җилпәзәсен селеккәләп, үзенә таба иелгән Олизарга караган килеш, изрәгән, көйле тавыш белән:

— Граф, чынлап, нигә миңа гел шулай кызу була икән? Зинһар дим, әйтегезче шуны!.. — диде.

Олизар, чак кына баш кагып, шпорларын чыңлатып алды, тырпы мыегын башта бер якка, аннан икенче якка сыпырды.

— Ханым-солтаным, моны хәтта Мартын Задека үзе дә әйтеп бирә алмас.

Шулай дип, ул Петерсон ханымның яссы ачык изүенә күзен текәде; тегесе, моны сизеп, сулышын үтә еш һәм артык тирән итеп ала башлады.

— Ах, минем температурам гел шулай югары була шул! — диде Раиса Александровна, үзенә бер төрле елмаеп. Аның бу елмаюында бүтән мәгънәгә, оятсыз мәгъ-

нәгә ишарә барлыгы ачыктан-ачык сизелеп тора иде.— Темпераментым шундый кайнар булгач, нишләмәк кирәк!..

Олизар серле генә итеп шаркылдап көлеп куйды.

Ромашов бер читтән Петерсон ханымны күзәтте һәм аның турында үзалдына: «Йа хода, бу кадәр җиңгеч булыр икән!» — дип уйлады. Бу хатын белән элегрәк физик якынлыкта булуын да күз алдына китергәч, ул үзен гүя берничә ай юынмаган һәм эчке киемнәрен алыштырмаган бер кеше итеп хис итте.

— Әйе, чынлап, чынлап, граф, сез көлмәгез! Сез белмисездер әле, минем әни грек милләтеннән бит!

«Сөйләшүенә хәтле косасыны китерә,— дип уйлады Ромашов.— Сәер, моңарчы шуны ничек сизмәгән икәнмен мин? «Бибеб әби грек билләтеббәб бит» — борынында шеш яисә бетмәс томау диярсең».

Шул чак Петерсон ханым Ромашовка таба борылып, ачулы кысык күзләрен аның йөзенә кадады.

Ромашов исә, гадәте буенча үзен өченче затка куеп, эченнән: «Аның йөзе, маска кигәндәй, чит күздән яшеренде» — дип уйлап алды.

— Исәнмесез, Юрий Алексеевич! Сез нигә әле килеп исәнләшми дә торасыз? — диде Раиса Александровна, көйләп.

Ромашов алар янына килде. Хатын, ачулы-усал һәм кинәттән генә тагы да кечерәеп, очлаеп киткән бәбәкләре белән егетнең йөзенә кадалып, аның кулын каты итеп кысты.

— Үтенечегезне искә алып, мин сезнең өчен өченче кадрильне калдырдым. Шәт, онытмагансыздыр?

Ромашов баш какты.

— Сезгә нәзакәтлек җитми,— дип, кылануын дәвам иттерде Петерсон.— Сез: аншанте, мадам! [1] дип әйтергә тиеш идегез (Ромашовның колагына бу сүзләр «адшадте, бадаб» булып ишетелде). Граф, ничек уйлыйсыз, ул чыннан да капчык бит, э?

— Онытмадым... Исемдә,— дип мыгырданды Ромашов, каушый калып.— Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

Бобетинский кичәне җанландыру өчен әллә ни артык тырышлык күрсәтмәде. Бүтәннәргә бик кирәкле, әмма үзе өчен һич әһәмияте булмаган, алай гына да түгел, үзен коточкыч туйдырып бетергән ниндидер мәҗбүри бер эшне башкаргандай, ул бал-мәҗлескә иренеп кенә дирижерлык итте, барысын да ничектер арыган, битараф кыяфәт белән

---

[1] Мин искиткеч шатмын.

эшләде. Ләкин өченче кадриль башланыр алдыннан аңа җан керде. Ул, боз өстеннән тимераякта шуып үткән сыман, чаш-чош атлап залны тиз генә бер әйләнеп чыкты да аеруча каты тавыш белән:

— Кадриль-монстр! Кавалье, ангаже во дам!»[1] — дип сөрән салды.

Ромашов белән Раиса Александровна музыкантлар утырган тәрәзә турысынарак елыша төштеләр. Аларга vis-a-vis[2] Михин һәм Лещенко хатыны бии иде. Лещенко хатыны артык тәбәнәк, буе кавалерының җилкәсенә дә җитәр-җитмәс кенә иде.

Өченче кадрильгә халык шактый күп җыелганлыктан, биюче парларны залның буена да, иңенә дә тезеп бастырып, чират белән биетергә булдылар. Шул сәбәпле музыкантлар һәр фигураны икешәр кат уйнарга мәҗбүрләр иде.

Ромашов, галерея тәрәзәсеннән залга ургылып кергән барабан һәм җиз трубалар гөрелтесенә тәмам колагы тонган хәлдә, үзалдына уйланып куйды: «Безгә, аңлашырга кирәк, бу эшкә чик куярга кирәк. Җитәр!»

Һәм тагы: «Аның чыраенда какшамас гайрәт, тәвәккәллек чагылып күренде».

Полк дирижерларында элек-электән бию вакытында нинди дә булса үзгә бер хәрәкәт яки мәзәк ясап кеше көлдерү гадәте бар иде. Мәсәлән, өченче кадрильдә фигураларның тәртибен бутау, биюгә юри ялгышлар кертеп җибәрү биючеләр арасында һәрвакыт күңелле ыгы-зыгы һәм шаркылдашу китереп чыгара иде. Бу юлы да Бобетинский, кадриль-монстрны һич көтмәгәндә икенче фигурадан башлап, кавалерларны башта соло биергә мәҗбүр итте, аннары, ялгышын төзәткән булып, аларны шундук дамалары янына кире кайтарды, аның соңында, grand-rond[3] ясап, түгәрәкне бутады да, дамаларын эзләттерә-эзләттерә, кавалерларны тәмам алҗытып бетерде.

— Медам, авансе... гафу итәсез, рекуле! Кавальо соло! Пардон, артка чигенегез, балянсе авек во дам![4] Артка чигенегез дим бит!

Раиса Александровна ул арада, ачудан сулышына буылып, әмма аны йөзенә чыгармыйча, алай гына да түгел, бөтенләй күңелле, җанга рәхәт нәрсәләр турында сөйлә-

---

[1] Кавалерлар, дамаларны чакырыгыз!

[2] Каршы.

[3] Зур түгәрәк.

[4] Дамалар, алга... артка! Кавалерлар, ялгыз! Гафу итегез, дамаларыгызны җитәкләп барыгыз!

гәндәй елмаюлы бер чырай белән, Ромашовка чәнечкеле сүзләрен яудыра бирде:

— Карагыз аны, мин үземнән көләргә ирек куймаячакмын. Ишетәсезме? Мин сезгә нәни кызчык түгел. Әйе. Әдәпле кеше болай эшләми. Әйе.

— Ачуланышмыйк, Раиса Александровна,— дип үтенде Ромашов, ягымлы гына итеп.

— Һи, ачулану сезнең өчен артык зур мәртәбә булыр иде! Сезгә минем нәфрәттән кала бүтән бернинди хиссем юк. Ләкин үземне мыскылларга мин беркемгә дә юл куймаячакмын. Ник сез минем хатка җавап бирмәдегез?

— Хатыгыз килгәндә мин өйдә юк идем, валлаһи менә.

— Һы! Әле алдашып маташкан буласыз! Әйтерсең, мин сезнең кая барып йөргәнегезне белмим... Ялгышасыз, бик яхшы беләм...

Бобетинский исә:

— Кавалье, ан аван! Рон, де кавалье [1], Л гош! Сулга, сулга! Сулга дим, сулга, әфәнделәр! Их, берни аңламыйлар! Плю де ля ви, месьё! [2] — дип, биючеләрне ашыктыра, аларны тыпыр-тыпыр сикергәлән зал буйлап бөтерелергә мәҗбүр итә иде.

— Ул лилипутка хатыныгызның барлык мәкерләрен беләм мин,— дип дәвам иттерде Раиса, янына Ромашов янәдән бии-бии әйләнеп килгәч. — Тик ул юкка алай борынын күтәрә! Аның казна карагы — нотариус кызы икәнлеген...

— Минем алда минем танышларым турында алай начар сөйләмәвегезне үтенер идем,— дип кырт кисте аны Ромашов.

Шул чак Петерсон ханым, бөтенләй чыгырдан чыгып, Шурочканы яман эшәке сүз белән телгә алды. Ясалма елмаюларын да онытып, ачудан кызарынган-бүртенгән кыяфәттә, ул үзенең томаулы, тыңкыш тавышы белән хәтта музыка гөрелтесен дә күмеп китәргә тырыша кебек иде. Ромашов тәмам аптырап калды һәм үзенең шундый көчсез булуыннан, Шурочка турында шундый мәсхәрә ишетү гарьлегеннән, колак тондыргыч кадриль шавы аша бу мәсхәрәгә каршы бер кәлимә сүз әйтә алмавыннан, нинаять, ин мөһиме — тирә-якта үзләренә кешеләр игътибар итә башлавын күрүдән күз яше килер дәрәҗәдә кызарынып чыкты.

— Әйе, әйе, әтисе казна карагы булган аның, һич тә борын чөяр урыны юк,— дип кычкыра бирде Петерсон

---

[1] Кавалерлар, алга! Кавалерлар, түгәрәккә тезелергә!

[2] Җанлырак итеп, әфәнделәр!

ханым.— Безне санга сукмый йөргән була, янәсе. Без дә аның хакында кайбер нәрсәләр беләбез! Әйе!

— Утенәм сездән,— дип мыгырданды Ромашов.

— Ярар, тырнакларымның нинди очлы икәнен күрерсез әле, икегез дә күрерсез. Җүләр Николаевыгызның да күзен ачармын. Шуны инде өч ел буена академиягә сөйрәп кертергә йөри бит әле, тегесен әйтәм. Кая инде аның иренә академиягә керү, шыр тиле ич ул, борыны астында ниләр эшләнгәнен дә күрми. Хәер, көндәшен дә әйтер идем — икесе бер чыбыктан сөрелгән!..

— Мазурка женераль! Променад! [1] — дип кычкырып җибәрде кинот Бобетинский. Ул, гәүдәсен очып барган фәрештәдәй алга ташлап, зал буйлап чабып узды.

Шуның артыннан ук зал идәне авыр аяк тыпырдавына дәррәү дерелдәп китте, люстра асмалары, төрле төсләр уйнатып, мазурка көенә чыңлап куйды, ә тәрәзәләрдәге пәрдәләр талгын гына дулкынланып чайкала башладылар.

— Ә ник безгә тыныч кына, тату гына аерылышмаска? — диде Ромашов, кыюсыз бер тавыш белән. Җирәнү хисеннән тыш, бу хатын аның күңелендә вак, әшәке икенче бер хис — котылгысыз шүрләү хисе тууга да сәбәп булган иде.— Сез мине бүтән яратмыйсыз, ахры... Аерылышыйк соң, әйбәт дуслар булып аерылышыйк.

— О-о! Сүзне читкә бормакчы буласызмы? Юк инде, жаныкаем,— бу сүз Ромашовка «жабыкаеб» булып ишетелде,— борчылмагыз, мин ташлап калдырыла торганнардан түгел. Вакыты җиткәч, мин үзем дә ташлый беләм. Ләкин мине сезнең шулкадәр түбән жанлы булуыгыз гажәпләндерә...

Ромашовның сабыры төкәнә башлады.

— Бетерик бу сүзне,— диде ул саңгырау тавыш белән, тешләрен кысып.

— Биш минутка тәнәфес. Кавалье, аккюпе во дам! [2] — дип кычкырды дирижер.

— Әйе, әйе, вакыты җиткәч, мин үзем дә бик әйбәт ташлый беләм. Сез мине оятсызларча алдап йөрткәнсез. Мин сезнең хакка бөтен нәрсәмне корбан иттем, намуслы хатын көченнән килгән бөтен нәрсәмне бирдем... Сезнең аркада иремнең, шундый әйбәт, гүзәл бер кешенең, күзләренә туры карый алмас хәлгә төштем. Сезнең хакка гаиләмне, ана һәм хатынлык вазифаларымны оныттым. Йа ходай, ник мин иремә генә тугры булып калмадым икән!

---

[1] Прогулка.

[2] Кавалерлар, дамаларыгызның күңелләрен ачыгыз!

— Шу-лай бул-мыйча!

Ромашов ихтыярсыз елмаеп куйды. Раиса Александровнаның полкка хезмәткә килгән барлык яшь офицерлар белән гыйшык куертуын полкта һәрбер кеше белә иде диярлек. Хәер, аныкын гына түгел, полктагы җитмеш биш офицерның һәркайсыныкын, аларның хатыннары, кардәш-туганнарыныкын да һәркем белә иде. Ромашов шундук Раисаның үз ире турында хатларында язган яисә телдән сөйләгәндә әйткән: «ахмак», «җебегән», «косасын китергеч бәндә», «агач бүкәне, һаман чыгып китми бит» кебек үтә чәнечкеле, кинәле тәгъбирләрен хәтеренә төшерде.

— А! Әле җитмәсә авызыгызны ук җырасызмы? — дип ярсып кычкырды Раиса, әмма шундук исенә килде: — Безгә башларга! — диде дә, йөзенә көчәнүле елмаю галәмәте чыгарып, Ромашовны кулыннан алды һәм арт санын мәһабәт төстә тулгандыра-тулгандыра, вак адымнар белән уртага таба биеп китте.

Бию фигурасы тәмамлануга аның чырае янәдән әүвәлге җенле-ачулы рәвешенә кире кайтты,— «ярсып котырынган бөҗәк танавымыни»,— дип уйлап алды Ромашов, ирексездән.

— Мин моны бәхиллә дип өмет итмәгез! Гомерем буе бәхилләмәячәкмен, ишетәсезме? Мине шулай оятсыз, минһербансыз рәвештә ни өчен ташлап китәргә теләвегезне бик яхшы беләм мин. Ләкин сез теләгән ул нәрсә барыбер барып чыкмаячак, барып чыкмаячак, чыкмаячак! Мине яратмый башлавыгызны ачыктан-ачык, ихластан әйтәсе урында, сез алдашырга керешкәнсез. Янәсе, тегендә алай-болай каршылык туа калса, мине үзенең... хайвани хисен канәгатьләндерү өчен вакытлыча саклап тота... Ха-ха-ха!..

Ромашов, агарынганнан-агарына барып, ярсудан иренәрен тешләп-тешләп алды.

— Ярар соң, ачыктан-ачык сөйләшик алайса,— диде ул, үз-үзен чак кына тыеп. — Үзегез шуны телисез бит. Әйе, дөрес — мин сезне яратмыйм.

— Һай, харап булдым, гарьлегемнән нишләрмен икән!

— Моңарчы да яратмадым. Хәер, сез үзегез дә мине яратмадыгыз. Без икебез дә ул чакта ниндидер үтә әшәке, ялган, пычрак уен, һәвәскәрләрчә ниндидер эчпошыргыч фарс уйнап йөргәнбез. Мин сезне бик шәп, искиткеч шәп аңладым, Раиса Александровна. Сезгә наз да, мәхәббәт тә кирәк булмаган, хәтта, гади бер күңел багланышы да кирәкмәгән. Моның өчен сез артык вак җанлы, кысыр күңелле кеше, күрәсең; чөнки,— дип дәвам итте Ромашов, кинәт кенә Назанскийның сүзләрен исенә төшереп,— чөнки

чын ярату хисен фәкать олы җанлы, нечкә күңелле шәхесләр генә татый ала.

— Ха, ул нечкә хисле шәхесләрнең берсе — сез инде, әлбәттә, шулаймы?

Янә музыка яңгырады. Ромашов галерея тәрәзәсе аша ялтырап күренгән һәм залга ярсулы бер ваемсыз битараф-лык белән ниндидер ырылдау, хырылдау авазлары төкереп торган тромбонның җиз авызына нәфрәтле күз карашы ташлап алды. Шулай ук аның уйнаучысы — яңакларын бүлтәйтә-бүлтәйтә тромбон көпшәсенә өргән һәм артык көчәнүдән йөзе тәмам зәңгәрләнеп бүртенгән, күзләре пыялаланып акайган солдат та Ромашов күңелендә нәфрәттән гайре хис уятмады.

— Ул хакта сүз куертмыйк. Бәлки, мин үзем андый чын мәхәббәткә бөтенләй лаек кеше түгелмендер, ләкин хикмәт бит анда түгел. Хикмәт шунда: сезгә, тар, провинциаль фикерле, мин-минлеге шул провинциаль дәрәҗәдән югары күтәрелмәгән кешегә, һәрвакыт кемнеңдер сезгә табынып торуы, сезне «чолгап» торуы кирәк. Җитмәсә тагы, моны башкалар да күрсен, белсен. Кичәләрдә бергә булган чакта сезнең, әйтик, чит кешеләр алдында миңа ачыктан-ачык үз үтеп, күрәләтә яратып каравыгыз, тәкәллефсез, боеручан, интим тон белән эндәшүегез — боларның асыл мәгънәсен мин әллә аңламагандыр дип уйлыйсызмы? Әйе, әйе, нәкъ менә тамаша булсын өчен генә шулай эшли идегез сез моны! Кеше карап тормаса, бу уенның сезгә бернинди мәгънәсе булмас иде. Сезгә миннән мәхәббәт түгел, бәлки барлык кешеләр алдында сезнең минем белән кат-кат фаш ителүегез кирәк булган.

— Андый гына максат өчен мин сездән күп мәртәбә шәбрәк, кызыклырак кеше дә таба алган булыр идем,— диде Петерсон, һаваланып.

— Борчылмагыз, моның белән сез мине рәнҗетә алмыйсыз. Әйе, кабатлыйм: сезгә кемнеңдер сезнең алда, сезнең «тиңдәшсез чибәрлек» алдында табынуы, кол булуы һәм кешеләрнең шуны күреп торуы кирәк. Ә вакыт уза, яңа коллар азайганнан-азая бара. Һәм сез, хиссез-дәртсез кеше, салкын йөрәк, соңгы табынучыгызны югалтмас өчен, гаилә алдындагы бурычыгызны да, иргә тугрылык дигән нәрсәне дә аяк астына салып таптыйсыз.

— Юк, сез минем турыда бер ишетерсез әле! — дип, сүзләренә күп мәгънә салып, ачу белән пышылдады Раиса.

Залның икенче очыннан аларга таба, биюче парларга бәрелмәс өчен әле бер якка, әле икенче якка тайпылакача, Раисаның ире — капитан Петерсон килгәне күренде.

Ябык гәүдәле, чахотка йөзле, сары тире белән капланган такыр башлы, тыштан дымлы, ягымлы нур сарган, ләкин эчтән ниндидер яшерен мәкер уты белән көйдереп караган коңгырт-кара күзле бер кеше иде бу. Сөйләүләренә караганда, ул үзенең хатынын шашып ярата, имеш: шулкадәр ярата ки, хатынының барлык сәяркә егетләре белән үтә якын, төче һәм ялган дуслык мөнәсәбәтендә яши. Ә инде бу сәяркәләр аның хатыныннан туеп, аны шатлык һәм үзенә бер төрле җиңеләю хисе белән ташлап китүгә, ул алардан шундук үч ала башлый, аларның тормыш һәм хезмәт юлларына төрле мәкерләр корырга керешә дип сөйлиләр иде.

Ул, авызы тирәли ябышып каткан күм-күк иреннәрен ничектер сәер генә җәеп, ерактан ук елмаеп килде.

— Биюләр ничек бара, Раечка? Саумысез, Жоржик, кадерлем. Сез нигәдер бездә бик күптәннән күренгәнегез юк? Ияләшеп кенә беткән идек югыйсә, килмәгәч, сагындыра башладыгыз.

— Ни... бер дә вакыт тими шул... һаман занятиеләр,— дип мыгырданды Ромашов.

— Беләбез без сезнең занятиеләрне, — диде Петерсон, бармак янап, һәм чыелдаган тавыш белән кеткелдәп көлеп куйды. Шул ук вакытта аның кара күзләре борчу катыш игътибар белән хатынының һәм Ромашовның йөзе буйлап шуып үтте.

— Ә мин, гөнаһшомлык, сезне ачуланышкансыздыр дип уйлаган идем. Күрәм: утыргансыз да үзара нидер кызып бәхәсләшәсез. Берәр хәл булдымы әллә?

Ромашов дәшмәде, Петерсонның җыерчык баскан, ябык, кара муенына күзләре белән текәлгән килеш, уңайсызланып тик утырды. Әмма ялганга һәрвакыт оста Раиса, күзен дә йоммыйча, чатлатып әйтеп салды:

— Менә Юрий Алексеевич фәлсәфә сата. Танецлар заманы узган, хәзер биюче кеше бик көлке һәм ахмак булып күренә, ди.

— Ә үзе бии ич, — диде Петерсон кинә катыш бер ягымлылык белән. — Ярар, әйдә, биегез, биегез, балакайларым, мин сезгә комачауламыйм.

Ул китүгә, Раиса, ясалма хәсрәт, һавалану белән, үкенеп әйтте:

— Менә шул әүлияны, шул искиткеч кешене алдап йөргәнмен бит!.. Кем өчен диген әле! Ой, әгәр дә ул моны белгән булса...

— Маз-зурка женераль! — дип сөрән салды тагы Бобетинский. — Дамаларны йолып алу биюен башлыйбыз.

Паркеттан күтәрелгән тузан һәм кайнар тәннәрнең өзлексез хәрәкәте залдагы һаваны шактый бөркүлятте, шәм утлары томан эчендәге соргылт шәүләләргә әверелде. Биючеләр күп, ә зал кысан иде, шуңа күрә биюче парлар, бер-берләренә бәрелә-сугыла, күбрәк бер урында таптанырга мәҗбүр булдылар. Бобетинскийның дамаларны йолып алу дигәне шуннан гыйбарәт иде: ялгыз кавалер бии-бии нинди дә булса пар артыннан эзәрлекләп йөри. Эзәрлекләнүче пар тирәли мазурка хәрәкәтләре ясый-ясый әйләнгәләп, — бу ифрат көлке һәм мәгънәсез тамаша иде, — ул даманың үзенә таба йөзе белән борылган моментын көтә. Шул моментта ул кул чабып өлгерсә, дама йолып алынган исәпләнә. Ләкин даманың кавалеры моңа комачаулык итәргә тырыша, дамасын бирмәс өчен, аны төрлечә борып бастыра, әле бер якка, әле икенче якка өстери, ә үзе йә яны белән биеп китә, йә артка чигенә, кайвакыт хәтта буш терсәге белән әлеге әзәрлекләп йөрүче көндәшнең күкрәгенә төртеп җибәрергә дә күп алмый. Бу уеннан залда һәрвакыт шау-шулы, ямьсез, тупас, уңайсыз бер ыгы-зыгы туа иде.

Ромашов Раисаның колагына якынрак иелде дә хырылдык тавыш белән әкрен генә:

— Актриса! — дип куйды. — Сезне тыңлап торуы да көлке һәм кызганыч.

— Сез исерек, ахрысы!— диде Раиса, чыраен чытып, һәм Ромашовны баштанаяк үтергеч күз карашы белән көйдереп алды. Гадәттә, болай итеп романнарда героиняләр үзләрен рәнҗетүче явыз юлбасарларга карый торган булалар.

— Юк, әйтеп бирегез, ник сез мине алдадыгыз?— дип каныкты Ромашов, явызланып. — Димәк, сез мине үз яныгызда тотып тору өчен генә минем белән шундый якын мөнәсәбәткә кергәнсез. У-у, әгәр сез моны мәхәббәт хисенә, яки, һич югы, гади бер хайвани хискә буйсынып эшләгән булсагыз икән, ул чакта, бәлки, аңлашылыр да иде. Ләкин бит сез моны азгынлык, шөһрәт казану хакына эшләдегез. Аңлыйсызмы, без бернинди яратусыз-нисез, эч пошудан, бары күңел ачар өчен генә, хәтта бер-беребезгә аз гына да кызыксыну уянмаган көйгә, нәкъ менә бәйрәм көндә асрау кызлар... эч пошудан көнбагыш ярырга утырган кебек, әнә шундый эшәке эшкә барганбыз. Шул сезне аз гына да җирәндермимени? Аңлагыз: бу бит хатын-кызның үз тәнен акчага сатуына караганда да хурлыклырак нәрсә. Анда ичмасам акчага кызыгу, мохтаҗлык бар... Аңлагыз, бу максатсыз, гафу иткесез, салкын азгын-

лыкны искә төшерү үзе генә дә мине хурландыра, күңелне болгата!

Ромашовның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ул, сүздән туктап, башын күтәрде дә нурсыз, боек күзләрен залга күчерде. Кешеләр һаман бии иде. Әнә, аякларын көч-хәл белән генә сөйрәп, әйләнәсендә кәҗә төкәседәй тып-тып сикеренүче көләч кавалерына, карсак Епифановка күз дә төшермичә, иңбашларын катырып барган мәһабәт гәүдәле, беркадәр үпкәчел, кырыс чырайлы, кагылгысыз-саф кыяфәтле Тальман ханым. Әнә бәләкәй Лыкачева. Аның бөтен бит-яңаклары уттай яна, күзләрендә нур балкый, э ап-ак шәрә муеныннан кызларча бер сафлык бөркелеп тора... Әнә циркуль җәпләре сыман төз, нечкә аяклы Олизар... Ромашов боларның барысын күздән кичерде һәм кинәт башы авырта башлавын тойды. Аның елап җибәрәсе килде. Ә янәшәдә ачуыннан тәмам чырае качкан Раиса үтә бер һавалану, театральлек белән үзенең зәһәрен чәчә иде.

— Искиткеч шәп! Пехота офицеры Иосиф Прекрасный роландә, имеш!

— Әйе, әйе, нәкъ менә рольдә шул... — дип әлеп алды аның сүзен Ромашов, кызып. — Моның көлке, әшәке нәрсә икәнен мин үзем дә беләм... Ләкин мин сафлыгым, физик сафлыгым югалуына үкенеп кайгыруны үземә оят санамыйм. Без икебез дә үз иркебез белән юынтык су чокырына кереп баттык. Хәзер инде мин беркайчан да, беркемне дә әйбәт, саф хис белән ярата алмаячакмын. Һәм моның шулай булуына бары сез генә гаепле. Әйе, бары сез, сез генә гаепле! Сез миннән өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк ич, мәхәббәт мәсьәләләрендә сез инде үзенә күрә эт ашаган кеше.

Петерсон ханым, нәфрәт чагылган чырай белән эре генә урыныннан торды.

— Җитте! — диде ул, тавышына фаҗигале аһәң биреп. — Сез үз теләгегезгә ирештегез. Мин сезне күралмыйм! Бүгеннән башлап сез безнең өйгә аяк та басмассыз дип ышанам. Сез кунакчыллык, туганнарча үз итү, ашатуэчертүнең кадерен белми торган явыз кеше икәнсез. Нинди кызганыч: бу хакта иремә сөйли алмыйм! Ходай исәнлек бирсен үзенә, әгәр боларны сөйләсәң, ул, изге бәндә, шундук йөрәге ярылып үләр иде. Ләкин, ышанығыз, көчсез, ярдәмчесез хатын-кызны шулай рәнҗеткәннәре өчен ул тиешенчә үч тә ала белгән булыр иде.

Ромашов хатынның каршысында, аның ачудан кыйшайган нечкә, сулган иренле зур авызына күзлек пыяласы

аша кырын күз ташлап, дәшми басып торды. Галерея тәрәзәсеннән залга колак тондыргыч музыка тавышлары тарала, корык-корык итеп, берөзлексез теге эчпошыргыч тромбон йөткерена, э төрек барабанын даң-доң суккан каты тавыш исә Ромашовның башы эчендә үк яңгырый сыман иде. Ул Раисаның сөйләгән сүзләрен өзек-өзек кенә ишетте һәм бөтенләй диярлек аңламады. Ләкин алар да, барабан тавышы кебек үк, туп-туры аның башына китереп сугалар һәм берөзлексез миен яңгыраталар сыман иде.

Раиса җилпәзәсен чыгырт иткән тавыш белән капылт кына япты да, чыраена фаҗигый бер галәмәт бирепː

— У-у, кабахәт жан, явыз! — дип пышылдады һәм зал аша йөгерә-чаба киенү-бизәнү бүлмәсенә таба элдертте.

Бу инде бөтенесе җайлы гына төгәлләнде дигән сүз иде. Ләкин Ромашов үзендә нигәдер канәгатьлек хисе тоймады; әүвәлге әшәке, пычрак авырлык, күңелдән алай тиз генә китмичә, аның жанын әле һаман басып, тырнап торды. «Юк, бөтен әхлакый гаепне бу аңсыз, бичара хатын өстенә аударып, мин әйбәт эшләмәдем, ахрысы», — дип уйлады ул, һәм Раисаның хәзер анда, киенү-бизәнү бүлмәсендә, жен ачулары чыккан хәлдә, аптырап, хәсрәтләнеп утыруы, ачы күз яшьләре агызуы бөтен фаҗигасе белән аның күз алдына килеп басты.

«Мин түбән тәгәрим, түбән тәгәрим,— дип уйлады Ромашов, хәсрәт һәм жирәнү белән. — Шундый тормыш буламы! Тормыш түгел, ниндидер кысан, соры, пычрак бер нәрсә бу... Азгынлык, жирәнгеч, кирәге юк элемтәләр, исереклек, сагыш, күңел биздергеч бертөрле хезмәт — тоташ әнә шулардан гыйбарәт минем бу тормышым. Ичмасам бер генә жылы сүз, бер генә чиста-саф шатлык хисе дә таба алмыйсың. Китап, музыка, фән — алар кайда соң?»

Ул тагы ашханәгә юнәлде. Алда Осадчий һәм Ромашовның рота буенча хезмәттәше Веткин, икәүләп, бөтенләй исереп житкән Лехны кулларыннан тотып ишеккә таба өстериләр иде. Лех үз-үзен белештермичә әкрен генә башын чайкый һәм үзен архиерей дип ышандырырга тырыша. Осадчий исә житди кыяфәт һәм күк күкрәгәндәй яңгыравык тавыш белән, дьяконнарча аны үгетләпː

— Изге ата, гыйбадәт башланыр вакыт житте, фатихаңны бир... — дип сөйләнгәли иде.

Бию кичәсенең ахырына таба ашханәдәге тавышлар тагы да көчәя төште. Бүлмәдә өстәлнең баш-башына утырган кешеләр дә бер-берсен күрмәслек дәрәҗәдә куе тәмәке төтене асылынып тора иде. Бер почмакта жырлый-

лар, тәрәзә янында, зур төркем җыелып, шаркылдашашаркылдаша, оятсыз анекдотлар сөйлилəр; анекдотлар монда һәрбер аш табынына бирелә торган үзенә бер төрле тәмләткеч хезмәтен үти иде.

— Юк, юк, әфәнделəр... рөхсәт итегез, менә мин сезгә икенче бер нәрсә сөйлим! — дип кычкырды Арчаковский.— Бервакыт бер солдат хохол йортына фатирга төшə. Хуҗаның бик тә чибəр бичәкəе бар икəн. Шул солдат уйлый: ничек итеп, ди, бу бичəкəйне...

Арчаковский сөйләп бетерер-бетермəс үк, түземсезләнеп үз чиратын көткəн Василий Васильевич Липский сүз алды:

— Юк, əфəнделəр, моның нəрсəсе гаҗəп... Мин менə шəбрəген белəм...

Ул да булмады, үз хикəясе белəн өченче берəве килеп кысылды:

— Ə менə тагын мондые, əфəнделəр. Одессада була бу хəл...

Анекдотларның һəммəсе дə оятсыз, артык төче, кызыксыз булып, гадəттəгечə, сөйləүчелəрдəн бары берсе генə, иң оятсызы һəм үз-үзенə иң ышанып сөйлəгəне генə гомуми көлү тудыра иде.

Лехны экипажга утыртып, ишегалдыннан əйлəнеп кергəн Веткин табын янына Ромашовны чакырды:

— Утырыгыз əле, Жорженька... Берəрне аударып алыйк. Мин бүген баймын, яһүд кебек. Кичə картада откан идем; менə бүген дə уйнарга исəбем бар.

Ромашовның инде баядан бирле күңелен бушатасы, тормыштан туюы, хəсрəт-сагышлары турында кем белəн булса да сөйлəшеп утырасы килə иде. Рюмка артыннан рюмка бушаткан арада ул, Веткинга таба əледəн-əле ялварулы күз карашлары ташлап, ышанычлы, йомшак, калтыравык тавыш белəн үзенең күңелендəгеп сөйлəргə кереште.

— Павел Павлыч, дөньяда бүтəн төрле тормыш барлыгын без барыбыз да ничектер онытып җибəрəбез. Ə бит кайдадыр, кайда икəнен мин төгəл белмим, — бөтенлəй икенче төрле тормыш, чын, тулы, бəхетле, шатлыклы тормыш та бар лабаса. Анда кеше чын мəгнəсендə көрəшə, газаплана, көчле итеп ярата белə... Ə без, энə, ничек яшибез! Əнə, ничек яшибез!

— Əйе, əйтəсегез генə бармы, шундый инде безнең тормыш, туган, — дигəн булды Павел Павлович ялкау гына. — Əмма, гомумəн алганда... болар натурфилософия белəн энергетикадан башка бүтəн берни дə түгел. Карале,

туганкай, энергетиканың ни нәрсә икәнен белəсеңме әле син?

— О, ниләр эшлибез бит без, ниләр эшлибез! — дип сөйли бирде Ромашов, тәэсирлəнеп. — Бүген егылганчы эчəбез, иртəгесен ротага барып, бер, ике, уң да сул дип бугаз киерəбез, кичен тагы эчү, аннан — тагы рота. Бөтен тормыш шуннан тора микәнни? Юк, уйлап кына карагыз: гомер, гомер буе — шул бер үк нәрсə!

Веткин, пленка аша карагандай, аңа томанлы күз карашын ташлап алды, кикереп куйды да кинәт нәзек, калтыравык тавыш белəн җырлап җибəрде:

В тиши жила,
В лесу жила,
И веретено крути-ила... [1]

— Төкер бөтенесенə, фəрештə, сəламəтлегеңне сакла.

И от всей своей души
Прялочку любила [2].

Киттек карта уйнарга, Ромашевич-Ромашовский, мин сиңа бер кызыл кəгазьне бурычка биреп тора алам.

«Мине беркем аңламый. Бер генə якын кешем дə юк минем», — дип, пошынып уйлады Ромашов. Шул чак ул бер генə мизгелгə Шурочканы — шундый горур җанлы, көчле, чибəр Шурочканы исенə төшерде, һəм аның йөрəгe татлы да, сагышлы да, өметсез дə булган ниндидер хистəн сыкранып куйды.

Җəмгыять клубында ул иртəнге якты хəтле булды; офицерларның карта уйнавын карап утырды, үзе дə бераз уйнады, əмма уеннан бернинди тəм дə, рəхəтлек тə тапмады. Бер мəртəбə ул, аерым өстəл янында мыексыз ике яшь подпрапорщик белəн карта уйнап утырган Арчаковскийның карта өләшкəндə ике картаны берьюлы үзенə таба шудырып җибəрүен күреп алып, аңа шелтə белдермəкче дə булган иде, ләкин тыелып калды, гамьсезгə сабышып: «Их, барыбер түгелмени. Моның белəн генə берни дə төзəлмəячəк ич», — дип уйлады.

Үзенең биш миллионын биш минутта оттырып, тəмам чырае качкан Веткин хəзер авызын ачкан көе урындыкта йоклап утыра. Ромашовның янəшəсендə исə Лещенко; ул

---

[1] Яшəгəн ул(кыз) урманда
Ялгызы тынычта,
Орчыгын бөтереп...

[2] Каба — шул булган аның
Яратканы күңел бирeп...

да боек күзләре белән уенны күзәтә, һәм аның монда шулай сәгатьләр буе хәсрәт чигеп утыруының сәбәбен һич тә аңлап булмый иде.

Менә тәк атты. Төпләренә май җыелып юанайган шәмнәрнең җемелдәвек озын ялкын телләре ничектер сүрелеп, сары-соргылт төскә керде. Уйнаучыларның да агарынган чырайларына арыганлык галәмәте чыкты. Ә Ромашов һаман урыныннан кузгалмады, күзен дә алмыйча, уен карталарын, акбур белән чуарланып беткән яшел өстәл сукносын һәм аның өстендә яткан өем-өем көмеш һәм кәгазь акчаларны карап утырды. Шул ук вакытта аның авырайган, томан баскан башында талгын гына баягы уйлары — түбән тәгәрәве, күңелсез, пычрак, бертөрле тормыш турындагы сагышлы уйлары буталып бөтерелде.

X

Шомырт шау чәчәктә утырган язның ямьле, кояшлы, ләкин салкынча бер иртәсе иде.

Яшьләрчә каты йоклау гадәтеннән әле булса аерыла алмаган Ромашов, һәрвакыттагыча, бүген дә өеннан шактый соңарып чыкты һәм ротасының занятиеләре булырга тиешле плацка барып җиткәнче юл буе үзалдына оялып һәм борчылып атлады. Яшь офицер өчен күптән таныш бу гарьлек хисенең иң яман ягы шунда, рота командиры, капитан Слива, үзенең бәйләнчеклеге белән бу хисне тагы да кабартырга, тагы да гарьлеклерәк итәргә тырыша иде.

Гомумән, капитан Слива, үзенең бөтен холкы, кыланышлары белән үткән заманның иске тәртипләрен — бар кешене тоташтан каезлау, йодрык ярдәмендә өйрәтү, жан чыкканчы марш атлату һәм һәрбер вак нәрсәгә бәйләнү кебек аяусыз ысулларны үз эченә алган хәрби дисциплинаны гәүдәләндерүче офицерлардан иде. Провинциянең кыргый шартларында яшәве аркасында болай да гуманлык дигән нәрсәдән бик ерак торган полкта — хәтта менә шундый полкта да ул үзенең ерткычлыгы, мәрхәмәтсез мөгамәләсе белән дан тота һәм кеше ышанмастай төрле гыйбрәтле анекдотлар тууына сәбәп булган иде. Аның өчен гаскәри тәртип, устав һәм ротадан тыш игътибарга лаеклы берни дә булырга мөмкин түгел; алардан кала барлык нәрсә, әгәр Сливаның мыскыллы үз сүзләре белән әйтсәк, фәкать чүп, мандрагория генә иде. Үзе ул гомере буе әнә шул устав кысасына кысылып яшәде, һәм «Инвалид»ның рәсми өлешеннән кала аның бер генә газета да, китап та укыганы булмады. Бию, һәвәскәр спектакль

шикелле нәрсәләрне ул үзенең бөтен тупас йөрәге белән дошман күрде, җае килгәндә аларны солдат лексиконындагы иң әшәке, иң кабахәт сүзләр, тәгъбирләр белән сүкте. Дөрестерме, юктырмы, аның хакында хәтта шундый бер гыйбрәтле вакыйганы да сөйлиләр иде. Имеш, язның искиткеч ямьле бер төнендә ул ачык тәрәзә каршында ротаның отчет кәгазьләрен тикшереп утыра икән. Шул чак кайдадыр янәшәдә генә, агачлар арасында, сандугач сайрап җибәргән. Слива колагын салып тыңлап торган-торган да кинәт денщигына:

— З-захарчук! Ш-шул ж-җүнсез к-кошка таш т-тондыр әле, к-комачаулый... — дип кычкырган, имеш.

Карап торышка үшән, йолкыш кыяфәтле бу кеше солдатлар белән мөгамәләдә коточкыч мәрхәмәтсез булып, унтер-офицерларга аларны кыйнарга рөхсәт итә генә түгел, еш кына үзе дә йодрыгын эшкә җигә һәм кайчакта солдатны тәмам канга батырганчы, хәлсезләнеп аяктан егылыр дәрәҗәгә җиткәнче кыйнап ташлый иде. Аның каравы солдатның көндәлек ихтыяҗларына ул ифрат сизгер: алар исеменә авылдан килгән акчаларны беркайчан тоткарламас һәм көн саен шәхсән үзе солдатны ничек ашатуларын тикшереп йөрер. Дөрес, солдатның яллы хезмәттә эшләп тапкан акчасын үз белдегенчә тотудан чирканмый иде ул чирканмавын. Кыскасы, аның солдатлары туклык, көләчлек ягыннан полктагы роталар арасында икенче урынны тота иде.

Ротасындагы яшь офицерлар белән Слива шулай ук усал кыланды. Аларны тәртиптә тоту өчен әллә нинди тупас алымнарны һәм үзенең тумыштан оста әче телен эшкә җикте. Аның хохолча бу әче теле яшь офицерларны тәмам үтереп ташлый иде. Мәсәлән, хәрби өйрәнүләр вакытында сафта барган субалтерн-офицер адымын ялгыштырса, Слива, гадәтенчә беркадәр тотлыгыбрак:

— Бу ни бу! Бөтен р-рота а-аякны дөрес атламый икән л-ләбаса! Б-бердәнбер п-подпоручик кына дөрес ат-атлап бара! — дип төрттереп куя.

Кайчакны исә бөтен ротаны атасы-анасы белән сүгеп ташлый да шундук мәсхәрә белән өстәп әйтә:

— Бу с-сүзләрем о-офицер әфәнделәргә һәм подпрапорщикка кагылмый, — ди.

Ләкин Сливаның аеруча җенләнеп, үчләнеп бәйләнүе берәр кече офицер рота занятиесенә соңгарып килгән чакта була иде. Бу мәсхәрәне барыннан да күбрәк Ромашов татыды. Андый чакта Слива, подпоручикны ерактан ук күреп алып, ротаны юри «смирно»га бастыра да, ку-

лындагы сәгатеннән вакытны билгеләп, Ромашовның оялудан кылычына әбәләнә-чәбәләнә ашыгып якынлашуын һәм сафтагы үз урынын таба алмыйча ыгы-зыгы килеп буталуын мыскыллы кыяфәт белән, эндәшмичә һәм урыныннан кузгалмыйча карап тора. Яки ул, солдатлар ишетер дип һич тартынып тормастан, үтә бер ярсулы ихтирам, нәзакәт белән Ромашовтан сорап куя: «Сез, подпоручик, миңа занятиене дәвам итәргә рөхсәт бирерсез бит?» — ди. Икенче вакытны, шундый ук ихтирамлы кайгыртучанлык белән, ләкин юри каты кычкырып, Ромашовтан аның ничек йоклавы, йоклаганда нинди төшләр күрүе хакында сораштыра башлый. Бары тик шундый мәзәкләрнең берәрсен эшләп алганнан соң гына ул Ромашовны читкә чакырып ала һәм, балыкныкыдай түгәрәк күзләре белән туп-туры аның йөзенә кадалып, үзенең күңелендә яткан тупас шелтәсен белдерә иде.

«Их, хәзер барыбер инде! — дип уйланды Ромашов, рота янына якынлашып. — Монда да начар, анда да начар — һич аермасы юк. Тормышның кызыгы калмады!»

Плац уртасында басып торган рота командиры, поручик Веткин, Лбов һәм фельдфебель, якынлашып килүче Ромашовны күрүгә, бөтенесе берьюлы аңа таба әйләнеп карадылар. Шулай ук солдатлар да башларын бордылар. Шушы җентекле күз карашлары астында үзенең ифрат уңайсызланган кыяфәттә эпен-төпен атлап килүен күз алдына китергәч, Ромашов бөтенләй коелып төште.

«Ахыр чиктә бу, бәлки, ул кадәр хурлыклы да түгелдер? — дип, оялчан кешеләргә генә хас бер гадәт белән, күңеленнән үз-үзен юатып маташты ул. — Бәлки, мин генә моны шулай күңелгә якын аламдыр, ә бүтәннәрнең моңа исе дә китмидер. Ярый, менә, әйтик, занятиегә мин түгел, ә Лбов соңга калды, ди; мин сафтагы үз урынымнан Лбовның монда ничек якынлашып килүен карап торам, ди. Йә, шуннан ни булган: Лбов барыбер шул Лбов инде... Уфтанырлык берни юк, — дип нәтиҗә ясады, ниһаять, Ромашов һәм шундук тыныч ланып китте. — Ярар, хурлыклы да булсын, ди... Ләкин бит ул хурлык тойгысы ай буена сузылмаячак, хәтта атна буена, бер көнгә дә сузылмаячак. Ахыр чиктә, безнең гомер шундый кыска, анда бөтенесе бик тиз онытыла бара».

Гадәтенә каршы дигәндәй, Слива бу юлы аңа әллә ни игътибар итмәде һәм теге гарьләндергеч мәзәкләреңең дә һичберсен эшләргә җыенмады. Тик Ромашов, бер адымда каршысына килеп туктап, түбәнчелекле кыяфәт белән үкчәгә бәреп, кулын козырегына тидереп честь биргәч кенә,

ул салкын биш сосиска кебек мимылдык бармакларын аның учына китереп төртте дә шелтә төсендә әйтеп куйды:

— Хәтердән ч-чыгармавыгызны үтенәм, подпоручик: сез р-ротага һәрвакыт субалтерн-офицердан биш минутка, ә рота командирыннан ун минутка алдан килеп җитәргә т-тиешсез.

— Гаеплемен, господин капитан, — диде Ромашов, ниндидер агач тавыш белән.

— Гаеплемен, имеш!.. Йокыдан айный а-алмыйсыз. Йокы симертеп эш майтарып булмый. Офицер әфәнделәр, үз взводларыгызга т-таралышуыгызны үтенәм.

Рота бөтен плац буенча взвод-взвод таратылып, һәр взвод аерым рәвештә иртәнге гимнастика ясарга керешкән иде. Солдатлар, бер-береннән берәр адым ара калдырып, шеренгага тезелеп басканнар. Хәрәкәт җиңелрәк булсын өчен, һәркайсысы мундир изүен чишеп җибәргән иде.

Ромашов ярым ротасының җитез-елдам унтер-офицеры Бобылев, үзенә таба якынлашып килгән өлкән офицерга ихтирамлы күз карашы ташлап алды да, аскы теш казнасын алга таба суза төшеп һәм күзләрен кылыйландырып, көр тавыш белән солдатларга кычкырды:

— Аяк очына басып югары үрелү һәм салмак хәрәкәт белән түбән чүгү күнекмәсе. Куллар-рны... бөер-гә! — Шулай дип дә калын, көйле тавыш белән боерык бирде:— Баш-шла-адык!

— Ра-аз! — дип, бердәм рәвештә күтәреп алдылар аны солдатлар, көйләп, һәм салмак кына итеп җиргә чүгәләделәр. Бобылев исә, шулай ук җиргә чүгәләп, шеренгадагы һәрбер солдатны кырыс күз карашыннан кичерде.

Ә янәшәдә кечкенә буйлы, кыбырсык ефрейтор Сероштан яшь этәчнекедәй өзек, нечкә һәм кискен тавыш белән үз боерыкларын сибә иде:

— Аякларны алмаш-тилмәш алга ташлыйбыз, аякка карап кулны да шулай алга чыгартып алабыз. Тыңла! Башладык! Ать-два, ать-два! — һәм ун көр тавыш, һәр авазны кистереп, һау, һау, һау һау! дип һауларга тотынды.

— Тукта! — дип, әче, чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде кинәт Сероштан. — Ла-апшин! Син нәрсә анда килде-китте маташтырасың? Уфат тоткан Рязань мужигы хатынымыни: хоу! хоу! йодрыкларыңны болгыйсың!.. Кара аны, хәрәкәтне чиста ясыйсы бул моннан болай, ишеттеңме!

Аннары унтер-офицерлар взводларын йөгерек адым белән атлатып плацның төрле почмакларында урнашкан гимнастик машиналар янына алып киттеләр. Подпрапор-

щик Лбов, тәнгә таза, җитез егет һәм бик шәп гимнаст, өстендәге шинель һәм мундирын тиз генә салып ташлады да, бер кат зәңгәр ситсы күлмәктән, беренче булып параллель бруслар янына йөгереп килде. Брусларның очларына тотынып, ике кулы өстенә күтәрелде, аннары икеме, өчме тапкыр аллы-артлы тирбәлеп чайкалу тизлеген арттыргач, көч белән этәрелеп, кинәт гәүдәсен югары чөйде дә, һавада баштүбән мәтәлчек атып һәм дуга ясап, снарядтан бер сажин чамасы ераккарак аяклары өстенә очып барып төште. Моны ул бик оста, чын песи өлгерлеге белән эшләде.

— Подпрапорщик Лбов! Тагы фокус күрсәтергә тотындыгызмы! — дип, ясалма кырыс тавыш белән шелтәләп алды аны Слива. Карт «бурбон» күңеле төбендә бу прапорщикка ярату сымаграк бер хис саклый, аны яхшы фронтовик һәм хәрби уставны нечкәләп белүче солдат буларак тәкъдир итә иде. — Уставта кушылганны эшләгез. Изгеләр атнасындагы кәмит уены түгел ич бу сезгә.

— Тыңлыйм, господин капитан! — дип, көләч йөз белән шартлатып җавап бирде Лбов һәм, Ромашовка күз кысып, әкрен генә өстәп куйды: — Тыңлыйм, әмма кушканын үтәмим.

Дүртенче взвод авыш баскыч дигән снарядта күнегүләр ясый иде. Солдатлар баскыч янына берәм-берәм киләләр дә, үрелеп, баскычның аратасына асылыналар һәм кулларын алмаш-тилмәш бер аратадан икенчесенә күчереп, югарыга үрмәлиләр. Унтер-офицер Шаповаленко аларга астан төрле искәрмәләр ясап тора иде.

— Аякларыңны болгама. Аяк очын катырып тот!

Нинаять, сул флангта иң кырыйга баскан солдат Хлебниковка чират җитте. Бөтен ротада гомуми көлү объекты булып хезмәт иткән бу кәрлә диярдәй кыска буйлы, мыексыз, шапшак һәм йодрык кадәр генә битле, йолкыш, мескен кыяфәтле солдатка күзе төшкән саен, Ромашов еш кына: «Моны солдатка ничек алдылар икән?» — дип гажәпләнә торган иде. Аның күзләрендә тумыштан, дөньяга яратылган беренче көненнән үк дигәндәй катып калган ниндидер буйсынучан, ахмак, мәгънәсез бер өркү чагыла, һәм бу күзләр белән очрашканда Ромашовка һәрвакыт күңелсез булып китә, йөрәгендә исә вөждан газабына охшаш сәер бер үкенү хисе уяна иде.

Хлебников, элмәктәге мәет сыман, шыксыз кыяфәттә кулларында асылынып торды.

— Күтәрел диләр сиңа, аңгыра сарык, күтәрел! — дип кычкырынды унтер-офицер. — Ну, югартын күтәрел!

Хлебников, бөтен көченә тырышса да, гәүдәсен җыя алмады, аякларын болгый-болгый, як-якка чайкалып әүвәлгечә асылынып тик торды. Шул чак ул, шапшак, тырпы борынлы, саргаеп кипкән бәләкәй йөзен янтайтып, куркынган, ахмак күзләре белән түбән карап алды һәм, кинәт кулларын аратадан ычкындырып, җир өстенә лапылдап төште.

— Ә-ә! Син әле емнастика ясаудан баш тартасыңмы! — дип акырып җибәрде унтер-офицер. — Шулай бөтен взводны бозасыңмы, кабахәт! Мин с-сине хәзер!

— Шаповаленко, солдатка кул күтәрәсе булма! — дип кычкырды Ромашов, ачу һәм гарьлегеннән тәмам кабынып китеп. — Ишетәсеңме, мондый нәрсәне беркайчан да эшлисе булма! — дип кабатлады аннары һәм йөгереп килде дә унтер-офицернең җилкәсеннән тотты.

Шаповаленко, үрә катып, кулын козырегына тидерде, чырае шундук юашланып, солдатча мәгънәсез бер төс алды. Ләкин аның буйсынучан күз карашында ниндидер серле көлемсерәү дә чагыла кебек иде.

— Тыңлыйм, ваше благородие. Тик сезгә әйтергә рөхсәт итегез: алар белән башкача һич мөмкинчелек юк.

Хлебников, офицерга ахмак күзләрен текәп, янәшәдә бөкрәебрәк басып тора һәм учының кыры белән борынын ышкый иде. Ромашов аңа чарасыз, тирән кызгану хисе белән бер карап алды да, борылып, өченче взводка таба китеп барды.

Гимнастик күнегүләр тәмамланып, кешеләргә ун минутлык ял бирелгәч, офицерлар янәдән плац уртасындагы параллель бруслар янына җыелдылар. Бу юлы май аенда булачак парад хакында сүз купты.

— Ни, кая һәм ничек килеп кабасыңны алдан белеп булмый шул! — дип, кулларын җәя-җәя һәм гажәпләнгән төстә дымлы күзләрен шарландыра-шарландыра үзалдына сөйләнде Слива. — Ягъни, мин шуны әйтмәкче: һәр генералның бу мәсьәләдә үз фантазиясе була. Әйе. Хәтеремдә, бездә Львович дигән бер генерал-лейтенант бар иде, корпус командиры ягъни. Инженерлар арасыннан килгән кеше. Шул, аның вакытында безнең җир казудан баш чыкмады. Устав өйрәнү, күнегүләр, марш йөрүләр — һәммәсе бер якка, димәк. Иртәдән кичкә хәтле ниндидер ложементлар корып җан чыга, шайтан алгырысы! Җәен балчыктан, кышын кардан эвәлисең. Бөтен полк баштанаяк ләпеккә буялып йөри торган иде. Исемдә, унынчы рота командиры капитан Алейников, — урыны оҗмахта булсын мәрхүмнең, — шул чакта ике сәгать вакыт эчендә

люнетмы, барбетмы дигән ниндидер бер корылма ясап, Анна орденына тәкъдим ителгән иде.

— Шәп! — дип сүз кыстырды Лбов.

— Аннары, генерал Арагонский заманындагы ату кагыйдәләрен өйрәнүне алыйк. Анысын сез дә хәтерлисездер әле, Павел Павлыч?

— Э! «Примостився стреляти»не әйтәсезме? — диде Веткин, авызын ерып.

— Анысы нәрсә тагын? — дип сорады Ромашов.

Слива җирәнүле төстә кулын селтәп куйды.

— Ә ул шундый бер мәзәк инде. Ул чакта безнең башлар атарга өйрәтү кагыйдәләреннән тәмам аңгыраеп беткән иде. Шул, бер солдат смотр вакытында «при Понтийском Пилате» диясе урында «примостився стреляти» дип әйтеп ташламасынмы! Менә бит ул нишләтә зиһен чуалу дигәнең! Анда имән бармакны имән бармак дип түгел, ә «басма бармак», уң күзне исә «төзәү күзе» дип атап йөртә торганнар иде.

— Ә теорияне ничек ятлый идек, хәтерлисезме, Афанасий Кириллыч? — дип сүзгә кушылды Веткин. — Әллә нинди траекторияләр, деривацияләр... Валлаһи, мин үзем берни аңламый торган идем. Кайчак солдатка әйтәсең: «Менә сиңа мылтык, көпшәсенең эчен кара әле, анда нәрсә күрәсең?» — дисең. Ә ул сиңа җавап бирә: «Күңелдә фараз ителгән һәм көпшәнең күчәре дип йөртелгән линияне күрәм», — ди. Аның каравы атуны шәп ата идек. Исегездәме, Афанасий Кириллыч?

— Ничек инде истә булмасын. Шәп атканы өчен безнең дивизияне хәтта чит ил газеталарында да язып чыктылар. Уйлап кына карагыз: отличнодан шәп атучылар саны бездә ун процент тәшкил итә иде. Алдашуын да алдаштык инде үзебез, валлаһи менә. Яхшы атучыларны бер полктан икенче полкка эҗәткә алган акча сыман күчереп йөртә торган идек. Яисә, әйтик, рота ату күнегүләре алып бара, ә кече офицерлар блиндаждан торып шул ук мишеньгә револьвердан сиптерәләр. Бервакыт шулай, бер рота алдын чыккач, мишеньдәге пуляларны санап карадык. Шул, атылган пулялар белән чагыштырганда, мишеньдәге пуля эзе биш данәгә артык чыга. Ягъни тию проценты — йөз дә биш. Ярый әле, фельдфебель вакытында тишекләрне клейстер белән томалап өлгерде.

— Ә теге Слесарев вакытында Шрейберча гимнастика хәтерегездәме?

— Хәтердә булмыйча! Менә кай төштә утыра ул минем. Балет булып балетка хәтле бии торган идек. Их,

исәпләсәң, аз булдымы алар, генералларны диюем, шайтан алгырлары! Ләкин, әйтсәм әйтим, әфәнделәр, хәзергесе белән чагыштырганда болар барысы чепуха, мандрагория. Элек бөтенесе ничектер ачык, ярылып ята иде. Һәрхәлдә, синнән ни сораячакларын алдан белеп тора идең, э хәзер? Ah, солдатик — ул якын кешең, аңа гуман булу кирәк, янәсе. Гуман булырга түгел, һәйбәтләп каезларга кирәк аны, кабахәтне! Ah, акылын, зирәклек, җитезлеген үстерергә кирәк, янәсе. Суворовчылар! Хәзер солдатка ни өйрәтергә дә белмисең. Әнә, рәхим ит, ниндидер үтәли атака дигән нәрсә уйлап тапканнар бит әле...

— Әйе, бу инде кәнфит түгел! — дип, теләктәшлек белән баш какты Веткин.

— Син, әнә теге бүкән сыман, аңлы-миңле басып торасың, э синең өскә, әйтик, казаклар томырылып килә. Үтәли атака белән! Йә, шунда, әйтик, читкә тайпылып кара әле. Шундук приказ: «Фәлән-фәлән капитанның нервлары какшаган. Колагына киртеп куйсын: аны хәрби хезмәттә беркем дә көчләп тотмый».

— Хәйләкәр карт, — диде Веткин. — К. полкында ул шундый бер нәрсә эшләп ташлады, исең-акылың китәр. Ротаны зур бер күлдәвек уртасына керттерде дә шуннан рота командирына әйтә: «Ятарга»! дигән команда бир ди. Теге мескен ык-мык, шулай да команданы бирергә мәҗбүр булды. Солдатлар аптырап калдылар, боерыкны ялгыш ишеттек дип уйладылар бугай. Ә генерал кече офицерлар алдында рота командирын сүгепме-сүгәргә тотынды: «Шушы булдымы ротагызның тәртибе! Аксөякләр! Җебегәннәр-фәләннәр! — ди. — Әгәр хәзер шушы суга ятарга куркалар икән, сугыш вакытында алар нишләр? Дошман уты астында берәр чокырда яткан җирләреннән аларны атакага ничек итеп күтәрерсез?— ди. — Болар солдат түгел, э куркак хатын-кызлар, ди. Сез үзегез дә шундый ук куркак хатын-кыз, ди. Абвахтага!» — дип сүзен бетерде.

— Ә аңардан ни файда? Кеше алдында командирны эт итеп сүгәләр дә, аннан тәртип турында лыгырдыйлар. Пычагыммыни монда тәртип булсын! Ә солдатны кыйнарга ярамый, башы беткерене, хакың юк. Кай-я ул... Солдат, янәсе, шәхес, кеше! Юк инде, элекке заманда бездә бернинди шәхес-мәхесләр дә юк иде, солдатларны хайванны яисә угры кәҗәне кыйнагандай дөмбәслиләр иде. Ә бит бездә Севастополе дә, итальян походы да, бүтәнебашкасы да булды югыйсә. Мин үзем, хет хезмәттән куса-

лар да, барыбер, әгәр солдат ярамаган эш эшли икән, ул кабахәтнең тиешле җиренә менеп төшми калмыйм!

Әлегә кадәр бер сүз дәшми басып торган Ромашов кинәт телгә килде.

— Солдатны кыйнау вөҗдансызлык, — диде ул саңгыравык тавыш белән. — Сукканга җавап бирү түгел, хәтта сугудан ышыкланыр өчен кулын үзенең битенә таба күтәрергә яки башын читкә борырга да хакы булмаган солдатны кыйнау офицер кешегә һич килешми, бу — хурлык!

Слива җирәнүле кыяфәттә күзләрен кысты һәм, чал кергән кыска мыеклары астыннан аскы иренен бүлтәйтеп, Ромашовны ян яктан башыннан аягына хәтле үтергеч күз карашы аша уздырды.

— Сез нәрсә-ә дидегез? — дип сузды ул, чиксез бер нәфрәт белән.

Ромашов шундук ап-ак булды. Күкрәге һәм корсагы эченнән ниндидер салкын йөгереп узды, э йөрәге бөтен тәнне дерелдәтеп дөп-дөп сугарга тотынды.

— Кыйнау яхшы түгел димәкче булам... Әйе, әйе, кабатлап әйтәм, менә шул, — диде ул, сүзләрен бутабрак, әмма нык тавыш белән.

— Һы, кара син аны, ә! — дип сузды Слива, гөрелдәп. — Күп күргән инде без андый кәнфитләнүләрне, борчылмагыз, зинһар! Полктан куылмый калсагыз, сез үзегез дә бер ел эчендә яңак төпкә менәргә күнегеп китәрсез әле. Менә әйтте диярсез! Миннән һич ким булмассыз.

Ромашов, нәфрәтле күз карашын туп-туры аның йөзенә кадап, пышылдагандай әкрен тавыш белән янап әйтте:

— Әгәр солдатларга тагын кул күтәрсәгез, мин сезнең өстән полк командирына рапорт язып бирәчәкмен.

— Нәрсә-ә? — дип, дәһшәтле төстә акырып җибәрде Слива, ләкин шундук өзелеп калды һәм тынычланганрак, коры тавыш белән өстәп куйды: — Ярар, юк-бар сөйләп баш катырмыйк. Сез, подпоручик, патша хәзрәтләренә егерме биш ел буе намуслы хезмәт иткән офицерларны өйрәтергә артык яшьсез әле. Офицер эфәнделәр, һәммәгезнең дә рота мәктәбенә баруыгызны үтенәм, — диде ул, ачу белән сүзен тәмамлап.

Шулай диде дә офицерларга таба аркасы белән борылды.

— Нигә кирәк булгандыр сезгә сүзгә катышу? — диде Веткин, Ромашов белән янәшә атлап барышлый. — Үзегез күрәсез, алай бик татлы җимешләрдән түгел ул, Сливаны әйтәм. Сез белеп бетермисез әле аны, э мин бик

яхшы беләм. Ул сезне шундый китереп кысар, кая керер тишек тапмассыз. Карыша башласагыз — арест белән теңкәгезне корытыр.

Ромашовның хурлану һәм ачудан күзләренә яшь килгән иде.

— Карагыз әле, Павел Павлыч, бу бит хезмәт түгел, ә ниндидер тәмуг газабы, — диде ул, ачыргаланып. — Бу барабан каешлары безнең өстән өзлексез көләләр, безне мәсхәрәлиләр. Офицерлар арасында алар юри тупас мәгамәлә, солдафонлык, ниндидер ялган, оятсыз егетлек урнаштырырга тырышалар.

— Ну, анысы шулай, әлбәттә, — дигән булды Веткин, исе китмичә генә һәм авызын ачып иснәп куйды.

Ә Ромашов кайнарланган төстә сүзен дәвам иттерде:

— Йә, уйлап кара: бу дорфа кычкыру-акырулар, бу гимнастика уеннары кемгә кирәк? Ах, офицерлыкка укып чыкканда мин һич тә менә, һич тә болай булыр дип көтмәгән идем. Мондагы беренче тәэсиремне әле булса онытасым юк. Полкка килүемнең өченче көнендә үк әлеге җирән пономарь Арчаковский минем бөтен кәефемне бозды. Җәмгыять клубында булды бу хәл. Ул миңа подпоручик дип гади генә эндәшкәнгә, мин дә сүз арасында аңа поручик дип дәшеп куйдым. Без аның белән янәшә, өстәл янында сыра эчеп утыра идек. Шунда ул миңа кычкырып җибәрде: «Беренчедән, мин сезгә поручик түгел, ә господин поручик, ди, ә икенчедән... өлкәнрәк чинлы кеше сезгә замечание ясаганда, рәхим итеп, аяк өсте басыгыз!» Һәм мин, урынымнан күтәрелеп, аның каршысында хурлыклы бер кыяфәттә үрә катып торырга мәҗбүр булдым. Ярый әле подполковник Лех арага керде, тегене сүгеп, бераз кикриген шиндерде. Юк, юк, берни дә әйтмәгез, Павел Павлыч. Шулкадәр күңелем бизде, шулкадәр туйдым мин бу тормыштан, белмисез генә!..

XI

Рота мәктәбендә «тел гыйльме» өйрәнәләр иде. Кысан бүлмәдә, дүртпочмак рәвешендә ян-яклап тезелгән эскәмияләргә, йөзләре белән уртага карап, өченче взвод солдатлары утырышкан. Дүртпочмак уртасында, арлы-бирле атлап, ефрейтор Сероштан йөренә. Күршедә, шундый ук дүртпочмак эчендә, ярымротаның икенче бер өйрәтүчесе — унтер-офицер Шаповаленко да шулай киләп сарып йөри иде.

— Бондаренко! — дип, зыңгылдавык тавыш белән кычкырды Сероштан.

Бондаренко, ике аягын берьюлы идәнгә бәреп, пружиналы агач курчак сыман бик тиз генә сикереп торды да үрә катты.

— Мисал өчен, син, Бондаренко, сафта корал тотып басып торасың диик. Шул чак синең каршыңа начальство килә дә сорый синнән: «Бондаренко, синең кулыңда нәстә ул?» — ди. Шуннан син ни дип җавап бирергә тиешсең?

— Мылтык, ие? — диде Бондаренко, чамалап.

— Ялганлыйсың. Нинди мылтык булсын ул сиңа? Син тагы, саладагыча, алтатар диясең калган. Анда гына ул мылтык, ә монда, хезмәттә, исеме аның бик гади: Бердан системасындагы кечкенә калибрлы, тиз атышлы, шудырма затворлы, икенче номерлы пехота винтовкасы. Кабатла, сукин сын!

Бондаренко моның җавабын электән үк белә, әлбәттә; шуңа күрә, һич тотлыгып тормастан, ефрейторның сүзләрен тиз-тиз кабатлап чыга.

— Ярый, утыр! — диде Сероштан, шәфкать күрсәтеп.— Ә ни өчен бирелгән ул солдатка? Минем бу соравыма хәзер җавап бирер... — Сероштан кырыс күз карашын әйләнәсендәге кешеләр өстеннән йөртеп чыкты: — Шевчук!

Шевчук караңгы чырай белән урыныннан торды һәм, ике-өч сүз саен нокта куйгандай туктала-туктала, саңгырау, тыңкыш, калын тавыш белән әкрен генә җавабын әйтте:

— Ул миңга бирелгән шуныңчөн. Тыныч вакытта мин аның белән мылтык уены өйрәнәм. Ә сугыш вактында Ватанны һәм тәхетне дошманнардан саклар өчен. — Шевчук бераз тукталып торды да, янә күз-кашын җимереп, өстәп куйды: — Эчке дошманнардан, шулай ук тышкы дошманнардан.

— Ярый. Әйбәт кенә беләсең, Шевчук. Тик артык сузып сөйлисең. Солдат, бөркет кебек, дәрт белән сөйләргә тиеш. Утыр. Хәзер син әйт, Овечкин: тышкы дошманнар дип без кемне атыйбыз?

Электә вак товар сатучы приказчик булганлыгы ашыгып һәм төчеләнеп сөйләшүендә үк сизелеп торган елтыр Овечкин — Орлов ягы егете, — куанычыннан йотлыга-йотлыга, кыланып-көязләнеп, тиз-тиз тезеп китте:

— Тышкы дошманнар дип без шундый мәмләкәтләрне атыйбыз, кайсылары ки безнең белән сугыш алып бара:

француҙлар, немецлар, атальяннар, түрекләр, аурупалылар, һинд...

— Сабрит, — диде Сероштан, аны сүзеннән бүлеп. — Анысы инде уставта күрсәтелмәгән. Утыр, Овечкин. Ә хәзер миңа... Архипов әйтсен! Э-эч-чке дош-шманнар дип без кемне атыйбыз?

Соңгы җөмләсенең беренче ике сүзен Сероштан аеруча басым ясап, кычкырып әйтте һәм шул ук вакытта үзирекле саналган Маркусон ягына таба тирән мәгънәле күз карашы ташлап алды.

Шадра битле, шыксыз кыяфәтле Архипов, рота мәктәбе тәрәзәсенә күзләрен төбәп, дәшми тик басып торды. Хезмәттән тыш үзен һәрвакыт акыллы, эшлекле, җитез тоткан бу егет занятиеләрдә ничектер югалып кала, җүләр сымак бер кешегә әверелә иде. Күрәсең, бу шуның белән аңлатыладыр: аның авыл тормышына җайлашкан, андагы гади, ачык аңлаешлы вакыйга-күренешләрне күзәтергә һәм алар турында иркенләп фикер йөртергә күнеккән салмак акылы әлеге үзенә өйрәтелә торган «тел гыйльме» белән чын тормыш арасында бәйләнеш таба алмыйча аптырый иде. Шуңа булса кирәк, ул хәрби эштәге иң гади нәрсәләрне дә аңлый һәм хәтереңә сеңдерә алмый, шуның аркасында үзенең взвод командирында һәрвакыт нәфрәт катыш бер гаҗәпләнү тудыра иде.

— Җә-ә! Озакмы сине көтәргә, сөйлә әйдә? — диде Сероштан, кыза башлап.

— Эчке дошманнар дип... дошманнар дип...

— Белмисеңме? — дип җикерде Сероштан дәһшәт белән. Ул хәтта Архиповның өстенә ташланырга да уйлаган иде, ләкин, янәшәсендә офицер барлыгын абайлап, ниятеннән кире кайтты, башын ачулы селкеп, Архиповка үтергеч күз карашы ташлап алу белән чикләнде. — Ну, колагыңа киртеклә. Эчке дошманнар дип без законга каршы һәрбер кешене атыйбыз. Мисал өчен, кемнәрне?.. — Сероштан күзгә керердәй булып кыбырсып утырган Овечкинны күрде. — Җә, син әйт булмаса, Овечкин.

Овечкин янә урынныннан сикереп торды, куанычы эченә сыймыйча, кычкырып җибәрде:

— Фетнәчеләр, стюдентлар, ат караклары, жидләр һәм поляклар!

Янәшәдә генә үз взводы белән унтер-офицер Шаповаленко шөгыльләнә. Кулында — солдатларга бирелергә тиешле сораулар тупланган кечкенә генә китапчык. Эскәмияләр уртасында берөзлексез киләп сорып йөргән хәлдә, ул шул китапчыктан солдатларга сораулар яудыра.

— Солтыс, часовой кем ул?

Литвалы Солтыс, көчәнүдән сулышы кысылып һәм күзләрен акайтып, каты кычкырып җавап бирә:

— Часовой — ул кагылгысыз кеше.

— Анысы шулай, ә тагы кем?

— Часовой — ул нинди дә булса постка куелган кораллы солдат.

— Дөрес. Күрәм, син, Солтыс, шактый тырышлык күрсәтә башладың. Инде син әйт, Пахоруков: син постка нәрсә өчен куелгансың?

— Йокламасын, йокымсырамасын өчен, тәмәке тартмасын өчен, беркемнән бернинди әйбер, бүләк кабул итмәсен өчен.

— Ә честь бирү?

— Яннан узган барлык офицер әфәнделәргә тиешле честь биреп калсын өчен.

— Шулай. Утыр.

Шаповаленко үзирекле Фокинның мыскыллы елмаюын инде баядан бирле күреп тора иде. Шуңа күрә ул аеруча кырыс тавыш белән аңа эндәште:

— Үзең ирекле Фокин! Кем шулай аягүрә баса? Командир эндәшкәндә, урыннан пружина кебек атылып торырга кирәк! Нәрсә ул байрак?

Күкрәгенә университет значогы таккан үзирекле Фокин түбәнчелекле кыяфәттә гәүдәсен турайтты. Ләкин аның яшь, соры күзләрендә сизелер-сизелмәс генә булып күңелле очкыннар җемелдәп күренә иде.

— Байрак — ул гаскәрнең изге хоругвие, аның янында...

— Ялганлыйсыз! — дип, ачулы төстә аны сүздән бүлде Шаповаленко һәм китапчыгы белән учына шапылдатып сукты.

— Юк, мин дөресен әйтәм, — дип, тыныч кына үз сүзен куәтләде Фокин.

— Нәрсә-ә?! Начальство юк ди икән, димәк, юк!

— Уставны үзегез ачып карагыз.

— Унтер-офицер булгач, мин, димәк, уставны да сездән яхшырак беләм. Кара син аны! Теләсә нинди үзләре ирекле борын чөярга маташа. Ә бәлкем мин үзем дә юнкерлар мәктәбенә укырга китәргә җыенамдыр, сез каян беләсез? Ниткән нәрсә ул хоругвий? Хе-руг-ва! Ә хоругвий түгел. Икона сымак изге бер нәрсә, хәрби хе-руг-ва, димәк.

— Шаповаленко, бәхәсләшмә, — дип сүзгә катышты Ромашов. — Занятиене дәвам ит.

— Тыңлыйм, ваше благородие! — диде Шаповаленко, үрә катып. — Тик, ваше благородие, әйтергә рөхсәт итегез: бу үзе ирекле гел шулай акыл сатарга ярата.

— Ярар, ярар, дәвам иттер!

— Тыңлыйм, вашбродь... Хлебников! Кем безнең корпус командиры?

Хлебников аптыраган кыяфәттә унтер-офицерга төбәлә. Ачык авызыннан карылдык карга тавышына охшаш нидидер кызганыч аваз ертылып чыга.

— Тиз бул! — дип кычкырды янә унтер-офицер, усал итеп.

— Его...

— Ну, — его... Ну, әйт, шуннан нәрсә?..

Бу минутта Ромашов икенче якка карап тора иде. Шулай да ул Шаповаленконың хырылдык тавыш белән әкрен генә әйткән янау сүзләрен ачык ишетте:

— Ярар, сабыр ит, дәрестән соң танавыңны сыйпармын әле мин синең!

Ромашов янә аңа таба борылып басты. Тегесе, моны шундук абайлап алып, яңгыравык-сабыр тавыш белән өстәп куйды:

— Его превосходительство... Җә, нәрсә катып торасың, Хлебников, әйт, дәвамы ничек?

— Его... инфантерия... лентинанты... — дип, каушый-каушый, тагы мыгырданды Хлебников.

— И-и-и! — дип ысылдады Шаповаленко, тешләрен кысып. — Җә, нишләргә инде синең белән, Хлебников, тәмам аптыраш! Син аны өйрәтәсең, өйрәтәсең, ә ул ишәк дисәң ишәк, тик мөгезе генә юк. Тырышмыйсың, Хлебников! Менә тор инде шулай багана кебек катып дәрес беткәнче! Ә обедтан соң минем янга килерсең, аерым калып өйрәнербез. Греченко! Кем безнең корпус командиры?

«Бүген дә, иртәгә дә, иртәгесе соңга да һаман шул бер үк нәрсә булачак. Гомерем буе, үлгәнче шулай булачак, — дип уйланды Ромашов, взводлар арасында киләп сарып йөри-йөри. — Әллә барысын ташлап китеп барасы микән?... Үтереп эч поша!..»

«Тел гыйльме»ннән соң солдатлар ишегалдында атуга хәзерлек күнегүләре ясарга керештеләр. Берәүләр бер почмакта мылтыктан көзгегә төзәп маташа, икенче берәүләр вак ядрәләр белән мишеньгә ата, ә өченче җирдә Ливчак приборы ярдәмендә винтовкадан цельгә төзәргә өйрәнәләр иде. Икенче взводта подпрапорщик Лбовның бөтен плацка ишетелерлек дәртле, нәзек чәрелдек боерыклары яңгырап тора:

— Туп-тур-ры... колоннага төзәп... бөтен рота белән... атарга әзерләнергә... ать, два! Рота-а,— дип суза ул соңгы авазны, аннары бераз тын алып тора да, кистереп әйтеп куя: — Ут ач!

Чакмалар чыкылдый. Ә Лбов, тавышын уйнатып-кыландырып, янәдән чыелдарга керешә:

— К но-о-о... ип!

Слива исә, гадәтенчә бөкрәя биреп, әле бер взвод, әле икенче взвод янына килә, солдатларның басып тору рәвешләрен тикшерә, кыска, тупас сүзләр белән аларны шелтәләп ала иде:

— Бүксәңне җый! Буаз хатын кебек торасың! Кара, винтовкаң ничек тора? Кулына шәм тоткан дьякон түгелсеңдер ич? Карташов, нәрсә авызыңны җырдың? Әллә ботка телисеңме? Кая трыньчигың? Фельдфебель, күнегүләр беткәч, Карташовны мылтык астына бастырып куй. Кан-налья! Веденеев, кара, шинеленне ничек төргәнсең. Ни башы, ни очы юк, кыяфәтең кыяфәт түгел. Балбес!

Ату күнегүләреннән соң солдатлар, мылтыкларын бер-беренә терәтеп өеп куйдылар да, шуның янәшәсендә генә, җирдән яңа тибеп чыккан һәм урыны-урыны белән күн итекләрдән тапталган беренче язгы яшел чирәм өстенә ял итәргә яттылар. Аяз һәм җылы көн иде. Шоссе буйлап ике рәт төзелеп киткән тупыл агачларыннан һавага яшь яфрак исе таралган иде. Веткин янә Ромашов янына килде.

— Төкерегез барсына, Юрий Алексеевич, — диде ул, подпоручикны култыклап. — Нәрсә хафаланырга? Менә занятиеләр генә бетсен, җәмгыятькә барырбыз да берәр рюмка төшереп алырбыз, бөтенесе узар да китәр. Ә?

— Эч поша, Павел Павлыч, җаныкаем, эч поша, — диде Ромашов хәсрәт белән.

— Анысы шулайдыр, тормыш күңелледән түгел, — диде Веткин. — Ләкин нишләмәк кирәк? Кешеләрне өйрәтмичә булмый бит инде. Көтмәгәндә генә сугыш чыкса нишләрсең?

— Шул сугыш дисәгез генә инде, — дип, килешкәндәй, моңсу гына әйтеп куйды Ромашов. — Ә шулай да: нигә кирәк ул сугыш? Бәлки, ул сугыш дигәннәре безнең гомуми, дөньякүләм бер ялгышуыбыз гынадыр, акылдан шашу сымак нәрсәдер? Кеше үтерү — табигыймени?

— Э-э, тагы фәлсәфәгә кереп киттегез. Ни хаҗәт! Ә кинәт, әйтик безгә немецлар һөҗүм итсә? Россияне алардан кем саклар соң?

— Мин бит берни дә белмим, берни әйтмим дә, Павел

Павлыч, — диде Ромашов, ниндидер еламсык, күндәм тавыш белән. — Мин берни дә, берни дә белмим. Ләкин менә, әйтик, Төньяк Америкадагы сугышны яки Италиядәге азатлык сугышын алыйк. Наполеон заманындагы — гверильясларны... революция вакытындагы шуаннарны алыйк... Кирәк чагында сугыша белгәннәр ич! Игенчеләре, гади көтүчеләренә хәтле сугыша белгәннәр...

— Американнар бит алар... Таптыгыз чагыштырырга... Анысы кысыр кайгы. Ә минемчә, алай уйлаганда, гомумән хезмәт итәргә кирәкми. Аның соңында, безнең эштә уйлау дигән нәрсә тиеш тә түгел. Тик менә четерекле мәсьәлә: хезмәт итмәсәк, без кая барырбыз икән? Нинди эшкә ярарбыз икән дим, чөнки сул да уң диюдән башка без әлифне таяк дип тә белмибез бит. Үлә беләбез — анысы дөрес. Таләп итсәләр, хет бүген үк үләргә әзербез, шайтан алгыры! Кыскасы гына, әпәйне юкка ашамыйбыз димәкчемен. Менә шулай ул, филозоф хәзрәтләре. Занятие беткәч, бергәләп җәмгыятькә барырбыз, ярыймы?

— Ярар, барырбыз, — диде Ромашов, килешкән булып.— Дөресен әйткәндә, көнне көнгә болай аударып яшәү — чын дуңгызлык. Сез хаклы: болай уйланганда, бөтенләй хезмәт итмәвең хәерлерәк.

Сөйләшә-сөйләшә, алар плац буенча йөренделәр һәм, ниһаять, дүртенче взвод янына килеп туктадылар. Солдатлар бастырып куелган мылтыклар өеме төбендә утырып яисә ятып ял итәләр иде. Кайберләре ипи ашый, — соңгысын аларның иртәдән кичкә хәтле иң яратып эшләгән шөгыльләре дияргә мөмкин. Смотрлар вакытындамы, маневрлардан туктаган ял сәгатьләрендәме, чиркәүдә гыйбадәт кылганда яисә тән җәзасы алыр алдыннан — һәр буш минутны алар әнә шулай ипи кимереп уздырырга күнеккән иде.

Ромашовның колагына кемнеңдер үзенә бер төрле үҗәт-сабыр тавыш белән әйткән сүзләре килеп керде:

— Хлебников, ишетәсеңме, Хлебников!..

— Нәстә? — дип тавыш бирде тегесе, тыңкышланып.

— Өеңдә чакта син ни эшли иден?

— Нишлим, эшләдем, — диде Хлебников йокылы тавыш белән.

— Нәрсә эшләдең дим мин, тинтәк?

— Нәстә булсын: җир сөрдем, мал карадым.

— Нәрсә бәйләндең әле син аңа? — дип сүзгә катышты карт солдат Шпынев. — Билгеле инде: бала-чагага имчәк каптырудан башы чыкмагандыр.

Ромашов узып китешли Хлебниковның соры, шәрә кыз-

ганыч йөзенә күз төшерде, һәм аның күңелен янә оялуга охшаш ниндидер әрнеткеч бер хис тырнап алды.

Ул арада капитан Сливаның плац уртасыннан:

— Коралны алырга! Офицер әфәнделәр, үз урыннарыгызга басыгыз! — дигән командасы ишетелде.

Бер-беренә бәрелеп чыңлаган штык, тимер тавышлары яңгырап китте. Солдатлар, ашыгып-кабаланып, сафка тезелделәр.

— Рравняйсь!— дип кычкырды Слива. — Смирна!

Аннары, ротага якынрак килеп, көйле тавыш белән өстәп әйтте:

— Корал йөртү приемнары, аерым-аерым рәвештә, саный барып... Рота, ша-ай... на кра-ул!

— Рраз! — дип акырып җибәрделәр солдатлар һәм мылтыкларын дәррәү җилкәгә күтәрделәр.

Слива сафлар буенча йөри-йөри боерыкның дөрес үтәлешен тикшерде, өзек-кискен тавыш белән искәртүләр ясады: «прикладны турырак тот», «штыкны югарырак», «прикладны янтыкка кыса төш». Аннан, янә рота алдына чыгып басып, команда бирде:

— Дела-ай... два!

— Два! — дип кычкырдылар солдатлар.

Һәм Слива тагы саф буенча йөреп боерыгының үтәлешен тикшереп чыкты.

Мылтык белән эш итү ысулларын аерым-аерым рәвештә өйрәнгәч, аларны тоташтан эшләү күнегүләре башланды. Аннан соң сафта борылып басу, сафны икеләндерү, кысу, киңәйтү кебек күнекмәләр өйрәнелде. Ромашов боларның һәммәсен уставта талэп ителгәнчә һәм автомат сыман төгәллек белән эшли барды, әмма шул ук вакытта аның башында бая Веткин ычкындырып җибәргән теге сүзләр бөтерелде: «Алай уйлаганда, гомумән хезмәт итәргә кирәкми. Хезмәтне ташлап китүең хәерлерәк». Һәм кинәт аңа хәрби уставның хәйләле бу барлык хикмәтләре: үкчәне үкчәгә бәреп борылып басулар, мылтык уйнау, сафта йөрү осталыклары, шуларга бәйле төрле тактика һәм фортификация дигән нәрсәләр — һәммәсе, һәммәсе үтә күңелсез, максатсыз һәм кирәксез, гайре табигый бер нәрсә булып, бөтен кешелек дөньясының үз-үзен алдап яшәве нәтиҗәсендә туган ниндидер мәгънәсез саташуы сыман нәрсә булып тоелды. Иң үкенечле ягы тагын шунда: ул, Ромашов, шушы мәгънәсез нәрсәләрне мөһим, акыллы эш санап, алар хакына гомеренең иң әйбәт тугыз елын — киләчәгенә нигез салырга тиешле кадерле тугыз елын әрәм итте бит.

Хәрби өйрәнүләр тәмамлангач та ул Веткин белән бергә җәмгыять клубына китте, анда бик күп аракы эчте. Бөтенләй диярлек исен-акылын югалткан хәлдә, селәгәйләнә-селәгәйләнә, Веткины кочаклады, үпте, аның җилкәсенә башын куеп, үкси-үкси елады, тормышының күңелсезлегенә, мәгънәсезлегенә, үзен беркем дә аңламавына зарланды, бер хатынны яратуын, әмма ул хатын аны яратмавын үкенеп сөйләде; кем ул хатын — анысын беркем беркайчан белмәячәк, диде. Веткин исә, рюмка артыннан рюмканы авызына каплый барып, кызгану катыш мәсхәрә белән ара-тирә сүз кыстыргалады:

— Иң яманы шул, Ромашов: сез аракы эчә белмисез. Бер рюмкадан мәлҗерәп төштегез.

Аннан ул кинәт кенә өстәлгә йодрыгы белән суга да:

— Ә үләргә кушсалар — үләрбез! — дип куя иде.

— Үләрбез, үләрбез, — дип кабатлый Ромашов, еламсык тавыш белән. — Үлү — нәрсә ул? Чүп ул үлү... Менә җан әрни минем...

Ромашов үзенең ничек өйгә кайтканын да, караватына кем чишендереп яткырганын да хәтерләмәде. Ул үзен миллиард-миллиард кеп-кечкенә очкыннар сибелгән ниндидер куе зәңгәр томан эченә йөзә итеп күрде. Томан, туктаусыз тирбәлеп, Ромашовның гәүдәсен гүя бер югары күтәрә, йә түбән ташлый иде, һәм шушы ритмик чайкалу-тирбәлүдән подпоручикның йөрәге кысылып-кысылып куя, туктый, күңеле болганып, тамагына ниндидер тәмсез, әрнеткеч төер килеп тыгыла. Башы исә, гүя чиксез зураеп, кабарып, өзлексез яңгыраган: «Дела-ай раз!.. Дела-ай два!» — дигән сүзләрдән үтереп сызлый, чәнчеп-чәнчеп авырта иде.

XII

Егерме өченче апрель Ромашов өчен бик мәшәкатьле һәм бик тә сәер көн булды. Ул урыныннан торып та җитмәгән иде әле, иртән сәгать уннарда Николаевларның денщигы Степан Александра Петровнадан хат китерде.

«Кадерле Ромочка, — дип язган иде Александра Петровна, — әгәр миңа: сез безнең бүген уртак туган көн булуын оныткансыздыр дип әйтсәләр, мин моңа һич тә гаҗәпләнмәгән булыр идем. Кыскасы шул: мин сезнең исегезгә төшерәм. *Бернигә карамыйча,* бүген мин сезне күрергә телим! Тик, эшһәр, тәбрикләр өчен көндез түгел, ә төп-төгәл кичке сәгать бишкә килегез. Имәнлеккә пикникка чыкмакчыбыз.

Сезнең *А. Н.*».

Хатны укыганда Ромашовның кулларына хәтле калтыранды. Менә бер атна инде аның Шурочканы күргәне юк иде. Ул шундук аның әле иркәләп, әле көлемсерәп, әле дусларча игътибар белән елмайган һәм күңелне һәрвакыт кытыклап, җилкендереп торган сөйкемле, чибәр йөзен күз алдына китерде. «Бүген!» — дип, куанып һәм тантана белән пышылдады аның йөрәк тавышы. Аннан ул тавыш ургып тышка чыкты:

— Бүген! — һәм Ромашов яланаяк килеш караватыннан идәнгә сикереп төште. — Гайнан, юынырга!

Бүлмәгә Гайнан керде.

— Ваша благородия, анда денщик көтә. Сорый: җавап язармы, ди.

— Шулаймыни! — Ромашов күзләрен шарландырды һәм карават кырыена чүгә төште. — Ссс... Чәйлек бирергә иде дә, бер тиен дә акчам юк. — Ул аптыраган чырай белән денщигына карады.

Гайнан көләч елмаеп куйды.

— Минем дә тиен юк!.. Синең дә юк, минем дә юк. Э, ярар ла! Болай да китәр.

Ромашов кинәт теге вакыттагы караңгы төнне хәтеренә төшерде. Пычрак, юеш язгы төн; ул дымлы читәнгә сыенып басып тора. Шул чак караңгыдан Степанның ачулы тавышы ишетелә: «Йөри шунда көн саен буталып...» Ромашов шул вакытта үзенең җир тишегенә керердәй булып оялуын да исенә төшерде. У, ике тиен өчен, бердәнбер ике тиенлек акча өчен ул хәзер үзенең киләчәктәге әллә никадәр шатлык-куанычларыннан да ваз кичәргә әзер иде!

Ромашов, өметсезлектән нишләргә белмичә, битен учы белән угалап, ыңгырашып куйды.

— Гайнан, — дип пышылдады ул аннары, ишеккә таба куркынган күз карашы ташлап алып, — Гайнан, бар чыгып әйт үзенә, кичен подпоручик чәйлек акча бирер, диген. Ишетәсеңме: һичшиксез бирер, диген.

Ромашовның акчага бик интеккән көннәре иде бу. Бурычка алыр җир юк: буфетта да, офицерларның экономия кибетендә дә, офицерларның җыелма капиталыннан да аңа бурычка акча бирми башладылар... Тик җәмгыять клубында гына көндезге һәм кичке аш алырга була иде, анысы да аракысыз һәм закускасыз бирелә иде. Өендә хәтта чәе, шикәре дә юк иде аның. Ярый әле, ниндидер мәкерле очрак белән дигәндәй, өйдә зур бер калай савыт кофе сакланып калган иде. Һәр иртәне Ромашов, үзен иректезли-иректезли, шикәрсез-нисез шул кофены болгатып эчә, инде эчеп бетерә алмаса, калганын шундый ук

ирексезләнү белән денщигы Гайнан чөмереп бетерергә тырыша иде.

Менә хәзер дә, куе кара төстәге әче, зәһәр кофены чыраен чытып чөмерә-чөмерә, подпоручик үзенең аяныч-лы хәле турында уйланды: «Һм... иң әүвәл, бүләксез ничек бармак кирәк? Конфет яки перчатка алырга микән? Перчатка алсам, аның ничәнче номер перчатка киеп йөргәнен белмим. Конфет алсам? Җүнле конфеты да юк бит әле аның монда. Ислемай шәбрәк булыр иде булуын... Ә җилпәзә? Һм!.. Юк, шулай да ислемай алу хәерлерәк... Ул эсс-буке дигәнне ярата бугай. Әле пикниккa да акча кирәк: барып кайту өчен извозчикка түләргә, әйтик, биш сум, Степанга чәйлек — бер сум! Әйе-е, подпоручик Ромашов хәзрәтләре, бер ун сумсыз сезгә берничек тә котылып булмаячак монда!..»

Һәм ул күңеленнән үзе табардай барлык ресурсларны исәпләргә кереште. Жалованье? Юк, өмет аз. Әле кичә генә жалованье бирү кәгазенә үзе имза куеп чыкты бит: «Расчет дөрес. Подпоручик Ромашов». Аның бөтен жалованье акчасы төрле графалар буенча тотып калынган, шул җөмләдән хосусый вексельләр буенча түләүгә дә исәпләнелгән иде. Нәтиҗәдә, аның үз кулына хезмәт хакыннан бер тиен дә акча тимәде. Бәлки, киләчәк хезмәт хакы исәбенә сораргадыр? Хәер, моны кимендә бер утыз мәртәбә эшләп карады инде ул, ләкин берсендә дә теләктәшлек таба алмады. Полкта казначей штабс-капитан Дорошенко — ифрат кырыс, караңгы чырайлы кеше; бигрәк тә «фендрикларны» сөйми. Төрек сугышында яра алган кеше иде ул үзе, ләкин ярасы ифрат җайсыз, хөрмәтсез урында — үкчәсендә булып, бу хәл шактый күп мәзәк, үртәүләр тудырган иде (гәрчә, әйтергә кирәк, ул бу ярасын чигенгән, качкан чакта түгел, ә һөҗүмгә ташланырга боерык бирер өчен үзенең взводына таба борылып баскан чакта алган булган). Сугышка тормыш сөючән, күңелле прапорщик булып киткән Дорошенко, менә шушы көлүүртәүләр аркасында, сугыштан соң бөтенләй зәһәр холыклы, тиз кабынучан бер ипохондрикка әверелеп калган иде. Юк, Дорошенко акча бирмәячәк, билгеле; бигрәк тә аңа, инде менә өч ай рәттән ведомость кәгазенә «Расчет дөрес» дип имза куя килгән подпоручик Ромашовка бирмәячәк.

«Ярар соң, нәрсә ул кадәр пошынырга! — дип үзалдына уйланды Ромашов. — Офицерларны хәтердән барлап чыгыйк. Иң элек рота командирларыннан башлыйк. Тәртип саны буенча. Беренче рота — Осадчий».

Ромашов Осадчийның ерткычныкыдай авыр күз карашлы, гаҗәеп чибәр кыяфәтен күз алдына китереп бастырды. «Юк, кем кем, әмма Осадчий бирмәячәк. Үтерсәң дә бирмәячәк. Икенче рота — Тальман. Сөйкемле Тальман: гомер буе үзе бер тәңкәләп әҗәткә акча җыеп йөри, хәтта подпрапорщиклардан да сорый. Хутынский?»

Ромашов янә уйга калды. Кинәт аның миенән малайларча дуамал бер фикер йөгереп узды: тотарга да полк командирының үзеннән барып сорарга? «Күз алдына китерергә була! Башта, мөгаен, коты алынудан тораташтай катып калыр, бераздан шашып калтырана башлар, аннары мортирадан аткан кебек: «Нәрсә-ә? Ма-ал-чать! Дүрт тәүлеккә гауптвахтага!» — дип акырып җибәрер».

Подпоручик ирексездән шаркылдап көлеп куйды. Юк, барыбер, барыбер ни дә булса уйлап табылырга тиеш! Шундый куанычлы башланган көн уңышсыз тәмамланырга мөмкин түгел! Моны аңлап та, аңлатып та булмый, әмма күңелнең кай төшендәдер, тирәндә, бөтенесе әйбәт тәмамланачак дигән ышаныч үзен ачык сиздереп тора.

«Капитан Дювернуа? Солдатлар аны, көлеп, Дөберкуа дип атап йөртәләр. Кушамат дигәннән, Будберг фон Шауфус исемле бер генерал булган икән, шуны солдатлар Бутка-ашар Зурауз дип йөрткәннәр, имеш. Юк, Дювернуа артык саран кеше, мине дә яратмый — белеп торам...»

Шулай бер-бер артлы барлап-тикшереп, Ромашов беренчедән уналтынчы ротага хәгле барлык рота командирларын күңеленнән уздырды, аннары, уфлап, кече офицерларга күчте. Эзләнүенең уңышлы чыгасына өмете бетмәсә дә, аны беркадәр шик борчый башлаган иде инде. Нәкъ менә шул вакыт аның хәтере түрендә «Подполковник Рафальский!» дигән исем калкып чыкты.

— Рафальский. Ә мин баш катырып утырам!.. Гайнан! Сюртук, перчатка, пальто — тиз бул!

Дүртенче батальон командиры подполковник Рафальский сәер генә, буйдак бер карт булып, полкта аны шаяртып, — әлбәттә инде, үзе юк чагында, — полковник Брем дип атап йөртәләр иде. Пасха һәм яңа ел бәйрәмнәрендә рәсми визитларны исәпләмәгәндә, ул беркем белән дә кунак йөрешми, хезмәткә мөнәсәбәте исә шундый битараф, илтифатсыз иде ки, хәрби приказларда яки хәрби өйрәнүләр вакытында аңа гел шелтә, сүгү сүзләре яудырып торалар иде. Бөтен вакытын, җегәрен, йөрәгендә файдаланылмый яткан бөтен дәртен, мәхәббәт хисен ул үзенең яраткан җанварларына — кошларга, балыкларга һәм

башка төрле дүрт аяклы хайваннарга багышлаган һәм шуларны өендә асрап, шулар белән юанып яши иде. Аның хатын-кызга игътибарсызлыгын күреп ачулары кайнаган полк дамалары, аның турында сүз чыкканда: «Ах, ничек инде шундый кешенең өендә булмак кирәк? Өй түгел, җәнлек оясы ич ул! Җитмәсә, турысын әйткән өчен гафу итегез, — шундый сасы! Фу!» — ди торганнар иде.

Барлык саклык акчаларын полковник Брем әнә шул җанварларын асрауга сарыф итеп, үзен бөтенләй кайгыртмый, ач-ялангач диярдәй сәер бер тормыш алып бара иде. Өстендә — кайчан алынганлыгы да билгесез иске шинель һәм мундир; урын-жире урын-жир дип әйтерлек түгел, ашавы — унбишенче ротаның гомуми казанныннан, ягъни гади солдат азыгы. Хәер, солдат азыгы гына булса да, ул аның өчен акчаны үз бәясеннән күпкә арттырыбрак түли. Шуның өстенә, чамасы булганда, ул полкташ иптәшләренә, бигрәк тә кече офицерларга, бурычка аз-маз акча биреп торудан да беркайчан баш тартмас. Ләкин гаделлек йөзеннән шунысын да әйтергә кирәк: алган бурычны аңа кире кайтарып бирү гайре табигый, хәтта көлке санала,— исәр кеше, полковник Брем акчаны барыбер файдасызга исраф итеп бетерә, янәсе.

Азгынрак прапорщиклар, Лбов кебекләр, бурычка берме, икеме тәңкә акча сорап аңа барырга җыенганда: «Җәнлекләр карарга барам», — ди торганнар иде. Карт буйдакның күңелен йомшартып, кесәсен капшау өчен эшләнгән бер хәйлә иде бу. Янәсе: «Иван Антоныч, яңа җәнлекләр алып кайтмадыгызмы әле, күрсәтсәгез иде берәрсен? Алар турында сез бик кызык сөйли беләсез...»

Ромашов та Рафальский янына еш кына барып йөрде, ләкин әлегә бернинди максатсыз-нисез: җанвар-җәнлекләргә аның электән килә торган үзенә бер төрле самими, хисчән мәхәббәте бар иде. Мәскәүдә, кадетлар, аннары юнкерлар мәктәбендә чагында, ул театрдан бигрәк циркка, ә аннан да бигрәк зоология бакчасына һәм башка җәнлек асрау урыннарына йөрергә яратарак төшә иде. Бала вакытында ул, мәсәлән, үзендә сер-бернар эте булдырырга, ә соңыннанрак, уку чорында, батальон командиры адъютанты дәрәҗәсенә ирешеп, атлы булу турында хыялланды. Ләкин боларның берсе дә гамәлгә ашмады: бала чагында — фәкыйрьлек, мохтаҗлык комачаулады, ә инде «мәһабәт буй-сын» таләп ителгән адъютантлык вазифасына аны барыбер куймаган булырлар иде.

Ромашов урамга чыкты. Язгы җылы һава, иркәләгәндәй, аның яңак-битләренә килеп сарылды. Яңгырдан соң

әле кипшереп тә өлгермәгән дымлы җир аяк астында рәхәт бер тирбәлү белән батып-батып куя. Өй алды бакчаларыннан койма аша урам якка ак башлы шомырт һәм аксылшәмәхә чәчәкле сирень ботаклары салынып төшкән иде. Ромашовның күкрәге эчендә нәрсәдер, очыртып китәргә теләгәндәй, кинәт ашкынулы бер көч белән киңәеп, талпынып куйды. Ул, тирә-ягына борылып һәм урамда беркемнең дә юклыгын күреп, кесәсеннән Шурочканың хатын тартып чыгарды, аны тагы бер мәртәбә укып чыкты да имзасына иреннәрен тидерде.

— Изге, сөекле күк йөзе! Сөекле агачларым! — дип пышылдады ул, күзләре дымланып.

Полковник Брем яшел ихаталы ишегалдының түрендә үк тора иде. Урам як ишеге өстенә: «Шылтыратмыйча кермәскә! Этләр!» дигән язу кадаклап куелган иде. Ромашов кыңгырау бавын тартты. Ишектә йокылы, иренчәк кыяфәтле, тузгыган чәчле денщик күренде.

— Полковник өйдәме?

— Керегез, ваше благородие.

— Иң элек кереп әйтеп чык булмаса.

— Ярар, болай гына керегез. — Денщик йокылы кыяфәттә ботын кашып алды. — Алай кереп әйтеп торуларны яратмый ул.

Ромашов кирпеч җәюле сукмак буйлап өйгә таба атлады. Йорт почмагы артыннан каршыга бозау хәтле зур, китек колаклы, соры ике яшь эт — доглар атылып чыкты. Берсе, ачусыз-нисез генә дигәндәй, каты тавыш белән өреп куйды. Ромашов аңа бармак шартлатты, һәм теге, алгы аяклары белән уңга-сулга ташланып, тагы да катырак өрергә тотынды. Икенче дог исә, кызыксынучан бер кыяфәт белән борынын суза-суза, Ромашовның шинель чабуыннан иснәштергәләп, арттан иярде. Ишегалды түрендәге яшел чирәмдә, кояш нурына күзләрен кыса төшеп һәм озын колакларын рәхәт селеккәләп, бәләкәй генә бер ишәк йокымсырап тора. Шунда ук тавыклар, чуар төстә әтәчләр, үрдәкләр һәм шеш борынлы кытай казлары чемченеп йөри; әче тавышлар белән мисыр тавыклары кычкыра, ә мәһабәт ана күркә, койрыгын җәеп һәм җир өстеннән канатларын сөйрәп, горур-тәкәббер кыяфәттә нечкә муенлы бала күркәләр тирәсендә хозурланып әйләнә. Тагарак янында алсу йонлы зур йоркшир дуңгызы кырын яткан иде.

Тәрәзә каршында күн швед курткасыннан, ишеккә таба аркасын куеп басып торган һәм, пыяла аквариумга кулы белән терсәк тиңентен тыгылып, нәрсәдер эшләп маташ-

кан подполковник Брем өйгә Ромашовның килеп керүен бөтенләй сизмәде дә. Кунак икеме-өчме тапкыр каты итеп тамак кырып куйгач кына, ул ташбака кабырчыгыннан ясалган кысалы борынгы күзлек кигән, сакаллы, ябык-чандыр йөзен ишеккә таба борды.

— Ә-ә, подпоручик Ромашов. Рәхим итәсез, рәхим итә-сез... — дип, шатланып каршы алды ул кунакны. — Гафу, кулымны бирмим — юеш. Менә балыкларга, үзенә күрә дигәндәй, яңа сифон куеп маташуым иде. Искесен үзгәр-теп, җиңеләйтеп кордым. Шәп кенә килеп чыкты әнә. Чәй эчәсезме?

— Рәхмәт. Әле генә эчкән идем. Минем монда килүем-нең максаты, полковник әфәнде...

— Ишеткәнсездер, шәт: полкны бүтән шәһәргә күче-рәләр, имеш, — дип, әле генә өзелгән сүзне дәвам иттер-гәндәй, сөйләп китте подполковник Рафальский. — Үзегез аңлыйсыздыр, бу хәбәр мине, үзенә күрә дигәндәй, зур хафага салды әле. Йә, үзегез уйлап карагыз, балыкларым-ны мин ничекләр итеп күчерермен? Яртысы юлда тончы-гып үләчәк бит. Ә аквариумны? Пыялалары — әнә үзегез күз салыгыз — сажин ярым озынлыкта бит алар. Аһ, бел-сәгез иде, Севастопольдә шундый шәп аквариум күрдем мин! — дип, кинәт сүзне бөтенләй икенчегә борды ул. — Зурлыгы... үзенә күрә дигәндәй... нәкъ менә шушы бүлмә хәтле булыр, валлаһи... суы — диңгезнеке, гел алмаштырып торалар. Электр уты яна! Өстән торып карыйсың — бөте-несе күз алдында, балыкларны әйтәм. Белуга, акула ди-сеңме, скат яки диңгез этәчләре дисеңме, — аһ, ни генә юк, җаныкайларым! Яки, үзенә күрә дигәндәй, диңгез мәчесен алыйк: белен сымак ялпак бер җан иясе, диамет-ры аршин ярым булыр, ян-яклары, ничек дип әйтергә, дул-кынланып, селкенеп тора үзенең, — шәт, күз алдына ки-терәсездер; ә артында — ук сыман озын койрыгы бар... Ике сәгать буе карап басып торганмындыр... Сез ник кө-ләсез?

— Гафу итегез... әле генә күреп алдым — иңбашыгыз-да ак тычкан утыра икән...

— Аһ, наян, кара син аны, кая менеп кунаклаган! — диде Рафальский, башын борып карап, һәм суырып үпкән-дәгедәй бер тавыш белән, әмма аңа тагы да нечкәрәк, нәзегрәк аһәң биреп, чын тычкан сыман чыелдап куйды. Кызыл күзле бәләкәй җәнлек, бу чыелдауны ишетүгә, шундук хуҗасының битенә таба үрмәләде һәм, бөтен гәү-дәсе дерелдәгән хәлдә, борыны белән Рафальскийның са-калын һәм авызын кармаларга тотынды.

— Белеп торалар үзегезне! — диде Ромашов.

— Әйе... беләләр шул. — Рафальский, авыр сулап, башын чайкап куйды. — Ә без аларны белмибез бәла әнә кайда! Кешеләр, үзенә күрә дигәндәй, этләрне өйрәткәннәр, атларны, мәчеләрне кулга ияләштергәннәр, ә алар чынлыкта нинди җан иясе — менә монысын без өйрәнү түгел, хәтта белергә дә теләмибез. Кайбер галимнәр, шайтан алгырлары дигәндәй, борынгыдан калган нинди дә булса юк кына бер сүзне аңлату өчен бөтен гомерләрен сарыф итәләр, шуның белән әле, җитмәсә, дан казаналар, тереләй изге кеше булып танылалар. Ә монда... мисал өчен шул ук этләрне алып карагыз. Безнең белән янәшәдә үк шундый акыллы, фикерләүче, хисле-тойгылы җан ияләре яши бит югыйсә, ә бер генә приват-доцентның да шуларның психологиясе белән кызыксынганы юк!

— Бәлкем, бу хакта хезмәтләр бардыр, фәкать без генә белмибездер? — дип, кыюсыз тавыш белән әйтеп куйды Ромашов.

— Хезмәтләрме?.. Һм... әлбәттә, бар; хәтта ки бик төпле хезмәтләр бар. Әнә, карап багыгыз, миндә генә дә алар никадәр — бөтен бер китапханә, — диде подполковник, стена буендагы шкафларга төртеп күрсәтеп. — Акыллы итеп, тәэсирле итеп язалар! Гыйлемлекләре искитмәле! Нинди генә приборлар, нинди генә тапкыр ысуллар кулланмыйлар... Ләкин боларның берсе дә, берсе дә мин әйткән нәрсә түгел! Ну, әйтик, этнең яки мәченең бер көн эчендәге яшәү рәвешен игътибар белән күзәтү — менә бу нәрсә аларның, ул галимнәрнең, берсенең генә дә, үзенә күрә дигәндәй, башына килеп карамый! Син бар да күзәтеп кара әле: ничек яши ул эт дигәнең, ни уйлый, нинди хәйләләр кора, ничек газаплана, ничек шатлана. Игътибар итегез: минем хайваннар өйрәтүче клоуннарның эшен күзәткәнем бар. Шаккатарлык!.. Гипноз дигән нәрсәне генә күз алдына китерегез, — чын, ялгансыз гипнозны әйтәм! Киев мифманханәсендә бер клоун миңа үзенең осталыгын күрсәткән иде — искитмәле, тәмам акылга сыймастай нәрсә булды ул! Ә бит эшләүчесе кем диген — клоун, шамакай! Әгәр, әйтик, бу эшне берәр җитди кеше — табигать белгече, тәҗрибәләр ясарга оста, белемле һәм фәнни җиһазлар белән коралланган галим кеше алып барса, нинди генә сокланғыч нәтиҗәләргә ирешмәс идек без! Әйтик, этнең акыл сәләте, холкы, саннарны белүе һәм башка, һәм башка сыйфатлары турында әллә ниләр ишеткән булыр идек! Бу бит үзе бер дөнья — галәмәт зур, кызыклы дөнья! Ну, менә, сез теләсә ничек уйлагыз, әмма мин үзем,

мәсәлән, этнең үз теле, әйтергә кирәк, шактый камилләшкән үз теле булуына бөтен барлыгым белән ышанам.

— Алай булгач, әлеге галимнәр моңарчы бу эш белән нигә шөгыльләнмичә килгәннәр соң?— диде Ромашов. — Бу бит бик гади эш югыйсә!

Рафальский мәсхәрәле төстә кеткелдәп куйды.

— Шул шул менә — бик гади эш, хе-хе-хе. Бөтен хикмәт тә шунда. Бау ишүнең нәрсәсе бар! Әлеге галимнәр өчен, беренчедән, эт нәрсә ул? Умырткалылар семьясыннан этләр токымына карый торган имезүче һәм ерткучы хайван һ. б. Һәммәсе дә дөрес, әлбәттә. Ләкин син ул эткә фикер йөртүче җан иясе, кеше, бала итеп карап кара. Үзләрен әллә кемгә куеп йөрүче ул тәкәббер галимнәр, минемчә, теге кара мужиктан — эттә җан урынына пар дип уйлаучы мужиктан әллә ни алга китмәгәннәр, валлаһи!

Рафальский, сүздән туктап, ачулы төстә көчәнә-ыңгыраша аквариум төбенә янәдән резин көпшә беркетергә тотынды. Ромашов батырлыгын җыйды.

— Иван Антонович, сезгә зур, бик зур үтенечем бар иде...

— Акча кирәкме?

— Чын менә, сезне борчырга да оят. Миңа күп кирәкми, бер ун тәңкә чамасы. Тизүк кайтарып биралмам алуын, шулай да...

Иван Антонович кулларын судан чыгарып, аларны сөлгә белән корытырга кереште.

— Унны табарга булыр. Артыгы юк, әмма ун тәңкәне рәхәтләнеп бирәм. Шыр-шырамагадыр инде, шулаймы? Ярар, ярар, мин шаяртам гына. Киттек.

Ул аны бишме-алтымы бүлмәле квартирының иң түренә алып кереп китте. Бүлмәләрдә бернинди җиһаз-фәлән юк, тәрәзәләре пәрдәсез, һавасы тынчу, — анда вак җәнлекләр өнендәге кебек үзенә бер төрле ачыган ис аңкып тора. Идәннәре исә шундый пычрак, хәтта аяклар таептаеп китә.

Һәр почмакта диярлек будкалар сыман итеп яисә төпсез мичкә, куыш агач төпләренә охшатып җәнлекләр өчен оя һәм өннәр әмәлләштерелгән. Бүлмәләрнең икесендә хәтта ботакларын як-якка җәеп утырган ике агач та бар. Боларның берсе кошлар өчен, икенчесе сусар белән тиеннәр өчен булып, аларның ботакларына кош оялары, ә кәүсәләренә куышлар тишеп ясалган иде. Боларның һәммәсендә кош-корт һәм җәнлекләр турында үтә зур кай-

гыртучанлык, аларны ярату, белү һәм алар өчен бөтен уңайлыклар тудыру теләге ачык сизелеп тора иде.

— Әнә теге җәнлекне күрәсезме? — диде Рафальский, бөтен яктан чәнечкеле тимер чыбык койма белән әйләндереп алынган кечкенә куыш-ояга төртеп күрсәтеп. Ояның стакан төбе зурлыгындагы ярым түгәрәк тишегендә чемкара ялтыравык ике нокта җемелдәп күренә иде. — Бу, үзенә күрә дигәндәй, дөньядагы иң ерткыч, иң усал хайваннарның берсе — сасы көзән ягъни. Чынлап, аның каршында сезнең әлеге арслан, капланнарыгыз — һәммәсе юаш бозау кебек кенә. Арслан, әйтик, үзенә тиешле бер пот итне тыгына да янтыгына ава — әйдә, калганын шакаллар ашасын, янәсе, һич тә исе китмәгән кыяфәттә читтән карап тик ята. Ә бу сөйкемле әшәке җан, әгәр, әйтик, тавык кетәгенә үтеп керә икән, бер тавыкны исән калдырмас — һәрбersen менә бу төшеннән, кикрик астыннан, тешләп, кырып салыр. Холкы шундый тынычсыз аның, кабахәтнең. Шуның өстенә, көзән — барлык җәнлекләр арасында иң кыргые, кулга иң ияләшмәгәне. Ух, сине, авыз!

Шулай дип, Рафальский кулын тимер чыбык койма ярыгына тыкты. Оя тишегеннән шундук, үткен, ап-ак тешләрен усал ыржайтып, очлы, кечкенә борын сузылып чыкты да янәдән кереп югалды. Көзән шулай, башын бер чыгарып, бер кире алып, ачулы, ютәл сыман тавыш белән туктаусыз ырылдарга тотынды.

— Әнә, күрәсезме, нинди? Ә бит үзен бер ел ашатам югыйсә...

Подполковник, күрәсең, Ромашовның үтенечен бөтенләй онытkан иде. Ул, кунагын әле бер, әле икенче оя янына алып килеп, аңа үзенең яраткан җәнлекләрен күрсәтеп йөрде һәм, иң якын, иң сөйкемле танышлары турында сүз баргандай, ифрат җанлы, белдекле рәвештә, бу җәнлекләрнең холык-гадәтләрен мавыгып һәм яратып сөйләде. Чыннан да, гади бер һәвәскәрнеке, бигрәк тә үзәктән ерак караңгы бер шәһәрдә яшәүче һәвәскәрнеке буларак, аның җыйган коллекциясе шактый бай һәм кызыклы иде. Ак тычканнар, йорт куяннары, диңгез дуңгызлары, керпеләр, байбаклар, пыяла тартмаларда ябып асралган берничә агулы елан, берничә токым кәлтә еланнары, мартышка токымыннан ике маймыл, кара йонлы Австралия куяны һәм бик сирәк очрый торган чибәр-мәһабәт ангор мәчесе — боларның һәммәсе бар иде бу коллекциядә.

— Ничек? Шәпме? — диде Рафальский, ангор мәчесенә төртеп күрсәтеп. — Үзенә күрә дигәндәй, соклангыч экземпляр, шулай бит? Ләкин яратмыйм үзен. Ахмак хай-

ван. Мәчеләрнең иң ахмагы. Менә тагын бер дәлил! — дип, кинәт җанланып китте хуҗа кеше. — Йорт хайваннарыбызның психикасына игътибар итмәвебезгә дәлил диюем. Әйе! Мәче турында без ни беләбез? Ә ат турында? Сыер турында? Дуңгыз турында? Йорт хайваннарыннан, беләсезме, кайсы тагын бик акыллы? Дуңгыз ул! Әйе, әйе, сез көлмәгез, — Ромашовның көләргә уйлаганы да юк иде,— дуңгыз ул коточкыч акыллы хайван. Узган елны миндәге кабан дуңгызы шундый бер мәзәк эшләп ташлады, исең-акылың китәр. Яшелчә бакчасы өчен, шулай ук дуңгызлар өчен дә дигәндәй, мин шикәр заводыннан барда китерткәли идем. Шул, тегенең, кабан дуңгызының диюем, сабыры тәмам төкәнгән: йөкче абзый минем денщикны эзләп өйгә кереп китүе була, бу мичкәнең бөкесен тешләре белән суыра да чыгара. Агыпмы-ага барда җир өстенә, ә дуңгызга рәхәт: ауный-ауный чөмерә барданы. Әле алай гынамы: бервакыт, караклыкта тотылганнан соң, бу, мичкәнең бөкесен суырып алу белән генә канәгатьләнмичә, аны яшелчә бакчасына илтеп, түтәл арасына җиргә күмеп куя башлаган. Менә сезгә дуңгыз! Дөресен әйткәндә, — Рафальский, бер күзен кыса төшеп, хәйләкәр генә көлемсерәп куйды, — дөресен әйткәндә, мин дуңгызлар турында кечкенә бер мәкаләчәк язып ятам әле... Тик ләм-мим!.. әлегә сер. Уңайсызрак бит: данлы рус гаскәре подполковнигы дуңгызлар турында мәкалә язсын, имеш! Хәзер мин йоркшир дуңгызлары алдырдым. Күрдегезме? Теләсәгез, әйдәгез, карап керик? Анда, ишегалдында, тагы яшь кенә бер бурсык баласы да бар әле, сокланып туймассың үзенә... Карап керәбезме?

— Гафу итегез, Иван Антонович,— диде Ромашов, уңайсызланып, — бик рәхәтләнеп карар идем дә, тик һич вакытым юк, валлаһи менә...

Рафальский учы белән үзенең маңгаена шапылдатып сукты.

— Аһ, гөнаһ шомлыгы! Зинһар өчен кичерегез мин картлачны, тел бистәсен, бөтенләй онытканмын... Ну, ну, ну, әйдәгез тизрәк.

Алар поход ятагыннан — урта җире көймә эче сыман түбән сыгылып төшкән тәбәнәк карават һәм бәләкәй төнге өстәл белән артсыз урындыктан кала бернинди җиһазы-фәләне булмаган кечкенә генә, шәрә генә бер бүлмәгә барып керделәр. Рафальский өстәл тартмасын ачып акча алды.

— Сезгә ярдәм итәргә һәрвакыт шатмын, подпоручик, һәрвакыт шатмын. Ну, менә... нинди рәхмәтләр ди ул?..

Юк сүз... Бик шатмын... Вакыт булганда, кергәләгез. Сөйләшеп утырырбыз.

Урамга чыгуга, Ромашовка Веткин очрады. Мыек чылгыйларын Павел Павлович тагы да кабартыбрак җибәргән, ә фуражкасын, көязрәк күренсен өчен, ян читләрен батырып, башына кырын салып кигән иде.

— Ә-ә! Принц! Гамлет! — дип, шатланып кычкырды ул. — Каян һәм кая юл тотуыгыз? Фу, шайтан алгырысы, нәкъ туган көне диярсең: чыраенда нур балкый.

— Туган көнем шул, — диде Ромашов, елмаеп.

— Чынлапмы? Хәер, шулай булмыйча: Георгий һәм Александра. Бик тә илаһи. Кайнар кочагыма алырга рөхсәт итегез.

Алар шунда ук, урам уртасында, кочаклашып үбештеләр.

— Бәлки, бу уңай белән җәмгыятькә кереп, затлы дустыбыз Арчаковский әйтмешли, тамак төбен чылатып чыгарбыз, ә?

— Юк, булмый, Павел Павлыч. Ашыгам. Чылату дигәннән, сез инде шактый дәртләнеп өлгергәнсез бугай?

— О-о-о, — дип сузды Веткин, горур төстә ияген югары чөеп. — Мин бүген шундый бер комбинация эшләп ташладым, андый комбинацияне күреп, теләсә нинди финанс министрының көнләшүдән эче авырта башлар иде.

— Ягъни?

Веткинның комбинация дигәне гади генә, әмма шактый мәзәк бер эш булып, анда иң төп рольне полк тегүчесе Хаим уйнаган булып чыкты. Хикмәт шунда: хәйләкәр-тапкыр Павел Павлович, бер пар мундир алуы турында язу язып, тегүчедән мундирның үзен түгел, ә утыз сум акча алган икән.

— Ахыр чиктә без икебез дә канәгать калдык,— диде Веткин, куанычыннан сөйләнә-сөйләнә, — яһүд шуның белән канәгать, чөнки ул кием тәэминаты кассасыннан утыз сум урынына кырык биш сум алачак, ә мин акчалы булуым белән канәгатьмен: бүген җәмгыять клубында әлеге хөрәсән карта уйнаучыларның һәммәсен төп башына утыртачакмын, димәк. Нәрсә? Шәп эшләгәнменме?

— Шәп! — диде Ромашов, килешеп. — Икенче юлы моны мин дә искә алырмын. Шулай да, хәзергә сау булып торыгыз, Павел Павлыч. Сезгә бәхетле карта телим.

Алар аерылыштылар. Ләкин минут та үтмәстән, Веткин янәдән иптәшенә дәшеп кычкырды. Ромашов, туктап, артына борылды.

— Җәнлекләр карап кайтышмы? — дип шаяртып со-

рады Веткин, Рафальский йортына таба җилкә аша гына бармагы белән төртеп күрсәтеп.

Ромашов баш какты һәм эчке бер ышаныч белән:

— Безнең Брем шәп кеше ул. Шундый сөйкемле! — диде.

— Әйтәсе генәме! — диде Веткин, килешеп. — Тик — артык псих!

XIII

Сәгать бишләр тирәсендә Николаевлар яшәгән йортка якынлашып килгәндә, Ромашов, тирән гаҗәпсенү белән, үзендә эле иртән генә хис иткән ышанычның — бүгенге көн уңышлы тәмамланырга тиеш дигән куанычлы ышанычның ничектер сүрелеп, сәер, сәбәбсез бер борчылу хисе белән алышынуын тойды. Бу үзгәреш киноттән, менә хәзер генә булмыйча, элегрәк башланган икәнен дә сизенде ул. Күрәсең, борчылу яралгысы күңелдә бая ук туып, ул әкрен-әкрен үсә, көчәя барган һәм аның башлану моментын Ромашов үзе дә шәйләми калган иде булса кирәк. Нидән икән бу? Мондый хәл элегрәк тә еш кына булып, хәтта бала чагыннан ук күзәтелеп, бу авыр хистән арыныр өчен иң әүвәл аның сәбәбен табарга кирәклеген Ромашов бик яхшы белә иде. Исендә эле: бер вакыт ул шундый авыр борчылу хисе белән көне буе азапланып йөрде, бары кичен генә аның сәбәбен ачыклады: көндез, станциядә тимер юл аша чыкканда, искәрмәстән паровоз кычкыртып, ул шул тавыштан куркып һәм көефе бозылып калган икән. Шул вакыйганы исенә төшергәч тә, Ромашовка җиңел, хәтта күнелле булып китте.

Һәм ул бүген үзе булган барлык җирләрне һәм башыннан кичкән тәэсирләрне кирегә таба янәдән хәтереннән барлап чыгарга тотынды. Свидерский кибете; ислемай; извозчик Лейба — менә дигән извозчик, шәп алып бара; почтага кереп вакыт белешү; искиткеч матур иртә; Степан... Әллә чыннан да шул Степан аркасында микән? Юк, охшамый — кесәдә әнә Степан өчен махсус аерып куйган бер сум акча ята. Алайса нидән соң бу? Нидән?

Қойма буенда инде һәркайсы пар ат җигүле өч экипаж тора иде. Ике денщик исә иярле ике атның тезгеннәреннән тотканнар. Бу атларның берсе, көрән төстәге карт алаша — Олизарныкы булып (ул аны күптән түгел генә кавалерия өчен яраксыз табылган атлар арасыннан сатып алган иде), икенчесе, сөлектәй төз гәүдәле, кан баскан усал күзле, алтынсу-җирән төстәге бия — поручик Бек-Агамаловныкы иде.

«Ах — теге хат! — диде кинәт Ромашов, хәтеренә төшереп. — Хаттагы теге сәер җөмлә: *бернигә дә карамыйча*... Җитмәсә, астына сызылган иде... Берәр хәл булды микәнни? Бик ихтимал. Николаевның миңа ачуы чыккан, күрәсең! Әллә көнләшә башладымы икән? Бәлки, берәр төрле гайбәт ишеткәндер? Соңгы көннәрдә Николаев үзен минем алда болай да бик коры тота. Юк, юк, туктамый узып китәргә кирәк!»

— Туктамагыз, бара бирегез! — дип кычкырды ул извозчикка.

Әмма шундук, ишетеп тә, күреп тә түгел, ә йөрәгенең татлы, ашкынулы тибүеннән дигәндәй, Николаевлар йортының кинәт ишеге ачылып китүен тойды. Ул да булмады, артта Александра Петровнаның яңгыравык, шат тавышы ишетелде:

— Ромочка! Кая китеп баруыгыз бу?

Ромашов извозчик Лейбаның янтыгына төртте дә экипаждан сикереп төште. Ачык ишекнең кара рамы уртасында Шурочка басып тора иде. Өстендә бизәксез ап-ак күлмәк; путасына, уң яктан, берничә бөртек кызыл чәчәк кыстырылган. Шундый ук кызыл, янар-ут чәчәкләр аның чәчләренә дә кадалган иде. Сәер: Шурочка икәнен тәгаен белсә дә, Ромашов аны гүя танымыйчарак торды. Аңардан ниндидер яңа бер нур, бәйрәмчә балкыш, куаныч ташып тора кебек иде.

Ромашов тотлыга-тотлыга тәбрик сүзләре мыгырдаган арада, Шурочка аны, кулыннан эләктереп, иркәләү катыш бер рәсмилек белән, караңгы чоланга өстерәп алып керде. Үзе ишетелер-ишетелмәс тавыш белән тиз-тиз пышылдавында булды:

— Ярый әле килгәнсез, Ромочка, рәхмәт сезгә. Белсәгез иде: килмәссез дип шундый курыктым мин. Сез бүген сөйкемле, шат чырайлы булырга тиешсез, ишетәсезме? Бернигә дә игътибар итмәгез. Сез бик мәзәк кеше бит: аз гына орынсаң да, мәлҗерәп төшәсез. Оялчан мимоза кебек.

— Александра Петровна... бүгенге хатыгыз мине аптырашта калдырды. Анда сәер бер җөмлә бар.

— Кирәкми, сөеклем, һич кирәге юк!.. — диде Александра Петровна һәм, егетнең ике кулын да учына алып кыса-кыса, туп-туры аның күзләренә төбәлеп карады. Бу күз карашында Ромашов өчен аңлап булмастай янә ниндидер яңа, ят төсмерләр чагылып күренде; анда, үзенә бер төрле иркәләүчән наз да, борчылу да бар, ә тирәндәрәк, зәңгәр күзләрнең иң караңгы төпкелендә, күңелнең үтә

яшерен, үтә изге серләрен чак кына сиздереп торган сыман, әлегә акыл ирешмәс тагы бер сәер ут җемелди иде.

— Зинһар, кирәкми. Ул хакта уйламагыз бүген... Туктамый узып китәрсез дип, урам сагалый-сагалый арып беттем инде мин. Шул да бик җиткән. Сез нинди куркак икәнне беләм ич. Алай итеп карыйсы булмагыз мина!

Александра Петровна, үзе үк уңайсызлангандай, көлеп һәм башын чайкап куйды.

— Ярар, булды... Сез тагы минем кулны үбәргә онытмагыз, Ромочка! Менә шулай. Хәзер икенчесен. Шулай. Зирәк икәнсез. Әйдәгез, керик. Хәтерегездән чыгармагыз, — диде ул аннары пышылдавык кайнар бер тавыш белән, ашыгып, — бүген безнең бәйрәм. Падиша Александра белән аның рыцаре Георгий туган көн. Ишетәсезме? Өйгә керик.

— Менә, рәхим итеп... Кечкенә генә бүләгем...

— Нәрсә ул? Ислемай? Нинди җүләрлек бу тагы! Юк, юк, шаяртуым гына. Зур рәхмәт сезгә, Ромочка. Володя!— дип, каты, көр тавыш белән эндәште ул, кунак бүлмәсенә керә-керешли. — Пикник өчен безгә менә тагын бер юлдаш өстәлде. Җитмәсә әле үзенең дә бәйрәме — исем кушкан көне.

Кунак бүлмәсендә гадәттә кая да булса күмәкләп барырга җыенганда була торган үзенә бер төрле шаушу һәм тәртипсезлек хөкем сөрә иде. Бөтен бүлмә эчен түшәмгә кадәр диярлек куе тәмәке төтене сарган; тәрәзә аша кыйгачлап төшкән язгы кояш нурларында ул нәкъ ачык зәңгәр күк төсендә дулкынланып күренә. Бүлмә уртасында җидеме, сигезме офицер үзара нидер кызып-кызып сөйләшеп торалар. Озын буйлы Тальман бигрәк тә нык кызган бугай: аның ютәл аралаш тыңкышланып сөйләгән сүзләре бөтен бүлмәгә яңгырап ишетелә. Аңардан башка монда капитан Осадчий, ахири адъютантлардан Олизар белән Бек-Агамалов, күсенекедәй очлы танаулы, тәбәнәк буйлы, елгыр хәрәкәтле поручик Андрусевич һәм әлегә Ромашов танып өлгермәгән тагы берничә офицер бар иде. Тальманның хатыны, битенә иннек-кершән ягып, тәмам купшы дәү курчак рәвешенә кергән Софья Павловна, чытлыклана-елмая, диванда подпоручик Михинның ике сеңелесе белән сөйләшеп утыра. Туташларның өстендә гади материядән яшел тасмалар тагып үзләре теккән килешле ак күлмәк; икесе дә алсу битлеләр, коңгырт күзле, кара чәчле һәм сипкеллеләр; тешләре күз явын алырлык җете ак төстә һәм, беркадәр кыек-мыек урнашкан булсалар да, кызларның яшьләрчә алсу, саф иренле авызларына үзенә

бер төрле күркәмлек өстәп торалар шикелле. Кыскасы, икесе дә мөлаем, шат күңеллеләр; бер-берсенә ике тамчы су кебек охшашлар, шул ук вакытта ифрат ямьсез абыйларына да бик нык охшаганнар кебек. Полк хатын-кызларыннан тагын поручик Андрусевичның кечкенә буйлы, юан гәүдәле, ак битле, үзе мәнсезрәк булса да, киноле сүзләр һәм оятсыз анекдотлар тыңларга бик яратучы шаркылдавык хатыны һәм күркәм чырайлы, күп сүзле сакау Лыкачевалар чакырылган иде.

Офицерлар җәмгыятендәге гадәт буенча, хатын-кыз халкы ир-аттан читтә, аерым төркем булып оешкан. Алар янында, эре-көяз һәм гамьсез бер ир сурәтендә, гәүдәсе белән креслоның бөтен иңенә җәелеп дигәндәй, штабс-капитан Диц утыра. Тәнгә сыланып торган кием кигән чандыр гәүдәсе һәм таушалган, тәкәббер чырае белән карикатуралардагы прус офицерларын хәтерләткән бу кеше элек гвардиядә хезмәт итеп, ниндидер караңгы, җәнҗаллы эшләре өчен пехота полкына күчерелгән офицерлардан иде. Ир-ат арасында ул үзен ифрат һавалы тота, ә хатын-кыз белән мөгамәләдә ачыктан-ачык тәкәллефсез кылана һәм карта уйнарга бик ярата иде. Уйнаганда һәрвакыт зурдан кубып һәм үзе өчен отышлы уйный, өстәвенә, офицерлар җәмгыятендә түгел, ә читтә — йә шәһәрчек клубына, йә чиновниклар яисә шәһәр тирәсендәге поляк алпавытларының өйләренә барып уйный. Полкта аны беркем диярлек яратмый, ләкин һәммәсе аңардан ничектер шүрләп, киләчәктә ул нинди дә булса ямьсез, гаугалы эш китереп чыгармагае дигән сагаюлы бер шик белән яши. Сөйләүләренә караганда, ул шушы ук шәһәрчектә яшәүче карт бер бригада командирының яшь, чибәр хатыны белән якын элемтәдә тора, имеш. Ә инде аның Тальман ханым белән якынлыгы һәркемгә мәгълүм; әнә шуның өчен дә аны кунак-мәҗлестән калдырмыйлар — моны полк кешеләре арасында яшәгән үзенә бер төрле игътибар һәм әдәплелек законнары таләп итә иде.

Ишектә Ромашов күренүгә, Николаев аңа таба атлады.

— Бик шатмын, бик шатмын, пикнигыбыз күңеллерәк булыр. Ник сез иртәнге якта пирогтан авыз итәргә килеп чыкмадыгыз?

Моны ул ягымлы елмаеп, көләч йөз белән әйтте, ләкин соңгы вакытларда Николаев белән очрашкан саен күңеленнән нидер сизенгән кебек, бу юлы да Ромашов, бөтенләй үз ихтыярыннан тыш дигәндәй, хуҗаның тавышында һәм күз карашында ниндидер ясалма корылык, чит-ят күрү галәмәтләрен дә ачык сизде.

«Ул мине яратмый, — дип, шундук күңеленнән нәтиҗә ясады Ромашов. — Нидән икән бу? Ачуы килгән микәнни? Әллә көнләшәме? Биздереп бетергәнмен, күрәсең...»

— Беләсез, вакыты шундый... ротада корал барлаутикшерү бара, смотрга хәзерләнәбез, хәтта бәйрәм көннәрендә дә ял тими, — дип ялганлады Ромашов кыю төстә. — Шулай да мин хәзер бик кыен хәлдәмен... Сездә пикник буласын башыма да китермәгән идем, инде менә — чакырылмаган җиргә үзем тыгылам шикелле. Чыннап, бик оят миңа...

Николаев, колагына кадәр авызын ерып, мәсхәрәле мөлаемлык белән Ромашовны иңбашынан чәбәкләде.

— Һи, юкка борчыласыз, егетем... Халык никадәр күбрәк булса, шулкадәр күңеллерәк ул... Нигә ди монда кытайлар нәзакәте!.. Тик менә, белмим, фаэтонда урын мәсьәләсе генә ничегрәктер инде. Хәер, ничек тә сыярбыз әле.

— Минем үз экипажым бар, — диде Ромашов, Николаевның кулын иңбашыннан чак кына читкә этәреп. — Кирәксә, мин аны бик рәхәтләнеп сезнең карамакка тапшыра алам.

Ул, башын борып, Шурочка белән күзгә-күз карашып алды.

«Рәхмәт, сөеклем!» — дигәнне аңлатты аңа Шурочканың әүвәлгечә ниндидер серле, сәер игътибар белән караган ягымлы күзләре.

«Бүген ул әллә нинди, артык гажәеп!» — дип уйлады Ромашов.

— Ни дим, искиткеч шәп булды бу алайса. — Николаев сәгатенә күз төшерде. — Ягез, әфәнделәр, — диде ул аннары сораулы аһәң белән, — бәлки, безгә кузгалырга вакыттыр?

— Кузгалырга икән кузгалырга, дигән ди попугай үзен ата мәче читлектән сөйрәп чыгарганда! — дип, шаяртып әйтеп куйды Олизар.

Һәммәсе күңелле шаулаша-көлешә урыннарыннан кузгалдылар; хатын-кызлар, перчаткаларын киеп, эшләпә, зонтикларын эзләргә керештеләр; поручик Тальман, бронхитлы тавышы белән бөтен бүлмәне яңгыратып, аларга: «Җылы шәлләрегезне алырга онытмагыз!» — дип кычкырды. Бүлмәдә әнә шулай юлга җыену ыгы-зыгысы башланды.

Кәрлә Михин Ромашовны бер читкә дәшеп алды.

— Юрий Алексеич, сезгә бер үтенечем бар иде, — диде

ул. — Ялварып сорыйм. Зинһар, экипажда минем сеңелләр белән бергә утырып барыгызчы, юкса алар янына Диц утырачак, э мин аның утыруын һич теләмим. Ул артык әшәке сөйләнә, кызларны җылар дәрәҗәгә җиткерә. Валлаһи дип әйтәм, көч кулланыга гомумән каршы кешеләрдән булсам да, кайчан да бер аның яңак төбенә менеп төшәчәкмен әле мин!..

Ромашовның Шурочка белән бергә утырып барасы килә иде. Ләкин, бердән, Михинны кеше буларак һәрвакыт ошатканга, икенчедән, менә хәзер ул, малайларча саф, ихлас күзләрен томырып, бик ялынып сораганга, аның соңында үзенең дә бу минутта бөтен күңеле чиксез шатлык хисеннән ташыганга, ул каршы сүз әйтергә җөрьәт итмәде, ризалыгын бирде.

Өй болдыры каршында экипажларга утырышканда да шактый озак шау-гөр килделәр. Ромашов, вәгъдәсен истә тотып, Михинның сеңелләре янына менеп утырды. Шул вакыт экипажлар арасында үзенең гадәти өметсез-боек, мескен кыяфәтендә таптанып басып торган штабс-капитан Лещенко күзгә чалынды. Аны берсе дә фаэтонга үз янына утыртырга теләми иде булса кирәк. Ромашов аны кычкырып дәшеп, алгы эскәмиядә үз янәшәсеннән аңа урын тәкъдим итте. Лещенко, тугры эт сыман, күндәм, нурлы күзләре белән подпоручикка күтәрелеп карады да, көрсенеп, экипажга менде.

Ниһаять, барысы да утырышып беттеләр. Кайдадыр алда Олизар, үзенең ялкау, карт алашасы өстендә боргалана-сыргалана шамакайланып, мәгълүм опереткадан җыр җырлап җибәрде:

Сядем в почтовую карету скорей,
Сядем в почтовую карету поскоре-е-ей... [1]

— Юырттырып ма-а-арррш! — дип, күк күкрәгәндәй тавыш белән команда бирде Осадчий.

Экипажлар кузгалып киттеләр.

XIV

Пикник күңелле булудан бигрәк ничектер тавышлы һәм ыгы-зыгылырак килеп чыкты. Алар шәһәрчектән өч чакрым ераклыктагы «Имәнлек» дигән җиргә барып туктадылар. Йөз яшәрлек мәгърур, юан кәүсәле сирәк-сирәк

[1] Утырыйк тизрәк почта каретасына,
Утырыйк, утырыйк тизрәк почта каретасына...

имәннәр үсеп утырган ун-унбиш дисәтинә чамасындагы озынча бер калкулык иде бу. Калкулык итәге буйлап борыла-сырыла саф сулы кечкенә генә инеш ага, аның тау ягын куе әрәмәлек каплаган булып, анда беренче язгы чирәмнән хәтфәдәй яшеллəнеп торган иркен, ямьле, матур-матур аланчыклар бар иде. Шундый аланчыкларның берсендә азык-төлек корҗиннәре һәм самавырлары белән махсус алдан җибәрелгән дежниклар сәйранчыларны көтеп тора иде инде.

Шунда чирәм өстенә үк эскәтер җәеп, утырыша башладылар. Хатын-кыз җәмәгате табынга закуска, тәлинкәләр куярга кереште, ирләр исә үтә нәзакәтле, шаярулы чырай белән аларга булышкалап йөрде. Олизар, бер тастымалны биленә алъяпкыч итеп, ә икенчесен башына калпак сыман итеп бәйләп, офицерлар клубындагы повар Лукичны уйнап күрсәтте. Хатын-кызлар белән ирләр үзара һичшиксез аралаш утырырга тиеш иде, шуңа күрә кешеләрне башта бик озак бер урыннан икенче урынга күчереп азапладылар. Урын бик җайсыз — кайсы ярым яткан, кайсы чөмәшеп утырган; ләкин һәммәсенә дә бу җайсызлык үзенә бер төрле кызык яңалык булып тоелды, һәм гадәттә аз сүзле Лещенко, һәммә кешедә гажəпләнү, гомуми көлү уятып дигәндәй, кинәт үтә купшы һәм ахмак бер чырай белән:

— Хәзер без борынгы Рим греклары сыман хозур кыйлып ятабыз, имеш, — дип әйтеп куйды.

Шурочка үз янына бер яктан Тальманны, ә икенче яктан Ромашовны утыртты. Ул бүген шундый көләч, шундый күп сөйләшə һәм шулкадәр күтәренке рухлы иде ки, моны башкалар да ачык сизде кебек. Һәрхәлдә, Ромашов аны мондый соклангыч-гүзәл сурәттә әле беркайчан да күргәне юк иде. Гүя аның күңелендә ниндидер яңа, олы бер хис кайный һәм, ирек сорап, тышка ташып чыгарга юл эзли. Кайчакны Шурочка Ромашовка таба башын бора да, бер сүз дә дәшмичә, гадәттә булгандагыдан яки, дөресрәге, тиеш булгандагыдан ярты секундка гына озаграк итеп аңа карап тора, һәм һәр юлы Ромашов аның бу күз карашында, баягыча, һаман шул ук аңлаешсыз, кайнар, үзенә тартып торган бер көч яшеренеп ятканын ачык тоя иде.

Табын башында утырган Осадчий, күтәрелə бирeп, аякларына тезлəнде. Стаканга пычагы белән суккалап, тынлык урнаштыргач, ул урманның саф һавасында дулкындай талгын тирбəлеп яңгыраган калын, күкрәк тавышы белән болай дип белдерде:

— Әфәнделәр... Беренче рюмканы безнең кадерле, гүзәл хуҗабыз Александра Петровнаның исәнлеге һәм бәйрәме хөрмәтенә эчәргә тәкъдим итәм. Ходайдан аңа зур бәхетләр сорыйк һәм аның генерал хатыны дәрәҗәсенә ирешүен телик.

Шулай дип, Осадчий кулындагы рюмкасын баш өстенә күтәрде дә коточкыч көчле бугазының бар куәтенә үкереп җибәрде:

— Урра!

Арслан үкерүенә тиң бу «урра»дан бөтен урман гүя ахылдап куйды, агачлар арасыннан тавыш дулкыннары гүелдәп узды. Осадчий янәшәсендә утырган Андрусевич, көленеч кыяфәттә юри йөзен чытып, тавыштан колагы тонган кеше рәвешендә йөзтүбән җиргә капланды. «Урра»ны бүтәннәр дә бердәм күтәреп алды. Аннары ирләр, урыннарыннан торып, Шурочка янына рюмкаларын чәкешергә җыелдылар. Ромашов юри иң соңыннан килде, моны Шурочка да шәйләп алды. Ромашовка таба чиксез дәрт белән елмайган нурлы йөзен борып, ул, сүзсез генә, ак шәраб салынган стаканын чәкешергә сузды. Бу моментта аның күзләре кинәт кенә киңәеп ачылып, серле карангылык белән капланды, э иреннәре, ниндидер сүз әйтеп, кыймылдап куйды. Аннары ул янә табынга таба борылып утырды да, көлә-елмая, Тальман белән сөйләшә башлады. «Ah, нинди сүз әйтте соң ул, нинди сүз әйтте?» — дип, тирән дулкынлану эчендә борчылып уйланды. Ромашов. Ул, кешеләргә сиздермичә генә, куллары белән йөзен каплап, иреннәрен, Шурочкадан күрә, әкрен генә кыймылдатырга кереште; шулай итеп, күңелендә Шурочка әйткән теге серле сүзне торгызырга теләде, әмма берни дә чыкмый иде. «Сөеклем», «Яратам», «Ромочка»? Юк, бу сүзләр түгел. Аңа тик бер генә нәрсә ачык иде: Шурочка әйткән сүз өч иҗектән торырга тиеш.

Аннары Николаев исәнлеге өчен, аның киләчәктә генеральный штабта яулаячак хезмәт уңышлары өчен эчтеләр. Ләкин эчү рәвешләренә карап фикер йөрткәндә, табында утыручыларның берсе дә аның, Николаевның, кайчан да булса академиягә укырга керә алуына ышанмый иде шикелле. Аннан соң, Шурочканың тәкъдиме буенча, шактый сүлпән генә дигәндәй, Ромашовны исем кушу бәйрәме белән котлап эчтеләр; шулай ук табында утыручы бүтән дамалар һәм ирләр өчен, гомумән барлык дамалар өчен, туган полкның данлы байрагы, җиңелмәс рус армиясе өчен дә аерым-аерым тостлар әйтеп эчтеләр...

Ниһаять, исерүе инде шактый җиткән Тальман торып

басты һәм карылдык, ләкин ихлас-тәэсирле тавыш белән каты итеп кычкырып җибәрде:

— Әфәнделәр, мин бу тостны безнең иң кадерле, иң сөекле кешебез — аның өчен һәркайсыбыз соңгы тамчы канына хәтле бирергә әзер торган кешебез — патша хәзрәтләре исәнлегенә эчәргә тәкъдим итәм!

Соңгы сүзләрне ул, сулышы җитмичә, ничектер бик нәзек, сызгыргандай бер тавыш белән әйтеп бетерде. Шул ук вакытта аның юлбасар чегәннекедәй ут янып торган чем-кара күзләре, кинәт кенә сүрелеп, кызганыч бер төстә җем-җем йомыла башлады һәм кара-кучкыл яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәрәп төште.

— Гимн, гимн! — дип чәрелдәде тәбәнәк, юан Андрусевич ханым, тәэсирләнеп.

Һәммә кеше аягүрә торып басты. Офицерлар, честь бирергә дип, кулларын фуражка козырекларына таба күтәрделәр. Урман аланы тәртипсез, әмма дәртле җыр авазы белән тулды, һәм арада сүзләрне иң каты кычкырып, әкөйне барысына караганда да яманрак бозып җырлаганы — артык тәэсирләнүдән чырае тагы да мескенләнә төшкән штабс-капитан Лещенко булды.

Гомумән, аракы һәрвакыттагыча — бер-берсендә кунакта, җәмгыять клубында яисә тантаналы мәҗлесләр һәм башка пикникларда булгандагыча, — бик күп эчелде. Табын әһеле инде барысы берьюлы сөйләшә, аерым кешенең сөйләгәне бөтенләй аңлашылмый иде диярлек. Ак йөзем аракысын шактый күп эчеп, бит-яңаклары тәмам кызарып чыккан, шомырт кара күзләре, киңәеп, тагы да кучкыллана төшкән Шурочка, дымлы алсу иреннәрен уйнатауйната, кинәт йөзен Ромашовка якын ук китерде дә:

— Мондый провинциаль пикникларны яратмыйм мин, аларда ниндидер вакчыллану, эчпошыргыч кылану бар,— диде. — Дөрес, бу пикник ирем хөрмәтенә, аның китү уңае белән эшләнде эшләнүен, әмма чынлап уйлаганда нинди мәгънәсез, нинди ахмак нәрсә бу, йа ходай! Бит боларның һәммәсен өйдә, безнең бакча эчендә дә оештырып була иде ләбаса! Сез безнең бакчаның нинди гүзәл, матур икәнлеген беләсез ич: агачлар зур, җәенке ботаклы, үзе шундый күләнкәле. Шулай да мин бүген чиксез бәхетле. Шулкадәр бәхетле, сәбәбен хәтта үзем дә белмим! Юк, Ромочка, җаныем, сәбәбен дә беләм шикелле, тик аны хәзер әйтәсем килми, мин сезгә аны соңыннан, соңыннан әйтермен, ярыймы... Мин әйтермен... Ah, юк, юк, Ромочка, мин берни дә, берни дә белмим.

Шурочканың матур күзләре ярым йомылып, йөзенә күң-

ңелне җилкендереп, үзенә тартып торган ниндидер газаплы, сабырсыз бер өмет балкышы җәелде. Оятсыз-гүзәл бер рәвешкә керде ул йөз, һәм Ромашов, акылы белән аңламаса да, күңеленең яшерен кыллары белән, Шурочканы хәзер биләп алган эчке дулкынны бик ачык сизде, аны аның бөтен гәүдәсе — аяк-куллары, күкрәкләре буйлап йөгереп узган татлы калтыраудан сизде.

— Сез бүген ничектер бөтенләй бүтән төрле. Ни булды сезгә? — дип сорады ул пышылдап кына.

Шурочка, кинәт үзе үк гаҗәпкә калгандай, балаларча беркатлы, юаш тавыш белән җавап бирде:

— Әйтәм бит, берни белмим. Берни белмим. Әнә карагыз: күк йөзе нинди зәңгәр, яктылык үзе дә нинди зәңгәр... Миндә дә әнә шундый зәңгәр бер халәт хәзер, ниндидер зәңгәр шатлык! Ромочка, сөйкемле малайкаем минем, салыгыз әле миңа тагы вино...

Ул арада табынның икенче башында Германия белән сугыш ихтималы турында сүз чыкты. Әйтергә кирәк, күпләр моны ул вакыт бөтенләй диярлек хәл ителгән мәсьәләгә саный иде. Менә хәзер дә, шул хакта шау-шулы бәхәс кубып, берничә авыз берьюлы, тәртипсез рәвештә, һәркайсы үз карашын дәгъваларга тотынды. Кинәт Осадчийның ачулы, кискен тавышы яңгырады. Матур, чибәр йөзенең коточкыч агарып китүенә караганда, ул инде шактый исергән, ә кара күзләренең авыр-салмак карашы тагы да караңгылана төшкән иде.

— Ерунда! — дип гүелдәде ул. — Мин әйтәм, боларның һәммәсе ерунда дим. Сугыш хәзер үзенең сугышлыгын югалтты. Дөнья йөзендә бөтенесе бетүгә таба бара. Балалар идиотлар булып туалар, хатын-кызлары кәкребөкре, ирләрендә нервы өянәге: «Ах, кан! Ах, мин һуштан язам!» — дип, кемнедер үчекләп алды Осадчий, тавышын тыңкышлатып. — Һәм боларның һәммәсе чын сугыш булмаудан. Дәһшәтле, аяусыз сугышлар заманы узды шул! Хәзерге сугыш сугышмыни ул? Унбиш чакрымнан торып сиңа — бах! — һәм син өйгә герой булып кайтасың. Шул да булдымы батырлык, ходаем! Әйтик, сине әсир алалар. «Ах, җаныкаем, ах, кадерлекәем, тәмәке төреп кабызырга теләмисеңме? Бәлки, чәй эчәсең киләдер? Салкынга җәберләнмисеңме, мескенкәем? Урын-җирең каты түгелме?» У-у! — Осадчий, кемнедер сөзәргә җыенгандай, үгез сыман башын түбән иеп, үкереп куйды. — Урта гасырларда — менә кайчан булган ул чын сугышлар. Әйтик, төнге һөҗүм. Бөтен кала янгын эчендә. «Шәһәрне өч көнгә солдатлар карамагына тапшырам!» Шуннан шәһәр

урамына бәреп керәләр. Кан һәм ут. Шәраб мичкәләренең төпләрен бәреп кенә чыгаралар. Урамда кан да шәраб дәрьясы. Хәрабәләр өстендә җиңү туе — менә ичмасам хозурлык! Шәрә, чибәр хатын-кызларны, ялварып җылауларына да карамыйча, чәчләреннән өстериләр. Кызгану дигәннең әсәре дә юк. Бу хатын-кызлар батыр солдатлар өчен ул вакыт татлы бер табыш сыман булган!..

— Шулай да сез алай бик үк тирәнгә кермәгез, — дип искәртте Софья Павловна Тальман, шаяртулы тавыш белән.

— Төннәрен йортлар янган, җилләр дулаган, җилдә дарда асылганнарның кара мәетләре тирбәлеп чайкалган, алар өстендә козгыннар очып йөргән. Ә дар агачлары төбендә, учаклар ягып, җиңүчеләр бәйрәм иткән. Әсирләр булмаган. Нигә ди алар? Алар өчен өстәмә көч сарыф итүнең ни хаҗәте бар? И-их! — дип, тешләрен кысып, тагы ярсулы төстә ыңгырашып куйды Осадчий. — Нинди кыю, нинди гүзәл заманнар булган бит! Ә сугыш дигәне! Кешеләр, күкрәккә күкрәк килеп, сәгатьләр буе сугышканнар, искиткеч осталык, акыл белән, ярсып, котырынып сугышканнар. Нинди көч, нинди коточкыч гайрәт булган аларда! Әфәнделәр! — диде аннары Осадчий, урыныннан торып, алыптай зур гәүдәсен турайтып басты да куанычлы, тупас бер тавыш белән сүзен әйтеп бетерде: — Әфәнделәр, мин беләм: сез барыгыз да хәрби училищедан хәзерге заманның гуманлы сугышы турында баллы-төчс, сыек төшенчәләр алып чыккан кешеләр. Әмма мин... хәтта берегез-бер миңа кушылмыйча, үземә генә эчәргә туры килсә дә, бу тостны үткән заманның шул күңелле, канлы, мәрхәмәтсез сугышлары өчен, шәфкатьсезлек өчен күтәрергә телим!

Һәммәсе, гадәттә караңгы чырайлы, аз сөйләүчән, астыртын бу кешенең көтмәгәндә генә шулай кайнар төстә ачылып китүеннән миңгерәүләнеп калгандай, тып-тын булдылар һәм аңа таба кызыксыну катыш тирән курку чагылган күз карашларын юнәлттеләр. Шул чак кинәт үз урыныннан Бек-Агамалов сикереп торды. Шулкадәр капылт һәм көтмәгәндә сикереп торды ки, күплэр берьюлы калтыранып китте, ә бер хатын хәтта куркудан эче итеп кычкырып җибәрде. Бек-Агамаловның күзләре, акаеп, ут яна, каты кысылган тешләре ерткыч җанварныкыдай ыржаеп елтырый иде. Ул, сулышына буылып, беравык сүзен әйтә алмыйча торды, ахырда Осадчийның кулын учына алып, аны ниндидер ачулы, үртәлүле көч белән селкиселки учына каты итеп кысты да:

— О, о!.. Менә ичмасам... менә ичмасам дөрес сүз әйт-

те бу! — дип, тәэсирләнеп кычкырды. — Бетсен төчеләнүләр! Бетсен кызгану! Ал Бөтенесен урталай ч-чап!

Ул, элек-электән, нәселдән килгән һәм гадәти вакытта томаланып, йокымсырап яткан вәхшилегенең, канга сусавының бөтен ачуын кемнәндер, нәрсәдәндер кайтарырга теләгәндәй, кан баскан күзләре белән тирә-ягын бер айкап алды да, кинәт, кынысыннан кылычын суырып чыгарып, тәмам ярсынган кыяфәттә, яшь кенә бер имән куагына китереп сукты. Куакның киселгән ботак һәм яфраклары, су тамчылары сыман чәчрәп, табын һәм аның тирәли утырган кешеләрнең өсләренә сибелде.

— Бек! Котырган! Вәхши! — дип чәрелдәп җибәрделәр ханымнар.

Бек-Агамалов, гүя шундук айнып, кире үз урынына барып утырды. Ул болай ярсып кабынып китүенә үзе дә оялды шикелле, ләкин аның пош-пош сулаган юка борын яфраклары туктаусыз дерелди, кабарып-кабарып куя, ә ярсудан акаеп шарланган һәм маңгай астыннан гына сөзеп караган шомырт күзләре табын янында утыручыларны көйдереп-көйдереп ала иде.

Ромашов Осадчийның сүзләрен тыңлады да, тыңламады да. Ул үзен төш күргәндәге кебек яисә, дөньяда булмаган ниндидер могҗизалы эчемлек эчеп, татлы исерү кичергән сәер бер халәттә тойды. Гүя ниндидер җылы, йомшак пәрәвез җепләре аның тәнен, рәхәт кытыклап, әкрен генә, иркәләп кенә үз эченә чолгый бара һәм күңелне шатлыклы көлү авазлары белән тутыра иде. Гүя үзе дә абайламастан, Ромашов кулы белән еш кына Шурочканың кулына орынып-орынып алды, ләкин ни тегесе, ни монысы бер-беренә борылып карамадылар. Ромашов, әйтерсең, мәрткә киткән иде. Осадчий белән Бек-Агамаловның сөйләгән сүзләре аңлашылса да, алар аңа каяндыр бик ерактан, ниндидер фантастик томанлык эченнән ишетелгән буш, мәгънәсез сүзләр булып тоелдылар.

«Осадчий... Шәфкатьсез кеше, ул мине яратмый, — дип уйлады Ромашов, һәм аның уйлаган бу кешесе хәзер аңа элеккеге Осадчий булып түгел, ә аңардан коточкыч ераква торган, җанлы фотография экранындагы шәүләгә охшаган, бөтенләй яңа бер кеше булып күренде. — Осадчийның хатыны бәләкәй генә, ябык кына бер бичара бәндә, үзе һәрвакыт йөкле булыр... Осадчий аны беркая да алып йөрми... Осадчий ротасында үткән ел бер солдат асылынып үлде... Осадчий... Әйе... Әйе... Кем ул Осадчий? Әнә хәзер Бек кычкырына... Анысы кем? Беләмме мин аны? Әйе, беләм, ләкин, белгәч, ни өчен соң ул миңа шун-

дый сәер, шундый чит-ят, аңлаешсыз кеше булып тоела? Ә менә янәшәмдә тагы берәү утыра... Кем син? Синнән шатлык нуры бөркелә, мин шул нурдан исергәнмен. Зәңгәр шатлык!.. Әнә каршымда — Николаев. Ул никтер ачулы. Бер сүз дәшми утыра. Монда бөтенләй карамый дияр-лек, күз карашы белән ничектер шуып кына уза. Һәй, ачулана бирсен сәнә — барыбер ич. Ух, зәңгәр шатлык!»

Эңгер төшә башлады. Агачлардан алан өстенә аксыл-шәмәхә күләгәләр ятты. Михин кызларының кечесе кинәт өтәләнеп куйды:

— Әфәнделәр, миләүшә чәчәкләре җыярга онытканбыз лабаса? Монда бик күп үсә диләр аларны. Әйдәгез, җыеп килик?

— Соң инде, — диде кайсысыдыр. — Хәзер үлән арасында берни табып булмаячак.

— Хәзер үлән арасында нидер табудан битәр нәрсәннедер югалтуың җиңелрәк, — дип өстәде Диц, тешләрен ыржайтып.

— Алайса, әйдәгез, учак ягабыз, — дип тәкъдим итте Андрусевич.

Зур бер өем чыбык-чабык һәм үткән елгы кипкән яфракларны җыеп килделәр дә учак ягып җибәрделәр. Ялкын, бик тиз үрләп, уйнаклый-уйнаклый, баганадай, күккә таба күтәрелде. Кичнең соңгы сүрән яктылыгы, өркетелгәндәй, шундук эреп югалды, аның урынына урман эченнән учакка таба куе караңгылык шуышты. Имәннәрнең ябалдашлары өстендә кызгылт шәүләләр чагылып уйнады, имәннәр үзләре дә, шул кызгылт шәүлә эчендә бер күренеп яисә артта җәйрәп яткан караңгылыкта күздән югалып, туктаусыз чайкала сыман тоелдылар.

Һәммә кеше табын яныннан торды. Денщиклар пыяла калпаклар эчендәге шәмнәрне кабыздылар. Яшьрәк офицерлар, мәктәп балалары кебек, шукланырга керештеләр. Олизар Михин белән көрәш башлап җибәрде һәм, барчасының гажәпләнүенә каршы, бәләкәй, шыксыз кыяфәтле Михин үзенең озын, зифа буйлы көндәшен бер-бер артлы ике мәртәбә җиргә әйләндереп салды. Аннан соң учак аша сикерешеп уйнадылар. Андрусевич төрле эш кораллары, кош-корт, бөҗәк тавышлары чыгарырга бик оста кеше иде. Башта ул тәрәзә пыяласына бәрелә-сугыла очкан чебен булып безелдәде, аннары, куаклык арасына посып, пычкы белән утын кискәнне һәм кайракта пычак кайраганны, тавык тотарга уйлаган кошчы хатынның мәтәлә-кадала чабып йөрүен кыланып күрсәтте. Хәтта Диц бу-

лып Диц та буш шешәләр белән жонглерларча уйнап алды.

— Әфәнделәр, рөхсәт итсәгез, мин сезгә бер бик шәп фокус күрсәтергә телим! — дип кычкырды кинәт Тальман.— Монда һичбер төрле сихер, могҗиза-фәлән юктыр; бу, ягъни, кулларның хәрәкәтләнү осталыгы гына. Рәхим итеп, хөрмәтле җәмәгатикум, минем җиңнәремә күз салыгыз: анда бернинди әйбер-фәлән юк, шулаймы? Башлыйм. Айн, цвай, драй... алле һоп!..

Шулай дип, ул кесәсеннән өр-яңа ике колода карта тартып чыгарды да, капларын чарт-чорт ертып, халыкка ачып күрсәтте. Һәммә кеше берьюлы шаркылдап көлеп җибәрде.

— Винт уйныйбызмы, әфәнделәр? — дип тәкъдим итте Тальман. — Саф һавада? Ә?

Осадчий, Николаев һәм Андрусевич карта уйнарга утырдылар. Лещенко, авыр көрсенеп, алар артына барып басты. Николаев башта, уйнарга теләмичә, мыгырданамыгырдана баш тартып маташкан иде дә, ахырда ризалык бирергә мәҗбүр булды. Утырганда ул, борчулы йөзен әле бер якка, әле икенче якка борып, берничә мәртәбә күзләре белән Шурочканы эзләп карады. Ләкин күзләр учак утына чагылганга, караңгыда берни дә шәйләрлек түгел, һәм башын шулай боргалаган саен Николаевның йөзе, киеренке, газаплы рәвештә җыерылып, ничектер мескен, ямьсез бер төс ала иде.

Карта уйнаучылардан кала барлык кешеләр учак тирәли аланчыкка таралыштылар. Башта алар сукыр тәкә уены оештырып җибәрделәр, ләкин уен озак дәвам итә алмады, чөнки Михин кызларының өлкәне, Диц тарафыннан тотылып, кызарынган-бүртенгән кыяфәттә кире әйләнеп килгәч, ул: бүтән уйнамыйм, дип уеннан баш тартты. Ачу һәм рәнҗүдән аның тавышына хәтле калтырана иде, ләкин ул рәнҗүенең сәбәбен әйтергә теләмәде.

Ромашов тар гына сукмактан урман эченә юл тотты. Аның йөрәге, алда ниндидер куаныч буласын сизенгәндәй, рәхәт, татлы бер талгынлык белән тибә иде, ләкин ул үзе бу куанычның нәрсәдән икәнен белмәде. Күпмедер баргач, ул туктады. Артта, колак шәйләр-шәйләмәс кенә булып, чыбык-чабык сынган, аннары ашыгып атлаган аяк тавышлары һәм ефәк күлмәк итәге шыштырдавы ишетелгәндәй булды. Ниһаять, карачкыл кәүсәле озын, юан агачлар арасында, өрәк сыман агарып, ак күлмәкле, зифа, җиңел гәүдәле берәүнең тиз-тиз якынлашып килгәне күзгә чалынды. Бу — Шурочка иде. Ромашов шундук аңа каршы

китте һәм, очрашкач, аны дәшми-нитми кочаклап алды. Шурочканың ашыгудан тәмам тыны кысылган, кайнар сулышы Ромашовның бит, иреннәренә бөркелә, ә йөрәгенең дөп-дөп тибүе егетнең кочаклаган кулы аша сизелеп тора иде.

— Утырыйк шунда, — диде Шурочка.

Ул чирәм өстенә утырды да, кулларын баш артына күтәреп, чәчен төзәткәли башлады. Ромашов исә аның аяклары очына сузылып ятты. Яткан җире сөзәгрәк урынга туры килгәнлектән, Ромашовка астан караганда Шурочканың нәфис муены белән ияк силуэты гына төсмерләнеп күренә иде.

Кинәт Шурочка калтыраулы, әкрен тавыш белән сорап куйды:

— Ромочка, рәхәтме сезгә?

— Рәхәт, — дип, тиз генә җавап бирде Ромашов. Аннары бер-ике секунд уйланып торгач, бүген кичергән барлык уй-хисләрен исенә төшереп, ашкынулы төстә тагы кабатлады: — О, бик рәхәт, чиксез рәхәт миңа! Әйтегез әле, нигә сез бүген шундый?

— Нинди?

Шурочка, аңа таба иелә төшеп, егетнең күзләренә төбәлеп карады, — Ромашовка шундук хатынның бөтен йөзе ачык күренде.

— Ниндиме? Сез бүген гажәеп, искиткеч матур. Сезнең әле беркайчан да болай гүзәл булганыгыз юк иде. Сездә бүген бөтен нәрсә җырлап, балкып тора. Сездә ниндидер серле яңалык бар, мин аны ни дияргә дә белмим... Тик... сез миңа ачуланмагыз, Александра Петровна... сезне анда югалтулары бар... курыкмыйсызмы?

Шурочка авыз эченнән генә кеткелдәп көлеп куйды, һәм аның иркәләүчән, ягымлы бу көлүе Ромашовның күкрәге эчендә ашкынулы, куанычлы бер кайтаваз булып яңгырады.

— Ромочка, җаныем! Сөеклем, ягымлы, куркак, оялчан Ромочкам минем! Әйттем ич инде мин сезгә: бүген — безнең көн. Берни турында да уйламагыз, Ромочка. Белә-сезме, нигә мин бүген шундый кыю? Белмисезме? Юк? Бүген мин сезгә гашыйк. Юк, юк, сез артык масаймагыз, иртәгә үк бу гыйшык сүреләчәк...

Ромашов, аның тәнен эзләп, кулы белән үрелде.

— Александра Петровна... Шурочка!.. Саша! — дип пышылдады ул ялварулы тавыш белән.

— Миңа Шурочка дип дәшмәгез, алай дәшүегезне теләмим. Башка теләсә нинди исем белән атагыз, тик Шу-

рочка гына димәгез... Исем дигәннән, — дип, кинәт исенә төшергәндәй, сүзен дәвам итте ул: — Георгий — менә бу шәп исем ичмасам. Юрий дигәннән мең мәртәбә шәбрәк исем... Гео-р-гий! — дип сузды аннары, һәр авазны хәтеренә сеңдереп калдырырга теләгәндәй. — Бу — горур яңгырый!

— Сөеклем! — диде Ромашов, дәрте ташып.

— Сабыр итегез... Йә, тыңлап бетерегез инде. Монысы иң мөһиме. Бүген мин сезне төшемдә күрдем. Искиткеч әйбәт төш иде ул. Имеш, ниндидер сәер бер бүлмәдә без икәү вальс биеп йөрибез. О, бу бүлмә бөтен вак-төяк җиһазларына хәтле минем күз алдымда тора. Анда бар нәрсә кызылдан иде — ике тәрәзәсенә кызыл пәрдәләр эленгән, өр-яңа кызыл пианино, кызыл фонарь, бик күп келәм-паласлар... Кайдадыр музыка уйный, ә кайда — анысы күренми. Без исә шунда биеп йөрибез, имеш... Безнең арада шундый татлы, шундый хиссиятле якынлык ки, андый якынлык фәкать төштә генә булырга мөмкин. Бик кызу вальс әйләнәбез, безнең аяклар идәнгә тимичә, ничектер һавада йөзеп йөриләр кебек. Аһ, шулкадәр озак биедек без, шулкадәр татлы, рәхәт булды бу бию — моны сүз белән аңлатырга мөмкин дә түгел... Карагыз әле, Ромочка, сез төштә очып йөрисезме?

Ромашов берьюлы гына жавап бирә алмады. Бу минутта ул үзен гүя ниндидер сәер, кызыктыргыч, бер үк вакытта жанлы, тылсымлы әкият дөньясында итеп күрде. Хәер, язгы төннең бу жылы һәм сихри караңгылыгы, тирәякта сабыр бер игътибар белән тынып калган бу агачлар, якында, янәшәдә генә, ак күлмәктән утырган бу сәер, күңелгә якын хатын — болар һәммәсе, чынлап та, әкияткә бик охшаган иде. Һәм, шушы тылсымлы әкият тәэсиреннән айну өчен, аңа күпмедер вакыт ихтыяр көчен тупларга кирәк булды.

— Әлбәттә, очам, — диде ул, нияәять. — Тик очу биеклегем генә елдан-ел түбәнәя бара. Элек, бала чакта, мин түшәмгә тияр-тимәс биеклектә оча торган идем. Шул биеклектән кешеләрне күзәтсәң, шундый көлке тоела: ничек алар шулай баштүбән йөриләр икән, дисең. Алар мине идән щеткасы белән бәреп төшерергә телиләр, ләкин булдыралмыйлар иде. Ә мин туктаусыз очам да очам һәм тегеләрне мыскыллап көләм. Мондый очулар юк инде хәзер, төшемдә мин хәзер сикерәм генә, — дип, көрсенеп өстәп куйды Ромашов. — Аякларым белән талпынам да, ераккa-ераккa очып барып төшәм. Бер егерме адым ерак-

лыкка. Очу биеклеге исә җирдән бер аршин чамасы — шуннан һич тә артык булмый.

Шурочка бөтенләй аякларын сузып ятты да, терсәкләре белән җиргә таянып, башын учына куйды. Аннары, бер мәл дәшми торганнан соң, уйчан төстә сүзен дәвам итте:

— Менә шул төшне күргәннән соң, иртән, минем сезнең белән очрашасым килде. Төмам үлеп күрәсем килде сезне. Әгәр килмәгән булсагыз, мин, белмим, нишләгән булыр идем икән. Шәт, үзем сезнең янга йөгереп барган булыр идем. Шуңа күрә дә мин сезнең сәгать дүрттән дә иртә килүегезне теләмәдем. Үзем өчен курыктым. Кадерлем, аңлыйсызмы, мин нәрсә әйтергә телим?

Шурочканың берсе икенчесе өстенә чалыштырып куйган аяклары Ромашовның йөзеннән бер ярты аршин чамасы ераклыкта гына ята иде. Ниндидер ярым түгәрәк ак бизәкләр төшерелгән кара оек һәм тәбәнәк үкчәле туфлиләр кигән ике бәләкәй генә аяк. Ромашов, колаклары шаулаган бер хәлдә, зиһене чуалып, кинәт шушы тыгыз, җанлы һәм оек аша салкын тоелган тәнгә иреннәре белән сыенды.

— Ромочка... Кирәкми, — диде Шурочка, иренеп кенә әйткәндәй, ниндидер зәгыйфь, сузынкы тавыш белән.

Ромашов башын калкытты. Һәм бу мизгелдә әйләнә-тирәдәге бар нәрсә аңа яңадан могҗизаи, тылсымлы бер әкият булып күренде. Әнә калкулык итәгеннән сизелер-сизелмәс кенә биегәя барган урман аралыгы; җиргә түшәлгән үлән ничектер серле булып, караеп күренә; шундый ук кара кәүсәле сирәк агачлар, тавыш-өнсез калып, йокы аралаш, бик игътибар белән нәрсәгәдер колак салып тынлап торалар шикелле. Ә сөзәклек башында, иң өстә, ерактагы агачларның куе ябалдашлары һәм кара кәүсәләре арасыннан, офыкның тигез һәм биек сызыгы буйлап, тар гына тасма булып, таң шәүләсе сызылып килә. Бу шәүлә алсу төстә дә, кызыл төстә дә түгел, ә ниндидер гадәтидән гайре куе-кызыл төстә — сүнеп барган күмер яки кызыл шәраб тулы шешә аркылы күренгән ут ялкыны төсенә охшаш карасу-кызгылт төстә. Һәм менә шушы сихри табигать эчендә, калкулык итәгендәге карачкыл агачлар арасында, шушы хуш исле карасу үлән өстендә, ял итәргә яткан урман алиһәсе сыман, ап-ак киемле, аңлаешсыз, гүзәл бер хатын ята.

Ромашов аңа таба тагы да якынрак күчеп ятты. Шурочканың йөзеннән гүя ниндидер тонык бер нур сирпелә иде. Күзләре ачык күренми — алар урынында ике эур кара

тап кына чокыраеп күренә, әмма Ромашов бу күзләрнең үзенә төбәлгәнен күңеле белән бик яхшы сизә иде.

— Чын әкият бу! — дип, бер сулыштан, пышылдап кына әйтеп куйды ул.

— Әйе, кадерлем, бу — әкият...

Ромашов хатынның күлмәк итәген үбә башлады; кулын эзләп табып, бите белән аның җылы, хуш исле, бәләкәй учына сыенды. Шул ук вакытта, сулышына буылып, өзек-өзек тавыш белән:

— Саша... Мин сезне яратам... Үлеп яратам... — дип сөйләнде.

Хәзер, югарырак күчеп яткач, ул Шурочканың күзләрен аермачык күрде. Алар зурлар һәм чем-каралар иде; вакыт-вакыт алар кысыла төшәләр, аннары тагы киңәеп ачылалар, һәм мондый чакта хатынның таныш та, таныш та түгел йөз сызыклары карангыда әллә нинди сәер төсләргә кереп үзгәрә иде. Ромашов кипшергән, комсыз-кайнар иреннәре белән аның авызын кармалап эзләде, ләкин Шурочка һәр юлы йөзен читкә бора, әкрен генә башын чайкый һәм ишетелер-ишетелмәс тавыш белән пышылдап:

— Юк, юк, юк... Кирәкми, кадерлем... — дип кабатлый иде.

— Бәгырем... Нинди бәхет!.. Мин сине яратам... — дип өзгәләнде Ромашов, саташулы нинди дер рәхәт бер куаныч-тан исереп. — Мин сине сөям. Әнә кара: төн, тынлык, без шунда икәүдән-икәү. Бәхетем минем, мин сине үлеп сөям!

Ләкин Шурочка, бөтен гәүдәсе белән җиргә сыланып яткан көе, көрсенеп, һаман: «Юк, юк», — дип пышылдый бирде. Ниһаять ул чак кына ишетелерлек, авырсынган бер тавыш белән сүз башлады:

— Ромочка... нигә сез шундый... йомшак-көчсез кеше! Яшерергә теләмим, минем күңелем сезгә тартыла, сез мина бөтен сыйфатларыгыз белән — оялчанлыгыгыз белән дә, саф, назлы йөрәгегез белән дә сөйкемле. Мин сезне яратам дип үк әйтә алмыйм, ләкин мин сезнең турыда туктаусыз уйланам, сезне төшләремдә күрәм, мин сезне... йөрәгем белән тоям. Сезнең минем янда булуыгыз, тәнемә орынып-орынып алуларыгыз мине һәрвакыт дулкынландыра. Ләкин сез — кызганыч кеше! Кызгануны нәфрәтнең туганы диләр. Үзегез уйлап карагыз: мин сезне һичкайчан ихтирам итә алмаячакмын. О, әгәр дә сез көчле кеше булсагыз иде! — Александра Петровна, Ромашовның башынан фуражкасын салдырып, бармаклары белән аның йомшак чәчләрен әкрен генә аралап сыйпарга кереште. —

Әгәр дә сез үзегезне таныта, зур дәрәҗәгә ирешә алсагыз иде!..

— Мин барысын эшләрмен, дәрәҗәсенә дә ирешермен! — дип тәэсирләнеп кычкырды Ромашов. — Тик сез минеке генә булыгыз. Миңа күчеп килегез. Мин гомерем буе...

Шурочка назлы, хәсрәтле бер аһәң сизелеп торган тавыш белән аның сүзен бүлде:

— Шундый теләктә икәнегезгә дә ышанам, җаным, бик ышанам, тик сез моны эшли алмаячаксыз бит. Әйе, әйе: эшли алмаячаксыз. О, сезгә аз гына ышанычым булса иде шул, ул чакта мин барысын ташлап, берсүзсез сезнең арттан китәр идем. Ah, Ромочка, җаныем, тәтием минем. Шундый бер рнваять ишеткәнем бар: имеш, аллаһе тәгалә адәмнәрне башта бер бөтен итеп яраткан да, аннары, ни өчендер, һәркайсын ике өлешкә бүлеп, дөнья буенча сипкән. Менә шул ярым адәмнәр гасырлар буе үзләренең икенче яртыларын эзлиләр, имеш, — тик берничек тә таба алмыйлар икән. Ромочка, җаныем, без дә бит бөтеннең шул ике яртысы кебек кешеләр; бездә барысы да уртак: ярату да, яратмау да; фикерләребез, төш күрүләребез, теләкләребез — һәммәсе бер төрле безнең. Без бер-беребезне ярым кинаядән, ярты сүздән дә аңлыйбыз, хәтта сүзсез дә, күңел күзе белән тоеп кына да аңлыйбыз. Шуңа карамастан, мин менә сиңең мәхәббәттән баш тартырга мәҗбүрмен. Ah, бу минем гомеремдә икенче мәртәбә инде.

— Әйе, беләм.

— Ул сиңа әйттемени? — дип, тиз генә сорап куйды Шурочка.

— Юк, мин моны очраклы рәвештә ишеттем. Мин беләм.

Алар тынып калдылар. Күктә, яшькелт нокталардай җемелдәп, беренче йолдызлар кабынды. Уң тарафтан, алан ягыннан, тонык кына булып, үзара сөйләшкән, көлешкән тавышлар һәм кемнеңдер җырлаганы ишетелә, урманның күгелҗем, йомшак караңгылык белән өртелгән бүтән почмакларында исә үзенә бер төрле уйчан, илаһи тынлык хөкем сөрә. Моннан караганда, учак үзе күренми, әмма ара-тирә якындагы имән агачлары өстеннән күз ачып йомган арада ажаган сыман кызыл шәүлә йөгереп уза иде. Шурочка әкрен генә Ромашовны башыннан һәм битеннән сыйпый бирде; кулы егетнең иреннәренә юлыкканда, ул, сыйпаудан туктап, учын аның авызы өстендә кысып тота иде.

— Мин үз иремне яратмыйм, — дип, үзалдына уйлан-

гандай, әкрен генә сөйли бирде ул. — Артык дорфа кеше ул, аңарда сизгерлек, нәзакәт дигән нәрсә юк. Ах,— әйтергә дә оят, — без, хатын-кызлар, беренче дорфалыкны беркайчан да онытмыйбыз бит. Аның соңында, ифрат көнче кеше ул. Әлеге бичара Назанский белән битәрләп, шушы көнгә хәтле минем йөрәк итемне ашый ул. Бөтен вагынатөягенәчә төпченә, әллә нинди коточкыч нәрсәләр юрап азаплый, фу... Оятсыз сораулар белән тыкшына. Әй аллам! Ярым балаларча, гөнаһсыз бер мәхәббәт кенә иде бит югыйсә! Ләкин ул Назанскийның исемен ишетсә дә тәмам котырына башлый.

Сөйләгәндә Шурочканың тавышы һәм баштан сыйпаган кулы калтырап-калтырап куя иде.

— Син туңмыйсыңмы?— дип сорады Ромашов.

— Юк, Ромочка, миңа рәхәт, — дип, сабыр гына җавап бирде Шурочка.

Һәм кинәт көтелмәгән, ашкынулы бер дәрт белән өстәп әйтте:

— Аһ, белсәң иде, шулкадәр рәхәт миңа синең янда, сөеклем!

Ромашов, аның кулын учына алып һәм нечкә бармакларын аралый-аралый әкрен генә сөеп, юаш, кыюсыз тавыш белән сүз башлады:

— Аңлатчы миңа... Үтенәм. Үзең үк әйтәсең, аны яратмыйм, дисең... Алайса нигә бергә соң сез?..

Шул чак Шурочка, кисәк кенә кузгалып, үләнгә торып утырды да, йокыдан уянган кешедәй, нервлы бер хәрәкәт белән кулларын югары күтәрде һәм маңгаен, яңакларын ышкып алды.

— Вакыт соңдыр инде. Кайтыйк. Эзлп башламагайлары тагын, — диде ул, баягыдан үзгә һәм бөтенләй тыныч тавыш белән.

Алар, үләп өстеннән торып, бер-берсенең сулышларын тойган хәлдә һәм бер-берсенә күзләрен төбәшеп, ләкин аларны күрмичә, сүзсез генә басып тордылар.

— Хуш! — диде кинәт Шурочка яңгыравык тавыш белән. — Мәңгегә хуш, шатлыгым, кыска вакытлы бәхетем минем!

Ул, Ромашовны муеныннан кочаклап, кайнар, дымлы иреннәрен аның иреннәренә тидерде дә, дәрт ялкыны эчендә ихтыярсыз ыңгырашып, аякларыннан алып күкрәкләренә кадәр бөтен тәне белән егет гәүдәсенә сарылды. Ромашов өчен вакыт гүя туктап калды, имән агачларының карачкыл күләгәләре берьюлы бер якка чайкалып, җир өсте, әйтерсең, икенче якка шуышып китте.

Аннары Александра Петровна көч-хәл белән егет кочагыннан ычкынып, катгый төстә:

— Хуш. Җитте. Инде кайтыйк, — диде.

Ромашов аның аягы астына егылды, тәмам ятты дияр-лек һәм хатынны тезләреннән кочаклады да озаклап-озаклап, шашынып-шашынып үбәргә тотынды.

— Саша, Сашенька! — дип үрсәләнде ул үз-үзен белештермичә. — Ник син минеке булырга теләмисең? Ни өчен? Бул минеке!..

— Киттек, кайтыйк, — дип ашыктырды аны Шурочка. — Бу ни эшегез, Георгий Алексеевич, эннәр торыгыз. Безне эзләүләре мөмкин. Кайтыйк!

Алар сөйләшү тавышлары ишетелгән якка таба атлап киттеләр. Ромашовның аяк буыннары калтырый, сыгылып-сыгылып китә һәм чигә тамырлары дөп-дөп суга иде. Ул исергән кешедәй чайкалып барды. Шурочка үзе дә тыныч-ланып җитмәгән иде әле.

— Мин алдашуны яратмыйм, — дип ашыгып сөйләнде ул. — Хәер, юк, алай түгел, мин алдашудан өстен торам, ләкин мин куркаклыкны яратмыйм. Алдашу төбендә исә һәрвакыт куркаклык ята. Мин сиңа дөресен әйтәм: иремә мин беркайчан да хыянәт итмәдем һәм, берәр сәбәп аркасында аерылышырга туры килмәсә, аңа хыянәт итмәячәкмен дә. Әмма аның наз, үбүләре мине җирәндерә, күңелемне болгата. Тыңла, мин сиңа нәрсә әйтәм: мин тик менә хәзер генә яраткан кешеңә бирелүнең нинди ләззәтле, нинди татлы булуын аңладым. Хәер, хәзер генә түгел икән, элек тә — синең хакта, синең иреннәреңнең хакында хыялланып уйланган чакларымда да миңа бу шулай ләззәтле тоела торган иде. Ләкин куркаклыкны, караклыкны женем сөймәс минем. Аның соңында... туктале, иелә төш, мин синең колагыңа гына әйтим, юкса моны кычкырып әйтергә дә оят... аның соңында — мин бала булдырырга теләмим. Фу, нинди җүләрлек! Обер-офицер хатыны, кырык сигез сум жалунья, алты-җиде бала, чүпрәк-чапрак, бетмәс фәкыйрьлек... У-у, коточкыч бит бу!

Ромашов аптырау катыш гаҗәпләнү белән аңа борылып карады.

— Ләкин бит сез ир хатыны... Бала котылгысыз лабаса, — диде ул, икеләнеп.

Шурочка шаркылдап көлеп җибәрде. Бу көлүдә күңел кайтаргыч ниндидер чит-ят нәрсә сизелә иде, Ромашовның җанына шундук салкын йөгерде.

— Ромочка... ай-ай, үләм, нинди җү-ләр әле сез! — дип, Ромашовка электән үк таныш нечкә, балаларча чә-

релдек тавыш белән сузып әйтте Шурочка. — Бу хикмәтләрне сез әллә чынлап та белмисезме? Юк, дөресен әйтегез — чынлап та белмисезме?

Ромашов аптыраулы чырай белән иңбашын җыерды. Үзенең беркатлылыгы өчен ничектер уңайсыз булып китте аңа.

— Гафу итегез... икърар итәргә мәҗбүрмен... чынлап менә...

— Ну, ярар, әйдә, шулай булсын, белмәвегез хәерле. Нинди ихлас күңелле, саф кеше сез, Ромочка! Алайса, менә шул, үсеп җиткәч, минем бу сүзләремне, бәлки, исегезгә төшерерсез: ир белән ике арада булган нәрсә сөйгән кешең белән ике арада һич тә булырга мөмкин түгел. Ах, бу турыда, зинһар, баш ватмагыз. Җирәнгеч нәрсә ул, ләкин нишләмәк кирәк.

Алар пикник булган урынга якынлашып киләләр иде инде. Әнә агачлар артында учакның ялкын телләре дә ялтырап куйды. Учак яктысында имәннәрнең кәкре кәүсәләре, кара металлдан коелган сыман, караеп күренәләр, ә аларның ян якларын үзгәрүчән кызгылт кайма ураган иде.

— Ярар, әгәр, әйтик, мин үз-үземне кулга алалсам ничек? — дип сорады Ромашов. — Әйтик, мин сезнең иregез теләгән дәрәҗәгә яки аннан да югарырак дәрәҗәгә ирешсәм? Ул чакта ничек?

Александра Петровна яңагы белән бөтен көченә Ромашовның иңбашына сыенып, ашкынулы төстә җавап бирде:

— Ул чакта — мин риза. Әйе, риза, риза...

Ниһаять, алар алан читенә чыктылар. Учак һәм аның тирәсендәге кешеләрнең кара күләгәләре инде аермачык күренә иде.

— Ромочка, монысы соңгы сүзем,— диде Александра Петровна, ашыгып. Аның тавышында хәсрәт һәм борчылу галәмәте сизелә иде. — Бүгенге кичәгезне бозмас өчен мин сезгә әйтми тордым. Тыңлагыз: сез безгә бүтән килеп йөрмәскә тиешсез.

Ромашов, гажәпләнүдән тәмам аптырап, шып туктады.

— Нигә алай дисез? Ой, Саша!

— Әйдәгез, әйдәгез... Кем икәнен белмим, тик кемдер иремне имзасыз хатлар язып алҗыта. Ирем ул хатларны миңа күрсәтмәде күрсәтүен, ләкин сүз арасында алар хакында әйткәләгәне бар. Сезнең белән миңа бәйләп нинди-дидер пычрак гайбәт, урам гайбәте турында язалар булса кирәк. Кыскасы, үтенеп сорыйм: безгә бүтән килеп йөрмәгез.

— Саша! — дип, кулларын Шурочкага таба сузып, тирән ачыну белән ыңгырашып куйды Ромашов.

— Аһ, моңардан минем үземә җиңел дисезмени, кадерлем, сөеклем, жанкисәгем минем! Ләкин бу шулай кирәк. Кыскасы, эш болай тора: ирем бу хакта сезнең белән үзе сүз башламагае дип куркам. Зинһар, алла хакы өчен, сак кыланыгыз, яме. Сак булырга сүз бирегез миңа.

— Яхшы,— диде Ромашов, хәсрәт белән.

— Ну, алайса сүзем битте. Сау булыгыз, бичаракаем. Мескенкәем! Кулыгызны бирегез. Авырттырганчы кулымны кысыгыз. Менә шулай... Ой!.. Инде хушыгыз. Хуш, минем назлы куанычым!

Учакка җитәр-җитмәс алар аерылыштылар. Шурочка — калкулык өстеннән турыга, ә Ромашов инеш буйлатып, астан, эйләнечтән китте. Карта уены әле бетмәгән иде, шулай да, Ромашовларның югалып торуларын һәммәсе дә сизгән иде булса кирәк. Һәрхәлдә, Диц учак янына килеп туктаган Ромашовка үтә мыскыллы күз карашы ташлап, шундый гайре табигый һәм ямьсез бер төстә тамак кырып куйды ки, Ромашовның хәтта учактан утлы кисәү алып, шуның белән Дицның башына тондырасы килеп китте.

Аннары ул Николаевның, хәтта уйнаган җиреннән аерылып, Шурочканы бер читкә чакырып алуын һәм нәфрәтле чырай белән, кулларын усал селкә-селкә, ана бик озак нидер исбатлап маташуын күреп торды. Кинәт Шурочка тураеп басты да, йөзенә язып аңлаткысыз җирәнү һәм нәфрәт галәмәте чыгарып, Николаевка ниндидер өч-дүрт сүз әйтте. Һәм бөтен кыяфәтендә көч-гайрәт ташып торган, таза, зур гәүдәле Николаев, берьюлы шиңеп, күндәм рәвештә һәм бер үк вакытта ачуын эченә яшергән ерткыч хайван сурәтен саклаган хәлдә, Шурочка яныннан ашыгып читкә китеп барды.

Озакламый пикник бетү ягына авышты. Төн салкынайды, инеш тарафыннан дымлы җил исә башлады. Күңел көрлеге инде күптән сүрелгән иде; арыган, кәефләре төшкән кешеләр, ризасызлыкларын яшереп тә тормыйча, авызларын зур ачып иснәнә-иснәнә, экипажларга утырыштылар. Ромашов, баягыча, тагы апалы-сеңелле Михина туташлар каршысына утырды һәм юл буе бер авыз сүз дәшми кайтты. Аның хәтер түрендә әле һаман карачкыл кәүсәле тын агачлар, кара калкулык, калкулык өстеннән сызылып килгән кан сыман таң шәүләсе, хуш исле карасу үлән арасында яткан ап-ак киемле гүзәл хатын күзалланды. Шулай да ул вакыт-вакыт күңелен биләп алган эчкерсез, тирән,

үкенечле-газаплы сагыш аша, патетик бер һавалану белән, үзе турында: «Аның матур йөзен кайгы болытлары каплады»,— дип, гадәттәгечә уйлап ала иде.

XV

Полкның шәһәрдән ике чакрым читтә, тимер юл полотносы артында, елдан-ел җәйге өйрәнүләргә чыгып йөри торган даими лагере бар иде. Бу елны да беренче майда полк шунда күченде. Лагерь чорында кече офицерлар, үз роталары белән янәшә агач баракларда яшәргә тиеш булсалар да, алтынчы ротага караган офицерлар торагының, коточкыч искереп, яшәр өчен тәмам куркыныч хәлгә килүе һәм аны ремонтларга полкның кирәк кадәр акчасы булмавы сәбәпле, Ромашов ихтыярлы-ихтыярсыз үзенең шәһәр фатирында яшәп калырга мәҗбүр булды. Бу исә өстәмә мәшәкатьләр китереп чыгарды. Аңа көн саен ике мәртәбә лагерьга барып-кайтып йөрергә туры килде: иртә белән иртәнге өйрәнүләргә бара, аннары төш вакытында шәһәргә кайтып, җәмгыятьтә тамак ялгап алгач, кичке өйрәнүләргә дип тагы лагерьга чыгып китә һәм өенә яңадан төнлә генә кайтып керә. Бу юл йөрүләр бик ардыра һәм кәефне кыра иде. Шушы лагерь чорының беренче ярты аенда гына да Ромашов тәмам ябыкты, кара көйде, күзләре эчкә батып керде.

Хәер, бер аңа гына түгел, башка офицер һәм солдатларга да кыен иде. Һәр кеше май смотрына әзерләнә, беркемгә бернинди ял да юк, кызгану да юк. Командирлар үз роталарын плацта икешәр-өчәр сәгать артыграк тоталар, солдатны тәмам җәфалап бетерәләр. Өйрәнүләр вакытында кайсы гына ротаны, взводны алма, һәркайда, һәр тарафта чалт-чолт яңак сугулар яңгырап тора. Ромашовның хәтта еш кына шундый тамашага да тап булганы бар: рота командирларыннан берәрсе, аеруча ярсып китеп, үз солдатларын сул флангтан уң флангка кадәр һәммәсен бер-бер артлы яңаклап чыга. Ерактан карап торасың: башта һавада тавышсыз гына селтәнгән кул күренә, аннары, бер секундтан, «чалт» итеп суккан кыска-коры аваз яңгырап ишетелә. Шулай бер-бер артлы чалт та чолт, чалт та чолт... Ифрат җирәнгеч һәм дәһшәтле тамаша иде бу...

Унтер-офицерлар тел гыйльмендә чак гына дөрес җавап бирмәгәне яисә сафта йөргәндә адымын ялгыштырганы өчен дә солдатны канга батырганчы кыйныйлар: авызына сугып, аның тешләрен коялар, яңагына сугып колак ярыларын шартлаталар яки бөтенләй аяктан ук бәреп егалар.

Шул ук вакытта беркемнең беркемгә зарланырга башына килми: барча кеше, гипнозлагандай, шушы дәһшәтле, шомлы гадәлсезлек шаукымына буйсынып яши. Моның өстенә, коточкыч эссе: быелгы май ае нигәдер бик кызу килгән иде.

Кешеләрнең күңел кыллары чиктән тыш тартылып, өзелер дәрәҗәгә җитте. Офицерлар җәмгыятендәге көндезге яки кичке аш вакытларында мәгънәсез бәхәсләр, сәбәпсез рәнҗү, ачуланышулар ешайганнан-ешая барды. Солдатларның битләре тәмам суырылып, чырайларына мәнсезлек күләгәсе ятты. Сирәк кенә булган ял минутларында палаткалар эченнән бернинди мәзәк, көлү тавышы да ишетелми иде. Шулай да кичке барлау-тикшерү узганнан соң, солдатларны бер җиргә җыйнап күңел ачарга мәҗбүр итәләр иде. Һәм алар, түгәрәккә басып, гамьсез-битараф чырай белән, мөгри-мөгри, әйтик, шушындый җыр сузып җибәрәләр:

Для расейского солдата
Пули, бонбы ничего,
С ними он запанибрата,
Все безделки для него.[1]

Аннан гармунда бию көе уйныйлар, фельдфебель команда бирә:

— Грегораш, Скворцов, уртага чык! Биегез, адәм актыклары!.. Күңел ачыгыз! — ди.

Солдатлар бииләр, ләкин бу биюдә, җырдагы кебек үк, ниндидер үлеп каткан, җансыз бер нәрсә бар — кыскасы, бу биюне карагач, шундук җылыйсылар килеп китә иде.

Полкта фәкать бишенче рота кешеләре генә ничектер җиңел һәм иркен яши иде. Бу рота плацка башкалардан бер сәгатькә соң чыга, э занятиеләрне алардан бер сәгатькә иртәрәк бетерә. Андагы солдатлар, махсус сайлап алынгандай, һәммәсе өлгер хәрәкәтле, тук чырайлы; теләсә нинди башлыклар белән дә акыллы һәм күзгә кыю карап сөйләшәләр; башка роталар белән чагыштырганда, аларның хәтта өсләренә кигән мундирлары, күлмәкләре дә ничектер гәүдәләренә ятып, килешеп тора шикелле. Бу ротаның командиры Стельковский дигән сәер генә бер буйдак капитан иде. Полкта ул шактый бай офицерлардан санала (аның ай саен каяндыр даими килеп торган ике йөз сум

---

[1] Рәсәй солдатының пуля,
Бомбаларга исе дә китми;
Алар белән ул агай-энечә кылана,
Аның өчен — барысы да чүп.

чамасы кереме бар иде); үзе ифрат мөстәкыйль характерлы, сөйләшүе коры-рәсми, хезмәттәшләре белән аралашмый, алардан ераграк булырга тырыша, өстәвенә — бик тә азгын кеше. Гадәттә, ул үзенә асрау итеп гади халык арасыннан чыккан һәм күп очракта балигъльк яшенә дә җитмәгән үсмер кызларны яллый; яллый да, бер ай үтүгә, аларны, үзенчә бик мул рәвештә бүләкләп, акчалар биреп, кире өйләренә кайтарып җибәрә, һәм бу хәл гаҗәеп бер төгәллек белән еллар буе әнә шулай кабатлана килә иде. Стельковский ротасында, солдат белән әллә ни кәнфитләнмәсәләр дә, кыйнау дигән нәрсә бөтенләй юк, хәтта анда сүгенү сүзе дә ишетмисең, әмма шул ук вакытта бу рота үзенең тышкы пөхтәлеге һәм хәрби өйрәнүләрдәге осталыгы белән теләсә нинди гвардия частена тиң торырлык иде. Стельковский үз дигәнен гаҗәеп сабыр, салкын канлы һәм максатчыл бер үҗәтлек белән башкара һәм бу сыйфатларын үзенең унтер-офицерларына да йоктыра белә иде. Башка роталарда җәза бирү, кыйнау, акыру-бакыру һәм төрлечә ыгы-зыгы белән атна буена ирешкәнне ул үз ротасында бер көн эчендә эшләп ташлый иде. Шул ук вакытта ул беркайчан күп сүз сөйләмәс, тавышын күтәрмәс, әмма инде сөйли башласа, һәммә кеше аның каршысында тораташтай катып кала иде. Офицерлар аны чит күрәләр, солдатлар исә үлеп яраталар: бу соңгысы, бәлки, бөтен рус армиясе өчен бердәнбер мактаулы мисал булгандыр.

Нинаять, унбишенче май көне килеп җитте. Бу көнне корпус командиры боерыгы буенча смотр узарга тиеш булып, унтер-офицерлар бешенче ротадан кала бар полкны иртәнге сәгать дүрттә үк аякка бастырдылар. Көн шактый җылы булуга карамастан, йокылары туймаган һәм өсләренә бер кат күлмәк кенә кигән солдатлар дер-дер калтырыйлар, аларның сулган йөзләре аяз иртәнең нурлы яктысында тоныкъ ялтырап, аеруча соры, кызганыч булып күренә иде.

Сәгать алтыда роталары янына офицерлар җыелды. Полкның гомуми җыелу вакыты әле сәгать унга гына билгеләнгән булса да, солдатларны смотр алдыннан туйганчы йоклату, аз гына ял иттереп алу уе, кызганычка каршы, Стельковскийдан кала бер генә рота командирының да башына кереп карамады. Киресенчә, бу иртәне солдатның болай да миңгерәүләнгән башын тел гыйльме һәм ату кагыйдәләре белән тагы да үҗәтләнебрк тинтерәтергә тырыштылар; һавада сүгенү авазлары тагы да күбрәк яңгырады, яңак төпкә менеп төшүләр гадәттәгедән күп өлеш артып китте.

Сәгать тугызда роталарны лагерьдан бер биш йөз адым читтә урнашкан мәйданга алып киттеләр. Анда инде, ярты чакрымлык арага тигез-туры сызык буенча бер-бер артлы тезелеп, мылтык көпшәләренә төрле төстәге кечкенә флаглар таккан уналты желонер басып тора иде. Аларга башлык тиешле офицер, поручик Ковако, бүгенге көннең иң төп геройларыннан берсе, әлеге фараз ителгән сызыкны мөмкин кадәр тигезрәк итәргә тырышып, акырына-бакырына, мәйданның бер башыннан икенче башына ат өстенә чаптырып йөри. Ул тәмам тиргә баткан, кызарынып-бүртенеп чыккан, бүреге башы артына шуып төшкән. Чаптырып барган уңайга аның кылыч кынысы картаюдан сырт, корсак тиреләрен кутыр, тимгел каплаган, уң күзенә ак төшкән ябык атының чыгынкы кабыргаларына дың-дың бәрелә, ә ат, кыска койрыгын гажизанә болгап, арт санын килбәтсез рәвештә сикерткән саен мылтыктан аткандай кискен-өзек бер тавыш белән көчәнеп-көчәнеп куя иде. Бүген поручик Ковакога күп нәрсә бәйле: аның желонерларына карап, полктагы уналты ротаның һәрберсе тартылган җептәй тигез, туры сызыкка тезелеп басарга тиеш иде.

Ун туларга нәкъ ун минут калгач, лагерьдан мәйданга таба бишенче рота якынлашып килгәне күренде. Берсе-берсеннән мәһабәтрәк, зифа-төз сынлы, житез хәрәкәтле, юынган-чистарынган йөз кеше, башларындагы бескозыркаларын уң як колакка таба чая бер төстә кырын салып һәм жирне селкетердәй нык, эре адымнар белән бердәм атлап, бөтен полкның сокланулы күз карашы астында мәйданга килеп керде. Гаять киң балаклы чалбар киеп куйган тәбәнәк буйлы, чандыр гәүдәле капитан Стельковский үзе, әллә ни исе китмәгән бер чырай белән, ротасының уң кул ягыннан — биш-алты адым читтән үз җаена атлап бара һәм вакыт-вакыт, күзләрен хәйләкәр жемелдәтеп һәм башын әле бер якка, әле икенче якка ташлап, сафның тигезлеген тикшерә иде. Башка офицерлар кебек үк, иртәдән бирле нервлы, ыгы-зыгылы бер ярсу эчендә булган подполковник Лех, батальон командиры, плацка соңарып чыгуы өчен капитан Стельковскийга ачуланып кычкырына башлаган иде дә, тегесе, ашыкмыйча, сабыр гына кесәсеннән сәгатен чыгарып, вакытны карады да кимсетүле диярдәй коры, кырыс тавыш белән:

— Приказда унга җыелырга диелгән. Хәзер исә ун туларга өч минут. Мин кешеләрне юкка тинтерәтеп торуның һич мәгънәсен күрмим,— диде.

Лех атын туктата төште һәм кулы белән һаваны ярып:

— Сөйләшмәскә-ә! — дип акырып җибәрде.— Ни... сезгә замечание ясыйлар икән, р-рәхим итеп, дәшми торыгыз!..

Ләкин ул үзенең хаклы түгеллеген аңлап алды булса кирәк: Стельковский янынnан тиз генә китте дә бөтен үченачуын сигезенче ротага яудырды. Анда офицерлар солдатларның кием-салымын тикшерү белән мәшгуль иде.

— Ни, ниткән тәртипсезлек бу! Нинди базар, ә? Ваклап сату кибетемени! Әллә ауга чыкканда эт ашатасызмы? Ни... элегрәк ни карадыгыз? Киенергә-ә! — дип җикеренде Лех.

Унберенче унбиш минутларда роталарны тигезләп тезә башладылар. Бу шактый озак вакыт сорый торган мәшәкатьле, интектергеч эш булып чыкты. Бер желонердан икенче желонерга кадәр, ике арага, казыклар кагып, озын бау тарттырдылар. Беренче шеренгадагы һәрбер солдат шушы сузылган бауга аяк очлары тияр-тимәс математик төгәллек белән тигезләнеп басарга тиеш — сафның көязлеге-матурлыгы әнә шуңа бәйле иде. Ләкин ул гына аз: ике аяк очы уртасында приклад түтәсе сыярлык ара калсын, аннан соң солдатларның гәүдә торышлары да бертөсле, бер авышлыкта булырга тиеш. Шуңа ирешү өчен, рота командирлары бертуктаусыз әле монда, әле тегендә: «Иванов, күкрәкне алгарак чыгар! Бурченко, уң җилкәңне кырга таба бора төш! Сул аяк очыңны арткарак күчер! Тагы бераз!..» — дип, солдатларга туктаусыз җикеренеп торалар иде.

Унберенче яртыда полк командиры полковник Шульгович килеп җитте. Ул сөлектәй сылу гәүдәле, дүрт аягы да тез тиңентен ак төстәге алмачуар атка атланган иде. Ияр өзәңгеләре кирәгеннән артык кыскартылып, утыруы артык пехотача булса да, аның кыяфәте шактый тәэсирле, мәһабәт күренә иде. Ул егетләрчә дәртле, шаян-шук тавыш белән кычкырып полкка сәлам бирде:

— Здорово, бөркетләр!..

Ромашов шундук үзенең дүртенче взводын, бигрәк тә малай сымак чандыр, зәгыйфь Хлебниковны күз алдына китереп бастырды һәм: «Әйтәсең бармы, харап инде синең ул бөркетләреңә!» — дип, иректән көлемсерәп куйды.

Полк оркестры уйнаган каршылау көенең яңгыравык авазлары астында мәйданга байраклар чыгарылды. Шуннан соң, дүрт күз белән, зарыгып-тилмереп, корпус командирын көтә башладылар. Ул килергә тиешле юл буена, вокзалга хәтле, сигналчылар куелып, алар командирның күренүен махсус флаглар болгап хәбәр итәргә тиешләр иде. Берничә мәртәбә ялган тревога да булып алды. Андый чакта әлеге бау тарттырылган казыкларны ашыга-ашыга

суырып чыгаралар, полк тиз генә «смирно»га баса, тигезләнә, шым була,— ләкин ике-өч минут шулай киеренке хәлдә көтеп торганнан соң, янәдән «вольно» командасы бирелә, кешеләр бераз ыркенәеп кала, шулай да аларга аякны баскан урыннан кузгатырга рөхсәт ителми иде. Каршыда, гаскәр сафыннан бер өч йөз адым алда, чәчәкле, чуар күлмәкләре, зонтик, эшләпәләре белән төрле төсләрдә елкылдап, хатын-кызлар төркеме басып тора. Болар — парад кararга килгән полк дамалары иде. Бәйрәмчә хозур, якты бу төркем эчендә Шурочканың юклыгын анык белсә дә, Ромашов ара-тирә анда да күз төшереп алгалый, һәм караган саен аның йөрәге ниндидер татлы бер хистән сулкылдап куя, ә күңеле төбеннән күтәрелгән сәбәпсез, сәер дулкын аны ихтыярлы-ихтыярсыз еш-еш суларга мәҗбүр итә иде.

Шул вакыт, кисәктән китереп бәргән җил кебек, сафлар буйлап: «Килә, килә!» дигән каударлы, кыска сүз йөгереп узды. Монысы инде ялган хәбәр түгел, аның җитдилеген һәммә кеше шундук бөтен йөрәге белән тоеп-аңлап алды. Иртәдән бирле нервлы киеренкелек эчендә тәмам миләре кайнаган, алҗыган солдатлар, командирларның боерыгын да көтмичә, үзләреннән-үзләре, кабалана-кабалана, борчылулы төстә йөткеренә-йөткеренә, төзәтенергә һәм тигезләнеп басарга керештеләр.

— Смирна! Желонерлар, үз урыннарыгызга!— дип команда бирде Шульгович.

Ромашов каш астыннан гына уң тарафка күз төшерде һәм шактый ераста, басу читендә, һавага соргылт сыек тузан болыты туздырып, ат менгән бер төркем кешенең, тоташ массадай, мәйданга таба тиз-тиз якынлашып килүен күрде. Полк каршысында, урта бер җирдә, аты өстендә кукыраеп утырган Шульгович, чыраена тагы да җитдирәк, тантаналырак төс биреп, артка чигенде — хәер, чигенде генә түгел, тиеш булганнан бер дүрт мәртәбә ераккарак китеп басты. Аннары, хәрби мәһабәтлекнең бөтен шартын китереп, көмештәй ак сакалын югары чөйде дә, каршысында хәрәкәтсез катып калган кара массага дәһшәт катыш чая күз карашын тегәп, әйләнә-тирәгә күкрәп таралган каты тавыш белән сузып кычкырды:

— По-олк, тыңла-а! На крррa-а-а...

Ул, сүзен әйтеп бетермичә, тукталып торды, гүя бу йөзләгән кешеләр өстеннән хакимлек итү ләззәтенең бөтен тәмен татып, шул мизгелне озаграк сузарга теләде, аннары кинәт, көчәнүдән тәмам бүртеп-кызарып һәм муен тамыр-

ларын катырып, күкрәгенең бар куәтенә, бүленгән сүзен тәмамлады:

— ул!..

Бер-ике! Куллар дәррәү мылтык каешына сузылды, бил каешы пеләжкәсенә бәрелеп, затворлар чыкылдады. Уң флангта каршылау маршының беренче чая, кискен-өзек авазлары яңгырады; шук балалар сыман, көлеп-шаярып, җитез флейта һәм кларнетлар йөгерешеп узды, галибанә тантана белән калын тавышлы җиз быргылар җырлап җибәрде, аларның мәһабәт авазына куәт биреп, даң-доң барабан дыңгылдады, ә салмак адымлы тромбоннар, барабан артыннан өлгерә алмыйча, иркәләнеп-назланып, куе-калын бәрхет тавышлары белән талгын гына ыңгырашып куйдылар. Станциядә исә, нәзек, саф тавышын уйнаклый-уйнаклый сузып, паровоз кычкыртты, һәм бу яңа йомшак аваз оркестрның тантаналы җиз моңнарына кушылып, үзенә бертөрле гүзәл, шатлыклы гармония тудырды. Ромашовны гүя ниндидер дәртле-ярсулы бер дулкын элəктереп алды да, рәхәт тибрәлдереп, җиңел генә югары күтәрде. Эсседән аксыллана төшкән зәңгәр күк йөзе, һавада рәшәдәй тирбәлгән алтынсу кояш нурлары һәм офык читендәге гүя әле генә күз алдында пәйда булгандай җәйрәп яткан тымызык, яшькелт ялан өсте — болар һәммәсе Ромашовка хозур бер төгәллек белән берьюлы ачылып күренделәр. Һәм ниндидер күзгә күренмәс серле ихтыяр көче белән бер-беренә аерылгысыз береккән шушы төзек, куәтле, хәрәкәтсез массага — кешеләр массасына үзенең дә турыдантуры катышы барлыгын уйлап, ул кинәт күңелендә чиксез горурлык хисе тойды һәм үзен яшь, гайрәтле, өлгер-оста бер кеше итеп күрде...

Шульгович, ялан кылычын бите турысында катырып тоткан килеш, генерал каршысына таба чаптырып китте.

Хәрби музыканың дәртле-тупас авазлары аша корпус командирының сабыр, йомры тавышы ишетелде:

— Здорово, беренче рота!

Солдатлар, бар жегәрләренә көчәнеп, беравыздан җавап кайтардылар. Һәм станциядә тагы паровоз кычкыртып куйды — бу юлы аның тавышы, шаярткандай, ничектер кыска-өзек һәм кискен булып ишетелде.

Генерал, һәр рота белән шулай чиратлап исәнләшә-исәнләшә, саф алдыннан әкрен генә юлын дәвам иттерде һәм Ромашовлар ротасына якынлаша башлады. Ромашов инде аның йөз сызыкларына кадәр аермачык күрә иде. Эре сөякле авыр-салмак гәүдә, май баскан түгәрәк корсак; шул симез гәүдәгә тарттырып киелгәндәй кысан кителе

түш һәм корсак турысында җыерылып-җыерылып тора; җәенке, дүрткел формадагы йөзе солдатларга таба борылган. Ромашов шулай ук аның ялтырап торган кунычлы бәләкәй, тәбәнәк үкчәле күн итегенә, мәһабәт тимеркүк атының кызыл төстәге вензелләр белән бизәлгән япмасына, сөяк алкалар тагылган пыренә дә игътибар итте.

— Здорово, алтынчы!

Ромашов әйләнәсендә бар кеше, бугазларын киереп, коточкыч каты тавыш белән кычкырып җибәрделәр. Генерал ияр өстендә үз-үзенә бик ышанган һәм беркадәр искитмәүчән кыяфәт белән утыра, ә аты, муенын матур дугайландырып һәм авызлык тимерен шыкыр-шыкыр чәйнәп, сыгылмалы аякларын еш-еш атлап, биеп бара; аның ягымлы күзләрен кан баскан, авыз кырыйларыннан исә ак күбек тама иде. «Генералның чигә чәчләре ак, ә мыегы кара, фабра сөрткән, ахрысы»,— дип уйлап куйды Ромашов.

Корпус командиры үзенә таба төбәлеп каткан һәрбер пар күзгә беркадәр көлемсерәү катыш мәсхәрәле, акыллы һәм яшьләрнекечә үткер кара күзләрен юнәлтеп, алтын кысалы күзлегенең пыяласы аша игътибар белән карап-карап уза иде. Менә ул Ромашов белән тигезләнде дә кулын фуражка козырегына тидереп честь бирде. Ромашов, аяк мускулларының авыраеп тартышуын сизгән бер хәлдә, тораташтай үрә катты, бил каешына тагылган кылычының сабын кулы авыртырлык дәрәҗәдә тагы да кысыбрак тотты. Күңелендә кинәт уянган тугрылык, шатлык хисеннән аның бөтен тәне буйлап салкын кымыршык йөгереп узды һәм аяк-кул тиресе шундук вак, каты төерчекләр белән капланды. Һәм корпус командирының йөзенә текәлгән килеш, ул тагы элеккеге беркатлы, малайларча гадәтенә буйсынып: «Сугышчан генерал яшь подпоручикның чандыр, зифа сынына рәхәт бер соклану белән озак-озак карап торды»,— дип, үзалдына уйланып куйды.

Корпус командиры, һәрбер рота белән шулай честь биреп исәнләшә-исәнләшә, бөтен полкны карап-йөреп чыкты. Аның артыннан шәп, таза-тук атларга атланган бер өер штаб офицерлары — генералның свитасы ияргән иде. Ромашов аларны да тугрылыклы, сокланулы күз карашы белән озатып калды, әмма свита кешеләреннән берәү дә аның үзенә борылып карамады: мондый парадлар, музыкалы каршылаулар, түбән дәрәҗәле пехота офицерларының мондый сокланулы күз карашлары һәм кичерешләре алар өчен сару кайнаткыч гадәти бер нәрсәгә әверелгән иде инде. Һәм Ромашов, бу тәкәббер кешеләр бөтенләй бүтән тормыш, буй җитмәс матур, югары тормыш белән яши-

ләрдер дигән фикергә килеп, үзенең күңелендә аларга карата көнләшү һәм дошман күрү сымаграк томанлы бер хис уянуын тойды.

Ул арада кайсысыдыр, ерактан кул болгап, музыканы туктатырга боерды. Корпус командиры сул флангка барып җиткән җиреннән кире борылды да, атын эре адымнар белән сикертеп чаптыра-чаптыра, яңадан уң флангка таба юнәлде. Бәйрәмчә купшы киенгән чуар свитасы исә, таркалып, дулкындай айкала-чайкала, аның артыннан сузылды.

Полковник Шульгович беренче рота янына чаптырып килде. Тезгененнән тартып, туры алашасын туктатты да, симез гәүдәсен артка ташлый биреп, янгын вакытындагы брандмайорлар сыман, үтә ярсулы, куркынган һәм хырылдык тавыш белән:

— Капитан Осадчий! Ротагызны чыгарыгыз-з! Тиз булыгыз-з!.. — дип кычкырды.

Хәрби өйрәнүләр вакытында полк командиры белән Осадчий арасында үзенә бертөрле ярыш — тавыш ярышы башланып китә торган иде. Бу юлы да Осадчийның металл чыңыдай яңгырап чыккан купшы-көяз, калын бас тавышы иң кырыйдагы уналтынчы ротага хәтле барып җитте:

— Рота, на плечо! Равнение на середину, шагом марш! [1]

Осадчий ротасы тырыш хезмәт һәм озакка сузылган күнегүләр нәтиҗәсендә марш атлап йөрүдә үзенә генә хас бер ысул булдырган иде. Аның солдатлары атлаганда аяклары ифрат югары күтәрәләр дә көч белән алга ташлыйлар, шуңа күрә аларның адымнары эре дә, нык та килеп чыга һәм карап торышка да бик тәэсирле, мәһабәт күренә иде. Шул ук вакытта бу йөреш башка рота командирларын көнләштерә дә иде.

Ләкин беренче рота үзенә хас әлеге адымы белән кырык-илле метр җир үтәргә дә өлгермәде, корпус командирының түземсезләнеп җикергән тавышы кинәт һаваны ярды:

— Ниткән нәрсә бу тагын? Туктатыгыз ротаны. Туктатыгыз! Ротаның командиры, килегез әле минем янга. Сез монда нәрсә күрсәтәсез? Матәм процессиясеме, әллә факельцугмы? Яисә бу җәелмәле-кушылмалы солдат уенымы? Иә булмаса өч тизлекне аралаштырып марш атлаумы? Солдат егерме биш ел буе өзлексез хезмәт иткән Николай заманнары түгел хәзер, капитан. Бу кордебалетны өйрәнү өчен күпме көн әрәм иттегез? Кадерле көннәрне диюем!

[1] Рота, мылтыкны җилкәгә! Уртага карап тигезләп, шагом марш!

Озын буйлы Осадчий, ялан кылычын түбән салындырып, караңгы чырай белән аның каршында хәрәкәтсез тик басып торды. Генерал, беравык дәшми торганнан соң, йөзенә мәсхәрә катыш моңсу бер төс биреп, тынычланганрак тавыш белән сүзен дәвам иттерде:

— Чынлап тикшерсәң, сез бу гыйльме адымиягез белән солдатның башын тәмам тинтерәтеп бетергәнсездер инде, шулаймы? Их сез, коры куыклар. Ә бит тиешлесен сорап кара әле сездән... Мәсәлән, менә бу солдатның фамилиясе ничек, әйтеп биргезче?

Шулай дип, генерал уң флангтан икенче булып басып торган солдатка бармагы белән төртеп күрсәтте.

— Игнатий Михайлов, ваше превосходительство,— дип, агачтай коры, солдатча битараф, калын бер тавыш белән җавап бирде Осадчий.

— Яхшы. Ә аның үзе хакында сез нәрсә беләсез? Өйләнгәнме ул? Өйләнмәгәнме? Бала-чагасы бармы, юкмы? Бәлки, анда, авылында, аның берәр төрле кайгысы, фажигасе бардыр? Әйтик, мохтаҗлыгы? Ә?

— Һич әйтә алмыйм, ваше превосходительство. Йөз кеше. Һәммәсен истә тотып булмый.

— Истә тотып булмый, имеш! — дип, ачыну белән кабатлады генерал. — Их сез, әфәнделәр, әфәнделәр! Изге китап ни ди: рухи дәртне сүндерә күрмәгез, ди. Ә сез нишлисез? Ә бит эш сугышка килеп терәлсә, сезнең бу кара сарык дигәнегез әүлиягә әвереләчәк: күкрәге белән каплап сезне ут эченнән алып чыгачак, салкында сезне тишек-тошык шинеле белән каплап җылытачак, ә сез аны белмим дисез.

Һәм, янә ярсуы кабынып, кулындагы тезгенне һич кирәксезгә нервланып тарткалый-тарткалый, ул Осадчий башы аша полк командирына кычкырды:

— Полковник, смотрдан алыгыз бу ротаны. Карыйсым да, күрәсем дә килми. Хәзер үк алыгыз! Шамакайлар! Катыргы мәзәкчеләр! Чуен миләр!

Шушы вакыйгадан полкның смотрдагы уңышсызлыгы башланды. Солдатлардагы арыганлык, куркытылганлык, унтер-офицерларның мәгънәсез шәфкатьсезлеге, гомумән, офицер халкының хезмәткә искечә һәм салкын, ваемсыз мөнәсәбәте — болар һәммәсе смотр вакытында ачык һәм хурлыклы рәвештә өскә калкып чыкты. Икенче ротада «Отче наш»ны җырлый белмәделәр, өченчедә — чәчмә строй белән йөргәндә офицерлар үзләре үк буталып хурлыкка калдылар, дүртенчедә исә мылтык белән эш итү ысулларын күрсәткәндә ниндидер бер солдат, хәлсезләнеп,

чак кына һуштан язып егылмады. Ә иң хурлыклысы — полк көтелмәгән кавалерия һөҗүменә каршы нинди ысуллар куллану мәсьәләсендә үзен бик нык сынатты. Бу ысулларның әһәмиятен дә яхшы беләләр, аларны өйрәнү буенча махсус күнегүләр дә уздырылган иде, шулай булса да полкның, бишенчедән кала, бер генә ротасы да бу ысулларны җиренә җиткереп үти алмады. Корпус командиры үзе гамәлгә керткән бу ысуллар гаскәр сафын кыска бер вакыт эчендә төрлечә үзгәртеп коруга нигезләнеп, башлыклардан һәр даим тапкырлык, зирәклек һәм шәхси инициатива таләп итә иде. Һәм менә шул ысулларны гамәлдә күрсәткәндә, барлык роталар бер-бер артлы уңышсызлыкка очрады.

Ротаның гомуми торышын күздән кичергәч, генерал өлкән һәм кече офицерларга сафтан читкә чыгып басарга куша да солдатлардан тегеме-бу турыда сораштыра башлый иде. Янәсе, алар хезмәттән канәгатьме, үзләренә тиешлене тулаем алалармы, зарлары яки берәр төрле дәгъвалары юкмы? Ләкин һәрбер рота аңа бердәм кычкырып җавап бирә: «Нәкъ шулай — бөтенесеннән канәгать»,— ди. Беренче рота солдатларына шундый сорау бирелгәч, Ромашов үзенең артында басып торган Рынданың — үз ярым ротасы фельдфебеленең чыжылдаулы тавыш белән, янап:

— Берәрсе дәгъва-фәлән дип авызын гына ачсын! Соңыннан күрсәтермен мин аңа дәгъвасын! — дигән сүзләрен ишетеп калды.

Аның каравы, бишенче рота үзен бөтен яктан искиткеч шәп күрсәтте. Кыяфәтләрендә үк егетлек һәм көч-дәрт сизелеп торган бу рота солдатлары үзләре эшләргә тиешле күнегүләрне шундый күтәренке рух һәм җиңеллек, шундый ирекле, табигый, өлгер хәрәкәтләр белән башкарып чыктылар ки, әйтерсең, бу смотр алар өчен дәһшәтле, читен имтихан түгел, ә ниндидер күңелле, кызыктыргыч бер уен гына иде. Хәтта кашы-күзе җимерелгән генерал да, бераз-га йомшара төшеп: «Әйбәт, егетләр!» — дип, бишенче ротаны мактарга мәҗбүр булды. Бу — аның бөтен смотр дәвамында мактап әйткән беренче сүзләре иде.

Кавалерия һөҗүмен кире кагу ысуллары белән Стельковский корпус командирын тәмам үзенә мөкиббән иттерде. Фараздагы дошман һөҗүменең юнәлешен генерал: «Кавалерия — уң якта, сигез йөз адымда!» — кебек ашыгып, искәртмичә әйткән сүзләре белән үзе күрсәтеп торды. Стельковский исә, секунд та көттермичә, үз ротасын тиешле урында туктатып, җан-фәрманга чаптырып килгән дошман кавалериясенә каршы йөзе белән борып бастыра да,

ашыкмыйча-кабаланмыйча, әмма бирелгән вакытның минутын минутына төгәл туры китереп, сафларны тыгызлый — алдагы взводны җиргә теәләндереп, арттагыларын аягүрә калдырып, шул хәлдә фараздагы дошманга икемеөчме тапкыр дәррәү ут ачарга боера иде. «Бик шәп, туганнар! Булдырасыз, рәхмәт сезгә!» — дип мактап-мактап куйды аларны корпус командиры.

Генерал солдатлардан тегене-моны сораштырганнан соң, бишенче рота янәдән әүвәлгечә тезелеп басты. Ләкин генерал алар яныннан китәргә ашыкмады. Атын әкрен генә атлатып, ул үтә бер игътибар, кызыксыну белән солдатларның йөзләренә озаклап текәлә-текәлә саф алдында йөренде, һәм анын чырае торган саен яктырып, шешенке, авырсалынкы кабаклары астыннан пыяла аша караган акыллы күзләрендә нечкә, канәгать бер елмаю балкып китте. Кинәт ул атын туктатты да, артына борылып, үзенең штаб начальнигына эндәште:

— Полковник, зинһар, карап кына багыгыз — танауларын әйтәм, чиртсәң — кан чәчрәп чыгарлык! Юкса әллә бәлеш ашатасызмы сез аларга, капитан? Әй, син, кабартма бит,— дип, ияге белән ым какты ул бер солдатка,— ни атлы син, Коваль түгелме?

— Нәкъ шулай, ваше превосходительство, Михайла Борийчук! — дип, сабыйларча канәгать елмаеп, дәртле тавыш белән җавап бирде солдат.

— Ә мин сине тагы Коваль атлыдыр дип уйлаган идем. Димәк, ялгышканмын,— диде генерал, шаяртып.— Бернишләп булмый, зирәклек житенкерәмәде... — дип өстәде аннары һәм ахырга шактый тоэлы гына сүз кыстырып куйды.

Солдатның йөзенә куанычлы, ахмак бер елмаю җәелде.

— Һич тә ялгышмагансыз, ваше превосходительство! — дип, тагы да катырак кычкырды ул.— Авылда тимерчелектә эшләдем мин. Коваль [1] идем.

— Менә бит, рәхмәт төшкере! — диде генерал, солдатка таба дусларча ым кагып. Солдат халкының күңеленә керә белүе белән бик горурлана иде ул. Ничек соң, капитан, әйбәт солдатмы ул сезнең?

Стельковский үз-үзенә ышанган, гадәттәге нык тавышы белән:

— Бик әйбәт солдат. Миндә барысы да әйбәтләр,— дип җавап бирде.

---

[1] Монда сүз уйнату: *коваль* — ат дагалаучы дигәнне аңлата. *(Тәрҗемәче искәрмәсе.)*

Генералның кашлары ризасыз төстә калтырап куйды, шулай да йөзендәге елмаю сүрелмәде. Бу минутта аның бөтен чырае ничектер бик мөлаем, картларча сөйкемле иде.

— Карыйм, сез, капитан, шактый дигәндәй... Ротагызда штрафка эләгүчеләр бармы?

— Берәү дә юк, ваше превосходительство. Бишенче ел инде — андый хәл булганы юк.

Генерал, ияре өстеннән көч-хәл белән иелеп, Стельковскийга таба ак перчатка кигән йомшак, мимылдык кулын сузды.

— Зур рәхмәт сезгә, кадерлем,— диде ул калтыранган тавыш белән, һәм аның күзләрендә кинәт яшь тамчылары ялтырап күренде. Картлык сәерлеге керә башлаган күпчелек сугышчан генераллар шикелле, ул да ара-тирә күз яше агызгалап алырга ярата иде.— Рәхмәт, куандырдыгыз мин картлачны. Рәхмәт сезгә, баһадирлар! — дип, гайрәт белән кычкырды ул солдатларга.

Стельковский калдырган яхшы тәэсир аркасында, алтынчы ротаның да эшләре башта чагыштырмача шактый ярыйсы барды. Генерал аларны мактамады да, сүкмәде дә. Шулай да, агач рамнар эченә беркетелгән салам карачкыларны штык белән кадарга чират җиткәч, алтынчы рота барыбер хурлык кичерергә мәҗбүр булды.

— Алай кирәкми, алай түгел, алай түгел! — дип, ияре өстендә кыбырсый-кыбырсый, битәрләде аларны корпус командиры.— Бөтенләй алай түгел! Туганнар, мине тыңлагыз. Йөрәк ягыннан када, нәкъ уртасына, штык көпшәгә кадәр батып керсен. Ачуланып када! Син бит дошманны кадыйсың, ә көрәк белән мич түренә ипи тыкмыйсың...

Бүтән роталар бер-бер артлы уңышсызлыкка очрый торды. Корпус командиры, күрәсең, аларга кул селтәгән иде, артык борчылмады да, үзенең гадәттәге әче-тозлы шелтәләрен дә яудырмады, күңелсез чырай белән, ничектер картларча бөкрәя биреп, аты өстендә дәшми-тынмый юлын дәвам иттерде. Унбишенче һәм уналтынчы роталарны исә ул бөтенләй кararга теләмәде, арыган кыяфәттә кулын селтәп, җирәнү белән:

— Ну, болары... бөтенләй ясалулары җитмәгән,— дип белдерде.

Полкка хәзер тантаналы марш атлап узасы гына калган иде. Аны ярым роталап тыгыз бер колоннага тезделәр. Уң флангка, хәрәкәт тигезлеген һәм юнәлешен күрсәтер өчен, янә желонерлар чыгып басты. Көн һаман эсселәнә бара иде. Бер-беренә терәлеп диярдәй басып торган кешеләрдән күтәрелгән тир, юынмаган, пычрак тән исе, күн итек, тә-

мәке һәм ашказанында эшкәртелеп ачыган кара ипи исе — болар һәммәсе болай да эссе һаваны шулкадәр бөркүләтте, хәтта сулыш алырга да кыен иде.

Шулай да тантаналы марш алдыннан һәммә кешегә ничектер җан керде. Офицерлар, ялынгандай бер тавыш белән: «Туганнар, зинһар тырышыгыз инде, корпус командиры алдында хур булмыйк, матур атлап узыгыз»,— дип, солдатларны үгетләделәр. Бу үгетләү сүзләрендә яшерен курку, үз-үзләрен гаепле санап солдатлар алдында ялагайлану кебек нәрсә дә ачык сизелә иде. Гүя буй җитмәс бөек затның — корпус командирының — баягы җикеренүләре офицерларның да котын алып, аларны солдат белән бертигез дәрәҗәгә куйган һәм солдатныкы кебек үк кызганыч, аптырашлы, афәтле курку хәлендә калдырган иде.

Ниһаять, ераста Шульговичның командасы яңгырап ишетелде:

— Полк, смирррна-а!.. Музыкантлар, юнәлеш сызыгына чыгып бас!..

Һәм мең ярым кеше ашыгулы-кабаланулы бер тоныкгөжелдәү белән берьюлы кыймылдап алды да, кинәт тураеп, тынны кысып, үрә катты.

Шульгович үзе күренми иде. Янә аның көйләп әйткән гүелдәвек тавышы яңгырады:

— Полк, на плечо-о-о!..

Дүрт батальон командиры, атларын үз батальоннарына таба борып, тигезсез тавыш белән:

— Батальон, на пле... — дип кабатладылар һәм полк командиры торган якка күзләрен текәделәр.

Кайдадыр ераста, мәйданның түрендә, һаваны ерып түбән төшкән ялан кылыч ялтырап күренде. Бу — гомуми команда бирүгә сигнал булып, батальон командирларының дүртесе дә шундук берьюлы дәррәү кычкырып җибәрделәр:

— ... чо!

Полк тигезле-тигезсез, саңгырау бер чыкылдау белән, мылтыкларны җилкәгә күтәрде. Кайдадыр штык штыкка бәрелгән тавышлар да ишетелеп куйды.

Шуннан соң Шульгович, сүзләрне кирәгеннән артык суза биреп, шатлык катыш кырыс, тантаналы тавыш белән, киң күкрәгенең бөтен куәтенә:

— Тан-та-на-лы марш-ка-а әзер бул! — дип кычкырды.

Бу юлы инде батальон командирлары гына түгел, һәркайсы үзенчә сузып-көйләп, команданы кабатлады:

— Тантаналы маршка әзер бул!

Койрык ягында берсе, команданы вакытында абайламый калып булса кирәк, һәммәсеннән соң:

— Тантаналы... — дип, кыюсыз гына әйтә башлаган иде дә, оялып, ярты сүзендә шып туктады.

— Ярым ро-та-ла-ап! — дип янә команда бирде Шульгович.

Рота командирлары тагы кабатладылар:

— Ярым роталап!

— Дис-тан-ция — ике взвод сыешлы! — диде Шульгович, һаваны ярып.

— Дистанция — ике взвод сыешлы!..

— Ра-внение на-права-а!

— Равнение направо! — дип кабатлады чуар тавышлы кайтаваз.

Шульгович ике-өч секунд тын алып торды, аннары өзеп-кистереп:

—Беренче ярым рота — кузгалырга! — дип кычкырды.

Тыгыз сафлар арасыннан җиргә сыена-сыена якынлашып килгәндәй, ерактан ук саңгырау яңгырап, капитан Осадчийның куе-калын командасы ишетелде:

— Беренче ярым рота! Равнение направо. Шагом.... арш!

Алда полк барабанчылары дәррәү барабан сугып җибәрделәр. Ул да булмады, артка таба ярым авыш штыклар урманының озынча, тигез бер өлеше, салмак кына тирбәлә-тирбәлә кузгалып, колоннадан аерылды.

— Икенче ярым рота, прямо! — дигән, хатын-кызларныкыдай чәрелдек тавыш ишетте Ромашов. Монысы — Арчаковский тавышы иде.

Һәм штык урманының икенче кисәге, колоннадан аерылып, янә дулкынланып чайкала башлады. Барабан суккан тавыш, җир астына төшеп ераклашкандай, һаман тоныклана, әкренәя бара иде. Кинәт аның өстенә, аны тәмам егып, изеп дигәндәй, үтә матур, көләч, күңелле икенче бер дулкын килеп бәрелде. Монысы — полк оркестрының дәртле музыкасы иде. Полк шундук берьюлы җанланып, үзүзен җыя төште: башлар югары чөелде, билләр турайды, алҗыган, сулган йөзләргә нур әсәре кунды.

Ярым роталар бер-бер артлы шулай китә торды, аның саен полк оркестры уйнаган маршның яңгыравык тавышы тагы да дәртлерәк, көләчрәк, тәэсирлерәк була барды. Менә беренче батальонның ахыргы ярым ротасы да урыныннан кузгалды, чират икенче батальонга җитте. Эре сөякле кара ат менгән подполковник Лех, адъютанты Олизарны иярткән, алдан атлады. Икесе дә, уң кулны йөз тиңентен югары күтәреп, ялан кылычларын «катырып» тоткаллар. Әнә Стельковскийның гадәттәгечә тыныч һәм беркадәр ва-

емсызрак тавыш белән биргән салмак командасы ишетелде. Штык урманы өстендә, югарыда, озын саплы байрак чайкалып куйды. Менә, ниһаять, алга капитан Слива чыгып басты; бөкре гәүдә, карт маймылныкыдай озын, килбәтсез куллар, шешенгән бит. Ул нурсыз акай күзләре белән ротасына бер карап алды да:

— Б-беренче ярым рота... к-кузгал! — дип боерды.

Ромашов, җиңел һәм чая атлап, ярым ротасы каршына, аның нәкъ урта бер җиренә чыгып басты да, йөзе белән солдатларга таба борылып, беренче рәттәгеләрне тиз генә күзеннән кичерде. Һәм шундук аны ниндидер рәхәт, гүзәл бер горурлык хисе биләп алды. «Карт сугышчы үзенең лачын солдатларына горурланып карады»,— дигән купшы фраза ялтырап узды аның күңеленнән, ә теле, көйләп-сузып, дәрт белән боерык сүзләрен кычкырды:

— Икен-нче ярым ро-ота-а...

«Бер, ике!» — дип, аяк очларын кыймылдатып, күңеленнән такт үлчәвен санады Ромашов. «Адымны сул аяктан башларга кирәк. Сул, уң...» Ниһаять, башын артка ташлап, күзләрен бәхетле елтыратып, бөтен әйләнә-тирәгә чыңгылдап яңгыраган нәзек тавышы белән сүзен әйтеп бетерде:

— Пряма! [1]

Һәм, сыңар аягында пружинадай тирбәлеп, алдына борылды да, ярым ротасына карамый-нитми генә, тавышын бер-ике тонга калынайта төшеп, баягыча көйләп-сузып:

— Ра-авне-ние направа-а! — дип өстәде.

Мизгелнең гүзәллеге аның тәмам миен томалады. Музыка күз камаштыргыч якты, кайнар дулкыннары белән Ромашовны гүя нурга коендыра, аның тантаналы җиз авазлары каяндыр югарыдан, күктән, кояшның үзе эченнән коела кебек иде. Бая каршылау маршы уйналган чактагыча, Ромашовның тәне буйлап янә татлы, салкын бер кымыр-җык йөгереп узды, тәне каты, вак төерчекләр белән капланды, башындагы чәче һәр бөртегенәчә кыймылдап, тетрәп куйды.

Әнә, генералның мактау сүзенә каршы, музыка тактына тәңгәл китереп, бишенче рота бердәм җавап кайтарды. Маршның дәртле авазлары, үз юлларында инде бернинди каршылык, солдатлар киртәсен очратмыйча, иреккә чыгуларына шатлангандай, Ромашовка таба тагы да җитезрәк, күңеллерәк яңгырап йөгерештеләр. Үзеннән алда, уң кул якта тимеркүк аты өстендә ишелеп утырган генералны һәм

---

[1] *Пряма! (Прямо!)* — турыга атлап китүне аңлаткан хәрби команда *(тәрж.)*.

аның артында хәрәкәтсез басып торган свитаны подпоручик хәзер инде бөтенләй аермачык күрде диярлек; ә тагы да алдарак аның күз карашы кояш нурларында тәмам әкияттәге ут чәчәкләре сыман җемелдәп күренгән чуар киемле хатын-кыз төркемен шәйләп алды. Сул кул якта исә әлеге дәртле музыканы уйнаган оркестрның алтынланып ялтыраган җиз трубалары пәйда булды. Бу музыка белән генерал арасында гүя күзгә күренми торган ниндидер тылсымлы җеп сузылган иде, һәм ул җепне атлап чыгу Ромашовка чиксез шатлыклы да, коточкыч куркыныч та булыр шикелле тоелды.

Ләкин беренче ярым рота бу чик сызыгына килеп житкән иде инде. Әнә корпус командирының:

— Әйбәт, егетләр! — дигән канәгать тавышы да ишетелде.

Солдатлар аның мактавын шундук куанычлы, каты:

— А-а-а-а! — авазы белән эләктереп алдылар.

Ул арада музыка тагы да катырак уйный башлаган сыман тоелды. «Акыллы баш, егет кеше!» — дип, тәэсирләнеп уйлады Ромашов генерал турында.

Менә Ромашов, үзеннән кала бөтен кешене онытып, җиргә тияр-тимәс сыгылмалы адым белән, әлеге тылсымлы җеп сызыгына якынлаша башлады. Башы чая төстә артка ташланган, горур күз карашы сул тарафка төбәлгән. Тәнендә чиксез бер җиңеллек һәм хөрлек, әйтерсең ул шушы мизгелдә үк һавага күтәрелеп очып китәргә җыена. Һәм үзен дөньяның соклангыч гүзәл бер ноктасы, гомум игътибар үзәгә итеп тойган хәлдә, ул ниндидер куанычлы, сихри адарыну белән үзе турында күңеленнән уйланып барды:

«Әнә, карагыз әле, карагыз әле,— бу Ромашов килә». «Ханымнарның күз карашларында соклану очкыннары ялтырап күренде». Бер, ике, сул!.. «Әнә, ярым ротаның иң алдында, аякларын мәһабәт атлап, яшь, чибәр подпоручик килә». Сул, уң!.. «Полковник Шульгович, сезнең бу Ромашовыгыз карап туймаслык, мин аны үземә адъютант итеп алырга теләр идем»,— ди, имеш, корпус командиры. Сул, уң...

Тагын бер секунд, бер мизгел — Ромашов әлеге тылсымлы сызыкны атлап үтәчәк. Музыка ниндидер куәтле, ялкынлы, шашкын тантана белән уйнавында дәвам итә. «Менә хәзер мактап сүз әйтер»,— дип уйлый Ромашов, һәм аның бөтен җаны бәйрәмчә хозур бер шатлык эченә чума. Әнә корпус командирының тавышы ишетелде дә сыман, әнә Шульгович та нәрсәдер әйтте, әнә тагы кемнәрдер сүз

кыстырды... «Генерал мактау сүзе әйтте, әлбәттә; тик шулай да солдатлар ни өчен аңа җавап кайтармадылар икән соң? Әнә кемдер арттан, саф эченнән кычкыра. Бу ни бу?»

Шулай дип, Ромашов артына борылды һәм куркудан агарынып китте. Аның гөмбәндагы туры, тигез ике сызык арасыннан хәрәкәт итәргә тиешле ярым ротасы, төзек тәртибен югалтып, берсе өстенә берсе өерелеп, уңга-сулга боргаланып атлаган сарык көтүен хәтерләтә иде. Хикмәт шунда, Ромашов, күңелендәге куаныч һәм сихри хисләрдән исереп, үзе дә сизмичә, адымы саен аз-азлап уртадан уңга таба каерыла барган һәм, ярым ротасын шул яктан кыскрыклый-кыскрыклый, ахырда аның уң флангысына барып чыгып, гомум хәрәкәтне тәмам буталуга китергән иде. Моны ул күз ачып йомган кыска бер мизгел эчендә күреп һәм аңлап алды. Шулай ук төркемнән унбиш-егерме адым арттан, нәкъ менә генерал турысыннан, берьялгызы өстерәлеп атлаган солдат Хлебниковның да аянычлы хәлен шундук күреп-аңлап алды. Мескен солдат егылган булган, күрәсең: хәзер, бөтен өсте-башы тузанга баткан көе, амуниция-се авырлыгыннан җидегә бөгелеп, ярым ротасын куып җитәр өчен дүрт аяклап дигәндәй чаба; бер кулында — утын агачыдай урта җиреннән тоткан мылтык, икенче кулы белән ул кызганыч кыяфәттә борынын сөртеп-сөртеп ала иде.

Ромашовның күз алдында май аеның нурлы, аяз көне гүя берьюлы караңгыланып китте, җилкәсенә ком тавыдай үле-җансыз, чит-ят бер авырлык менеп утырды, хәтта музыка тавышы да ничектер кисәк кенә тонык лаңып, күңелсезләнеп калды. Бу минутта ул үзен янәдән бәләкәй, зәгыйфь, ямьсез бер кеше итеп, аяк атлауларына хәтле шыксыз, килбәтсез кеше итеп күрде.

Ул арада аның янына полк командирының адъютанты Федоровский чаптырып килеп җитте. Бөтен йөзе кызарып бүртенгән, ияге калтыр-калтыр сикеренә, каты чабу һәм ярсудан хәтта тыны беткән. Ул ерактан ук буыла-буыла зәһәрләнеп кычкырды:

— Подпоручик... Ромашов... Полк командиры сезгә... каты шелтә белдерә... Җиде көнгә... гауптвахтага... дивизия штабына... Башбаштаклык бу, җәнҗәл... Бөтен полкны... хур иттегез!.. Маңка малай!

Ромашов бер сүз әйтмәде, хәтта аңа таба борылып та карамады. Ни дисен, сүгәргә аның хакы бар, әлбәттә. Адъютантның аңа ничек җикеренгәнен әнә солдатлар да ишетеләр бугай. «Һәй, ишетмәгәйләре, ишетсеннәр сәнә, шул кирәк миңа,— дип, үз-үзенә ачы нәфрәт хисе белән уйлап

куйды Ромашов.— Минем өчен хәзер бары да бетте. Бары да, бары да бетте. Миңа гомерлек хурлык тамгасы ягылды. Миңа фәкать атылып үләргә генә кала. Бәләкәй, көленеч кеше мин, ямьсез, сулган йөзлемен, андый ахмак, җирәнгеч йөзне дөньяда бүтән таба да алмассың. Бары да бетте! Артымнан атлаучы солдатлар, мөгаен, мине үчеклиүчекли, бер-берсенә терсәкләре белән төртә-төртә миннән көлеп баралардыр. Кем белә, бәлки, кызганалардыр да әле? Юк, миңа фәкать, фәкать атылып үләргә генә кала!»

Ярым роталар, корпус командиры турысыннан шактый ераккa китеп, сулга борылалар да бер-бер артлы яңадан әүвәлге урыннарына кайтып туктыйлар. Монда алар роталап-роталап янәдән җәенке сафка тезелергә тиешләр иде. Арткы частьлар шулай бер-бер артлы килеп туктаган арада, беренче килгәннәренә «вольно» басып торырга рөхсәт ителә, офицер халкы исә, сафтан читкә чыгып, бераз буын язып алырга яисә җиң эченә яшерә-яшерә генә тәмәке көйрәтергә керешкән иде инде. Тик Ромашов кына, үз ярым ротасының уң флангысы белән алгы сызык арасына ничек килеп туктаган булса, шул рәвешендә басып тора бирде. Ялан кылычының очы белән ул берөзлексез аяк астындагы җирне чокыды һәм, башы түбән иелгән булуына да карамастан, үзенә таба бөтен яктан мәсхәрәле, нәфрәт катыш кызыксынучан күз карашлары төбәлгәнен тойды.

Әнә капитан Сливаның, узып барышлый, Ромашовка карамыйча гына, гүя үз-үзе белән сөйләшкәндәй, теш аралаш нәфрәтле ысылдап:

— Б-бүген үк б-бүтән р-ротага күчерүне сорап р-рапорт бирегез,— дигән янау сүзләре ишетелде.

Аннары Ромашов янына Веткин килде. Аның да ягымлы, саф-ихлас күз карашында һәм кырыйлары түбән салынып төшкән иреннәрендә гадәттә поезд астында калып үлгән эт үләксәсен күргән чакта була торган үзенә бер төрле кызганулы, җирәнүле сәер галәмәт катып калган иде. Ромашов, үз-үзенә тирән нәфрәт тойган хәлдә, ирекле-ирексез, тонык һәм мәгънәсез бер елмаю белән елмаеп куйды.

— Әйдәгез, без дә тәмәке көйрәтик булмаса, Юрий Алексеич, — диде Веткин. Һәм кинәт башын чайкап, телен чупылдатып алды да: — Их, җаный-җаныкаем!.. — дип өстәде.

Ромашовның ияге дерелдәп китте, тамагына ачы төер килеп тыгылды. Үксеп елап җибәрүдән үзен көчкә тыеп, ул үпкәләгән сабый бала сыман өзек, кызгандыргыч тавыш белән:

— Кая инде монда тәмәке көйрәтүләр... ул кайгымыни... тартасым килми... — дип җавап бирде.

Веткин дәшми генә Ромашов яныннан читкә китеп барды. «Менә хәзер Слива янына барам да яңагына берне менәм дә төшәм,— дип, һич көтмәгән җирдән кыюланып, үзалдына батыраеп уйланды Ромашов.— Яки корпус командирының үзе каршына ук барам, әйтәм аңа: «Сезгә, карт кешегә, ничек оят түгел: халыкны шулай солдат уены белән иза чиктерү ярыймыни? — дип әйтәм.— Аларны ичмасам бераз ял иттерер идегез, болай да ике атна буе башлары кыйналудан чыкмады»,— дип әйтәм».

Ләкин шул вакыт, үзенең баягы уй-хыялларын — зифа буйлы, чибәр подпоручик турындагы, хатын-кызларның һәм сугышчан генералның аңа таба сокланулы, канәгать күз карашлары юнәлтүе турындагы горур хыялларын исенә төшереп, ул күңеленнән шундый бер чиксез оят хисе кичерде ки, шул ук мизгелдә аның йөзе, юк, йөзе генә түгел, бөтен арка, күкрәкләре комачтай кызарынып, кызыша башлады.

«Син көлке, җирәнгеч, әшәке кеше! — дип үз-үзенә эндәште ул күңеленнән.— Менә күреп торырсыз, мин бүген атылып үләчәкмен!»

Смотр инде бетеп килә иде. Полк корпус командиры каршында сафта йөрүнең тагы берничә төрен күрсәтте: башта һәрбер рота аерым-аерым марш атлап узды, аннары йөгереп, ахырда барысы бер колоннада, мылтыкларны штыклары белән алга каратып, сугышчан саф белән уздылар. Генерал беркадәр йомшара төште ахры, берничә тапкыр солдатларны мактап та алды. Кичке дүртләр тирәсендә, ниһаять, смотрны тәмамлап, полкка «вольно» басып торырга рөхсәт иттеләр. Штаб быргычысы «командирларны җыю» көен уйнап җибәрде. Сафлар буенча:

— Офицер әфәнделәр, корпус командиры янына җыелырга! — дигән боерык тавышы яңгырап узды.

Офицерлар, саф эченнән чыгып, корпус командиры тирәли тыгыз бер түгәрәккә килеп бастылар. Ул үзе, бөкрәя биреп, аты өстендә утыра; кыяфәте шактый арыган күренә, әмма аның шешенке күз кабаклары астыннан алтын кысалы пыяла аша көлемсерәп караган акыллы күзләрендә әле булса дәртле бер очкын елтырый иде.

— Күп сөйләмәм,— дип, өзек, кискен-салмак тавыш белән сүзен башлады ул.— Полк бернигә яраксыз. Солдатларны сукмим, башлыкларны гаеплим. Кучер начар икән — ат һәрвакыт чыгымлый. Күңел биреп эшләү юк сездә, кеше турында ихлас кайгырту юк. Бер нәрсәне исе-

гездә нык тотыгыз: «Хөрмәтле шулдыр, кайсы үз җанын кардәше, дусты өчен фида кыйла». Ә сезнең бар белгәнегез — смотр вакытында начальство алдында яхшатлану. Халыкны извозчик атыдай җәфалап бетергәнсез. Офицерларга карарлык та түгел, әллә нинди килбәтсез, кыргый кыяфәттә, мундир кигән дьячоклар дип уйларсың. Хәер, бу хакта язма приказымнан укырсыз. Алтынчымы, җиденчеме ротадан кайсыдыр прапорщик, тигезлекне саклый алмыйча, ротаны тәмам боткага әверелдерде. Хурлык бу! Мин сездән өч темп белән атлауны таләп итмим, әмма сафта барганда күз контроле һәм сабыр җыйнаклык — иң зарури нәрсәләр.

«Мине әйтә!» — дип, коты алынып, күңеленнән уйлап куйды Ромашов. Бу минутта бөтен кеше үзенә таба борылып карыйдыр төсле тоелды аңа. Әмма беркем дә Ромашовка игътибар итмәде. Һәммәсе, гаепле төстә күзләрен генералга төбәп, бер сүз дәшмичә, баскан урыннарында хәрәкәтсез торалар иде.

— Бишенче ротаның командирына кайнар рәхмәтемне белдерәм! — диде корпус командиры, сүзен дәвам иттереп.— Капитан, кайда әле сез? Ә, менә икән! — дип, генерал беркадәр театральлек белән ике куллап фуражкасын югары күтәрде дә, маңгайга таба бүлтәеп килгән зур, такыр башын түбән иеп, Стельковскийга сәлам бирде.— Тагы бер мәртәбә сезгә рәхмәтемне белдерәм һәм сезнең кулыгызны кысам. Әгәр дә, алла боерып, минем корпуска дошман гаскәре белән йөзгә-йөз килеп сугышырга туры килсә,— генералның җем-җем йомылган керфекләрендә күз яше ялтырап күренде,— белегез, капитан, иң беренче хәтәр эшне мин сезгә тапшырачакмын. Ә хәзер, эфәнделәр, сезгә исәнлек телим. Сез азат, сезнең белән бүтән бер вакыт һәм бүтәнчәрәк тәртиптә очрашырга язсын. Атыма юл бирегезче.

— Ваше превосходительство,— дип, алгарак чыгып басты Шульгович,— офицер эфәнделәр исеменнән сезне җәмгыять клубыбызга аш мәҗлесенә чакырырга рөхсәт итегез. Без бик тә...

— Юк, нигә кирәк! — дип, кырыс кына аның сүзен бүлде генерал.— Ниятегез өчен рәхмәт, мин бүген граф Ледоховскийларга чакырылган.

Шулай дип, ул офицерлар төркеме як-якка тайпылып уртадан ачкан юл аша полкка таба атын чаптырып китте. Солдатлар, аны күрүгә, боерыксыз-нисез, үзләреннән-үзләре тураеп, үрә катып тынсыз калдылар.

— Рәхмәт, туганнар! — дип кычкырды генерал үзенең ягымлы, көр тавышы белән.— Сезгә ике көнлек ял бирәм. Ә хәзер... — ул тавышын тагы да күтәрә төште,— ә хәзер палаткаларыгызга бегом марш! Ура!

Бу боерыгы белән ул бөтен полкны гүя берьюлы урыныннан кузгатты. Меңәрләгән кешелек саф, колак тондыргыч аваз белән шатланышып кычкыра-кычкыра, шундук якякка сибелде, ә аяк астындагы җир, тетрәп китеп, шомлы төстә гүелдәп куйды.

Ромашов шөһрәгә кайтырга чыккан офицерлар төркеменнән аерылды да берьялгызы әйләнеч юлдан, лагерь аша китте. Бу минутта ул үзенә үзе ифрат кызганыч кеше булып, полкның бердәм гаиләсеннән куып чыгарылган, һәммәсе тарафыннан читкә кагылган ниндидер йорт-җирсез килмешәк булып тоелды, алай гына да түгел, ул үзен хәтта олы кеше итеп тә санамады, ә ниндидер гарип, бозык, шөкәтсез бер малай итеп күрде.

Үз ротасының солдатлары торган палаткалар артыннан, офицерлар линиясе дип йөртелгән сукмактан узганда, аның колагына кинәт ниндидер хырылдаулы, буылулы, әмма нәфрәт аһәңе дә сизелгән бер тавыш килеп сугылды. Ромашов туктады да тавыш килгән якка борылып карады. Ике янәшә палатка арасында буйга тәбәнәк, әмма таза, базык гәүдәле, кызыл битле фельдфебель Рында, әшәке сүзләр белән ярсып сүгенә-сүгенә, солдат Хлебниковны яңаклап тора иде. Хлебниковның тәмам чырае бозылган, мәгънәсез, аптыраулы күз карашында хайваннарча ахмак бер кот алыну галәмәте катып калган. Йодрык килеп төшкән саен аның теш казналары чырт-чырт итеп куя, башы әле бер, әле икенче якка тайчана иде.

Ромашов йөгерек диярдәй адым белән тиз генә ары узып китте. Үзендә Хлебниковка ярдәм итәрлек көч-әмәл тапмады ул. Шул ук вакытта бу кимсетелгән, рәнҗетелгән, бичара солдатның язмышы белән үз язмышының бүген ничектер сәер, кардәшләрчә якын һәм җирәнгеч бер рәвештә үзара үрелеп баруын ул бөтен ачылыгында тойды. Әйтерсең алар бер үк авыру белән авыручы, кешеләрдә бер үк төрле җирәнү хисе уятучы ике зәгыйфь игезәкләр иде. Язмышларының мондый тәңгәллеге Ромашов күңелендә ачы хурлык һәм ризасызлык хисе уятса да, ахыр чиктә бу охшашлыкта үзенә бер төрле самими, тирән, чын кешелеклелек сыйфатлары да бар иде.

XVI

Лагерьдан шәһәргә кайту өчен бер генә сукмак булып, бу сукмак тимер юлын кисеп чыга һәм алар кисешкән урында тимер юл текә ярлы, тирән тарлавык аша уза иде. Ромашов тарлавыкның лагерь ягындагы шул текә сукмагыннан йөгерә-чаба түбән төште дә уфылдый-уфылдый икенче ягына күтәрелә башлады. Ярның урта җиренә җитәр-җитмәс үк әле, тау башында басып торган кительле һәм кителе өстеннән шинель бөркәнгән бер кеше күзгә чалынды. Подпоручик туктап калды, күзен кыса төшеп, әлеге кешегә текәлеп карады һәм аның Николаев икәнлеген таныды.

«Иң күңелсезе менә хәзер башланачак!» — дип уйлап алды Ромашов. Аның йөрәге, ниндидер хәвеф буласын сизгән сыман, авырттырып чәнчеп куйды. Шулай да ул, урынныннан кузгалып, күндәм бер төстә сукмак буйлап югарыга таба юлын дәвам итте.

Ромашов белән Николаевның инде дүртме, бишмә көн бер-берсен күргәннәре юк иде, шулай булса да алар хәзер, очрашкач, ни өчендер бер-беренә сәлам бирмәделәр, һәм, иң гаҗәбе, моны Ромашов үзе ни сәбәптәндер бик тә табигый нәрсә итеп тапты; әйтерсең бүгенге кебек аянычлы, авыр көндә бу очрашу башкача булырга да мөмкин түгел иде. Исәнләшү кая, хәтта фуражка козырегына кул тидереп алуны да кирәк санамады алар.

Николаев, күз карашын Ромашовның җилкәсе аша каядыр еракка, лагерьга таба юнәлтеп, беравык дәшми торды да:

— Мин сезне монда махсус көттем, Юрий Алексеич, — диде.

Ромашов үзен мөмкин кадәр иркенрәк тотарга тырышып, ләкин ирексездән калтырап киткән тавыш белән:

— Мин сезне тыңлыйм, Владимир Ефимыч,— дип җавап бирде.

Шулай диде дә, иелеп, җирдән коңгырт төскә кереп кипкән үткән елгы үлән сабагын өзеп алды һәм, авызына кабып, битараф бер кыяфәттә аны чәйнәргә тотынды. Шул ук вакытта ул Николаевның пальто төймәләрендә көзгедәге кебек чагылып күренгән үзенең буй-сынына күз төшерде. Анда ул тәмам бозылып, озынча кечкенә башлы, ян яклары бүлтәйгән кыска аяклы шыксыз бер кеше кыяфәтендә күренә иде.

— Мин сезне озак тоткарламам, фәкать ике-өч сүз генә әйтәсем бар,— диде Николаев.

Сүзләрен ул аеруча йомшак итеп, ачуын һәм ярсуын басарга алдан ук күңелен беркеткән кешеләргә генә хас сабыр, үтә нәзакәтле бер тавыш белән әйтергә тырышты. Әмма болай күзгә-күз карашмыйча сөйләшүнең секунд саен кыенлаша баруын күреп, Ромашов аңа сорау катыш аһәң белән:

— Бәлки, бара-бара сөйләшербез? — дип тәкъдим итте.

Кеше йөри-йөри такыраеп, шомарып беткән сукмак, борыла-сырыла, зур гына бер чөгендер басуын кисеп уза иде. Еракта кызыл чирәп түбәле шәһәр йортлары агарып күренә. Офицерлар, бер-берсеннән ара калдырып, сукмакның ике ягы буйлап янәшә атлап киттеләр. Аяк астында адым саен куе, итләч чөгендер сабаклары чыртлап куя. Бераз вакыт алар икесе дә дәшми бардылар. Ниһаять, Николаев, күкрәген киереп, авыр, гаҗизанә бер уфтану белән сулышын җыйды да беренче булып сүз башлады:

— Барыннан да элек мин сезнең алга бер сорау куярга тиешмен: әйтегез әле, сез минем хатынга... Александра Петровнага ягъни... тиешле ихтирамны күрсәтәсезме икән?

— Мин сезне аңламыйм, Владимир Ефимович... — дип каршы төште аңа Ромашов.— Ул чакта мин дә, үз нәүбәтемдә, сездән сорарга тиешмен...

— Гафу! — дип туктатты аны Николаев, кинәт кенә тавышын күтәреп.— Сорауларны чиратлашып бирик: башта — мин, аннары — сез. Юкса без һич аңлаша алмабыз. Әйдәгез, берни яшермичә, ачыктан-ачык сөйләшик. Иң элек минем сорауга җавап бирегез: хатыным турында кеше арасында йөргән төрле сүзләр, гайбәтләр сезне аз гына булса да кызыксындырамы, әллә юкмы? Ну, кыскасы... әй шәйтан!.. аның абруе борчыймы диюем? Юк, юк, сабыр итегез, сүземне бүлмәгез... Мин нәрсә димәкче булам... Сез безнең икебездән — хатынымнан да, миннән дә яхшыдан гайре бернинди яманлык күрмәдегез, без сезне өебездә моңарчы һәрвакыт үз кеше, якын, хәтта кардәш кешебез сыман кабул итә килдек. Шәт, сез моны инкяр итмисездер бит?

Аягы йомшаграк җиргә туры килеп, Ромашов сөрлегеп куйды һәм ачыктан-ачык уңайсызлану белән авыз эченнән генә мыгырданып җавап бирде:

— Ышаныгыз, сезгә дә, Александра Петровнага да минем тирән рәхмәттән башка...

— Аһ, эш андамыни, эш бөтенләй рәхмәттә түгел.

Мин сездән бернинди рәхмәт сорамыйм,— диде Николаев, ачуы кабарып.— Мин сезгә фәкать хатыным турында әллә нинди пычрак, ялган сүзләр таралуын искәртмәкче булам... Хикмәт шунда: бу гайбәтләр... ну, ничек дип әйтергә...— Николаев, тынын ешрак ала башлап, яулыгы белән битен сөртте.— Кыскасы, бу гайбәтләрдә сезнең дә исем бар. Без, ягъни хатыным белән мин, һәркөн диярлек ифрат хурландыргыч, кабахәт эчтәлекле имзасыз хатлар алабыз. Аларны сезгә күрсәтүнең хаҗәте булмас... артык җирәнгеч эчтәлекле хатлар алар. Менә шул имзасыз хатларда язалар...— Николаев бер секундка сүзен әйтә алмый торды.— Ну, ничек дип әйтергә соң!.. имеш, сез — Александра Петровнаның сөяркәсе... имеш... ух, нинди җирәнгеч!.. Ну, фәлән дә төгән, янәсе... һәркөн яшерен рәвештә икәүдән-икәү очрашасыз, бу турыда бөтен полк белә, янәсе. Әнә шундый пычрак нәрсәләр язалар!

Николаев, тешләрен шыкырдатып, ачу белән җиргә төкерде.

— Ул хатларны кем язганын беләм мин,— дип, әкрен генә әйтеп куйды Ромашов, башын читкә борып.

— Беләсез?

Николаев туктады да тупас рәвештә Ромашовның җиненнән эләктереп алды. Искәрмәстән ташып чыккан ачу аның тышкы ясалма сабырлыгын берьюлы челпәрәмә китерде. Үгез күзләре киңәеп, елтырап акайды, йөзе кызарып бүртенде, ә дерелдәгән ирен кырыйларына куе төкерек саркып чыкты. Ул, алга таба иелә төшеп, Ромашовның йөзенә үз йөзен терәде дә ярсулы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Белгәч, ни өчен сез моңарчы дәшми йөрдегез! Аз гына вөжданы булган кеше сезнең хәлдә ул кабахәт җанварның күптән авызын каплар иде бит инде. Сез... армейский донжуан, аңлыйсызмы шуны, ә? Әгәр сездә бөртек кадәр генә намус дигән нәрсә булса...

Ромашов, ирексездән агарынып, нәфрәтле күзләре белән туп-туры Николаевның йөзенә кадалды. Аяк-куллары кисәктән коточкыч авыраеп, башы ничектер бушанып, җиңеләеп китте, йөрәге исә, каядыр түбәнгә, тирәнгә өзелеп төшеп, бөтен тәнне дерелдәтерлек гайрәт белән ярсып, авырттырып тиберченергә тотынды.

— Мин сездән миңа кычкырмавыгызны үтенер идем,— диде ул саңгырау тавыш белән, сүзләрен беркадәр сузарак төшеп.— Әдәплерәк сөйләшегез, миңа җикерергә сезнең бернинди хакыгыз юк.

— Мин сезгә җикерергә уйламадым да,— дип, һаман әле тупас, әмма баягыдан беркадәр әкренрәк тавыш белән җавап кайтарды Николаев.— Таләп итәргә хакым булса да, мин сезгә фәкать аңлатырга гына тырышам. Шул, әгәр сез Александра Петровнаның тапсыз, саф исемен чак кына хөрмәт итәсез икән, ул чакта элеге гайбәт, эзәрлекләүләргә кичекмичә чик куярга тиешсез.

— Яхшы, мин үз кулымнан килгәннең бөтенесен эшләргә тырышырмын,— диде Ромашов, коры гына итеп.

Шулай диде дә, кырт борылып, сукмакның нәкъ уртасыннан атлап, ары китеп барды. Әмма Николаев аны шундук артыннан куып җитте.

— Аннан соң... тик сез, зинһар, миңа ачуланмагыз... — дип, инде тәмам йомшарган һәм беркадәр аптыраганрак тавыш белән янә сүз башлады Николаев.— Инде сүзне бер башлаганбыз икән, күңелдәген ахырынача әйтеп бетерергә кирәк... Шулаймы?

— Бәлки, шулайдыр? — дип куйды Ромашов сорау катыш бер аһәң белән.

— Безнең, ягъни Александра Петровна белән минем, сезне ничек тәкъдир итүебез сезгә бик яхшы мәгълүм. Инде хәзер, мәҗбүрилектән чыгып дигәндәй, әгәр мин сезне... Аһ, сез үзегез дә күреп торасыз: бу кабахәт шәһәрчектә гайбәттән дә коточкычрак бүтән берни юк бит!

— Яхшы, мин сезгә бүтән килеп йөрмәмен,— диде Ромашов, моңсу гына итеп.— Сез миннән шул хакта үтенмәкче идегез бит, шулаймы? Ярар, мин риза. Хәер, сезгә бүтән килеп йөрмәскә дип миң үз-үземә күптән сүз биреп куйган идем инде. Берничә көн моннан элек, нибары биш минутка сезгә кереп, мин Александра Петровнага үзем алып торган китапларын биреп чыктым. Ышанығыз, бу минем сезнең өйдә соңгы күренүем булыр.

— Әйе... шулай булгач, димәк... — дип әйтә башлады Николаев һәм, уңайсызланып, янә сүздән туктады.

Офицерлар бу вакыт сукмактан шоссега борылганнар иде инде. Шәһәргә җитәргә әле тагы ике-өч йөз адым җир бар, ә сөйләшер сүз беткән, шуңа күрә алар бер сүз дәшмичә һәм бер-беренә борылып карамыйча әкрен генә янәшә атлап бардылар. Ни тегесенең, ни монысының тукталып калырга яисә борылып киргә китәргә кыюлыгы җитмәде. Шулай итеп, хәл минут саен киеренкеләнә һәм ялганрак төс ала бара иде.

Ярый әле, шәһәр урамына килеп керүгә үк буш извозчик очрады. Николаев аны шундук дәшеп туктатты.

— Әйе... шулай булгач, димәк,— дип, янә кабатлады ул, Ромашовка таба борылып.— Ярый, сау булып торыгыз, Юрий Алексеевич.

Алар кул бирешеп тормадылар, фәкать бармак очларын, хушлашкандай, фуражка козырекларына гына тидереп алдылар. Ләкин Николаев кузгалып китеп, аның таза, ак муены юлдан күтәрелгән тузан болыты эчендә ераклашып күздән югалгач та, Ромашовны кинәт шундый ачынулы ялгызлык хисе биләп алды ки, гүя аның гомереннән менә хәзер генә иң кадерле, иң мөһим бер зур кисәкне өзеп төшерделәр дә үзен дөньяви тормыштан бөтенләй читкә алып ташладылар.

Ул ашыкмыйча гына өенә таба атлады. Гайнан ишегалдында йөри иде. Хуҗасын ул ерактан ук көләч елмаеп, ак тешләрен дустанә ыржайтып, канәгать төстә каршы алды. Подпоручикның өстен салдырганда да ул шулай канәгать төстә елмаеп, гадәтенчә, баскан урынында кыбырсый-кыбырсый биенгәләп торды.

— Син әле ашамаган, ие? — дип, иптәшләрчә хәленә кереп, Ромашовтан сораштыра башлады ул.— Ач, ие? Хәзер җәмгыятькә йөгердем, сиңа обед китерәм.

— Бар, олакчы янымнан! — дип, чәрелдек тавыш белән җикереп җибәрде аңа Ромашов.— Бар, бар, чыгып кит, бүтән минем бүлмәгә кереп йөрисе булма. Аннан шул: кем генә сораса да — мин өйдә юк. Хет император хәзрәтләре үзләре килсә дә — өйдә юкмын.

Ул караватына ауды да, башы белән мендәр йомшагына тәмам күмелеп, тешләрен чытырдатып кысты. Аның күз алмалары әчетеп кызыша, бугазда ниндидер чит-ят бер нәрсә әле киңәеп, әле тараеп тынны кыса, ә күңелдә елау теләге көйри иде. Бу минутта аның чыннан да кайнар, ачы, татлы күз яше белән үксеп-үксеп елыйсы һәм шулай елап эчен бушатасы килде. Шул максатына ирешү өчен ул бүгенге көннең барлык михнәтле, рәнҗүле, хурлыклы вакыйгаларын кабат-кабат хәтерендә торгызырга, аларны юри тагы да рәнҗеткечрәк төстә, тагы да куерак буяуларга буяп күзалларга кереште; үзен читтән күзәтеп торган бер кеше сыман, әнә ул нинди бичара, бәхетсез, зәгыйфь бәндә, нахакка рәнҗетелгән, ташландык бәндә дип, үзенүзе кызгандырырга да тырышып карады. Ләкин күздән яшь һаман килми иде.

Аннары аның белән шактый сәер бер нәрсә булып алды. Үзенең фараз итүенчә, ул һич тә йокыга китмәгән, хәтта йокымсырый да башламаган, фәкать ниндидер кыска

бер мизгел эчендә караватында күзен йомып, уйсыз-фикерсез генә тик ятып торган иде шикелле. Һәм кинәт һич көтмәгәндә ул үзен яңадан уяу итеп, әүвәлге сагышлы халәтендә күрде. Ләкин бу юлы урамга караңгы төшкән иде инде. Шул рәвешчә, аның әлеге аңлаешсыз акыл торгынлыгы биш сәгатьтән артык дәвам иткән булып чыкты.

Шул чак Ромашовның үтереп ашыйсы килеп китте. Ул урыныннан торды, биленә кылычын тагып, иңбашына шинелен бөркәнде дә җәмгыятькә юл тотты. Җәмгыять клубы ерак түгел, бер ике йөз адымда гына иде; гадәттә, Ромашов анда урам ягыннан түгел, ә йортлар артыннан, ниндидер ялан җирләр, бәрәңге бакчалары, коймалар аша барып йөри һәм клубка һәрвакыт арткы ишектән керә иде.

Ашханәдә, бильярд бүлмәсе белән кухняда лампалар балкып яна; тәрәзәләр каерып ачып куелган, һәм шул тәрәзәләр аша төшкән тоник яктыда офицерлар клубының кысан, пычрак ишегалды, язу карасы түгелеп җәелгәндәй, кап-кара булып ялтырап күренә. Бүлмәләрдән исә сөйләшкән, көлешкән, җырлаган һәм бер-беренә шак-шок бильярд шарлары бәрелгән тавышлар яңгырап ишетелә иде.

Ромашов арткы ишекнең баскычына ук менеп җиткән иде инде, шул чак ашханәдән ишетелгән ачулы, мәсхәрәле таныш тавышка игътибар итеп, ул туктап калды һәм баскыч башыннан гәүдәсен ия төшеп, ике адымда гына торган ачык тәрәзә аша бүлмә эченә күз төшерде. Рота командиры капитан Сливаның бөкрерәк аркасын ул бер карауда ук таныды. Капитан, алга таба сузган кулын әле югары чөеп, әле түбән ташлап, тотлыга-тотлыга үзенең зарын сөйли иде:

— Б-бөтен рота б-бер кешедәй т-тигез атлап бара — ать! ать! ать! — ә ул берүзе, көтү алдындагы к-кәҗә тәкәсәдәй, т-тегендә-монда ташлана. О! о! — егылып үләрсең! — Слива шыксыз бер рәвештә, ашыгып-кабаланып, имән бармагы белән берничә мәртәбә һаваны бораулап алды.— М-мин аңа т-туп-туры әйттем: сез, мәйтәм, хөрмәтлем, б-бүтән ротага күчегез. П-полктан бөтенләй китсәгез, б-бигрәк шәп булыр, мәйтәм. Сездән нинди офицер чыксын, мәйтәм. Ниндидер ясалуы җитмәгән нәмәрсә...

Ромашов, ихтыярсыз бөрешеп килеп, күзләрен чытырдатып йомды. Аз гына кымшанса да, ашханәдәгеләр үзен шундук күреп алырлар һәм тәрәзәдән башларын тыгып карарга керешерләр кебек тоелды аңа. Шул рәвешендә ул берме, икеме минут кымшанмыйча басып торды. Аннары,

сулышын тәмам кысып, башын якасы эченә тагы да җыярак төште дә, аяк очларына гына баса-баса һәм адымын кызулый-кызулый, стена буйлап капкага таба кире китте, яктыртылган урамны йөгерә-чаба аркылы чыкты да каршы як койма күләгәсенә яшеренде.

Бу кичне Ромашов шәһәрнең урамнары буйлап бик озак йөрде. Кайсы, нинди урамда йөргәненә ул үзе бөтенләй диярлек игътибар итмәде, йөргәндә тик урамнарның караңгырак ягыннан барырга гына тырышты. Шулай каңгырып йөргәндә, ул бер мәртәбә Николаевлар өе янына да барып чыкты һәм, тукталып, ай яктысында яшел калай түбәләре белән салкын-сәер җемелдәп, агарып утырган йорт каршысында шактый вакыт басып торды. Урам гүя бөтенләй таныш түгел кебек: тып-тын, бернинди җан әсәре сизелми. Йорт һәм коймалардан төшкән тигез сызыклы ачык, анык күләгәләр урамны икегә бүлгән; аның бер ягы — дөм караңгы, ә икенче ягы — яп-якты, йомры таш җәйгән юл өсте исә майлагандай ялтырап, елкылдап күренә иде.

Куе кызыл төстәге калын пәрдәләр аша лампаның зур, җылы, түгәрәк тап сыман тонык уты саркып күренә. Ромашовның хәтта елыйсылары килеп китте, һәм ул, ике кулын да күкрәгенә кысып, үзалдына: «Сөеклем, син минем хәлемне аз гына булса да аңлыйсыңмы икән: мин сине үлеп яратам бит, синсез миңа күңелсез, моңсу, мин газапланам!» — дип пышылдады.

Шул чак аңарда үз хәлен Шурочкага ерактан, стена аша сүзсез генә ишеттерү, төшендереп бирү теләге туды. Һәм, кулларын тырнак аслары авыртканчы чытырдатып йодрыклаган, теш казналарын кысып, аркасында салкын кымыргыклар йөгерешүен сизгән бер хәлдә, ул бөтен ихтыярын бер ноктага туплап, үзалдына боерык сүзләре тәкрарлый башлады:

«Тәрәзәгә килеп урамга күз төшер... Пәрдә янына килеп бас. Диваныңнан тор да пәрдә янына килеп бас. Пәрдәне ачып, урамга кара, урамга кара, урамга кара. Ишетәсеңме, мин сиңа боерам: хәзер үк тәрәзә янына килеп бас!»

Әмма тәрәзә пәрдәләре селкенмәде. «Син мине ишетмисең! — дип, ачы бер рәнҗү белән янә үзалдына пышылдады Ромашов.— Хәзер син, бернигә илтифат итмичә, лампа төбендә, ирең янында, үзалдыңа балкып һәм бар нәрсәдән гафил булып, тыныч кына утырасың. Ah, йа раббым, йа раббым, мин нинди бәхетсез кеше!»

Ул, авыр уфылдап, башын түбән салындырды, арыган аякларын көч-хәл белән өстери-өстери ары атлады.

Шәһәр буйлап шулай каңгырып йөргәндә, ул ничектер бер мәртәбә Назанский торган квартирның да тәрәзәләре яныннан узып китте. Өйдә ут алынмаган иде, шулай булса да хуҗаның бүлмәдә эрле-бирле киләп сарып йөргән ак шәүләсен Ромашов тәрәзә аша бик ачык күрде, әмма, ни сәбәптәндер тирән куркуга төшеп, ул аңа дәшәргә җөрьәт итмәде.

Берничә көннән соң, шәһәр урамнары буйлап үзенең фантастик, саташулы диярдәй әлеге каңгырып йөрүләрен исенә төшергәч, Ромашовка алар гомер онытылмас күптәнге бер төш булып күз алдына килделәр. Һәрхәлдә, яһүдләр зираты янына ничек барып чыгуын ул үзе дә аңлатып бирә алмас иде. Бу зират шәһәр читендәге тау битенә урнашкан булып, ул тәбәнәк ак ихата белән тотып алынган һәм анда үзенә бер төрле серле тынлык хөкем сөрә иде. Йокыга талган һәм ай яктысында аксылланып күренгән үлән араларыннан әле монда, әле тегендә шәрә, салкын, һәммәсе бертөсле ташлар күтәрелеп тора, алардан җиргә нечкә, озын күләгәләр сузылган. Тирә-якта шылт иткән тавыш та юк, бар нәрсәдә ниндидер самими ялгызлык тантанасы, хозурлык хөкем сөрә иде.

Аннары Ромашов үзен шәһәрнең капма-каршы икенче ягына барып чыккан итеп күрде. Бәлки, бу йөрүләр чыннан да төш кенә булгандыр? Менә ул Буг елгасы аркылы салынган һәм кеше йөри-йөри такыраеп, шомарып беткән буа-плотинаның нәкъ урта бер җирендә ялгызы басып тора. Аяк астында гына, бер көйгә ярга бәрелә-сугыла, йокымсыраган, ялкау, куе тавыш белән су чупылдый, ә аның чак кына дулкынланып, тирбәлеп торган өсте буйлап шаярышып уйнаучы миллионлаган көмеш балыклар тулы тере, озын тасма сыман булып, ерактагы караңгы, тын, шомлы ярга таба ай нурының ялтыравык чагылышы сузылып яткан. Ромашовның тагы шул исендә: кая гына юл тотса да — урамнар буйлап йөриме ул, әллә шәһәр читенә чыгамы,— һәркайда аны чәчәккә күмелгән ак акацияләрнең тәмле, нәфис, хуш исе чолгап ала иде.

Әллә нинди сәер уйлар килеп бетте аның башына бу төнне. Ялгызлыкка тартым моңсу уйлар хәвефле, шомлы уйлар белән алышынды, бераздан алары урынына ниндидер вак, сабыйларча көлкеле уйлар килде. Шулай да аның зиһенен күбрәк бүгенге көннең рәнҗүләренә кагылышы булмаган хыялый уйлар биләде. Бер кичтә бар мөлкәтен

картада оттырган тәҗрибәсез уенчы кебек, ул, кинәт, бөтен дөньясын онытып, үзен гадәти тормышында бернинди үзгәреш булмаган бер кеше итеп күзалларга тотына иде. Янәсе, аның белән бернинди күңелсезлек, рәнҗүләр дә булмаган, ул, зифа буйлы, чибәр подпоручик Ромашов, тантаналы марш вакытында, янәсе, генерал каршысыннан менә дигән итеп, һәммә кешене сокландырырлык адым белән атлап узган; янәсе, менә хәзер дә ул иптәшләре белән бергә офицерлар клубының якты ашханәсендә утыра, ашый, эчә, көлә, күңел ача. Ләкин хыялының шундый күңелле бер моментында гына хәтер күгенә Федоровскийның җикеренүе, рота командирының зәһәрле сүзләре яки Николаев белән үзе арасындагы катгый сөйләшү калкып чыга да, Ромашов үзен янә гомерлеккә хур ителгән, рәнҗетелгән бәхетсез бер кеше итеп тоя башлый иде.

Эчке, яшерен тоем аны янәдән бая Николаев белән аерылышкан урынга кире алып килде. Бу вакыт Ромашов үз-үзен үтерү турында уйлана, ләкин катгыйлык һәм курку белән түгел, ә ниндидер яшерен, татлы-хозур бер хис белән уйлана иде. Бу очракта да аның тынгысыз фантазиясе үз-үзен үтерү турындагы коточкыч уйны төрле төсләргә буяп, бизәп-матурлап күзалларга омтылды.

«Менә Гайнан хуҗасының бүлмәсеннән атылып килеп чыга. Куркудан чырае качкан, күзләре акайган, үзе дердер калтырана. Менә ул халык белән шыгрым тулы офицерлар клубына уфылдап килеп керә, аны күрүгә һәммә кеше ихтыярсыз урыннарыннан сикереп тора. «Ваше высокоблагородие... подпоручик... атылып үлде!» — ди, имеш, Гайнан, сулышын көчкә алып. Клубта ыгы-зыгы башлана. Кешеләрнең йөзләре кинәт агарынып китә, күзләрендә коточкыч курку галәмәте калкып чыга. «Кем атылып үлгән? Кайда? Нинди подпоручик?» — диләр, имеш, алар. Шунда кемдер Гайнанны танып ала: «Әфәнделәр, Ромашовның денщигы ич бу, аның чирмеше»,— ди. Барысы да йөгерәчаба Ромашов торган квартирга ташланалар; кайберәүләр баш киемнәрен киргә дә онытканнар. Менә ул, Ромашов, үзенең караватында хәрәкәтсез ята, имеш. Идәндә кан күле, шунда ук револьвер аунап ята. Гаскәри типтагы Смит-Вессон револьверы ул... Кечкенә бүлмәгә кереп тулган офицерларны аралый-ера, карават янына полк докторы Зойко якынлаша. «Туп-туры чигәсенә! Вәссәлам!» — ди, имеш, ул әкрен генә. Тирән тынлык эчендә кайсысыдыр шундый ук әкрен-моңсу тавыш белән: «Әфәнделәр, ичмасам баш киемегезне салыр идегез!» — дип әйтеп куя. Күп кенә офи-

церлар чукыну галәмәте ясап алалар. Ул арада Веткин өстәл өстеннән бер язу табып ала да шуны кычкырып укып күрсәтә. Анда карандаш белән каты басып шундый сүзләр язылган, имеш: «Кайгылы-хәсрәтле бу авыр тормыштан тәмам туйдым, үз теләгем белән үләм, һәммәгезне дә бәхиллим! Үлемем турында читләтеп кенә әниемә хәбәр итегез. Георгий Ромашов». Офицерлар сүзсез генә бер-берсенә гаепле күз карашы ташлашып алалар; һәрберсенең йөзендә яшерен, борчулы бер үк фикер катып калган: «Аны без үтердек!»

«Менә сигез иптәше, ефәк япма ябылган табутны күтәреп, акрын гына зиратка таба баралар. Табут артыннан офицерлар төркеме атлый. Алар артында — алтынчы рота. Капитан Сливаның тәмам күзе-кашы җимерелгән. Елый-елый инде күзләре шешенеп беткән Веткин хәзер, урамда, күз яшен яшерергә тырышып атлый. Лбов исә — әйбәт, сөйкемле Лбов! — хәсрәтен һич яшереп тормыйча, ачыктан-ачык үксеп елап бара. Язгы һавада матәм маршының кайгырып үксегән җан тетрәткеч моңсу тавышы яңгырап ишетелә. Озатучылар төркемендә, полкның барлык хатын-кызлары белән бергә, Шурочка да бар, имеш. «Мин аны үпкән идем! Мин аны ярата идем! Теләсәм, мин аны бу коточкыч адымыннан туктатып, аны коткарып кала да алган булыр идем бит!» — дип, үзалдына ачынып уйлый, имеш, Шурочка. «Юк, инде соңга калдың шул!» — дип, күңеленнән җавап кайтара, имеш, аңа Ромашов, хәсрәтле елмаеп».

«Җеназа артыннан иярген офицерлар үзара шыпырт кына сөйләшеп баралар. «Аһ, шулкадәр кызганыч, бичара! Нинди әйбәт иптәш иде бит, нинди әйбәт, сәләтле офицер иде!.. Әйе, аңлый алмаганбыз шул без аны!» Матәм маршы торган саен хәсрәтлерәк үкси: бу «Батырның үлеменә» дигән Бетховен музыкасы, имеш. Ә Ромашов, тәне мәңгегә суынган хәлдә, табутында хәрәкәтсез ята, иреннәрендә мәңгелек елмаю катып калган. Күкрәге өстендә исә — кечкенә генә миләүшә чәчәкләре бәйләме. Аны анда кем куйган — беркем дә белми, имеш. Ромашов һичкемгә дә ачу тотмый, һәммәсен бәхилли: Шурочканы да, Сливаны да, Федоровский белән корпус командирын да. Шуңа күрә аны сагынып кайгырышмасалар да ярый. Бу фани тормыш өчен артык саф, артык гүзәл кеше иде шул ул! Аңа анда яхшырак булачак!»

Ромашовның керфекләре күз яшенә чыланды, ләкин ул аларны сөртергә уйламады да. Үзен гаделсезгә рәнҗетел-

гән һәм үлгәч сагынып искә алынган кеше итеп күрү аның күңелендә чиксез бер рәхәтлек хисе тудырды.

Хәзер ул баягы чөгендер басуы кырыйлатып атлый иде. Аяк астында аклы-каралы чуар, чуалчык таплар сыман булып тәбәнәк, юан сабаклы чөгендер төпләре тезелеп киткән. Ай нурыннан яктырып җәйрәп яткан кыр Ромашовны әйтерсең төрле яктан һаман баса-кыса бара сыман иде. Подпоручик кечкенә генә бер калкулык өстенә менде дә каршындагы тимер юл чокыры ярында беравык тукталып торды.

Чокырның бу як яр итәге дөм-караңгыда булып, аргы як яры айның аксыл-соргылт нурына чумган һәм андагы һәрбер үлән сабагын аермачык күреп булыр шикелле иде. Яр үзе түбән таба бик текә төшә һәм аның упкындай караңгы төбендә беленер-беленмәс кенә булып рельслар ялтырый, ә чокырның аръягында исә, ялан кыр уртасында, рәт-рәт тезелгән очлы кыеклы палаткалар агарып күренә иде.

Ромашов яр башыннан бераз түбәндәрәк чокыр буйлатып сузылган тар гына иңкүлеккә төште дә чирәмгә утырды. Ару һәм тамагы ачыгудан аның күңеле болгана, тез буыннары калтырый иде. Тирә-якта җәйрәп яткан ялан кыр, яртылаш караңгыга, яртылаш якты ай нурына чумып утырган бу чокыр эче, аксыл-тонык күк йөзе, чыклы чирәм — боларның һәммәсендә ниндидер сизгер, яшерен бер тынлык хөкем сөреп, колакта үзенә бер төрле чың барлыкка килә иде. Тик ара-тирә генә, бу тирән тынлыкны бозып, станциядә маневр паровозы кычкыртып куя, һәм аның эче, өзек-кискен тавышы тирә-якның сәер хәрәкәтсезлеге эчендә җанлы, хәвефле, янаулы бер кисәтү булып яңгырый сыман иде.

Ромашов җиргә сузылып чалкан ятты. Күк гөмбәзендә хәрәкәтсез асылынып торган аксыл, җиңел болытлар өстеннән ашыга-ашыга тулы ай йөзә. Иксез-чиксез, буш, салкын шул күк гөмбәзе белән җир арасы гүя мәңгелек шом, мәңгелек сагыш белән өртелгән кебек. «Анда — тәнре үзе!» — дип уйлап куйды Ромашов һәм кинәт, үз-үзен кызганудан сабыйларча күңеле нечкәреп, хәсрәт, рәнҗү, ачыну тулы тавыш белән үзалдына ашкынып, тәэсирләнеп пышылдарга тотынды:

— Йа раббым! Ник син мине мәрхәмәтеңнән мәхрүм иттең? Мин синең тузан бөртегедәй кечкенә, зәгыйфь бер бәндәң ич, синең алда нинди гөнаһым бар минем, әйтче, раббым? Син мәрхәмәтле, игелекле бит, син барын белеп-

күреп торасың,— шулай булгач, нигә син миңа, үз колыңа, шундый гаделсезлек күрсәтәсең?

Шул чак Ромашов, үз сүзеннән үзе курка калып, ашыгычлык белән янә кайнар төстә тезеп китте:

— Юк, юк, кичер мине, мәрхәмәтле аллам, кичер мин гөнаһлы бәндәңне! Мин сиңа бүтән тел тидермәм.— Һәм ул бөтен гаебен йоларлык күндәм, буйсынучан тавыш белән өстәп әйтте.— Мин синең иркеңдә, мине теләгәнеңчә хөкем ит. Синең һәр эмереңне мин рәхмәт хисе белән кабул итәчәкмен.

Ул шулай сөйләнде, әмма бер үк вакытта аның күңеле төбендә илаһи зат бу ялваруларны ишетмәсме дигән сабыйларча беркатлы-гөнаһсыз өмет чаткысы да уянып куйды. Янәсе, аллаһе тәгалә, аның буйсынучан сабырлыгын күреп, йомшарып китәр дә, кызганып, аңа могҗизаи мәрхәмәтен күрсәтер. Ул чакта инде бүгенге барлык хәсрәт-кайгылар төштәге саташу гына булып калыр.

«Син кай-да?» — дип, ашыгып, ачуланып кычкыртты паровоз.

Ә икенче берәве калын, сузынкы, янау тавышы белән аңа җавап бирде:

«Мин — сез-зне!»

Шул вакыт чокырның каршы яктагы ай яктырткан ярында, аның иң түбә җирендә, нәрсәдер шыштырдады да күзгә ниндидер карачкы чалынып киткәндәй булды. Ромашов, яхшырак күрер өчен, чак кына башын күтәрде. Кешегә аз охшашы булган һәм тонык-соргылт ай яктысында әйләнә-тирәдәге үлән төсеннән бөтенләй диярлек аерылмаган ниндидер соры, йомры бер нәрсә яр башыннан тиз-тиз түбән төшеп бара; аның хәрәкәт юнәлешен фәкать күләгәсе һәм аягы астында шыбырдаган туфрак кантарлары тавышы буенча гына чамаларга була.

Менә ул, чокыр төбенә төшеп җитеп, тимер юл аша чыга башлады. «Әллә инде солдат? — дип үзалдына борчылып уйлады Ромашов. — Һәрхәлдә, бу — кеше булырга тиеш. Ләкин кем булыр икән? Болай сәер кыяфәттә тик исерек яки берер саташкан, исәр бәндә генә йөрергә мөмкин».

Соры шәүлә, тимер юлны кисеп чыгып, чокырның күләнкәле ягына күчте. Хәзер инде аның солдат икәнлеге аермачык күренә иде. Ул ничектер ава-түнә, әкрен генә атлый, вакыт-вакыт Ромашовның күзеннән дә югалып тора иде. Ниһаять, ике-өч минут узгач, Ромашовның каршысын-

да чокыр төбеннән ашыкмыйча гына күтәрелеп килгән чәчсез-ялан, йомры бер баш күренде.

Айның тоник яктысы солдатның йөзенә туп-туры төшә, шуңа күрә Ромашов аны бер карауда таныды. Бу — Хлебников иде. Фуражкасын кулына тоткан, күз карашын гафил, исәр бер кыяфәттә каядыр алга төбәгән. Гүя ул, үз ихтыярыннан тыш, ниндидер серле, яшерен, чит-ят бер көчкә буйсынып атлап бара. Ул, офицерның шинель чабуына ышкылып дигәндәй, бөтенләй янәшәдән узып китте. Аның күз бәбәкләрендә елтыр, очлы төрткеләр булып ай яктысы чагылып күренә иде.

— Хлебников! Бу синме? — дип дәште аңа Ромашов.

— Ай аллам! — дип кычкырып җибәрде солдат, коты алынып, шып туктады да, бөтен гәүдәсе агач яфрагыдай калтыраган хәлдә, Ромашовка таба борылып басты.

Ромашов тиз генә яткан җиреннән күтәрелде. Хлебниковның кыйнап эштән чыгарылган җәрәхәтле, шешенке битен, канлы иреннәрен, җимерелгән күз-кашларын ул хәзер аермачык күрде. Күз күреме болай да саташучан төнге яктылыкта җәрәхәтләр тагы да зураеп, шомлырак булып күренәләр һәм солдатның йөзенә үлек төсе өстиләр иде. Ромашов, Хлебниковның йөзеннән күзен алмыйча, үзалдына: «Менә шушы кеше, минем белән берлектә, бүген бөтен полкны хурлыкка калдырды. Без икебез дә бичара кешеләр», — дип уйланды. Аннан кинәт, үзе дә абайламастан, кулларын солдатның ике иңбашына куйды да ягымлы, иркәләүле тавыш белән:

— Кая болай юл тоттың? Ни булды сиңа, туганкай? — дип сорады.

Хлебников аңа ниндидер кыргый, ятсынулы, аптыраулы караш ташлап алды һәм шундук йөзен читкә борды. Аннары аның чапылдап авызы ачылганы һәм хырылдауга охшаш ниндидер мәгънәсез, аңлаешсыз кыска бер сүз әйткәне ишетелде. Ромашовның корсагы һәм күкрәге эчендә гадәттә кирәгеннән артык кытыклаганда яисә һуш киткәндә хис ителә торган бер кату чыгып, нәрсәдер авырттырып сызлап куйды.

— Сине кыйнадылар, әйе? Ник дәшмисең? Шулаймы? Кая, утырыйк әле шунда.

Шулай дип, Ромашов Хлебниковны җиңеннән тотып түбән өстерәде. Тегесе карышмыйча-нитмичә, җыелмалы-сүтелмәле манекен сыман, ничектер килешсез-килбәтсез бер рәвештә, чыклы үлән өстенә, подпоручикның янәшәсенә авып төште.

— Кая бара идең? — дип янә сорады Ромашов.

Хлебников дәшмәде, аякларын үлән өстенә агачтай сузып, гайре табигый кыяфәтендә тик кенә утыра бирде. Кинәт аның башы, кискен-өзек хәрәкәтләр белән, әкрен-әкрен түбән салына башлады һәм авызыннан баягы кебек кыска хырылдау авазы өзелеп чыкты. Ромашовның күңелендә янә баягы әрнеткеч хис кыймылдап куйды.

— Син качмакчы идеңме? Башыңа ки әле. Менә нәрсә, Хлебников, мин хәзер сиңа начальник түгел, мин үзем дә, синең кебек, ялгызлыктан тилмергән, үзен-үзе кая куярга аптыраган бәхетсез, бичара бер бәндәмен. Сиңа кыен, әйе? Авыртамы? Әйдә, ачыктан-ачык бер сөйләшик әле. Бәлкем, син үз-үзеңә кул салырга теләгәнсеңдер, ә? — дип, бер сораудан икенчесенә сикерә-сикерә, пышылдап сөйләнде Ромашов.

Хлебниковның бугазында тагы нәрсәдер быгырдап, иреннәре чапылап куйды, ләкин кеше аңлардай сүзе ишетелмәде. Шул вакыт Ромашов аңа игътибар белән карап куйды һәм аның бөтен әгъзалары — башы да, теш казналары да туктаусыз дер-дер калтырап торуын күрде. Секунд эчендә офицерның җанына тирән шом йөгерде. Борчулы, мәшәкатьле бу төн, бу ялгызлык, бөтен этрафка тигез булып таралган тонык-җансыз, соргылт бу ай яктысы, аяк астында гына төпсез упкындай караеп яткан бу тирән чокыр эче һәм, ниһаять, янәшәдә генә бер сүз сөйләшмичә калтырап утырган, кыйнау-рәнҗетүләрдән шашар дәрәҗәгә җиткән солдат — болар һәммәсе Ромашовка ниндидер мәгънәсез, газаплы бер төш булып, үзенең инануынча, кешеләр фәкать дөнья беткәндә генә кичерергә тиешле үтә шомлы, саташулы төш булып тоелдылар. Ләкин кинәт аның күңелен иксез-чиксез кызгану, бөтен борчу-мәшәкатьләрен оныттырырдай кайнар бер теләктәшлек хисе биләп алды. Һәм бу зәгыйфь, бичара солдат янында үз-үзен олы, акыллы кеше итеп, ә үзенең барлык кайгыларын аныкы белән чагыштырганда бөтенләй чүп итеп тойган бер хәлдә, ул Хлебниковны муеныннан иркәләп, кысып кочаклады да үзенә таба тартып китерде һәм кайнар тәэсирләнү белән инанып-инанып сөйләнергә тотынды:

— Хлебников, син бик газапланасың, әйе? Мин дә газапланам, туганкай, минем дә хәлләр әйбәт түгел, чын менә. Дөньяда ниләр бар да ниләр эшләнә — берсен-бер аңламыйм мин. Бөтенесе — ниндидер мәгънәсез кыргыйлык, рәхимсез, шәфкатьсез бер хорафат, чүп. Ләкин һәммәсенә

түзәргә туры килә, һәммәсенә түзәргә туры килә, туганкай. Шулай кирәк.

Хлебниковның салынкы башы кинәт Ромашовның тезләре өстенә сыгылып төште. Һәм, тез өстенә шулай йөзтүбән капланган хәлдә, ул офицерның аякларын кысып кочаклады да, бөтен гәүдәсе белән калтырап, көзән җыергандай тартышып-боргаланып, сулкылдый-сулкылдый үксеп еларга кереште.

— Түземем калмады минем, барин... мин бүтән түзә алмыйм, түзә алмыйм... — дип, ыңгырашып пышылдады Хлебников.— Ай, барин... Кыйныйлар, көләләр... взводный акча сорап җәфалый, отделенный туктаусыз җикеренә... Каян алыйм ди мин акча? Авыр күтәреп эчем төшкән минем... бала чагымда ук әле... Бүсер миндә, барин... Ай аллам, ай аллам!

Ромашов үзенең тезләре өстендә бәргәләнә-бәргәләнә сулкылдап елаган солдатның башына таба йөзен ия төште. Борынга шундук юынмаган, шакшы тән исе, юрган урынына йәри-йөри сөрсеп, ачып беткән дымлы шинель исе килеп бәрелде. Офицерның бөтен җаны тетрәп, күңелен әйтеп биргесез тирән сагыш, курку, аптырау, ачыну, кызгану хисе биләп алды. Һәм, солдатның кыска, каты чәчле шакшы башына әкрен генә бите белән орынып, ул чак кына ишетелерлек итеп, ихлас күңеленнән:

— Туганым, кардәшем минем! — дип пышылдады.

Хлебников офицерның кулын элэктереп алды, һәм Ромашов үзенең учына җылы күз яше тамуын һәм чиркандыргыч салкын, ябышкак иреннәр орынуын тойды. Ләкин ул кулын тартып алырга җөрьәт итмәде, үпкәләгән баланы тынычландырырга тырышкан ягымлы ата сыман, солдатка төрле юату, үгет-нәсихәт сүзләре пышылдый бирде.

Аннары ул Хлебниковны лагерьга кадәр озатып куйды. Рота буенча дежур унтер-офицер Шаповаленконы чакыртып, аңа кичекмичә Хлебниковны дневальныйлыктан азат итәргә боерды. Палаткадан йокылы кыяфәттә авызын зур ачып исни-исни һәм кашына-кашына бер кат эчке күлмәктән килеп чыккан Шаповаленко:

— Ваше благородие, аны алыштырырга вакыт җитмәгән бит әле!.. — дип карышып маташкан иде дә, Ромашов:

— Сөйләшмәскә! — дип, аны шундук кырт кисте.— Иртәгә рота командирына мин шулай боерды дип әйтерсең... Ә син иртәгә минем янга кил, ярыймы? — диде ул аннары, Хлебниковка таба борылып.

Тегесе, рәхмәт белдергән кыюсыз чырай белән, сүзсез

генә аңа карады. Шул чак палаткаларның берсендә пышпыш сөйләгән тавыш ишетелеп, Ромашовны тукталырга һәм сүзгә колак салырга мәҗбүр итте. Кемдер буылып чыккандай басынкы тавыш белән көйләп-вәзенләп әкият сөйли иде:

— Шу-уннан әлеге шайтан теге солдат янына үзенең иң шәп сихерчесен җибәрә. Шул, килә дә бу сихерче, әйтә: «Солдат, әй, солдат, мин сине ашаймын!» — ди. Ә солдат җавабында болай ди моңа: «Юк, син мине ашай алмыйсың, мин бит сихерче!» — ди...

Ромашов янә баягы тимер юл тарлавыгына килеп җитте. Тормышның мәгънәсезлеге, аңлаешсыз буталчыклыгы аның күңел хисләрен тәмам өметсезлек чигенә китереп терәгән иде. Яр башында туктап, ул күзләрен югары күтәрде һәм күк йөзенә текәлде. Анда, баягы кебек үк, бетмәс-төкәнмәс шом белән өртелгән, чит-ят, салкын киңлек җәйрәп ята. Кинәт Ромашов, үзе дә белештермичә дигәндәй, кулларын йодрыклап башы өстенә күтәрде дә, аларны ярсып болгый-болгый, бөтен җен ачуы белән кычкырып җибәрде:

— Әй син! Карт алдакчы! Әгәр барысына көчең җитә икән, әйдә... күрсәт кодрәтеңне: мин менә хәзер аякларымны сындырыйм!..

Шулай дип, ул күзләрен чытырдатып йомды да текә ярдан түбән ташланды, ике-өч атлауда рельсларны сикереп чыгып, туктамый-нитми, эһ дигәнче каршы як яр башына менеп җитте. Еш-еш сулыш алудан аның борын тишекләре киңәеп ачылган, күкрәк читлеге исә туктаусыз бер күтәрелеп, бер төшеп тора иде. Шулай булса да ул бу вакыт күңеле төбендә кисәк кенә ниндидер үтә гайрәтле, горур, ярсулы бер каһарманлык хисе уянып куюын тойды.

XVIII

Шушы төннән соң Ромашовның халәте рухиясендә кискен үзгәреш туып, ул офицерлар җәмгыятеннән торган саен читләшә башлады, клубка танца кичәләренә йөрүдән туктады, ашауны да күбрәк өендә ашады, аракыдан исә бөтенләй бизде. Берничә көн эчендә ул гүя кисәк кенә олыгаеп, җитдиләнеп китте, кешеләргә, тирә-ягындагы әйберләргә ничектер искитмәүчән, моңсу бер күз белән карый башлады. Моны ул үзе дә ачык сизде һәм еш кына, үзендәге шушы үзгәрешне аңларга тырышып, кайчандыр бик күптән китаптан укыпмы, әллә ишетепме хәтердә кал-

ган сәер бер кагыйдәне исенә төшергәләде. Бу кагыйдә буенча кеше гомере, янәсе, ниндидер «люстрларга» бүленә; һәрбер люстр җиде ел тәшкил итеп, шул җиде ел эчендә кешенең кан һәм тән составы бөтенләй алышына, шуңа бәйле рәвештә фикер-хисләре, холкы да үзгәрә, имеш. Ә Ромашовка күптән түгел генә егерме бер яшь тулган иде.

Солдат Хлебников аның янына бер чакыруда гына килмәде килүен, ләкин икенче тапкыр күреп чакыргач килде. Аннары ул ешрак килеп йөри башлады.

Баштарак Хлебников үзенең бөтен холкы, тотышы белән кыйнала-кыйнала тәмам кулдан бизгән, үзенә таба дустанә якынлашкан кешедән дә өркеп кача торган ач, килмешәк этне хәтерләтә иде. Ләкин тора-бара офицерның ягымлы игътибары аның туң йөрәген әкренләп җылыта, эретә башлады. Ахырда Ромашов, кызганулы үкенечле бер хис кичергән хәлдә, аның бөтен тормышы белән җентекләп танышты. Өйдә — әнисе белән исерек этисе, ярым җүләр абыйсы һәм дүрт кечкенә сеңелесе бар икән; игәр җирләре юк, аны бернинди хаксызга һәм көчләп җәмәгать җыены кире тартып алган; торган урыннары — җимерек бер алачык, анысы да шул җәмәгать милке; балаларның олыраклары читләрдә ялланып эшли, кечерәкләре өй борынча хәер сорашып йөриләр икән. Шуңа күрә Хлебников өйдән бернинди ярдәм алмый, яллы эштә эшләргә исә аның көче-хәле юк. Ә солдатта аз гына да акчасы булмаган кешегә тормыш итүе бик кыен: ни чәен, ни шикәрен алып булмый, хәтта юынырга сабын да таба алмыйсың. Шул ук вакытта взводный белән отделенныйны әледән-әле солдатлар буфетына алып барып, аракы белән сыйларга кирәк — 22 1/2 күләмдәге айлык жалунья соңгы ярым тиененәчә әнә шул башлык кешеләргә бүләккә китә дә бетә. Болар өстенә — көн саен өзлексез кыйнау да көлү, мәсхәрә итү, нәүбәттән тыш эллә нинди авыр, күңел ятмас эшләрдә интегү.

Ромашов Хлебниковның сөйләгәннәрен тыңлады һәм тирән гажәпсенү, хәсрәт, курку эчендә шушы Хлебниковныкы кебек үк язмышка дучар булган йөзләгән башка солдатларны күз алдына китереп бастырды. Әлбәттә, аларның һәрберсенең үзләренә генә хас кайгы, шатлыклары бар, әмма тыштан караганда алар барысы да үз наданлыклары, уртак коллык, түрәләр изүе, көчләве һәм кимсетүе астында шәхси үзлекләрен югалткан тоташ бер масса булып кабул ителәләр. Иң аянычлысы тагы шунда, бер генә офицер да шушы бертөрле соры, күндәм, мәгънәсез чырайлы Хлеб-

никовларны тере кешегә исәпләми, ә рота, батальон, полк исемнәре белән аталган ниндидер механик бер берәмлек итеп санап килә. Соңгы вакытларга кадәр хәтта Ромашов үзе дә нәкъ шундый фикердә тора иде...

Ромашов ярдәм йөзеннән Хлебниковка беркадәр акча эшләп табу ягын җайлады. Офицерның гади солдатка күрсәткән бу сәер химаячелеген тиздән ротада да сизеп алдылар. Кайчакны Ромашов үзе дә күргәләде: унтер-офицерлар ул бар чагында Хлебниковка мыскыл катыш үтә ягымлы, төче-баллы тавыш белән күрәләтә ялагайланып эндәшәләр иде. Моны хәтта капитан Слива да сизде булса кирәк. Һәрхәлдә, ара-тирә ул, күзләрен бушлыкка тегәп, үзалдына ачулы мыгырданып куя:

— И-исең к-китәр кыланышларына. Л-либераллар басты дөньяны. Р-ротаны аздыралар. С-солдатны аны к-каезларга кирәк, ә алар аның белән төчеләнеп маташалар,— ди иде.

Хәзер, кешеләрдән читләшеп, буш вакыты күбәйгәч, Ромашовның башындагы уйлар торган саен куера, катлаулана бара иде. Үткән айда арест астында өйдә утырган чагындагы кебек, хәзер дә ул әллә нинди чит-ят, сәер уйлар, ачышлар белән таң калып яшәде. Андый уйлар аның башына гадәттә хезмәттән кайткач, кичен, төнге бөҗәкләрнең бертөрле гүелдәвен тыңлап һәм шәфәкъ төсе сүнә барган күк гөмбәзенә карый-карый тын бакчада йокыга талган куе агачлар арасында бер ялгызы моңаеп-хәсрәтләнеп йөргән чакта килә торган иде.

Эчке тормышының бу яңа сәхифәсе үзенең байлыгы, күп төрлелеге белән аны тәмам шаккатырды. Гадәти, гади генә бер нәрсәдә — кеше фикерендә шундый күп төрле шатлыклар, гайрәт, шундый мавыктыргыч төсләр, буяулар яшеренеп ятар дип ул элек уена да китерми иде.

Ромашов инде белә иде: хәрби училищеда алган белеме өчен түләнергә тиешле өч еллык мәҗбүри хезмәт срогы бетүгә, ул һичшиксез армиядән китәчәк, запаска чыгачак. Ләкин штатский тормышта үзенең нишләячәген Ромашов әле хәл итеп өлгермәгән иде. Шуңа күрә ул үзенә кулай булырдай эш урыннарын бер-бер артлы күңеленнән барларга тырышты: акциз, тимер юл, сәүдә, берәр утарга идарәче булып керү, департамент. Һәм шул вакыт, дөньяда кешеләр шөгыльләнә торган чиксез күп эш, кәсепләрне бөтен төрлелегендә беренче тапкыр күз алдына китереп, ул үзалдына гаҗәпләнеп куйды. «Ул кәсепләрнең бер төрлесе көлке, мәгънәсез, бер төрлесе куркыныч яки ифрат җирән-

геч, пычрак,— дип уйланды Ромашов.— Каян килеп чыктылар икән алар? Мәсәлән, төрмәчеләр, акробатлар, сөял куллы операторлар, бәдрәф чистартучылар, эт йоны кыркучылар, жандармнар, фокусчылар, тәннәре белән сату итүче хатыннар, мунчачылар, хайван дәвалаучылар, кабер казучылар, шымчылар бу дөньяда каян һәм ничек барлыкка килде икән? Әллә, югыйсә, кеше акылы уйлап чыгарган һәртөрле эшкә-кәсепкә, хәтта аның иң очраклы, буш, иң четерекле яки мәрхәмәтсез, бозык дигәненә дә, шундук башкаручысы, хезмәтчесе табыла бара микән?»

Уйлары шул рәвешчә тагы да тирәнгәрәк киткәч, аны янә икенче бер нәрсә гажәпләндерде: интеллигенциягә бәйле профессияләрнең күпчелеге, төптән караганда, кеше намусына ышанмауга нигезләнеп, асылда тормыштагы шул ук бозыклык, тәртипсезлек файдасына хезмәт итә икән ләбаса. Башкача булганда, ягъни кешелек дөньясы инде камиллек дәрәҗәсенә җиткән булса, әлеге конторчы, бухгалтер, чиновник, полиция, таможня, контролер, инспектор һәм тәртип күзәтүче дигәннәренең бу тормышта нинди хаҗәте булыр иде икән?

Ромашов шулай ук бүтән төрле профессияләр турында — шөгыльләре буенча һәрвакыт кешенең җаны белән, уй-хисләре һәм газаплары белән якыннан эш итүче руханилар, докторлар, педагоглар, адвокатлар һәм судьялар турында да уйланды. Һәм ихтыярлы-ихтыярсыз шундый күңелсез нәтиҗәгә килде: бу категория кешеләре, башкаларга караганда да туң йөрәкле булып, салкын-үле формалистика, күнегелгән һәм хурлыклы битарафлык, ваемсызлык сазлыгына тагы да тизрәк бата баралар икән. Дөрес, боларга капма-каршы икенче бер категория кешеләрен дә күз алдына китереп бастырды Ромашов. Дөньяның, җирнең тышкы ягын матурлаучы, аңа ямь бирүче инженерлар, архитекторлар, уйлап табучылар, фабрикантлар, заводчылар иде болары. Ләкин, гомум көч белән кешелек тормышын гажәеп гүзәл һәм җайлы итеп корырга бөтен мөмкинлекләре булуга карамастан, бу кешеләр дә фәкать байлык хакына гына хезмәт итәләр. Аларның һәрберсе үз тиресе өчен кан калтырап тора, үз балалары һәм ояларына хайваннарча мәхәббәт, җанлы тормыштан курку аларны бер урынга бәйләп куйган, шуңа күрә аларның һәммәсе фәкать акчага гына табына. Шулай булгач, бичара Хлебниковның язмышын кем рәтләсен дә, кем аны ашатып, акылга өйрәтеп, аңа: «Бир кулыңны, туган!» — дип әйтсен.

Менә шул рәвешчә, ифрат әкрен һәм ышанычлы-ыша-

ныҫсыз адымнар белән дигәндәй, Ромашов тормыш күренешләренә торган саен тирәнрәк керә барды. Элек аңа барысы да бик гади күренә иде. Янәсе, кешелек бер-берсеннән ныҡ аерылып торган тигезсез ике кисәккә бүленгән: берсе, кечкенәсе — офицер халкы, икенчесе, гаять зур һәм нәсел-нәсәпсез, үзенчәлексез кисәге — штатскийлар, ягъни, бүтәнчә әйткәндә, сукбайлар, мокытлар, өтек койрыклар. Болардан офицер халкы дигән өлеше көч-гайрәт, власть, мундир намусы кебек зур өстенлекләр белән файдалана; шул ук вакыт алар, тылсымлы мундир белән бергә, ни өчендер, батырлык, физик көч, горурлык, эрелек шикелле сыйфатларга да ия дип уйланыла. Шуңа күрә алар әлеге күпчелек өлешкә — штатскийларга жирәнеп карыйлар; штатский кешене тиктомалга сүгеп яки кыйнап ташлау, аны мыскыл итү, әйтик, аның борынына төртеп янган папирос сүндерү яки башындагы цилиндрын колакларына хәтле батырып кигезеп кую — болар һәммәсе офицер халкы арасында мактауга лаек бер батырлык санала; әле училищеда чакта ук яшь юнкерлар бу хакта бер-берсенә селәгәйләрен агыза-агыза, мактанышып сөйли торганнар иде.

Һәм менә хәзер, бу чынбарлыктан гүя читкә китеп, аңа каяндыр ерактан, ниндидер яшерен урыннан ярык аша карагандай төбәлеп карагач, Ромашов ялган батырлык нурына өртелгән бу гаскәри хезмәтнең гомумкешелек ялгышы белән туган хурлыклы, мәрхәмәтсез бер нәрсә икәнлеген әкренләп-әкренләп аңлый башлагандай булды. «Тыныч заманда, беркемгә бернинди файда китермичә, бүтәннәр тапкан икмәкне, итне ашап, бүтәннәр теккән киемне киеп, бүтәннәр корган йортларда торып, дөнья корытып яткан, ә сугыш вакытында үзләре кебек үк кешеләрне һич мәгънәсезгә үтерү, гарипләтү белән шөгыльләнгән бу сословие ничек әле шулай яши ала?» — дип, үз-үзенә сорау бирде Ромашов.

Тирәнрәк уйланган саен, аның башында бер фикер ачыклана барды: дөньяда кеше өчен горурланып сөйләрлек фәкать өч кенә шөгыль бар икән, ул да булса — фән, сәнгать һәм ирекле физик хезмәт. Шушы фикер аңардагы күптәнге хыялны — әдәби эш белән шөгыльләнү хыялын яңадан тергезеп жибәрде. Кайчак, кулына чын илһам, зәвык белән язылган берәр әйбәт китап төшеп, шуны укыганда, Ромашов үзалдына ачынып уйлап куя: «Йа ходай, нинди гади, аңлаешлы, боларны бит мин үзем дә күпме уйладым, баштан кичердем. Моны мин дә яза алган булыр идем ләбаса!» — ди иде. Аңарда хәрби тормыш, аның коточкыч

мәрхәмәтсезлеге, күңелсезлеге турында берәр әсәр — хикәяме, зур романмы язу теләге бар иде. Хәтта күңелдә һәммәсе әйбәт кенә оеша да кебек иде — күренешләр тәэсирле, каһарманнар җанлы чыга, вакыйгалар да, төрле чуар, килешле бизәкләргә үрелеп, эзлекле үсешләрендә күз алдына тәмам ачыкланып килеп басалар; боларны шулай уйлап, күзаллап утыру үзе генә дә йөрәкне җилкендерә, дәртләрне кузгатып җибәрә иде. Ләкин язарга утырдымы, бөтенесе төссез, килешсез, сабыйларча беркатлы, йә кирәгеннән артык күперенке, йә үтә шаблон сурәтле килеп чыга иде. Кызып, дәртләнеп язып утырганда бу кимчелекләр әллә ни сизелми дә шикелле, әмма соңыннан, үз язганын бөек рус даһилары иҗат иткән кечкенә генә өзек белән чагыштырып укып карагач та, аңа ифрат оят булып китә, күңелдә тирән ачыну, өметсезлек, үз иҗатына нәфрәт хисе уяна иде.

Май ахырының җылы, тымызык төннәреи Ромашов әнә шундый буталчык, каршылыклы уйлар белән шәһәр урамнарында йөреп уздырды. Үзе дә абайламастан, йөргәндә ул гел бер юлны сайлады диярлек: башта яһүдләр зиратына кадәр бара, аннан плотина аша тимер юл чокырына юнәлә иде. Дөрес, кайчакны, күңелен биләп алган дәртле уй-хисләр белән артык мавыгып китеп, ул үзенең күпме юл үткәнен сизми кала да, кинәт, йокыдан уянган кешедәй, тирәягына карана башлый һәм үзен бөтенләй икенче җиргә, шәһәрнең бүтән очына барып чыккан итеп күрә иде.

Ромашов шулай ук һәр төнне Николаевлар торган йорт каршысыннан да узып йөрде. Аннан ул гадәттә дөпелдәп суккан йөрәк белән, тынын кысып һәм, угрылыкка чыккан кеше сыман, урамның икенче ягыннан кача-поса гына атлап уза иде. Николаевларның кунак бүлмәсендә ут сүнеп, караңгы тәрәзә пыялаларына тонык ай яктысы төшүгә, ул койма янына килеп сыена да, кулларын күкрәгенә кысып:

— Йокла, гүзәлем, йокла, бәгырькәем! Мин — синең яныңда, мин сине саклап торам! — дип ишетелер-ишетелмәс, ялварулы тавыш белән пышылдый башлый иде.

Мондый чакта аның керфекләре яшькә чылана, күңеле, тәмам нечкәреп, ашкынулы, тугрылыклы мәхәббәт хисләре белән тула, ләкин бер үк вакытта йөрәкнең кайсыдыр төшендә өлгереп җиткән хайвани ирлек хисе — ачы, ярсулы сукыр көнчелек тә кыбырсып куя иде.

Көннәрдән бер көнне Ромашов Николаевның полк командиры өенә винт уйнарга чакырылуын ишетеп белде. Шул кичне урамнан узып барышлый ул, кемнеңдер йорт

алды бакчасыннан бөтен тирә-якка исерткеч чәчәк исе таралуын тоеп, койма аша тиз генә түтәлгә төште дә, караңгыда кулларын юеш туфракка пычрата-пычрата, бер кочак хуш исле, дымлы, нәфис, ап-ак нәркиз чәчәкләре җыеп алды һәм шул чәчәк бәйләме белән Николаевлар өенә таба юнәлде.

Шурочка бүлмәсенең ишегалды ягына караган тәрәзәсе ачык һәм утсыз иде. Ромашов, үзе дә көтмәгән бер кыюлык белән, шыгырдавык калитка аша ишегалдына узды, йорт стенасы янына ук килеп, чәчәк бәйләмен ачык тәрәзәдән бүлмә эченә ыргытты. Әмма бүлмәдә хәрәкәт-мазар ишетелмәде. Ромашов, йөрәге бөтен урамга ишетелердәй тавыш белән дөп-дөп типкәне хәлдә, бер өч минут чамасы шулай колагын салып тыңлап, көтеп торды. Аннары, оятыннан тәмам кызарынып, бөрешеп, аяк очларына гына баса-баса кире урамга чыкты.

Икенче көнне ул Шурочкадан ачуланып язган хат кисәге алды:

«Бүтән беркайчан да мондый җүләр эшне эшләмәгез. Ромео һәм Джульетта рухындагы төчеләнү-хисләнүләр көлке, әгәр мондый нәрсә гаскәри пехота полкында була икән — бигрәк тә».

Көндезен Ромашов аны ичмасам ерактан гына күреп булмасмы дип тә өметләнгән иде, ләкин андый очрак туры килмәде. Еш кына ул, аяк атлавы, гәүдәсе яки эшләпәсе белән Шурочканы хәтерләткән берәр хатын-кызны ерактан күреп ала да тыны кысылып, йөрәге сулкылдап типкән хәлдә, шундук аның артыннан йөгерә һәм һәр юлы, үзенең ялгышканлыгын аңлап алгач, җанында хәсрәт, сагыш, ялгызлык хисе һәм ниндидер бушлык тоя иде.

XVIII

Үткән ел май ахырларында Осадчий ротасында бер солдат асылынып үлгән иде. Язмышның сәер шаяруы дигәндәй, быел майның шул ук числосында, шул ук ротада тагы бер солдат асылынды. Мәетне ярасы көнне Ромашов полк буенча дежурный ярдәмчесе иде, шуңа күрә аңа, иректән, яру вакытында бөтенесен күреп-кареп торырга туры килде. Мәетне тәмам кискәләп, тураклап бетерделәр. Ул әле чери башламаган, аңардан үзенә бер төрле куе, җылымса ис — яңа суелган хайван түшкәсенеке сыман чи ит исе аңкып тора иде. Ромашов аның актарылып ташлан-

ган, лайлаланып ялтыраган зәңгәрсу-соргылт эчәк-бавырларын күрде, ашказанындагы азык калдыкларын, баш мие́н — аяк атлаган саен өстәл өстендә савытыннан бушатылган желе-койка́ сыман мимылдап-дерелдәп торган һәм бөтен өсте аркылы-торкылы сырлар белән капланган сорылт-сары җелек массасын күрде. Ромашов өчен боларның һәммәсе яңа, күңел болгаткыч шомлы, куркыныч нәрсәләр иде, шул ук вакытта алар аның күңелендә кешегә карата ниндидер җирәнү катыш ихтирамсызлык хисе дә уяттылар.

Ара-тирә полктагы офицер халкының өерелешеп, ду килеп, шашынулы эчү мәҗлесләре оештыра торган сәер бер гадәте бар иде. Кем белә, бәлки, алар — бер-берләре белән очраклы гына бәйләнгән, ләкин һәммәсе эчпошыргыч эшсезлеккә, мәгънәсез, рәхимсез гаскәри тормышка дучар ителгән бу кешеләр — аерым моментларда бер-берләренең күңел түрләрендә пыскып янган яшерен хәсрәтне, шом һәм шашкынлыкны күз карашларындагы чагылыштан кинәт кенә аңлап-тоеп алып, үзләрен биләгән коточкыч бу рухи халәттән әнә шул эчү мәҗлесләре ярдәмендә бераз котылып торырга теләгәннәрдер. Андый чакта полктагы тыныч, нәсел үгезләренекедәй тук тормыш агымы үз ярыннан кинәт кенә ургылып ташып чыга иде.

Әлеге солдат асылынып үлү вакыйгасыннан соң да нәкъ шулай булды. Эчү-дуамалланууны Осадчий башлап җибәрде. Җитмәсә, ике-өч көнлек бәйрәм вакыты туры килеп, шул көннәр дәвамында Осадчий берөзлексез җәмгыять клубында котырына-котырына карта уйнады һәм үз-үзен белештермичә аракы эчте. Сәер хәл: шушы ерткыч җанвардай рәхимсез, алыптай зур гәүдәле, көчле кешенең корыч ихтыяры бөтен полкны үзе артыннан каядыр караңгы чокыр төбенә бөтереп алып төшеп китте, аннан да сәеррәге — шул стихияле, шашынулы типтерү дәвамында Осадчий, бәйләнешергә, сүз көрәштерергә сылтау эзләгәндәй, әлеге асылынып үлгән солдатны әллә нинди оятсыз, әшәке сүзләр белән туктаусыз сүкте дә сүкте.

Кичке алтылар тирәсе иде. Ромашов аяклары белән тәрәзә төбенә үк менеп утырды да авыз эченнән әкрен генә «Фауст»тан вальс сызгырына башлады. Бакчада чыпчыклар чыркылдый һәм саесканнар кычкырып-кычкырып куя. Кич әле җитмәгән, шулай булса да агачлар арасына моңсу, сыек күләгәләр иңгән иде инде.

Кинәт шул вакыт өй каршында гына кемдер кычкырып, дәртләнеп, әмма көйне бозган тавыш белән җырлап җибәрде:

Бесятся кони, брепчат мундштуками,
Пенятся, рвутся, храпя-а-ат... [1]

Ул да булмады, дөбер-шатыр ишекләр ачылып, бүлмә бусагасында Веткин күренде. Аягында көчкә басып торган хәлдә, ул җырын дәвам иттерде:

Барыни, барынни взором отчаянным
Вслед уходящим глядят. [2]

Веткин кичәдән бирле айпымаган, дөм исерек иде. Йокысыз үткән төннән аның күз кабаклары кызарынып, шешенеп чыккан. Фуражкасы баш артына шуып төшкән. Әле һаман да юеш мыек чылгыйлары, пиндидер куе, коңгырт төскә кереп, моржныкы сыман очлаеп түбән салынган иде.

— Р-ромуальд! Сурия дәрвише, кая бер үбимче үзеңне! — дип, бөтен бүлмәне дер селкетеп кычкырды ул.— Йә, нәрсә монда сөрсеп утырасың? Әйдә, киттек, туган. Анда күңелле: уйныйлар, җырлыйлар. Киттек!

Шулай сөйләнә-сөйләнә, ул озаклап Ромашовны иреннәреннән үпте, мыек чылгыйлары белән аның битен тәмам юешләтеп бетерде.

— Ярый, булды, җитте, Павел Павлович, нигә кирәк алай артык хисләнү? — дип карышырга тырышып маташты Ромашов.

— Дустым, бир кулыңны! Назлы гөлкәем. Яратам мин яшьлегемнең синдә калган газаплы һәм нурлы көннәрен. Әле генә Осадчий анда шундый гүр нотыгы сөйләп ташлады, хәтта тәрәзә пыялалары зыңгылдап торды. Ромашевич, яратам мин сине, туганкай! Кая тагы бер үбимче, чын безнеңчә, иреннәреңнән суырып үбим!

Веткинның шешенгән бите, пыялаланып ялтыраган күзләре, авызыннан килгән махмыр исе, юеш мыек һәм иреннәренең тәнгә орынуы — болар һәммәсе дә Ромашов өчен гаять жирәнгеч иде. Ләкин ул, гадәтенчә, каршы сүз әйтергә үзен мәҗбүрли алмады, буйсынучан кыяфәттә, ясалма, үшән бер елмаю белән елмаеп, Веткин каршында тик басып торды.

— Туктале, синең янга нәрсәгә кергән идем соң әле?.. — дип, очкылык тоткан хәлдә, чайкала-чайкала, һаман гөрелди бирде Веткин.— Ниндидер бик кирәкле йомышым бар иде

[1] Атлар шашына, авызлык тимерләрен чыңлата,
Күбек чәчрәтеп алга ыргыла, хырылдый, котырына.

[2] Ханымнар, туташлар, җан ачысы белән
Китүчеләр артыннан күз ата.

шикелле. Ә, менә нәрсә икән. Мин, туган, бүген Бобетинскийны кәкре каенга терәттем. Аңлыйсыңмы — соңгы тиененәчә оттым үзен. Шул дәрәҗәгә җитте, әйдә, бурычка уйныйк ди башлады! Ну, мин аңа әйттем: алай шухри-мухри килеп чыга, син инде, мәйтәм, бүтән җиңелрәк юл эзләп тап, мәйтәм. Шуннан өстәлгә револьверын чыгарып салмасынмы. Менә, Ромашенко, җаныем, булмаса үзең күреп бак.— Шулай дип, Веткин чалбар кесәсенә тыгылды да, аның эчәгесе-ниен тышка әйләндереп дигәндәй, соргылт төстәге йомшак замша чехолга салынган нәфис револьвер тартып чыгарды.— Бу, туган, Мервин системасындагы револьвер. Сорыйм тегеннән: «Күпмегә куясың?» — мәйтәм. «Егерме биш тәңкәгә»,— ди бу. «Ун тәңкәгә риза!» — дим. Ул: «Әйдә, унбишкә»,— ди. «Ярар, әйдә, синеңчә булсын!» — мәйтәм. Шул, револьверны түгәрәккә салды да бу, уйнарга тотындык. Бац, бац, бац, бац! Бишенче абцугта мин аның дамасын — шалт! Исәнме-саумы, кодагый! Әле тагы күпмедер бурычлы булып калды. Менә дигән револьвер, патроннары да бар. Мә ал, Ромашевич, истәлегем булыр, дуслыгыбыз хөрмәтенә аны сиңа бүләк итәм. Батыр офицер Веткинны сагынып искә алырсың. Мә! Шигърият бу.

— Нигә ул миңа, Павел Павлович? Кесәгезгә кире салып куегыз.

— Әллә хөрти револьвердыр дип уйлыйсыңмы? Аның белән филнең үзен атып үтерергә була. Тукта, хәзер сынап карыйбыз. Кайда утыра әле синең колың? Аңардан такта-мазар сорап керим. Әй, алла колы! Рыцарь хезмәтчесе!

Шулай дип ул, ава-түнә атлап, гадәттә Гайнан көтеп утыра торган ишек төбе бүлмәсенә чыкты, анда бераз ыгы-зыгы килеп маташкач, уң култыгы астына Пушкин бюстын кыстырып, кире әйләнеп керде.

— Кирәкми, Павел Павлович, яхшы түгел,— дип, аны кыюсыз гына туктатырга тырышып карады Ромашов.

— Һи, исең киткән! Шундый карачкыны жәлләп маташырга. Менә без аны шушы урындык өстенә бастырыйк әле. Туры утыр, каналья! — диде Веткин, бюстка бармагы белән янап. — Ишетәсеңме? Хәзер арт сабагыңны укытам!

Веткин, артка чигенеп, Ромашов белән янәшә тәрәзә яңагына сөялеп басты да чакманы күтәрде. Ләкин аның исерек кулында револьвер шулкадәр айкалып хәрәкәтләнә иде ки, менә-менә хәзер ялгыш атылып китәр дип, Ромашов

тирән курку эчендә чыраен чытты һәм күзләрен челт-челт йомарга тотынды.

Бюстка кадәр ара җиде-сигез адымнан да артык түгел иде. Веткин револьвер көпшәсен төрле якка айкый-чайкый бик озак төзәп маташты. Ниһаять, ул атып җибәрде, һәм бюстның уң як битендә шундук тигезсез кырыйлы зур гына бер кара тишек пәйда булды. Ромашовның исә ату тавышыннан колаклары чыңлап яңгырады.

— Күрдеңме инде? — дип шатланып кычкырды Веткин.— Ну, әйдә, ал тизрәк револьверны, гомерең буе аны минем төсем һәм дуслык ядкәрем итеп сакла. Ә хәзер кителенче ки дә, җәмгыятькә киттек. Рус гаскәри коралының даны өчен һәйбәтләп тамак чылатып алырбыз.

— Павел Павлович, кирәкмәс иде. Чынлап, анда бармасак хәерлерәк булыр иде, — дип үгетләп, ялварып карады Ромашов.

Ләкин аяк терәп баш тартырга көче җитмәде: моның өчен аңарда Веткинга тәэсир итәрдәй катгый сүз дә, тавыш аһәңе дә табылмады. Һәм, боламыклыгы, ихтыярсызлыгы өчен үз-үзен эчтән битәрләп, ул яшелчә бакчасындагы кыяр, кәбестә түтәлләре өстеннән айкала-чайкала, борыласырыла капкага таба юнәлгән исерек Веткин артыннан күндәм төстә, әкрен генә атлап китте.

Ниндидер тәртипсез, шау-шулы, баш миңгерәүләткеч кич — чын мәгънәсендә шашынкы бер кич булды бу. Башта җәмгыять клубында эчеләр, аннары глинтвейн эчәргә дип вокзалга бардылар, аннан тагы җәмгыятькә кире кайттылар. Баштарак Ромашов гел кыенсынып утырды, Веткинның тәкъдименә күнгән өчен үз-үзенә ләгънәтләр укыды һәм, исерекләр арасына килеп эләккән һәрбер аек кеше кебек, күңеленнән тирән эч пошу, уңайсызлану, җирәнү тойгысы кичерде. Көлү-шаярулар аца гайре табигый булып, үткен сүзләр ясалма, җырлар ялган булып тоелдылар. Ләкин вокзалда эчелгән кызыл аракы искәрмәстән башына китеп, аның бөтен җаны кинәт ниндидер хозур, гасабилы бер куаныч белән тулды. Күзләрне, әйтерсең, миллионлаган вак, дерелдек ком бөртекләреннән тукылган соргылт пәрдә каплады, һәм шуннан бөтен нәрсә җайлы да, көлке дә, аңлаешлы да булып китте.

Шул исереклек шаукымы белән вакытның узганы сизелмәде дә, һәр сәгате гүя секундтай тоелды, бары ашханәдә лампалар кабынгач кына, Ромашов вакытның инде

шактый күп узганлыгын һәм төн җиткәнлеген абайлап алды.

Шул чак кемдер:

— Әфәнделәр, әйдәгез, кызлар янына барыйк. Җыеныбыз бергә Шлейферша ханым өенә барабыз да керәбез,— дип тәкъдим ясады.

— Шлейферша ханымга барабыз, Шлейферша ханымга. Ура!

Офицер халкы, урындыкларны дөбер-шатыр кузгатып, шаулый-көлә, табын яныннан сикерешеп торды. Бу кичне һәммә нәрсә ничектер үзеннән-үзе эшләнә иде. Ромашов инде баядан бирле онытылып-онытылып китә: тирә-ягындагы күренеш, вакыйгаларны аермачык аңга сеңдерү белән бергә, вакыт-вакыт аның хәтер күген йоклагандагы кебек караңгы пәрдә каплап ала иде. Кинәт ул үзен экипажда Веткин белән янәшә утырган хәлдә күрде. Каршысында тагын өченче берәү дә бар, әмма Ромашов, бөгелә-сыгыла никадәр генә иелеп караса да, төнге караңгыда ул кешене таный алмады. Аның кара тап сыман төсмерләнгән йөзе әле йодрык кадәр генә булып кечерәеп кала, әле кыек юнәлештә ничектер сузылып-киңәеп китә һәм гаҗәеп тә таныш кебек тоела иде.

Ромашов кинәт үзалдына шаркылдап көлеп куйды һәм, үз тавышын читтән тыңлап торган кешедәй, аның агачтай шыңгырдап, саңгырауланып ишетелүенә игътибар итте.

— Алдыйсың син, Веткин, кая барганыбызны мин бик яхшы беләм,— диде ул, исерекләрчә шаяртып, кыланып.— Син, туганкай, мине хатыннар янына алып барасың. Белми дип уйлама.

Таш юл өстеннән дөбер-шатыр чаптырып, алар яныннан икенче бер экипаж узып китте. Фонарь яктысында ул экипажның чыгымлап, тәртипсез саф булып чапкан тимеркүк атлары, баш өстендә чыбыркысын ярсый-ярсый болгап барган кучеры һәм экипаж эчендә сызгырына-җикеренә, айкалып-чайкалып утырган дүрт офицер күзгә чалынып калды.

Бу вакыт Ромашовның зиһене тәмам ачыкланып, ул инде тирә-ягындагы нәрсәләрне янәдән гаҗәеп бер төгәллек, сурәтлелек белән аңлый башлаган иде. Әйе, менә ул хәзер теге, һәркемгә мәгълүм йортка китеп бара. Анда бер төркем кыз-хатыннар яши, алар теләсә кемгә теләсә нинди вакытта үзләренең тәннәрен, назларын, мәхәббәтнең бөек сер-тылсымнарын бирергә әзерләр. Акча бәрабәренәме? Минутлык рәхәт хакынамы? Ах, барыбер түгелмени!

Хатын-кыз! Хатын-кыз! — дип сөрән салды Ромашовның күңеле төбеннән ниндидер кыргый, татлы, сабырсыз бер аваз. Шуңа ук, кайдадыр бик-бик ерактагы ишетелер-ишетелмәс, тонык аваз рәвешендә, Шурочка турындагы уй да килеп кушылды, ләкин бу кушылуда күңел рәнҗеткеч, хурландыргыч берни дә юк, кипрессенчә, анда күңелне талгын гына рәхәт кытыклап, дулкынландырып торган ниндидер куаныч, өмет бар иде шикелле.

Менә ул хәзер үзенә моңарчы таныш булмаган, моңарчы әле беркайчан да күрергә туры килмәгән шул сәер, серле, тылсымлы җан ияләре янына — хатын-кызлар янына барып керер! Барып керер дә хыял күгендәге яшерен уйхисләре берьюлы өнгә әверелер: бу хатын-кызларга туйганчы карап торыр, аларның кулларын кысар, ягымлы көлү һәм җырлауларын тыңлар, һәм болар барысы да Ромашовның дөньяда фәкать бердәнбер кешегә — аңа, Шурочкага гына юнәлгән дәртле хыялы, омтылышында мәхәббәт сусавын басардай аңлаешсыз, әмма куанычлы, хозур бер юану чарасы булыр! Шулай да Ромашовның күңелендә махсус күздә тотылган хисси теләк-максат юк иде,— бердәнбер сөйгәне тарафыннан кире кагылган кеше буларак, аны анда гадиләштерелгән, ялгансыз, ачык-шәрә мәхәббәтнең гомум тәэссораты үзенә тартты; туңган, арып хәлсезләнгән очар кошлар салкын төндә маяк утына тартылган сыман, ул анда стихияле, табигый бер көчкә буйсынып барды. Фәкать шул гына.

Атлар уңга борылды, һәм тәгәрмәчләр дыңгырдавы, күчәр тимерләренең шылтыравы шундук тынып калды. Экипаж, тирән әз һәм чокыр-чакырларда як-якка янтаеп, текә таудан салмак кына, ава-түнә түбән тәгәрәде. Ромашов күзләрен ачты. Кайдадыр түбәндә, аяк астында, тәртипсез рәвештә киң мәйданга таратып сибелгәндәй, бөрчек-бөрчек утлар җемелдәп күренде. Алар әле агач кәүсәләре, күзгә күренмәс карацгы йортлар артына кереп чумалар, әле янәдән кире калкып чыгалар иде. Гүя анда, үзәнлектә, ниндидер фантастик җан ияләре, сибелеп-таралып, кулларындагы фонарьлары белән яктырта-яктырта нидер эзләп йөриләр. Ул арада каяндыр җылы җил чыгып, борынга әрем исе килеп бәрелде, баш түбәсенә тиеп узган зур бер агач ботагының яфраклары шыштырдап куйды, аннан, шул ук мизгелдә, иске, ташландык кар базындагы кебек янә салкын, дымлы һава чолгап алды.

— Без кая барабыз соң? — дип тагы сорады Ромашов.

— Завальега! — диде каршыда утыручы кеше, һәм Ромашов үзалдына гаҗәпләнеп уйлап куйды: «Һи, поручик Епифанов икән ләбаса. Без, димәк, Шлейферша ханымнарга барабыз».

— Сезнең анда әллә чынлап та булганыгыз юкмы? — дип сорады Веткин.

— Бәйләнмәгезче, икегез дә кадалып китегез! — дип кычкырды Ромашов.

Әмма Епифанов шаркылдап көлә-көлә сүзен дәвам иттөрде:

— Карагыз әле, Юрий Алексеич, әгәр бик теләсәгез, без сезнең анда беренче тапкыр гына килүегез хакында хуҗа хатынны алдан искәртеп куя алабыз, ә? Йә, ничек уйлыйсыз, җаныкаем? Анда яңа кешене бик яраталар. Нәрсә оялып торырга?

Ромашовның аңын яңадан үтә күренмәс, тыгыз, караңгы пәрдә томалады. Һәм гүя бернинди вакыт өзеклеге булмагандай, ул үзен шундук паркет идәнле, стена буйларына венский урындыклар тезеп куелган зур бер зал эчендә күрде. Зал ишегенә, шулай ук залдагы кечкенә бүлмәләргә алып керә торган өч ишеккә сары чәчәкле кызыл ситсы пәрдәләр эленгән. Караңгы ишегалды ягына таба ачып куелган тәрәзә өсләрендә дә шундый ук ситсы пәрдәләр дулкынланып тирбәлә. Стеналарда лампалар яна. Зал эчендә якты, бөркү һәм гадәттә яһүдләр әзерли торган тозлы-борычлы азык исе аңкый, ләкин ара-тирә ачык тәрәзәләр аша бүлмәгә язгы тымызык һава белән бергә дымлы яшеллек, ак акация чәчәкләре исе дә килеп керә һәм бүлмә һавасын беркадәр җиләсләндереп, сафландырып җибәрә иде.

Шлейферша ханымнарга бер унлап офицер килгән иде. Аларның һәркайсы Ромашовка бер үк вакытта җырлый да, кычкыра да, көлә дә шикелле тоелды. Ул, килүчеләр арасында Бек-Агамалов, Лбов, Веткин, Епифанов, Арчаковский, Олизар һәм башкалар булуын абайлап, аларны гомерендә беренче тапкыр күргәндәй, үзалдына рәхәт һәм гафил бер төстә елмаеп, офицерларның әле берсе, әле икенчесе янына күчеп йөрде. Штабс-капитан Лещенко да шунда иде; ул, гадәттәге басынкы, моңсу кыяфәте белән, тәрәзә янына барып утырган. Өстәлгә, бүген кичнең кич буе булгандагыча, тагы каяндыр шешәле сыра һәм куе чия төнәтмәсе чыгарып куйдылар. Ромашов, стаканын кем беләндер чәкештерә-чәкештерә, алдында булганның һәммәсен эчә барды һәм күршесе белән туктаусыз үбеште. Чия төз-

нәтмәсеннән аның куллары, иреннәре җилем сыман ябышып һәм балланып тора иде.

Залда бишме, алтымы хатын-кыз бар иде. Берсе, алсу трико-чалбардан, паж булып киенгәне, карап торышка ундүрт яшәрдәй кызчык, Бек-Агамаловның тезләре өстендә утыра һәм аның аксельбант чуклары белән уйный иде. Икенче берәве, эре гәүдәле, аксыл чәчле, дугайланып торган кара кашлы, акшарланган булса да, чибәр-матур битле, өстенә кызыл ефәк кофта белән кара юбка кигәне, Ромашов янына килде һәм калын-куе тавыш белән:

— Егет, нигә сез болай күңелсезләнеп утырасыз? Әйдәгез, бүлмәгә керик,— диде.

Шулай диде дә, иркен-талымсыз хәрәкәт белән, өстәл янына утырды һәм бер аягын икенчесе өстенә атландырып куйды. Аның юбка итәге аша кабарып-бүлтәеп торган шома-йомры ботларына күзе төшеп, Ромашовның ихтыярсыздан куллары калтырап, авыз эче салкынаеп китте.

— Сезнең исемегез ничек? — дип сорады ул кыюсыз гына.

— Минемме? Мальвина,— диде кызый һәм бернигә исе китмәгән кыяфәттә йөзен читкә борды да аякларын селеккәли башлады.— Папирос белән сыйлагыз әле.

Ул арада каяндыр ике яһүд музыканты пәйда булды. Берсе кулына скрипка, икенчесе шөлдерле кечкенә барабан тоткан иде. Шуларның әллә нинди тыңкыш-саңгырау тавышлар белән дан-доң бәреп, ялгыштырып уйнаган эчпошыргыч полька көенә Олизар һәм Арчаковский канкан[1] бии башладылар. Алар, кулларын алга таба сузып, бармак шартлата-шартлата, әле сыңар аякта бер-беренә каршы сикереп киләләр, әле чүгәләп, баш бармакларын култык астына кыстырып, артка таба чигенәләр дә, ботларын ямьсез, оятсыз рәвештә тулгандыра-тулгандыра, гәүдәләрен бер алга, бер артка ташлап-ташлап алалар иде. Шул чак Бек-Агамалов утырган урыныннан сикереп торды да ярсулы нәзек, кискен тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Шпаклар шәйтанга олаксын! Хәзер үк чыгып китсеннәр! Фью!

Моны ул ишектән әле яңа гына килеп кергән ике штатский кешегә карата әйтте. Болар җәмгыять кичәләрендә еш кына күренгәләгән һәм шул сәбәпле полк офицерларының һәммәсенә дә диярлек яхшы таныш булган казначейство

---

[1] *Канкан* — әдәпсез тән хәрәкәтләре белән башкарыла торган эстрада бию е.

чиновнигы белән бер алпавыт — шәһәр хөкем палатасы приставының энесе иде. Икесе дә яшь кенә, тәртипле генә кешеләр иде.

Бек-Агамаловның әлеге янау сүзләрен ишеткәч, чиновник дигәне көчәнеп кенә елмаеп куйды һәм, үзен мөмкин кадәр иркенрәк тотарга тырышып, әмма ялвару аһәңе сизелеп торган тавыш белән:

— Әфәнделәр... Компаниягезгә кушылырга рөхсәт итегез. Сез мине беләсез бит, әфәнделәр... Мин Дубецкий ич, әфәнделәр... Без сезгә, әфәнделәр, һич комачауламабыз,— ди башлады.

— Кунак кунакка комачауламый, сыярбыз әле,— дип өстәде суд приставының энесе һәм киреренке генә итеп көлеп куйды.

— Эзегез булмасын! Марш! — дип, янә кычкырды Бек-Агамалов.

— Әфәнделәр, куыгыз моннан шпакларны! — диде Арчаковский да, шаркылдап.

Бүлмәдә шундук ыгы-зыгы башланды. Һәммәсе берьюлы урыннарыннан купты, мәсхәрәләп көләргә, идән тибеп кычкырырга тотынды. Лампаларның ялкын телләре, сөремләнеп, югары сикерде. Тәрәзәләр аша ургып кергән салкынча төнге һава бүлмәдәгеләрнең йөзләренә килеп бәрелде. Штатскийлардан инде җилләр искән, аларның яный-яный кычкырынган курку катыш ярсулы, ыңгырашулы, җыламсык-мескен авазлары урам яктан ишетелә иде инде:

— Мин моны болай гына калдырмаячакмын! Полк командирының үзенә җиткерәчәкмен. Өстегездән губернаторга язам. Опричниклар!

— У-тю-тю-тю-тю! Тот үзләрен! — дип, яшь әтәчнекедәй нәзек тавыш белән кычкырды Веткин, тәрәзәдән башын тыгып.

Ромашовка барлык вакыйгалар, гүя күз алдында ниндидер үтә чуар, шомлы, мәгънәсез, шыксыз сурәтле рәсем тасмасы сүтелгән сыман, бәйләнешсез рәвештә бер-бер артлы гел алышынып тора кебек тоелды. Эчпошыргыч бертөрле тавыш белән янәдән скрипка чыелдап җибәрде, янәдән даң-доң шөлдерле барабан кагарга тотынды. Әнә кемдер, кителен салып ташлап, эчке ак күлмәктән, бүлмә уртасында чүгәли-чүгәли һәм арка якка егылып китмәс өчен әледән-әле кулы белән идәнгә таяна-таяна, биергә тырышып маташа. Икенче берәве — моңарчы Ромашов абайлап өлгермәгән чибәр йөзле, тузгыган озын кара чәчле бер хатын,— шәрә иңбашының умрау сөякләрен тырпай-

тып үрелә-үрелә, ялан куллары белән боек Лещенконы муеныннан кочаклый һәм авызын аның колагы төбенә үк терәп, бүлмәдәге бар гөрелтене һәм музыканы ерып чыгардай эче, чәрелдек тавыш белән җыр суза иде:

Когда заболеешь чахоткой навсегда,
Станешь бледный, как эта стена,—
Кругом тебя доктора.[1]

Бобетинский исә әледән-әле стаканындагы калдык сыраны ширма өстеннән стена буендагы бүлмәләрнең берсе эченә сибеп җибәрә, ә аннан һәр юлы ачулы мыгырданган канәгатьсез, йокылы калын тавыш ишетелә иде:

— Әй сез, эфәнделәр... Җитәр диләр! Кем ул анда шаяра? Шулкадәр дуңгыз булмагыз инде!

— Карагыз әле, сез монда күптәннәнме? — дип сорап куйды Ромашов янәшәсендәге кызыл кофта кигән хатыннан һәм, үзе дә искәрмәгәндәй, каракларча яшерен бер хәрәкәт белән кулын аның кайнар, тыгыз боты өстенә куйды.

Хатын нидер әйтте, әмма Ромашов аны ишетмәде. Бу вакыт аның бөтен игътибарын каргый бер тамаша биләп алган иде. Подпрапорщик Лбов бүлмә буенча барабанчы яһүдне куып йөри һәм үзенең үк барабаны белән бар көченә аның башын дөмбәсли иде. Теге мескен тиз-тиз нинди дер аңлаешсыз сүзләр кычкыра, сюртугының озын чабуларын җыеп һәм артына таба коты алынган чырай белән борылып карый-карый, бер почмактан икенче почмакка ташлана. Һәммәсе дә шаркылдашып көләләр. Арчаковский көлүдән эче катып идәнгә үк егылган, ауный-ауный көлә, аның күзләренә яшь бөртекләре атылып чыккан иде. Ул да булмады, бүлмәнең икенче башында скрипкачы яһүдне дә ачыргаланып кычкырган эче тавышы яңгырады. Кайсыдыр аның кулыннан скрипкасын тартып алган да бөтен көченә селтәнеп идәнгә бәргән икән. Скрипка декасы, челпәрәмә уалып, соң мәртәбә көйле, сузынкы аваз белән моңсу гына ыңгырашып куйды, һәм бу ыңгырашу сәер бер рәвештә скрипкачының ачыргаланып кычкырган үз тавышына килеп кушылды. Аннары Ромашов берничә минутка үзалдына онытылып, чынбарлыктан тагы аерылып торды. Һәм кинәт, янәдән айнып, бүлмә эчендә ниндидер мәхшәр

---

[1] Гомерлек чахотка белән авырый башлагач,
Чыраең шушы стена төседәй саргайгач,—
Сине һәр яктан докторлар чолгап алыр.

башлануын күрде. Һәммәсе берьюлы кычкыра, йөгерә-чаба, кулларын болгый иде. Бек-Агамалов тирәли тиз арада кешеләр төркеме җыйналды, аннан ул төркем, шундый ук тизлек белән таралып, як-якка сибелде дә мәтәлә-кадала бүлмә буенча ташланды.

— Берегез-бер калмыйча чыгып ычкынығыз! Берегезне дә күрәсем килми! — дип ярсып акыра иде Бек-Агамалов.

Ул тешләрен шыкырдата, йодрыкларын янап селки, аяклары белән идәнгә тибеп-тибеп ала. Йөзе ярсудан тәмам бүртенгән, ике як чигәдән маңгай уртасына, борын төбенә таба сузылган кан тамырлары шнур сыман бүлтәеп чыккан, ә башын дәһшәтле төстә түбән салындырып, каш астыннан акаеп караган елтыр-шәрә күзләрендә җан тетрәткеч зәһәр бер шашкынлык чагылып күренә иде.

Бек-Агамалов, адәмчә сөйләшүне онытқандай, котырган җанвар сыман ярсып-ырылдап, «А-а-а-а!» дип, тавышын ничектер куркыныч рәвештә тибрәлдереп үкерүендә булды.

Қинәт ул, һич көтмәгәндә-уйламаганда, бөтен гәүдәсе белән җәһәт кенә сул кул ягына таба янтаеп, кынысыннан кылычын тартып чыгарды. Қылыч, чыңлап-сызгырып, аның баш очында ялтырап китте, һәм шул мизгелдә үк бүлмәдәге бөтен кеше мәтәлә-кадала ишек, тәрәзәләргә ябырылды. Хатын-кызлар үз-үзләрен белештермичә чәрелдиләр, ирләр бер-берсен төртешәләр иде. Шашкын төркем үзе белән бергә Ромашовны да ишеккә таба өстерәде, һәм кайсыдыр шунда, этә-төртә алга үткәндә, погонының кыры, әллә китель төймәсе белән Ромашовның яңагын сыдырып узды. Авырту өстенә, ярадан шундук кан саркып чыкты. Шул арада бүлмә тәмам бушап, кешеләрнең бер-берсен бүлә-бүлә дулкынланып сөйләшкән, кычкырышкан тавышлары ишегалдыннан ишетелә башлады. Бусага төбендә Ромашов ялгызы басып калды. Аның йөрәге ашыгып, дөпдөп суга, җанында курку-өркү, ләкин курку белән бергә анда ниндидер татлы, шатлыклы, дуамал бер хис тә үзен сиздерә иде.

— Урталай чабам-м-м! — дип кычкырынды Бек-Агамалов, тешләрен шыкырдата-шыкырдата.

Кешеләрне биләп алган гомум курку өянәге аны бөтенләй иләсләндереп җибәргән иде. Ул шашынкы гайрәт белән берничә селтәнүдә өстәлне теткәләп ташлады, аннары стена көзгесенә китереп сукты,— шулкадәр ярсу-ачу белән сукты ки, көзге, вак кисәкләргә таралып, кояшлы яңгыр тамчылары сыман, бөтен бүлмә эченә җемелдәп сибелде.

Икенче өстәл өстеннән ул бер сугуда барлык шешә, стаканнарны кырып төшерде.

Ләкин шул чак бүлмәдә кемнеңдер чит-ят, гайре табигый, әдәпсез-әче тавыш белән һаваны ярып кычкырган сүзләре яңгырады:

— Дурак! Җир бит!

Бу сүзләрне әлерәк кенә шәрә беләкләрен Лещенконың муенына сарып утырган яланбашлы чибәр хатын кычкырды. Қилгән шәпкә Ромашов аны күрми калган иде. Хатын, гәүдәсен чак кына алга бөгә төшеп, йодрыклары белән ботларына таянган хәлдә, мич аралыгында басып тора һәм, товар алучылардан алданып, акчасының исәбе чыкмаган базар хатыны сыман, бертуктаусыз чәрелдәп кычкыра:

— Дурак! Җир бит! Хөрәсән! Синнән беркем курыкмый! Дурак, дурак, дурак!.. — ди иде.

Бек-Агамалов кашларын җыерды һәм тәмам аптырашта калган бер кыяфәттә кылычын түбән төшерде. Ромашов аның чыраеның әкренләп-әкренләп агара башлавын һәм күзләрендә ниндидер хәвефле, шомлы, соргылт бер хәтәр ут кабынуын читтән генә күреп, күзәтеп торды. Шул ук вакытта Бек-Агамалов, дошманы өстенә сикерергә әзерләнгән ерткыч җанвар сыман, һаман саен түбән таба чүгә һәм, пружинадай, гәүдәсен җыя бара иде.

— Яп авызыңны! — дип, төкергәндәй, хырылдык тавыш белән кискен генә әйтеп куйды ул.

— Дурак! Акылга зәгыйфь! Әрмән калдыгы! Минем авызны яба алмассың! Дурак! Дурак! — дип кычкыра бирде хатын, һәр сүзе саен бөтен тәне белән тетрәнеп.

Ромашов үзенең дә әкрен-әкрен генә агарына башлавын тойды. Күңелендә әүвәлге таныш хис — авырлык югалту, көрлек, бушлык хисе янәдән баш калкытты. Курку белән шатлык тойгысының сәер кушылмасы аның җанын, стакандагы вино күбегедәй, каядыр югарыга чөйде. Бек-Агамаловның, хатыннан күзен алмыйча, кылычын салмак кына баш очына күтәрүен ул читтән күреп торды. Қинәт Ромашовны ниндидер шашынкы куаныч ялкыны, курку-өркү, физик туңу, көлү һәм тәвәккәллек дулкыны биләп алды. Бек-Агамаловның ярсулы хырылдык тавыш белән:

— Син әле һаман туктамыйсыңмы? Мин сиңа соңгы тапкыр... — дип әйтә башлаган сүзләрен тыңлап та бетермәстән, ул алга ташланды һәм үзеннән хәтта үзе дә көтмәгән үтә зур бер көч-гайрәт белән офицерның беләгеннән барып тотты. Алар шулай, бер-берсеннән күп булса биш-алты карыш ераклыкта, йөзне йөзгә терәп, берничә секунд

күз дә йоммый карашып тордылар. Ромашов үзенең колак төбендә аның ат пошкыруыдай тавышлап еш-еш сулыш алуын ишетте, күз акларын коточкыч акайтып, үтәли чәнчеп-көйдереп караган елтыр бәбәкләрен һәм шыкыр-шыкыр уйнаган яңак сөякләрен күрде, ләкин шул ук вакытта Бек-Агамалов чыраендагы бу шашынкы ярсу галәмәтенең әкренләп-әкренләп сүрелә баруын да искәртте. Һәм үзен шушы хәтәр хәлдә, үлем белән яшәү арасында басып торган хәлдә күрү аңа ифрат куркыныч та, әйтеп биргесез куанычлы да иде; ә инде бу хәтәр хәлдән җиңүче булып чыгачагына ышаныч аның күңелен горурлык хисе белән тутырды. Читтән тамаша кылып торучылар аның нинди афәткә таруын, әлбәттә, аңлаган булырга тиешләр. Һәр хәлдә, ишегалды ягыннан инде бернинди тавыш-фәлән ишетелми иде; әйләнә-тирә тып-тын, шундый тын, кинәт якында, ике адымда гына, гамьсез бер моң белән, баскычлап-баскычлап, ялгыз сандугач сайрап җибәрде:

— Җибәр! — диде ниһаять Бек-Агамалов, теш арасыннан ысылдап.

— Бек, син хатын-кызга кул күтәрмәссең дип ышанам,— диде Ромашов тыныч кына.— Кара аны, Бек, бөтен гомереңдә буена үкенәчәксең. Син аңа сукмыйсың, ярыймы?

Бек-Агамаловның күзләрендә яшган шашкын ут тәмам сүрелде, сүнде. Ромашов, һуш китүдән айныгандай, тирән сулыш алды, керфекләре дерелдәп куйды. Йөрәге, бая үлем куркуы алган чагындагыча, көйсезләнеп, тук-тук тибәргә тотынды, ә башы янә кайнарланып, авыраеп китте.

— Җибәр! — дип, ачу белән тагы бер мәртәбә кычкырды Бек-Агамалов һәм, ычкынырга теләп, кулын тартты.

Аңа карышып булмаслыгын Ромашов үзе үк сизенде, ләкин хәзер ул инде аңардан курыкмый иде, шуңа күрә иптәшенең иңбашына чак кына орынып, кызгану катыш иркәләүле тавыш белән әйтеп куйды:

— Кичерегез мине... Тик сез миңа соңыннан барыбер рәхмәт әйтәчәксез бит.

Бек-Агамалов кылычын дуамал төстә бәрә-суга кынысына тыкты.

— Ярар! Шайтанга олагыгыз! — дип кычкырды ул ачу белән, ләкин аның тавышында инде ясалмалык һәм үзүзеннән оялу аһәңе дә сизелә иде.— Арт сабагыгызны укытырмын әле мин сезнең. Монда сезнең бернинди катышыгыз юк иде!..

Ишегалдыннан тәрәзә аша тамаша кылып торучылар, афәтнең иң хәтәр ноктасы узып китүен аңлап, киренке

төстә һәм кирәгеннән артык каты тавыш белән шаулашашаркылдаша янә ишектән ябырылып керделәр. Керделәр дә, дустанә ихахайлап, кыланып, Бек-Агамаловны үзләренчә тынычландырырга һәм үгетләргә керештеләр. Ләкин тегесе инде тәмам сүнгән, хәлсезләнгән, аның берьюлы каралып киткән чыраенда арыганлык һәм җирәнү галәмәте генә күренә иде.

Ул арада бүлмәгә Шлейферша ханым да йөгереп кереп җитте. Түш турылары майланып-каешланып беткән, юан гәүдәле, керфексез, шешенке күз кабаклы, миһербансыз каты карашлы бер ханым иде бу. Ул шундук әле бер, әле икенче офицер янына ташланды, аларның җиңнәреннән, китель төймәләреннән тотып-тотып, еламсык тавыш белән бертуктаусыз карганып сөйләнде:

— Ягез, бу ни бу инде, әфәнделәр, боларның акчасын миңа кем түләр? Менә бу ватылган өстәл, көзге өчен, эчемлек, кызлар өчен акча кем түләр дим?

Һәм тагы арадан кайсыдыр бер билгесезе аның янында аңлашырга дип калды. Башкалар барысы бергә өерелешеп урамга чыктылар. Май ае төненең чиста, йомшак һавасы рәхәт бер җиңеллек белән шундук Ромашовның күкрәге эченә бәреп керде һәм бөтен тәненә шатлыклы, саф дулкын булып таралды. Юеш болыт-губка белән сыпырып алгандай, аның баш миендәге бүгенге исереклек эзләре берьюлы юкка чыккандай булды.

Шул чак аның янына Бек-Агамалов килде һәм аны култыклап алып:

— Ромашов, минем янга утырып кайтыгыз, яме? — дип үтенде.

Һәм экипажга утырып кузгалып киткәч,— Ромашов, гәүдәсен уңга янтайта төшеп, атларның симез арт саннарын сикертә-сикертә тәртипсез рәвештә үргә таба ничек чаптырып менүләрен карап барганда,— янәшәдә утырган Бек-Агамалов аның кулын кармалап эзләп тапты да бик озак каты итеп, авырттырып кысып торды. Шушы кул кысышудан башка алар арасында бүтән бернинди аңлашу да булмады.

XIX

Ләкин әле генә һәммәсе кичергән борчылу-дулкынлану болай да тәртипсез юлга борылган гомум халәтнең нервлы киеренкелеген тагы да арттыра төште. Җәмгыятькә кайтышлый офицерлар шактый күп әшәкелек, башбаштаклык-

лар эшләделәр. Мәсәлән, узгынчы берәр яһүдне туктатып, башыннан бүреген йолкып алалар да атларны җан-фәрманга чаптырып китеп баралар; аннары әлеге бүрекне кая да булса,— әйтик, койма артына яки агач башына,— ыргытып калдыралар иде. Бобетинский исә бер гаепсезгә извозчикны кыйнап ташлады. Акырып җырлау, сөрән салып кычкыруларны әйткән дә юк. Фәкать Ромашовның янәшәсендә ачулы мышкылдый-мышкылдый ярым йокымсырап утырган Бек-Агамалов кына юл буе бер сүз сөйләшмичә кайтты.

Вакыт шактый соң булуга карамастан, җәмгыять клубында балкып утлар яна һәм эчендә дә шыгрым тулы халык иде. Ашханәдә, буфетта, карта һәм бильярд бүлмәләрендә аракы эчү, тәмәке тартудан, азартлы уеннардан башлары миңгерәүләнеп беткән мескен кыяфәтле кешеләр тулганып йөриләр; китель изүләре җилбәгәй ачылган, күз карашларында ниндидер ачы хәсрәт эзе катып калган, аяк атлаулары, кул хәрәкәтләре — ялкау, иренчәк. Офицерларның кайберләре белән исәнләшеп узганда, араларында Николаевны да күреп, Ромашов үзалдына гажәпләнеп куйды. Николаев Осадчий янында утыра һәм, шактый күп эчеп, йөзе бурлаттай кызарган булса да, карап торышка әле һаман нык күренә иде. Ромашов өстәлне әйләнеп узып, алар янына якынлашкач, Николаев аңа таба тиз генә күз атып алды да, кул бирмәс өчен, башын шундук читкә борды һәм үтә мавыктыргыч сүз тапкан бер кыяфәт белән күршесенә мөрәҗәгать итте.

— Веткин, килегез монда, җырлыйбыз! — дип, иптәшләре башы өстеннән түргә карап кычкырды Осадчий.

Веткин исә теленә килгән беренче сүзләрне чиркәү көенә салып җырлап җибәрде:

— Җыр-лый-к бул-ма-са бе-рәр җыр!

Бүтәннәр хор белән аңа иярделәр:

— Җыр-лый-к бул-ма-са бе-рәр җыр! Җырлыйк булма-са бе-рәр җыр!

— Поп ишегалдында бер еяны өчәү сугышкан ди берьюлы,— дип, шул ук чиркәү көенә тиз-тиз тезеп китте Веткин: — поп та дьяк, пономарь, губернадан тагын бер секретарь. Сук берне, Ничипоре, сук бер-не.

— Сук берне, Ничи-поре, сук бер-р-не,— дип, бөтен аккордлары белән әкрен генә тагы җавап кайтарды хор. Бу аккордлар арасында иң йомшагы, иң җылысы, иң сабыр дигәне Осадчий тавышы иде.

Веткин өстәл артына баскан җиреннән, җырлаучылар-

га таба кулларын сузып, хорга житәкчелек итеп торды. Ул күзләре белән әле акаеп, куркыныч итеп карый, әле, мактагандай, мөлаем, иркә караш ташлый, көйне бозучыларга ысылдап та куя, ә инде кирәгеннән артык мавыгып китүчеләрне алга сузылган учының сизелер-сизелмәс хәрәкәте-калтыравы белән тыелырга, әкренрәк җырларга мәҗбүр итә иде.

— Штабс-капитан Лещенко, сез көйне бозасыз! Сезнең колак шәрифегезгә аю аягы баскан, күрәсең, сез җырны тоя белмисез. Булмаса бөтенләй туктагыз! — дип кычкырды Осадчий.— Әфәнделәр, шаулашмагыз әле! Кеше җырлаганда, тын гына торыгыз!

— Бай бер му-жик пунш чөмергәндә... — дип, янә башлады Веткин.

Бүлмәдәге тәмәке төтене күзләрне әчеттерә иде. Өстәлгә җәелгән клеенкага тәмам кул ябыша, һәм шул чак Ромашов бүген кич үзенең кулларын юмаганлыгын исенә төшерде. Ул ишегалды аша «офицер номерлары» дип йөртелгән бүлмәгә юнәлде,— анда һәрвакыт юыгыч була торган иде. Бер тәрәзәле шәрә, салкын бүлмә иде бу. Стена буена ике карават куелган; больница палаталарындагы сыман, аларны бер-берсеннән кечкенә шкаф аерып тора. Караватларга җәелгән урын-җир беркайчан да алыштырылмый, шулай ук бүлмә үзе дә җилләтелми һәм һичбер вакыт җыештырылмый, себерелми иде. Шуңа күрә бүлмә эчендә һәрвакыт үзенә бер төрле сөрсегән ис — юылмаган, шакшы кер исе, иске тәмәке, майланган күн итек исе аңкып тора иде. Бу бүлмә ерактагы хезмәт урыннарыннан полк штабына килеп-китеп йөрүче офицерлар өчен билгеләнгән булса да, асылда анда, кичәләр вакытында, һәр караватка икешәрләп, хәтта өчәрләп, исерек офицерларны яткыралар иде. Шунлыктан бу бүлмәне кайвакыт «үлекләр бүлмәсе», «мәетханә» һәм «морг» дип тә йөртәлиләр. Аңсыз рәвештә бирелгән бу исемнәр астында тирән мәгънә, коточкыч тормыш ирониясе ята иде. Һәрхәлдә, полк шәһәргә күчеп килгәннән соң узган кыска гына вакыт эчендә анда, шушы офицер номерларында, нәкъ менә әлеге ике караватта, берничә офицер белән бер денщик атылып үлгән иде.

Ромашов «мәетханәгә» кергәндә, караватларның түр башында, тәрәзә янында, ике кеше утыра иде. Бүлмәдә ут алынмаган, караңгы, шунлыктан Ромашов аларның мондалыгын кыштырдаулары буенча гына чамалады һәм якынрак килеп өсләренә иелде дә, берсенең штабс-капитан

Клодт, ә икенчесенең подпрапорщик Золотухин икәнлеген таныды. Боларның Клодт дигәне рота командирлыгы вазифасыннан читләтелгән алкоголик һәм карак бер кеше булып, Золотухины, олы яшьтәге, пеләш башлы, колга буйлы, чандыр гәүдәле кеше, гомерлек подпрапорщиклар тибындагы гаскәриләрдән саналып, полкта җәнҗалчы, уенчы, әшәке сүгенүче һәм шулай ук төзәлгесез эчкече буларак дан тота иде. Менә хәзер дә алар аракы эчеп утыралар иде. Ике карават арасына куелган өстәл өстендә, төнге караңгыда чак кына төсмерләнеп, чирекле аракы шешәсе, ниндидер куе апара салынган тәлинкә һәм аракы тулы ике стакан күренә. Ашамлык, закуска дигәннең әзе дә юк. Үзләре исә һичбер сүз сөйләшмиләр, әйтерсең килеп кергән иптәшләренә серләрен белдерәселәре килми, ә инде Ромашов өслә-ренә иелеп карагач, алар караңгыда мыек астыннан гына елмаеп, күзләрен каядыр түбән текәделәр.

— Ай аллам, сез нишлисез монда? — дип сорады Ромашов, куркынып.

— Тссс! — дип әкрен генә пышылдады Золотухин, бармагын кисәтүле төстә югары күтәреп.— Сабыр итегез. Комачауламагыз.

— Шауламагыз! — диде Клодт та, шундый ук пышылдавык тавыш белән.

Шул чак кайдадыр ераkта арба шыгырдаган тавыш ишетелде.

Бу икәү шундук стаканнарын югары күтәрделәр, чәкештерделәр дә, икесе бер үк вакытта эчеп җибәрделәр.

— Бу ни дигән сүз, әйтәсезме-юкмы сез, ниһаять?! — дип кычкырды Ромашов, борчыла калып.

— Бу ягъни шундый закуска дигән сүз, туганкай,— дип, серле генә пышылдап җавап бирде Клодт.— Тәгәрмәч тавышын кабып эчү, димәк. Фендрик,— дип дәште ул аннары Зототухинга: — җә, хәзер нәрсәне кабып эчәбез? Ай нурын кабып эчмибезме?

— Ай нуры белән эчтек ич инде,— диде Золотухин житди итеп һәм шәһәр өстендә түбән генә эленеп торган монсу ай урагына таба тәрәзә аша күз атып алды.— Сабыр итик. Бәлкем, менә берәр эт өреп куяр. Тын кына утырыйк.

Алар шулай, исереклекне шомлы бер мәзәккә әверелдереп, берсе берсенә иелә-бөгелә, тын гына пышылдашып утырдылар. Ә бу вакыт ашханә ягыннан, стеналар аша үзганда шактый басылып-йомшарып һәм, шул сәбәпле, каяндыр бик ерактан килгән матәм көе сыман, тагы да моңлы-

рак, хәсрәтлерәк булып, чиркәү җырының тигез-әкрен аваз-лары ишетелә иде.

Ромашов аптыраган кыяфәттә кулларын җәеп, башын кочаклап тотты да тирән хәсрәт белән:

— Әфәнделәр, алла хакы өчен, ташлагыз бу мәзәкне, коточкыч бит бу,— диде.

— Барсана, шайтанга олак! — дип, кинәт аңа акырып җибәрде Золотухин.— Хәер, тукта, сабыр ит, туган! Кая алай ашыгасыз? Башта менә мөхтәрәм әфәнделәр белән берне чәкештереп ал. Ю-юк, туган, алай гына чыгып китә алмассың. Тотыгыз аны, штабс-капитан, мин ишекне бик-лим.

Алар икесе дә караватларыннан дәррәү сикереп тордылар да, шашынкы, мәзәк бер көлү белән шаркылдап көлә-көлә, Ромашовны куып тотарга керештеләр. Боларның һәммәсе — бу сасы, караңгы бүлмә, шунда төн уртасында оештырылган бу серле, гайре табигый эчү мәҗлесе, шуны оештыручы әлеге ике шашкан кеше — барысы да Ромашовка коточкыч бер нәрсә булып, акылдан язу, үлемне үзе булып тоелдылар. Ул әче тавыш белән кычкырып Золотухинны бар көченә бер читкә этәреп җибәрде дә, бөтен әгъзалары тетрәп калтыранган хәлдә, «мәетханәдән» урамга атылып чыкты.

Акылы белән Ромашов үзенең өйгә кайтырга тиешлеген дә яхшы белә иде, ләкин, ниндидер зиһен ирешмәс теләккә буйсынып, ул янәдән ашханәгә керде. Анда инде күп кеше табын янындагы урыннарында, тәрәзә төпләрендә йокымсырап утыра иде. Бүлмәдә коточкыч эссе һәм, тәрәзәләр шар ачык булуга карамастан, бернинди җил әсәре дә юк; лампа, шәм утларының ялкын телләре селкенмичә, үрә катып яналар. Егылыр дәрәҗәгә җитеп арыган хезмәтче хатыннар һәм буфетчы солдатлар аяк өсте йоклыйлар, минут саен иснәнәләр, тик авыз ачып түгел, борын тишекләрен киереп иснәнәләр иде. Шулай да һәммәсен үз эченә сөйрәп алган шаукымлы, авыр эчү өянәге әле булса дәвам итә иде.

Веткин инде өстәл өстенә үк менеп баскан һәм нечкә, тәэсирле тенор тавыш белән җырын дәвам итә:

Бы-ы-стры, как волны-ы,
Дни-и нашей жиз-ни...[1]

---

[1] Дулкындай тиз ага
Безнең тормыш көннәре...

Полкта рухани гаиләләрдән чыккан офицерлар шактый күп булу сәбәпле, дини жырларны шәп җырлыйлар, хәтта исерек чакта да көйне бозмыйлар иде. Моң, хәсрәт белән өртелгән гади көй ярты-йорты мәгънәле сүзләрне дә ничектер тәэсирле, күңелне дулкынландырырлык итә иде. Һәм менә хәзер дә җыр тәэсирендә һәммә кешенең күңелендә аз гына вакытка моңлы, хәсрәтле бер хис уянып куйды. Үзләрен шушы тәбәнәк түшәмле, кысан, бөркү бүлмәдә гомер уздырырга мәҗбүр иткән тар, караңгы, сукыр тормыштан канәгатьсезләнү хисе иде бу.

Умрешь, похоронят,
Как не жил на свете...[1] —

дип җырлый бирде Веткин һәм, бугазыннан тирбәлеп-калтырап чыккан матур, нәзек үз тавышын, шулай ук хорның бердәм, тигез агышын тоюдан күңеле тәмам йомшарып, аның беркадәр ахмаграк, әмма эчкерсез нур чәчеп караган күзләрендә яшь бөртекләре ялтырап күренде. Арчаковский бик тырышып, артык каты кычкырмыйча гына аңа ияреп бара. Тавышы калтырап чыксын өчен, ул кулының ике бармагы белән бугаз төерен тибрәлдереп, селкетеп тора иде. Осадчий исә үзенең куе, калын тавышы белән, сузып-сузып, хорга булыша, һәм хордагы калган барлык аваэлар шушы куе, органныкыдай гөрелдәүле тавыш эчендә, карасу диңгез дулкыннарында чайкалган кебек, йөзеп-тирбәлеп баралар сыман иде.

Җыр беткәч, күпмедер вакыт сөйләшмичә утырдылар. Исереклек сөременнән айныгандай, һәммә кешене бер минутка талгын, уйчан бер халәт биләп алды. Кинәт Осадчий, керфекләрен түбән төшереп, күзләре белән өстәлгә текәлде дә, көйләп, әкрен генә әйтеп куйды:

«Кыен, хәсрәтле юлдан атлап баручы адәмнәргә тормыш авыр йөктер...»

— Җитәрдер инде сезгә! — диде кайсыдыр боек тавыш белән.— Такылдапмы такылдадыгыз шул гүр догагызны. Унынчы тапкыр диимме.

Ләкин бүтәннәр көйне шундук элеп алдылар һәм, күп тә үтмәде, изге Иоанн Дамаскинның дөньядан кичкәннәрне тетрәндергеч сүзләр, кайнар хис-сагыш, хәсрәт белән сагынып жырлаган мәгълүм гүр догасының саф, самими аһәңнәре тәмәке төтене сарган, пычрак, шакшы ашханәнең иң түр почмакларына кадәр таралды:

---

[1] Үлсәң, күмәрләр,—
Дөньяда торган кебек тә булмассың...

«Миңа иман китергәннәр, килегез, игелегемне күрегез, мин сезгә ожмах рәхәтләре, хөрмәтләре әзерләдем...»

Һәм догаларны теләсә нинди дьяконнан да ким белмәгән Арчаковский шундук күтәреп алды:

— Барчабыз да ихлас күңелебездән иман китерәбез...

Гүр догасын алар шулай ахырынача укып-җырлап чыктылар. Ә инде нәүбәт иң соңгы өмдәмәгә килеп җиткәч, Осадчий, муенын пружинадай җыеп, башын түбән таба ия төште дә, бер үк вакытта усал да, куркыныч та, сәер һәм хәсрәтле дә булган күз карашын бер ноктага төбәп, контрабас кылларын чирткәндәгедәй калын, гүелдәвек тавыш белән көйләп тезеп китте:

«Ходаем, дөнья кичкән гөнаһлы бәндәң, Никифор колыңның гүр туфрагын җиңел ит, аның гөнаһларын ярлыка... — Бу урында Осадчий үзенең догасына бик тә әшәке, коточкыч оятсыз сүгенү сүзе кыстырып алды,— аның әрвахларын...»

Ләкин ул сүзен әйтеп бетерә алмады: Ромашов, урыныннан сикереп торып, шашынкы бер гайрәт белән өстәлгә китереп сукты.

— Рөхсәт итмим! Бүтән сүз әйтәсе булмагыз! — дип, әче, газаплы бер тавыш белән кычкырып җибәрде ул.— Ник алай үлгән кешедән көләсез? Капитан Осадчий, мин күреп торам бит: сезгә бер дә көлке түгел, сезгә куркыныч, сезнең җаныгыз кыйнала! Җаныгызны нәрсә борчыганын мин бик яхшы беләм!

Һәммә кеше тынып калган иде. Арадан тик берәү генә аптыраулы тавыш белән әйтеп куйды:

— Исергәнме әллә ул?

Ләкин шул сүзләр артыннан ук бүлмә дәррәү хәрәкәткә килде. Бая Шлейферша ханымнарда булгандагыча, кешеләр тагы урыннарыннан сикерешеп тордылар, кычкырынашаулаша һәм, чуар төстәге бер төркемгә өерелешеп, җанлы йомгактай әрле-бирле тулгана башладылар. Веткин өстәл өстеннән сикереп төшкән чагында башы белән ялгыш асылма лампага бәрелде; лампа, чайкалып китеп, баш өстендә зур зигзаглар ясап, салмак кына әйләнергә тотынды, һәм аның хәрәкәтләнүчән яктысында ашханәдә шашынып кайнашкан кешеләрнең күләгәләре әле озая — галәмәт зур гәүдәле әзмәверләргә әверелә, әле кыскарып, идән уртасында бөтенләй күздән югала яки, бүлмәнең ак стеналарында шәүләләнеп, шомлы, буталчык бер төстә уйнаклый-уйный башлый иде.

Җәмгыять клубына килеп тулган шушы исерек, ярсын-

ган, зиһеннәре чуалып беткән халыкның барлык эш, кыланышлары, ул бичараларга бәйле барлык вакыйгалар — болар һәммәсе хәзер ничектер бик тиз, бүтән беркайчан төзәтеп булмаслык ашыгычлык һәм мәгънәсезлек белән эшләнде. Әйтерсең дуамал холыклы, акылсыз, усал, явыз, мәсхәрәчел ниндидер бер иблис кешеләрнең ихтыярын үзенә буйсындырып алган да, аларны төрле тәртипсез, эшәке эшләр эшләргә, яман сүзләр сөйләргә мәҗбүр итә иде.

Кинәт Ромашов шушы томана гавам эчендә, үзенең янәшәсендә үк, авызын тәмам киереп ачып кычкырынган бер кешене күреп алды. Аның чырае явызлыктан, ачудан шулкадәр бозылган, ямьсезләнгән иде ки, баштарак Ромашов аны хәтта танымыйчарак торды. Николаев иде бу; авызыннан төкерекләр чәчә-чәчә һәм сул күз астындагы бит мускулларын нервлы уйната-уйната, ул кычкыра иде Ромашовка:

— Сез үзегез полкны хурлыкка калдырасыз! Сезнең бер сүз әйтергә хакыгыз юк! Сезнең һәм Назанский ишеләрнең! Башыгыз керсә, аягыгыз кермәгән!..

Кемдер арттан Ромашовны әкрен генә читкә өстери иде. Ромашов борылып карады һәм артында Бек-Агамаловны күрде, ләкин шундук, кире алдына борылып, иптәшен янә онытты. Аннан ул, әйтәсе сүзенең нинди нәтиҗә китерәчәген алдан ук сизенгәндәй, чырае агарынып, газаплы, кызганыч бер елмаю һәм хырылдап чыккан әкрен тавыш белән:

— Ә монда Назанскийның нинди катышы бар? Әллә югыйсә сезнең аңа үпкәләр өчен бүтән төрле, аерым, серле башка сәбәпләрегез бармы? — диде.

— Беләсезме, мин хәзер сезнең танавызызга менеп төшәм! Оятсыз! Кабахәт, җир бит! — дип, эт чинагандай каты итеп кычкырып җибәрде Николаев.

Шулай дип, ул күзләрен дәһшәтләндереп, йодрыгын югары күтәрде, әмма сугарга җөрьәт итмәде. Ромашовның күкрәге һәм корсагы эчендә гадәттә һуш китү алдыннан була торган ниндидер күңел болгаткыч, сару кайнаткыч салкын бер нәрсә йомарланып катты. Моңарчы әле ул уң кулында ниндидер чит әйбер барлыгын искәрми тора иде, хәзер, шуны исенә төшереп, ул кинәт кискен бер хәрәкәт белән кулын югары күтәрде һәм стаканындагы калдык сыраны Николаевның битенә сипте.

Шул ук мизгелдә сул күзеннән яшеннәр чәчрәп чыгып, үзәк өзгеч бер авырту тойды. Аннары ерткыч җанвар тавышы белән улап, ярсып, Николаев өстенә ташланды. Алар

шулай, аяк-куллары бер-берсенә сарылган хәлдә, түбән авып, урындыкларны аудара-аудара, шакшы, сасы, тузанлы идән буенча әүмәкләшеп тәгәрәргә тотындылар. Алар улый-улый, сулышларына буыла-буыла бер-берен дөмбәслиләр, кысалар, тарталар, кнемнәрен ертышалар иде. Хәтерендә, бер мәл Ромашов үз бармагының ялгыш Николаевның авызы эченә эләгүен тойды, һәм ул шушы селәгәйле, кайнар, җирәнгеч авызны бөтен көченә тарткалап, ертып чыгарырга маташты... Һәм, шашынкы бу көрәш тәмам кызып, башы һәм тереәкләре белән шак-шок үзе идәнгә бәрелгәндә, ул инде берничә авырту да сизмәде.

Шулай ук ул бу сугышуның кайчан, ничек бетүен дә белмәде. Исенә килгәндә, аны инде Николаевтан аерып, почмакка китереп бастырганнар иде. Янында Бек-Агамалов тора, ул аңа су эчереп маташа, ләкин калтыраудан Ромашовның тешләре стакан кырыена шак-шок бәрелә, һәм ул бу вакыт стакан кырые кителеп, кыйпылчыгы тамак төбенә китмәгәе дип тә куркып куйды. Кителе арка ягыннан һәм култык асларыннан ертылып чыккан, погоннарның да берсе, умырылып, нәзек бер тасма элмәктә генә асылынып тора иде. Тавышы тәмам карлыккан, шуңа күрә Ромашов сүзләрен фәкать иреннәре белән, ишетелер-ишетелмәс итеп кенә әйтте:

— Мин аңа... күрсәтермен әле!.. Дуэльгә чакырам!..

Әлеге җәнҗалга хәтле өстәлнең түр башында тәмле йокымсырап утырган Лех карт хәзер, тәмам күзләре ачылып, җитди, айнык бер кыяфәт алган иде. Ул моңарчы үзенә хас булмаган кырыс, боеручан тавыш белән әйтеп куйды:

— Иң өлкәнегез буларак, сезгә хәзер үк таралышырга боерам, әфәнделәр. Ишетәсезме, хәзер үк. Бүгенге хәлләрнең һәммәсе хакында иртәгә полк командирына минем тарафтан рапорт бирелер.

Кешеләр боек, күңелсез кыяфәттә, бер-берләренә күтәрелеп карарга да оялып, әкрен генә таралыша башладылар. Һәркем, кинәт кенә зиһене ачылып киткәндәй, иптәшенең күз карашында үзенең колларча гаҗиз хәлен, үкенүле сагышын — үзенең явыз холыклы, шапшак, вак җәнлекләрчә яшәү гаҗизлеген һәм сагышын күрермен дип курыкты.

Җилсез-хәрәкәтсез, салкынча һавалы, сабыйлар күз яшедәй саф, аяз күкле таң вакыты иде. Күзгә күренер-күренмәс дым-рәшә белән өртелгән агачлар үзләренең тылсымлы, серле төшләр күреп яткан төнге йокыларыннан әк-

рен генә уянып киләләр. Ромашов, өенә кайтышлый, моңланып-сагышланып, шул хозур күренешләрне күзәтте, күк йөзенә, чык тамчыларыннан чаларып торган дымлы чирәм өсләренә карап-карап узды һәм шушы беренче көн яктысы белән көләч елмаеп уянып килгән гөнаһсыз, саф, хиссиятле табигать уртасында үзен бөтенләй чит-ят, кирәксез, ямьсез-шыксыз, түбән уйлы бер җан иясе итеп тойды.

XX

Шул ук көнне — бу чәршәмбе иде — Ромашов кыска гына язылган рәсми хат алды.

«...нче номерлы пехота полкы офицерлары җәмгыятенең суды подпоручик Ромашовның бүген сәгать алтыда җәмгыять клубы залына килүен үтенә. Кием формасы — гадәттәгечә.

Суд председателе подполковник Мигунов».

Ромашов, ихтыярсыз, үзалдына моңсу гына елмаеп куйды: бу «кием формасы — гадәттәгечә» дигән нәрсә — погонлы мундир белән төсле каеш — нәкъ менә гадәттән тыш очракларда — судта, саф каршына басып шелтә алганда һәм нинди дә булса берәр күңелсез эш белән түрәләр янына барганда киелә торган иде.

Сәгать алтыда Ромашов җәмгыятькә килде һәм үзенең килеп җитүе турында хәбәр итәргә суд председателе бүлмәсенә вестовойны кертеп җибәрде. Вестовой, әйләнеп чыгып, бераз көтәргә куштылар, дип белдерде. Ромашов ашханәнең ачык тәрәзәсе янына барып утырды да, кулына газета алып, бернинди кызыксынусыз һәм сүзләрнең мәгънәсен аңламыйча, хәрефләр өстеннән күзләрен йөртергә кереште. Ашханәдә булган өч офицер аның белән салкын гына исәнләштеләр дә, читкә китеп, Ромашов ишетмәсен дигәндәй, үзара нәрсәдер пышылдаша башладылар. Фәкать подпоручик Михин гына, күзләрен яшьләндереп, аның кулын бик озаклап кысып торды, ләкин бер сүз дә әйтмәде, кызарынып, ашык-пошык киенде дә тизрәк шылу ягын карады.

Бераздан ашханәгә буфет аша Николаев килеп керде. Чырае агарган, күз кабаклары күгәреп чыккан, сул бит алмасы, көзән җыергандай, тартышып-тартышып куя, ә шуннан өстәрәк, чигә белән ике арада, зәңгәрләнеп торган шактый зур бер шеш-тап күренә иде. Ромашов газап эчендә аермачык итеп кичәге сугышуны күз алдына китереп бас-

тырды һәм, бу хурлыклы хатирәләр авырлыгыннан тәмам бөрешеп, чыраен чытып, йөзен газета артына яшерде, хәтта күзләрен чытырдатып йомды.

Ул Николаевның буфетта бер рюмка коньяк сорап алуын һәм кем белəндер хушлашуын ишетеп утырды. Аннары аның янәшəдəн генə үтеп киткəн аяк тавышларын искəртте. Шапылдап ишек ябылды. Һəм берничə секундтан кинәт үз артында, ишегалды ягыннан, сагаюлы пышылдау тавышы ишетте:

— Артыгызга борылып карамагыз! — диде аңа əлеге тавыш.— Тын гына утырыгыз. Тыңлагыз.

Бу — Николаев сөйли иде. Ромашовның кулындагы газетасы калтыраныш куйды.

— Асылда, мин сезнең белән сөйләшергə тиеш тə түгелмен. Ләкин хəзергə ул француз эдəпләрен бер якка куеп торыйк. Булган — беткəн, аны инде төзəтеп булмый. Шулай да мин сезне əлегə тəртипле кеше дип саныйм. Кыскасы, мин сездəн үтенеп сорыйм, ишетəсезме, үтенеп сорыйм: хатыным һəм аноним хатлар турында зинһар сүз кузгатмагыз. Сез мине аңладыгызмы?

Ромашов, ашханəдəге кешеләрдəн газета артына яшеренеп, əкрен генə баш какты. Ишегалдындагы ком аяк атлаудан шыгырдап калды. Бер биш минут чамасы вакыт үткəннəн соң, Ромашов тəрəзəгə таба борылып карады. Ишегалдында Николаев юк иде инде.

Шул чак аның каршында каяндыр вестовой калкып чыкты.

— Ваше благородие, галижəнап офицерлар сезнең керүегезне үтенəләр,— дип белдерде ул.

Залда, аның түрге тар стенасы буенда, берничə ломбер өстəлен янəшə тезеп, озынча бер өстəл əмəлләштергəннəр һəм өстенə яшел сукно җəеп куйганнар иде. Өстəл янында, стенадагы тəрəзəләргə таба аркаларын куеп, судьялар утыралар; шунлыктан аларның йөзләре беркадəр күләгəләнеп күренə иде. Уртада, кресло-урындыкта, суд председателе подполковник Мигунов үзе утырган; тырпайган йомры иңбашлы, кыска муенлы, тəкəббер чырайлы юан бер кеше иде бу; аның як-ягында — подполковниклар: Рафальский белəн Лех; шуннан соң капитаннар тезелешеп китə: сул кул якта — Осадчий белəн Петерсон, уңда — Дювернуа белəн полк казначее штабс-капитан Дорошенко. Өстəл өсте буп-буш, тик суд секретаре вазифасын башкаручы Дорошенко алдында гына бер өем кəгазь ята. Тышта кояшлы, эссе көн булуга карамастан, монда, бу киң, зур зал эчендə, шак-

тый салкын һәм караңгы, өстәвенә, черегән агач, искергән мебель һәм күгәрек исе аңкый иде.

Председатель ап-ак, зур симез кулларының икесен дә учлары белән өскә каратып өстәл өстенә сузып салды да, аларны алмаш-тилмәш җентекләп карый-карый, агач тавыш белән сүзен башлады:

— Подпоручик Ромашов, полк командирының шәхси боерыгы буенча җыелган офицерлар җәмгыяте суды менә хәзер, үзенең утырышында, кичә кич сезнең белән поручик Николаев арасында булган күңелсез һәм офицерлар дәрәсендә һич гафу ителмәслек хәлнең сәбәпләрен ачыкларга тиеш. Сездән шул хакта берни яшермичә, җентекләп сөйләп бирүегезне үтенәм.

Ромашов алар каршында кулларын түбән салындырып һәм фуражкасының кырпулы кырыен угалап, боек кыяфәттә басып торды. Кайчандыр мәктәптә укыган елларында имтихан тапшырырга кереп тә, берни сөйли алмыйча аптырап, уңайсызланып торган кебек, ул хәзер дә сүзен нидән башларга белмәде. Ахырда, ничек кирәк алай исен җыеп, буталчык, бәйләнешсез, өзек җөмләләр белән, кирәк-кә-кирәксезгә дә мәгънәсез сүзләр, ымлыклар кыстыра-кыстыра, күрсәтмәләрен бирергә кереште. Шул ук вакытта ул, күзен бер судьядан икенчесенә күчерә-күчерә, эченнән генә аларның үзенә карата нинди карашта, мөнәсәбәттә булуларын бәяләргә тырышты: «Мигунов — таш йөрәк, искитмәүчән кеше, ләкин үз өстенә алган баш судьялык роле һәм шуңа бәйле коточкыч зур хокуклар, җаваплылык аны артык һаваландырып җибәргән булса кирәк. Подполковник Бремның күз карашында хатын-кызларга гына хас ниндидер кызганучан теләктәшлек, моңсулык чагыла. Их, кадерле Брем, кадерле Брем, исеңдәме, мин ничек синең янга бурычка ун сум акча алырга дип килгән идем? Лех картлач артык җитди булып кылана. Бүген ул аек, күз төпләре әнә тирән җәрәхәт сыман капчыкланып салынып төшкән. Ул миңа дошман кеше түгел түгелен, ләкин аның төрле заманнарда җәмгыятьтәге эшләгән башбаштаклыклары шулкадәр күп, хәзер аңа үзен офицерлык намусын саклаучыларның иң гадел, кырыс тарафдары итеп күрсәтү, әлбәттә, файдалырак булачак. Ә Осадчий белән Петерсон — менә болары инде чын дошман кешеләр. Закон буенча, мин Осадчийның суд составына кертелмәвен дә таләп итә алган булыр идем, әлбәттә,— әлеге якалашу бит асылда аның аркасында башланды — тик ни файда, аны чыгартудан ни үзгәрер? Петерсон әнә авызының бер почмагы белән сизелер-сизелмәс кенә елмаеп утыра — аның бу ел-

маюында ниндидер мәкер, эшәкелек, зәһәрлек яшеренгән шикелле. Әллә теге аноним хатлар турында хәбәре бар микән? Дювернуаның бөтен кыяфәтендә йокымсырау чагыла, күзләре болганчык су тутырылган ике шар кебек. Дювернуа мине яратмый, билгеле. Дорошенкосы да шулай. Аның өчен мин — жалунья алу турында имза куеп та, аны беркайчан да кулына ала алмый торган бер подпоручик кына. Их, начар сезнең эшләр, хөрмәтле Юрий Алексеевич!»

Осадчий киноят аның сүзләрен һәм уйларын бүлде:

— Бер минутка гафу. Полковник әфәнде, соравым бар, рөхсәт итегезче?

— Рәхим итәсез,— дип баш какты Мигунов җитди кыяфәт белән.

— Подпоручик Ромашов, әйтегез әле безгә,— дип, һәр сүзен сузып-басымлап, эре генә башлап китте Осадчий,— җәмгыятькә шул шыксыз, затсыз кыяфәтегездә килеп кергәнчегә кадәр сез кайда булган идегез?

Ромашовның йөзенә шундук кызыллык йөгерде, ә маңгаена бөрчек-бөрчек тир тамчылары бәреп чыкты.

— Мин... мин булдым... ну, бер җирдә булдым,— диде ул, тотлыгып; аннары ярым пышылдап өстәп куйды: — Фәхешханәдә булдым.

— Әһә, сез алайса фәхешханәдә булдыгыз? — дип, юри каты тавыш, мәсхәрә белән элеп алды Осадчий.— Сез ул ханә дигән урында ни дә булса эчкәнсездер дә әле, шулаймы?

— Әйе, эчтем,— дип кистереп җавап бирде Ромашов.

— Алай, алай. Бүтән соравым юк,— диде Осадчий, председательгә таба борылып.

— Рәхим итеп, сүзегезне дәвам итегез,— диде Мигунов Ромашовка.— Димәк, сез поручик Николаевның йөзенә сыра сиптегез... Ягез, шуннан нәрсә булды?

Ромашов бутала-бутала, әма ихлас күңелдән кичәге вакыйганы бөтен ваклыкларына кадәр сөйләп чыкты. Ул инде килешсез сүзләр белән, оялу катыш, үзенең эшләгән эшләре өчен үкенүен дә әйтә башлаган иде, ләкин аны шул чак капитан Петерсон бүлдерде. Тырнаклары зәңгәрләнеп тырпаеп торган озын, үле бармаклы, кипшергән сары тиреле кулларын, юынгандай бер-берсенә ышкый-ышкый, ул үтә ягымлы, юмакай, төче, хәтта иркәле диярдәй тавыш белән Ромашовка эндәште:

— Ярый, анысы шулайдыр, әлбәттә, шулайдыр, болар һәммәсе сезнең хисләрегезнең гүзәллеген күрсәтә, билгеле. Әмма ләкин бер сорау килеп туа... Әйтегез әле, подпоручик

Ромашов, сез әлеге күңелсез, үкенечле вакыйга булганчы-га кадәр поручик Николаевлар өенә баргалап йөрмәдегезме?

Ромашов сагая калды һәм, Петерсоннан битәр Мигуновка карап, шактый дорфа төстә җавап кайтарды:

— Әйе, баргалаганым булды, ләкин мин аңламыйм: бүгенге мәсьәләгә моның нинди катышы бар икән?

— Сабыр итегез. Фәкать сорауларга гына җавап бирүегезне үтенәм,— диде Петерсон, аны янә бүлдереп. — Мин шуны белергә телим: сезнең поручик Николаев белән мөнәсәбәтләрегездә үзара дошманлык хисләре тууга этәргән бүтән төрле, махсус сәбәпләр,— ну, әйтергә яраса, хезмәткә кагылышлы сәбәпләр түгел, ә шәхси тормышка, гаилә тормышына кагылышлы сәбәпләр булмадымы диюем?

Ромашов тураебрак басты һәм ачыктан-ачык нәфрәт белән Петерсонның чахоткалы коңгырт-кара күзләренә текәлде.

— Башка танышларымның өйләрендә никадәр еш булсам, Николаевлар өендә дә мин шуннан артык булмадым,— диде ул каты, кискен тавыш белән.— Моңарчы безнең мөнәсәбәтләрдә бернинди дә дошманлык юк иде. Бу дошманлык бөтенләй көтмәгәндә һәм очраклы рәвештә генә килеп чыкты, чөнки без икебез дә исерек идек.

— Һи-һи-һи, сезнең ул исереклегегез хакында ишеттек инде без,— дип, тагы сүздән бүлде аны Петерсон.— Минем сездән тик шуны гына сорыйсым килә: элегрәк сезнең арада нинди дә булса чарпылыш-мазар булмадымы дим? Юк, дөрес аңлагыз мине, низаг, ачуланышу дип әйтмим, ә берәр төрле аңлашылмаучылык, шәхси нигездә үзара бер-берегезне чит күрү, яратмау кебегрәк нәрсә булмадымы дим? Ну, әйтик, фикер каршылыгы яки интрига кебек берәр нәрсә. Ә?

— Председатель әфәнде, миңа куелган кайбер сорауларга җавап бирмәскә минем хакым бармы? — дип сорады кинәт Ромашов.

— Әйе, хакыгыз бар,— диде Мигунов салкын гына.— Теләсәгез, сез бөтенләй җаваптан баш тарта аласыз яки күрсәтмәләрегезне язма рәвештә бирә аласыз. Аныcы сезнең ихтыярда.

— Алайса, белдерү ясыйм: мин капитан Петерсон куйган сорауларның берсенә дә җавап бирергә теләмим. Бу аның үзе өчен дә, минем өчен дә хәерлерәк булыр,— диде Ромашов.

Аңардан әллә ни әһәмияте булмаган янә берничә вак-

төяк нәрсә турында сораштылар, шуннан соң председатель: «Сез азат, китәргә мөмкин»,— дип белдерде. Ләкин аңа әле тагын ике тапкыр — берсе шул көннең кичендә, әйкенчесе пәнҗешәмбе көн иртән — өстәмә аңлатмалар бирү өчен кабат судка барып килергә туры килде. Практик яктан искиткеч тәҗрибәсез Ромашов — хәтта ул да судның үз эшен ифрат гамьсез, игътибарсыз, белер-белмәс рәвештә, бик күп хата һәм тотнаксызлыклар белән алып баруын искәртте. Иң зур тотнаксызлыклары шул: судтагы эш-мәгънәләрне ачу, сөйләп бирү дисциплинар уставның 149 нчы статьясы белән катгый тыелган булуга карамастан, суд членнары гайбәт сатудан сакланып кала алмадылар. Алар суд утырышларында сөйләнгән бар сүзне шул ук көнне хатыннарына җиткерделәр, хатыннарыннан ул сүз, кабарып-арттырылып, шәһәрдәге бүтән таныш ханымнарга күчте, алардан тегүче хатыннар, акушеркалар теленә керде, хәтта хезмәтче-асрауларга кадәр барып житте. Кыскасы, тәүлек эчендә Ромашов шәһәрнең бер әкияте, заман каһарманы булып әверелде. Урамнан узып барганда, аңа тәрәзәләрдән, капка төпләреннән, бакча эчләреннән һәм койма ярыкларыннан карап калалар; хатын-кызлар ерактан ук бармаклары белән төртеп күрсәтәләр, һәм ул бик еш үз артында кемнәрнеңдер «Ромашов, Ромашов» ди-ди ашыгып пышылдашуларын ишетә иде. Аның Николаев белән дуэльгә чыгачагына шәһәрдә беркем дә шикләнмәде диярлек. Хәтта бу дуэльнең ихтималый нәтиҗәсе турында үзара бәхәс тотучылар да бар иде.

Пәнҗешәмбе көн иртән Лыкачевлар өе яныннан җәмгыятькә таба узып барганда, Ромашов кинәт кемнеңдер аңа исеме белән дәшеп кычкыруын ишетте:

— Юрий Алексеевич, Юрий Алексеевич, килегез әле монда.

Ромашов туктады да башын югары күтәрде һәм бакча рәшәткәсенең аргы ягында эскәмия өстендә басып торган Катя Лыкачеваны күрде. Кыз өстенә юка жиңел япон халаты кигән; халатның өчпочмак рәвешендәге ачык изүеннән аның яшьләрнекечә саф, шома, озын нечкә муены аеруча матур булып күренә иде. Гомумән, Катяның пешеп-янып торган бөтен йөзе-кыяфәте, тәмле-нәгыз сыны Ромашовның кәефен берьюлы ачып жибәргәндәй булды.

Кыз рәшәткә аша үрелеп бөгелде дә юынудан соң әле жылынып та өлгермәгән салкын, дымлы учын күрешер өчен Ромашовка таба сузды. Шул ук вакытта ул сакау теле белән тиз-тиз сөйләп китте:

— Ник сес бесгә килмисес? Дуслаьны алай опытыьга яьыймыни, оят киьәк. Явыс, явыс, явыс... Тссс, мин баьын да, баьын да беләм! — Ул куркынган төстә күзләрен шарландырды.— Менә моны алыгыс да муеныгысга тагыгыс, чынлап әйтәм — тагыгыс, такмый калмагыс.

Шулай дип, ул халатының изүенә, нәкъ күкрәге турысына, кулын тыкты да, аннан шнурлы һәм зәңгәр төстәге ефәк чүпрәккә төрелгән бөти сыман бер нәрсә чыгарып, аны шундук Ромашовның учына төртте.

— Ярдәм итәме соң? — диде Ромашов, шаяртып.— Нинди нәрсә ул?

— Анысы минем сеь, көлмәгес. Диннән ясган! Явыс!

Ромашов Катя белән саубуллашты да юлын дәвам иттерде. «Әйбәт кызый,— дип уйлап куйды ул эченнән.— Менә кайчан, димәк, минем даным шаулый башлады». Ләкин шундук, үзен өченче затка күчереп, бу юлы да үз-үзенә купшы фраза белән соңгы бәясен әйтмичә кала алмады:

«Карт бретернең[1] кырыс чыраеннан йомшак-ягымлы елмаю галәмәте чагылып узды».

Шул ук көнне кичен аны — монысында инде Николаев белән бергә — яңадан суд утырышына чакырып алдылар. Хөкем өстәле каршында көндәшләр бөтенләй янәшә, иңгә-иң тиеп дигәндәй басканнар иде. Бер-беренә бер мәртәбә дә күтәрелеп карамасалар да, бу вакыт аларның һәркайсы көндәшенең кәефен, күңеленнән ни кичергәнен аңлап-тоеп торды һәм киреңке бер халәттә шул турыда борчылып уйланды. Хөкем карары укылганда да алар шулай, күзләре белән председательнең йөзенә кадалып, кымшанмыйча басып тордылар.

«...№ нче пехота полкы офицерларының җәмәгать суды,— дип укыды Мигунов суд составына кергән барлык кешеләрнең чин, вазифа һәм фамилияләрен санап чыкканнан соң,— офицерлар җәмгыяте бинасында поручик Николаев белән подпоручик Ромашовның үзара бәйләнешүе хакындагы эшне тикшереп, түбәндәге нәтиҗәгә килде: югарыда исемнәре аталган офицерлар арасындагы бу низаг, артык тирәнгә китеп, намуска тию, бер-берен чамадан тыш хурлау, бер-беренә каршы кул күтәрү төсен алганлыктан, ул гади татулашу юлы белән генә хәл ителә алмый, шуңа күрә суд әлеге ике офицерның дуэль мәйданына чыгып басуын офицерлык намусын һәм горурлыгын канәгатьләндерердәй бердәнбер чара итеп саный.

---

[1] *Бретер* — дуэльдә сугышырга яратучы, дуэль чукмары.

Судның бу фикере полк командиры тарафыннан да расланды».

Карарны укып бетергәч, подполковник Мигунов борыны өстеннән күзлеген тартып алып футлярына салды да, чыраендагы кырыс тантаналык галәмәтен саклаган хәлдә, үзеннән болай дип әйтте:

— Хәзер сезгә, әфәнделәр, секундантлар сайларга кирәк булыр, һәр яктан — икешәр кеше. Сайлагач, аларны иртәгә сәгать тугызга монда жибәрерсез, без шунда бергәләп дуэльнең шартларын эшләп чыгарбыз. Хәер,— дип өстәде ул, урынынан торып һәм күзлек савытын чалбарының арткы кесәсенә яшереп,— хәер, әле генә укылган хөкем карары сезнең өчен мотлак мәжбүри түгел. Сез ирекле: яки бер-берегезгә каршы дуэль мәйданына чыгып басасыз, яки... — Мигунов, кулларын жәеп, бераз пауза ясап торды,— яки хәрби хезмәтне ташлап китәсез. Шул... сүзем бетте, әфәнделәр... Хәер, туктагыз, тагы әйтәсем калган икән. Председатель буларак түгел, өлкән иптәшегез буларак, мин сезгә, офицер әфәнделәр, шуны киңәш итәр идем: дуэльгә кадәр жәмгыять клубында күренмәү хәерлерәк булыр. Юкса көтелмәгән аңлашылмаучылыклар килеп чыгарга мөмкин... Хушыгыз...

Николаев, кырт борылып, кызу адымнар белән залдан чыгып китте. Аның артыннан әкрен генә атлап Ромашов та чыкты.

Күңелдә курку-фәлән юк иде, ләкин ул үзен бу вакыт кинәт кенә бөтенләй япа-ялгызы калган, бөтен дөньядан сәер рәвештә аерымланып, гүя аңардан кисеп алынган бер кеше хәлендә хис итте. Жәмгыять клубының баскыч башына чыккач, ул, туктап, гажәпсенгән тыныч күз карашы белән бик озак күк йөзен, агачларны, каршыдагы койма буенда утлап йөргән сыерны, юл уртасында тузанда чыркылдашып әүмәкләшкән чыпчыкларны тамаша кылып торды һәм үзалдына: «Менә — барлык тереклек ияләре үзләренчә яши бирәләр, нәрсәдер кайгырталар, ыгы-зыгы киләләр, үсәләр, балкыйлар, тик минем генә бернигә катышым юк, миңа гына берни кирәкми, берни кызык түгел. Мин — хөкем ителгән кеше. Мин — ялгыз»,— дип уйланды.

Ул, бөтенләй теләр-теләмичә, иренеп кенә дигәндәй, үзенә секундантлар итеп алырга уйлаган ике иптәшен — Бек-Агамалов белән Веткинны эзләргә китеп барды. Тегеләр аның үтенечен шундук кабул иттеләр — караңгы чырайлы Бек-Агамалов, артык күп сөйләшмичә, сабыр гына ияген кагып куйды, ә Веткин, күп мәгънәләр белдергән серле күз

карашы белән иркәләп-сөеп, бик озак Ромашовның кулын кысып торды.

Күңелсез, шомлы фатирга кайтып керәсе килми иде. Бу авыр минутта — рухи гаҗизлек, ялгызлык, тормыштан бизү минутында — Ромашовның җаны үзенә сердәш булырдай якын, кайгыртучан дусны, бар хәсрәтен аңлый алырдай нечкә күңелле, сизгер, саф йөрәкле кешене күрергә теләде. Һәм кинәт аның хәтер күгендә янә Назанский калкып чыкты.

XXI

Назанский, гадәттәгечә, өйдә иде. Ул әле генә авыр, махмырлы йокыдан уянган һәм хәзер, ике кулын баш артына куеп, бер кат эчке күлмәктән, караватында ята иде. Күзләрендә — арыганлык, ниндидер битарафлык сөреме белән өртелгән томанлы пәрдә. Ромашов, өстенә иелеп, икеләнү катыш борчылу белән:

— Исәнмесез, Василий Нилыч, сезгә комачауламадыммы? — дигәч тә, аның бу йокылы, битараф кыяфәте аз гына да үзгәрмәде.

— Исәнмесез,— диде ул карлыккан, зәгыйфь тавыш белән.— Ниләр бар дөньяда? Утырыгыз.

Шулай дип, ул Ромашовка таба кайнар, дымлы учын сузды, ләкин күз карашында нур әсәре сизелмәде, әйтерсең аның каршында яраткан ахири дусты, күңелле иптәше түгел, ә кайчандыр бик күптән саташулы төшендә күргән кызыксыз бер күләгә, өрәк басып тора иде.

Ромашов, кыюсыз гына, караватның аяк очы ягыннан үзенә урын алып утырды.

— Әллә авырыйсызмы, Василий Нилыч? Алайса мин китим, мәшәкатьләп тормыйм сезне.

Назанский мендәреннән чак кына башын күтәрде һәм, йөзе-кашы җыерылып, Ромашовка таба көчәнүле күз карашы ташлап алды.

— Юк... Китми торыгыз. Аһ, үтереп баш авырта! Карагыз әле, Георгий Алексеич... сезнең чыраегызда да нидер бар бүген... ниндидер... гадәттән тыш нәрсә бар. Бераз сабыр итегез, мин һич зиһенемне җыя алмыйм. Сезгә ни булды?

Ромашов кызганулы бер теләштәшлек белән сүзсез генә аның йөзенә төбәлеп карады. Сәер: соңгы тапкыр күрешкәннән соң узган кыска гына вакыт эчендә Назанскийның кыяфәте бик нык үзгәреп киткән. Кара кайма ураган

күзләре тәмам эчкә батып кергән; чигә-яңакларына сары тут йөгергән; сирәк көдрә сакал каплаган кытыршы, пычрак бит-ияклəренең тиресе, лыҗбырдап кабарып, аска таба салынып тора.

— Болай берни дә булмады, сезне күреп чыгыйм дип кенә кергән идем,— диде Ромашов, мөмкин кадәр гамьсезрәк булырга тырышып.— Иртәгә мин Николаев белән дуэльдә атышам. Өйгә кайтасым килмәде. Хәер, кайтсам да ярый инде хәзер. Хушыгыз. Сөйләшеп утырырдай кеше тапмадым, шуңа гына керүем иде... Җан бик сызлана.

Назанский күзләрен йомды, йөзенә чиксез бер газаплану галәмәте чыкты. Ул шулай, гайре табигый көчәнү белән ихтыярын бер ноктага туплап, томанлы акылының уйлау-фикерләү сәләтен кире кайтарырга тели иде булса кирәк. Күзләрен яңадан ачканда инде аның керфекләре арасыннан җылы, игътибарлы нур чаткылары елтырап күренә иде.

— Юк, китмәгез... без менә нәрсә эшлик,— диде ул һәм ыңгыраша-ыңгыраша яны белән борылып ятты да терсәгенә таянды.— Шуннан, шкафтан алып килегез әле... нәрсә икәнен үзегез беләсез... Юк, алмасы кирәкми... Анда баллы кабартмалар бардыр. Рәхмәт, кадерлем. Без менә нәрсә эшлик... Фу, нинди тәмсез!.. Иң яхшысы, сез мине кая да булса берәр җиргә алып китегез — монда бөтенесе җирәнгеч, аннан мин монда куркам да... Күз алдында гел әллә нинди өрәкләр йөри кебек. Су буена барып, сөйләшәсөйләшә дигәндәй, көймәдә йөреп кайтырбыз. Телисезме?

Ул чиксез җирәнү белән чыраен чыта-чыта, рюмка артыннан рюмканы авызына каплый торды, һәм эчкән саен аның йөзенә әкрен-әкрен тормыш нуры кунып, зәңгәр күзләренә әүвәлге җанлылык, сөйкемлелек өстәлә барды.

Урамга чыккач, алар извозчик ялладылар да шәһәрнең икенче башына, елга буена китеп бардылар. Монда буып алынган шактый зур сулык булып, сулыкның бер як ярында бер яһүд баеның турбина ярдәмендә эшли торган һәм кызыл кирпечтән салынган галәмәт зур тегермән бинасы тора, ә икенче як ярда су коену корылмалары һәм көймә станциясе урнашкан иде. Шунда бер көймә алып, Ромашов ишкәккә утырды, ә Назанский койрыкта өстенә шинелен ябынып бортка кырын ятты.

Плотина белән буып алынганлыктан, елганың суы шактый киң җәелгән һәм күлдәге кебек агымсыз иде. Аның ике яклап еракка сузылып киткән тигез, сөзәк үрлә ярларын яшел чирәм каплаган; ерактан караганда бу чирәм ке-

ләме шундый ачык төсләр белән уйный һәм шундый тигезтоташ булып күренә иде ки, аны, ирексездән, барып кулга тотып карыйсы килә иде. Яр астында, су читендә, камыш сабаклары яшелләнеп утыра, ә карасу төстәге түгәрәк куе яфраклар арасында ак башлы зур төнбоеклар күренә иде.

Ромашов үзе белән Николаев арасында булган җәнҗалны бөтен ваклыкларына хәтле сөйләп чыкты. Аны тыңлаганда Назанский, уйчан кыяфәттә башын түбән салындырып, гел суга карап утырды — суның куе пыяла эремәсе сыман салмак кына тирбәлә-дулкынлана көймә борыныннан як-якка аерылып, җемелдәвек эз булып артта сызылып кала баруын тамаша кылды.

— Дөресен генә әйтегез әле, Ромашов: сез курыкмыйсызмы? — дип сорады ул кинәт шыпырт кына.

— Дуэльдәнме? Юк, курыкмыйм,— дип җавап кайтарды Ромашов. Ләкин шундук, иртәгә буласы атышуны, Николаев каршысында, шомлы револьвер көпшәсенә күз төгәп, үзенең ни рәвештә басып торачагын күз алдына китереп, ашыгып өстәп куйды: — Юк, юк, курыкмыйм дип әйтү бигүк дөрес булмас. Куркыныч, әлбәттә. Ләкин мин сер бирмәячәкмен, атышудан баш тартырга яисә гафу үтенергә уйламаячакмын да.

Назанский кичкә авышкан тымызык көн яктысында чакчак кына шадраланып күренгән җылы елга суына бармак очларын тидереп алды һәм әкрен, зәгыйфь тавыш белән, минут саен ютәлли-ютәлли, сүзен башлады:

— Их, Ромашов кадерлем, Ромашов кадерлем, нигә кирәктер бу сезгә? Уйлап карагыз: әгәр сез үзегезнең курыкмавыгызны беләсез икән,— аны әгәр төгәл беләсез икән,— ул чакта бит бу атышудан бөтенләй баш тарту күп мәртәбә кыюрак адым булыр иде.

— Ул минем... битемә сукты! — диде Ромашов, аклангандай, һәм аның күңеленда янәдән чиксез нәфрәт-ачу дулкыны кузгалып куйды.

— Сукса соң, шуннан ни булган? — диде Назанский һәм Ромашовка таба моңсу, мөлаем күз карашын юнәлтте.— Хикмәт сугудамыни? Дөньяда бер нәрсә дә мәңгелек түгел, сезнең күңелдәге рәнҗү, ачу-нәфрәт тә шулай тиз үтеп китәр. Бервакыт бу җәнҗалны сез үзегез дә онытырсыз. Ләкин менә үз кулыгыз белән үтергән кешене сез беркайчан да оныта алмаячаксыз. Урында ятканда да, өстәл янында утырганда, ялгыз калганда, кеше арасында йөргәндә дә ул гел сезнең белән бергә булачак. Бугаз киерүчеләр, фильтрланган дураклар, туң маңгайлар, попугай

җонына төренгән сыбызгылар ышандырмакчы булалар: янәсе, дуэльдә кеше үтерү — ул үтерү түгел. Нинди мәнсезлек! Шул ук вакытта бу кешеләр, сентиментальләнеп, юл басучыларны җан кыючы, адәм канын эчүче ерткыч җанварлар итеп күз алдына китерәләр. Юк, кеше үтерү — ул һәр очракта да үтерү. Хикмәт монда кемнедер рәнҗетүдә, көчләүдә, аның каныи коюда яисә шул коелган канны күреп, мәетне күреп күңелдән җирәнү хисе кичерүдә дә түгел, юк, монда иң коточкычы — бу кешене тереклек рәхәтеннән, тереклек шатлыгыннан мәхрүм итүдә. Бөек тереклек шатлыгыннан мәхрүм итүдә!— дип кабатлады Назанский калтыранган, яшьле, каты тавыш белән.— Югыйсә бит беркем дә — сез дә, мин дә, ах, алай гынамы, гомумән, җир йөзендәге бер кеше дә — теге дөньяда тормыш барлыгына ышанмый. Әнә шуңа күрә дә һәммә кеше үлемнән курка, ләкин зәгыйфь рухлы дураклар — үлемне көткәндә әллә нинди җәннәт бакчалары, моңлы кастрат җырлары турында уйлап, үз-үзләрен алдап маташалар, көчле рухлылар исә бу зарури чикне тавыш-тынсыз гына кичеп чыгалар. Без — көчле рухлылар түгел. Үлгәннән соң нәрсә буласын уйлаганда, без гадәттә караңгы, салкын, буш базны күз алдына китерәбез. Юк, туганкай, барысы да ялган моның: андый баз ул әле үзенә күрә бер бәхетле алдану, шатлыклы юаныч булыр иде. Ә сез менә болай итеп күз алдына китерегез: үлгәч, әйтик, берни калмый — базы да юк, бушлыгы, караңгысы, салкыны да юк... хәтта бу турыдагы фикер үзе дә булырга мөмкин түгел, хәтта курку дигәне дә юк! Аңлыйсызмы, хәтта курку дигәне дә юк! Уйлап карагыз!

Ромашов ишкәкләрне көймә кырына күтәртеп куйды. Көймә әкрен генә, бөтенләй күзгә сизелмичә диярлек йөзеп бара, аның хәрәкәтен фәкать яшел ярларның артка таба ашыкмыйча шууына карап кына чамаларга мөмкин иде.

— Әйе, үлгәч берни дә булмаячак,— дип кабатлады Ромашов уйчан төстә.

— Ә сез карагыз, юк, ичмасам бер генә мәртәбә тирәягыгызга күз салыгыз: нинди гүзәл, нинди соклангыч бит ул тереклек дигәнең! — дип, кулларын җәеп, дәртле тавыш белән кычкырып җибәрде Назанский.— И син, тереклекнең бетмәс куанычы, илаһи тормыш матурлыгы! Әнә карагыз: зәңгәр күк йөзе, кичке шәфәкъ, талгын су өстә — боларны күргәч кенә дә бөтен тәнне калтырау ала бит; әнә анда, ераста-ераста, җил тегермәне канат кагына: әнә тегендә,

яр өстендә, яшел чирәмлек җәйрәп ята, ә су читтә алсу, алсу — шәфәкъ нурлары эчендә коена диярсең. Их, нинди гүзәл, нинди соклангыч, куанычлы бит болар барысы да!

Назанский кинәт күзләрен куллары белән каплады һәм үксеп елап җибәрде. Ләкин шундук, тыелып, йөзен ачты да шулай елап җибәрүенә һич кенә дә уңайсызланмыйча, Ромашовка яшьле, нурлы күзләре белән тутырып карап, өзелгән сүзен дәвам иттерде:

— Юк, мин бернинди очракта да тормыштан туймаячакмын. Поезд тәгәрмәче астында гәүдәм урталай өзелеп, эчәгеләрем ком-балчык белән бергә буталып яисә көпчәккә уралып беткәндә дә — менә шундый очракта да: «Йә, тормыш сиңа хәзер дә гүзәлме?» — дип сораган кешегә мин барыбер, соңгы көчләремне җыеп булса да: «Ah, ул шундый гүзәл!» — дип җавап бирәчәкмен. Күз күреме үзе генә дә күпме шатлык-куаныч китерә бит безгә! Ә аннан башка музыка бар әле, гөлләр исе, хатын-кыз назы, сөю-сөелү бар! Һәм, ниһаять, берни белән дә чагыштырмаслык гүзәл ләззәт — тереклекнең алтын кояшы — фикер-акыл дигән нәрсә бар! Юрочка, кадерлем!.. Алай эндәшүем өчен, зинһар, гафу итегез.— Назанский, кичерү үтенгәндәй, ерактан Ромашовка таба калтыранган кулын сузды.— Әйтик, сезне мәңге-мәңгегә зинданга яптылар, ди; сез анда япа-ялгыз, ди, стенадагы бәләкәй ярык аша сезгә нибары кыршылып-кителеп беткән ике кирпеч кисәге генә күренә, ди... юк, алай түгел, сезнең ул зинданыгызга гомумән бернинди яктылык әсәре үтеп керми, хәтта анда тавыш-аваз да ишетелми дип фараз итик! Шулай булса да, сез бу зинданны шомлы үлем куркынычы белән чагыштырыр идегезме соң? Юк, әлбәттә! Дөм караңгы зинданда да сезнең белән бергә фикерләү сәләте калачак, хыял, хәтер, иҗат ялкыны калачак — болар булганда исә һәркайда яшәргә мөмкин. Сезнең анда хәтта яшәү шатлыгын татып куанган бәхетле минутларыгыз да булырга мөмкин.

— Әйе, яшәү гүзәл нәрсә шул,— дип куйды Ромашов.

— Гүзәл шул! — дип кабатлады Назанский, тәэсирләнеп.— Һәм менә шундый гүзәл яшәү шатлыгы бар чагында, ике кеше берсе икенчесенә сукканы өченме анда яки берсе икенчесенең хатынын үпкәне өченме, яисә бөтенләй юк кына сәбәптән, әйтик, урамнан узып барганда берсенең, мыек чылгыйларын бөтерә-бөтерә, икенчесенә мыскыллы күз карашы ташлап алганы өчен — менә шулар өчен бу ике кеше мәйданга чыгып баса да бер-беренә атыша, бер-берен үтерешә. Ah, юк, хикмәт һич тә аларның җәрәхәтлә-

рендә, газапларында, үлемнәрендә түгел — болары шайтанга олаксын аның! Ул әллә үзен — кеше дип аталып йөртелгән кечкенә, кызганыч, тере ит йомарламын үтерә дип уйлыйсызмы? Ул бит кояшның үзен, кайнар, көләч кояшның үзен үтерә, аяз күкне, табигатьне — тереклекнең бөтен матурлыгын үз эченә җыйган табигатьне үтерә, нинаять, кешелекнең иң бөек горурлыгы, ләззәте булган фикеракылны үтерә! Бер үлгәч беркайчан да, беркайчан да кире кайтмый торган иң кадерле нәрсәләрне үтерә ул! Их, ахмаклар, ахмаклар!

Назанский, авыр уфылдап, хәсрәт белән башын чайкап торды, күзләрен түбән төшерде. Көймә камыш арасына килеп кергән иде. Ромашов янәдән ишкәкләрне кулына алды. Камышларның сыек яшел төстәге биек каты сабаклары, көймә бүксәсенә шыштырдап ышкыла-ышкыла, сәламләп биргәндәй, арттан салмак кына башларын иеп калалар. Ачык су өстендәгегә караганда монда караңгырак та, салкынчарак та иде.

— Нишләргә соң миңа? — дип, караңгы чырай һәм шактый ук дорфа тавыш белән сорап куйды Ромашов.— Запаска китәргәмени? Анда мин ни кылырмын?

Назанскийның йөзенә басынкы, мөлаем бер елмаю галәмәте чыкты.

— Сабыр итегез, Ромашов. Күзләремә туры карагыз әле. Менә шулай. Юк, сез читкә борылмагыз, туп-туры күзгә карагыз һәм сорауларыма алдашмыйча, ихлас күңелдән җавап бирегез. Сез әллә, үзегезне яхшы, кызыклы, файдалы эш белән шөгыльләнә торган бер кеше итеп ышанып йөрисезме? Мин сезне яхшы беләм бит, башка барлык офицерларга караганда да әйбәтрәк беләм, шулай ук жаныгызда ни барын да күрәм. Сез бит әлеге мин әйткән нәрсәгә бөтенләй ышанмыйсыз.

— Әйе, ышанмыйм,— диде Ромашов бернинди икеләнүсез. — Ләкин миңа кая барырга соң?

— Туктагыз, ашыкмагыз. Сез әнә безнең офицер халкына күз төшерегез. О, юк, мин теге, бай ата-аналары яки законлы хатыннары исәбенә яшәп, гомерләрен бал-мәҗлесләрдә биеп уздыручы, французча сөйләшүче гвардия офицерлары турында әйтмим. Сез менә безнең ишеләргә, бичара армеутларга, шөһрәтле, батыр рус армиясенең төп көче, үзәге булган гаскәри пехота офицерларына күз салыгыз, алар турында уйланыгыз. Аларның һәммәсе дә — әтрәк-әләм, өтек койрык, йолкыш, сукбайлар бит асылда. Иң затлы дигәннәре дә — сугыштан гарипләнеп кайткан ка-

питан малайлары. Күпчелеге исә — мәгърифәт нурыннан куркып качып килгән гимназистлар, реалистлар, ярымйорты семинаристлар. Мисалга безнең полкны гына алып карыйк. Кем бездә һәммәсеннән дә тәртиплерәк һәм озаграк хезмәт итә? Ишле семьялы фәкыйрь-фокара, әлбәттә; бер кашык щи хакына теләсә нинди алдашуга, мәрхәмәтсезлеккә барган, хәтта кеше үтерүдән, солдат акчасын урлашудан да чирканмаган шул хәерче бәндәләр яхшырак һәм озаграк хезмәт итә. Андый офицер ул кушканның бөтенесен эшли; аңа фәләнне атып үтер дип әйтәләр икән, ул күз дә йоммый ата да үтерә. Кемне? Ни өчен? Бәлки, һич гөнаһсызгадыр? — Анда аның кайгысы юк, ул фикер йөртеп маташмый. Өендә бер өер рахитлы, ач-ялангач балачагасы чырылдашып ятканын белә бит ул, шуңа күрә аның теләндә бер генә сүз: «Ант!» Шул сүзне ул, попугай сыман, күзләрен ахмакларча акайландырып, гомере буе кабатлый да кабатлый. Инде араларында берәр талантлысы, сәләтлесе бар икән — аныны эчүгә сабыша. Бездә офицерлар составының җитмеш биш проценты сифилис белән авырый. Биш елга бер мәртәбә бер бәхетлесе академиягә укырга керә, аны анда тирән нәфрәт, ачу белән озатып калалар. Шомараклары, яклаучысы, элемтәсе булганнары тизрәк жандармлык хезмәтенә күчүне карыйлар яки берәр зур шәһәрдә полиция приставы урыны турында хыялланалар. Мал-мөлкәтләре бәләкәйрәк булган дворяннар — хәтта алары да земский начальнигы урынына омтылалар. Аннан тагы, әйтик, сизгер йөрәкле, хискә бай офицерлар бар әле. Алары нишли соң? Мондыйлары өчен гаскәри хезмәт — җирәнгеч, күңел биздергеч, авыр бер йөк, җәбер. Бу кешеләрнең һәммәсе гаскәри хезмәткә бәйләнеше булмаган берәр төрле кызыклы эш-шөгыль уйлап табарга тырыша һәм шуңа бөтен башы-аягы белән кереп чума. Берәве коллекция җыя, икенче берсе, кич життеме, мәтәлә-кадала өенә чаба, кайта да лампа кабызып, кулына тамбур инәсе алып, киергегә тартылган берәр чүпрәккә төрле чигүләр, бизәкләр төшерергә тотына яисә лобзик пычкы белән кисеп, үз портреты өчен сырлы-челтәрле рам ясарга керешә. Хезмәттә чагында да алар гел шул эшләре белән саташалар, күңелләрендә аны татлы, яшерен бер хыял итеп саклап йөртәләр. Карта уйнаучылар, хатын-кыз артыннан йөгерүче бушбугазлар турында әйтеп тормыйм. Әмма иң чирканғычы — шөһрәтчеләр, рәхим-шәфкатьне белмәгән вак жанлы, дуамал холыклы шөһрәтчеләр. Мин монда солдатның тешен сугып сындыру, күзен бәреп чыгаруны бернигә

санамаган Осадчий һәм башка шуның ишеләрне күздә тотам. Беләсезме, бервакыт миңа Арчаковскийның үз денщигын ярсып-ярсып кыйнаганын үз күзләрем белән күргә туры килде. Әле ярый мин аралап калдым. Бичара денщикның каны стена, түшәмнәргә хәтле чәчрәгән иде. Бу кыйнауның соңы ни белән бетте, беләсезме? Шулай: денщик хуҗасыннан зарланырга дип рота командиры янына китә, тегесе моны язу язып фельдфебель янына җибәрә, ә фельдфебель денщикның шешкән, күгәргән, канлы яңагын тагы ярты сәгать буе уңлы-суллы яңаклый. Бу солдат инспекторлар смотры вакытында да ике тапкыр жалоба биреп карады, ләкин жалобасының нәтиҗәсе булмады.

Назанский, сүздән туктап, гасаби бер төстә учлары белән чигә-яңакларын уарга тотынды.

— Тукта... ни сөйли идем соң әле?.. — диде ул бераздан, тирән борчуга калып.— Уйны һичбер эздә тотар хәл юк. Син уйны түгел, ә уй сине ияртеп барса бик яман икән ул, каһәр... Әһә, хәтерләдем! Дәвам итик. Инде офицерларның бүтәннәренә карап багыйк. Менә, әйтик, мисал өчен штабс-капитан Плавский. Шайтан белсен, ашаганы аш түгел — өендә керосинкада үзе әзерләгән ниндидер калдык-постык белән туена, өс-башы — сәләмә, карарга оят. Шул ук вакытта үзе кырык сигез сумлык жалуньясыннан егерме биш сумын ай саен банкка салып бара. Иһи-һи! Аның анда инде ике мең сумга якын акчасы ята диләр, шул сумадан ул зур процент алу шарты белән дус-ишләренә бурычка акча биреп тора. Моны сез тумыштан килгән бер саранлыктыр дисезме әллә? Юк, саранлык түгел бу. Бу — гаскәри хезмәтнең мәгънәсез, аңлаешсыз, авыр көндәлек тормышыннан качу, аны онытып тору өчен эшләнгән бер сылтау, чара гына... Капитан Стельковскийны алыйк. Ифрат акыллы, ихтыярый көчле, кыю кеше. Ә аның дөньяда яшәвенең асыл мәгънәсе нәрсәдә? Тәжрибәсез, яшь крестьян кызларын аздыруда — менә нәрсәдә. Нинаять, подполковник Бремны алыгыз. Сокланып туймаслык әйбәт, сөйкемле, гажәеп нечкә күңелле бер карт югыйсә, ә үзе әнә җәнлекләр арасына кереп баткан. Хезмәт нәрсә дә аңа, парадларың, байрак, намус шелтәләрең нәрсә? Тормыш вак-төяге — бары шул гына.

— Брем — искиткеч әйбәт кеше. мин аны бик яратам,— дип сүз кыстырды Ромашов.

— Сүз дә юк, әйбәт кеше, әлбәттә,— дип, сүлпән генә әйтеп куйды Назанский, аннары, кинәт кенә кашын җыерып, дәвам итте: — Беләсезме, бервакыт маневрларда мин

нинди хәлгә тап булдым? Төнге авыр, озын юл үткәннән соң атакага ташланырга әзерләнеп ятабыз, димәк. Һәммәбез дә — солдатлар да, офицерлар да — тәмам хәлдән таеп, алҗып, нервланып беткән идек. Шул чак Брем быргычыга атака сигналын уйнарга боерык бирде, теге, ни өчен икәнен алла белсен, атака сигналы урынына резерв чакыру сигналын уйнап җибәрмәсенме! Бер мәртәбә уйный бу, икенче, өченче мәртәбә... Кинәт әлеге сөйкемле, нечкә күңелле, әйбәт кеше дигәнебез, Брем ягъни, аты өстендә быргычы солдат янына чаптырып килде дә, селтәнеп торып, тегенең авызга капкан быргысына сугып та җибәрде! Менә шул. Быргычының уалган тешләрен кан белән бергә ничек җиргә төкерүен мин ул чакта үз күзләрем белән күрдем.

— Аһ, нинди вәхшилек! — дип, җирәнү катыш ыңгырашып куйды Ромашов.

— Алар һәммәсе, хәтта иң әйбәт дигәннәре, яхшы ата, игътибарлы ир булганнары да,— хезмәт урынында әнә шулай түбән, куркак җанлы, явыз, ахмак җәнлекләргә әвереләләр. Ни өчен? дип сорарсыз сез. Шуның өчен, чөнки аларның берсе дә гаскәри хезмәткә ышанмый, бу хезмәтнең мәгънәсен, акылга сыярдай максатын күрми. Бала-чаганың ду килеп сугыш уены уйнарга яратуын, шәт, беләсездер. Кешелек тарихында да әнә шундый кайнар балалык чоры, яшь буынның шашынкы, күңелле тормыш белән ду килеп яшәгән чоры булган. Ул чакта кешеләр ирекле шайкалар булып яшәгәннәр, сугыш алар өчен үзенә бер уртак бәйрәм, шашынкыланып күңел ачу, канлы батырлыклар күрсәтү чарасы булып хезмәт иткән. Башлык итеп гадәттә иң көчле, иң батыр, иң хәйләкәр кешене сайлаганнар, аның хакимлеге, кул астындагы берәр кешесе тарафыннан ул үзе үтерелгәнчегә кадәр, илаһи бер кодрәт сыман тәкъдир ителгән. Ләкин менә бер заман кешелек дөньясы үсеп җитә, аның акылы елдан-ел камилләшә, карашлары көннән-көн тирәнәя, җитдиләнә бара, элеккеге балалык шуклыклары тәмам онытыла. Әүвәлге батыр йөрәкле авантюристлар хәзер шулерларга әвереләләр. Солдат инде хәрби хезмәткә, электәгечә, күңелле талау кәсебенә барган кебек бармый. Юк, аны анда муенына аркан салып өстериләр, ә ул һаман карыша, каргана, елый. Башлыклар да инде әүвәлге мәһабәт, дәһшәтле, рәхимсез һәм үзләрен яраттыра белә торган атаманнар түгел, ә гап-гади чиновниклар, барлы-юклы жалуньяларына исәп тотып яшәүче вак җанлы кешеләр. Аларның батырлыгы — кысыр батырлык. Хәрби дисциплина дигәне дә, фәкать куркытуга корылып, үзара

нәфрәт уятудан башка бернигә хезмәт итми. Кыскасы, әүвәлге купшы фазаннарның матур төсләре тәмам уңып калды хәзер. Кешелек тарихыннан моңа охшашлы бер генә мисал беләм мин. Ул да булса — монахлык. Аның да башлангыч чоры бик самими, матур һәм тәэсирле үткән. Кем белә, ул вакыт монахлык, бәлки, дөньякүләм зарурилык таләбеннән килеп чыккан кирәкле бер күренеш булгандыр. Әмма хәзер, берничә гасырдан соң, без ни күрәбез? Монах дип аталучы йөзләгән мең таза, әмма эшсезлектән бозылып беткән әрәмтамаклар өерен күрәбез. Аларны бит хәтта үзләре белән вакыт-вакыт рухани аралашкан тарафдарлары да сөймн. Шул ук вакытта аларның һәммәсе тышкы форма астына — каста, мәзһәбчелек, шарлатанлык, искереп беткән, көлкеле гадәт-йолалар битлеге астына яшеренгән. Әйе, әйе, монахлар турында сүз башлавым юкка түгел минем, аларны офицерлар белән чагыштыруым логикага каршы килми, моңа мин үзем дә шат. Чынлап та, ныклап уйлап карасаң, уртаклыклары шактый күп бит. Монахларда, әйтик,— ряса, кадило; офицерларда — мундир белән корал. Анда — күндәмлек, икейөзләнеп ах-вах килү, тәмле тел; монда — ясалма гайрәтлелек, кәпәренү, «син миңа тиеп кенә кара!» дигәндәй, һәр даим кабынып китәргә торган ялган горурлык, киерелгән күкрәк, тырпайган терсәк, югары чөелгән иңбашлар. Ләкин тегеләре дә, болары да әрәмтамаклар, һәм иң гаҗәбе: әрәмтамак икәнлекләрен күңелләре белән бик яхшы тойсалар да, акыллары һәм, аннан да битәр, корсаклары белән моны һич тә аңларга теләмиләр. Шуңа күрә мин аларны кеше тәне белән тукланучы симез бетләргә охшатыр идем: тән никадәр күбрәк кипсә, алар аны шулкадәр комсызланыбрак ашыйлар.

Назанский ачулы кыяфәттә пошкырып куйды да сүзеннән туктады.

— Сөйләгез, зинһар сөйләгез,— диде Ромашов, ялварып сорагандай.

— Әйе, яңа заман килер, ул әнә капка шакый инде. Коточкыч үзгәрешләр заманы, мәгънәви кыйммәтләр алышыну, күңел бизү, өметсезлекләр заманы булыр бу. Исегездәме, мин сезгә кайчандыр бер әйткән идем шикелле инде: кеше дәһилыгы заман күзенә күренмәс үҗәтлек белән алга юл ярып бара. Аның хәрәкәт законнары төгәл һәм котылгысыз. Һәм акылы отыры үскән саен, кешелек әлеге законнар кысасына тагы да тирәнрәк керә, аларга тагы да күндәмрәк буйсына. Һәм минем иманым камил: бу катгый законнар иртәме, соңмы дөньядагы бөтен нәрсәне тигезләп

куячак. Әгәр коллык гасырлар буена дәвам итә икән, аның җимерелүе дә коточкыч афәтле төс ала. Җәбер никадәр көчле булса, аңардан үч алу рәвеше дә шулкадәр рәхимсез. Шундый бер заман килер, безнең ише патентлы көязләргә, азгын, талымсыз күпшы әтәчләргә хатын-кызлар карарга да оялыр, алай гынамы, солдатына хәтле безне санламый башлар. Гомер буе ул бичара, хокуксыз солдатларны канга батырганчы кыйнап яшәгәнебез өчен дә булмас бу үч алу, мундир биргән хокукка сыенып, бернинди жаваплылык хисе тоймыйча, адым саен хатын-кызны мәсхәрәләгәнебез өчен дә түгел, яки дөм исереп, харчевняларда кул астына эләккән бер кешене тиктомалга кыйнап, кылыч белән тураклап йөргәнебез өчен дә түгел. Әлбәттә, алары өчен дә өлешчә үч алыныр. Ләкин безнең бу эйткәннәрдән күп мәртәбә коточкычрак бүтән гаебебез — инде хәзер бөтенләй төзәтеп булмый торган зуррак гаебебез бар. Бу — безнең һәрнәрсәдән гафил, сукыр-чукрак булып яшәвебез. Кайдадыр читтә, безнең пычрак, сасы җәйләү-кышлакларыбыздан ераста-ераста, күптән инде зур, яңа, нурлы тормышның яралгылары шытып килә. Дөньяда яңа, кыю, горур кешеләр пәйда булды; күңелләрдә ялкынлы, хәр фикерләр дөрләп кабынды. Мелодраманың соңгы пәрдәсендәге кебек, искелек башнялары, зинданнар дөбер-шатыр җимерелә, алар артыннан инде киләчәкнең күз камаштыргыч нурлы балкышы күренә. Ә без, һинд әтәчедәй кукраеп, йоныбызны кабартып, һаман әле бер урында аптырап басып торабыз, тәкәбберләнеп: «Нәрсә? Кайда? Тавышыңны чыгарма! Бунт ясаргамы? Шундук атып үтерермен!» — дип акырудан башканы белмибез. Дөнья безне нәкъ менә шуның өчен — кешенең рухи хөрлегенә элеге һинд әтәчедәй тәкәббер төстә каршы торуыбыз өчен гафу итмәячәк, мәңге гафу итмәячәк ул безне.

Көймә шул чак ниндидер тын, аулак һәм әйләнә-тирәсе куе, биек камыш сабаклары белән яшел стенадай уратып алынган сай урынга килеп керде. Монда ул бөтен дөньядан качып, яшеренергә кергән сыман күренә иде. Камышлык өстендә әче авазлар белән һаваны ярып кычкыра-кычкыра акчарлаклар бөтерелә; кайчак алар баш очыннан шулкадәр якын очып узалар, Ромашовның йөзенә хәтта канат җилләре бәрелеп-бәрелеп китә иде. Күрәсең, кайдадыр якында гына, камышлык арасында, аларның оялары бар иде. Назанский көймә койрыгында утырган җиреннән бортка чалкан ятты да күк йөзенә, анда берән-сәрән хәрәкәтсез эленеп торган һәм инде шәфәкъ нурларына манчыла баш-

лаган алтынсу болыт кантарларына бик озак карап торды.

Ромашов кыюсыз гына аңа эндәште:

— Сез бик арымадыгызмы, Василий Нилыч? Тагы сөйләгез әле.

Һәм Назанский, башында кайнаган фикерләрен сүзгә күчереп дәвам иткәндәй, янә сөйләргә кереште:

— Әйе, яңа, искитмәле, гаҗәеп шәп заман якынлашып килә. Мин бит проста шактый озак яшәгән кеше, миңа күп кенә нәрсәләрне үз җилкәмдә татырга, күпне күрергә, шактый гына китаплар укырга туры килде. Моңарчы, мәктәп эскәмиясеннән алып хәзергәчә дигәндәй, чиркәү козгыннары һәм каргалары безгә гел бер нәрсәне тукыдылар. Янәсе: «Кешене ярат, аны үз туганың кебек сөй; исеңдә тот: кешене кеше иткән сыйфатлар — ул буйсыну, күндәмсабыр булу, өркү-тетрәнү». Намуслыраклары, гайрәтлерәк, ерткычрак булганнары исә бүтән сүзләр белән үгетләделәр: «Кулга-кул тотынышып дәррәү күтәрелик тә, киләчәк буыннарның якты, хөр тормышта яшәүләре хакына яу кырында башларыбызны салыйк». Ләкин мин үзем мондый сафсаталарны гомерем буе аңлый алмадым. Йә, әйтегез алайса: үз туганымдай сөяргә тиешле ул бәндәгә — шайтан алгырысы! — шул кабахәт кол, шакшы, җирәнгеч идиотка минем нинди галәкәм бар? — Йә, моны миңа кем исбатлап бирер дә, кем мине моңа ышандырыр? Дини риваятьләрдән минем бөтен җаным-тәнем белән сөймәгәнем, минем иң җен ачуларымны чыгарганы — ул да булса Юлиан Рәхимле турындагы риваять. Анда махау авырулы бер үләксә бәндә болай ди: «Мин калтыраям, кил, минем яныма ят. Мин туңдым, кил, иреннәреңне минем бозылып сасыган авызыма якынайт, миңа сулышыңны өр». Ух, женем сөйми! Махаулыларын да, үз туганымдай яратырга тиешлеләрен дә женем сөйми! Аннан әлеге теге үзеңне корбан итү турындагы сафсатаны алыйк. Йә, нигә әле мин ерак киләчәк, ниндидер утыз икенче гасыр кешеләренең бәхете өчен башымны гүргә салырга тиеш? Ниндидер гомум кешелек җаны, изге бурыч турындагы андый тавык фәлсәфәсен күп ишеттем инде мин. Хәтта акылым ышанып куйган чакларда да, күңелем белән мин аларны беркайчан да кабул итмәдем. Сез минем фикер сөрешен аңлыйсыздыр, шәт, Ромашов?

Ромашов Назанскийга таба рәхмәт катыш ятсынулы күз карашы ташлап алды.

— Мин сез сөйләгәннәрне бик яхшы аңлыйм, Василий Нилыч, бик яхшы аңлыйм,— диде ул.— Мин үлгәч, минем

өчен дөнья үзе дә юкка чыга. Сез шул хакта сөйлисез бит?

— Нәкъ үзе. Мин әйтәм, гомум кешелеккә мәхәббәт хисенең әүвәлге ялкыны инде тәмам сүрелде, адәм йөрәгеннән төтенгә пыскып чыгып бетте, дим. Аңа алмашка хәзер бүтән иман, яңа, илаһи иман килә; анысы мәңгелек, анысы мәхшәргәчә дәвам итәчәк. Бу иман — үз-үзеңне ярату, үзеңнең гүзәл тәнеңне, кодрәтле акылыңны, иксез-чиксез бай хис-тойгыларыңны ярату. Юк, сез уйлагыз, Ромашов, ныклап уйлагыз: сезгә үз-үзегездән дә кадерлерәк, якынрак тагын кем бар? Беркем дә юк. Сез — дөньяның солтаны, аның горурлыгы, бизәге. Сез — үз тереклегегезнең бердәнбер алласы. Күзегез күргән, колагыгыз ишеткән, күңелегез хис иткән бар нәрсә — һәммәсе, һәммәсе дә фәкать сезнеке генә. Нишлисегез килә, шулай эшләгез. Күңелегезгә нәрсә ошый, бөтенесен үзегез алыгыз. Дөньяда бернидән дә курыкмагыз, чөнки сездән өстен, сезгә тиң кеше бөтен галәмендә юк. Шундый бер заман килер, әлеге бөек иман — үзеңнең «Мин»еңә табыну,— изге фәрештәнең ялкынлы сулышы белән иңдерелгән дога кебек, барлык кешеләрнең җаннарына кереп урнашыр, һәм менә шул вакыт инде дөньяда бернинди коллар, бернинди түрәләр, бернинди гарип-гораба да булмас, кызгану, бозыклык, явызлык, көнчелек дигәне дә булмас. Ул чакта һәр кеше үзенә аерым бер алла булып яшәр. Инде шуннан уйлап карагыз: һәркемне үзеңә тиң, пакь алла итеп хис иткәндә, мин кемне дә булса рәнҗетә, аны төртеп җибәрә яки алдый аламмы соң? Юк, әлбәттә. Ул чакта яшәү искиткеч матур, ямьле булыр. Кая карама анда якты тәрәзәле, җиңел, нәфис йортлар балкып торыр; күз карашын бернинди тупас тамашалар да рәнҗетмәс, яшәү үзе үк татлы хезмәт, азат фән, тылсымлы музыка бәйрәменә — мәңге күңелле тормыш бәйрәменә әйләнер. Мәхәббәт тә, хәзергечә, караңгы почмакта тирәякка куркып карана-карана, яшерен рәвештә эшләнә торган җирәнгеч, хурлыклы гөнаһ булмас, ул, наданлык, хәсусыйчылык богауларыннан мәңгегә котылып, кешелек дөньясының бердәнбер якты, уртак диненә әверелер. Тәнебез, буй-сыныбызга хәтле үзгәрер, камилләшер безнең; без мәһабәт кыяфәтле, көләч-матур йөзле, көчле кешеләр булырбыз, күз явын алырдай матур киемнәр киеп йөрербез. Баш очымдагы шушы күк йөзен күреп инанганым шикелле,— дип, кулын тантаналы төстә югары чөйде Назанский,— мин ул киләчәк матур, илаһи тормышның барлыгына да шулай ышанам!

Чиксез дулкынлау эчендә тетрәнеп утырган Ромашов, күм-күк иренпәрен чак кына кыймылдатып, әкрен генә әйтеп куйды:

— Василий Нилыч, хыял гына бит бу, фантазия бу!

Назанский үзалдына кеткелдәп көлеп алды.

— Әйе,— диде ул шуклык аһәңе сизелгән тавыш белән,— моны берәр догматик юнәлештәге дин гыйльме яки классик филология профессоры ишетсә, ул шундук утырган җиреннән аякларын аера биреп һәм башын кырын салып, як-якка кулларын җәеп җибәрер иде дә: «Ләкин бу — чиктән ашкан индивидуализм чагылышы бит!» — дияр иде. Хикмәт бит хыялның коточкыч дәһшәтле сүзләр булып яңгыравында түгел, кадерле егеткәем, ә гомумән аның дөньялык өчен гамәли яктан бик файдалы булуында. Хәзер генә ул кешеләр хыялны онытып баралар. Ә чынында хыял, фантазия — кешеләрне берләштерү өчен иң ышанычлы, иң кулай чараларның берсе. Үзебезнең хәрби кешеләр икәнебезне беразга онытып торыйк. Без — шпаклар диик. Әнә урамда, чатта, аждаһа — ике башлы, мәзәк кыяфәтле аждаһа тора. Янып нан кем генә узса да, ул аның танавына менә дә төшә, менә дә төшә. Әлегә миңа сукканы юк югын, әмма аның миңа сугуы мөмкин дигән уй, миңа, мин яратканхатынга сугуы, мине иректән мәхрүм итүе мөмкин дигән уй — менә шушы шик үзе генә дә минем горурлыгымны тәмам тырнакларын тырпайтып ыржаерга мәҗбүр итә. Ялгызым мин ул аждаһаны җиңә алмыйм. Ләкин, әйтик, минем янымда үзем кебек үк кыю, горур тагы бер кеше бар, ди; мин аңа тәкъдим ясыйм, ди: «Әйдәгез, икәү бергәләп, шул аждаһаны акылга утыртыйк әле,— моннан соң сиңа да, миңа да сугасы булмасын»,— дим, имеш. Һәм без тегене шулай акылга утыртабыз да. О, бу, әлбәттә, тупас мисал, схема бу, ләкин мин үземне рухи һәм ихтыяры яктан кысылырга, кимсенергә мәҗбүр иткән, үз шәхесемә ихтирамымны киметкән нәрсәләрнең төп сәбәпчесен әнә шул ике башлы аждаһа йөзендә күрәм. Ә инде әлеге, «якыныңны сөй, ярат» дигән кызганулы фәлсәфә урынына миндә үз-үземә илаһи ихтирам, ярату булганда, мин үз көчләремне һәм омтылышларымны бүтәннәрнең — рухи яктан миңа тиң кешеләрнең — көч-омтылышлары белән берләштерә алачакмын!

Назанский сөйләүдән туктады. Нервлы, гадәтләнелмәгән рухи күтәренкелек, әсәрләнү аны шактый алҗыткан иде булса кирәк. Бераздан янә сүз башлаганда, аның тавышы инде бөтенләй тоныкланып, зәгыйфьләнеп ишетелде:

— Менә шулай эшләр, кадерле Георгий Алексеевич. Безнең әйләнә-тирәбездә катлаулы, зур тормыш кайный, анда ялкынлы, илаһи фикерләр туа, моңарчы табынган иске потлар дөбер-шатыр җимерелә. Ә без менә, йодрыкларны бөергә терәп, үз җәйләвебез мәйданында кукраеп басып торабыз һәм ни генә күрсәк тә, тамак ертып: «Ах, сезме бу, идиотлар! Шпаклар! Каезларга кирәк сезне! — дип акырынабыз. Әйе, моның өчен тормыш безне беркайчан да гафу итмәячәк...

Ул, гәүдәсен калкыта биреп, пальтосына төренебрәк утырды да арыган тавыш белән:

— Салкын... Кайтыйк өйгә... — диде.

Ромашов көймәне камышлар арасыннан кайту юлына алып чыкты. Кояш инде шәһәр артына кереп яшеренгән, һәм аның ерактагы офык сызыгы буйлап сузылган кызгылт яктылыгында йорт түбәләре караеп, аермачык булып шәүләләнәләр иде. Әле монда, әле тегендә шәфәкъ нурына чагылып, тәрәзә пыялалары җемелдәп күренә. Алда, кояш баешы ягында, су өсте тип-тигез, шома, көләч һәм алсу нур эчендә коена, ләкин көймә артында ул инде куе зәңгәр төскә кереп карала, шадралана башлаган иде.

Ромашов кинәт, күңелендәге уйларын дәвам иткәндәй:

— Сез хаклы. Миңа чыплап та запаска китергә кирәк. Ул ни рәвешле килеп чыгар — анысын әйтә алмыйм, әмма запаска китү турындагы уй миндә күптәннән бар инде,— диде.

Назанский, калтыравын баса алмыйча, һаман пальтосына ныграк төренергә тырыша иде.

— Әйе, запаска китүегез хәерлерәк булыр,— дип, йомшак сагыш белән әйтеп куйды ул.— Белмим, аны ничек дип атаргадыр, әмма сезнең күңелдә... ниндидер серле бер ут яна шикелле тоела миңа. Белегез: безнең бу аю өнендә ул ут озак яна алмаячак — өстенә төкереп, аны шундук сүндерәчәкләр. Иң беренче шарт — сез яшәүдән курыкмагыз, тормыштан курыкмагыз: гажәеп күңелле, кызыклы нәрсә ул тормыш дигәне. Ну, ярар, бәхетегез туры килмәде, ди,— сез, түбән тәгәрәп, сукбай хәленә, эчкече хәленә төштегез, ди. Ләкин бит теләсә нинди сукбай да Адам Иваныч Зегржтка яки капитан Сливага караганда мең өлеш, ун мең өлеш кызыклырак, тулырак тормыш белән яши, валлаһи шулай. Җирне аркылыга-буйга иңләп тик йөри бирәсең, шәһәр, авыллар аша узасың, төрле-төрле кешеләр — сәер, гамьсез-кайгысыз, мәзәк шәхесләр белән оч-

рашасың; кыскасы, барысын күрәсең, ишетәсең, барысын иснәп-татып карыйсың, чыклы үләнгә ятып йоклыйсың, туңасың, пешәсең; шул ук вакытта беркемнән курыкмыйсың: син бәйсез, ирекле кеше; әнә шуңа да син аны, ул ирекле тормышны, бөтен бәгырь парәләрең белән яратасың... Эх, кешеләр мондый нәрсәләрне аңлап бетермиләр шул әле! Барыбер түгелмени: кипкән балык ашадың ни дә трюфель белән майлы кыргый кәҗә сырты кимердең ни, аракы чөмердең ни дә шампанский эчтең ни, зиннәтле чатыр эчендә җан бирдең ни дә полицейский участогы идәненә ятып үлдең ни. Болар тик көнкүреш ваклыклары, тиз онытыла торган тормыш уңайлыклары, гадәтләре генә. Алар безнең яшәвебезнең иң зур, иң төп мәгънәсен күләгәләп, аның асыл бәясен төшереп торалар. Менә миңа еш кына байкупшы женазаларны күрергә туры килә. Чук-тасмалар белән бизәлгән көмеш тартма эчендә, әйтик, бер маймыл үләксәсе ята, ә аның артыннан, танаулары белән һаваны сөзеп, алдан да, арттан да әллә нинди сәер, мәзәк йолдызлар, шалтырамалар таккан бер өер тере маймыллар ияреп бара... Ә кунак-мәҗлесләрне, тантаналы утырыш, докладларны күз алдыгызга китерегез... Юк, кадерлекәем, дөньяда барыннан да өстен, гүзәл, бәхәссез бер генә нәрсә бар — ул да булса җан хөрлеге. Ә җан хөрлеге — ул иҗади фикер дигән сүз, яшәргә ашкыну, тормышка сусау дигән сүз. Трюфельләр булырга да, булмаска да мөмкин — анысы төрле очраклы сәбәпләргә, язмыш шаяруына бәйле нәрсә. Кондуктор, әйтик, тумыштан бик үк ахмак булмаса, бер ел эчендә ниндидер дәрәҗәгә ирешеп, үзендә ярыйсы гына хакимлек дәгъвасы, сыйфатлары буядыра ала. Ә менә сугым хайваныдай симереп, каптай зур корсагына калай шалтырамалар тезеп таккан, урамда фәкать кареталарга гына утырып йөргән баягы ахмак, тәкәббер чырайлы маймыл хөрлекнең горур матурлыгын беркайчан да аңламаячак, җанында беркайчан да иҗади ашкыну шатлыгы тоймаячак, тал ботагында нәфис, йомшак песиләрнең көмештәй ялтыравын күреп, беркайчан да татлы, куанычлы күз яшьләре агызмаячак!

Назанский, йөткеренә башлап, бик озак ютәлен туктата алмый азапланды. Аннары какырыгын көймә борты аша суга төкерде дә сүзен дәвам иттерде:

— Китегез, Ромашов. Моны мин сезгә ихлас күңелдән әйтәм, чөнки үзем дә хөрлек дигәннең бераз тәмен татып караган кешемен. Әгәр мин монда, шушы сасы читлеккә кире әйләнеп кайтканмын икән, анысы... ну, ничек дип әй-

тергә... ну, анысы бүтән сәбәптән... үзегез дә аңлыйсыз булыр. Тормыш дулкынына курыкмыйча сикерегез, ул сезне алдамас. Исәпсез-хисапсыз бүлмәләргә бүленгән галәмәт зур бина шикелле ул тормыш; аның эчендә олы, дәһшәтле, бөек сәнгатькә хас барлык нәрсәләр бар — яктылыгы да, җыры да, мәһабәт, гүзәл картиналары да, акыллы, нәфис кешеләре дә, уен-көлке, сөю-сөелү дә бар. Ә сез олегә бу дәү сарайның фәкать бер почмагын — чүп баскан, пәрәвез җебе сарган караңгы, кысан чоланын гына күреп беләсез һәм шул шакшы төнлектән чыгарга куркып яшисез.

Ромашов, көймәне пристаньга китереп туктаткач, Назанскийга көймәдән ярга төшәргә булышты. Назанскийның фатирына кайтып кергәндә инде көн тәмам сүрелеп, күз бәйләнер вакыт җиткән иде. Ромашов иптәшен караватка яткызды да өстенә юрган белән шинелен каплады.

Шулай булса да, Назанский өзлексез калтырана, калтыраудан аның хәтта тешләре бер-беренә шак-шок бәрелә иде. Ул, юрганы астында йодрыктай бөгәрләнеп, башын тәмам мендәр йомшагына батырды һәм сабый бала сыман ифрат кызганыч, мескен тавыш белән сызланып әйтеп куйды:

— Һай, шулкадәр куркам мин үз бүлмәмнән... Яттым-мы — бастырыла башлыйм, әллә нинди куркыныч төшләр кереп йөдәтә!

— Теләсәгез, мин сезнең янда кунарга кала алам? — дип тәкъдим итте Ромашов.

— Юк, юк, кирәкми. Бром алырга кеше җибәрегезче, зинһар... аннары... бераз аракы да. Мин бөтенләй акчасыз-мын...

Ромашов аның янында төнге сәгать унбергәчә утырды. Назанскийның бизгәге беркадәр кими төшкән иде инде. Кинәт ул күзләрен зур итеп ачты. Алар шашынкы бизгәк ялкынсынуы белән Ромашовка төбәлделәр.

— Инде китегез! Хушыгыз! — диде ул, боерып, кис-тереп.

— Хушыгыз,— диде Ромашов та моңсу тавыш белән.

Башта аның: «Хушыгыз, остаз!» — дип әйтәсе килгән иде, ләкин, җөмләнең артык ят ишетелү ихтималыннан уңайсызланып, ул тыелып калды һәм киеренкеле шаяру катыш:

— Ни өчен — хушыгыз? Ник сау булыгыз түгел? — дип сорап куйды.

Назанский ниндидер көтелмәгән, шомлы, мәгънәсез бер көлү белән шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ә ни өчен бәхил булыгыз түгел алайса? — диде ул, шашынкы күзләрен елтыратып.

Һәм Ромашов үзенең бөтен тәне буйлап кан калтыраткыч бер салкын кымырҗык йөгереп узуын тойды.

XXII

Үзе торган йорт каршына килеп чыгуга, Ромашов гажәпләнә калды: җәйге төннең тымызык караңгылыгында аның бүлмә тәрәзәсендә беленер-беленмәс кенә булып ут күренә иде. «Бу ни тагы? Әллә дуэль шартларын белешеп кайткан секундантларым көтеп утырамы?»— дип борчылып уйлады Ромашов һәм адымын кызулатты. Чоланга кергәч, абайламыйча Гайнанга бәрелеп, ул тәмам куркып-тетрәнеп китте һәм ачу белән кычкырып җибәрде:

— Шайтан алгырлары! Бу синме, Гайнан? Кем килде анда?

Караңгы булса да, Ромашов Гайнанның, иске гадәте буенча, бер урында таптанып басып торуын искәртте.

— Анда сиңа барина килде. Утыра,— диде Гайнан.

Ромашов ишекне ачты. Керосины тамчысына хәтле сызып беткән лампа, менә-менә сүнәм дигәндәй, чытыр-чатыр килеп, корымнар чәчрәтеп, соңгы минутларын янып утыра. Караватта исә, бүлмәдәге шул сөремле, шомлы караңгылык эченнән чак кына төсмерләнеп, хәрәкәтсез бер хатынкыз күләгәсе күренә иде.

— Шурочка! — дип, тәмам сулышына буылып, калтыранган тавыш белән эндәште Ромашов һәм, ни өчен икәнен үзе дә аңламыйча, аяк очларына сак кына басып карават янына килде.— Шурочка, бу сезме?

— Әкренрәк. Утырыгыз,— дип, ашыгып пышылдады хатын.— Сүндерегез лампаны.

Ромашов лампаның куыгына өрде. Зәңгәрсу ялкын гөлт итеп бер сикерде дә сүнде; бүлмә шундук дөм караңгыга чумды, тынып калды, һәм шул үле тынлык эчендә өстәл өстендә моңарчы барлыгы да сизелми утырган будильник сәгатьнең ашыгып кеткелдәгән тавышы яңгырап ишетелде. Ромашов Александра Петровна янына бөкрәя биребрәк утырды да күз карашын каядыр читкә, караңгылык эченә төбәде. Аны ниндидер курку хисе, йөрәк сулыктыргыч бер дулкынлану биләп алган, шул нәрсә аңа сүз башларга комачаулый иде.

— Бу стенаның теге ягында берәрсе бармы, сөйләшкән сүз ишетелерлек түгелме анда? — дип сорады Шурочка.

— Юк, буш бүлмә ул... иске мебель генә анда... хуҗасы — столяр кеше. Кычкырып сөйләшергә дә мөмкин.

Ләкин үзләре алар тавышларын күтәрмичә, шыпырт кына сөйләшә бирделәр. Һәм аларның шушы шомлы, куе караңгылык эченнән бер-беренә пышылдап әйткән сүзләрендә ниндидер шөбһә, уңайсызлану һәм яшерен генә якынлашып килгән билгесезлек авазлары да ачык ишетелә иде. Алар иңне-иңгә куеп, бер-беренә орынып диярлек утыралар; Ромашовның өзлексез колагы чыңлый һәм чигә тамырлары ярсып суга иде.

— Нигә, нигә сез шундый җүләрлек эшләдегез? — дип, рәнҗү, үпкәләү катыш бер шелтә белән шыпырт кына әйтеп куйды кинәт Шурочка.

Шулай диде дә кулын егетнең тезе өстенә куйды. Ромашов, үзенең киеме аша нервлы-калтыраулы кайнар тән җылысын тоеп, тынын кысты һәм күзләрен чытырдатып йомды. Ләкин аңа карап кына караңгылык куермады, киресенчә, бөтен нәрсә кинәт айкалып киткәндәй, күз алдында әкият күлләренә охшашлы ниндидер озынча кара бөжәралар һәм зәңгәр каймалы балкышлар сикерешә башлады.

— Исегездәме, мин сездән аның белән бик сак булуыгызны үтенгән идем. Юк, юк, шелтәләп әйтүем түгел. Мин беләм бит — сез аның белән юри ачуланышмагансыз. Ләкин, ачуыгыз кабарып, күңелегездә ерткычлык дәрте уянганда, сез иң элек минем турыда уйларга һәм вакытында туктап калырга тиеш идегез. Димәк, сез мине беркайчан да яратмагансыз!

— Мин сезне үлеп яратам,— дип пышылдады Ромашов һәм калтыранган бармаклары белән акрын гына, куркып кына хатынның кулына орынды.

Шурочка, Ромашовны үпкәләтә күрмим дигәндәй, кулын аның учы астыннан ашыкмыйча, әкрен-әкрен генә суырып чыгарды.

— Әйе, беләм, сез дә, ул да судта минем исемне телгә алып сөйләмәгәнсез, ләкин бу рыцарьлыгыгызның файдасы барыбер булмады: шәһәрдә гайбәт куерганнан-куера бара.

— Кичерегез, зинһар, мин тыелып кала алмадым... Мине сукыр көнчелек харап итте, — дип акланып маташты Ромашов.

Шурочка мәсхәрәле, явыз көлү белән шаркылдап көлеп куйды.

— Сукыр көнчелек, имеш! Сез инде: минем ирем, сезнең белән сугышып өйгә кайткач, миңа мәрхәмәт йөзен-

нән берни дә сөйләмәгәндер, сезнең ул көнне җәмгыятькә килгәнче кайларда йөрүегез турында бер сүз дә әйтмәгәндер, дип уйлыйсыз, шулаймы? Бик ялгышасыз, ул моны миңа куана-куана сөйләде. Ул хәтта Назанский турындагы сүзләрегезне дә әйтте.

— Кичерегез, зинһар. Мин анда бернинди гөнаһлы эшләр дә эшләп йөрмәдем. Кичерегез мине,— дип, һаман кабатлый бирде Ромашов.

Шурочка кинәт тавышын күтәрә төшеп, кискен, кырыс пышылдау белән сөйләргә кереште:

— Менә нәрсә, Георгий Алексеевич: минем һәр минутым исәпле. Мин сезнең монда бер сәгать буе көтеп утырдым. Шуңа күрә сүзне кыска тотыйк һәм эш турында гына сөйләшик. Сез минем Володяга булган мөнәсәбәтемне яхшы беләсез. Мин аны яратмыйм, ләкин шул ук вакытта мин аның абруе хакына җанымның ярты жегәрен сарыф иттем. Миндәге мин-минлек хисе аныкыннан көчлерәк. Ул ике тапкыр академиягә имтихан тотарга барып, икесендә дә уңышсызлыкка очрап кайтты. Моның ачысын, хурлыгын аның үзеннән дә бигрәк мин күбрәк татыдым. Генеральный штаб турындагы фикер тулысы белән мин уйлап тапкан нәрсә бит ул. Мин көчемне кызганмадым, Володяны гел дәртләндереп, куалап тордым, аның белән бергә фәннәр өйрәндем, кагыйдәләр ятладым, күнекмәләр ясадым, аның мин-минлеген котыртып, өметсезлеккә төшкән минутларында рухын күтәрергә, аны юатырга тырыштым. Кыскасы, Володяны академиягә әзерләү — ул минем иң яраткан, иң зур эшем. Бу эштне башкарып чыкмый торып, минем күңелем беркайчан да тынычланмаячак. Ни генә булса да, ул академиягә керергә тиеш.

Ромашов, башын учы өстенә салындырып, тын гына утыруында булды. Кинәт ул үзенең башына Шурочканың кулы орынуын һәм әкрен генә, йомшак кына итеп чәчтән сыйпап алуын тойды.

— Мин нишләргә тиеш соң? — дип сорады ул аптырау катыш бер ачыну белән.

Шурочка аны муеныннан кочаклап, башын күкрәгенә таба тартып китерде. Хатын корсетсыз иде. Яңагының тыгыз, нәфис-шома, жылы, шәрә тәнгә орынуыннан, борынына бөркелгән исерткеч, татлы хуш истән Ромашов тәмам югалып калды. Шурочканың сүз арасында еш-еш сулаган кайнар тыны аның чәч төпләренә кадәр үтеп керә иде.

— Теге вакытны... пикникта... төнге сөйләшүебез хәтерендәме? Мин ул чакта сиңа бөтен дөресен әйттем. Мин

иремне яратмыйм. Ләкин үзең уйлап кара: өч ел — өзлексез өч ел буена күпме тырыш хезмәт куелган бит, күпме планнар корылган, өметләр багланган, күпме дәрт, фантазия сарыф ителгән! Үзең беләсең: бу хәерче, мещаннарча тормышны минем женем сөймәм, аны искә төшергәч тә калтырый башлыйм мин. Минем матур киемнәр киеп йөрисем, һәрвакыт матур, нәфис күренәсем килә, табыну, власть телим мин! Менә шундый өметләр белән яшәгәндә генә кинәт менә сиңа мә: ниндидер исерекләр сугышы, офицерлар җәнҗалы! Бөтенесе берьюлы челпәрәмә килде дә бетте! Коточкыч бәхетсезлек бит бу! Мин беркайчан да бала анасы булган кеше түгел, шулай да ана хисләрен бик яхшы күз алдыма китерәм. Менә, әйтик, минем балам үсеп килә — йөрәк парәм, бердәнберем, киләчәк өметем; аны кайгыртып, мин төннәр йокламыйм, күз яшьләре түгәм... Һәм кинәт — һич көтелмәгән, мәгънәсез, кыргый, стихияле бер афәт: шул кадерле балам, нәнәсе чак кына читкә карап торган арада, тәрәзә төбендә уйнап утырган җиреннән кисәк кенә ычкынып китеп, урам ташына гөрселдәп бара да төшә... Сөеклем, үземнең хәзерге кайгы-хәсрәтемне, йөрәгемдә ташыган ачуны мин әнә шундый аянычлы хисләр — баласын мәңгегә югалткан ана хисләре белән генә чагыштыра алам. Ләкин мин сине гаепләмим.

Ромашовка Шурочка яныңда урталай сыгылып, муенын бөгеп, кымшанмыйча утыру шактый җайсыз иде җайсызын. Ләкин ул, мөмкин булса, Шурочка күкрәгенә шулай башын куеп, бөркүле-исерткеч сәер бер халәттә аның үтә тигез төгәллек белән еш-еш типкән бәләкәй йөрәгенең дөпелдәвен тыңлап, сәгатьләр буе утырырга да риза булыр иде.

— Син минем сүзләремне тыңлыйсыңмы? — дип сорады Шурочка, башын ия төшеп.

— Әйе, әйе... Сөйли бир... Әгәр булдыра алсам, мин син теләгәннең барысын да эшләячәкмен.

— Юк, юк. Сүземне тыңлап бетер. Әгәр ул, Володя, дуэльдә үтерелсә яки имтихан тоту хокукыннан мәхрүм ителсә — барысы да бетте дигән сүз! Бу хәбәрне ишеткән көнне үк мин, бөтенесен ташлап, моннан китеп барачакмын. Петербургкамы анда, Одессага, Киевкамы — барыбер. Моны газетада басыла торган роман сүзләре — буш сүзләр дип уйлама, зинһар. Сине андый арзан эффектлар белән һич тә өркетергә теләмим. Ләкин мин үземнең яшь, акыллы, гыйлемле бер хатын икәнемне яхшы беләм. Дөрес, чибәрләрдән түгелмен. Әмма, кирәк икән, мин теге, бал-

мәҗлесләрдә матурлык өчен мельхиор поднос яки күкеле сәгать ише бүләкләр ала торган мәгълүм чибәр хатыннарның күбесеннән чибәррәк була да беләм. Әйдә, хурлыгы үземә төшсен: янарга икән, **фейерверк шикелле**, бер мизгел эчендә гөлт итеп янып бетәрлек булсын!

Ромашов тәрәзәгә карады. Хәзер аның күзләре, караңгыга ияләшеп, тәрәзәнең рамына хәтле төсмерли ала иде инде.

— Алай димә... кирәкми... йөрәгемне кисмә,— диде ул хәсрәт белән. — Алайса мин иртәгә тотам да атышудан баш тартам, ирекнән гафу үтенәм. Йә, эшлимме шулай?

Шурочка бераз дәшми торды. Өстәл сәгатенең металл теле бөтен бүлмәне шаулатып кеткелдәвендә дәвам итә иде. Ниһаять, Шурочка, үзалдына уйлангандай, ишетелер-ишетелмәс тавыш һәм, Ромашовның фаразынча, ниндидер үзгә бер чырай белән пышылдап әйтеп куйды:

— Шулай тәкъдим итәсеңне мин алдан ук сизенгән идем.

Ромашов башын күтәрде һәм, Шурочканың җибәрмәскә тырышып муенга сарылуына да карамыйча, гәүдәсен турайтып утырды.

— Мин бернидән курыкмыйм! — диде ул саңгырау тавыш белән, кычкырып.

— Юк, юк, юк, син мине дөрес аңламадың,— дип ялварулы кайнар бер дәрт белән ашыгып пышылдады Шурочка.— Якынрак килеп утыр... баягыча... йә, кил инде!..

Шулай дип, ул Ромашовны үзенә таба тартып китереп, муеныннан ике куллап кочаклады да аның битенә кайнар сулышын өрә-өрә һәм йомшак, нәфис чәчләре белән чигәяңакларын рәхәт кытыклый-кытыклый, янә сүзгә кереште:

— Син мине дөрес аңламадың. Минем теләгәнем бөтенләй башка нәрсә. Тик аны сиңа әйтергә генә оялам. Син шундый саф күңелле, әйбәт кеше, күңелдәген әйтергә ничектер тел әйләнми, уңайсыз тоела. Ә мин үзем әшәке, исәп-хисап белән яшәүче хатын...

— Юк, син яшермичә сөйлә. Мин сине яратам.

— Алайса тыңла,— дип башлады Шурочка, һәм Ромашов аның сүзләрен аерым-аерым ишетүдән битәр, аларның гомум мәгънә сөрешләрен генә чамалап утырды. — Әгәр атышудан бөтенләй баш тартсаң, син никадәр мәсхәрә-хурлау, никадәр рәнҗү-газап күрәчәксең бит. Юк, юк, мин тагын тиешлесен сөйләмим. Ай аллам, нигә дип һәммәсен туп-туры әйтмәскә! Бу минутта мин сиңа һич тә ялганларга теләмим. Мин боларның барчасын бөтен яктан уйлап-ча-

малап куйдым инде. Ярый, син атышудан баш тарттың, ди. Иремнең дә намусы чиста калды, абруена тап төшмәде, ди. Ләкин, аңлыйсыңмы, татулашу белән беткән дуэльдән соң һәрвакыт ниндидер бер ризасызлык... сиңа ничек ачыграк аңлатыйм икән?.. Ну, ниндидер бер шикләнүле аптырау, күңел кайту, ышанмау шикеллерәк юшкын утырып кала... Син минем нәрсә әйтергә теләгәнне аңлыйсыңмы? — дип сорады Шурочка һәм назлы бер сагыш белән Ромашовның чәченә иреннәрен тидерде.

— Әйе, аңлыйм. Шуннан нәрсә?

— Шуннан шул: бу очракта Володяны академиягә якын да жибәрмәүләре мөмкин. Генеральный штаб офицерының репутациясе бөртек кадәр дә таплы булырга тиеш түгел. Ә инде сез чынлап та атышсагыз икән, ул чакта моның халык күзендә каһарманлык сымаграк көчле бер тәэсир калдыруы ихтимал. Үзенә таба төбәлгән мылтык каршысында кыю басып тора белгән кешеләргә тормышта күп нәрсә, бик күп нәрсәләр гафу ителә. Аннары... дуэльдән соң... бик теләсәң, син аңардан гафу үтенә дә алыр идең... Хәер, анысы инде синең үз эшең.

Алар, берсе икенчесенең сулышларын ишетерлек дәрәҗәдә тәмам бер-беренә сыенышкан хәлдә, битләре, куллары белән тиешеп, яшерен эшкә әзерләнгән кешеләр сыман, әнә шулай пышылдашып сөйләштеләр. Ләкин шул ук вакытта Ромашов ике арага күзгә күренмәс ниндидер яшерен, жирәнгеч, лайлалы бер нәрсә шуышып керүен тойды һәм моңардан шундук жаны салкынаеп китте. Ул, кочактан янә ычкынырга теләп, читкә тартылды, ләкин Шурочка аны жибәрмәде. Күңелендә кинәт кенә кабынган ачу хисен сиздермәскә тырышып, Ромашов коры гына әйтеп куйды:

— Алла хакы өчен, сүзеңне ачыграк итеп әйт. Мин сиңа бөтенесен эшләргә вәгъдә итәм.

Шуннан соң Шурочка авызын Ромашовның колагы төбенә үк китереп терәде дә, боеручан аһәң белән, сүзләрен чуп-чуп үбешкәндәй тиз-тиз әйтеп сөйләргә кереште:

— Сез иртәгә һичшиксез атышырга тиешсез. Ләкин берегез дә бернинди яра-фәләң алмаячак. Син аңла, аңларга тырыш, ачуланма, гаепләмә мине! Мин — хатын-кыз, куркак жанлы кешеләрне женем сөймәм минем. Ләкин син моны минем хакка эшлә, Георгий! Юк, ирем турында сорашма, ул белә. Мин барысын да, барысын да сөйләштем, жайладым инде.

Ромашов бу юлы, ниһаять, Шурочканың йомшак, көчле

кулларын аралап, кочактан ычкынды. Караваттан торып басты да катгый төстә, өзеп-кистереп:

— Яхшы, әйдә шулай булсын. Мин риза,— диде.

Шурочка да аягүрә торып басты. Караңгыда чак-чак кына төсмерләнгән күл-баш хәрәкәтләре буенча, аннан да битәр, эчке бер тоем белән, Ромашов аның ашыга-ашыга чәчен төзәткәләргә керешкәнлеген чамалап алды.

— Син китәргә җыенасыңмы? — дип сорады ул.

— Хуш, китәм,— диде Шурочка, ишетелер-ишетелмәс, зәгыйфь тавыш белән.— Мине соң мәртәбә үбеп кал.

Кызгану, яратудан Ромашовның йөрәге дәррәү тетрәнеп куйды. Караңгыда куллары белән кармалап, ул Шурочканың башын эзләп тапты да шашып-шашып яңак, күзләреннән үбәргә тотынды. Шурочка үзалдына тын гына елый, аның бит-яңаклары яшькә чыланган иде. Бу елау Ромашовны тагы да дулкынландырып, аның күңел кылларын тәмам нечкәртеп җибәрде.

— Кадерлем минем... Саша... җанкисәгем... елама... — дип, иркәләп-назлап, кызганулы тавыш белән туктаусыз кабатлады ул.

Шул чак Шурочка ашкынып, талпынып Ромашовның муенына сарылды, түземсезләнеп дерелдәгән гәүдәсе белән баштанаяк аңа сыланып, кайнар иреннәрен аның авызына тидерде һәм шул хәлдә, сулышына буыла-буыла, өзек-дәртле тавыш белән пышылдап әйтте:

— Мин синең белән болай гына хушлашып китә алмыйм. Без бүтән күрешмәячәкбез. Шуңа күрә, әйдә, бернидән дә курыкмыйк... Мин үзем телим, үзем телим моны. Ичмасам гомеребездә бер тапкыр... бәхетебезне татып карыйк... Кил, җаным, кил, якынрак кил...

Һәм менә бөтен бүлмә, бүлмә генә түгел, бөтен дөньясы, шул җөмләдән алар үзләре дә, шундук ниндидер түзеп булгысыз татлы-рәхәт, кайнар-эссе, саташулы бер төшкә әверелделәр. Шул саташулы томан эченнән Ромашов бер генә мизгелгә ак мендәр табы өстендә, үзеннән бик-бик якында гына, Шурочканың иксез-чиксез бәхет нуры белән балкыган күзләрен күреп алды һәм шашынып-комсызланып аның иреннәренә ябырылды...

Ишек алды болдырына чыккач, Ромашов Шурочкадан сорап куйды:

— Өеңә кадәр озата бармаскамы соң?

— Юк, кирәкми, сөеклем, моның һич тә кирәге юк... Зинһар, андый җүләрлекне эшли күрмә. Синең өйдә күпме

гомер утырганымны мин болай да белмим инде. Хәзер сәгать ничә?

— Белмим шул, минем сәгатем юк. Һич менә әйтә алмыйм.

Шурочка китәргә ашыкмады, ишек яңагына сөялгән көе, сүзсез генә басып торды. Һавада эссе төннең кайнар, дәртле сулышы белән аралашып, кызган таш, кипкән җир исе аңкый иде. Төн шактый караңгы, шулай булса да Ромашов, теге көнне имәнлектә бергә утырган чактагыча, Шурочканың йөзеннән ниндидер сәер, мәрмәр һәйкәл чыраеныкыдай аксыл-тоныклык бер яктылык сирпелүен күрде.

— Йә, хушлашыйк булмаса, кадерлем,— диде ниһаять Шурочка арыган тавыш белән.— Хуш, сау бул.

Алар, кочаклашып, тагы үбештеләр. Ләкин бу юлы Шурочканың иреннәре салкын һәм хәрәкәтсез иде инде. Ул кызу-кызу атлап капкага таба китте һәм шул секундта ук караңгыда эреп югалды.

Ромашов, калитка ишеге шапылдап ябылып, Шурочканың йомшак аяк тавышлары ераклата тәмам йотылып беткәнче, болдыр баскычында кузгалмыйча басып торды. Аннары өенә керде.

Бүлмәгә керүгә үк аны үтә көчле бер хәлсезлек, ләкин рәхәт-татлы хәлсезлек биләп алды. Ул чак кына чишенеп өлгерде — шулкадәр йокысы килә иде аның. Һәм йокыга киткәндә иң соңгы җанлы тәэссораты итеп ул Шурочканың мендәргә сеңгән татлы-тәмле хуш исен — хушбуй, чәч һәм гүзәл, яшь тән исен истә калдырды.

XXIII

2 нче июнь, 18 **.

Z шәһәре.

N нче пехота полкы командиры галиҗәнабләренә
шул полкның штабс-капитаны
Дицтан

Рапорт

Бу язма рапортым белән Сез галиҗәнабләр игътибарына түбәндәгеләрне белдерергә җөрьәт итәм:

Бүген 2 нче июньдә, алдан уйлап килешенгән һәм 1 нче июнь көнне Сезнең тарафтан расланган шартлар нигезендә, поручик Николаев белән подпоручик Ромашов арасында дуэль булды. Көндәшләр, иртәнге вакыт белән сәгать 6 туларга биш минутта, шәһәрдән $3^1/_2$ чакрым ераклыктагы

«Имәнлек» дип йөртелгән мәгълүм урман аланында очраштылар. Сигналлар бирү вакытын да кертеп исәпләгәндә, атышу тулаем 1 минут 10 секунд дәвам итте. Атышучыларның кайсы кайда басып торырга тиешлеге жирәбә салып хәл ителде. «Алга» дигән команда бирелгәч, көндәшләр, берьюлы урыннарыннан кузгалып, бер-беренә каршы киттеләр. Ара шактый якынайгач, поручик Николаев туктады да беренче булып атып җибәрде. Пуля подпоручик Ромашовның корсагына, корсакның уң як югарыгы өлешенә тиде. Шуннан соң поручик Николаев, туктаган урыныннан кузгалмыйча, җавап атуны көтә башлады. Җавап ату өчен билгеләнгән ярты минут үткәч, подпоручик Ромашовның җавап бирерлек хәлдә түгеллеге мәгълүм булды. Шул сәбәпле подпоручик Ромашовның секундантлары дуэльне тәмамланган дип санарга тәкъдим керттеләр. Бу тәкъдим гомуми ризалык белән кабул ителде. Коляскага күтәреп илткәндә, подпоручик Ромашов аңын югалтты һәм жиде минуттан эченә кан саву аркасында дөньядан китте. Поручик Николаев ягыннан булган секундантлар: мин һәм поручик Васин; подпоручик Ромашов тарафыннан булганнары — поручик Бек-Агамалов белән поручик Веткин. Үзара килешү буенча, дуэль белән гомуми житәкчелек миңа тапшырылган иде. Кече врач кол. ас. Знойконың таныклама язмасын рапортыма терким.

Штабс-капитан *Диц.*

1905





ГРАНАТ ҚАШЛЫ БЕЛӘЗЕҚ

L. von Beethoven. 2. Son. (op. 2. № 2).

Largo Appasionato.

I

Август урталарында, яңа ай туар алдыннан, Кара диңгезнең төньяк ярлары буенда еш кына булганча, кинәт ямьсез көннәр башланды. Әле тәүлекләр буе диңгез һәм җир өстен куе авыр томан пәрдәсе томалап торды, һәм маяктагы зур сирена, котырган үгез тавышлары чыгарып, көнен-төнен үкерергә кереште. Әле иртәдән кичкә хәтле, берөзлексез, су тузанындай вак яңгыр сибәләде, һәм балчыклы сукмак, юллар ат-арба ерып чыга алмаслык тоташ боламыкка әверелде. Әле төньяк-көнбатыштан, дала ягыннан, дәһшәтле давыл купты да, табигатьтә мәхшәр башланды: агачлар, ябалдашлары белән бер җиргә кадәр бөгелеп, бер тураеп, давыллы диңгез өстендәге дулкыннар төсле ярсып-ярсып чайкалырга тотындылар; дача йортлары өстендә кемнәрдер дагалы итекләре белән чабышып йөргәндәй, төннәр буе дан-доң түбә калайлары шыңгырдап торды. Җил тәрәзә рамнарын дер селкетте, капка-ишекләрне шак-шок ачып япты һәм әллә нинди кыргый тавышлар

белән моржа куышларында улап йөрде. Давыл вакытында диңгездә балыкчыларның берничә баркасы адашып калган иде, аларның икесе ярга бөтенләй әйләнеп кайтмады; һәлакәткә очраган балыкчыларның үле гәүдәләрен дулкын бары бер атнадан соң гына яр кырыена кагып чыгарды.

Шәһәргә якын урнашкан диңгез буе курортында ял итүчеләр — күбесенчә, тормыш сөючән һәм, барлык көньяк кешеләре кебек, беркадәр вәсвәсәгә бирелүчән греклар белән яһүдләр,— ашыгыч рәвештә шәһәргә күченеп китә башладылар. Җәбеп изрәгән олы юл өсте шәһәргә кайтучы көймәле озын арбалар белән тулды. Бу арбаларга төрле йорт-җир әйберләре түбәләмә төялгән иде. Хәерче сәләмәседәй искереп, керләнеп беткән түшәк-мендәрләр, диваннар, сандыклар, урындыклар, кулъюгычлар, самавырлар; йөкләр өстендә юеш брезент җәймәләрдә бөрешеп утырган һәм кулларына үтүк, калай савыт, кәрҗин ише нәрсәләр тоткан асрау кызлар, пешекчеләр; әледән-әле туктап, уңга-сулга чыгымлый-чыгымлый авыр йөк тартып барган, тез буыннары калтыраныр дәрәҗәдә арыган, хәлдән тайган һәм шабыр тиргә баткан атлар; яңгырдан чыпта астына яшеренгән һәм карлыккан ачулы тавыш белән атларга җикеренеп-җикеренеп барган олаучы агайлар — болар һәммәсе дә сибәләп яуган яңгырның томанлы пәрдәсе аша гаять тә кызганыч, моңсу һәм хәтта җирәнгеч бер күренеш хасил итә иде. Кисәк кенә бушап, иркенәеп калган шәрә дача йортлары, аларның ватык тәрәзәләре, бозылган-тапталган түтәлләре, ташлап калдырылган этләре, әле анда, әле монда калкып утырган чүп өемнәре: тәмәке төпчекләре, кәгазь кисәкләре, сөяк-санак, тартма-ящик, дару шешәләре — болары инде карар күзгә тагын да күңелсезрәк булып тоела иде.

Ләкин сентябрь башында һавалар кисәк кенә һәм бөтенләй көтмәгәнчә тагын да үзгәреп, әйбәтләнеп китте. Хәтта июль аенда да булмаган тын, аяз, кояшлы һәм җылы көннәр башланды. Кипшергән һәм игеннәре урып-җыеп алынган басуларның тырпаеп утырган камыллары өстендә, пыяла сыман ялтырап, көзге пәрәвез җепләре сузылды. Тынып калган агачлар, бернинди шау-шусыз һәм буйсынучан бер төстә, әкрен генә саргайган яфракларын коярга керештеләр.

Дворяннар предводителенең хатыны княгиня Вера Николаевна Шеина, шәһәрдәге йортларында ремонт эшләре бетеп җитмәү сәбәпле, дачадан китә алмый калган иде. Һәм хәзер, яңадан шундый матур, ямьле көннәр башлан-

гач, тирә-яктагы гүзәллеккә, аулак бер тынлыкка, саф һавага, күченергә әзерләнеп, өерләре-өерләре белән телеграф чыбыкларына кунган карлыгачларның күңелле чыр-чуына һәм диңгез эченнән ярга таба талгын гына искән тозлы йомшак җилгә ул сөенеп бетә алмады.

II

Өстәвенә, бүген княгиняның туган көне — унҗиденче сентябрь иде. Бала чагының кадерле, ерак хатирәләрендә туган көне аның иң яратып каршы алына торган күңелле бер бәйрәме булып истә калган; бу көн аңа һәрвакыт нинди-дидер гадәттән тыш зур куаныч-бәхет алып килер шикелле тоела иде. Иртән, шәһәргә ашыгыч эшләре белән чыгып китәр алдыннан, ире әнә төнге өстәл өстенә үзенең бүләген куеп калдырган. Груша формасындагы вак энҗе бөртекләреннән тезеп ясалган һәм махсус футляр эченә салынган искиткеч матур алкалар иде бу. Аларны күргәч, княгиняның күңеле тагы да ачылыбрак киткәндәй булды.

Өйдә ул берьялгызы иде. Гадәттә алар белән бергә бер өйдә торучы һәм шәһәрдә прокурор ярдәмчесе булып эшләүче буйдак абыйсы Николай да шәһәргә китеп барган. Ире исә төш вакытларында гына кайтырга тиеш. Ул үзе белән кунаклар иәртеп кайтырга вәгъдә иткән иде. Кунаклар бик аз булачак, дус-ишләрнең дә иң якын дигәннәре генә киләчәк. Туган көннең шулай дача чорына туры килүе әйбәтрәк тә әле. Андый бәйрәмне шәһәрдә ясасаң, зур мәҗлес, хәтта бал-мәҗлес җыярга кирәк булыр иде, ә монда, дачада, аны кечкенә генә итеп, күп акча түкмичә дә уздырып җибәрергә була. Князь Шеин, җәмгыятьтә шактый күренекле урын тотып торуына карамастан, ә бәлки шул күренекле урын тотуы аркасындадыр, акча мәсьәләсендә бик кысан яши һәм тормышын көчкә-көчкә генә алып бара иде. Ата-бабадан мираска калган зур имение инде күптән, шул ата-бабалар заманында ук, таркалып бетә язган, ә князь Шеинның хәзерге тормышы көч җитмәслек чыгымнар сорый иде. Аңа әледән-әле зур мәҗлесләр җыярга, җәмгыяте хәйрияләрдә катнашырга, киенергә-ясанырга, яхшы атлар тотарга туры килә иде... Иренә булган дәртле мәхәббәтен инде күптән икенче бер хискә — тугрылыклы чын дуслык хисенә алыштырган княгиня Вера исә, бөтен көч-куәтен куеп, князьга ярдәм итәргә, аны тәмам бөлгенлеккә төшүдән саклап калырга тырыша иде. Ул, иренә сиздермичә

генә, күп нәрсәдә үзен кысып яши һәм хуҗалык чыгымнарын мөмкин кадәр киметергә омтыла иде.

Хәзер ул менә, кулына кайчы тотып, бәйрәм табынына куяр өчен бакчада чәчәкләр кисеп йөри. Гөл түтәлләре тәртипсез бер кыяфәттә бушап, сирәкләнеп калган. Күп төрле төстәге, катмарлы чәчәк уңышы бирә торган канәферләр инде соңгы чәчәкләрен коярга әзерләнәләр; шулай ук шеббуй гөлләре дә, чәчәкләрен яртылаш коеп, кәбестә иседәй бер ис аңкытып торган нәзек яшел кузаклар чыгара башлаганнар; роза гөлләре эле булса — бу җәйдә инде өченче мәртәбә — чәчәк атып яисә яңа чәчәккә бөреләнеп утыралар, ләкин аларның чәчәкләре, нәсел сыйфатларын югалта баргандай, бик вакланып, зәгыйфьләнеп һәм сирәкләнеп калган. Аның каравы, дәлияләр, пионнар һәм кашкарыйлар, үзләренең, салкын-тәкәббер гүзәллекләре белән мактангандай, шау чәчәккә күмелгән; алардан тынсызгер һавага чирәм исен хәтерләткән моңсу бер ис — көз исе тарала иде. Калган гөлләр исә, купшы мәхәббәт һәм җәйге мул үрчем бирү чорын кичергәннән соң, хәзер ашыкмыйча гына уңдырышлы җир өстенә үзләренең киләчәктә уянырга тиешле исәпсез-хисапсыз тереклек яралгыларын сибеп утыралар иде.

Якында гына, олы юл ягында, автомобиль быргысының сузып-сузып кычкырткан калынлы-нечкәле таныш тавышы ишетелде. Бу княгиня Вераның сеңелесе — Анна Николаевна Фриессе булырга тиеш иде. Кунакларны каршылауда һәм хуҗалык эшләрендә апасына булышу өчен ул иртән үк килеп җитәрмен дип телефоннан шылтыратып куйган иде.

Сизгер колагы Вераны алдамады. Княгиня сеңелесен каршыларга дип дача капкасына таба китте. Берничә минуттан инде ялтырап торган автомобиль — карета капка төбенә килеп туктады, һәм шофер, үз урыныннан өлгер генә сикереп төшеп, ишекне ачты.

Апа белән сеңел шатлыклы төстә кочаклашып, үбешеп күрештеләр. Әле бала чакларыннан ук алар арасында җылы, кайгыртучан дуслык мөнәсәбәтләре урнашып калган иде. Тышкы кыяфәтләре белән исә алар бер-берсеннән сәер дәрәҗәдә аерылып торалар иде. Олысы, Вера, үзенең озын, зифа сыны белән, нәфис, ләкин шул ук вакытта салкын, горур йөзе, күрер күзгә дәүрәк булса да, үзенә килешле матур куллары һәм борынгы миниатюраларда гына очратырга мөмкин булган гажәеп гүзәл иңбашлары белән үзенең чибәр әнисенә — инглиз токымына охшаган иде.

Кечесе — Анна, — киресенчә, күбрәк этисенә — бабасы әле XIX гасыр башында гына чукынган татар морзасына охшаган иде. Вера белән Аннаның әтиләре бик борынгы нәселдән булып, бу нәселнең бер очы каядыр бик еракка, мәшһүр Тамерланның үзенә үк барып тоташа иде. Әти кеше үзенең бу борынгы бабасын — шул канечкеч сугыш чукмарын — горур төстә, татарчалап, Аксак Тимер дип кенә атап йөртә торган иде. Аннаның буе апасыныкыннан ярты башка кечерәк, ә җилкәсе, киресенчә, киңрәк иде. Үзе ул тере, шаян һәм беркадәр җилбәзәгрәк табигатьле иде. Чын монгол хатын-кызларыныкыча бераз яңак сөякләре калкыбрак торган бит, кысык күзләр,— җитмәсә, ерактан начар күрүе сәбәпле, ул күзләрен тагын да кысарак төшеп карый иде,— аскы ирене бүлтәебрәк торган тәкәббер һәм дәрт кузгатучан кечкенә авыз — кыскасы, Аннаның йөзен матур дип әйтеп булмый иде. Ләкин, шуңа да карамастан, бу йөздә ниндидер яшерен, серле бер гүзәллек тә бар иде. Ул гүзәллек, бәлки, аның елмаюында яисә гомумән хатын-кызларга хас мөлаемлылыгында, ә бәлки дәртле-шаян мимикасында яшеренгән булгандыр. Һәрхәлдә, аның нәзакәтле ямьсезлеге апасының аристократларча затлы матурлыгына караганда ирләрне ешрак һәм ныграк җәлеп итә иде.

Анна ниндидер ярлыларга ярдәм күрсәтү җәмгыятендә хезмәттә саналган һәм камер-юнкер исеме йөрткән бик бай һәм бик томана бер кешегә кияүгә чыккан иде. Ирен ул аз гына да яратмады, шулай да аңа ике бала — бер малай һәм бер кыз табып бирде; шуннан соң ул бала тапмаска карар итте һәм бүтән тапмады да. Вера исә гомере буе бала теләде, хәтта аңа балалар никадәр күп булса, шулкадәр әйбәтрәк булыр шикелле тоела иде; ләкин ул ни өчендер бер генә тапкыр да балага узмады. Һәм ул үзенең кимсенеп сызланган күңелендәге бөтен кайнар хисләрен сеңелесенең һәркайчан пөхтә, сүз тыңлаучан, аксыл йөзле һәм курчакларныкыдай бөдрәләнеп торган җитен чәчле мөлаем балаларына сарыф итте.

Аннаның бөтен холкы-табигате шаян бер җилбәзәклектән һәм ара-тирә сәер төс алган эчке каршылыклардан гыйбарәт иде. Ул Европаның барлык башкалаларында, барлык курортларында бик теләп хәтәр мәхәббәт уеннары башлап жибәрә, әмма үзе беркайчан да иренә хыянәт итми иде. Шул ук вакытта ул иреннән аның үзе алдында да, үзе артында да мыскыллап көләргә ярата иде. Анна акчаны ифрат бәрәкәтсез тота, азартлы уеннарга, төрле бию

кичәләренә, көчле дәрт-хисләр кузгата торган тамашаларга коточкыч һәвәслек күрсәтә һәм чит илдә булган чакларында әллә нинди шикле кафеларга барып йөри иде. Ләкин, шуның белән бергә, аның күңеле гаять яхшы, игелекле һәм тирән диндарлык белән сугарылган иде. Шушы ихлас диндарлыгы аркасында ул яшерен рәвештә католик диненә күчәргә дә мәҗбүр булган иде. Аннаның аркасы, иңбашлары һәм түш турылары сокланып туймаслык матур иде. Шуңа күрәмедер, зур мәҗлес-балларга барганда ул иңбашларын әдәп һәм мода рөхсәт иткәннән дә артыграк дәрәҗәдә ачык калдыра торган иде. Ләкин, әйтүләренә караганда, аның бу ачык изүле киеме астында һәрвакыт тагын башка киеме дә — кылдан үрелгәне дә була, имеш.

Верага исә җитди гадилек хас иде. Ул кешеләр белән салкын ягымлы һәм беркадәр югарыдан торыбрак сөйләшә, алар алдында үзен патшаларча тыныч һәм мөстәкыйль тота иде.

III

— Йа ходай, шундый ямьле сезнең монда! Шундый ямьле! — диде Анна һәм тар юл буйлап вак-вак адымнар белән апасы янәшәсеннән атлап китте.— Мөмкин булса, әйдә, шушында яр башындагы эскәмиядә бераз гына утырып торыйк әле. Күптәннән бирле диңгезне күргәнем юк. Һавасы соң, һавасы нинди — бер тын алсаң, ничектер, күңелләр ачылып китә. Уткән җәйне Кырымда, Мисхорда, мин искитмәле бер ачыш ясадым. Беләсеңме, ярга дулкын бәргәндә диңгез суыннан нинди ис килә? Ышанасыңмы — резеда исе.

Вера мөлаем гына көлемсерәп куйды:

— Фантазерка син.

— Юк, юк. Әле дә исемдә: бервакытны шулай, ай нурында ниндидер алсу төс бар, дигәч, һәммәсе дә миннән шаркылдап көлгәннәр иде. Ә шушы көннәрдә генә художник Борицкий — әлеге минем портретны ясаучы художник — әйтеп утырды, син хаклы булгансың, бу турыда художниклар күптән беләләр, ди.

— Ул художник дигәнең синең яңа гыйшкыңмы?

— Син гел шулай арттырырсың инде! — диде Анна, көлеп, һәм урынныннан торып, диңгез өстендә текә стена сыман күтәрелеп торган ярның кырыена ашыгып килде дә түбән карады һәм кинәт, әче тавыш белән кычкырып җибәреп, тәмам чырае качкан бер хәлдә артка чигенде.

— У-у, ничек биек! — диде ул, калтыранган зәгыйфь, хәлсез тавыш белән.— Шундый биектән аска карадым исә, күңелемне һәрвакыт ниндидер татлы бер нәрсә кытыклый башлый... аннары аяк бармакларын нидер яман чәнчештерә... Ә үзең, куркыныч булса да, барыбер карыйсы килә, күрәсе килә...

Ул тагын бер мәртәбә яр астына үрелеп карамакчы булган иде дә, апасы туктатып калды.

— Анна, кадерлем, алла хакы өчен карама! Син шулай караганда, минем үземнең дә башым әйләнә. Зинһар дим, утыр.

— Йә, булды, булды, утырдым... Тик син карап кына бакчы, нинди матур, нинди ямьле — чын менә, күреп туймаслык. Беләсеңме, безнең хакка шундый гүзәллекләр, могҗизалар тудырганы өчен ходайга нинди генә рәхмәтләр әйтсәң дә җитмәс кебек.

Алар икесе дә уйга калдылар. Алардан аста, түбәндә, тын диңгез җәйрәп ята. Эскәмиядә утырган җирдән яр буе күренми иде, шунлыктан диңгез тагын да чиксезрәк, биегрәк булып тоела. Су өсте тыныч-ягымлы һәм шат-зәңгәрсу төстә, бары агым булган урыннарда гына ул кыйгач-кыйгач аксыл шома тасмалар жемелдәгәндәй сыегаеп күренә һәм офыкка таба бөтенләй куе зәңгәр төскә — тирәнлек төсенә керә бара иде.

Ярдан ерак түгел, диңгез тигезлегендә, күзгә күренер-күренмәс кечкенә һәм йокымсырап яткан хәрәкәтсез ноктала булып, балыкчы көймәләре төсмерләнә. Ә алардан арырак, бер урында һавада асылынып торгандай, өч мачталы һәм баштанаяк жилдән киерелгән бертөрле ак жилкәннәргә төренгән ялгыз кораб күренә.

— Мин сине аңлыйм,— дип куйды княгиня Вера уйчан гына,— тик үзем ничектер синеңчә була алмыйм. Озак вакыттан соң диңгезне кабат күргәч, мин дә аңа шулай синең кебек дулкынланып, шатланып һәм шаккатып, сокланып карыйм. Ул миңа беренче мәртәбә күргән ниндидер мәһабәт, тантаналы бер могҗиза булып тоела. Әмма соңыннан, ияләшә, күнегә төшкәч, ул мине үзенең мәгънәсез бушлыгы, киңлеге белән ничектер баса, изә башлый... Аңа карадым исә, минем эчем поша, шуңа күрә дә мин аңа бүтән карамаска тырышам. Күңел кайта, туйдыра.

Анна елмаеп куйды.

— Нигә елмаясың? — дип сорады апасы.

— Узган җәйне,— диде Анна шат-уенчак тавыш белән,— без атларга атландык та зур бер компания булып

Өч Кош түбәсенә чыгып киттек. Өч Кошны беләсеңдер бит, урман хуҗалыгы артында, шарлавыктан югарырак урнашкан тау. Башта болытлар эченә килеп кердек, һава дымлы, томан аркылы берни күрерлек түгел, ә без, бернәрсәгә карамыйча, наратлар арасыннан сузылган текә сукмак буйлап югарыга таба һаман менәбез дә менәбез. Аннары урман кинәт кенә бетте дә, без томан эченнән ачыклыкка килеп чыктык. Инде күз алдыңа китер: кыя өстендә — тар гына мәйданчык, ә безнең аяк астында упкын җәйрәп ята. Астагы авыллар шырпы кабы шикелле генә күренә, урманнар белән бакчалар җиргә ятып үскән чирәм кебек. Диңгезгә таба сөзәкләнеп төшкән тау итәге уч төбендәге кебек күренә, география картасы диярсең. Ә шуннан ары — диңгез! Илле, йөз чакрымнарга сузылган иксез-чиксез диңгез! Шул чакта мин үземне һавада асылынып торгандай хис иттем һәм менә-менә очып китәрмен дип көттем. Шундый гүзәллек, шундый җиңеллек! Куанычымнан нишләргә белмичә, артыма борылдым да юл күрсәтүче татарга: «Ничек? Матурмы, Сәед оглы?» — дип кычкырдым. Ә ул иренәрен генә чупылдатып куйды: «Их, барина, барина, күреп туйган инде без боларны. Һәр көн күз алдыбызда».

— Чагыштыруың шәп, рәхмәт,— диде Вера, көлеп.— Мин бары тик без, төньяк кешеләре, диңгезнең гүзәлекләрен беркайчан да аңлый алмаячакбыз дип кенә әйтергә теләгән идем. Мин үзем урманны яратарак төшәм. Безнең Егоровскидагы урманны хәтерлисеңме?.. Аңардан кайчан да булса туярга мөмкинме соң? Наратлары нинди!.. Ә урманындагы мүге!.. Чебен гөмбәләре! Әйтерсең лә кызыл атлас өстенә ак төрткеләр чигеп чыкканнар. Ә нинди тынлык... нинди җиләс һава!..

— Миңа барыбер, мин бөтенесен дә бертигез яратам,— дип җавап бирде Анна.— Ә барысыннан да битәр апамны, минем акыллы Веренькамны яратам. Без бит бөтен дөньяда икәүдән-икәү.

Ул апасын кочаклады да бите белән аның битенә сыенды. Һәм кинәт сискәнеп китте.

— Менә бит мин нинди юләр! Романдагы хатыннармыни, икәүдән-икәү генә утырганбыз да рәхәтләнеп табигать турында гәп сатабыз, ә мин үземнең сиңа алып килгән бүләгем турында бөтенләй онытып җибәргәнмен. Менә, карале. Тик сиңа ошар микән ул?

Ул үзенең кул янчыгыннан кечкенә генә китапчык — куен дәфтәре чыгарды. Тышы бик гажәеп иде бу китапчыкның: кайчандыр ямь-яшел булган һәм вакыт үтү белән кыр-

шылган, төсе тоныклана төшкән бәрхеткә,— һичшиксез, үз эшен бик яраткан сабыр холыклы ниндидер оста кулы белән,— искиткеч матур итеп, нечкә-пөхтә итеп, борынгы кара алтыннан хикмәтле бер сурәт-бизәк ясалган иде. Эчтәге битләре урынына фил сөягеннән эшләнгән таблеткалар куелып, үзе ул җептәй нечкә алтын чылбырга тагылган иде.

— Искиткеч шәп нәрсә бит бу! Сокланып туймаслык! — диде Вера һәм сеңелесен кочаклап алды.— Бик рәхмәт инде сиңа. Кәян таптың син шундый хәзинәне?

— Бер антиквар кибетеннән табып алдым. Борынгыдан калган төрле иске-москы арасында казынырга яратканымны беләсең ич. Менә шунда юлыктым да инде бу догалыкка. Әнә, күрәсеңме, бу урында аның бизәге ничек тәре сурәтенә күчеп китә. Дөрес, антиквардан алганда аның шушы тышлыгыннан башка бүтән бер нәрсәсе дә юк иде югын, эчке битләрен, каптырмаларын, карандашын аның миңа соңыннан гына уйлап табарга туры килде. Никадәр аңлаттым бит Моллинега — барыбер җиренә җиткереп эшли алмады. Югыйсә, каптырмалар, бизәкнең үзе кебек үк, борынгы кара-тоныкалтыннан шундый үк стильдә, нечкәләп кырып ясалырга тиеш иде, ә Моллине аларны әнә ничек әштер-өштер генә ясап куйган. Аның каравы, чылбыры чын борынгы чылбыр, Венеция заманындагы чылбыр.

Вера китапчыкны иркәләп сыйпап куйды.

— Нинди чал борынгылык!.. Кайсы заманнарда эшләнгән икән бу тышлык? — дип сорады ул.

— Тәгаен генә әйтүе дә читен. Шулай да якынча унҗиденче йөзнең ахырларында яисә унсигезенче йөзнең урталарында булырга тиеш...

— Уйласаң кызык та инде,— диде Вера, уйчан гына елмаеп.— Менә мин хәзер аны, шушы китапчыкны, кулымда тотып торам, ә кайчандыр ул, бәлкем, маркиза Помпадурныңмы яисә королева Антуанеттаныңмы үз кулында булгандыр... Шулай да, Анна, минем сиңа шуны әйтәсем килә: догалык китабыннан хатын-кыз carnet [1]ы ясау шикелле дуамал теләк туса да бары тик синең башта гына туа алыр. Ярар, әйдә, өйгә керик әле, анда ниләр бар икән?!

Алар «изабелла»дигән үрмәле йөзем куакларының куе яшел чаршавы белән томаланган зур таш терраса аша өйгә юнәлделәр. Террасаның урыны-урыны белән кояш нурында алтынланып җемелдәгән ярым караңгы яшел стенасыннан, бөтен тирә-якка җир җиләгенекедәй җиңелчә

[1] Куен дәфтәре (французча).

хуш ис аңкытып, эре һәм авыр йөзем тәлгәшләре асылынып тора иде. Террасага иңгән яшькелт яктылыктан исә хатын-кызларның йөзләре шундук агарынып киткәндәй булды.

— Син табынны шушында җәйдермәкче буласыңмы? — дип сорады Анна.

— Баштарак шушында җәйдерермен дигән идем дә, хәзер инде кире уйладым... Кичләрен бик салкынайта. Аш бүлмәсендә утырсак яхшырак булыр дим. Ә ирләр монда тәмәке тартырга чыгып йөрерләр.

— Берәр кызыклы кеше киләсеме соң?

— Кем киләсен үзем дә белмим әле. Тик безнең бабай буласын гына ачык беләм.

— Ах, алайса, бабакай киләчәк? Менә монысы шәп! — диде Анна, куанычыннан кулларын чәбәкләп.— Минем инде аны йөз ел күргәнем юк шикелле.

— Васяның апасы булачак, аннары профессор Спешников та килергә тиеш бугай. Кичәгенәк, Анненька, шуларны уйлый-уйлый бөтенләй зиһенем чуалып бетте. Беләсең ич, алар икесе дә — бабай да, профессор да — ашарга бик яраталар. Ә азык-төлекне ни монда, ни шәһәрдә — бернинди бәягә дә табарлык түгел. Лука үзенең таныш сунарчысы аша берничә бүдәнә тапкан табуын, хәзер әнә шулардан нәрсәдер әмәлләп маташа. Ростбиф болай чагыштырмача ярыйсы гына туры килде, ләкин ул һаман да шул туйдырып бетергән бер ростбиф бит инде. Кыслалар менә әйбәт дисәң дә әйбәт булыр шикелле.

— Алай булгач, барысы да яхшы чыга түгелме соң? Син инде, зинһар, ул кадәр борчылма. Хәер, ашау дигәндә син үзең дә, әйтсәм әйтим, бик тәмле тамак шул.

— Болардан башка да кайбер тәмле нәрсәләр булыр, билгеле. Бүген иртән бер балыкчы диңгез әтәче китерде. Үзем күреп калдым. Коточкыч нәрсә. Хәтта кararга да куркыныч.

Һәрбер нәрсәгә — үзенә кагылганына да, үзенә кагылмаганына да бертөрле комсыз кызыксыну белән караган Анна шундук диңгез әтәчен үзенә китереп күрсәтүләрен таләп итте.

Озак та үтми, ишектә озын буйлы, кырылган шома битле пешекче Лука күренде. Кулына ул, ике колагыннан эләктереп, озынча авыр ап-ак лакан күтәргән һәм, лакандагы су чайпалып паркет идәнгә түгелмәсен өчен, аны бик сакланып кына тотып килә иде.

— Авырлыгы унике кадак ярым булды, ваше сиятель-

ство,— диде ул, поварларга гына хас бер горурлык белән.— Баягынак юри үлчәп карадык.

Лакан балык өчен артык кечкенә булганга, ул аның төбенә койрыгын чорнап бөгәрләнеп яткан иде. Балыкның тиресе алтын сыман ялтыравык тәңкәләр белән капланган, йөзгечләре җете кызыл төстә, ә зур ерткыч башының саңаклары астыннан як-якка таба җилпәзә сыман җыелмалы һәм сыек зәңгәр төстәге ике озын канаты тырпаеп тора иде.

Анна чәнти бармагының очы белән бик сакланып кына балыкның башына орынды. Ләкин шул чакны диңгез этәче койрыгын кисәк кенә чупылдатып куйды да, Анна чәрелдәп кычкырып җибәрде һәм кулын кире тартып алды.

— Борчылмагыз, ваше сиятельство, бөтенесе дә менә дигән булыр,— диде повар, Аннаның нидән борчылуын аңлагандай.— Әле генә бер болгар абзые ике кавын китереп китте. Менә дигән ананас кавыннар. Теге канталупа кавыннары сыман, хәтта аңардан да хуш ислерәк. Аннары, ваше сиятельство, сездән шуны сорыйсы килә иде: этәч янына ниндирәк соус куярга боерасыз? Тартарча [1] соус булсынмы, әллә полякча соусмы? Әллә булмаса майлы сохари шулпасы да ярармы?

— Үзең ничек беләсең, шулай эшлә. Бар! — диде княгиня, боерып.

IV

Кичке сәгать биштән соң дачага кунаклар җыела башлады. Иң әлек, үзе белән дүрт кеше ияртеп, князь Василий Львович кайтты. Ул алып кайткан дүрт кунакның берсе князьнең тол апасы — юан, симез гәүдәле, яхшы күңелле һәм ифрат дәрәҗәдә аз сөйләшүчән Людмила Львовна, яисә, ире буенча әйткәндә, Дурасова ханым; икенчесе — югары җәмгыятьтә үзенең җилкуарлыгы белән, яхшы җырлавы һәм декламацияләрне оста сөйләве, шулай ук еш кына җанлы тамашалар, спектакльләр, җәмгыяте хәйрия файдасы өчен махсус бал-мәҗлесләр оештыруы белән дан тоткан, шәһәр халкы арасында күбрәк Васючок дип кенә атап йөртелгән, азган-тузган, шалапай бер байбәтчә; өченчесе — княгиня Вераның Смольный институтта бергә укыган ахирәт дусты, хәзер атаклы пианистка Женни Рейтер һәм дүртенчесе князьнең каенагасы Николай Николаевич

[1] *Тартарча* — ягъни татарча.

иде. Озакламый автомобиленә утырып Аннаның ире дә килеп жите. Ул да үзе белән бергә ике кунак: такыр башлы, юан-шыксыз гәүдәле профессор Спешников белән төбәк вице-губернаторы фон Зеккны алып килгән иде. Иң соңыннан, махсус ялланган һәйбәт ландога утырып һәм ике офицер иярткән, генерал Аносов килде. Аны озата килгән офицерларның берсе штабтагы ми корыткыч авыр эштә тәмам таушалып, холкы бозылып беткән һәм вакытыннан элек картайган, өшәнгән чандыр гәүдәле полковник, ә икенчесе Петербургта иң оста биюче һәм бал-мәҗлесләрдә табын тотучы буларак дан-шөһрәт казанган гвардия гусары поручик Бахтинский иде.

Генерал Аносов — озын буйлы, көмеш чәчле, юан, симез карт — бер кулы белән кузла башына, икенче кулы белән экипаж аркасына таяна-таяна, ашыкмыйча гына коляскадан төшә башлады. Сул кулына ул колак торбасы, ә уң кулына резин башлы кул таягы тоткан иде. Генералның киң, тупас йөзе кызарып чыккан, борыны итләч, ә табак битенә жәя сыман ярым түгәрәк ясап урнашкан шешенке һәм кысык күзләре үлем һәм хәтәр хәлләрне якыннан белгән һәм алар белән күп мәртәбәләр күзгә-күз очрашкан батыр йөрәкле гади кешеләрдә генә була торган тантаналы бер мөлаемлык белән һәм аз гына мыскыл сиздереп карый иде. Апа белән сеңел, генералны ерактан ук танып, коляска янына йөгереп килделәр һәм, шаяру катыш бер житдилек белән картны ике яктан култыклап алып, аңа жиргә төшәргә ярдәм иттеләр.

— Архиерейны... каршылыйлармыни! — дип куйды генерал, карлыкканрак ягымлы калын тавыш белән.

— Бабакай, сөеклебез, кадерлебез безнең! — диде Вера, шелтә белдереп.— Без сезне көн саен көтәбез, ә сезнең монда бер генә мәртәбә дә күренеп киткәнегез юк.

— Безнең бабакай көньякта бөтенләй оятын жуйган,— диде Анна, көлеп.— Юкса, ул үзенең дингә ярәштергән кызын исенә төшермичә калмас иде. Чыннан да, оятыгыз качкан сезнең, бабай, үзегезне донжуандай тотасыз, безнең дөньяда барлыгыбызны да онытасыз...

Генерал, чал башын ялангачландырып, бер-бер артлы ханымнарның кулларын үбәргә тотынды, аннары аларны битләреннән үпте дә тагын кулларына күчте. Үзе ул, элек-электән килгән тын бетү хастасы белән жәфаланып, буыла-буыла, һаман сөйләнүендә булды:

— Кызлар... зинһар, сабыр итегез... ачуланмагыз... Чыннан менә... бөтенесенә шул каһәр суккыры докторлар гаеп-

ле... Җәй буе ревматизмымны... ниндидер шакшы ... кесәлдә коендырып маташтылар... Исенә түзәрлек түгел, кайәрнең... Ничек чыгарырга теләмәделәр... Менә... беренче булып... сезгә килдем... Сезнең белән күрешүемә... искиткеч шатмын... Ничек яшәп ятасыз соң?.. Син, Верочка... инде бөтенләй леди булгансың димме... мәрхүмә әниеңә тагын да... охшыйрак төшкәнсең... Бала чукындырырга мине кайчан чакырасың соң?

— Ой, бабакай, чакырырга туры килмәс дип куркам...

— Өметеңне өзмә алай... барысы да алда әле синең... Ходадан рәхим-шәфкать сора... Ә син, Аня, бер дә үзгәрмәгәнсең... Алтмыш яшькә җиткәч тә... син һаман шул чикерткә булып калырсың, ахры. Кая, туктагыз әле. Мин сезне офицер әфәнделәр белән таныштырыйм.

— Мин инде күптән андый бәхеткә ирештем! — диде полковник, башын иеп.

— Мине княгиня белән Петербургта таныштырганнар иде,— диде гусар поручигы да, полковникның сүзен элеп алып.

— Алайса, Аня, рөхсәт ит, мин сине поручик Бахтинский белән таныштырам. Оста биюче һәм сугыш чукмары, ләкин үзе бик яхшы кавалерист та. Кая, чыгар әле коляскадан теге нәрсәне, сөеклем Бахтинский... Киттек, кызлар... Безне нәрсә белән сыйламакчы буласың, Верочка? Лимандагы режимнан соң... минем аппетит... яңа укуын бетереп чыккан... прапорщик аппетитынннан бер дә ким түгел.

Генерал Аносов мәрхүм князь Мирза-Булат-Тугановскийның сугышчан юлдашы һәм иң якын дусты иде. Князь вафат булганнан соң, ул үзенең бөтен дуслык һәм мәхәббәт хисләрен аның кызларына күчергән иде. Кызларны ул әле сабый чакларыннан бирле белә, ә кечесе Аннага хәтта чукындыру йоласын үтәүче бабай да булган иде. Ул вакытларда — шулай ук бүгенге көндә дә — Аносов «К» шәһәрендә зур һәм асылда хәрби әһәмиятен бөтенләй югалткан бер крепостьның коменданты булып тора иде һәм көн саен диярлек Тугановскийларның өенә килеп йөри иде. Һәрвакыт ачык чырайлы булуы, назлы иркәләүләре, китергән бүләкләре һәм цирк белән театрга еш кына ложадан урыннар алып бирүе һәм шулай ук башка бүтән беркем дә булдыра алмаганча кызыклы, мавыктыргыч уеннар оештыра белүе өчен балалар аны үлеп ярата торганнар иде. Ләкин барыннан да бигрәк генералның хәрби походлар, сугыш күренешләре, бивуакларда тукталып ял итү-

ләр, җиңүләр һәм чигенүләр, үлем белән йөзгә-йөз очрашулар, яраланулар һәм үзәккә үтәрлек салкын кышлар турындагы соклангыч хикәяләре балаларның күңелләрендә мәңге җуелмас бер истәлек булып сеңеп калган иде. Карт генерал үз башыннан кичкән бу хәлләрне ихлас күңелдән чыккан көйле-тыныч бер тавыш белән һәм, гадәттә, балаларның иң күңелсез вакытлары җиткәндә, ягъни кичке чәйне эчеп, аларны йокларга яткырыр алдыннан сөйли торган иде.

Хәзерге заманның гореф-гадәтләре ноктасыннан караганда, бу искелек калдыгы, Аносов, гадәттән тыш мәһабәт һәм бәһадир бер шәхес иде. Генералның холкындатабигатендә аның үз заманында да офицерлардан бигрәк солдатлар арасында гына еш очрый торган үзенә бертөрле гади, ләкин ифрат дәрәҗәдә тирән һәм тәэсир итүчән сыйфатлар,— гомумән, рус кешесенә, бигрәк тә аның мужигына хас сыйфатлар, кайчакны безнең рус солдатын җиңелмәс итә торган, алай гына да түгел, котылгысыз минутларда аңа газап чигүгә хәзер торырлык бер ныклык, фидаилек, хәтта ки изгелек хасияте өсти торган сыйфатлар: дөньяда хәйләсез, беркатлы ышаныч белән яшәү, тормыш ыгы-зыгысына ачык һәм мөлаем-шук мөнәсәбәттә булу, искитмәүчән салкын канлылык белән батырлык эшләү, үлем алдында гамьсез бер күндәмлек күрсәтү, җиңелгәнне, бәлагә тарыганны кызгану һәм физик яктан да, әхлакый яктан да искиткеч чыдам булу кебек сыйфатлар бергә кушылган иде.

Польшадагы фетнәне бастыру сугышыннан башлап, Аносов Россия алып барган барлык хәрби кампанияләрдә катнашкан иде диярлек. Ул катнашмаган сугыш — бары рус-япон сугышы гына. Ул, бәлкем, анда да бернинди икеләнүсез китеп барган булыр иде, ләкин аны чакырмаганнар, ә Аносовның андый чакта тыйнак бер горурлык белән әйтә торган мәшһүр сүзе бар: «Чакырмыйча торып, үлем кочагына үзең барып кермә!» Ул үзенең хәрби хезмәте чорында солдатлардан кемне дә булса чыбык-шомпол белән суктыру түгел, хәтта кул да тидереп карамаган. Бервакытны, поляклар фетнәсен бастырганда, ул, полк командирының турыдан-туры боерыгы булуга да карамастан, әсирләрне атып үтерүдән баш тарткан. «Шпионны ату түгел, боерсагыз, хәтта үз кулым белән буып үтерәм,— дигән ул.— Ә болар әсирләр, мин аларны аттыра алмыйм». Һәм ул шушы сүзләрне, үзенең ачык, куркусыз күз карашын туп-туры командирның күзләренә текәп, шундый гади

итеп, шундый ихтирамлы кыяфәт белән һәм бернинди дошманлык яисә һавалану әсәре сиздермичә әйткән ки, боерыкны үтәмәве өчен үзен аттырасы урында, аны тыныч-лыкта калдырырга мәҗбүр булганнар.

Аз белемле яки, үзе әйтмешли, «аюлар академиясен» генә тәмамлаган булуына карамастан, Аносов 1877—1879 еллардагы төрек сугышында полковник дәрәҗәсенә ирешә. Ул Дунай елгасын кичүдә катнаша, Балкан тауларын кичә, Шипка крепостен саклаша; Плевнага ясалган соңгы хәлиткеч һөҗүмдә катнаша; сугыш кырында аны биш тапкыр яралыйлар; шуларның берсе — бик каты, дүртесе жиңелчә яра була. Аның соңында, граната шартлаганда башына кыйпылчык тиеп, Аносов коточкыч әшәке контузия ала. Радецкий белән Скобелев аны якыннан белгәннәр һәм аңа искиткеч ихтирам белән караганнар. Скобелевның: «Мин үземнән күп мәртәбәләр батыррак булган бер генә офицерны беләм, ул да булса — майор Аносов!» — дигән сүзләре нәкъ аның турында әйтелгән була да инде.

Башына граната кыйпылчыгы тиюдән Аносов бөтенләй диярлек чукрак кала; Балкан таулары аша кичкәндә аягын өшетеп, өч бармагын кистерергә мәҗбүр була һәм, ниһаять, Шипка крепостен саклаганда үзенә гомерлек ревматизм авыруы элэктерә. Сугыштан кайтып, тыныч тормыш шартларында ике ел хезмәт иткәннән соң, аны отставкага чыгармакчы булалар, ләкин ул кирелек күрсәтә. Бәхетенә каршы, Дунай елгасын кичкәндә Аносовның сугышчан батырлыкларын үз күзе белән күргән йогынтылы бер түрә — өлкә башлыгы аңа ярдәм кулын суза. Петербург әһелләре шөһрәтле полковникның күңелен рәнжетергә базмыйлар, һәм озакламый Аносовны дәүләт иминлеге өчен әһәмияте булмаса да, шулай да мактаулы вазифа булып саналган хезмәткә — К. шәһәренә гомерлек комендант итеп билгелиләр.

Бу шәһәрдә аны, олысы-кечесе дигәндәй, һәммәсе дә яхшы белә иде. Аның сәер гадәтләре, киеме-салымы барлык кешеләрдә ягымлы бер елмаю уята иде. Аносов өстенә һәрвакыт иске модалы сюртук, башына озын, туры козыреклы һәм киң читле фуражка киеп йөри; урамга чыкканда үзе белән беркайчан да корал алып чыкмас; уң кулында һәрвакыт таяк, сул кулында колак торбасы булыр; әртыннан, бер адым да калышмыйча, җәрәхәтләнеп беткән тел очларын авызларыннан чак кына чыгарып, карлыккан тавышлы, ялкау хәрәкәтле ике симез эт — мопслар иярген булыр. Иртәләрен гадәттәгечә урамда йөргәндә бе-

рәр танышы очрап куйса, кешеләр аның бу танышы белән ничек кычкырып сөйләшүен һәм ике этенең һау-һаулап өрә башлавын берничә урам аркылы да ишетеп тораларлар иде.

Чукрак кешеләрнең күбесе кебек, Аносов та опера кадарга бик ярата иде. Кайчакны, нинди дә булса берәр моңлы дуэт башкарылганда, залда кинәт кенә аның бөтен театрны дер селкетерлек гөрелдәвек калын тавышы яңгырап китә: «Күрче, «до»ны ничек чиста алды, шайтан, ә! Чикләвек кабыгын шартлатып ярдымыни!» Бу сүзләрдән соң, әлбәттә, залдагы кешеләр арасында тыелып кына көлешкән тавышлар ишетелеп куя, әмма генералның үзенең гамендә дә булмый: беркатлылыгы аркасында, ул үзенең җырдан алган тәэсире турында күршесенә пышылдап кына әйттем дип уйлый иде.

Комендантлык вазифасы буенча ул еш кына, карлыккан тавышлы әлеге мопсларын иярткән, шәһәрнең үзәк гауптвахтасына барып килгәли. Кулга алынган офицерларның күбесенә бу гауптвахта үзенә күрә бер ял итү урыны кебек иде. Хәрби хезмәтнең авыр мәшәкатьләреннән, ыгы-зыгыларыннан соң, алар монда бернинди ваемсыз, рәхәтләнеп карта уйнап, чәй эчеп яисә төрле мәзәк сүзләр сөйләшеп утыралар иде. Гауптвахтага килгәч, Аносов иң элек һәрбер офицердан аның исеме, монда кем тарафыннан утыртылуы, күпмегә һәм нәрсә өчен утыртылуы турында җентекләп сорашып чыга. Кайвакытны теге яки бу офицерны эшләгән эше өчен — гәрчә ул законга сыймаслык бер эш булса да — үтереп мактап ташлый яисә аны тетмәсен тетеп сүгәргә тотына. Андый чакта генералның гөрелдәвек калын тавышы бөтен урамга ишетелеп тора иде. Шулай туйганчы җикеренгәч, ул кинәт, сүзендә бернинди тукталыш яисә күчеш ясап тормастан, әлеге офицерның ашавы-эчүе турында сорап куя. Янәсе, ашарга кайдан китерәләр, азык-төлек өчен күпме акча түли? Ара-тирә шулай да була: каяндыр ерактан, үз гауптвахталары булмаган берәр аулак урындагы гаскәри частьтан зур сроклы җәзасын үтәү өчен бирегә җибәрелгән нинди дә булса ярлы подпоручик аңа, Аносовка, акчасы юклыктан үзенең солдатларга хәзерләнгән азык-төлек белән тукланырга мәҗбүр булуын әйтә. Андый чакта инде генерал бу мескен офицерга аш-суны үз өеннән — гауптвахтадан нибары ике йөз адым чамасы гына ераклыкта урнашкан комендант йортыннан китертергә дип боерык бирә.

К. шәһәрендә яшәгәндә генерал Аносов Тугановскийлар

гаиләсе белән дуслашып алды. Бигрәк тә бу гаиләдәге ике кызга бик ияләште ул. Аларны көн саен күреп тору аның өчен тыелгысыз бер ихтыяҗга әверелгән иде. Әгәр туташлар кая да булса китеп барса яисә ул үзе, хезмәттәге эшләре белән тоткарланып, аларны озаграк күрми торса, генерал тәмам сагышка бирелә һәм комендант йортының иркен, буш бүлмәләрендә үзенә урын таба алмыйча аптырап бетә иде. Һәр җәйне ул, ял алып, бер ай буе Тугановскийлар гаиләсе белән бергә Егоровскида — аларның К. шәһәреннән кырык-илле чакрым ераклыктагы имениеләрендә тора иде.

Генерал үзенең мәхәббәткә сусаган күңеле төбендәге барлык хис-тойгыларын, йөрәк җылысын балаларга, бигрәк тә әлеге ике кызга күчергән иде. Кайчандыр, бик күптән, ул үзе дә өйләнгән булган, имеш. Ләкин бу өйләнешеп торуны ул инде хәзер бөтенләй хәтерләми дә диярлек. Әле сугышка кадәр үк аның хатыны, узгынчы бер актерның бәрхет курткасына һәм челтәрләп эшләнгән җиң очларына кызыгып, шул актер белән качып киткән. Генерал бу хатынга, ул үлгәнчегә хәтле, пенсия җибәреп торган, ләкин аны, тәүбәгә килүенә һәм күз яшьләре белән ялварып хатлар язуына да карамастан, үз өенә аяк бастырмаган. Балалары исә аларның беркайчан да булмаган иде.

V

Кичен, алдан көтелгәнчә, салкынайтмады, бәлки тын һәм җылы булды. Террасадагы һәм ашау бүлмәсендәге шәмнәрнең ялкын телләре бөтенләй хәрәкәтсез янып тордылар. Табын янында һәммә кешене князь Василий Львович көлдереп утырды. Аңарда ниндидер гадәти булмаган, үзенә бертөрле сөйләү сәләте бар иде. Сөйләгән сүзенең төп нигезе итеп ул һәрвакыт чын вакыйганы ала, ә вакыйганың үзгендә исә табында утыручыларның берәрсе яки аларның уртак тавышы була; ләкин бу вакыйганы князь шундый җитди кыяфәт һәм эшлекле тавыш белән сөйли һәм аның буяуларын шундый куертып бирә, тыңлаучылар бертуктаусыз эчләре катып көлеп утырырга мәжбүрләр. Бүген ул Николай Николаевичның чибәр һәм мул тормышлы бер бай хатынга өйләнергә йөреп тә, өйләнә алмыйча калуы турында сөйли иде. Бу вакыйганың чын дигәне шул: әлеге хатынның никахлы ире аңа аерылышырга рөхсәт бирмәгән. Ләкин Василий Львович сөйләвендә хакыйкать белән уйдырма гажәеп төстә бергә аралашып бара иде. Җит-

ди һәм беркадәр кыланчыграк табигатьле Николайны ул, аякларына оек кына кидертеп һәм башмакларын култык астына кыстыртып, төнлә белән урам буенча йөгертеп йөртте. Бер урам чатында аны шушы кыяфәтендә городовой очрата да урам карагы итеп кулга алырга тели, имеш. Шактый озакка сузылган җәнҗаллы сүз көрәштерүдән соң гына Николай городовойга үзенең прокурор ярдәмчесе икәнлеген исбатлап бирә. Сөйләүченең фараз итүенчә, туйны да алар чак-чак кына ясамыйча калалар; туйны уздыруга, имеш, ялган шаһитлар бандасының хезмәт хакын арттыруны сорап забастовка күтәрүләре генә комачау иткән. Николай, имеш, үзенең саранлыгы (ул чыннан да бераз саранрак кеше иде) һәм стачка, забастовка ише нәрсәләргә принципиаль төстә каршы булуы аркасында, шаһитларның хезмәт хакларын арттырудан баш тарткан. Моның өчен ул хәтта законнар җыелмасыннан кирәкле статья да тапкан һәм бу статьяны кассация департаментының фикере белән дә раслаттырган, имеш. Менә шуннан соң инде ялган шаһитларның тәмам ачулары чыккан, һәм алар никахлашу йоласында попның: «Монда җыелучылардан берәрегез бу никахлашуга комачау итәрдәй нәрсә белмиме?» — дигән гадәти соравына каршы бердәм рәвештә: «Әйе, беләбез. Судта без ант итеп сөйләгәннәрнең һәммәсе дә ялган, алай сөйләргә безне прокурор әфәнде мәҗбүр итте. Ул безгә янады, үч алам дип куркытты. Ә бу ханымның ире турында без, хәбәрдар кешеләр буларак, шуны әйтә алабыз: дөньяда ул хөрмәткә иң лаек, Йосыф пәйгамбәрдәй саф һәм фәрештәдәй шәфкатьле бер кеше»,— дип җавап кайтарганнар, имеш.

Никах-өйләнешү мәсьәләләренә бер кереп киткәч, Василий Аннаның ире Густав Иванович Фриессене дә читтә калдырмады — аның турында да шактый чәнечкеле бер мәзәк сөйләп алды. Янәсе, туйдан соң икенче көнне Густав Иванович, үзе белән полицейскийларны алып, бабалары өенә килгән дә, яшь кәләшнең үзенә аерым паспорты булмавын сылтау итеп, аны кичекмәстән ата-ана йортыннан куып чыгаруларын һәм сак астында кияве өенә озатуларын таләп иткән. Бу мәзәктә хак булганы шул: туйдан соң Анна, апасы Вераның ашыгыч рәвештә көньякка китеп баруы сәбәпле, чыннан да күпмедер вакыт үз өйләрендә авыру әнисен карап торган иде, ә Густав Иванович, яшь кәләшен юксынып, аерым яшәргә мәҗбүр булган иде.

Князь Василийның мәзәге һәммә кешегә дә хуш килде. Анна да аны яратып, үзенең кысык күзләре белән елмая-

елмая тыңлады. Густав Иванович исә, куанычыннан нишләргә белмичә, шаркылдап көлеп утырды. Көлгән чакта аның ялтыравыклы соргылт тире белән тартылган ябык шома йөзе, ялап куйгандай сыланып яткан аксыл сирәк чәчләре һәм эчкә баткан күз төпләре — бөтенесе бергә ниндидер мәет йөзен яки тешләрен ыржайтып көлеп торган баш сөяген хәтерләтә иде. Өйләнешүнең беренче көнендәге кебек үк, ул хәзер дә үзенең Аннасына сокланып туя алмый; мәҗлесләрдә гел аның янына утырырга тырыша һәм кеше күрмәгәндә генә аңа орынып-орынып куя иде. Аның кылануларын, сукыр гашыйкларча Аннага ярарга тырышуларын күреп, еш кына хәтта чит кешеләр дә аның өчен оялып, уңайсызланып утыра торганнар иде.

Табын яныннан торып китәр алдыннан Вера Николаевна ничектер аңсыз рәвештә күпме кунак җыелганын санап чыкты. Барысы унөч кеше иде. Хорафатларга ышанучы кеше буларак, ул эченнән генә: «Шәп түгел бит бу! Элегрәк санап чыгарга ничек башыма килмәде икән? Вася да гаепле — күпме кунак киләсен алдан ук телефоннан әйтеп куйса ни булган инде!» — дип уйлап куйды.

Вера да, Анна да азартлы уеннарны бик яратканга күрә, Шеинларда яисә Фриесселарда дус-ишләр җыелды исә, табын яныннан торгач та шундук покер[1] уйнарга керешәләр иде. Бу мәсьәләдә хәтта һәр ике йортның махсус кагыйдәләре дә бар иде. Гадәттә, монда барлык уенчыларга алдан ук бертигез санда һәм күләмдә сөяк шакмаклар бүлеп бирелә иде. Шушы сөяк шакмаклар бер кеше кулына күчеп беткәнче, уенны дәвам итәргә мөмкин, аннары, уйнаучыларның бернинди карышуына карамастан, уен үзеннән-үзе тукталып калырга тиеш. Кассадан өстәмә шакмаклар алу каттый төстә тыела. Мондый катгый закон княгиня Вераны һәм Анна Николаевнаны күздә тотып чыгарылган иде, чөнки алар, уен вакытында артык мавыгып китеп, бернинди чикне белми башлыйлар иде. Гомуми оттырыш исә беркайчан да йөз-ике йөз сумнан артмый иде.

Бу юлы да кунаклар покер уйнарга утырдылар. Бары тик Вера гына уенга катнашмады. Ул чәй табынын әзерләгәнне кәрарга дип террасага чыгып кермәкче булды, ләкин чыгып өлгермәде, кинәт ишектә асрау кыз күренде һәм ниндидер серле бер кыяфәт белән княгиняны кунак бүлмәсеннән чакырып чыгарды.

---

[1] Карта уенының бер төре.

— Нәрсә булды, Даша? — дип сорады княгиня, кәефсезләнү сизелеп торган бер тавыш белән, йокы бүлмәсенә янәшә урнашкан үз кабинетына узып.— Нәрсә шыр жүләрдәй катып калдыгыз? Нәрсә ул кулыгызда?

Даша ак кәгазьгә пөхтәләп төрелгән һәм тышкы ягыннан алсу тасма белән чорнап бәйләнгән ниндидер шакмаклы нәрсәне өстәл өстенә куйды.

— Чын менә, ваше сиятельство, минем бернинди гаебем юк,— диде ул, рәнҗүеннән бит алмалары кызарып.— Ул килде дә әйтте...

— Кем ул — ул?

— Кызыл башлыклы бер кеше, ваше сиятельство... йомышчы егет.

— Шуннан нәрсә?

— Кухняга килеп керде дә менә шушы нәрсәне өстәл өстенә китереп куйды. «Моны, ди, барыняга тапшырыгыз, ди. Тик аның үз кулына гына бирегез»,— ди. Мин әйтәм: «Кемнән соң ул?» — дим. Ул әйтә: «Анда барысы да язылган»,— ди. Шулай диде дә йөгереп чыгып та китте.

— Барыгыз, куып житегез үзен.

— Аны хәзер ничек куып житмәк кирәк, ваше сиятельство? Ул бит инде мәҗлес башлангач та килгән иде, мин бары сезне борчырмын дип кенә курыктым. Ул киткәнгә инде ярты сәгать вакыт узды.

— Ярар алайса, барыгыз чыгыгыз.

Княгиня Вера, кулына кайчы алып, төргәкнең тасмасын кисте дә, аны үзенең адресы язылган кечкенә кәгазь кисәге белән бергә йомарлап, кәржингә ташлады. Төргәк эченнән бәрхет тышлы бәләкәй бер тартмачык килеп чыкты. Тартмачык бик яңа, әле генә ювелир кибетеннән сатып алынганга охшый иде. Вера аның сыек яшел төстәге ефәк эчле капкачын ачты һәм тартмачык төбендә кара бәрхет аслыкка жайлап урнаштырылган озынча-түгәрәк алтын беләзек күрде. Беләзекнең уртасына, пөхтәләп, сигезгә бөкләп, хат салынган иде. Княгиня шундук хатны алып ачып карады. Хатны язган кешенең кулы аңа бик таныш кебек тоелды, ләкин ул, хатын-кызга хас булган бер омтылышка буйсынып, хатны бер читкә алып куйды да иң элек беләзекне жентеклəп карарга кереште.

Түбән сыйфатлы алтыннан эче куыш итеп эшләнгән шактый калын һәм килбәтсез бер беләзек иде бу. Аның өске ягы тоташ борынгы вак асылташлар — шомартылуы, ялтыратылуы житмәгән гранатлар белән бизәлгән иде. Аның каравы, беләзекнең урта өлешендә, кашында, яшел төстәге

ниндидер сәер бер ташчык тирәли, һәрберсе борчак зурлыгында түгәрәкләп шомартылган икенче төр гранатлар — биш бөртек гүзәл кабошон [1] калкып тора иде. Вера, беләзекне кулында әйләндереп карый-карый, ничектер искәрмәстән генә аны электр лампасыннан төшкән яктыга җайлап куйды, һәм шундук кабошон гранатларның эчендә, бик тирәндә, тере нәрсәләр сыман, җете кызыл утлар кабынып китте.

«Канмыни!» — дип уйлап куйды Вера, күңеле төбендә ниндидер шомлы бер хис уянуын тоеп.

Аннары ул хатны исенә төшерде дә аны яңадан кулына алып укырга кереште. Гаҗәеп матур вак хәрефләр белән язылган бу хатта менә нинди сүзләр укыды ул:

«Ваше сиятельство,
Могтәбәр ханым, Хөрмәтле Княгиня
Вера Николаевна!

Сезне түбәнчелекле төстә нурлы һәм шатлыклы Туган көнегез белән котлап, Сезгә шушы тугрылыклы хатымны һәм кечкенә генә бүләгемне юлларга рөхсәт итегез».

«Ah, бу теге егетмени әле!» — дип уйлап алды Вера, кәефсезләнеп. Ләкин шулай да үзе хатны ахырынача укып чыгарга булды.

«Мин, шәхсән үзем сайлап, Сезгә лаек бернинди бүләк тә тәкъдим итә алмас идем: моның өчен минем Сезнең алда хокукым да, нәфислекне аңлардай зәвыгым да һәм — дөресен әйтим — акчам да юк. Хәер, миңа калса, мин үзем Сезгә лаек булырдай бүләк гомумән дөнья йөзендә юктыр дип уйлыйм.

Шулай да минем бу бүләгем бөтенләй үк хикмәтсез түгелдер. Кайчандыр аны минем әбиемнең әбисе киеп йөргән, ә соңгы мәртәбә ул мәрхүмә әниемнең беләген бизәгән. Беләзекнең кашында, эре асылташлар уртасында, сез тагын бер яшелен дә күрерсез. Гранат асылташларның шактый сирәк очрый торган бер төре — яшел гранат ул. Безнең гаилә риваятьләренә караганда, бу яшел гранатны тагып йөргән хатын-кыз күрәзәлек сәләтенә ия була, имеш; аннары ул аларны авыр уйлардан арындыра, ә ир-атны фажигале үлемнән саклый, имеш.

Мондагы асылташлар барысы да борынгы көмеш беләзектән әүвәлге тәртипләрендә күчереп куелганнар, һәм,

---

[1] *Кабошон* — берме, икеме ягыннан түгәрәкләп шомартылган асылташ.

ышанығыз сүземә, бу беләзекне әле беркемнең дә киеп йөргәне юк.

Әлбәттә, Сез бу сәер бүләкне киряксез бер уенчык итеп чүплеккә ташлый аласыз яисә кемгә дә булса бүләк итеп бирә аласыз, ләкин Сезнең аңа бер орынуыгыз да минем өчен зур бәхет булачак.

Сездән ялварып сорыйм: зинһар, миңа ачуланмагыз. Моннан жиде ел элек Сезгә, кыз кешегә, әллә нинди ахмак, кыргый эчтәлекле хатлар язарга җөрьәт итүемне һәм хәтта ул хатларга Сездән җавап алырга өметләнеп йөрүемне искә төшерсәм, мин әле дә оятымнан жир тишегенә керерлек булам. Хәзер миндә Сезгә карата бары тирән хөрмәт хисе, мәңге күндәмлек һәм колларча буйсыну хисе генә торып калды. Минут саен Сезгә бәхет теләп яшәү һәм Сез бәхетле булганда шатлык хисе кичерү — минем бөтен белгәнем менә шул. Сез утырган урындыкларга, Сез басып йөргән паркет идәннәргә, Сез кулыгыз белән орынып киткән агачларга, Сез сөйләшкән асрауларга — һәммәсенә дә мин түбәнчелек белән башымны иям. Миндә хәтта көнләшү хисе дә юк, мин Сезне кешеләрдән дә, жиһаз-әйберләрдән дә көнләмим.

Шундый озын, кирәкмәс хат язып Сезне борчыганым өчен тагын бер мәртәбә Сездән гафу үтенәм.

Үлгәнче һәм үлгәч тә Сезгә тугрылыклы булып калачак колыгыз.

Г. С. Ж.»

«Васяга күрсәтергәме моны, әллә күрсәтмәскәме? Күрсәтәсе булса — кайчан күрсәтергә? Хәзер үкме, әллә кунаклар таралышкачмы? Юк, кунаклар таралышкач күрсәтү хәерлерәк булыр — хәзер күрсәтсәм, алар бу бичара егеттән генә түгел, минем үземнән дә көлә башлармар».

Княгиня Вера әнә шулай уйлады һәм биш бөртек гранатның бишесе эчендә дә кан төсле алсуланып янган дерелдәвек ялкын телләреннән күз ала алмыйча бик озак басып торды.

VI

Полковник Понамаревны покер уйнарга көчкә-көчкә генә күндерделәр. Башта ул, андый уенны белмим дип, гомумән азартлы уеннарны яратмыйм, хәтта аларны уенга да санамыйм дип, шактый озак киреләнеп маташты. «Мин,— диде ул,— бары винт дигән уенны гына яратам

һәм шуны гына аз-маз уйный беләм»,— диде. Ләкин үгетли-кыстый торгач, түземе җитмәде, уйнарга ризалыгын бирде.

Уен башында аны бераз өйрәткәләргә, төзәткәләргә туры килде, ләкин ул уен кагыйдәләрен шундый тиз үзләштерде, бер ярты сәгатьтән инде барлык сәяк шакмаклар аның кулына күчеп беткән иде.

— Болай батмый! — диде Анна, көлкеле бер үртәлү белән.— Бераз гына күңелне тирбәндерерлек тә булмады ич бу.

Кунакларның өчесе — Спешников, полковник һәм әдәпле-җыйнак, ләкин томана йөзле немец — артык тыйнак һәм эчпошыргыч кешеләрдән булганлыктан, Вера аларның ничек күңелләрен ачарга һәм аларны нәрсә белән мавыктырырга икәнен дә белмәде. Ахырда ул аларга винт уйнарга тәкъдим итте һәм дүртенче кеше итеп яннарына Густав Ивановичны да утыртты. Анна, рәхмәтен белдереп, апасына таба башын борды да күзләрен йомды, һәм Вера бу хәрәкәте белән аның нәрсә әйтергә теләгәнен шундук аңлап алды. Густав Ивановичның гадәтен барысы да яхшы беләләр иде; әгәр хәзер аны карта уйнарга утыртмасаң, кичнең кич буе ул, үзенең черегән тешләрен ыржайтып, хатыны артыннан тагылып йөриячәк һәм аның көефен тәмам бозып бетерәчәк иде.

Мәҗлес ничектер үз эзенә төшкәндәй булды; хәзер ул бернинди кыстаусыз, җанлы төстә бара башлады. Васючок, Женни Рейтерның пианинода уйнавына кушылып, артык көчәнмичә генә, итальян халык җырларыннан канцонетталар һәм Рубинштейнның Шәрекъ җырларын җырларга кереште. Аның тавышы көчле булмаса да, шактый ягымлы, матур тавыш иде; һәм көйләрне ул бер дә бозмыйча, дөрес итеп җырлый иде. Женни Рейтер — яхшы, таләпчән музыкант — Васючок җырлаганда һәрвакыт бик теләп пианино уйнарга утыра иде. Хәер, дөрес булса, кешеләр арасында, Васючок Женнигә гыйшык тотып йөри икән, дигән сүзләр дә ишетелгәли иде.

Почмактагы кушеткада Анна гусар офицеры белән бик мавыгып фәлсәфә сатып утыра иде. Вера шунда килде һәм, сабыр гына елмаеп, аларның сөйләшкән сүзләренә колак салды.

— Юк, юк, сез, зинһар, алай көлмәгез,— диде Анна, үзенең татарныкыча кысык, сөйкемле, шук күзләре белән офицерга елмаеп карап.— Сез, әлбәттә, җан-фәрманга эскадрон башында чабып баруны яисә ат чабышларында

киртәләр аша сикереп чыгуны зур бер хезмәт итеп саныйсыз. Ләкин сез безнең эшкә дә игътибар беләнрәк карагыз. Әле шушы көннәрдә генә без лотерея-аллегри эшен тәмамладык. Безгә бик җиңел булгандыр дип уйлыйсызмы? Җиңел булмыйни! Бүлмәдә шыгрым тулы халык, тәмәке төтене, ниндидер дворниклар, извозчиклар, тагын әллә кемнәр — исемнәрен дә белеп бетерерлек түгел... Һәммәсе дә нәрсәгәдер рәнҗи, һәммәсе дә ниндидер зар белән килә... Көне буе шулай аяк өстендә, утырырга да вакыт юк. Ә алда тагын ниндидер интеллигент булып җитмәгән хатын-кыз хезмәткәрләр файдасына концерт куясы бар, аннары бал-мәҗлес тә оештырырга кирәк...

— Ул бал-мәҗлесегездә мин дә сездән бер мазурка өмет итә алырмын дип уйлыйм? — диде Бахтинский, башын иеп, һәм кушетка астына сузылган үкчәләрен бер-берсенә бәреп куйды.

— Рәхмәт... Ләкин безнең өчен иң-иң мәшәкатьлесе — ятимнәр йорты. Бозык балалар приюты, аңлыйсыздыр, шәт...

— О, бик яхшы аңлыйм. Бик тә кызыклы йорт булырга тиешледер ул, ә?

— Шундый изге нәрсәдән көләргә ничек оялмыйсыз!.. Беләсезме, безнең бәхетсезлек нәрсәдә? Без үзебезнең приютка күнелләренә әшәкелек тулган, тумыштан бозык булган балаларны алабыз, ул бичараларны юатырга, иркәләп күнелләрен ачарга тырышабыз...

— Һем!..

— ...аларда эхлаклылык тәрбияләргә, аларның күнелләрендә өмет чаткысы уятырга телибез... Сез мине аңлыйсызмы?.. Шул, безгә һәр көн саен йөзәрләгән, меңәрләгән бала алып киләләр, әмма шулар арасында, ичмасам, бер генә бозык дигәне дә юк! Әгәр ата-аналарыннан балагыз бозык түгелме дип сорасаң, алар хәтта үпкәлиләр, рәнҗиләр. Менә бит эшләр ничегрәк! Хәзер приюты да ачык, бөтен кирәк дигәне дә бар, әмма үзендә кызлардан булсын, малайлардан булсын — бер генә бала да юк! Бозык бала табып китерүчегә хет акча вәгъдә ит — барыбер килүче юк.

— Анна Николаевна, аның өчен нигә акча әрәм итәргә? — дип куйды гусар, җитди һәм серле бер тавыш белән.— Менә тотыгыз да мине алыгыз, мин бушлай барам. Валлаһи дип әйтәм, сез миннән дә бозыграк баланы беркайда да таба алмассыз.

— Зинһар, көлмәгез! Сезнең белән бер дә чынлап сөй-

ләшеп булмый икән,— диде Анна һәм, кушетка аркасына ятарак төшеп, шаркылдап көлеп җибәрде.

Князь Василий Львович зур түгәрәк өстәл янында үзенең апасына һәм Аносов белән кайнагасына үзе ясаган көлкеле рәсемнәр альбомын күрсәтеп утыра иде. Аларның дүртәүләшеп рәхәтләнеп көлеп утырган тавышларына башкалар да игътибар итте, һәм карта уенында катнашмаган кайбер кунаклар әкренләп-әкренләп алар тирәсенә җыела башлады.

Василийның бу альбомындагы рәсемнәрне аның үзе сөйләгән сатирик хикәяләренә бер бизәк, иллюстрация дип карарга мөмкин булыр иде. Үзенә хас бер җитдилек белән, Василий анда, мәсәлән: «Каһарман генерал Аносовның Төркиядә, Болгариядә һәм башка илләрдә башыннан кичергән гыйшык мажараларын»; яисә «Петиметр князь Николай Булат-Тугановскийның Монте-Карлодагы кызыклы мажараларын» һәм башка шундый бик күп хәлләрне тасвирлап күрсәтә иде.

— Хәзер сез, әфәнделәр, безнең сөекле апабыз Людмила Львовна ханымның кыскача тәрҗемәи хәятын күрерсез,— диде ул, апасына таба хәйләле күз карашы ташлап.— Беренче кыйсем — балачак. «Сабый бала үсә. Аның исеме — Лима».

Альбом битенә балалар рәсемедәй юри көлкеле итеп бер кызчык профиле ясап куелган иде. Әмма профиль генә булса да, рәсемнең ике күзе бар, юбкасы астыннан аяклар урынына ике сынык сызык чыгып тора, ә тырпайган бармаклы куллары як-якка җәеп җибәрелгән иде.

— Мине беркем дә Лима дип атап йөртмәде,— диде Людмила Львовна, көлеп.

— Икенче кыйсем. Беренче мәхәббәт. Кавалерия юнкеры, Лима алдына тезләнеп, аңа үзе язган мәхәббәт шигырен тәкъдим итә. Бу шигырьдә энҗе бөртегедәй менә шушындый соклангыч юллар да бар:

Синең гүзәл аягың
Илаһи хис уята!

Менә монысы шул гүзәл аякның чын рәсемедер.

Ә менә монда юнкер гыйффәтле Лима туташны ата-анасы өеннән качып китәргә үгетли. Монда исә качып китү вакыты сурәтләнгән. Ә менә бусы — шул качып китүнең күңелсез нәтиҗәсе: җен ачуы чыккан ата кеше качакларны артларыннан куып җитә... Юнкер, куркакларча, бөтен гаепне инсафлы Лима туташ өстенә аудара.

Пудра сөртеп вакыт уздырдың —
Әткәннәрдән безне кудырдың...
Җавабын да үзең бирәсең —
Мине соңгы тапкыр күрәсең!

Лима турындагы сурәтләрне күрсәтеп бетергәч, Василий «Княгиня Вера белән гашыйк телеграфчы» дигән яңа темага күчте.

— Ошбу кызганыч хәлнең монда каләм вә төсле карандашлар белән ясалган рәсемнәре генә бирелгән,— диде ул, җитди бер кыяфәт белән.— Әлегә сүзләре әзер түгел, соңрак язылачак.

— Монысы нәрсәдер бөтенләй яңа тема булырга охшый,— дип куйды Аносов,— моңарчы бер дә ишеткәнем дә, күргәнем дә юк иде шикелле.

— Иң-иң соңгы чыгарылыш. Китап сәүдәсендәге иң соңгы яңалык,— диде Василий Львович.

Вера әкрен генә аның җилкәсенә орынып алды.

— Кирәкмәс иде, Вася, сөйләмә,— дип үтенде ул.

Ләкин Василий Львович аның сүзләрен әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә игътибар итмәде.

— Бу вакыйганың башы әле тарихка кадәр булган чорларга карый,— дип сөйләп китте ул.— Май аеның матур бер көнендә Вера дигән бер кызга почтадан хат китереп бирәләр. Үбешеп торган ике күгәрчен рәсеме төшерелгән гыйшык хаты була бу. Менә ул хат, менә күгәрченнәре дә.

Имля кагыйдәләре белән бөтенләй исәпләшмичә язылган бу хатта егет кеше үзенең кызга булган ялкынлы мәхәббәтен бәян итә. Хат менә болай дип башланган була: «Гүзәлләрнең гүзәле, аксыл чәчле Фәрештә, син... минем күңелемнең төпсез упкынында ялкын диңгезе дөрләтеп җибәрдең, синең күз карашың минем газапланып өзгәләнгән бәгыремә агулы елан булып кадалды» һәм башкалар, һәм башкалар. Иң ахырда хат болай тәмамлана: «Кәсебем буенча мин фәкыйрь бер телеграфчыдыр, әмма минем күңелемдә милорд Георгка тиң дәрт-хисләр кайный. Сезгә тулы исемемне әйтә алмыйм — артык оятсыз булыр дип куркам. Шуңа күрә имзамның баш хәрефләрен генә куям: П. П. Ж. Җавап хатын почтамтка, посте рестанте [1] белән язуыгызны үтенәм». Биредә сез, әфәнделәр, телеграфчының төсле карандашлар белән ясалган һәм, минемчә, шактый уңышлы чыккан портретын да күрә аласыз.

---

[1] Ягъни почтаның үзенә барып алына торган хат.

Вераның йөрәгенә мәхәббәт угы кадала (менә йөрәге, менә угы). Шулай да, яхшы тәрбияле һәм инсафлы кыз буларак, ул иң элек әлеге хатны әти-әнисенә һәм үзенең яшьлек дусты чибәр Вася Шеинга — ярәшелгән егетенә күрсәтергә карар итә. Менә шул хәлне тасвирлаган рәсемнәр. Соңыннан бу рәсемнәр астына шигъри аңлатмалар да язылачак, билгеле.

Вася Шеин, күз яшьләре түгеп, вәгъдә балдагын Верага кире кайтарып бирә. «Мин синең бәхетеңә комачау булырга теләмим,— ди ул,— тик, зинһар өчен, бу эшне алай бик капылт кына хәл итеп ташлама. Яхшылап уйла, төпле бер фикергә кил, үзеңне дә, аны да сынап кара,— ди.— Син әле сабый бала кебек, тормышны аңламыйсың; кызыл төсенә кызыгып, күбәләктәй, туп-туры ут ялкынына таба очасың,— ди.— Мин исә — аллага шөкер! — дөньяның салкын мәкерле, икейөзле икәнлеген бик яхшы беләм. Исеңдә тот: телеграфчылар кызыксыну уятырлык матур булалар, ләкин аларның күңелләре бозык һәм мәкерле була. Үзләренең горур матурлыкларына һәм ялган дәрт-хисләренә кызыккан тәҗрибәсез кызларны алдау һәм мыскыллау аларга берни тормый, моңардан алар чиксез бер ләззәт кенә табалар»,— ди.

Тагын ярты ел уза. Тормыш өермәсендә бөтерелә торгач, Вера, әкренләп, үзенең телеграфчысын бөтенләй оныта һәм, нинһаять, әлеге яшь чибәр Васяга кияүгә чыга. Ләкин телеграфчы үзе Вераны онытмый. Менә бервакытны ул, моржа чистартучы кеше киеменә киенеп һәм бит-кулларын корымга буяп, княгиня Вераның будуарына үтеп керә. Аның биш бармагыннан һәм ике иреннән йогып калган корымлы тапларны сез һәр җирдә — менә бу паласларда да, мендәр тышларында да, обойларда һәм хәтта паркет идәндә дә күрә аласыз.

Менә монысы аның гади авыл хатыны киемендә безгә савыт-саба юучы булып эшкә ялланган чагы. Ләкин пешекче Луканың кирәгеннән артык вәсвәсәлек күрсәтүе аны моннан качып китәргә мәҗбүр итә.

Менә монда ул тилеләр шифаханәсендә. Ә монысы монахлыкка күчкән чагы. Ләкин монахлыкка күчүенә дә карамастан, ул көн саен Верага дәртле гыйшык хатлары җибәреп тора. Күрәсезме, хатка күз яшьләре тамган урында язу карасы җәелеп-җәелеп киткән.

Нинһаять, ул үлем түшәгенә егыла, ләкин үләр алдыннан васыятьнамә язып, Вера исеменә ике телеграф төймәсе

һәм ислемай шешәсенә тутырып үзенең күз яшьләрен калдыра.

— Әфәнделәр, кайсыгыз чәй эчәргә тели? — дип сорады Вера Николаевна.

VII

Көзге кичнең шәфәкъ нурлары әкренләп сүрелә, тоныклана барды. Ниһаять, офык читендәге зур күгелҗем болытның җиргә тиеп торган җирендә нечкә бер ал тасма сыман сызылып киткән соңгы кызыллык та сүнде. Җир өсте, күк йөзе, әйләнә-тирәдәге агачлар — һәммәсе дә караңгыда эреп, күренмәс булдылар. Бары тик баш очында, тоташ караңгылык эченнән керфекләрен сирпеп елмайгандай, эре йолдызлар җемелдәде дә диңгез ярындагы маяктан туп-туры күк йөзенә таба зәңгәрсу нечкә нур баганасы сузылды; бу нур баганасы күк гөмбәзенә барып терәлә дә, чайпалып түгелгәндәй, сыекланып, аксыл томан сыман бер түгәрәк шәүлә хасил итә иде. Шәмнәрнең пыяла калпаклары әйләнәсендә, бәрелә-сугыла пырылдап, төнге күбәләкләр очып йөрде. Ә йорт алды бакчасыннан, караңгыда һәм салкынча һавада тагын да көчлерәк аңкып, ак тәмәке чәчәкләренең хуш исе таралды.

Спешников, вице-губернатор һәм полковник Понамарев, генералның яллаган ландосына утырып, инде күптән шәһәргә кайтып киткәннәр иде. Атларны алар шәһәр станциясеннән кире монда җибәрергә вәгъдә иттеләр. Калган кунаклар һәммәсе дә террасага чыгып утырдылар. Вера белән Анна, Аносовның киреләнүенә дә карамыйча, аның өстенә көчләп пальтосын кидерделәр һәм аякларын калын, җылы шәл белән урадылар. Генерал каршында, өстәлдә, аның иң яраткан кызыл шәрабе — Pommard төра, э ике ягында Вера белән Анна утыра иде. Алар, берсеннән-берсе уздырып, генералның күңелен күтәрергә, аны сыйларга тырыштылар: әледән-әле аның нечкә билле стаканына авыр куе шәраб салып тордылар, сыр турадылар, шырпысын, тегесен-монысын алып бирделәр. Карт генерал бу хозурлыкка тәмам изрәп, күзләрен ярты лаш йомып утырды.

— Әйе... Көз җитте, көз, көз җитте, — дип куйды ул, шәм ялкынына күзен төбәп һәм уйчан кыяфәттә башын чайкап. — Көз җитте. Шулай ук миңа да җыеныр вакыт җитте. Ах, бер дә китәсе килми дә килүен! Көннәре ничек матурланды бит! Монда, диңгез буенда, тыныч кына, хозурланып кына яшәп ятасы иде, югыйсә...

— Соң, калыгыз бездә, бабакай, — диде Вера.

— Юк, кызым, ярамый. Хезмәтем көтә... ял вакытым бетте... Ә монда калу болай шәп кенә булыр иде анысы, әйтәсе дә юк! Син карап кына бакчы, роза чәчкәләре нинди хуш ис бөрки... Шушыннан ук борын сизә. Ә җәйге челләдә чәчәк исе бөтенләй сизелми, бары сәрви агачлары гына бераз ис тарата... анда да ниндидер конфет исе.

Вера вазадан берсе алсу, икенчесе җете кызыл төстәге ике роза чәчкәсен суырып алды да генерал пальтосының петлицасына кадады.

— Рәхмәт, Верочка, — диде Аносов һәм башын иеп чәчкәләрне иснәде дә картларча мөлаем бер елмаю белән елмаеп куйды.

— Әле дә хәтеремдә, Бухарестта булган иде бу хәл. Без анда квартирларга урнашып торган идек. Беркөнне шулай урамнан барам. Кинәт минем борынга көчле бер хуш ис — роза чәчкәсе исе килеп бәрелде. Туктап як-ягыма карасам — ике солдат. Яннарында зур гына хрусталь шешә тора, ә шешәдә — роза мае. Шул май белән болар күн итекләрен, мылтыкларын да майлап өлгергәннәр. «Нәрсә сезнең бу шешәгездә?» — дип сорыйм солдатлардан. «Ниндидер май шунда, ваше высокоблагородие, — диләр болар. — Без инде аны боткага да салып карадык, тик рәте булмады, бик каты тамакны әчеттерә, ә үзе болай искиткеч хуш исле», — диләр. Мин солдатларга бер тәңкәлек көмеш акча суздым да, әлеге роза маен үземә алдым. Шешәдәге май яртылаш кимегән булса да, аның калганы да әле, бәһасенең бик кыйммәт йөрүен исәпкә алганда, кимендә бер ике йөз тәңкә торырлык иде. Солдатларга килгәндә инде, алар, аны-моны уйлап тормастан, мин биргән бер тәңкәгә бик разый булдылар. Аннары тагын әйтәләр болар: «Бездә әле, ваше высокоблагородие, төрек борчагы да бар, — диләр. — Без аны пешереп караган идек тә, никтер пешмәде, каһәр суккыры», — диләр. Аларның бу төрек борчагы дигәннәре кофе булып чыкты. Шуннан әйттем боларга: «Бу борчакны, мәйтәм, төрекләр генә ашый, солдатларга аны ашарга ярамый», — дим. Бәхетләренә каршы, ничек эфьюнга юлыкмаганнар әле, юкса, харап булган булырлар иде; миңа берничә урында пычракка тапталган эфьюн кабартмаларын да күргә туры килде.

— Бабакай, дөресен генә әйтегез әле, — дип куйды кинәт Анна, — сугышта йөргәндә курка идегезме?

— Курыктыңмы-курыкмадыңмы дип сорау үзе үк сәер, Аннечка. Курка идем, билгеле. Сугышта бернәрсәдән дә

курыкмадым, колак төбендә пулялар сызгыруын музыка сыман тыңладым дигән кешегә син, зинһар, ышана күрмә. Андый кеше йә шыр тиле, йә буш бугаз булыр. Сугышта һәммә кеше бер дәрәҗәдә курка. Тик берсе куркудан бөтенләй җебеп төшә, ә икенчесе аны эченә йота, белгертми. Димәк, курку һәрвакыт курку булып кала, ә аны эченә йота белү осталыгы тәҗрибә аркасында бирелә: әнә шуның инде батыр йөрәкле кешеләр, геройлар туа. Менә ничек бит ул, Аннечка. Шулай да мин бер мәртәбә куркудан чак-чак кына үлми калдым.

— Сөйләгез әле, бабакай, — дип, беравыздан элеп алдылар Вера белән Анна.

Алар Аносовның сөйләвен сабый чакта ничек яратып тыңласалар, хәзер дә шулай яратып, сокланып тыңлыйлар иде. Анна хәтта, нәкъ бала вакытындагыча, ике терсәге белән дә өстәлгә таянып, ияген аяк үкчәседәй бөгелгән йомшак учлары өстенә җайлап куйды. Аносовның ашыкмыйча гына, сабыр гына сөйләвендә һәрвакыт ниндидер эчкерсез беркатлылык, самимилек сизелеп тора иде. Сугыш вакыйгаларын тасвирлаган сүзләре, тәгъбирләре дә аның ничектер бик сәер, серле була, китапчарак килеп чыга иде. Әйтерсең лә ул борынгыдан калган ниндидер бер күңелле стереотип буенча сөйли иде.

— Сөйләр өчен бик кыска хикәя ул, — диде Аносов. — Кыш көне, Шипкада чакта, башыма контузия алганнан соң булды бу хәл. Без дүрт кеше бер землянкада тора идек. Менә шул землянкада булды да инде әлеге коточкыч фажига. Бервакытны иртән йокыдан торып аягыма бассам, зиһенем таралды да китте бит: имеш, мин Яков түгел, ә ниндидер Николай, имеш. Үземне-үзем Яков дип ышандыра алмыйча тәмам алҗып беттем. Шуннан, акылдан яза башлаганмын икән дип, су китерегез дип кычкырып җибәрдем. Су белән башымны чылаткач кына зиһенем рәтләнеп китте.

— Яков Михайлович, сез анда бик күп хатын-кызларның башын әйләндергәнсездер, ә? — дип куйды пианистка Женни Рейтер. — Яшь чакта сез бик чибәр булгансыздыр?

— О, безнең бабакай әле хәзер дә чибәр! — диде Анна, куанып.

— Беркайчан да чибәр булмадым анысы, дөресен әйтергә кирәк, — диде Аносов, тыныч бер елмаю белән. — Ләкин яшь чакта кызлар мине дә алай бик читкә какмадылар. Менә шул Бухарестта ук минем белән бик кызык бер хәл булды. Бухарестка кергәндә, шәһәр халкы безне

үзәк мәйданга куелган туплардан атып каршылады; шул туп аткан тавышлардан күп кенә йортларның тәрәзә пыялалары коелып төшкән; ләкин тәрәзә төпләренә стакан белән су куелган йортларда андый хәл булмаган. Моны мин каян белдем дисезме? Ә менә каян белдем. Үземә билгеләнгән квартирага килгәч, мин иң элек бүлмәмнең тәрәзәсе төбенә куелган тәбәнәк бер читлеккә игътибар иттем; читлек эчендә чиста су салынган зур гына хрусталь савыт тора, савытта алтын балыклар йөзеп йөри, ә аларның нәкъ уртасында, кечкенә генә куначада, кенәри утыра. Шаккатарлык хәл бит: су эчендә кенәри утырсын, имеш! Ләкин, җентекләбрәк карый торгач, мин әлеге хрусталь савытның төбе эчкә таба уелып кергән булуын шәйләп алдым; кенәри әнә шул уентыкка кереп утырган икән. Шунда гына мин үземнең алданганлыгымны аңладым.

Өйдә мине искиткеч чибәр бер болгар кызы каршы алды. Мин аңа вакытлыча монда фатирга тукталуым турындагы рәмси кәгазьне күрсәттем дә, сүз уңаеннан, тәрәзәләренең пыялалары ни өчен шулай ватылмый калуын сорадым, ә ул миңа моның сәбәбен әйтте: тәрәзә төбенә куелган су аркасында ватылмый калды, диде. Аннары ул миңа кенәри хакында да аңлатып бирде: менә бит мин нинди ахмак булганмын ул чакта!.. Шул, сөйләшә торгач, ничектер очраклы рәвештә генә безнең күзләребез очраште да, безнең арадан электр тогы сыман бер чаткы йөгереп узгандай булды. Шуңда инде мин үземнең бөтен җаным-тәнем белән аңа гашыйк булганлыгымны аңлап алдым.

Карт генерал, сүзеннән туктап, куе кызыл шәраб салынган стаканын иренена тидерде.

— Соңыннан сез аның белән аңлаштыгызмы соң? — дип сорады пианистка.

— Һем... аңлаштык, билгеле... Тик сүзсез генә аңлаштык. Болай булды бу...

— Бабакай, сез безне кызарырга мәҗбүр итмәссездер бит? — дип куйды Анна, шук бер елмаю белән.

— Юк, юк, безнең арада алай кызарырлык бернинди әдәпсезлек булмады. Гомумән, без фатирга туктаган шәһәрләрдә халыкның төрлесе очрый торган иде. Әмма Бухарестта безне шәһәр халкы бөтенләй үз итеп каршы алды. Бервакытны мин скрипкә уйный башлаган гына идем, әйләнә-тирәмә шундук бер өер киенгән-ясанган кызлар җыелды да рәхәтләнеп биергә дә тотынды. Шуннан соң бу бию кичәләре көн саен кабатланып тора башлады.

Бервакыт, ай яктысы төшкән бер кичне, кызлар биергә

җыелгач, мин әлеге болгар кызы артыннан өйалдына кердем. Мине күргәч бу юри генә кипкән роза чәчкәләрен әйләндерергә тотынды; ул яклардагы халык, әйтсәм әйтим, роза чәчкәләрен капчыклап-капчыклап киптерә... Мин кызны күкрәгемә кысып кочакладым да, берничә мәртәбә үбеп тә алдым...

Шул көннән башлап һәр кичне, күк йөзендә ай белән йолдызлар калыккач та, мин үземнең мәгъшукам янына ашыга торган булдым. Аның янына килгәч, мин үземнең барлык көндәлек мәшәкатьләремне оныта торган идем. Шәһәрдән китәр вакыт җиткәч, аерылышканда, без бербербезгә булган сөю хисен мәңге сакларга дип антлар итештек һәм шул рәвешчә гомерлеккә саубуллаштык.

— Шуның белән бетте дәме? — диде Людмила Львовна, кәефе кырылып.

— Сезгә тагын нәрсә кирәк иде соң? — диде комендант.

— Юк ла инде, Яков Михайлович, кыек әйтсәм гафу итегез, шулай да чын мәхәббәт түгел бу, ә ниндидер гаскәри офицерның бивуактагы гади бер гыйшык мажарасы гына.

— Белмим, сөеклем, белмим; мәхәббәт булгандырмы ул, әллә бүтән төрле бер хисме, — валлаһи, әйтә алмыйм...

— Шулай да... әйтегез әле... сезнең беркайчан да чын мәхәббәт белән яратканыгыз булмадымыни? Көчле мәхәббәт белән... Ничек дип әйтергә... кыскасы... изге, саф, мәңгелек мәхәббәт белән... илаһи мәхәббәт белән... яратканыгыз булмадымыни?

— Чынлап менә, ничек дип әйтергә дә белмим сезгә, — диде карт, каушый калып һәм креслодан торып. — Күрәсең, яратканым булмагандыр. Баштарак моның өчен бөтенләй вакыт табылмады: яшьлек, типтерүләр, карта уеннары, сугыш бөтенесен үз эченә йотып бетерде... Тормышның, яшьлекнең, сәламәтлекнең чиге-ахыры булмас кебек тоела иде ул чакта. Аннары әйләнеп карасам — инде барысы да артта калган, мин үзем өшәнгән бер картка әверелгәнмен... Ярар, Вера сөеклем, мине артык кыстама инде, хушлашыйк... Гусар, — диде ул аннары, Бахтинскийга эндәшеп, — төн бик җылы, әйдәгез экипажга каршы бара торыйк.

— Мин дә сезнең белән барам, бабай, — диде Вера.

— Мин дә, — диде Анна, апасының сүзен элеп алып.

Чыгып китәр алдыннан Вера ире янына килде дә аның колагына пышылдады:

— Анда... минем бүлмәдә, өстәл тартмасында, кызыл бер футляр ята, э футляр эчендә хат булыр. Шуны алып укы әле.

VIII

Анна белән Бахтинский алдан киттеләр; алар артыннан, бер унбиш-егерме адым ара калдырып, комендант белән Вера иярде. Баштарак, яктыдан чыккан күзләр төн караңгылыгына ияләшеп җиткәнче, юлны кармалап кына барырга туры килде. Аносов, карт кеше булуына да карамастан, бик үткер күзле иде әле, шунлыктан ул үзенең юлдашына юлны күрсәтә-күрсәтә барды. Вера комендантны терсәгеннән, пальто җиңеннән култыклап тоткан иде. Аносов, зур, салкын кулын сузып, ара-тирә аның кулын сыйпап-сыйпап куя иде.

— Иллә кызык та кеше инде бу Людмила Львовна, — дип кинәт сүзгә башлады ул, күңелендәге фикер агышын кычкырып дәвам иткәндәй. — Тормыш юлымда миңа күп мәртәбәләр очратыргә туры килгәләде: хатын-кыз илле яшьтән уздымы, — тол хатын яисә карт кыз булса бигрәк тә, — ул шундук тыелгысыз бер үҗәтлек белән чит кешеләрнең мәхәббәтләрендә казына башлый. Ул яисә шымчылык итә, усал, мәкерле гайбәтләр тарата, яисә чит кешенең бәхетен җайларга керешә, яисә ниндидер илаһи мәхәббәт турында сүз боткасы куерта. Минем әйтәсе килгәнем шул: хәзерге заманда кешеләр гомумән ярата белмиләр. Чын мәхәббәтне күрмим мин хәзер. Хәер, мин аны үз заманымда да күрмәдем!

— Ничек инде чын ярату булмасын, бабакай? — дип каршы төште Вера, картны терсәгеннән җиңелчә генә кысып. — Нигә шулай нахак сүз сөйләргә? Сез үзегез дә кайчандыр өйләнеп торгансыз ич. Шулай булгач, димәк, сез дә яраткан булгансыз. Дөрестер бит?

— Дөрес түгел шул менә, кадерлем Вера. Беләсеңме, мин ничек өйләндем. Күз алдыңа китер: янәшәмдә тупылдык кына яшь бер кызый утыра, диик. Тын алган саен моның кофтасы астыннан күкрәге күтәрелеп-күтәрелеп китә. Йә ул керфекләрен идәнгә теки дә комачтай кызарына. Йөзе нәфис, шома, муены фәрештәнекедәй ап-ак, куллары йомшак, җылы. Йә, яшь кешегә тагын ни кирәк! Ә якында гына кызның эти-әнисе бөтерелә; алар ишек артыннан гына синең кызлары белән сөйләшүеңне тыңлыйлар, очрашканда сиңа, тугры эттәй, моңсу бер өмет белән күзләрен

текиләр. Ә чыгып киткәндә инде син ишек артында ашык-пошык кына үбешеп аласың... Табында утырганда кыз аяклары белән ялгыш кына синең аякларына орынып куя... Шуннан инде эш көйләнде дигән сүз. «Кадерле Никита Антоныч, мин сездән кызыгызны сорарга килдем. Ышаныгыз, сезнең кызыгыз изге бер җан иясе...» Ә әти кешенең күзләре яшькә чыланган, ул синең янга инде үбәргә дип ыргыла... «Җанкисәгем! Мин инде күптән сизенгән идем... Болай булгач, аллаһы тәгалә сезгә... Тик кара аны, күз нурыбызның кадерен бел...» Һәм өч айдан әлеге изге җан, күз нуры дигәнең, өстенә иске капот, яланаякка туфли киеп йөри башлый; таралмаган юка, сирәк чәчләрендә папильоткалар тырпаеп тора; денщиклар белән сөйләшкәндә кухарка шикелле этләшә; яшь офицерлар алдында койрык болгый, кылана, сакауланып сөйләшә, чыелдый, күзләрен уйната. Үзенең иренә кешеләр барында ни өчендер Жак дип эндәшә; менә болай, борын белән, тыңкышлатып, назланып: «Жа-а-ак», — дип суза. Үзе дөньяда бер талымсыз, кыланчык, шапшак, комсыз. Алдакчы икәнлеге күзләреннән үк күренеп тора иде... Хәзер инде барысы да үтте, онытылды, көйләнде. Күңелемнән хәтта мин аны иярткә китүче мутка рәхмәт тә әйтәм... Аллага шөкер, ярый әле балаларыбыз булмады...

— Сез аларны гафу иттегезме соң, бабакай?

— Бу урында гафу сүзе бармый, Верочка. Баштарак мин нәкъ котырган эт кебек йөрдем. Әгәр шул чакта аларны бергә очраткан булсам, һичшиксез, икесен дә атып үтергән булыр идем. Аннары үч алу тойгысы өкренләп онытыла барды, барды да, ахырда күңелдә нәфрәт хисеннән башка берни дә калмады. Кыскасы, ахыры әйбәт булып бетте. Аллаһе тәгалә кирәксезгә адәм канын коюдан саклап калды. Шул җирәнгеч хәл булмаса, мин менә хәзер кем булган булыр идем? Гөнаһка күз йомып торучы ширма, савым сыеры, йорт җиһазы, ишәк булган булыр идем... Әйе! Ахыры яхшы булып бетте, Верочка.

— Гафу итегез мине, бабакай, шулай да сез хәзер дә шул әүвәлге нәфрәт хисе тәэсирендә сөйлисез кебек тоела миңа... Сез үзегезнең тормышта булган бәхетсез бер очракны бөтен кешелек дөньясына күчерәсез. Сез менә Вася белән мине генә алып карагыз. Безнең тормышны бәхетсез тормыш дип әйтеп буламыни?

Аносов шактый озак дәшмичә барды. Аннары теләр-теләмәс кенә сүзләрен сузып әйтеп куйды:

— Ярар... сезнең тормышны... бәхетле тормыш диик...

Ләкин күпчелек очракта кешеләр ни өчен өйләнешәләр соң? Алыйк хатын-кызны. Башта ул карт кыз булып калудан курка. Иптәш кызлары кияүгә чыгып беткән булса, аның өчен бу бигрәк тә хурлык булып тоела. Аннары гаиләдә артык кашык булып яшәү дә кыен. Кыз кеше һәрвакыт үзе йорт хуҗасы булырга, мөстәкыйль ханым, хозяйка булырга омтыла... Аңарда шулай ук ана булу теләге, әйтергә мөмкин — табигый теләк тә бик көчле; аның үз оясын булдырасы, балалар үстерәсе килә. Ә ирләрне өйләнергә икенче төрле сәбәпләр мәҗбүр итә. Ир кеше, беренчедән, үзенең буйдак тормышыннан туя; өендәге тәртипсезлек, шакшылык, теләсә кайда аунап яткан тәмәке төпчекләре, кайсы кая ташланган ертык киемнәр, бирәсе бурычлар, оят белми торган дус-ишләр, гомер буе трактирларда ашап йөрүләр һәм башка бик күп, бик күп тормыш вакътәякләре аны тәмам алҗытып бетергән була. Икенчедән, аңа гаилә тормышы белән яшәү җиңелрәк булыр, экономлырак булыр, сәламәтлек өчен дә яхшырак булыр кебек тоела. Өченчедән, варис калдыру теләге дә бар; үзең үлеп китсәң дә, нәселең, каның яшәп кала, янәсе... Үзенә күрә үлемсезлек иллюзиясе сымаграк бернәрсә инде бу. Дүртенчедән, һәрбер ир кеше, минем шикелле үк, нинди дә булса берәр гыйффәтлелек вәсвәсәсенә тап була. Аның соңында, күңелгә бирнә турындагы уйлар да килеп киткәли. Ә мәхәббәт үзе кайда соң? Бернинди бүләкләр сорамый торган, хирыссыз, саф, фидакарь мәхәббәт кайда соң? Әлеге, «үлем кебек көчле» дип әйтелә торган мәхәббәт кайда? Аңлыйсыңмы, Вера, мин бөтенләй икенче төрле мәхәббәт — олы мәхәббәт турында әйтәм. Андый мәхәббәткә ия булган кеше дөньяда теләсә нинди батырлыкка бара ала, шул мәхәббәт хакына үзен корбан итә ала, газап кабул итә ала; һәм боларның барысына да әзер тору — аның өчен авыр хезмәт түгел, бәлки шатлык, чын бәхет. Тукта, сабыр ит, Вера, син тагын үзеңнең Васяң турында әйтмәкче буласың бугай? Чынлап, мин аны бик яратам. Әйбәт кеше ул. Белмәссең, киләчәктә, бәлки, аның мәхәббәте дә шулай гүзәл бер яктылыкта ачылып китәр. Ләкин син минем нинди мәхәббәт турында сүз алып барганымны аңларга тырыш. Мәхәббәт ул фаҗига булырга тиеш. Дөньяның иң бөек сере булырга тиеш! Тормыштагы бернинди уңайлыклар, исәп-хисаплар, компромисслар аңа кагылырга тиеш түгел.

— Бабакай, шундый мәхәббәтне сезнең үзегезнең кай-

чан да булса күргәнегез булдымы соң? — дип сорап куйды Вера әкрен генә.

— Юк, — диде карт, кискен итеп. — Дөрес, шуңа охшашлы ике очракны белəм белүен. Ләкин ул ике очракның берсе ахмаклык нәтиҗәсе булса, икенчесе... тоташ кислоталы дип әйтимме... ниндидер кызганыч мәхәббәт иде... Теләсəң, сөйлим. Тарихлары кыска аларның.

— Зинһар, сөйләгез, бабакай.

— Алайса, болай булды. Безнең дивизиянең бер полкында (тик безнекендә түгел) бер ханым — полк командирының хатыны бар иде. Кыяфәте, мин сиңа әйтим, Верочка, күз күтәреп карарлык та түгел иде үзенең. Шыр сөяк, озын, җирән, ябык, зур авызлы... Мәскәүнең берәр иске йорты кебек, үзеннән гел штукатурка коелып тора иде. Әмма шул ук вакытта гаҗәеп тә темпераментлы, боеручан табигатьле, усал бер хатын иде ул; кешеләргә җирәнеп карый, ифрат бозык, әйтергә мөмкин, полкның үз Мессалинасы сымаграк кеше. Җитмәсә тагын — морфинистка.

Бервакытны, көз көне, алар полкына авызында сөте дә кибеп җитмәгән, хәрби училищены әле яңа тәмамлаган яшь бер прапорщик килеп төште. Бер ай вакыт үтми, әлеге карт бия прапорщикны үзенә каратып та өлгерде. Бичара егет хатынның пажы да, хезмәтчесе дә, колы да, танцы вакытындагы даими кавалеры да. Ул аның артыннан тагылып, җилпәзәсен, яулыгын күтәреп йөри, экипажын чакырырга кирәк булса, өстенә мундир гына кигән килеш салкын урамга чыгып йөгерә. Чиста, саф күңелле бер яшүсмернең шулай үз мәхәббәтен — беренче мәхәббәтен — күпне күргән, тәҗрибәле, бозык һәм мәкерле бер хатынның аягы астына салып таптатуы үзе генә дә коточкыч бер хәл бит. Әгәр бу хатыннан исән-имин котылса да — киләчәктә ул барыбер харап булачак кеше. Бу — аның тормыш юлындагы явыз бер мөһер кебек.

Шул, рождество бәйрәме җитәрәк, хатын инде егеттән туеп та өлгерә. Ул яңадан үзенең әүвәлге, сыналган мәгъшукларының берсе белән бәйләнешкә керә. Прапорщик исә газап утында яна, хатынны оныта алмый; өрәк шикелле, аның артыннан тагылып йөри. Тәмам сулып бетте мескен: йөзе саргайды, кара күмергә әйләнде. Югары штиль белән әйткәндә — «аның йөзенә инде әҗәл сөреме кунган иде». Көнләшүе ифрат көчле иде аның. Мәгъшукасының тәрәзәсе каршында ул төннәр буе басып чыга икән дип тә сөйлиләр иде.

Менә бервакыт, яз көне, боларның полкында ниндидер

күмәк мәҗлес — пикникмы, маевкамы оештыралар. Прапорщикны да, хатынны да күреп белгән кеше булсам да, әлеге бәйрәм вакытындагы хәлне мин үзем күрмәдем. Гадәттәгечә, алар анда бик каты сыйланганнар, исерешеп беткәннәр. Төн җиткәч кенә, җәяүләп, тимер юлы кырыйлатып өйгә кайтырга чыкканнар. Кинәт каршыдан товар поезды килгәне күренгән. Шактый текә үр булганлыктан, поезд бик әкрен килә икән. Үзе әледән-әле сызгыртып-сызгыртып куя, ди. Шуннан шул, паровоз уты компания турысына килеп җитүгә, әлеге хатын прапорщикның колагына пышылдап әйтә икән: «Сез менә гел әйтәсез, мине яратам, дисез. Ә бит үзегез, мин кушсам, шәт, поезд астына кермәс идегез», — ди икән. Ә егет, аңа бер сүз белән дә җавап биреп тормастан, йөгереп киткән дә — туп-туры поезд астына ташланган. Әйтүләре буенча, ул бик төгәл чамалаган булган, вагонның алгы тәгәрмәче белән арткы тәгәрмәче арасына ташланырга уйлаган: алай иткәндә тәгәрмәч аны нәкъ урталай кисеп чыккан булыр иде. Ләкин ниндидер бер ахмагы егетне тоткарлап калырга теләгән, аны сөйрәп чыгармакчы булган. Тик көче җитмәгән. Прапорщик, рельска чытырдатып ябышкан килеш, ике кулын да тәгәрмәчкә кистергән. Шулай гарип калды егет.

— Ох, нинди коточкыч! — диде Вера, калтыраган тавыш белән.

— Күп тә үтми прапорщикка хәрби хезмәттән бөтенләй китәргә туры килде. Иптәшләре аны юлына акча җыеп озатып җибәрделәр. Шәһәрдә калу аның өчен уңайсыз иде: бердән, үзенә читен, икенчедән, полк исеменә дә зур тап. Менә шулай... кабахәтлек аркасында... харап булды кеше... теләнчегә әверелде... Соңыннан кайдадыр Петербург пристаненда катып үлгән диделәр.

Ә мәхәббәтләрнең икенчесе бөтенләй җан әрнеткеч булды. Беренче очрактагы кебек үк, монысында да мәгъшука дигәне гаять азгын, үзсүзле бер хатын иде. Аерма тик шунда гына: монысы яшь һәм бик чибәр иде. Үзен ифрат та начар, әдәпсез тота иде ул. Хәтта без дә, гаилә романнарына бармак аша гына караган гаскәри офицерлар да, аның кайбер кыланышларын күреп исебез китә иде. Ә ире — ник кенә бер кыл кыймылдатсын! Һәммәсен белеп, күреп тора, әмма хатынына бер сүз дә әйтми иде. Дуслары кинаяләп әйтә башласалар, ул: «Зинһар, калдырыгыз... Минем эш түгел ул, минем эш түгел... Леночка бәхетле булса — миңа шул җиткән!..» — дип, кулын гына селти торган иде. Шундый да бер ахмак инде!..

Ахырда Леночка иренең ротасындагы субалтернга [1] — поручик Вишняковка ияләшеп китте. Алар шулай өчәүләп — ике ир, бер хатын — гаугасыз гына тора башладылар. Никахлы гаиләнең иң законлы бер төре дип уйларсың. Шулай тыныч кына ящәп яткәнда, кинәт безнең полкны сугышка җибәрделәр. Хатыннарыбыз, билгеле инде, поездга кадәр безне озата бардылар. Озатучылар арасында әлеге Леночка да бар иде. Ләкин аңа бу вакытта әйләнеп карарга да чирканыч иде, валлаһи менә. Ичмасам, әдәп өчен генә булса да иренә таба бер борылып караса иде — юк, кая ул карау: корыган тирәк кәүсәсенә сырышкан шайтан сыман, поручигының муенына асылынган да, яныннан ник кенә бер адым читкә китсен! Җитмәсә әле, хушлашкан вакытта, — без барыбыз да вагоннарга төялеп, поезд кузгалып киткәч, — арттан иренә кычкырып, янап калды, оятсыз: «Кара аны, Володяны саклап йөр! — янәсе. — Аңа бер-бер хәл булса, йортыңны ташлап китәм, беркайчан да кире әйләнеп кайтмыйм, балаларны да үзем белән алып китәм!» — имеш.

Син, Вера, бәлкем, аның ире, әлеге капитан, нинди дә булса җебегән кеше, чикерткә җанлы, чүбек башлы кеше булгандыр дип уйлыйсыңдыр? Һич юк. Батыр йөрәкле, кыю солдат иде ул. Зеленые Горы дигән шәһәр янында ул үзенең ротасын алты мәртәбә төрек редутына каршы һөҗүмгә алып барды; шул чакта аның ике йөз солдатыннан ундүрте генә исән калды. Үзе ул, ике тапкыр яраланып, ике тапкырында да яра бәйләтү пунктына барудан баш тартты. Менә нинди кеше иде ул. Аңа исәнлек теләп, солдатлары хәтта гыйбадәт кыла торганнар иде.

Ләкин шул ук вакытта ул, бернинди карусыз, *аның*... Леночкасының боерыгын үти иде!

Куян йөрәкле, ялкау Вишняковны — шул әрәмтамак соры кортны — ул бала караучы кебек, әни кеше кебек тәрбияләп, карап торды, аны хәвеф-хәтәрдән саклады. Яңгырлы пычрак төннәрдә аны үзенең шинеленә төреп йоклатты; аның урынына саперлык эшләрен эшләргә йөрде, ә тегесе бу вакытта землянкада рәхәтләнеп йоклап ятты яисә штосс уйнап утырды. Төннәрен еш кына Вишняков өчен караул постларын тикшерергә дә йөрде ул. Ә син, Веруня, шуны да истә тот: ул вакытларда төрек башыбозыкларының иң котырган чагы иде. Алар кайчакны безнең сакчылык пикетларын, авыл хатыннары яшелчә бакчасында

---

[1] Патша армиясендә кече офицер.

кәбестә күчәнен кискән кебек кенә итеп, соңгы кешесенә кадәр турап-кисеп китә торганнар иде. Хәтергә алып әйтүе дә гөнаһтыр, шулай да әйтим: Вишняковның госпитальдә тифтан үлүен ишеткәч, без, чын менә, ихлас күңелдән шатландык...

— Ярар, болары ирләр мәхәббәте, ә менә хатын-кызларны... өзелеп яратучы хатын-кызларны очратканыгыз бармы сезнең, бабакай?

— О, әлбәттә, бар, Верочка. Мин хәтта болай дип әйтер идем: хатын-кызның һәркайсысы диярлек мәхәббәт мәсьәләсендә иң зур фидакарьлеккә, батырлыкка сәләтле. Син шуны истән чыгарма: хатын-кыз бер үптеме, кочакладымы, бирелдеме — ул инде ана кеше. Әгәр ул чынлап яратса, аның мәхәббәте тереклекнең бөтен мәгънәсен — бөтен галәмне үз эченә сыйдыра! Кешеләр арасындагы мәхәббәтнең хәзерге заманда шулай әдәпсез формалар алуында, ниндидер тормыш уңайлыкларына буйсындырылуында һәм аның вак бер күңел ачу чарасына әверелүендә хатын-кызның бернинди гаебе юк. Мәхәббәтнең вакланuына тулысынча ирләр үзләре гаепле. Егерме яшьтә үк тормыштан күңеле кайткан, көчле дәрт-хисләргә, каһарманлыкларга сәләтсез булган, сөю-сөелүнең төмен дә, кадерен дә белмәгән чеби җанлы, куян йөрәкле ирләр гаепле моңа. Әүвәлге заманда мәхәббәттә әнә шундый көчле дәрт-хисләр дә, каһарманлыклар да булган, диләр. Булгандырмы, юктырмы — анысы билгесез, әмма кешелекнең иң бөек акыл һәм хис ияләре — шагыйрьләр, әдипләр, музыкантлар, рәссамнар — әнә шул турыда хыялланмаганнармыни, шуларны юксынып моңланмаганнармыни? Әле менә шушы көннәрдә генә мин Машинька Леско белән кавалер де Грие турындагы мәхәббәт тарихын укып чыктым... Ышанасыңмы, шуны укыганда минем җылый-җылый күзләрем шешенеп бетте... Ярый, менә син әйт, алайса, Вера, вөжданың кушканча әйт: һәрбер хатын-кыз үзенең күңеле түрендә әнә шундый олы мәхәббәт турында — барысын да кичерә торган, барысына да әзер булган тыйнак, фидакарь мәхәббәт турында хыял йөртмимени?

— О, әлбәттә, әлбәттә, бабакай...

— Ә андый олы мәхәббәт булмагач, хатын-кыз үч алырга керешә. Тагын бер егерме-утыз ел узсын әле... мин инде ул заманны күрмәм, ләкин син, бәлки, күрерсең, Верочка. Мин әйткән сүзләрне колагыңа салып куй: егерме-утыз елдан соң хатын-кызлар дөньяда моңарчы күрелмәгән хакимияткә ирешәчәкләр. Алар, һинд потларыдай, өсләренә

әллә нинди сәер киемнәр киеп йөрерләр; безгә, ирләргә, колларга караган кебек, җирәнеп карарлар, безне санга да сукмый башларлар. Аларның дуамал капризлары, нәфесләре безнең өчен газаплы бер закон төсен алыр. Нигә соң бу шулай булыр? Чөнки без күп буыннар дәвамында мәхәббәтнең кадерен белми яшәдек, аның алдында баш иргә теләмәдек. Менә шуның үче булыр бу. Табигатьтәге бер законны беләсеңдер бит: хәрәкәт көче каршылык көченә тигез.

Карт бераз сүздән туктап торды да аннары кинәт Верага эндәште:

— Вера, әгәр сиңа бик кыен булмаса, миңа бер нәрсәне төшендереп бир әле: бая князь Василий ниндидер телеграфчы турында сөйләп утырды. Ул сөйләгәннәрнең нәрсәсе дөрес тә, нәрсәсе ялган — менә шуны әйтә алмассыңмы?

— Аның нинди кызыгын таптыгыз, бабакай?

— Күңелеңә ятмаган нәрсә булса, сөйләмә, Верочка, мин сине ирексезләмим.

— Ник алай булсын. Тыңлыйсыгыз килгәч, мин сезгә рәхәтләнеп сөйләп бирәм.

Һәм Вера карт комендантка үзенең кияүгә чыкканчыга хәтле ике ел элек үк инде ниндидер бер гашыйк егет тарафыннан эзәрлекләнә башлавын бөтен вагы-төягенәчә тәфсилләп сөйләп бирде.

Вераның аны беркайчан да күргәне юк икән; ул хәтта аның фамилиясен дә белми. Ул бары аңардан бик еш хатлар гына алып торган. Хатларында исә егет Г. С. Ж. дип имзасын куюдан башка үзе турында бүтән берни дә язмаган. Дөрес, ничектер бер тапкыр ул үзенең ниндидер казна йортында гади бер чиновник булып эшләвен телгә алып киткән китүен, ләкин телеграф турында анда бернинди сүз дә булмаган. Ул аны, Вераны, даими рәвештә күзәтеп тора булса кирәк, чөнки хатларында ул аның кайчан кайда булуын, нинди кешеләр белән очрашуын, анда нинди кием киеп баруын — һәммәсен дә шактый төгәл тасвирлап бирә торган булган. Аның язган хатлары, гомумән әдәпле генә күренсәләр дә, беркадәр вульгар эчтәлекле һәм артык дәрәҗәдә мәхәббәт ялкыны белән сугарылган булганнар. Шуңа күрә ул, Вера, бервакытны аңа үзе хат язып җибәргән (сүз уңаеннан гына әйтим әле, бабакай, зинһар, бу турыда безнекеләргә ишеттерә күрмәгез — алар бернәрсә дә белмиләр) һәм хатында аның, егетнең, башка гыйшык хатлары язып азапланмавын үтенгән. Шуннан соң егет чыннан да гыйшык хатлары язудан туктап калган;

бары тик бәйрәм көннәрендә генә — пасхада, яңа елда һәм Вераның үзенең туган көнендә генә котлау хатлары җибәреп тора икән.

Княгиня Вера шулай ук бүген килгән бүләк турында да әйтте һәм хәтта ул серле гашыйк язган соңгы хатның эчтәлеген дә, сүзгә-сүз дигәндәй, сөйләп-кабатлап чыкты...

— Әй-е, — дип сузды генерал, шактый вакыт дәшми барганнан соң. — Бу кеше яки акылыннан яза башлаган бер дивана, яисә — кем белсен! — бәлки, синең тормыш юлыңны, Верочка, олы бер мәхәббәт — әлеге хатын-кызлар хыяллана торган олы мәхәббәт кисеп чыккан булгандыр. Туктале. Алда фонарь утлары күренә түгелме? Мөгаен, минем экипаж кайтып киләдер.

Шул ук вакытта алар артында да дөбер-шатыр якынлашып килгән автомобиль тавышы ишетелде, һәм бераздан тәгәрмәч эзләре белән ергаланган юл өстен ацетилен ялкынындай ак нур көлтәсе яктыртып җибәрде. Бу — Густав Иванович Фриессе иде.

— Анночка, мин синең әйберләреңне үзем белән алдым. Әйдә утыр, — диде ул; аннары: — Ваше превосходительство, сезне илтеп куймаскамы соң? — дип өстәде.

— Юк инде, рәхмәт, җанкисәгем, — диде генерал. — Яратмыйм машина дигән нәрсәне. Бер рәхәте дә юк — дердер селкетә дә сасы исен генә тарата. Ярый, Верочка, хуш, сау бул. Хәзер инде ешрак килеп йөрермн, — дип, ул Вераның маңгаеннан һәм кулыннан үбеп алды.

Һәммәсе дә, саубуллашып, үз юллары белән китеп бардылар. Фриессе Вера Николаевнаны дача капкасына кадәр китереп җиткерде дә, киң түгәрәк ясап автомобилен тиз генә кайтыр юлга боргач, шаулап-гөрләп караңгылык эченә кереп югалды.

XI

Княгиня Вера, ниндидер күңелсез уйларга йотылып, баскычтан террасага менде дә туп-туры кунак бүлмәсенә юнәлде. Абыйсы Николайның нәрсә турындадыр бик кычкырып сөйләгән тавышын ул ерактан ук ишетеп алды һәм өйгә керүгә үк аның бер почмактан икенче почмакка тиз-тиз йөренгән озын чандыр гәүдәсен күрде. Василий Львович исә, кыска итеп алдырган аксыл чәчле зур башын түбән салындырып, ломбер өстәле янында акбур кисәге белән яшел сукнога ниндидер сызыклар сызгалап утыра иде.

— Мин инде сезгә күптән әйттем! — ди иде Николай, күзгә күренмәгән ниндидер әйберне идәнгә атып бәргән-

дәй, уң кулын ачу белән һавада болгап. — Күптән әйттем, бу ахмак хатларны туктатырга кирәк, дидем. Әле Вера сиңа кияүгә чыкмаганда ук әйттем: бу хатлардан кызык табып, сез бик ялгышасыз, дидем, алай балаларча кыланырга ярамый, дидем... Менә Вера үзе дә кайтып җитте... Карале, Верочка, без монда Василий Львович белән теге дивана хакында — синең Пе Пе Жең хакында сөйләшеп торабыз. Мин бу хат алышуларны әдәпсез, дорфа бернәрсә дип саныйм.

— Беркемнең дә хат алышканы юк, — диде Шеин салкын гына, Николайны сүзеннән бүлеп. — Хатны бары ул гына яза...

Иренең бу сүзләреннән Вера комачтай кызарынып китте һәм зур пальма гөле күләгәсенә — диванга барып утырды.

— Сүзләрем өчен гафу үтенәм, — диде Николай һәм тагын, баягыча, күкрәге өстеннән ниндидер күзгә күренми торган авыр әйберне идәнгә өзеп ташлагандай, кулы белән кискен бер хәрәкәт ясады.

— Ә мин синең аны минеке дип атавыңны аңламыйм, — дип куйды Вера да, иренең үзен яклавына шатланып. — Ул минеке ни, синеке ни — барыбер...

— Ярый, тагын бер мәртәбә гафу үтенәм. Кыскасы, минем әйтәсе килгәнем шул: аның бу ахмаклыкларына чик куярга кирәк. Монда эшләр, минемчә, көлү-шаярулардан, мәзәк рәсемнәр ясап юанулардан узган инде... Ышаныгыз сүземә: әгәр мин монда нәрсә турындадыр борчылам яисә кайгыртам икән — бу бары сезнең өчен, Вера белән синең, Василий Львович, керсез исемегезне саклап калу өчен эшләнә.

— Монысын инде син, Коля, бераз арттырып җибәрдең бугай, — диде Шеин, каршы килеп.

— Ихтимал, бик ихтимал... Ләкин сезнең ансат кына берәр көлкеле хәлгә төшүегез дә бик мөмкин.

— Ничек алай булыр икән ул — сәбәбен күрмим, — дип куйды князь.

— Күз алдына китер әле: әйтик, шушы килбәтсез беләзек, — Николай өстәл өстендә яткан кызыл тартмачыкны кулына алды да, җирәнеп, кире үз урынына ташлады... — әйтик, поп хатыннары гына кия торган шушы коточкыч әйбер бездә калды, ди, яки без аны чыгарып чүплеккә ташладык яисә Дашага бүләк итеп бирдек, ди. Ул чагында, беренчедән, Пе Пе Жегә үзенең дуслары яки хезмәттәшләре алдында авыз күтәреп: княгиня Вера Николаевна

Шеина миннән бүләкләр кабул итә, дип мактанырга юл ачылачак; икенчедән, җае чыгу белән ул янәдән үзенең каһарманлыкларын дәвам итәргә керешәчәк. Иртәгә ул, әйтик, брильянт кашлы йөзек җибәрә, иртәгәдән соңга — энҗе муенса, ә аннары — карыйсың — ул инде, алдашулары һәм казна акчасын туздыруы өчен, хөкем эскәмиясенә дә утырган; ә князь Шеиннар анда шаһит итеп чакырылган... Күңелле хәл, әйтәсе дә түгел!

— Юк, юк, беләзекне һичшиксез кире кайтарып бирергә кирәк! — диде Василий Львович, тәэсирләнеп.

— Мин дә шулай уйлыйм, — диде Вера, килешеп. — Һәм моны мөмкин кадәр тизрәк эшләргә кирәк. Ләкин ничек? Без бит аның исемен дә, фамилиясен дә, адресын да белмибез.

— О, анысы берни түгел аның! — диде Николай Николаевич, кимсетүле бер тавыш белән. — Без ул Пе Пе Женең инициалларын беләбез ич... Ничек әле алар, Вера?

— Ге Эс Же.

— Бик шәп! Аның соңында, безгә аның кайдадыр хезмәт иткәнлеге дә билгеле. Шулар бик җиткән. Иртәгә үк шәһәр исемлеген алам да аннан Г. С. Ж. инициалларына туры килгән чиновникны яки хезмәткәрне эзлим. Әгәр алай-болай таба алмасам, полиция агентын чакырттырып, аңардан эзләттерәм. Иң соңгы чиктә, минем кулда аның үз кулы белән язган менә бу кәгазе бар. Кыскасы, иртәгә көндезге сәгать икегә хәтле ул тәти егетнең төгәл исеменфамилиясен дә, адресын да, хәтта аның кай вакытларда өйдә була икәнлеген дә белеп куярмын. Боларны белгәч, димәк, без иртәгә үк аңа үзенең хәзинәсен кайтарып бирербез, алай гына да түгел, аңа карата тиешле чара да күрербез — дөньяда барлыгы да сизелмәсен бүтән!

— Син аны нишләтмәкче буласың? — дип сорап куйды князь Василий.

— Нишләтмәкчеме? Губернатор янына барам да аңардан...

— О, зинһар, губернаторны бу эшкә катыштырма. Безнең мөнәсәбәтләрне беләсең ич... Көлкегә калуыңны көт тә тор.

— Алайса, жандарм полковнигы янына барырмын. Клубтагы дус кешем ул минем. Әйдә шул Ромеоны үз янына чакыртып, борыны төбендә бармак янап бер җикерсен әле! Беләсеңме, ничек эшли ул моны? Бармагын кешенең борын төбенә үк менә болай китереп куя да, кулын һич тә селкетмичә, бары шул сыңар бармагын гына әйлән-

дергәләп, тегенә: «Мин, сударь, андый эшкә юл куймам!» — дип кычкыра башлый.

— Фу! Жандармнар катышы белән! — дип куйды Вера, йөзен чытып.

— Дөрес әйтәсең, Вера, — дип элеп алды князь. — Бу эшкә чит кешеләрне катыштырмау яхшырак булыр иде. Юкса, төрле имеш-мимеш, гайбәтләр таралачак... Шәһәребезнең халкын һәммәбез дә яхшы беләбез. Бөтенесе дә пыяла банка эчендә яшәгәндәй яшиләр... Иң яхшысы, аның янына... әлеге егет янына дим... мин үзем барып киләм... Хәер, егет дигәннән, ул, бәлкем, бөтенләй егет кеше дә түгелдер, алтмышка җиткән берәр карттыр?.. Шул, барам да беләзеген кулына тоттырам, аннары тагын үзенә бик һәйбәтләп үгет-нәсихәт тә укыйм...

— Алайса, мин дә синең белән барам, — диде Николай Николаевич, ашыгып, аның сүзен бүлеп. — Син артык йомшак күңелле. Аның белән сөйләшүне миңа тапшыр... Ә хәзер, дусларым, — дип, ул кесәсеннән сәгать чыгарды да вакытны карап алды, — мине гафу итегез, миңа үз бүлмәмә керергә кирәк. Аяк өстендә чак кына басып торсам да, мин әле ике эшне карап чыгарга тиеш.

— Нигәдер миңа ул бичара бик кызганыч булып китте әле, — диде Вера, икеләнеп кенә.

— Нәрсә аны кызганып торырга! — диде Николай, ишек төбеннән борылып карап. — Әгәр дә әлеге беләзек һәм хатлар белән булган шундый дорфалыкны безнең дәирәдәге берәр кеше эшләгән булса, Василий аны шундук дуэльгә чакырган булыр иде. Әгәр ул чакырмаса — мин чакырган булыр идем. Ә элеккерәк заман булса, мин аны бернинди мәшәкатьсез-нисез ат абзарына чыгарттырыр идем дә чыбык белән аркасын каезлаттырыр идем. Шулай, Василий Львович, иртәгә син мине үзеңнең канцелярияндә көтеп тор, мин сиңа барысы турында да телефоннан шылтыратып хәбәр итәрмен.

X

Басмаларына пычрак катып беткән баскычта әллә нинди сасы ис — мәче, тычкан, керосин һәм кер исе аңкып тора иде. Алтынчы катка менеп җитәрәк, Василий Львович туктап калды.

— Сабыр итче бераз, — диде ул каенагасына. — Хәл җыйыйм әле... Ах, Коля, кирәкмәс эшкә тотындык без...

Алар баскычның тагын ике буен менделәр. Баскыч ба-

шындагы мәйданчыкта бик караңгы булып, квартирларның номерлары күренмәгәнлектән, Николай Николаевичка ике тапкыр шырпы сызарга туры килде.

Кыңгырау тавышына ишектә чал чәчле, соры күзле, борынына күзлек кигән һәм ниндидер авырудан, күрәсең, алга таба бөкрәеп калган тулы гәүдәле бер хатын күренде.

— Желтков әфәнде өйдәме? — дип сорады Николай Николаевич.

Хатын башта ят ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә шикле күз карашын йөртеп чыкты. Ләкин аларның өсбашлары пөхтә булуы аны тынычландырды булса кирәк.

— Өйдә, рәхим итегез, — диде ул, ишекне иңеләй ачып. — Сул якта беренче ишек.

Булат-Тугановский кыска, кискен итеп өч тапкыр ишек шакыды. Бүлмәдә кемдер шыштырдап куйды. Николай Николаевич тагын бер тапкыр шакыды.

Ниһаять, бүлмә эченнән:

— Керегез, — дигән зәгыйфь бер тавыш ишетелде.

Тәбәнәк, әмма бик киң һәм бик озын булган бер бүлмә иде бу. Пароход иллюминаторларыдай түгәрәк ике тәрәзә аша бүлмә эченә тонык кына яктылык җәелгән иде. Гомумән, бүлмә үзенең бөтен эчке күренеше белән йөк пароходларындагы кают-компанияне хәтерләтә иде. Бер як стена буенда тар гына карават тора, икенче якта — искереп беткән затлы текин келәме белән капланган гаять зур киң диван, ә идән уртасына чуар малорус ашъяулыгы җәелгән өстәл куелган иде.

Кергән шәпкә хуҗаның йөзе күренмәде; ул, кечкенә тәрәзәләрдән төшкән тонык яктыга аркасын куеп, аптыраган кыяфәттә кулларын угалап тора иде. Ул озын буйлы, чандыр һәм кабарып торган озын чәчле иде.

— Ялгышмасам, сез Желтков әфәнде бугай? — диде Николай Николаевич эре генә.

— Әйе, Желтков. Бик шатмын. Танышырга рөхсәт итегез.

Ул, кулын сузып, берме-икеме адым алга — Тугановскийга таба атлады. Ләкин Николай Николаевич, аның күрешергә дип сузылган кулын күрмәгәндәй, бөтен гәүдәсе белән кисәк кенә Шеинга таба борылып басты.

— Әйттем ич мин сиңа, без чыннан да ялгышмаганбыз, — диде ул.

Желтков нәзек, тыңгысыз бармаклары белән, ашыгакабалана, кыска чабулы көрәнсу пинжәгенең каптырмаларын капшарга тотынды. Төймәләрен бер ычкындырып, бер

каптырып, күпмедер вакыт шулай аптырап торганнан соң, ул, ниһаять, авызын ачты һәм авырлык белән:

— Түргә узыгыз, утырыгыз, — диде дә килешсез генә итеп башын иеп куйды. Хәзер инде аны аермачык күрергә була иде: хатын-кызларныкы шикелле нәфис аксыл йөз, зәңгәр күзләр, сабый балаларныкыча бераз чокырланып һәм үҗәтлек сизелеп торган түгәрәк ияк; үзе ул карап торышка бер утыз-утыз биш яшьләр чамасында иде.

Желтковка зур игътибар белән, җентекләп карап торган Шеин итагатьле генә итеп:

— Рәхмәт сезгә, — дип җавап бирде, ә Николай Николаевич бераз һавалы төстә:

— Mercі, — дип куйды.

Алар икесе дә аяк өсте калдылар.

— Без сезгә бары берничә минутка гына дип килдек, — диде Николай Николаевич, сүзен башлап. — Бу әфәнде — губерна дворяннары предводителе князь Василий Львович Шеин. Минем фамилиям — Мирза-Булат-Тугановский. Вазифам буенча — прокурор ярдәмчесе. Без хәзер сезнең белән сөйләшергә теләгән мәсьәлә бер үк дәрәҗәдә князьгә дә, миңа да кагыла; дөресрәге, князь белән аның хатынына, ягъни минем туган сеңелемә кагыла.

Тәмам каушап калган Желтков кинәт диванга чүкте һәм күм-күк булып күгәренгән иреннәрен көчкә кыймылдатып: «Әфәнделәр, зинһар, утырыгыз», — диде. Ләкин әле бая гына шул ук тәкъдимне ясаган бүлуын һәм аның нәтиҗәсез калуын хәтеренә төшереп, ахрысы, урынныннан сикереп торды да, куллары белән башын тотып, тәрәзә янына йөгереп барды, аннары янә әүвәлге урынына — диванга килеп утырды. Қалтыранган бармаклары исә, баягыча, пинҗәгенең төймәләрен капшарга, аксыл-җирән мыек очларын бөтергәләргә, кирәккә-кирәксезгә чигә-яңакларын кармаларга тотындылар.

— Мин сезне тыңлыйм, ваше сиятельство, — диде ул саңгырау бер тавыш белән, ялварулы күз карашын Василий Львовичка төбәп.

Ләкин Шеин эндәшмәде. Сүзне Николай Николаевич дәвам итте.

— Иң элек сезгә әйберегезне кайтарып бирергә рөхсәт итегез, — диде ул һәм, кесәсеннән кызыл тартмачык чыгарып, аны ипләп кенә өстәлгә куйды. — Бу әйбер, әлбәттә, сезнең зәвыкның шактый югары дәрәҗәдә булуын күрсәтә, шулай да без сездән мондый сюрпризлар киләчәктә кабатланмасын иде дип үтенер идек.

— Гафу итегез... Мин аңлыйм, мин бик нык гаепле, — дип куйды Желтков әкрен генә һәм, бурлаттай кызарынып, башын түбән иде. — Бәлкем, берәр стакан чәй эчәрсез, әфәнделәр?

— Эш менә нәрсәдә, — диде Николай Николаевич, сүзен дәвам итеп, Желтковның сүзләрен бөтенләй ишетмәгәндәй. — Сезнең шулай ярты сүздән безне аңлый ала торган күркәм кеше булуыгыз, джентльмен булуыгыз мине бик шатландыра. Шулай булгач, димәк, без сезнең белән бик тиз аңлаша алырбыз дип уйлыйм. Ялгышмасам, сез менә җиде-сигез ел инде княгиня Вера Николаевнаны эзәрлеклисез, шулай бит?

— Әйе, — диде Желтков әкрен генә һәм нурлы, оялчан бер кыяфәттә керфекләрен түбән төшерде.

— Һәм без шушы көнгә кадәр сезгә каршы бернинди дә чара күрмәдек, гәрчә — сез үзегез дә килешерсез — без моны эшли алган булыр идек, хәтта, мин әйтер идем, без моны эшләргә тиеш идек. Дөрестер бит?

— Әйе.

— Әйе. Ләкин соңгы эшегез белән, ягъни менә шушы беләзекне җибәрүегез белән сез бөтенләй әдәплелек чикләрен үтеп чыктыгыз. Безнең сабырыбыз шартлады. Аңлыйсызмы? — сабырыбыз шартлады. Сездән яшереп тормыйм, без башта власть вәкилләренә мөрәҗәгать итмәкче, алардан ярдәм сорамакчы булган идек, ләкин без моны эшләмәдек, һәм моны эшләмәвебезгә мин хәзер бик шатмын, чөнки — кабатлап әйтәм — мин сезнең яхшы күңелле кеше булуыгызны шундук сизеп алдым.

— Гафу итегез. Сез ничек дип әйттегез әле? — диде кинәт Желтков һәм көлемсерәп куйды. — Власть вәкилләренә мөрәҗәгать итмәкче булган идек дидегезме?.. Шулай дип әйттегез бугай, әйеме?

Ул кулларын кесәләренә тыкты да, диван почмагына җайлабрак утырып, портсигары белән шырпысын алды һәм тәмәке кабызды.

— Димәк, сез әйтәсез, власть вәкилләреннән ярдәм сорарга булган идек дисез?.. Утырганым өчен сез мине гафу итегез инде, князь, — дип куйды ул, Шеинга эндәшеп.

— Йәгез, шуннан нәрсә?

Князь, урындык алып, өстәл янына утырды. Бу сәер кешегә — Желтковка — ул күзен дә алмыйча, аптырау катыш комсыз, җитди бер кызыксыну белән карап тора иде.

— Беләсезме нәрсә, сөеклем, ул чара сездән беркая да

качмас, — диде Николай Николаевич, мәсхәрә белән. — Чит кешенең гаилә тормышына тыкшыну — ул...

— Гафу итегез, сүзегезне бүлим...

— Юк, гафу итегез, мин сезнең сүзегезне бүләм... — диде прокурор, тавышын күтәрә төшеп.

— Ярар, алайса, сөйләгез. Мин тыңлыйм. Ләкин минем князь Василий Львовичка әйтергә теләгән берничә сүзем бар.

Һәм, Тугановскийга бөтенләй игътибар итмәстән, ул князьга эндәште:

— Хәзер минем тормышның иң авыр бер моменты башланды. Һәм мин сезнең белән, князь, бернинди шартлы әдәп кагыйдәләренә буйсынмыйча, ачыктан-ачык сөйләшергә тиеш... Сез мине тыңларсызмы?

— Тыңлармын, — диде Шеин һәм, Тугановскийның ачулы кыяфәттә нәрсәдер каршы әйтергә җыенуын күреп, сабырсыз бер тавыш белән аңа: — Ах, Коля, зинһар, туктап тор, — диде, аннары яңадан Желтковка таба борылды. — Сөйләгез.

Желтков, суларга тын җитмәгән кешедәй авызын зур ачып, бераз вакыт сүз башлый алмый торды, аннары кинәт, тау астына вак таш тәгәрәткәндәй, сүз яңгыры коярга тотынды. Сөйләгәндә аның мәетнеке төсле аксыл иреннәре бөтенләй селкенми, һәм ул сүзләрне бары үзенең теш казналары белән генә әйтә шикелле иде.

— Сезнең хатыныгызны... яратам дигән сүзләрне сезнең алда әйтүе минем өчен бик авыр, князь. Шулай да җиде ел буена сузылган ихтирамлы, өметсез мәхәббәтем миңа моны әйтергә хокук бирәдер дип уйлыйм. Килешәм: башта мин чыннан да Вера Николаевнага — ул әле кыз булган чагында — әллә нинди ахмак хатлар яздым, хәтта аңардан җавап хаты алмаммы дип тә өмет иттем. Шулай ук мин соңгы гаебемне дә таныйм: әлеге беләзекне Вера Николаевнага җибәреп, мин тагын да зуррак ахмаклык эшләдем. Ләкин... менә мин хәзер сезнең күзләрегезгә тупатуры карап торам, һәм сез мине аңларсыз дип ышанам. Мин бернәрсәне яхшы беләм: Вера Николаевнаны яратудан мин беркайчан да туктамаячакмын... Сез ачыктан-ачык әйтегез, князь... әйтик, минем бу мәхәббәтем сезнең ачуны китерә, ди... Менә шул хисне минем күңелдән йолкып ташлар өчен сез нишләргә тиеш булыр идегез икән? Николай Николаевич әйткәнчә, мине бүтән шәһәргә сөргергәме? Ләкин мин анда да Вера Николаевнаны яратудан туктамаячакмын бит. Мине төрмәгә ябаргамы? Ләкин төрмәдә дә

мин аңа үземнең дөньяда барлыгымны хәбәр итү юлын табачакмын. Минем бердәнбер юлым кала — үләргә... Сез кушсагыз, мин аны теләсә нинди формада кабул итә алам.

— Эш турында сөйләшәсе урында без монда ниндидер мелодекламация куертып маташабыз, — диде Николай Николаевич, эшләпәсен киеп. — Мәсьәлә ачык: сезгә икенең берсен тәкъдим итәләр: яки сез Вера Николаевнаны эзәрлекләүдән туктыйсыз, яки, риза булмасагыз, без, үзебезнең дәрәҗәбездән файдаланып — танышлыклар ашамы, башка юллар белән — сезгә карата тиешле чара күрергә мәҗбүр булачакбыз.

Ләкин Желтков, гәрчә Николай Николаевичның сүзләрен ишетеп торса да, аңа таба борылып та карамады. Ул әүвәлгечә бары князь Василий Львовичка гына карап сөйләде.

— Сезне бер биш-ун минутка ялгызыгызны калдырырга мөмкин булмасмы? — дип сорады ул князьдән. — Сездән яшереп тормыйм: мин хәзер телефоннан княгиня Вера Николаевна белән сөйләшергә телим. Алдан ук сезне ышандырып куя алам: әйтергә яраганның барысын да мин сезгә әйтермен.

— Барыгыз, — диде Шеин.

Василий Львович белән Тугановский бүлмәдә икәүдән-икәү калгач, Николай Николаевич шундук князьгә ябырылды.

— Болай ярамый, — дип кычкырынды ул, күкрәге өстеннән ниндидер күренми торган нәрсәне идәнгә алып ташлагандай, кулы белән кискен бер хәрәкәт ясап. — Болай һич ярамый. Сөйләшүнең эшкә кагылган өлешен тулысынча үз өстемә алам дип мин сине кисәтеп куйган идем ләбаса. Ә син җебеп төштең, аңа үзенең хисләре турында сүз куертырга ирек бирдең. Мин инде бу эшне бер-ике сүз белән күптән очлап куйган булыр идем.

— Бераз гына сабыр ит, — диде князь Василий Львович, — хәзер барысы да ачыкланыр. Иң мөһиме шул — мин үз алдымда аның саф, ачык йөзен күрәм; мондый кешенең күрәләтә ялганларга яки алдашырга сәләте булмаска тиеш. Чыннан да, Коля, син үзең уйлап кара, кешене кемгәдер мәхәббәт тотканы өчен гаепләргә мөмкинмени? Мәхәббәт бит ул бик катлаулы хис, аны акылга буйсындырып булмый; хәзергә хәтле әле беркемнең дә ул хиснең нидән гыйбарәт икәнлеген әйтеп биргәне юк. — Бераз уйланып торганнан соң, князь өстәп куйды. — Кызга-

нам мин бу кешене. Кызганам гына да түгел, мин монда үземне бу кешенең күңелендә барган ниндидер гаҗәеп зур фаҗиганең бер шаһиты итеп тоям. Шуңа күрә мин монда уйный да, кылана да алмыйм.

— Декадентлык бу, — диде Николай Николаевич.

Бер ун минуттан соң Желтков кайтып керде. Аның зәңгәр күзләре, түгелергә өлгермәгән күз яшеннән мөлдерәп торгандай, елт-елт килә һәм бик тирән булып күренә иде. Аның үз-үзен тотышында да үзгәреш сизелә: ул хәзер югары җәмгыятькә хас әдәп кагыйдәләрен дә, кемнең кайда утырырга тиешлеген дә оныткан, үзен бөтенләй джентльменнарча тотмый башлаган иде. Князь Шеин үзенең тынгысыз-киеренке, сизгер күңеле белән моны шундук аңлап алды.

— Мин әзер, — диде Желтков, — иртәгә сез минем турыда бер сүз дә ишетмәссез. Мин сезнең өчен, гүя, үлгән кеше кебек булырмын. Тик минем бер шартым бар, — моны мин сезгә әйтәм, князь Василий Львович, — эш шунда: мин шактый зур күләмдә казна акчасын туздырдым, шуңа күрә хәзер миңа бу шәһәрдән ничек тә качу ягын карарга кирәк. Сез миңа соңгы мәртәбә Вера Николаевнага хат язып салырга рөхсәт итәрсезме?

— Юк. Беткән булгач, бөтенесе берьюлы бетсен. Бернинди хат язулар да булмасын, — дип кычкырып җибәрде Николай Николаевич.

Шеин исә:

— Языгыз, — диде.

— Алайса, шуның белән эш бетте, — диде Желтков, масаюлы горур бер елмаю белән. — Сез минем турыда бүтән беркайчан да бер сүз дә ишетмәссез һәм, әлбәттә, мине күрә дә алмассыз. Княгиня Вера Николаевна минем белән бөтенләй сөйләшергә теләмәде. Мин аңардан: ара-тирә сезне ерактан гына күрергә мөмкин булырмы һәм шуның өчен миңа бу шәһәрдә калырга ярыймы, дип сорадым. Ул моңа каршы: «Ах, бу тамашадан ничек туйганымны белсәгез иде. Зинһар, моны тизрәк бетерегез», — дип җавап бирде, һәм мин менә ул тамашаны бетерәм. Мин үз кулымнан килгәннең бөтенесен дә эшләгәнмендер дип уйлыйм?

Кичен, дачага кайткач, Василий Львович Верага үзенең Желтков белән очрашуын бөтен вагы-төягенәчә сөйләп бирде. Шулай төгәл сөйләп бирүне ул үзе өчен бер бурыч итеп санады шикелле.

Вера, беркадәр борчуга калса да, тыштан бернинди га-

җәпләнү дә, тәшвишләнү дә күрсәтмәде. Төнлә белән, яныма ире килеп яткач, ул йөзе белән стенага таба борылды да:

— Зинһар, калдыр... Күңелем сизенә: ул, һичшиксез, үз-үзен үтерәчәк, — диде.

XI

Княгиня Вера Николаевна бервакытта да газета укымый торган иде. Беренчедән, ул аның кулын пычрата, икенчедән, хәзерге заман газета теле аңа ничектер аңлашылмый иде.

Ләкин бүген ул, тәкъдире шулай кушкангамы, газетаны ачып карады һәм күзләре шундук түбәндәге хәбәргә төртелде:

«Серле үлем. Кичә кич, сәгать җиделәрдә, контроль палатасы хезмәткәре Г. С. Желтков үз-үзен атып үтергән. Тикшерү мәгълүматларына караганда, үлемнең төп сәбәбе казна акчасын туздыру белән бәйле булырга тиеш. Һәрхәлдә, мәрхүмнең атылыр алдыннан язып калдырган хаты шул турыда сөйли. Мәрхүмнең шул ук хатында әйтелгән һәм шаһитлар катнашында расланган шәхси телӛген искә алып, мәетне анатомия театрына тапшырмаска дигән карар кабул ителде».

Вера эченнән генә үзалдына уйлап куйды:

«Күңелем ничек сизенде икән моны? Нәкъ менә шундый фажига буласын ничек сизенде икән? Һәм бу үлемнең төп сәбәбе нәрсә — мәхәббәтме, әллә акылдан язумы?»

Вера көне буе җиләк-җимеш бакчасында һәм чәчәклектәге түтәлләр арасында йөрде. Күңелендә минут саен үсә, көчәя барган борчылу хисе аңа гүя бер урында утырып торырга ирек бирми иде. Аның бөтен уйлары, хисләре бер кеше тирәсендә — Вераның беркайчан да күргәне булмаган һәм инде, мөгаен, күрергә дә язмаган әлеге серле кеше, алар өчен бары көлке чыганагы гына булып хезмәт иткән шул Пе Пе Же тирәсендә әйләнде.

Шул ук вакытта аның күңеленә Аносовның:

«Кем белсен, бәлки, синең тормыш юлыңны, Вера, олы, чын, фидакарь мәхәббәт кисеп чыккан булгандыр», — дигән сүзләре дә искә төште.

Кичке сәгать алтыларда почта ташучы килде. Бу юлы Вера Николаевна Желтковның кулын шундук таныды һәм үзе дә көтмәгән назлы бер ихтирам белән хатны ачып укырга тотынды.

Желтков хатында болай дип язган иде:

«Ходаның минем күңелгә шундый зур бәхет — Сезгә карата мәхәббәт индерүенә мин үзем һич тә гаепле түгел, Вера Николаевна. Нишләтәсең, минем язмыш шулай булып чыкты: дөньяда бернәрсә дә — политика да, фәннәр дә, философия дә, кешеләрнең киләчәк бәхетләре турында кайгыртулар да берсе-бер мине кызыксындыра алмады, минем бөтен гомерем, яшәвем Сезгә генә багышланды. Мин хәзер үзем дә ачык сизәм: мин Сезнең тормышыгызга ниндидер бер җайсыз чөй булып барып кердем, ахрысы. Әгәр булдыра алсагыз, моның өчен мине гафу итегез. Бүген мин китәм, башка беркайчан да кире әйләнеп кайтмаска китәм, һәм моннан соң мине искә төшереп Сезне бернәрсә дә борчый алмас.

Сез дөньяда яшисез — менә шуның өчен генә дә мин Сезгә чиксез зур рәхмәт хисе саклыйм. Мин үземне катькат сынап карадым — минем Сезгә булган хисем ниндидер авыру, маньяк саташуы түгел, бу — чын мәхәббәт, алла тарафыннан нәрсә өчендер миңа бүләк итеп бирелгән олы мәхәббәт.

Сезнең карашыгызда, шулай ук абыегыз Николай Николаевичның карашында мин, мөгаен, сәер, мәзәк бер кеше булып күренәмдер. Әйдә, шулай булсын! Ләкин юлга чыкканда, мин бөтен күңелем-җаным белән сокланып: *«Исемең синең мәңге изге булсын!»* — димен.

Мин Сезне беренче тапкыр моннан сигез ел элек циркта ложада күрдем, һәм шул чакта, Сезне беренче күргән мизгелдә үк, мин үземә үзем: мин аны яратам, дидем, чөнки дөнья йөзен бизәгән барлык нәрсәләр арасында — җанварлар, үсемлекләр арасында, йолдызлар, кешеләр арасында — аңа охшаган, гүзәллеге, нәфислеге белән аңа тиң булган бер генә нәрсә дә юк, дидем.

Сез үзегез уйлап карагыз: шуннан соң миңа нишләргә иде соң? Сезне күрмәс өчен башка шәһәргә качып китәргә идеме? Ләкин бит минем күңелем барыбер Сезнең янда, Сезнең аяклар астында калыр иде; минем яшәешнең һәрбер мизгеле бары тик Сезнең турыдагы уй, Сезнең турыдагы хыял... татлы саташу белән тулы.

Сезгә бүләк иткән теге ахмак беләзегем өчен мин бик үкенәм һәм аны уйлаган саен үзалдыма оялып кызарынам. Нишлисең бит, минем тарафтан эшләнгән зур ялгышлык булды ул. Сезнең кунакларга аның нинди мәзәк тәэсир ясаганын мин күз алдыма китерәм, билгеле.

Бер биш-ун минуттан миңа юлга чыгарга кирәк; шу-

ңарчы мин бары шушы хатыма марка ябыштырып, аны үз кулым белән почта ящигына илтеп салырга гына өлгерәчәкмен. Сез бу хатны, зинһар, утка ягыгыз. Мин үзем дә менә хәзер мичкә ягып, анда үземнең иң кадерле нәрсәләремне яндырып утырам. Алар арасында сезнең кулъяулыгыгыз бар; дөресен әйтим, урланган кулъяулык иде ул. Аны сез Благородный собраниедә урындыкта онытып калдырган идегез. Шулай ук мин Сезнең запискагызны — хат язуымны тыеп миңа язган запискагызны да яндырам. О, белсәгез иде, күпме тапкыр мин ул записканы үбә-үбә еладым икән! Бервакытны Сез сәнгать күргәзмәсендә күргәзмә программасын кулыгызда тотып йөреп, чыгып киткәндә аны ишек төбендәге урындык өстендә онытып калдырган идегез. Хәзер мин аны да утка ягам... Менә бөтенесе дә бетте кебек. Мин хәзер барысына да чик куйдым, ләкин шулай да Сез мине кайчан да булса бер искә алырсыз әле дигән уй, хәтта ныклы бер ышаныч минем күңелемдә кала. Әгәр мине искә төшерсәгез, ул чакта... мин Сезне беләм бит — Сез музыканы бик ярата торган кеше, бигрәк тә Бетховен квартетларында бик еш күрә идем мин Сезне,— ул чакта менә шул: әгәр Сез мине исегезгә төшерсәгез, соната D-dur № 2, ор. 2 не уйнагыз яисә башка берәрсеннән уйнаттырыгыз.

Мин бу хатымны ничек тәмамларга да белмим. Минем тормышымда бердәнбер куанычым, бердәнбер юанычым, бердәнбер уем-фикерем булган өчен мин Сезгә чын күңелемнән зур рәхмәтемне белдерәм. Аллаһе тәгалә Сезгә бәхет бирсен, һәм дөньяның бернинди фани нәрсәләре дә, бернинди тормыш ваклыклары да Сезнең гүзәл җаныгызны борчып рәнҗетмәсен. Кулыгызны үбәм.

Г. С. Ж.»

Елап күзләре кызарган һәм иреннәре кабарган княгиня Вера ире янына бүлмәгә керде һәм аңа Желтковның хатын күрсәтте.

— Мин күңелемдә булган бернәрсәне дә синнән яшереп калырга теләмим,— диде ул.— Ләкин минем күңелем сизә: безнең тормышка ниндидер коточкыч бернәрсә килеп керде. Сез Николай Николаевич белән анда нәрсәнедер артырып җибәргәнсездер кебек тоела.

Князь Шеин хатны зур игътибар белән укып чыкты да шактый вакыт дәшмичә торганнан соң, ниһаять:

— Мин бу кешенең ихлас күңелле кеше булуына һич тә шикләнмим; алай гына да түгел, мин аның сиңа булган

хисләре турында фикер йөртергә дә кыенсынам,— диде.

— Ул үлгәнме? — диде Вера.

— Әйе, үлгән. Минем тагын шуны әйтәсем килә: ул бернинди дә акылдан язган кеше булмаган, Вера, ул бары сине яраткан. Аның өендә чагында, мин аңа күземне алмый карап тордым, аның һәрбер хәрәкәтен, йөзендәге һәрбер үзгәрешне күрдем. Аның өчен синнән башка тормыш булмаган — мин менә шуны аңладым. Мин хәтта үземне кешенең үлем алды газабыдай чиксез зур газап кичергән чагына туры килгән ирексез бер тамашачы итеп тойдым. Шул чакта ук инде ул миңа ярым мәет кебек күренде. Аңлыйсыңмы, Вера, мин анда үземне ничек тотарга икәнлеген дә, нишләргә тиешлегемне дә белмәдем...

— Менә нәрсә, Васенька,— диде кинәт Вера Николаевна, иренең сүзен бүлеп,— әгәр мин шәһәргә аны күреп кайтырга барсам, синең күңелең рәнҗемәсме?

— Юк, юк, Вера, ник рәнҗесен, бар, күреп кайт. Мин үзем дә барыр идем дә, тик менә Николай гына бөтен эшне бозып ташлады. Хәзер мин анда барсам, үземне бик уңайсыз хис итәрмен дип куркам.

XII

Вера Николаевна Лютераннар урамына барып җитәргә ике чат кала ук экипажыннан төште. Желтков торган квартирны ул артык мәшәкатьләнмичә генә эзләп тапты. Ишек төбендә аны борынына көмеш кысалы күзлек атландырган соры күзле, юан, симез гәүдәле бер карчык каршы алды һәм, кичәгечә үк, Верадан:

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады.

— Желтков әфәнде,— диде княгиня.

Аның беркадәр боеручан тавыш белән әйткән бу сүзләре һәм эшләпә, перчаткалар кигән тышкы кыяфәте хуҗа карчыкка тәэсир итми калмады, билгеле: шундук аның теле чишелде.

— Рәхим итегез, пани, рәхим итегез, менә сулда беренче ишек... ә анда... хәзер... Бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда якты дөнья йөзен ташлады да китте бит, бичаракай. Ярый, растрата ясаган, ди. Соң, миңа әйткән булса ни булыр иде? Безнең ише йорт тотучыга буйдак фатирчылардан әллә ни акча тәтеми анысы, үзегез беләсездер, әмма инде ниндидер алты йөз-җиде йөз тәңкәне генә тапмый калмас идек. Ох, пани, белсәгез иде, шундый киң күңелле, асыл кеше иде бит ул! Сигез ел буе ул миндә фатирда

торды, һәм шул вакыт эчендә мин инде аны фатирчыдан бигрәк үз туган улым итеп күрә башлаган идем.

Шунда ук, ишек төбе бүлмәсендә, урындык тора иде. Вера урындыкка утырды.

— Мин сезнең мәрхүм фатирчыгызның дусты булам,— диде ул, сүзләрне бик нык сайлап-чамалап әйтергә тырышып.— Аның үләр алдыннан эшләгән эшләре, әйткән сүзләре турында ни дә булса сөйләгез әле.

— Пани, үләр алдыннан аның янына ике әфәнде килеп бик озак сөйләшеп утырдылар. Соңыннан ул әйтте миңа, алар аңа экономиядә управляющий урынын тәкъдим иткән булганнар икән. Алар монда чакта пан Ежий телефоннан сөйләшергә барып килде. Аннан ул бик шат чырай белән кайтты. Аннары әлеге ике әфәнде чыгып киттеләр, ә пан Ежий утырды да хат яза башлады. Хатны язып бетергәч, аны почта ящигына салып килде. Аннары без кинәт кенә шарт иткән бер тавыш ишеттек, балалар пистолетыннан аткан тавыш кебек кенә. Без аңа игътибар итеп тә тормадык. Кичке җидедә пан Ежий гел чәй эчә торган иде. Лукерья,— безнең асрау кыз ягъни,— аның ишеге төбенә барган да шакый башлаган, ә ул җавап бирми икән. Бу тагын шакыган, аннары тагын, тагын... Шул, ахырда ишекне ватып керергә туры килде. Керсәк, ул инде үлгән иде.

— Беләзек хакында берәр нәрсә сөйләгез әле,— диде Вера Николаевна, боерып.

— Ах, ах, ах, беләзек — кара син, каһәр, онытып та җибәргәнмен. Сез каян беләсез аны? Шул, хат язар алдыннан бу минем янга керә дә сорый: «Сез католичкамы?» — ди. Мин әйтәм: «Католичка»,— дим. Шуннан ул әйтә: «Сездә, ди, бер бик сөйкемле гадәт бар, ди, — ул нәкъ шулай, сөйкемле гадәт, дип әйтте, пани,— шул, сездә бик сөйкемле бер гадәт бар, ди: сез, ди, Мәрьям ана сурәтенә сәйләп, мәржән, муенса ише нәрсәләр, аннан бүләкләр тагарга яратасыз, ди. Менә минем үтенечемне дә үтәгез әле, бу беләзекне иконагызга элеп куя алмассызмы?» — ди. Мин, эләрмен дип, аңа сүз биреп калдым.

— Сез миңа мәетне күрсәтә алмассызмы? — дип сорады Вера.

— Рәхим итегез, рәхим итегез, пани. Менә сул якта беренче ишек аныкы. Аны бүген анатомия театрына алып китмәкче булганнар иде дә, бертуган абыйсы бар икән, шул ялвара-ялвара сорагач, христианнар йоласы белән күмәргә рөхсәт биргәннәр тагын. Рәхим итегез, рәхим итегез, пани.

Вера бөтен сабырлыгын җыеп ишекне ачты. Ладан исе аңкып торган тын бүлмәдә өч балавыз шәм яндырылган иде. Бүлмә уртасына кыйгачлап куелган өстәл өстендә Желтков ята. Мәет өчен барыбер инде дигәндәй, аның башы астына кечкенә, юка бер мендәр генә кыстырып куйганнар, шуңа күрә башы аның шактый түбән ята иде. Аның күзләре йомык, шулай булса да күз кабакларында ниндидер кырыс бер җитдилек катып калган; иреннәре исә ваемсыз, рәхәт бер елмаю белән елмаялар, әйтерсең лә, дөньяны ташлап китәр алдыннан ул үзенең бөтен тормыш серләрен ахырынача белгән дә, ниндидер татлы, тирән бер уйдан хәзер мәңгелек йокыга талган иде. Вераның хәтеренә төште: кайчандыр ул, дөньяның бөек газап чигүчеләре — Пушкин белән Наполеонның үлгәннән соң алынган битлекләрен караганда, алар йөзендә дә шундый ук тыныч-сабыр бер чырай күргән иде.

— Әгәр рөхсәт итсәгез, мин чыгып торыр идем,— диде хуҗа хатын, ниндидер үзенә бертөрле яшерен сердәшлек, дуслык сизелгән мөлаем тавыш белән.

— Барыгыз, бар, соңыннан мин сезне чакырырмын,— диде Вера һәм шундук кофточкасының ян кесәсеннән зур гына бер роза чәчкәсе тартып чыгарды һәм, сул кулы белән мәетнең башын чак кына югары күтәреп, уң кулы белән аның муены астына шул чәчкәне кыстырып куйды. Шушы кыска гына бер мизгел эчендә Вера бөтен күңеле белән һәрбер хатын-кызның хыял күгендә балкып тора торган олы мәхәббәтнең үз яныннан читләтеп узып китүен аңлап алды. Шул вакыт ул генерал Аносовның мәңгелек мәхәббәт турында күрәзәләрчә әйткән сүзләрен искә төшерде. Һәм, мәетнең маңгаена төшеп торган чәчләрен як-якка сыпырып, ике кулы белән дә чигәләреннән кысып тотты да, аның дымлы, салкын маңгаена иреннәрен тидереп, озак итеп дусларча үбеп алды.

Вера китәргә җыенгач, хуҗа хатын янә сүз башлап җибәрде.

— Пани, сез монда башкалар кебек тиктомалдан гына килмәгәнсез, ахры, миңа шулай күренә,— диде ул, үзенең полякларга хас ялагай-ягымлы тавышы белән. — Мәрхүм пан Желтков үләр алдыннан миңа тагын да бер сүз әйтеп калдырган иде. «Әгәр алай-болай үлә-нитә калсам, диде ул, мине кәрәрга, бәлкем, бер ханым килер, диде. Менә шул ханымга әйтегез, диде, Бетховенның, диде, иң яхшы әсәре...» Ничек диде соң әле? Хәер, ул миңа монда язып та куйды бугай. Менә карагыз...

— Кая, күрсәтегез әле,— диде Вера Николаевна һәм кинәт үксеп елап җибәрде.— Сез мине гафу итегез, мәет күрү минем күңелемне йомшартты, үз-үземне тыя алмый башладым.

Һәм ул хуҗа хатын биргән кәгазь кисәгендә таныш кул белән язылган сүзләрне укыды:

L. van Beethoven. Son. № 2, op. 2. Largo Appassionato.

XIII

Вера Николаевна өенә кичен бик соң гына кайтып керде һәм иренең дә, абыйсының да өйдә булмавын күреп, бик шатланды.

Аның каравы, өйдә аны пианистка Женни Рейтер көтеп утыра иде. Бүген күргән-ишеткәннәрдән күңеле тәмам тынычсызланган Вера шундук аның янына ташланды һәм, пианистканың зур, матур кулларыннан үбә-үбә:

— Женни, сөеклем, минем өчен зинһар ни дә булса уйна әле,— диде, аннары, бакчага чыгып, чәчәклектәге утыргычка утырды.

Женниның Бехтовенның икенче сонатасыннан нәкъ менә мәрхүм Желтков сораган урынын уйнаячагына Вера бу минутта ни өчендер аз гына да шикләнмәде.

Дөрестән дә, Женниның беренче аккордлары яңгырап китү белән үк, Вера гадәттән тыш тирән эчтәлекле, гажәеп гүзәл ул әсәрне шундук танып алды. Веранын күңеле ничектер икегә аерылгандай булды. Бер үк вакытта ул үзенең яныннан шулай сизелмичә генә узып киткән һәм мең елга бер мәртәбә генә кабатлана торган илаһи мәхәббәт турында уйлады. Аның хәтер күгендә яңадан генерал Аносовның сөйләгәннәре калкып чыкты, һәм ул үзенә үзе сорау бирепː ничек соң әле ул кеше, үзем телә-мәгән бер чакта, мине Бетховенның нәкъ менә шул икенче сонатасын тыңларга мәҗбүр итте икән? — диде. Һәм, ирексездән, аның күңелендә, музыка уйнавына кушылып, сүзләр тезмәсе туа башлады. Алар, җыр куплетлары сыман, тезелеп-тезелеп киләләр дә ахырда: *«Исемең синең мәңге изге булсын»,*— дигән сүзләр белән тәмамланалар иде.

«Хәзер мин сезгә нәфис авазлар агылышында үзен шатлык һәм күндәмлек белән газапка, авыр кичерешләргә һәм үлемгә дучар иткән гомерне тасвирлап күрсәтәм. Мин бернинди зарлану-сукрану да, шелтә дә, мин-минлек газа-

бы да белмәдем. Мин синең каршында — бердәнбер дога: *«Исемең синең мәңге изге булсын».*

«Әйе, мин үз алдымда газап, кан һәм үлем торганын ачық күрәм. Җан тәнне ташлап киткәндә бик авыр булачагын да уйлыйм, ләкин мин сиңа, гүзәлем, ашкынып дан җырлыйм, сабыр мәхәббәтем белән дәртләнеп дан җырлыйм. *«Исемең синең мәңге изге булсын».*

«Мин синең һәрбер адымыңны, елмаюыңны, күз карашыңны, аяк тавышыңны искә төшерәм. Минем соңгы хатирәләрем татлы сагыш — талгын, гүзәл сагыш белән өретелгән. Ләкин мин сине кайгы-хәсрәткә салмам. Мин бер үзем китәм, аллаһе тәгаләнең әмеренә һәм үз язмышыма буйсынып — бер ялгызым китәм. *«Исемең синең мәңге изге булсын».*

«Сагышлы үлем алды сәгатендә мин бары сиңа гына гыйбадәт кылам. Тормыш минем өчен дә гүзәл була алыр иде. Рәнҗемә, бичара күңелем, рәнҗемә. Җаным белән мин үлемне чакырам, ләкин шашкын күңелем сиңа дан җырлый: *«Исемең синең мәңге изге булсын».*

«Син үзең һәм синең тирәдәге башка кешеләр — сез барыгыз да синең нинди гүзәл булганлыгыңны белмисез. Сәгать суга. Вакыт җитте. Һәм үлгәндә, гомерем белән хәсрәтле саубуллашу сәгатендә, мин барыбер җырлыйм — дан сиңа».

«Әнә ул килә, бар нәрсәне тынычландыручы, татуландыручы үлем килә, ә мин барыбер жырлыйм — дан сиңа!..»

Княгиня Вера, сәрви агачына сөялеп һәм аның кәүсәсен куллары белән кочаклаган килеш, үксеп-үксеп елый иде. Агач үзе дә елагандай дерелдәп-дерелдәп куя иде. Әллә каян килеп чыккан талгын жил дә, Вераның сагышын уртаклашкандай, яфракларны шыштырдатып узды. Тәмәке чәчәкләренең исе тагы да көчәя төште... Һәм шул гомуми сагыш-хәсрәткә буйсынып, гажәеп музыка үзенең моңын дәвам итте:

«Тынычлан, кадерлем, тынычлан, тынычлан. Син мине хәтереңдә тотасыңмы? Хәтереңдә тотасыңмы? Син бит минем бердәнбер һәм соңгы мәхәббәтем. Уйла син минем турыда, шул чакта мин гел синең яныңда булырмын, чөнки без бер-беребезне бары бер генә мизгел яраткан булсак та, безнең мәхәббәтебез мәңге дәвам итәр. Син мине хәтереңдә тотасыңмы? Хәтереңдә тотасыңмы? Менә мин синең кайнар күз яшеңне тоям. Тынычлан. Минем йокым шундый татлы, шундый татлы, татлы».

Женни Рейтер уйнап бетереп бүлмәдән чыкты һәм чәчәклектәге утыргычта күз яшенә манчылып елап утырган княгиня Вераны күрде.

— Сиңа ни булды? — дип сорады ул, борчылып.

Вера, яшьле күзләрен елтыратып, тынгысыз бер ашкыну белән Женниның әле битеннән, әле иреннәреннән, әле күзләреннән үбәргә тотынды. Үзе берөзлексез:

— Юк, юк, ул мине хәзер гафу итте. Барысы да әйбәт,— дип пышылдады.

1911

А. И. КУПРИН

(Биографик белешмә)

Александр Иванович Куприн үткән гасырның ахырында һәм XX гасырның башында әдәбият мәйданына килгән зур төркем рус язучыларының иң күренеклеләреннән берсе булып санала. Билгеле булганча, XIX йөз рус әдәбияты Л. Н. Толстой, И. С. Тургенев, Ф. М. Достоевский, А. П. Чехов кебек бөтен дөньяга танылган бөек сүз осталарын бирде. А. И. Куприн XX гасыр башындагы рус әдәбиятында әнә шул бөек художникларның данлыклы иҗат эшчәнлеген дәвам иттерүчеләрдән булды һәм алар тудырган әдәби-эстетик принциплар — критик реализм принциплары нигезендә тирән эчтәлекле, югары сәнгать дәрәҗәсендә эшләнгән кыйммәтле әсәрләр язып калдырды. Аның повесть, хикәяләре, романнары хәзерге көндә дә җуелмас бер кызыксыну, иң таләпчән әдәби зәвыкны да канәгатьләндерерлек эстетик ләззәт белән укылалар һәм замандашыбызда, аеруча яшь буында, гуманистик карашлар тәрбияләүдә гаять зур уңай роль уйныйлар.

А. И. Куприн 1870 елның 8 сентябрендә элекке Пенза губернасы Наровчат дигән шәһәрчектә урта хәлле бер чиновник гаиләсендә туган. Үзе бик яшьли әтисез кала. 1874 елда аларның гаиләсе Мәскәүгә күчеп килә. Куприн башта ятимнәр училищесында тәрбияләнә, аннары Кадетский корпуста хәрби белем ала. Кадетский корпусны тәмамлаганнан соң, аны Подольск губернасындагы Проскуров дигән кечкенә бер шәһәрчеккә хезмәт итәргә җибәрәләр. Ләкин хөр фикерле, бунтарь йөрәкле яшь офицерны хәрби тормыш канәгатьләндерми, һәм өч ел хезмәт иткәннән соң Куприн отставкага чыга, үзе әйтмешли, «ирекле кеше» булуга ирешә.

Кесәсендә нибары өч тиен акчасы булган хәлдә, ул Киевка килә. Шул көннән алып булачак язучының тамак ялы өчен эш эзләп, бер урыннан икенче урынга күченеп йөргән авыр еллары башлана. Нинди генә эшләрдә эшләргә туры килми аңа! Ул газета репортеры да, грузчик та, имение управляющие да була, чиркәү хорында җырчы, провинция театрларында актер булып та хезмәт итә, хәтта металлургия заводында һәм балыкчылар әртиендә дә эшли. Бу эш алыштырулар эзсез үтми, әлбәттә: аның дөньяга карашын, белемен киңәйтергә ярдәм итә. Ул җентекләп тормышны, кешеләрне өйрәнә, киләчәктә язылачак әсәрләре өчен гаять бай тормыш материалы туплый. Гомумән, Куприн тормыштагы бөтен нәрсәне үз җилкәсендә татып белергә, барысын да үз күзе белән күрергә омтыла. Аның бу гадәте, күңел омтылышы соңыннан да сүрелми, гомере буе аңа юлдаш булып бара. Шул сәбәпле Купринның күпчелек әсәрләре реаль тормыш вакыйгаларына, үзе күргән, үзе белгән реаль кешеләр язмышына нигезләнеп язылганнар да инде.

1889 елдан А. И. Куприн үзенең кыска хикәяләре, фельетоннары белән матбугатта күренә башлый. Әлбәттә, аның беренче хикәяләре сәнгатьчә эшләнү ягыннан әле зәгыйфь булалар, әмма ул хикәяләрдә үк инде әдипнең язучылык таланты, идея-эстетик карашлары һәм стилендәге лирикага тартым үзенчәлек ачык сизелә.

Купринны әдәбият дөньясында язучы итеп таныткан беренче зур әсәре — «Молох» повесте (1896). Бу әсәрендә язучы рус әдәбиятында иң беренчеләрдән буларак капитализм китергән социаль үзгәрешләрне сурәтләргә омтыла һәм ул заманның сыйнфый каршылыкларын истә калырдай тормышчан вакыйгалар, образлар аша күрсәтеп бирә. Әсәрнең баш герое инженер Бобровның язмышы, шәхси драмасы фонында язучы капитализм шартларында кеше хезмәтенең асыл мәгънәсе югалуын, бу хезмәтнең тормышта шатлык чыганагы булудан ялыктыргыч бер авыр йөккә әверелүен расларга тели. Бобров, өстен сыйнфка якын бер кеше булса да, Квашнин ише канечкеч капиталистларны җанытәне белән дошман күрә, ә аларны баету өчен көне-төне бил бөгүче завод эшчеләренә карата теләктәшлек хисе саклый. Әмма ул капитализм тудырган социаль гаделсезлектән котылу юлын белми әле, шул сәбәпле аның протесты коры сөйләнүдән ары китә алмый. Монда, әлбәттә, автордагы идея позицияләренең чикләнгән булуы, XIX йөз ахырларында Россиядә башланган эшчеләр хәрәкәтенең асылын аңлый алмавы ачык чагыла. Шулай булуга да карамастан, «Молох» повесте капитализмның черек якларын фаш итүче реалистик бер әсәр буларак рус әдәбияты тарихында үзенчәлекле урын алып тора.

Шушы ук чорда Куприн, уңай герой проблемасы белән мавыгып, «Олеся» исемле атаклы повестен иҗат итә. 1898 елда басылып чыккан бу повесть үзенең композицион төзелеше ягыннан булсын, теле, сурәтләү чаралары, геройларны тасвирлаудагы эзлеклелек һәм психологик тирәнлек ягыннан булсын, Куприн иҗатында гына түгел, гомумән бөтен рус әдәбиятында иң лирик, иң эмоциональ әсәрләрдән берсе булып саналырга хаклы. Язучы монда, гаять зур осталык белән, цивилизацияле җәмгыятьтән бөтенләй читтә, табигать арасында тәрбияләнгән олы җанлы, саф күңелле гади бер кызның — Олесяның — самими образын, аның фидакарь мәхәббәтен һәм аянычлы язмышын гәүдәләндерә. Олеся үзенең бөтен эчке һәм тышкы матурлыгы, табигый акылы, ихтыяр көче һәм горур холкы белән укучыны тетрәндерә, аны үзенә гашыйк итә. Әсәрдәге башка геройлар да — Полесье сихерчесе Мануйлиха карчык, лирик герой Иван Тимофеевич, урман каравылчысы Ярмола һәм эпизодик образлар да шундый ук психологик тирәнлектә, тормышчан һәм дулкынландыргыч итеп бирелгәннәр.

1905 елда «Атышу» («Поединок») басылып чыкканнан соң, Купринның язучылык даны тагын да арта төшә. «Знание» нәшрияты аның әсәрләр җыелмасын чыгара башлый. Әдип үзе дә иҗат эшчәнлеген киңәйтеп җибәрә — күп санлы хикәяләр, повестьлар яза. Алар арасында аның «Гамбринус» (1907), «Тост» (1906), «Изумруд» (1907), «Суламифь» (1908), «Гранат кашлы беләзек» кебек соклангыч хикәяләре бар.

Куприн бу чорда балалар өчен дә күп хикәяләр иҗат итә. Аның «Ак пудель», «Фил», «Җир карынында», «Тылсымлы доктор», «Елга буенда», «Балалар бакчасы», «Ю-ю» кебек хикәяләре хәзергә кадәр балалар иң яратып укый торган китаплардан санала. Балалар өчен иҗат ителгән хикәяләрендә язучы яшь буынны кыю, гадел булырга, җәмгыятьтәге эшәкелеккә, ялганга каршы көрәшергә өнди; кешеләргә карата миһербанлылык, табигатькә һәм туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияли.

1914 елда язучыны армия сафына чакыралар. Ләкин озакламый Куприн сәламәтлеге буенча хәрби хезмәткә яраксыз табыла, һәм ул яңадан иҗат эшен дәвам иттерергә мөмкинлек ала. Сугыш елларында Куприн күбрәк Петербургта яисә Гатчинода яши; берничә тапкыр Кырымда, Кавказда була, чит илгә барып кайта.

Октябрь революциясен А. И. Куприн теләктәшлек белән каршылый, әмма аның асыл мәгънәсен ахырынача аңлый алмый. Шушы аңлашылмау нәтиҗәсендә ул 1920 елда ватанын ташлап чит илгә — эмиграциягә китә.

Эмиграциядәге унҗиде ел гомерен Куприн Парижда яшәп уздыра. Бу чорда ул әдәби иҗат эшеннән бөтенләй диярлек читләшә; ул үзенең туган илдән качып китеп гаять зур ялгышлык эшләгәнен аңлый, аңарда Россияне сагыну хисе елдан-ел көчәя бара. Нихаять, 1937 елда Куприн гаиләсе белән яңадан туган илгә әйләнеп кайта. Яңа тормыш шартлары аңарда иҗат ялкынын кабат кабызып җибәрә, ул социалистик тормышны чагылдырган әсәрләр язу турында хыяллана. Ләкин бу хыялларын ул эшкә ашырырга өлгерә алмый: 1938 елда кинәттән үлеп китә.

Совет халкы А. И. Куприннын әдәби мирасын кадерләп саклый. Аның китаплары миллионлы тиражлар белән чыгалар.

Татар телендә А. Куприн әсәрләре аерым китап булып беренче мәртәбә 1950 елда басылды («Ак пудель», хикәя, тәрҗемәчесе И. Туктаров). 1970 һәм 1976 елларда Р. Даутов тәрҗемәсендә авторның «Повесть һәм хикәяләр», «Атышу» исемле тагын күләмле ике җыентыгы дөнья күрде. Әлеге җыентыкка соңгы ике басмадан дүрт повесть сайлап алынды.

Р. Даутов

ЭЧТӘЛЕК

Молох 3
Олеся 87
Атышу 172
Гранат кашлы беләзек 434
А. И. Куприн (биографик белешмә) . . 493

Куприн Александр Иванович

ПОВЕСТИ

(на татарском языке)

Редакторы *Ш. Жиһангирова*
Тышлык художнигы *И. Воробьев*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Л. Тилк*
Корректорлары *М. Мирсалихова, Х. Фәйзрахманова*

ИБ № 4950

Җыярга таныпрылды 7.08.87. Басарга кул куелды 8.01.88. Форматы 84×108¹/₃₂. Китап журнал кәгазе. „Литературная" гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 26,0. Шартлы буяу-оттиск 26,3. Нәшер-хисап табагы 29,0. Тиражы 15000 экз. Заказ Р-409. Бәясе 2 сум 50 т.

Татарстан китап нәшрияты.
420084, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420084, Казань, ул. Баумана, 19.
Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.

2 с. 50 т.

АЛЕКСАНДР КУПРИН